# НУРИХАН ФАТТАХ

## ИЗБРАННЫЕ ПРОИЗВЕДЕНИЯ

В ПЯТИ ТОМАХ

5

ТОМ

КАЗАНЬ
ТАТАРСКОЕ КНИЖНОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО
2002

# НУРИХАН ФӘТТАХ

## САЙЛАНМА ӘСӘРЛӘР

БИШ ТОМДА

5

ТОМ

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2002

УДК 820/89(470)
ББК 84(2Рос=Тат)-4
Ф96

***Редколлегия:***

*З.Р.Вәлиева, Р.М.Миңнуллин, Ф.Г.Галимуллин,*
*Т.А.Миңнуллин, Д.С.Шакиров, Х.Г.Әюпов, Р.Х.Корбанов*

**Фәттах Нурихан**

Ф96 Сайланма әсәрләр. — 5 томда, 5 том. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. — 400 б.

ISBN 5-298-01203-5 © Татарстан китап нәшрияты, 2002



## Милләт аңардан күпне көтә

Нурихан Фәттах таныштыруга мохтаҗ язучы түгел, минемчә. Күп җирләрдә аны беләләр, ул инде безнең әдәбиятта бармак белән генә санарлык популяр язучылар рәтенә керә. Һәм бик хаклы рәвештә. Димәк, һәртөрле мактауга да лаек. Мәгәр мактаудан элек язучыны аңлау кирәк. Ә Нуриханны аңлау җиңел түгел. Ул бит гаять үзенчәлекле һәм үзсүзле (яхшы мәгънәсендә) әдип. Бигрәк тә дөньяны тану һәм фикерләүдә. Бу сыйфаты аның беренче әсәрләрендә үк күренгән иде. (Мәсәлән, «Сезнеңчә ничек?» романында һәм сугыш вакытында татар хатынының фаҗигасен чагылдырган бик көчле «Артта калган юллар» хикәясендә.)

Нурихан үзенең иҗатын беркайчан да конъюнктура таләпләренә буйсындырмады. Хәлбуки бит ул торгынлык чорында үскән, җитешкән язучы. Ә бу чор әдәбиятында ярау һәм яраклашу тенденциясе бик көчле иде. Билгеле, намуслы чын язучы мондый хәл белән килешә алмый — аңа иҗат итәр өчен барсыннан да элек фикри хөрлек кирәк. Ихтимал, аның «заман темасыннан» ерак тарихка күчүе дә үзе теләгәнчә язасы килүе белән бәйләнгәндер дә. Ләкин бу күчү аңа җиңел генә бирелмәгәндер, билгеле. Монда инде әдиплек таланты өстенә бик төпле фәнни тикшеренү дә кирәк була торгандыр. Һәм Нурихан бу эштә дә үзенең нинди зур сәләткә ия булуын ачык күрсәтте. Нәтиҗәдә без татар әдәбиятында моңарчы һич күренмәгән ерак бабаларыбызның (әгәр шулай әйтергә яраса) бик борынгы яшәешләре турында ике зур әсәр — «Итил суы ака торур» белән «Сызгыра торган уклар» романын алдык. Бу әсәрләр, миңа калса, бик озын гомерле булачак, укучыларның гына түгел, әдәбиятчылар һәм тарихчыларның да игътибарын үзенә гел тартып торачак. Хәтта әле яңа тарихчыларның тууына да сәбәпче булулары бик мөмкин.

Нурихан Фәттах һичшиксез көчле, талантлы шәхес. Шуңадыр ахрысы, аңа карата мактау сүзләрен чәчү дә ничектер артык кебек, ә менә аның иҗади эшчәнлегенә сокланмыйча мөмкин түгел. Аңардагы ныклык, бәйсезлек һәм эш өчен генә яши белү, мәсәлән, минем үземдә юк диярлек. (Халык әйткәнчә, җилгә җиленләп, бозга бозаулап йөрү аркасында күпме кадерле вакытыбызны заяга уздырдык без.) Нурихан исә эшли һәм үзенчә яши белү җәһәтеннән күпләребезгә үрнәк була алыр иде. Ләкин аңа охшарга тырышу кирәк микән? Чын талантлар берберсен кабатламаска тиешләр. Һәркемнең үз йөзе, үз юлы... Нурихан Фәттах та бит беркемгә дә охшамаган. Шуның белән кыйммәтле дә ул безнең өчен... Тик без аңа ихлас күңелдән иҗади озын гомер телик. Милләт аңардан әле күпне көтә — борынгыча әйтсәк!

*Әмирхан Еники*

# ШӘҖӘРӘ

*(Тарихи-лингвистик эзләнүләр)*

## Икенче басмага кереш сүз

«Шәҗәрә»нең икенче басмасын матбугатка тәкъдим итәр алдыннан мин аны яңадан карап чыктым. Моннан егерме еллар чамасы элек язылган, унике ел элек нәшер ителгән беренче басмада бүгенге көн күзлегеннән карaганда, күп кенә хаталар, төгәлсезлекләр, җитешсезлекләр киткән. Баштарак мин һәрбер хатаны, кимчелекне сызгалап, төзәткәләп бардым, ләкин ахырда мондый эштән баш тартырга туры килде. Мин «Шәҗәрә» беренче басма хәлендә дә яшәргә хаклы дигән фикергә килдем. Бу бигрәк тә «Фест дисбесе»нең татарча укылышы белән дәлилләнә.

Билгеле булганча, «Фест дисбесенең сере» дип аталган һәм 1986 елда «Казан утлары»нда басылган мәкаләдә мин тел гыйлемендәге чагыштырма-тарихи методны танымавымны белдердем һәм аның урынына үз методымны тәкъдим иттем. Бу юкка-барга күсәк күтәрү генә түгел, бу зур һәм җаваплы гамәл иде, бу нык утыра дип уйланылган иләмсез багананы төртеп аудару белән бер иде.

Җимерү, төртеп аудару яңаны төзүгә караганда җиңелрәк, әлбәттә. Яңа метод игълан итсәм дә мин «Шәҗәрә»не язганда иске методтан, иске карашлардан арынып җитмәгән булганмын. Югарыда әйткән хаталар-кимчелекләр, нигездә, менә шуңа кайтып кала. Бу хакта сүз озайту монда урынсыз булыр иде. Тел белән чынлап торып кызыксынган укучы тәкъдим ителгән иҗек методы турында да, башкасы турында да урысча «Язык богов и фараонов» китабында һәм аның дәвамы булачак икенче китапта да күп кенә яңалыклар табар дип уйлыйм.

*Нурихан Фәттах.*
*2002 ел, апрель.*

# БАШЛАУ

Дөньяда туктаусыз көрәш бара. Көчлеләр көчсезләрне җиңәргә, көчсезләр җиңелмәскә тырыша. Адәм балалары арасындагы дошманлыкның сәбәпләре күп төрле булырга мөмкин. Шуларның иң әүвәлгесе һәм иң таралганы — тел. «Сөйдергән дә тел, көйдергән дә тел» ди мәкаль. «Аңлаешсыз» телдә сөйләшкән халыклар, ыру-кабиләләр дөнья яратылган заманнарда ук инде «аңлаешлы» телдә сөйләшүчеләр өчен дошман булып тоелган. Дошманга карата мөнәсәбәт тә дошманнарча. Әгәр дошман бирелмәсә, аны юк итәләр, дигән бер язучы. Моннан фәлән миллион еллар элек Җир шарына хаким булып калган һомо сапиенсның* тарихы өзлексез сугышлардан, кан коюлардан гыйбарәт. «Иң дөрес» телдә сөйләшүче, акыллы һәм көчле һомо сапиенес «бозык телдә» сөйләшүче туганын, күршесен һәрвакыт тукмарга тырышкан. Җиңә икән, үзен үтергән, балаларын үтергән, хатынын, таш балтасын, күсәген бик зур байлык сыйфатында үз куышына алып кайтып киткән. Күп тә үтмәгән, «иң дөрес» телдә сөйләшүчеләрдән дә дөресрәк телдә сөйләшүчеләр, көчлеләрдән дә көчлерәкләр барлыкка килгән. Болары да ярсып күршеләренә яу чапканнар, үтергәннәр, талаганнар, әсир иткәннәр.

Заманалар үтү белән гореф-гадәтләр, йолалар да үзгәргән. Тора-бара җиңүчеләр акыллырак булырга өйрәнгәннәр. Әсирләрне үтермәгәннәр — кол итеп авыр эшләрдә файдаланганнар; җиңелгән күршеләренең җирен дә ташлап китмәгәннәр — үзләренеке дип игълан иткәннәр һәм мәңге шунда торып калганнар. Җиңелгән халыкны исә тырышып-тырышып культуралаштырырга тотынганнар. «Культуралаштыру» дигәне шул булган — көчләп, мәҗбүр итеп, алдап-юлдап күршеләрен «иң дөрес» телгә өйрәткәннәр һәм шул рәвешчә артта калган варварларны бер-бер артлы йотып — үз көчләрен арттыру белән шөгыльләнгәннәр.

Безнең үз җиребездә дә шулай ук патша хөкүмәте гасырлар буена урыс булмаган халыкларны урыслаштыру, көчләп чукындыру политикасын алга сөрде. Урыс патшаларының дини һәм милли изүеннән аеруча безнең халык

* Аңлы кеше (*латинча*).

җәфа чикте. Кайчандыр үзенең дәүләте, дине һәм югары культурасы булган татар халкы, исән-имин калу өчен, урыс колонизаторлары белән өзлексез көрәш алып барды.

Октябрь безгә ирек бирде. Без сөендек, без тантана иттек. Шулай да без иртәрәк сөенгәнбез икән. Ирекне без үзебезчә аңлаганбыз, ирек бирүчеләр үзләренчә аңлаган. Ирек безгә кешечә яшәү өчен кирәк булса, иске империянең яңа патшаларына ул безне ашлама сыйфатында куллану өчен генә кирәк булган икән. Хәзер инде яшерер нәрсә калмады кебек — барысы да ап-ачык, уч төбендәгедәй.

Җитмеш ел буена «милли ирек», «милли тигезлек» кебек сүзләр тукып, икейөзле хөкемдарлар безнең җанны, рухны мыскыл иттеләр. Мең ел буена ышанычлы юлдашыбыз булган язуыбызны үзләренчә әвеш-түеш китерделәр дә, гасырлар буена күз карасыдай саклап тоткан китапларыбызны олау-олау чүплекләргә чыгарып түктерделәр, череттеләр, яндырдылар. Аң-белемле, ихтыярлы кешеләребезне йөзәрләп, меңәрләп, ун меңәрләп сөргеннәргә, төрмәләргә озаттылар. Язу белән, китап белән бергә динебезнең тамырына балта чаптылар. Алар карашынча, безнең дин, безнең намус, безнең вөҗдан кемгәдер, нәрсәгәдер киртә булып тора икән. Диннең билен сугып сындыргач исә турыдан-туры телгә тотындылар. Алар карашынча, безнең тел дөньяда иң артта калган, иң бозык тел икән. Анысы да оҗмахка кергәндә безгә, имеш, киртә булып тора икән. Оҗмахка исә урысча сөйләшкән кешеләрне генә кертәләр икән.

Шулай. Мәктәпләр ябылды, газета-журналлар ябылды, китап бастыру туңу ноктасына кадәр киметелде. «Социалистик Татарстан» газетасында биш-алты яшьлек бала белән гаиләдә үк русча гына сөйләшүнең файдасы, рус-татар яшьләреннән оешкан гаиләләрнең прогрессивлыгы, милли хиснең, милли психологиянең зарары турында әледән-әле «фәнни» мәкаләләр басыла торды. «Казан утлары» журналы милли телләрне, ягъни рус теленнән башка вак-төякләрне сакларга тырышуның үзмаксат түгеллеген яклап чыкты. Авыл мәктәбендә татар балаларын урыслаштыруда зур җиңүләргә ирешкән бер татар укытучысына Социалистик хезмәт герое исеме бирелде. Рәсми мәкаләләрдә, радиода, сәхнәдә «татар» сүзе бөтенләй диярлек кулланылмый башлады. «Милләт» сызып

ташланды. Авыллардагы, шәһәрләрдәге барлы-юклы татар язулары урыс язулары белән алыштырылды. Күзгә төртелеп торган иң биек урыннарда әкәмәт зур хәрефләр белән язылган «Наша цель — коммунизм!» дигән сүзләр кычкырып торды. Урамда, кеше арасында, транспортта татарча сөйләшү — хәтта пышылдап сөйләшү!— үзеннән-үзе җинаять саналды.

Шулай итеп, чыннан да бетәрбез микәнни? Ник, ни өчен?! Нишләп минем телем гасырлар буена сөйләшү өчен яраклы булган да, нишләп хәзер генә — урамнарда сасы ис таратып тимер машиналар чабыша торган фәхеш заманда гына яраксызга әйләнгән? Татарча сөйләшеп, татарча китап язып кемнең өлешенә кердек икән соң без? Кемнең кытыгына тидек икән дә, кемнең авырткан җиренә кагылдык икән? Ни өчен әле иген басуында бары кукуруз гына, урманда бары каен гына үсәргә тиеш икән? Ни өчен тирә-якта бары карга гына каркылдарга, чыпчык кына чыркылдарга тиеш тә, ни өчен абзарда дуңгыз, ишегалдында алабай гына булырга тиеш икән? Әгәр тиздән минем телем бетә икән, озакламый тамырым корый икән, бу дөньяда ник яшәргә дә, нигә яратырга, балалар тудырырга, чәчәкләр үстерергә? Нигә җырлар, китаплар язарга?

Икенең берсе — йә тере килеш туфракка әйләнергә, йә көрәшергә. Ничек итеп? Үлем белән күпләр инде көрәшеп караганнар, тик әлегә беркемнең дә исән калганы юк шикелле.

Менә шундый шартларда каләменнән башка бернинди коралы булмаган ялгыз кеше нишли ала? Кул кушырып утырса, әлбәттә, берни эшли алмый. Мин көрәшергә булдым.

Барыннан да элек минем үз телемне, тарихымны беләсем, аңлыйсым килде. Кем булганбыз без, нинди булганбыз? Каян башланган, ничек яралган безнең телебез?

Элегрәк тел, тарих турында язылган һәр нәрсәне мин бернинди икеләнүсез сабыйларча йотып, үзләштереп килдем. Көрәш инстинкты баш калкыткач, күп нәрсәгә миндә шик туды. Төрки телгә, төрки тарихка кагылышлы рәсми сүзләрнең күбесе миңа ялгыш һәм ялган булып тоелды. Мин эзләндем, төпчендем һәм ничек тә мәсьәләнең асылына төшәргә тырыштым. Шуның бер нәтиҗәсе буларак, җитмешенче еллар уртасында «Ерак

гасырлар авазы» дигән мәкалә барлыкка килде. Сөйләм телендә кулланыла торган кайбер сүзләргә нигезләнеп мин ерак тарихны күз алдына китермәкче булдым. Мәкалә гамәлдәге методка һәм гамәлдәге карашларга нигезләнеп язылган. Ләкин иске методка нигезләнеп яңа сүз әйтеп булмый. «Ерак гасырлар авазын» хәзер өйрәнчек әйбер дип карарга кирәк.

Эзләнә торгач, мин телне, тарихны аңлауда үз юлымны, үз методымны таптым. Бу методның дөреслеген исбат итү өчен, төрки тел, төрки тарих белән генә чикләнмичә, үзем дә сизмәстән, бөтен дөньяга таралырга туры килде. Ун елга якын тырышлыктан соң роман дип тә, хикәя дип тә атап булмый торган зур күләмле бер хезмәт барлыкка килде. «Тел тарихы» дип аталган шушы кулъязмамны күтәреп көннәрдән бер көнне Татарстан китап нәшриятына киттем. Нәшриятның ул чактагы директоры — сабакташым Гарәф Шәрәфетдинов мин китергән кулъязманы укып чыкты, ләкин үз фикерен әйтергә ашыкмады. Бераздан әйтте, тагын бер кат укыйм әле, диде. Икенче кат укып чыккач, ниһаять, әйтте: коточкыч! коточкыч! диде. Бу көннәрдә мин исерек кебек йөрим, диде. Аның бу эчкерсез сүзләрендә яклау да, котлау да, таң калу да — барысы да бар иде. Нәшрият директорының соңгы сүзе шул булды — кулъязманы бастыра алмыйм, диде. Фәнни темага язылган әсәрләрне бары тик галимнәр, институтлар фатихасы белән генә чыгарып була икән. «Тел тарихы»н Главлитның (цензураның) ул вакыттагы директоры Даимә ханым Шакирҗанова да укыды. Ул да шул ук сүзләрне кабатлады.

Без Гарәф кордаш белән киңәштек тә, үзебезнең берәр атаклыга сүз кушып карарга булдык. Кулъязманы күтәрдем дә, киттем үзебезнең телчеләребез янына. Атаклы галимебез укыды һәм, тел гыйлемендә марксизмны танымый, дигәндәйрәк сүзләр язып, юк-бар хаталар табып, кире рецензия бирде. Соңыннан үзебезнекеләрнең башкаларына да сүз кушып карадым — алардан да ягымлы җавап булмады.

1983 елның март аенда, яклау эзләп, киттем Мәскәүгә. Якласа безне Мәскәү генә яклаячак. Барлык изгелек, барлык гаделлек башкаладан тарала. Мәскәүнең танылган тюркологларыннан бер-ике кеше янында булдым. Сөйләдем, аңлаттым, Коръәннән дә калынрак кулъязмам-

ны күрсәттем. Күрделәр, аңладылар, ләкин ярдәм кулы сузарга ашыкмадылар. Телне өйрәнүдә яңа метод тәкъдим итәм дигәч, берсе, әлбәттә, иске метод тарафдары, коты алынып: «Без нишләрбез?!» — диде. Шулай да ул танышырга дип кульъязманы алып калды һәм бер-ике көннән кире кайтарып биргәндә: «Мин биш йөз тел белмим»,— диде. Икенче галим сөйләшеп тә тормады — өченчесенә җибәрде. «Казан утлары»ның 1986 елгы май санында «Тел тарихыннан өзек — «Фест дисбесенең сере» басылды. Үзен татарның бердән-бер галиме дип хаталана торган берәү, кульъязманы да, хәтта журналда чыккан мәкаләне дә укып тормастан, «Фест дисбесенең сере»н фантастика дип атады.

Бүген инде мин кемне дә булса гаепләргә җыенмыйм. Бит боларның барысы да теге заманда булды. Узган эшкә — салават. Минем бары бозлавык чорындагы атмосфераны гына тасвирлап күрсәтәсем килде. Ләкин боз әле дә эреп җитмәгән. Күңелләрдәге, фикер сөрешендәге, үзара мөнәсәбәтләрдәге туңлык, тарлык, көнчеллек әле булса үз көчендә кала бирә. Шулай да инде боз эри. Эриячәк, Алла бирсә! «Шәҗәрә»нең дөнья күрүе — шуның бер билгесе.

Аяк чалучыларны, күрмәмешкә-белмәмешкә салынучыларны телгә алып та, иң авыр чакта ярдәм кулы сузган кешеләрне онытып калдырсам, бик зур гаделсезлек булыр иде. Журналда «Фест дисбесенең сере»н бастыру өчен дә галимнәрдән фатиха сүзе таләп ителде. Бу юлы мин Казан университетына мөрәҗәгать иттем. Университетның татар теле кафедрасы җитәкчесе профессор Диләрә ханым Тумашева журнал өчен әзерләнгән мәкаләне кафедраның гыйльми утырышында тикшерергә ризалык белдерде. 1985 елның 15 январенда кафедраның киңәйтелгән утырышы булды. Утырышта университеттан һәм башка фәнни оешмалардан 20 дән артык галим катнашты. Шуларның барысы да дип әйтерлек мине тулысынча яклап чыктылар

Укучыга тәкъдим ителә торган «Шәҗәрә» китабын 1982 елда тәмамланган, ләкин «Фест дисбесенең сере» дигән өзегеннән башка беркайда басылмаган «Тел тарихы»ның кыскача варианты дип тә, шул нигездә язылган яңа хезмәт дип тә атарга була. «Шәҗәрә» киң катлау укучыларын күз алдында тотып язылды. Шуны истә то-

тып, төп хезмәттәге бик күп материал — башлыча чит халыкларның теленә, этнографиясенә, мифологиясенә, фольклорына кагылышлы фактлар төшереп калдырылды. Укуны җиңеләйтү максатыннан чыгып, фәнни аппарат шактый кыскартылды. Шул ук вакытта төрки телгә, тарихка кагылышлы өр-яңа фактлар өстәлде. Аеруча әһәмиятле дип уйланылган фикерләрнең, фактларның чыганаклары күрсәтелде һәм китап ахырында файдаланылган хезмәтләр исемлеге бирелде.

Кайбер укучыга «Шәҗәрә» (бигрәк тә аның баштагы бүлеге) авыр һәм катлаулы булып тоелырга мөмкин. Бит без тел һәм тарих турында барысын да чәйнәп биргән садә һәм стандарт мәкалә һәм мәкаләчекләр генә укырга күнеккәнбез. Безнең тарих та, гадәттә, унҗиденче елдан башлана. Казан ханлыгы, Болгар чорлары исә рөхсәт ителгән тарихның иң ерактагы киртәсе булып тора. Аннан соң һәр яңа сүз — хәтта үз телебез, тарихыбыз турындагы яңа сүз дә, һичшиксез, Америкадан, Германиядән яисә Франциядән килергә тиеш дип уйланыла.

«Шәҗәрә»дә тел һәм тарих турында яңача фикерләү тәкъдим ителә. Яңача фикерләүне үзләштерү өчен яңача аңларга омтылыш та кирәк. Монысы инде тулысынча укучы ихтыярында.

## Беренче бүлек

# ТЕЛ ТӨБЕНДӘ НИ ЯТА

### 1. ТЕЛ ТЕОРИЯЛӘРЕ ТУРЫНДА КЫСКАЧА БЕЛЕШМӘ

Адәм баласы тел белән бик борынгы заманнарда ук кызыксына башлаган дип уйларга кирәк. Ләкин аның кызыксынуы шактый берьяклы булган. Борынгы кешене башлыча кемнең теле яхшырак та, кемнең теле начаррак дигән сорау кызыксындырган. Хәер, телләргә карата мондый карашның әле дә бетеп җиткәне юк. Билгеле булганча, һәркемгә үз теле якын, үз теле яхшы булып тоела. Элегрәк исә моның шулай икәнлеге үзеннән-үзе аңлашылып тора сыман тоелгандыр кебек. Борынгы цивилизация халыкларының барысы да, гадәттә, үзләрен генә дөньяның кендеге дип, башкаларны түбән дәрәҗәдәгеләр дип исәпләгәннәр. Шунлыктан башкаларның телләре дә сөйләшү-аңлашу өчен яраксыз дип уйланылган. Мәсәлән, борынгы Мисырда, борынгы Кытайда шундый карашлар булган.

Борынгы греклар күп нәрсәгә мисырлылардан өйрәнгәннәр, шул ук вакытта грек философларының, язучыларының күбесенә мисырлылар теле — варвар теле, грек теле — иң яхшы һәм иң дөрес тел булып тоелган.

Борынгы яһүд динчеләре иң әүвәлге тел яһүд теле булган дип исәпләгәннәр. Алар карашынча, атабыз Адәмне яһүд теленә Алла үзе өйрәткән һәм шуңа күрә Библия дә, имеш, иң беренче телдә — Алла телендә иҗат ителгән.

Б. э. к. VII гасырда яшәгән Мисыр патшасы Псамметих I кайсы халыкның теле борынгырак булуы мәсьәләсен үзенчә хәл иткән. Бер көтүчегә ул яңа туган ике баланы тәрбиягә биргән. Псамметих көтүчеләргә балалар алдында бер сүз дә сөйләшмәскә боерган. Балаларны аерым өйдә тотканнар. Көтүче көн дә кәҗә көткән, билгеле бер вакытта көтүен әлеге өй янына куып китергән дә балаларга сөт биргән, ашаткан-эчерткән, тегесен-монысын караган. Шул рәвешчә ике ел вакыт үтеп киткән. Көннәрдән бер көнне көтүче өйгә килеп керсә, балаларның икесе дә аның аягына егылганнар һәм кулларын сузып, «бекос» дигәннәр. Бу алар авызыннан чыккан беренче сүз булган, имеш. «Бекос»ның кем сүзе икәнлеген тикшереп карасалар, моның фригия сүзе икәнлеге ачыкланган. Кече Азиядәге фригия телендә «бекос» икмәк дигәнне аңлата икән. Шушы хәлдән соң мисырлылар фригияләрне беренче, үзләрен — икенче халык дип исәпли

башлаганнар, имеш. Бу хакта б. э. к. V гасырда яшәгән «тарих атасы» Геродот язып калдырган.

Әлеге вакыйга чын булган булса, моны телне өйрәнүдә иң беренче фәнни тәҗрибә дип атарга булыр иде. Шулай да, тел гыйлеменең беренче яралгылары Мисырда түгел, борынгы Грециядә барлыкка килгән. Телнең яралуы, телнең төзелеше, сүзләрнең әүвәлге мәгънәләре һәм башкалар турында иң беренче фикерләрне борынгы греклар әйтеп калдырганнар. Әйтелгәнчә, грек философлары грек телен генә игътибарга лаек дип исәпләгәннәр һәм аларның тел турындагы фикерләре дә грек теленнән ары узмаган.

Греклар мисырлылардан өйрәнгән кебек, латиннар да күп нәрсәгә греклардан өйрәнгәннәр. Аларга грек телен, грек фәлсәфәсен дә үзләштерергә туры килгән. Рим империясе көчәю белән, латин теленә игътибар арта төшкән һәм римлылар өчен латин теле иң әүвәлге, иң дөрес һәм изге тел санала башлаган. Рим империясе таркалгач та, латин теленең әһәмияте кимемәгән. Христиан дине белән бергә латин теле Көнбатыш Европа илләрендә хакимлек итә башлаган. Бу илләрдә латин теле дин һәм фән теле буларак кабул ителгән. Өйрәнү, китап язу, гыйбадәт кылу өчен латин теленнән башка барлык телләр яраксыз дип уйланылган. Җанлы телләрне, әйтик, немец, француз, инглиз телләрен өйрәнгән очракта да, аларның язу, сөйләү кагыйдәләрен латин теле кагыйдәләренә яраклаштырырга тырышканнар.

Телнең барлыкка килүе мәсьәләсендә грек-латин философлары һәм аларны дәвам иттерүчеләр, нигездә, ике төрле карашны алга сөргәннәр. Берәүләр тел Алла тарафыннан бирелгән дип, икенче берәүләр кеше тарафыннан уйлап табылган дип фикер йөрткәннәр. Б. э. к. IV гасырда яшәгән Платон, мәсәлән, тел Алла тарафыннан бирелгән дип исәпләгән. XVIII гасыр немец философлары И. Гердер һәм Д. Тидеман да шундый ук карашта торганнар. Атаклы француз язучысы һәм философы Ж.-Ж. Руссо тел иҗтимагый килешү нәтиҗәсендә барлыкка килгән дип фараз кылган. Аныңча, бик борынгы кешеләр бергә җыелганнар да, телнең кирәклеген аңлап, кемне, нәрсәне ничек атарга һәм ни рәвешлерәк сөйләшергә кирәклеге турында үзара килешү төзегәннәр, имеш.

Б.э.к. V гасырда яшәгән борынгы кытай философы Конфуций исемнәр акыллы патша тарафыннан иҗат ителгән дигән карашта торган. Монысы инде — тел закон тарафыннан барлыкка китерелгән дигәнгә туры килә.

1785—1863 елларда яшәгән немец галиме Я.Грим телне дөньядагы иң беренче ирле-хатынлы кешеләр һәм алар-

ның балалары уйлап тапкан дип исәпләгән. 1767—1835 елларда яшәгән атаклы немец философы, телчесе В.Гумбольдт милләтнең рухы — аның телендә, тел ул рух эшчәнлеге дип фикер йөрткән. Телнең яралгылары кешедә туганда ук була һәм аның (телнең) ничек барлыкка килүен акыл белән аңлату мөмкин түгел дип исәпләгән В.Гумбольдт.

Иң беренче тел нинди булган соң? Күп галимнәр бу сорауга да җавап бирергә тырышып караганнар. Борынгы грек философлары (стоиклар) беренче авазлар әйберләргә охшатылган дип фараз кылганнар. Табигатьтә тупас һәм каты әйберләр бар. Алар чыгарган тавышлар да тупас һәм каты. Йомшаграк әйберләрнең тавышы да йомшак һәм ягымлы. Менә мондый хәл телдә дә чагыла, имеш. 1646—1716 елларда яшәгән немец философы Лейбниц та шундыйрак фикер әйткән. Лейбниц иң беренче тел табигатьтәге тавышларга охшату нигезендә барлыкка килгән дип исәпләгән.

Иң беренче тел ымлыклардан-ишарәләрдән торган дигән караш та булган. Мондый фикерне немец галиме Тидеман әйткән. Аныңча, кешеләр әйберләрне башта күреп кенә белгәннәр. Әйбернең нинди булуына карап, иң беренче «сүзләр» дә барлыкка килгән, имеш. Ләкин бу «сүзләрне» кешеләр ишарәләп-ымлап кына аңлата алганнар. Соңга таба кайбер динчеләр ишарәләр-ымлыклар белән сөйләшүгә караганда сүзләрне әйтеп сөйләшүнең уңайлырак икәнлеген аңлап алганнар. Шуннан соң инде авазлардан торган чын сүзләр барлыкка килгән, имеш.

В.Гумбольдт фикеренчә, телнең үсеше өч чорга бүленә. Беренче чор язу уйлап табылган заманнарга кадәр дәвам иткән. Бу чорда тел бары «тамыр» сүзләрдән генә торган. Мондый сүзләрнең бернинди кушымчалары булмаган. Тора-бара «тамыр» сүзләр бер-берсенә кушылып әйтелә башлаганнар һәм, вакыт узу белән, аларның әүвәлге мәгънәләре дә онытылган.

Без Гумбольдтның бүтән чорлар турында әйткән фикерләренә тукталып тормыйбыз. Безнеңчә, немец галименең беренче чор турындагы фикере игътибарга лаек. Аны хәтергә салып кую яхшы булачак. Бу уңайдан 1732—1806 елларда яшәгән икенче бер немец галиме И.Аделунгның фикерләре белән танышу да безнең өчен файдалы булырга мөмкин. И.Аделунг дөньядагы барлык телләрдә иң беренче сүзләр бер иҗекле генә булган, иҗекләр исә сузыклардан гына торган, дигән. Аделунг карашынча, барлык телләр бер үк нигездә барлыкка килгәннәр. «Гуроннарның һәм гренландиялеләрнең телләрен Платон һәм Вольтер телләре дәрәҗәсенә күтәрү өчен бар-

лык мөмкинлекләр бар», дигән Аделунг (Дон, 54 бит). Бу — кыю һәм дөрес фикер. Ләкин, тиешенчә исбат ителмәгәнлектән, Аделунгның фикере күпчелек галимнәр тарафыннан яклау тапмаган.

В.Гумбольдт һәм И. Аделунг сүзләренә охшаш сүзләрне бүтән галимнәр дә әйткәннәр. Екатерина II заманындагы рус галиме А.С.Шишков иң әүвәлге телләр бер иҗекле сүзләрдән торган, ул иҗекләр сузык авазлар булган, ди. Аныңча, иң элек, а, е, и, о, у авазлары, аннан соң ба, ма, на, та иҗекләре, соңга таба баба, мама, няня кебек сүзләр барлыкка килгән.

Билгеле булганча, кытай теле бер-ике иҗекле сүзләрдән генә тора. Шуңа күрә, иҗек теориясе турында сөйләгәндә, иң элек кытай теленә «төртеп» күрсәтәләр. Мәсәлән, бүгенге совет галиме О.А.Донских: «Шул рәвешчә, кытай теле материалына нигезләнгән һәм бер иҗекле тамыр сүзләрдән генә торган дигән баба тел теориясе турындагы гипотеза дөрес түгел»,— дигән сүзләр яза (Дон, 93 бит).

Шушы уңайдан б. э. к. IV гасырда яшәгән грек философы Аристотельнең иҗек турында әйткән сүзләрен дә искә төшерсәк, начар булмас кебек. Иҗек ул тартыктан һәм сузыктан торган һәм мөстәкыйль мәгънәсе булмаган аваз дигән Аристотель (Кондр, 13 бит).

Шулай итеп, бүгенге көндә генә түгел, моннан ике мең ике йөз еллар элек тә сүз ясауда (димәк, телләрнең барлыкка килүендә дә!) иҗекнең бернинди катнашы булмаган дигән карашлар яшәгән икән. Кызык бит, теләсә нинди телдә теләсә нинди сүз авазлардан һәм иҗекләрдән тора. Иҗек яисә иҗекләр төркеме «сүз» рәвешендә нинди дә булса мәгънә белдерә. Белдерергә тиеш. Мәгънәсе булмаса, аны «сүз» дип атарга да кирәкми. Шул ук вакытта, күп кенә галимнәр фикеренчә, мәгънәле «сүз» иҗекләренең бернинди мәгънәсе юк, имеш! Ышаныргамы, ышанмаскамы мондый нәрсәгә?

Хәер, ашыкмыйк әле. Һәр нәрсәнең үз вакыты бар. Хәзергә без тагын бер кызыклы фикер белән танышып китик. V гасырда яшәгән һәм Аристотель хезмәтләренә аңлатмалар язган Аммоний, ир затындагы сүзләр ирләр рухына, хатын-кыз затындагы сүзләр хатын-кыз рухына туры килә, дигән. Аныңча, ирләргә тәэсир итү һәм керү хас, хатын-кызга кабул итү хас. Мәсәлән, акыл — ир затыннан, җан — хатын-кыз затыннан. Ни өчен дигәндә, исемнәрне барлыкка китерүче илаһи көч алдан ук шуны күз алдында тоткан: акыл җанны яктырта, җан исә акылның нурын кабул итә. Шуңа күрә, Аммоний фикеренчә, Кояш — ир

затыннан, Ай, Җир — хатын-кыз затыннан. Елгалар — ир затыннан, күлләр, диңгезләр — хатын-кыз затыннан, чөнки елгалар күлләргә, диңгезләргә коя (Як, 28 бит).

## 2. ЧАГЫШТЫРМА-ТАРИХИ МЕТОД ТУРЫНДА БЕЛЕШМӘ

Телне өйрәнү күптән башланган булса да һәм бу эштә бик күп атаклы фикер ияләре тырышлык күрсәтсәләр дә, телнең барлыкка килүе, телнең-сүзнең төзелеше турындагы иң гади тоелган сорауларга да канәгатьләнерлек җавап табылмаган. Шул ук вакытта тел гыйлеме фән буларак үскәннән-үсә, катлауланганнан-катлаулана барган. Хәзер инде фикер ияләре үзләре яхшы белгән туган тел кысасында гына калмыйча, башка телләрне дә өйрәнә, тикшерә башлаганнар. Шул рәвешчә, җанлы сөйләм телләренә игътибар арта төшкән. Күп тел белүче галимнәр барлыкка килгән, сүзлекләр, грамматикалар төзү активлашып киткән.

Тел гыйлеме башлыча Көнбатыш Европа илләрендә тернәкләнгән. Ләкин бу әле башка халыклар тел белән бөтенләй кызыксынмаганнар дигән сүз түгел. Урта гасырларда, мәсәлән, гарәп-фарсы илләрендә дә телгә карата игътибар шактый көчле була. Монда да тел турында китаплар языла, сүзлекләр төзелә. Ләкин, грек-латин фикер ияләре кебек, гарәп һәм фарсы галимнәре дә нигездә үз телләрен өйрәнү һәм үз телләрен пропагандалау белән шөгыльләнәләр. Без аларның барысына да тукталып тора алмыйбыз. Монда бары Мәхмүт Кашгари турында гына бер-ике сүз әйтеп китәсе килә. XI гасырда Урта Азиядә яшәгән Мәхмүт Кашгари тумыштан төрки телле булган. Тел турындагы китабын ул гарәп телендә язган. Аның заманында ислам дөньясында гарәп теле фән теле булып исәпләнелгән. М. Кашгариның *«Диван лөгат әт-төрек»*, ягъни «Төрки телләр җыентыгы» дип аталган атаклы хезмәте 1073—1074 еллар тирәсендә төгәлләнгән. Китапка XI гасырда билгеле булган барлык төрки телләрнең киң кулланыштагы сүзләре, җыр, шигырь үрнәкләре, мәкаль-әйтемнәре һәм төрки халыклар турындагы тарихи, географик, этнографик мәгълүматлар тупланган.

М. Кашгари турындагы шушы кечкенә белешмәдән соң яңадан Көнбатыш Европа якларына әйләнеп карыйк. XVIII гасырда Бенгалиядә судья булып эшләүче инглиз галиме һәм юристы Вильям Джонс беренче мәртәбә санскрит теленә игътибар итә. В. Джонс санскрит һәм Европа телләре арасында күп кенә охшашлыклар таба һәм, шуңа нигезләнеп, Европа телләре белән һиндстан телләр-

ренең үзара туганлыгы турында фикер әйтә. В.Джонсның ачышы Европа галимнәренә бик нык тәэсир итә. Европа галимнәре борынгы санскрит телен һәм һиндстандагы җанлы сөйләм телләрен ныклап торып өйрәнә башлыйлар. 1808 елда немец галиме Ф. Шлегельнең «һиндләрнең теле һәм акылы турында» дигән китабы басылып чыга. Бу хезмәтендә Шлегель грек, латин, герман һәм фарсы телләренең санскрит теле белән бертуган булуын исбат итә һәм әлеге телләрне санскриттан аерылып чыккан дип исәпли. Беренче мәртәбә ул «чагыштырма грамматика» дигән термин куллана. Соңга таба галимнәр славян, роман, балтик телләрен дә санскрит белән чагыштырып өйрәнә башлыйлар. Яңадан-яңа охшашлыклар табыла, яңадан-яңа ачышлар ясала. Төрле телләрне чагыштырып өйрәнүдә немец галимнәре аеруча зур тырышлык күрсәтәләр.

Шул рәвешчә, тел гыйлеме фән дәрәҗәсенә күтәрелә һәм чагыштырма-тарихи метод тел гыйлеменең төп методына, төп юнәлешенә әверелә. Бу методны шулай ук компаративистика дип тә атыйлар.

Хәзер без кыскача гына булса да әлеге методның кайбер карашларына тукталып китәрбез.

Грамматик төзелешләренә һәм лексикасына карап, телләр туганлык яисә кардәшлек төркемнәренә бүленә. Дөньяда һинд-европа, семит, фин-угор, дравид, кытай-тибет, банту, кавказ һ.б. тел семьялары бар дип исәпләнелә. Боларны тел семьяларының иң зур кардәшлек төркемнәре дип атарга була. Зур төркемнәр үзләре кечерәк төркемнәргә, кечерәкләр тагын да кечерәкләргә бүленә.

Төрки телләр дә аерым кардәшлек семьясы тәшкил итәләр. Тел гыйлемендә урнашкан тәртип нигезендә, монгол һәм тунгус-манчжур телләре дә төрки телләр белән бертуган дип исәпләнелә. Шунлыктан әлеге телләрнең барысын бергә «алтай телләре» дип аталган тел семьясына кертеп карыйлар. Кайберәүләр фин-угор, корей, япон, палеоазия (бик борынгы Азия) һәм Кавказдагы кайбер телләр дә төрки телләргә тугандаш дип фараз кылалар. Шуңа күрә төрки телләр турында сөйләгәндә еш кына «төрки-монгол телләре», «алтай телләре» яисә «урал-алтай телләре» дигән терминнар кулланыла.

Бүгенге көндә шактый таркау хәлдә булган зур-зур тел семьяларының һәркайсы кайчандыр мөстәкыйль бер тел хасил иткән дип уйланыла. «Кайчандыр» дигән ниндидер билгесез заманнарда ниндидер территорияләрдә, әйтик, «һинд-европа» телендә сөйләшүче «һинд-европа» халкы яшәгән дип исәпләнелә. Менә шул «кайчандыр»

заманында гамәлдә булган дип уйланылган бик борынгы телне баба тел дип, нәсел башы теле дип атыйлар. Баба телдә сөйләшүчеләр, имеш, баба халык булганнар һәм алар, имеш, ниндидер баба ватанда яшәгәннәр. Мәсәлән, «һинд-европа» халкының баба-ватаны кайдадыр Кавказ якларындамы, Урта Азиядәме, Кече Азиядәме булган дигән фикерләр бар. Кайберәүләр Гималай таулары ягында булган дип тә уйлыйлар. Бу мәсьәләдә уртак фикер юк. Әле булса Европа галимнәре һәм аларның карашларын яклаучылар «һинд-европа» халыкларының баба ватанын эзләү белән шөгыльләнәләр. Бу мәсьәләдә яңадан-яңа «ачышлар» туып кына тора.

Шул ук вакытта башка тел семьяларының әүвәлге ватаннарының кайда булуы тулысынча хәл ителгән сыман тоела. Мәсәлән, «алтай» яисә «урал-алтай» телендә сөйләшүче халыкларның баба ватаны турында бәхәсләшеп тә тормыйлар. Алар, имеш, дөнья яратылганнан бирле хәзерге Монголия һәм Алтай якларында яшәгәннәр, ниндидер сәбәпләр аркасында төрле якка таралып һәм, культуралы халыкка әйләнү теләге белән, моннан фәлән гасырлар элек Көнбатышка таба агыла башлаганнар.

Шулай да баба телләр кайчанрак барлыкка килделәр икән соң? Мәсәлән, «һинд-европа» телләре моннан 8-10 мең еллар элек формалашкан дип уйланыла. Семит телләре дә, имеш, шул заманнарда яисә бераз соңлабрак барлыкка килгән булырга мөмкиннәр. Чагыштырма-тарихи метод тарафдарлары ышандырырга тырышканча, «алтай» телләре барлык тел семьяларыннан соңрак барлыкка килгәннәр. «Алтай» телләреннән бүленеп чыккан төрки телләр исә, кайберәүләр фикеренчә, тагын да соңрак формалашкан булырга тиешләр. Кайберәүләр төрки телләрне моннан өч мең, биш мең еллар элек туган дип фикер йөртәләр. Тюрколог С. Е. Малов төрки телләрне аерата яшь итеп күрсәтергә тырыша. Аныңча, төрки телләр безнең эрага кадәр биш йөз еллар элек барлыкка килгән булырга тиеш.

Мәгълүм булганча, үз баласының яшен ата-ана баланың туган көненнән башлап исәпли. Ул аның кайчан туганын язып куя яисә аны хәтерендә калдыра. Хәзерге вакытта һәр туган балага туу таныклыгы языла. Шуңа күрә, фәлән кешегә фәлән яшь тулды диләр икән, моңа беркем шик белдерми. Күп кенә тарихи вакыйгалар турында да ышанычлы истәлекләр саклана. 1941 елның 22 июнендә Германия безгә каршы сугыш башлады. Бу — мәгълүм факт. Моңа беркем каршы килми. Тарихи даталарны билгеләү өчен ышанычлы язма истәлекләр булмаганда галимнәр еш кына археологик табылдыкларга һәм

башка төрле чыганакларга таянып фикер йөртәләр. Борынгы каберлекләрдә, сарай калдыклары арасында елы язылган борынгы акчалар һ.б. нәрсәләр табылырга мөмкин. Моны иң гади метод дип әйтергә була. Дата билгеләүдә галимнәр яңадан-яңа методлар уйлап табалар. Мәсәлән, моннан бик күп еллар элек җир астында күмелеп калган агач, сөяк, үсемлек калдыкларын махсус лабораторияләрдә тикшереп, аларның чагыштырмача төгәл яшьләрен билгеләргә мөмкин.

Ләкин нинди дә булса телнең кайчан барлыкка килүен төгәл итеп (һич югы, чагыштырмача төгәл итеп) әйтеп буламы соң? Юк, булмый. Фәлән телнең фәлән елда, фәлән айда барлыкка килүе турында беркем безгә язу да калдырмаган, бу хакта берәр төрле матди дәлилләр дә табып булмый. Телнең-сүзнең калдыкларын җир астыннан казып та чыгара алмыйсың, аның яшен кеше, хайван сөякләре, агач, үсемлек калдыклары сыман, лабораторияләрдә тикшерә дә алмыйсың. Тел халык белән туа, халык белән бергә юкка да чыгарга мөмкин. Халык яшәсә тел дә яши, яши алмый икән, тел дә бозыла һәм онытылып бетә. Алай гына да түгел, сүз ул сөйләү мизгелендә туа һәм шундук җилгә дә оча.

Әйтәсе килгәнем шул: фәлән тел моннан фәлән мең еллар элек, төгән тел моннан төгән еллар элек барлыкка килгән дип язарга батырчылык иткән кеше ул йә ахмак, яисә... хәйләкәр политик.

Моннан биш-алты мең еллар элек борынгы Шумер илендә адәм баласы үз авызыннан чыккан сүзләрне каты әйберләргә күчерү ысулын уйлап тапкан. Бүген без моны язу, язу-сызу дип атыйбыз. Шул рәвешчә, кемнең нинди телдә сөйләшүен билгеләү өчен дөньяда беренче мәртәбә ышанычлы чара барлыкка килә. Әгәр без бары шушы чара нигезендә генә фикер йөртсәк, дөньяда иң беренче тел моннан биш-алты мең еллар элек барлыкка килгән дип әйтер идек. Ул беренче тел «һинд-европа» теле дә, «семит» та, «дравид» та яисә анда «кытай-тибет» тә булмас, бары шумер теле генә булыр иде.

Тик шулай да кайсы телнең кайчан барлыкка килүен мондый нигездә исбат итәргә тырышу да дөрес булмас иде. Шумер телендә язылган беренче язулар табылуы гына әле шумер телен, гомумән, дөньядагы иң беренче, иң әүвәлге тел дип игълан итү өчен ышанычлы дәлил була алмый. Чөнки, беренчедән, телгә кагылышлы барлык серләр әле ачылып бетмәгән. Күрәсең, баркайчан андый нәрсә булмас та. Бит көннәрдән бер көнне Җир шарының бөтенләй икенче бер төбәгендә көтелмәгән яңа төр язу үрнәкләре табы-

лырга һәм ул язу үрнәкләре шумер чөй язуыннан да борынгырак булып чыгарга мөмкин. Икенчедән, шумер чөй язуын шумерлар түгел, бәлки шумерларга кадәр яшәгән башка халыклар уйлап тапкан, шумерлар исә шуларның ачышын гына файдаланган булырга мөмкиннәр. Галимнәр арасында шулайрак фикер йөртүчеләр дә бар.

Кыскасы, компаративистларның төрле телләрне төрле заманда барлыкка килгән дигән фикерләрен фәнни яктан исбатланылган дип әйтеп булмый.

### 3. ТЕЛЛӘРНЕҢ ҮЗАРА МӨНӘСӘБӘТЕ ТУРЫНДА

Чагыштырма-тарихи метод тарафдарлары фараз кылганча, баба халыклар төрле чорда төрле сәбәпләр аркасында тарала башлаганнар. Баба халыктан кечерәк төркемнәр бүленеп чыккан. Бүленеп чыккан төркемнәрнең яшәү урыннары әүвәлге үзәктән һәм бер-берсеннән ерагайган саен һәм шулай ук бүленеп чыгудан соң бик күп вакытлар үтү сәбәпле, әлеге төркемнәрнең телләре дә бер-берсеннән аерымлана барган. Шул рәвешчә, яңа төркемнәр белән бергә, яңа, мөстәкыйль телләр барлыкка килгән. Менә шушы яңа, мөстәкыйль телләрдә, бик борынгы заманнарның истәлеге булып, баба тел заманында бергәләп яшәгән чакларның уртак сүзләре, уртак грамматик формалары сакланып калган.

Чагыштырма-тарихи метод белән коралланган бүгенге тел гыйлеме кайчандыр бер баба телдән аерылып чыккан дип уйланылган ике яисә аннан да күбрәк телләрдә булырга тиешле уртак сүзләрне, уртак грамматик формаларны эзләп табарга тырыша. «Табылдыклар» нигезендә теге-бу телнең фәлән телгә ни дәрәҗәдә туган булуы-булмавы ачыклана, ягъни, башкача итеп әйткәндә, «фәлән сүзне кем кемнән алган?» дигән мәңгелек сорауга җавап табылды дип уйланыла.

Менә шушы нигездә бик күп халыкларның тарихы, тел-культура мәсьәләләре хәл ителә. Мәсәлән, баба тел тарафдарлары уйлаганча, иң элек «һинд-европа» халыклары барлыкка килгән. Димәк, башка барлык халыкларга караганда алар аңлырак һәм культуралырак булганнар булып чыга. Әгәр дә мәгәр «һинд-европа» семьясына кермәгән башка телләрдә «һинд-европа»ныкына охшаш сүзләр бар икән, ул сүзләрне башка тел вәкилләре «һинд-европа»лардан алганнар дигән фикер алга сөрелә. Югарыда әйтелгәнчә, тел гыйлемендә «алтай» халыклары, шул исәптән төркиләр дә барлык башка халыклардан соңрак формалашканнар дигән караш үткәрелә. Шулай булгач...

Әйе, шулай булгач, төркиләр телендәге барлык охшаш сүзләр борынгырак, алдынгырак халыклардан алынган булырга тиеш. Менә бер мисал. Совет тюркологы Д.Е.Еремеев хәтта «төрек» сүзен дә төркиләр иран теленнән алган булырга мөмкиннәр дип исәпли. Орхон-Енисей язмаларындагы күп кенә төрки сүзләрне Еремеев «һинд-европа» телле тохарлардан һәм иранлардан алганнар дип ышандырмакчы була. Шундый алынмалардан ул *беш (биш), тюмен (төмән), кюн* яисә *гюн (көн, гөн), огюз (үгез), бэг (бәк), берю (бүре), тон* яисә *дон (тун)* сүзләрен күрсәтә (Ер, 16 бит).

Хәзер шундый нәрсәгә игътибар итик. «Алтай» семьясына кергән төркиләр, монголлар билгеле бер тарихи шартларда, бер төбәктә күчмә тормыш белән яшәгәннәр. Монголларның күпчелеге, төркиләрнең кайберләре әле дә күчмә тормыш белән яши яисә күчмәлектән тулысынча арынып җитмәгәннәр. Күчмәләрнең үзләренә генә хас культуралары булган. Көтү көтеп мал асрау, башлыча малчылык азыклары белән туклану, киез өйләрне арбаларда күчереп йөртү һ.б. — боларның барысы да күчмә төркиләрдә һәм монголларда булган нәрсәләр. Ләкин, кайбер галимнәр исәпләгәнчә, чынлыкта боларның берсе дә төрки, монгол халыкларыныкы түгел икән. Атны да, арбаны да, күчмә киез өйләрне дә алар имеш, үзләреннән элегрәк далада хаким булган... иран телле «һинд-европа»лардан алганнар икән.

Төрки халыкларның шәһәр культурасы гомумән читтән, утрак халыклардан (башлыча «һинд-европа»лардан) — Иранннан, һиндстаннан йә булмаса Кытайдан алынган дип уйланыла. Алай гына да түгел, тышкы кыяфәтләре белән монголоид булмаган төрек, төрекмән, азәрбайҗаннар, казан татарлары, кырым татарлары, балкарлар, карачайлар, кумыклар һ.б. кайбер галимнәргә төркиләшкән борынгы иранлар булып тоела. Шулай итеп, безнең телебез, культурабыз гына түгел, хәтта тышкы кыяфәтебез дә үзебезнеке түгел — барысы да читтән, күршеләрдән алынган!

Алынмалар турында сүз чыккач, тагын берничә мисал белән танышып китик. Алла сүзе безгә гарәптән, Ходай — фарсыдан алынган дип уйланыла. Анысы гына җитмәгән, без саф төрки сүз дип йөргән тәңре дә читтән, бу юлы... монголдан алынган икән. Бу фикерне казакъ галимнәре С. К. Кенесбаев белән Т. Д. Җанузаков әйтеп чыкты (Кен, 87бит).

Димәк, төркиләрнең беркайчан үз диннәре, үз аллалары булмаган икән. Төркиләрнең шулай ук ил-дәүләт, гаскәр белән идарә итүгә бәйле сүзләре-терминнары да булмаган, имеш. Фин галиме Пенти Аалто *тархан, җаб-*

*гу-ябгу, шад, каган (хаган), тигин (тәгин), хан* кебек терминнарны төркиләр әлеге дә баягы фарсылардан алганнар дип исәпли. Совет тюркологы В. Л. Гукасьян бу фикергә теләктәшлек белдерә (Гук, 35 бит).

Безнең күп кенә туганлык терминнарыбыз да, имеш, үзебезнеке түгел. Югарыда телгә алынган Д. Е. Еремеев *ир(әр)* сүзен иран теленнән, П. Аалто *хатун (хатын)* сүзен фарсыдан алынган дип исәпли. Татар галиме Рифкать Әхмәтҗанов фикеренчә, *кияү, кодагый* сүзләре монголдан, С. К. Кенесбаев белән Т. Д. Җанузаков фикеренчә, *куда (кода), аха (ага)* шул ук монголдан алынган икән.

«Ахыр чиктә иранлылар башка культуралардан — һәрвакытта да кадерле кунак рәвешендә килмәгән кунакларыннан үзләре биргәнгә караганда азрак алдылар. Басып алучылар мәдәният үсешенең түбәнрәк дәрәҗәсендә иде. Яшәү шартларының һәм мәдәниятенең югары дәрәҗәдә булуы белән Иран аларны һәрвакыт үзенә тартып торды һәм тиз арада рухи яктан тез чүктерде. Чүлләрдән кузгалып чыккан гарәпләр яисә Азия далаларының балалары — күчмә халыклар үзләре белән нәрсә генә алып килделәр соң? Бары тик яңа көч-куәт ташкыны да, мәдәни дәүләт тормышына кушылып китүгә дәртле омтылыш кына алып килделәр» дип яза Англия тарихчысы Питер Авери Иран һәм күчмә халыклар мөнәсәбәте турындагы мәкаләсендә (Аб, 8 бит).

Менә шушы өзектә бөтен «һинд-европа» тел-тарих гыйлеменең төп фикере үзенең тулы чагылышын тапкан: бер якта — мәдәният һәм байлык чыганагы Иран, ягъни «һинд-европа», икенче якта — бары тик чит казанышларны үзләштерүгә генә сәләтле булган аңсыз «дала балалары», варварлар, азиатлар.

Безне кимсетүгә, түбәнсетүгә юнәлтелгән мондый карашлар белән без, әлбәттә, килешә алмыйбыз. Килешмәү — бер нәрсә, кире кагу икенче нәрсә. Күрәләтә мондый расистик карашларны кире кагу өчен барыннан да элек «һинд-европачы»ларның төп терәге булган чагыштырма-тарихи методны һәм баба тел теориясен юкка чыгарырга кирәк булыр иде. Заманында атаклы телче Н.Я.Марр да баба тел теориясен җиңел генә селтәп атты, ләкин аның үзенең дүрт элементка нигезләнгән стадиаль үсеш теориясе фәнни яктан исбатланыла алмады һәм тел гыйлемендәге чагыштырма-тарихи методны алыштыруга ирешмәде. Совет тел гыйлеменнән чагыштырма-тарихи методны Н. Я. Марр административ юл белән куалап чыгарды һәм үз карашларын тел гыйлемендәге марксистик караш дип игълан итте. 1950 елда совет тел гыйле-

мендә «революция» булды. Иптәш Сталин, Марр теориясен кире кагып, чагыштырма-тарихи методка фатиха бирде. Менә кырык ел инде бездә тел гыйлемендә сталинчыл марксистик метод хакимлек итә.

Әгәр ул чыннан да «сталинчыл» гына булса, бүгенге көндә аны фаш итү, юкка чыгару җиңелрәк тә булыр иде, бәлки. Ләкин ул «сталинчыл» гына түгел, ул метод киң таралган, тамырларын тирәнгә һәм еракка җибәргән, йөзләгән, меңләгән институтларга, кабинетларга кереп оялаган, ун меңләгән, йөз меңләгән галимнәрнең, кандидатлар һәм докторларның ихтыярын биләп алган. Бу методны туп аттырып та җимерә алмыйсың, танклар белән дә таптата алмыйсың. Монда бары акыл, ихтыяр һәм логика кирәк.

Шулай да без беркадәр читкә тайпылдык шикелле. Без әле бүгенге тел гыйлеменең теоретик һәм практик казанышлары турындагы сүзне тәмамламадык.

## 4. ТЕЛ СЕМЬЯЛАРЫ ҺӘМ ТЕЛ ФАКТЛАРЫ

Телләрне туганлык төркемнәренә бүлеп тикшерү билгеле бер чиккә кадәр үз-үзен аклый. Мәсәлән, татар, үзбәк, казакъ, төрек, төрекмән һ.б. төрки телләр аерым семья тәшкил итәләр икән, моңа каршы бер сүз әйтеп булмый. Шулай ук славян телләре, герман телләре, роман телләре һ.б. тел семьялары турында да шул ук фикерне әйтә алабыз. Ләкин төрки телләр белән монгол, тунгус-манчжур телләре яисә славян телләре белән грек, латин, герман, роман телләре тугандаш дип әйтү ни дәрәҗәдә хакыйкатькә туры килә икән? Бу семьяларга карый торган телләр арасында кайбер охшашлыклар бар, әлбәттә, ләкин охшаш булмаган моментлар да җитәрлек. Кардәшлекне билгеләгәндә шуларның кайсына таянырга — кайбер охшашлыкларгамы, әллә шактый күп аерымлыкларгамы?

Мәсәлән, монгол телендә татардагы кебек *ә, ө, ү* авазлары бар, *къ* тартыгы исә юк. Татарча *къ* кулланылган сүзләрдә монголча *х* кулланылырга мөмкин. Төрки телләрнең дә кайберләрендә *къ* урынына *х* куллана. Янә дә шул ук сорау: кардәшлекне билгеләгәндә авазлар системасындагы охшашлыкка гына таяныргамы, әллә башка күрсәткечләрне дә исәпкә алыргамы? Әйтик, төрки телләр белән монгол телләрендә авазлар системасы берберсенә туры килә ди. Шулай да бүгенге татар белән бүгенге монголның һәркайсын үз телендә сөйләштереп карасаң, ике телдә дә кайбер охшашлыклар булуына да карамастан, бер-берсен алар аңламаячаклар. Төрки телдә

сөйләшүчеләрнең теләсә кайсын үзара сөйләштереп карасак, алар, күрәсең, бер-берсен шактый җиңел аңлый алырлар иде. Тик монда чуваш теле белән якут теле генә беркадәр читтә тора. Бу телләр, төрки исәпләнелсәләр дә, үз тугандашларыннан бик нык аерылалар.

Башка тел семьяларына мөрәҗәгать итсәк тә без шундыйрак күренешкә тап булырбыз. Борынгы грек, латин, санскрит телләре генә түгел, бүгенге герман, славян, роман, һинд, фарсы, албан һ.б. телләре дә «һинд-европа» семьясына карый дип уйланыла. Рус теле, белүебезчә, славян телләре төркеменә карый. Димәк, рус теле дә «һинд-европа»ның бер вәкиле. Бүгенге рус теленең авазлар системасы үзенең «канкардәшләре» немец, инглиз, француз, һинд, фарсы телләрендәге авазлар системасына йә бөтенләй туры килми, яисә бик аз туры килә. Мәсәлән, һинд, фарсы, француз, инглиз телләрендә татарның йомшак әйтелешле *ә, ө, ү, җ, ң, һ,* йомшак *в* кебек авазларына охшаш яки тәңгәл авазлар бар. Кайбер «һинд-европа» телләрендә хәтта *къ* авазы да бар. Рус телендә боларның берсе дә юк. Бүгенге рус белән бүгенге һинд, фарсы яисә инглиз, французның һәркайсын үзара үз телендә сөйләштереп карагыз, алар бер-берсен аңлый алырлар микән? Юк, аңлый алмаслар. Аңлый алмаганга күрә дә бездә һәм башка илләрдә мәктәпләрдә, институтларда, төрле курсларда «тугандаш» телләрне чит тел буларак өйрәнәләр түгелме соң?! Бер-берсенең телен һич югы чама белән дә аңлый алмаган «туганнар» нишләп канкардәш була алырлар икән?

Бер зур семьяга карый дип уйланылган төрле телләрдәге авазлар системасы гына түгел, аларның лексикасы да, грамматик чаралары да бер-берсенә туры килмәскә мөмкин. Мәсәлән, «һинд-европа» телләре семьясына карый торган үле хет телендә «су» *ватар* дип атала. *Ватар* русча *вода*, немецча *вассер*, һиндчә *уда* сүзләренә якын. Әйе, якын, ләкин тәңгәл түгел. Шул ук «һинд-европа» телләреннән исәпләнелгән латин телендә «су» *акъуа*, грекча *һидор* дип атала. Күрәсез, *ватар*га да, *вода*га да, *вассер*га да, *уда*га да якын да килмәгән.

Хет телендә «сөяк» *хаста* дип атала. Бу сүз русча шул ук мәгънәдәге *кость*, грекча *остеон*, латинча *ос* сүзләренә якын. Димәк, «сөяк» мәгънәсендәге сүзләр ярдәмендә әлеге өч телнең бер-берсенә туганлыгын исбат итәргә була сыман. «Һинд-европа» телләренә карамаган япон телендә дә «сөяк» *кость* һәм *хаста* сүзләренә якын *коцу* рәвешендә әйтелә. Болай булгач, япон телен дә «һинд-европа»га кертәбезме, әллә «сөяк» мәгънәсендәге сүзне кем кемнән ал-

ган дип котылабызмы? Чыннан да, кем кемнән алган — японнар «һинд-европа»лардanмы, әллә киресенчәме?

Югарыда әйтелгәнчә, «һинд-европа» телләре моннан 8—10 мең еллар элек формалашкан дип уйланыла. Япон теле кайчан барлыкка килде икән соң? С.Е.Яхонтов фикеренчә, Көнчыгыш һәм Көньяк-Көнчыгыш Азия телләре моннан 6—7 мең еллар элек барлыкка килгән булырга мөмкин. Кайбер галимнәр фараз кылганча, хәзерге ватаннарына японнар моннан 30 мең еллар элек Азиядән күченгән булырга тиешләр. Әгәр дә мәгәр 30 мең ел турындагы гипотезаны дөрес дип исәпләсәк, бик борынгы заманнарда японнар «һинд-европа»лар белән, гомумән, очраша да алмаганнар һәм «сөяк» мәгънәсендәге сүз дә бер телдән икенче телгә күчә алмаган.

Игътибар беләнрәк тикшерә башласаң, бүгенге фәндә бер-берсенә тугандаш исәпләнелмәгән һәм беркайчан берберсе белән аралашмаган, аралаша алмаган сыман тоелган һәм территориаль яктан бер-берсеннән бик еракта урнашкан бик күп халыклар телендә коцу-кость-хаста кебек охшаш сүзләр табылачак. Мәсәлән, япон телендә «көтү көтмәк» *боку* (ягъни багу), «кояш баю» *боцу* (ягъни *бату*), «кагу-сугу», «бәргәләү» *коку* (ягъни *каку-кагу*), «яндырып җибәрү» *яку* дип атала. Индонезия телендә «янып торган ут» («факел») *обор* (ягъни *убыр*) дип, Яңа Гвинеядәге телок-кируру телендә «ут» *ута* дип, Индонезиядәге ментавай телендә «дин башлыгы» *сикере* (ягъни *сихерче*) дип, Яңа Зеландиядәге маори телендә «сугу», «кыйнау» *пату* (ягъни *вату*) дип, Африкадагы луба телендә «эченә», «эчендә» *мунда* (ягъни *монда*) дип атала. Әйтик, япон теле белән татар телендә охшаш сүзләр булуы әллә ни гаҗәп түгел ди, чөнки япон теле белән төрки телләр типологик яктан бертуган исәпләнелә.

Ләкин япон теле белән, әйтик, рус телендәге охшаш сүзләрне ничек аңлатырга? «һинд-европа» телләре белән япон теле арасында бернинди туганлык булмагач, рус теле белән япон теле арасында да туганлык элементлары булмаска тиеш иде кебек. Япон телендә «әби», «карчык» *баба* дип атала. Русча гади сөйләм телендә *баба* «хатынкыз», «әби», «карчык» дигәнне белдерә. Яңа Гвинеядәге били-били телендә дуңгыз *бор* дип атала, русча «печтерелгән дуңгыз» *боров* дип атала. Японча «икенче исем» *имө* дип, русча «исем» — *имя*, Мадагаскар утравындагы мальгаш телендә «койма», «киртә» *вала* дип русча «туфрак өеме», ягъни киртә-койманың бер төре *вал* дип, Африкадагы оромо телендә «тау» *гаара* дип, русча *гора* (әйтелеше гара) дип, шул ук Африкадагы луо телендә «агу»

*йат* дип, русча *яд* (*йад*) дип, Көньяк Азиядәге (Таиландтагы) тай телендә «җир» *тина* дип, русча су төбендәге «баткак җир» *тина* дип атала.

Рус теле белән татар телендәге охшаш һәм уртак сүзләрнең күбесе безгә билгеле дип уйларга кирәк, чөнки татарча, русча матбугатта бу хакта әледән-әле язып торалар. Мондый охшаш һәм уртак сүзләрне, гадәттә, фәлән телдән фәләненче гасырда алынган дип аңлатырга яраталар. Әйтик, колхоз, совхоз, председатель кебек сүзләрнең татар теленә рус теленнән алынуы һәм кайчан алынуы турында бернинди бәхәс булырга мөмкин түгел. Ләкин шул ук вакытта рус телендә дә, татар телендә дә кем кемнән алган булуын һәм кайчан алган булуын берничек тә аңлатып булмый торган сүзләр очрый. Мәсәлән, татарда *мәрткә китү* бар. Мәрткә китү ул тулысынча үлемне түгел, ярым үлем хәлдә булуны аңлата. Русча «үлем» *смерть*, «үлгән кеше» *мертвый* дип атала, һәр ике сүздә *мәрт* иҗекләре катнаша. Кем кемнән алган да, кайчан алган? Бар, исбатлап кара!

Русча «томау» *насморк* дип атала. Бу сүзне *нас* һәм *морк* иҗекләренә таркатсак, *нас* дигәне русча «борын» *нос* булачак. *Морк* дигәне татарча «мырык»ка туры килә түгелме соң? Шул ук вакытта бу бик таныш *морг* та бит әле. Мәетне күмгәнче куеп тора торган бинаны, бүлмәне *морг* диләр. Сүзлектә бу француз сүзе дип аңлатыла. Болай булгач, безгә *муртайган*, ягъни «катып калган», ягъни «үлгән» дигән сүзне дә, *мур кыргыры* дигән сүзне дә искә төшерергә туры килә. Ни генә булмасын, *мур-мор-мыр* һәм шулай ук *мәрт, мерт* үлемгә, үтерүгә бәйле. Бу уңайдан тагын мәрхүм сүзен дә теркәп узасы килә. *Мәрхүм* гарәпчә «үлгән ир кеше» дигәнне белдерә. Татар телендә дә *мәрхүм* «үлгән кеше» дигәнне аңлата, тик без үлгән кешенең ирме-хатынмы икәнлегенә игътибар гына итмибез. Полинезиядәге танна телендә «он убит» (ир кеше турында — «ул үтерелде») дигән сүз *марком* дип атала икән. Күрәсез, бер-ике сүз безне татар-рус уртаклыгыннан бөтенләй читкә алып китте.

Димәк, русның *насморк* сүзе «борын үлеге» дигәнне, татарның *мырык* дигәне шулай ук борын «үлеге» дигәнне белдерә икән. *Насморк* сүзенең *нас* иҗекләренә тукталып тормыйбыз — бу да безне читкә алып китәргә мөмкин. Җыеп әйткәндә, шул: менә шундый охшаш һәм уртак сүзләрне, грамматик формаларны без Җир шарындагы теләсә нинди ике яисә аннан да күбрәк телләрдә таба алабыз. Билгеле бер чорда, билгеле бер территориядә бер-берсенә күрше булып яшәгән яки күрше булып яшәгән дип уйланылган халыклар телендәге охшаш һәм

уртак сүзләрнең ничек барлыкка килүен аңлатуы авыр түгел кебек. Фәлән халык төгән халыктан алган дисең дә, ышандыргычрак булсын өчен «фәлән гасырда» дип өстисең һәм шуның белән вәссәлам. Кем аны тикшереп торсын? Әгәр аны берәр атаклырак галим әйткән булса, беркем моңа каршы килмәячәк. Бүгенге тел гыйлеме үтә четерекле мәсьәләләрдән менә шул рәвешчә котыла бирә. Ләкин бар яктан да диңгезләр белән уратып алынган Яңа Гвинея, Яңа Зеландия, Австралия яисә Танна утрауларында яшәүче төп халыкларның телендә, әйтик, татарчага, русчага, гарәпчәгә охшаш сүзләр булуын шулай да ничек аңлатырга? Бит ул халыклар унар мең еллар буена Җир шарының башка төбәкләрендә яшәүчеләр белән берничек тә аралаша да, «тел-лөгать алыша» да алмаганнар!

## 5. ТЕЛЛӘРНЕҢ ИКЕ ТӨРЛЕ ТУГАНЛЫГЫ: ГЕНЕТИК ТУГАНЛЫК ҺӘМ СТРУКТУР ТУГАНЛЫК

Бүгенге тел гыйлеме өйрәткәнчә, телләрнең туганлыгы ике төрле була. Аның берсе генетик яки генеалогик туганлык, икенчесе структур туганлык дип атала. Генетик туганлык тумыштан килә торган чын туганлыкны белдерсә, структур туганлык исә чын туганлык була алмый. Бу бары формаль туганлык кына.

Генетик туганлык төшенчәсе бер баба телдән аерылып чыккан дип уйланыла торган телләргә карата гына кулланыла. Структур туганлык исә бер баба телдән аерылып чыкмаган дип, башка тел семьяларына карый дип уйланыла торган телләрдәге охшашлыкны күз алдында тота. Мәсәлән, япон белән руслар бер баба халыктан аерылып чыкмаганнар, шуңа күрә япон теле белән рус телендәге *кость-коцу* кебек охшаш сүзләр структур (формаль) туганлык турында гына фикер йөртергә нигез була ала. Шулай ук төрки телләр белән, әйтик, Африка, Австралия, Америка телләрендәге охшаш мәгънәле, охшаш формалы сүзләр дә әлеге телләрнең генетик туганлыгы турында түгел, бәлки структур туганлыклары турында гына мәгълүмат бирә алалар.

Латинча «баш» *капут* дип атала. Австралиядәге аранта телендә «баш» *капута* рәвешендә формалашкан. Күренеп тора, аранта телендә *капута* сүзендә соңгы *а* сузыгы гына артык сыман, һәр ике телдәге сүзләр формалары белән дә, мәгънәләре белән дә бер-берсенә тәңгәл. Ләкин аранта теле латинга, латин теле арантага генетик туган түгел. Австралиянең җирле халыклары үзләренең хәзерге ватаннарына моннан утыз мең еллар элек

күченгән булырга тиешләр дип уйланыла. Шул утыз мең ел эчендә алар башка материклардагы кешеләр белән аралаша алмаганнар. Чөнки Австралия аборигеннары диңгездә йөзә белмәгәннәр. Димәк, *капут-капута* сүзен кемнең кемнән алып торуы турында уйларга да мөмкин түгел.

Шулай да ничек, нинди шартларда барлыкка килде икән соң менә мондый гаҗәеп дәрәҗәдәге охшаш сүзләр?

Компаративистлар өйрәткәнчә, мондый охшаш сүзләр, имеш, кешелек җәмгыяте үсешендә билгеле бер вакытта һәркайда бер үк төрле ихтыяҗлар туу аркасында барлыкка килгән. Төгәлрәк итеп әйткәндә, латин телендә дә, аранта телендә дә ниндидер билгеле бер вакытта «баш»ны *капута* дип атау ихтыяҗы туган, һәм бу хәл, имеш, очраклы рәвештә генә булган. Барлык телләрдә охшаш сүзләр, охшаш атамалар, имеш, менә шулай очраклы рәвештә, теләсә ничек барлыкка килгәннәр.

Инде генетик туганлык мәсьәләсенә килик. Монысы бераз катлаулырак. Ике яисә аннан да күбрәк телләрнең генетик туганлыгын исбат итәсең килсә, чагыштырыла торган телләрдән охшаш сүзләрне түгел, бәлки охшаш булмаган сүзләрне сайлап алырга кирәк ди совет компаративистларының берсе И.М.Дьяконов. Ләкин охшашмау билгеле бер система хасил итәргә тиеш. Аннан соң шунысы да бар: чагыштыру өчен теләсә нинди охшаш булмаган сүзне алырга ярамый. Моның өчен бары тик өчтән бишкә яки тугызга кадәрге саннарны, кешенең иң гади эшен, хәрәкәтен, кеше әгъзаларын белдерүче сүзләрне генә алырга ярый. Ни өчен? Чөнки телнең фонетикасы, имеш, туктаусыз үзгәрә. Әлеге төрдәге сүзләр, имеш, бик борынгы чорларда барлыкка килгәннәр һәм андый сүзләр яңадан да уйлап табылмаганнар, күршедән дә алынмаганнар. Кыскасы, мондый төр сүзләр телләрнең баба тел чорын ачыклауда иң ышанычлы чыганак булып хезмәт итәләр (Дьяк, 11—16 битләр).

Ләкин, әле генә күреп киткәнчә, латин телендә дә, аранта телендә дә «баш» *капут(а)* дип атала. «Баш», белүебезчә, кеше әгъзасы төрендәге сүзләргә карый.

И.М.Дьяконов гади саннарны да чагыштырып карарга ярый ди. Тик нишләптер аның чагыштырырга рөхсәт ителгән гади саннары «бер»дән түгел, «өч»тән башлана. Шулай да без кызык өчен генә «бер»не дә түгел, «өч»не дә түгел — «ике»не чагыштырып карыйк әле. «Ике» сүзе латинча *дуо*, итальянча *дуе*, русча *два*, немецча *цвай*, латышча *диви*, молдаванча *дой*, һиндстандагы маратхи телендә *дон*, күрд, белуҗ, фарси-кабули телләрендә *ду* дип атала. Боларның барысы да «һинд-европа» телләре. Ләкин

«һинд-европа» телләре семьясына кермәгән һәм Европа, һиндстан халыкларыннан еракта, океан уртасындагы ялгыз утрауларда яшәгән халыкларның телләрендә дә «ике» төшенчәсе югарыдагы мисалларга охшаш сүзләр ярдәмендә белдерелә. Мәсәлән, Индонезия, сунда, купан, даяк, илоко телләрендә «ике» *дуа* дип, батахи телендә *дува* дип атала. Азия континентында яшәүче эвенкиләр телендә «ике» *дүр*, нанайча *дүер*, орокча *ду*, айну телендә *ту*, корейча *тул* дип атала.

Мисаллардан күренгәнчә, әлеге телләрдәге «ике» мәгънәсендәге сүзләр компаративистларның таләбенә тулысынча туры килә: алар бер-берсенә тулысынча охшамаганнар, ләкин аларның аерымлыгы билгеле бер закончалыкка нигезләнгән һәм тулаем бер система хасил итәләр. Димәк, әлеге «ике»ләр ниндидер баба телдән аерылып чыккан булырга тиешләр! Хәер, онытып җибәргәнбез, И.М.Дьяконов «ике» санын белдерүче сүзләрне чагыштырып карарга ярамый дигән иде бит әле.

Төрки телләр белән монгол һәм тунгус-манчжур телләре үзара генетик туганнар дип исәпләнелә. Әгәр шушы телләрдәге гади саннарны чагыштырып карасак, монда берниндн закончалык һәм система таба алмаячакбыз. Мәсәлән, «бер» саны монгол телләренең берсе шира-югурда *неге* дип, калмыкча *негн*, иске монгол язма телендә *ниген*, хәзерге монгол телендә *неген* дип атала. «Өч» саны хәзерге монгол телендә *пурван*, тунгус-манчжур телләреннән нанай телендә *илан*, орок телендә *ила(н)*, эвенки телендә *илан*, манчжур телендә *илань*, эвен телендә *илън* дип атала. Төрки телләрдә «бер»нең *бер* яисә *бир*, «өч»нең *өч, үч* булуын әйтеп торуның кирәге юк дип уйлыйм.

Шулай итеп, Дьяконов әйткән гади саннар мәсьәләсендә кызык хәл килеп чыга: Индонезия, сунда, даяк һ.б. телләр белән «һинд-европа» телләре генетик туган саналмый, ләкин «ике» сүзен белдерүче сүзләр аларның генетик туганлыгын исбатлый сыман. Төрки телләр белән монгол, тунгус-манчжур телләре генетик туган исәпләнелә, әмма «бер» һәм «өч» мәгънәсендәге гади сан сүзләре мондый туганлыкны кире кага.

Чагыштырма-тарихи метод тарафдарлары фикер йөрткәнчә, генетик туганлыкны исбат итү өчен туганлык терминнарын да чагыштырып карарга рөхсәт ителә. Тик монда да уяу һәм сак булырга кирәк, чөнки «ата», «ана» кебек туганлык терминнары чын, реаль, нормаль сүзләр түгел икән. Бу бик гаҗәп, әлбәттә. Бит кеше өчен ата-ана, әтиәни кебек сүзләрдән да якынрак туганлык термины юк.

Шулай да без тагын да кызык итеп кенә «ата», «ана»

төшенчәләрен белдерүче кайбер сүзләргә тукталып китмәкче булабыз. Мәсәлән, русча «әни» мәгънәсендәге *мама* бик күп телләрдә очрый һәм төрле туганлык терминнарын аңлата. Төрекләрдә *мама* «әни», грузиннарда «әби» дигәнне белдерә. Занзибар, кытай, лингала, мальгаш һ.б. бик күп телләрдә *мама* — «әни», лавелла, хиу, нгуна (ңуна) телләрендә «әби», пушту, таййал, телугу телләрендә — «абзый», «абый», татар, үзбәк һ.б. телләрдә — «әби», «дәү әни» дигәнне белдерә.

Менә шундый киң таралган охшаш туганлык терминнарын бүгенге тел гыйлемендә «балалар теле», «балалар сүзе» дип атап йөртәләр. Моның нигезе шуңа кайтып кала: һәркайда, һәр халыкта балалар, имеш, бер үк төрле авазлар, бер үк төрле сүзләр белән «сөйләшәләр». Бик күп телләрдә «әти», «әни» мәгънәсендәге сүзләрнең охшаш булуы, имеш, әнә шул аңсыз рәвештә лыбыр-лыбыр сөйләнгән авазлар җыелмасын чагылдыра икән. Әйтергә кирәк, «әти», «әни» төшенчәсен белдерүче сүзләр тел гыйлемендә «генетик туганлыкны» исбатлау өчен дә, «структур туганлыкны» исбатлау өчен дә кулланылмый.

Һәркемгә билгеле дип уйларга кирәк: «балалар теле» дигән тел юк һәм була да алмый. Яңа теле чыга башлаган сабыйга сүзләрне, авазларны бары тик ата, ана һәм, гомумән, өлкәннәр генә өйрәтә. Димәк, «әти», «әни» мәгънәсендәге гади туганлык терминнарын да теле чыкмаган сабыйлар түгел, бәлки өлкәннәр, ягъни нормаль физик һәм психик үсеш дәрәҗәсенә җиткән аңлы кешеләр уйлап тапканнар.

## 6. АВАЗЛАРНЫҢ ТУКТАУСЫЗ ҮЗГӘРҮЕ ЯКИ ТАРИХИ ФОНЕТИКА

«Тарихи фонетика телләрне чагыштырма-тарихи юнәлештә өйрәнүнең нигезе булып тора» ди Б.А.Серебренников (Сере, 14 бит).

Тарихи фонетика барыннан да элек фонетиканың, ягъни авазлар системасының тарихын күз алдында тота. Тарих фәне, белүебезчә, үткән чорларны тикшерә һәм сакланып калган төрле фактик материаллар нигезендә элекке заманнарның чагыштырмача дөрес күренешен тасвирлап бирә. Халыклар тарихы, илләр, шәһәрләр, авыллар тарихы, материаль культура, рухи культура тарихы һ.б. «тарих»лар була. Ләкин «тарих» төшенчәсен теге-бу авазлар системасына карата кулланып буламы соң? Әгәр без бүгенге телебез фонетикасының тарихы бар дип исәплибез икән, димәк безнең бүгенге көнегелгән сүзләребез

элекке заманнарда башкачарак яңгыраганнар булып чыга түгелме соң? Шулаен шулай, ләкин бүгенге сүзләрнең элекке заманнардагы әйтелешен нәрсәгә нигезләнеп билгели алырбыз икән?

Җанлы сөйләм телендә бер үк сүзне төрле кеше төрлечәрәк әйтергә мөмкин. Мәсәлән, татар әдәби телендә *чиш* рәвешендә кулланыла торган сүз кайбер диалектларда *тиш, шиш* рәвешендә әйтелә. Әдәби телдәге *йодрык* сөйләм телендә *йозырык, җозырык* булырга мөмкин. Төрки телләрнең берсе карай (караим) телендә шул ук сүз *йумрукъ, йудрукъ* диелә. Берәүләр *маңгай* дип, икенче берәүләр *маңлай* дип сөйлиләр.

Күренә ки, бер үк мәгънәдәге һәм бер үк формадагы сүзләр төрле телдә, төрле диалектта гына түгел, хәтта бер-берсенә якын урнашкан төркемнәрдә дә (әйтик, бер үк авылда, бер үк гаиләдә) төрлечәрәк әйтелергә мөмкин икән. Компаративистка тарафдарлары ике һәм аннан күбрәк телләрдәге бер үк мәгънәдәге сүзләрне үзара чагыштырып карыйлар да, чагыштырыла торган сүзләрдәге менә мондый төрлелекне тарихи пландагы үзгәреш дип исәплиләр. Алар фикеренчә, чагыштырыла торган сүзләрдәге кайбер авазларның бер-берсенә тәңгәл килмәве ул чагыштырыла торган телләрдәге авазлар хәрәкәтен, авазларның бер сыйфаттан икенче сыйфатка күчүен, яңаруын, димәк, фонетика тарихын чагылдыра.

«Тарих» булгач, чагыштырыла торган сүзләрдәге охшаш булмаган авазларның берсе әүвәлрәк, икенче берсе соңрак барлыкка килгән булырга тиеш. Шулай булмаган очракта авазлар системасындагы тарихи үзгәрешләр турында сүз алып баруның кирәге дә юк. Тел гыйлемендә мәсьәлә шулай куела да. Бер үк мәгънә аңлаткан, бер төслерәк яңгыраган һәм ике яисә аннан күбрәк телдә кулланыла торган сүзләрнең билгеле бер позициядәге авазларының берсе әүвәлрәк, икенчесе соңрак барлыкка килгән дип уйланыла. Соңгырак, яңарак авазлар төрле сәбәпләр аркасында әүвәлгерәк авазларны кысрыклап чыгаралар, яңарак авазларны исә аларыннан да яңарак башка төрле авазлар алыштыра дип исәпләнелә. Шул рәвешчә, фонетикада туктаусыз хәрәкәт бара, имеш.

Югарыда без формасы һәм эчтәлеге ягыннан татар сүзләренә охшаган берничә япон сүзе белән танышып киттек, японча *коку* — кагу, кагу-сугу, *яку* — ягу дигәнне белдерә дидек. *Коку* бүгенге татар телендәге *къагъу* сүзенә бик нык охшаган булса да, җентекләп тикшергәндә бу сүзләрнең фонетикасында күп кенә аерымлыклар табарга була. Беренчедән, японда каты *къ, гъ* авазлары юк. Шуңа

күрә татарча каты *къ* японча̄да йомшак *к* тартыгына тәңгәл. Татардагы каты *гъ* авазы да японча̄да йомшак *к* тартыгы аша белдерелә. Икенчедән, татарча *а* сузыгына әлеге сүздә японча *о* сузыгы тәңгәл. *Яку-ягъу* сүзләрендә аерма азрак. Японча йомшак *к* тартыгы татарча *гъ* тартыгына тәңгәл.

Хәзер без шундый нәрсәгә игътибар итеп карыйк: *коку-къагъу, яку-ягъу* сүзләре нигезендә авазлар тарихын ачыклап буламы? Була кебек. Мәсәлән, *коку-къагъу* сүзләрендә *о* сузыгы *а* сузыгына, йомшак *к* тартыгы каты *гъ* тартыгына әйләнгән, *яку-ягъу* сүзләрендә йомшак *к* тартыгы каты *къ* тартыгына әйләнгән дип фараз кылсак, японча *коку, яку* әүвәлгерәк, *къагъу, ягъу* соңгырак дигән нәтиҗәгә килә алабыз. Димәк, *къагъу, ягъу* сүзләрен төркиләр японнардан алган булып чыга.

Әллә соң киресенчәме? Ягъни *о* сузыгы *а* сузыгыннан, йомшак *к* тартыгы каты *къ, гъ* тартыкларыннан үзгәргәнме? Ләкин моны ничек белергә? Кая монда ышанычлы таяну ноктасы? Дөресрәге, каян, ничек, нинди ноктадан кузгалып китәргә?

Тагын бер мисал белән танышып карыйк. Татарча боз сүзе каракалпакча *муз* формасында кулланыла. Чагыштырыла торган сүзләрнең өченче авазлары гына бер-берсенә тәңгәл. *Бо* белән *му* иҗекләренең кайсы әүвәлгерәк? Каян, ничек белергә моны? Татарга, билгеле, *бо* әүвәлгерәк, каракалпакка *му* әүвәлгерәк булып тоелырга мөмкин, чөнки татарга *боз* якынрак, каракалпакка *муз* якынрак. Ләкин бу мәсьәләне без мондый якынлык принцибыннан чыгып хәл итә алмыйбыз. Без монда тагын шуңа да игътибар итеп карыйк. *Коку-къагъу* мисалында *о* белән *а* сузыклары очрашты, *боз* белән *муз* мисалында *о* белән *у* сузыклары очрашты. Кайсы сузык әүвәлгерәк тә, кайсы соңгырак?— без моны әлегә белә алмадык. Күрәсең, моны тиз генә, җиңел генә белеп тә булмаячак.

Чагыштырма-тарихи метод тарафдарлары мондый нәрсәләрне үзләренчә хәл итәләр. Чагыштырыла торган сүзләрдә бер-берсен алыштырып килә торган авазларның сүз башында, сүз уртасында, сүз ахырында килүенә, басым белән яисә басымсыз әйтелүләренә һ.б.ш. үзенчәлекләренә карап, алар нинди телдә нинди авазның беренчел, нинди авазның икенчел, өченчел булуын, нинди сүзнең нинди сүздән үзгәрүен һәм, ахыр чиктә, тикшерелә торган сүзләрнең иң борынгы рәвешен — баба тел заманнарындагы праформасын ачыклап була дип исәплиләр.

Компаративистлар сузыкларга бөтенләй диярлек игътибар итмиләр. Мәсәлән, *коку-къагъу, боз-муз* кебек мисалларда *а, о, у* сузыкларын алар күрмиләр дә. Алар баш-

лыча тартыкларны тикшерәләр. Моның сере бик гади. Беренчедән, дөнья телләрендә сузыкларга караганда тартыклар ике-өч мәртәбә күбрәк, төрлерәк. Шулай булгач, тартыкларны төрле комбинациядә тикшереп карау һәм бер-берсен алыштыра торган вариантларны күбрәк табу мөмкинлеге бар. Икенчедән, чагыштырма-тарихи метод Көнбатыш Европада, «һинд-европа» телле галимнәр ватанында барлыкка килгән. Немец, француз, инглиз, рус, чех, поляк һ.б. телләрендә исә сүз башында да, сүз азагында да, сүз уртасында да икешәр, хәтта өчәр тартык аваз бергә килә ала. Моның шулай икәнлеген русча ссуда, введение, всплеск кебек сүзләр мисалында күрергә була. Компаративистларның тартыкларга табынуы, тартыкларны идеаллаштыруы шул дәрәҗәгә җиткән, кайберәүләр хәтта иң әүвәлге тел тартыклардан гына торган дип ышандырмакчы булалар. Мәсәлән, ван Гиннекен, кавказ һәм готтентот телләрен тикшереп карагач, нәкъ менә шундый фикергә килгән.

Кайбер кавказ телләрендә тартыклар чыннан да күп. Ләкин тартыклар күп булу әле ул сузыклар бөтенләй юк дигән сүз түгел. Кайбер телләрдә тартыкларның күп булуы гына яисә кайбер телләрдә берничә тартык авазның бергә җыелып килә алуы гына тартыкларны идеаллаштыруга нигез була аламы? Юк, әлбәттә. Кеше дигән зат ир җенесендәге һәм хатын-кыз җенесендәге затлардан торган кебек, тел дә сузык һәм тартык авазлардан тора, һәм монда инде бер затны икенчесеннән өстен итеп кую яисә берсен икенчесеннән аерып карау мөмкин нәрсә түгел.

Ярар, монысы болай да аңлашыла дип исәплик. Бер телдә тартыклар фәләнчә, икенче телдә төгәнчә, аларның әйтелеше дә төрле телдә төрлечә. Ләкин тагын бер үк балык башы: кайсы тартыкның әүвәлгерәк, кайсысының соңгырак икәнлеген шулай да ничек белергә соң?

Төрки телләрдә *р* тартыгы *л, з, с,* тартыкларына караганда борынгырак дип исәплиләр кайберәүләр. Шуңа күрә *күз* сүзе *күрү* фигыленнән үзгәргән дип уйланыла. Яисә, киресенчә, *күз* сүзе *күрү* фигыленнән үзгәргән дип уйланылганга күрә, кайберәүләр *р* тартыгы борынгырак, *з* тартыгы соңгырак дигән фикергә килгәннәр дип әйтергә дә була. Татарча «мин» алмашлыгы элекке заманнарда *бин* яисә *би* булган дигән карашлар бар. Әлеге мисал татар телендә *м* тартыгының *б* тартыгыннан барлыкка килүен һәм *б* тартыгына караганда яшьрәк булуын исбат итә, имеш. Болай булгач, татарча *боз* каракалпакча *муз* сүзеннән борынгырак дип әйтергә мөмкин сыман тоела. Бары тоела гына. Шулаймы, түгелме — *б* һәм *м*

тартыкларына гына нигезләнеп моны берничек тә исбат итеп булмый.

Сөйләм телендә бер тартык урынына икенче тартык, бер сузык урынына икенче сузык куллануны аңларга да була кебек. Чөнки теләсә нинди телдә авазларның мондый чиратлашуына мисаллар тулып ята. Ләкин мисалларның төрлесе бар. Без, мәсәлән, *тау* дип сөйләшәбез, уйгурлар *тагъ*, кырым-татарлар *дагъ* дип сөйлиләр. Күренеп тора, әлеге сүзләрнең ахырдагы авазлары бер-берсенә тәңгәл килми: татарча *тау у* сузыгына, уйгурча һәм кырым-татарча *тагъ, дагъ* сүзләре *гъ* тартыгына тәмамлана.

Нинди хикмәт бу? *У* сузыгыннан *гъ* тартыгы барлыкка килгәнме, әллә соң *гъ* тартыгыннан *у* сузыгымы? Ничек исбат итәргә моны? Моның серен әлегә бер генә тел галименең дә аңлатып бирә алганы юк — иң дөрес җавап хәзергә шул.

Телләрнең бик борынгы чорларын баба телләргә кайтарып калдыру һәм бер төрле баба телләрне элегрәк, икенче төрле баба телләрне соңрак барлыкка килгән дип игълан итү безне ышандыра алмый. Төрле семья телләрендәге охшаш һәм уртак сүзләрне генетик туганлык һәм структур туганлык яисә балалар теле, стихиялек, очраклылык теорияләре белән аңлату шулай ук ышандырмый. Төрле телләрдәге сүзләрне чагыштыруда һәм бер сүзнең әүвәлгерәк, икенче сүзнең соңгырак, ахыр чиктә бер телнең яисә тел семьясының борынгырак, икенче телнең яисә тел семьясының соңгырак — яңарак, яшьрәк булуын исбат итүдә төп критерий хезмәтен үти торган тарихи фонетиканың нигезе ышанычсыз. Авазлардагы төрлелек ул авазларның тарихи пландагы үзгәрешен түгел, бәлки сөйләүченең һәм сөйләүчеләрнең теге яки бу авазларны әйтүдәге төрлелеген генә чагылдыра. Бер төрле авазларны беренчел, икенче төрле авазларны икенчел дип игълан итүдә тел галименең субъектив карашларыннан башка бернинди таяну ноктасы юк. Әгәр дә мәгәр телнең фонетикасы компаративистлар уйлаганча туктаусыз һәм шактый тиз үзгәрә торган булса, телләрнең авазлар системасы, гомумән, тотрыксыз булыр иде. Бер үк система эчендәге кайбер авазлар әледән-әле бер-берсен алыштырырга, бер төрле формадан икенче төрле формага күчәргә мөмкин. Шул ук вакытта кайбер авазлар гасырлар буена бөтенләй үзгәрмәскә яисә бик аз гына, җиңелчә генә үзгәрергә мөмкин.

Телне, сүзне борынгы кеше изге дип, хәтта җанлы дип белгән һәм телгә, сүзгә, иҗеккә карата аеруча сак һәм сизгер булган. Борынгы кешедә телгә-сүзгә карата

шундый мөнәсәбәт булмаган булса, кешелек җәмгыяте, гомумән, бүгенге үсешкә ирешә алмаган булыр иде, күрәсең. Бары тик эчке логикага буйсынган һәм билгеле бер дини-фәлсәфи карашларга нигезләнгән, бик озак вакытлар дәвамында тотрыклы авазлар системасы саклаган тел ярдәмендә генә кеше үзенең юлындагы каршылыкларны җиңеп чыга алган һәм, кыргый хәлендәге аңыннан, хайванга якын кыяфәтеннән арына барып, чын мәгънәсендә кеше дәрәҗәсенә күтәрелә алган.

Чагыштырма-тарихи метод тарафдарларының телнең табигатен аңлатудагы теорияләре буталчык һәм каршылыклы. Заманында греклар бары тик грек телен генә, латиннар — латин телен, яһүдләр — яһүд телен генә Алла тарафыннан бирелгән иң әүвәлге, иң дөрес тел дип исәпләгән кебек, «һинд-европа» тел гыйлеме әһелләре дә иң борынгысы, иң алдынгысы — «һинд-европа» телләре дигән карашны алга сөрәләр.

Без, әлбәттә, мондый фикер белән дә килешә алмыйбыз.

## 7. КЕШЕНЕҢ ҺӘМ ТЕЛНЕҢ БАРЛЫККА КИЛҮЕ

Барлык тереклек ияләре арасында кеше үзенең ике аякка басып йөри алуы, корал җитештерә алуы белән генә түгел, билгеле бер тәртиптә җайланган тавыш сигналлары ярдәмендә үзара аралаша алуы белән дә аерылып тора. Кешенең сөйләшә алу сәләте — тел ул табигатьтә тиңдәше булмаган бер күренеш.

Ничек ирешкән адәм баласы мондый сәләткә? Каян, кемнән өйрәнгән ул моңа яисә ничек, нинди шартларда иҗат иткән ул аны? Иң беренче тел, иң беренче сүзләр, иң беренче мәгънәле авазлар нindирәк булган?

Фән исбат иткәнчә, кеше маймулдан яралган. Физик кыяфәте белән төрле расадагы, төрле типтагы кешеләрнең барысының да бик борынгы ата-бабалары приматларның нindидер аерым бер төренә барып тоташа. Җирдәге барлык раса кешеләре биологик яктан бертуганнар.

Бүгенге көндә төрлечә яңгырый торган, төрле юнәлештә үсә торган күп төрле телләрне без кеше иҗат иткән уртак хәзинә дип таныйбыз. Шуңа күрә «һинд-европа» телләренә кагылышлы тел законнары бер төрле, Африка, Австралия яисә кытай, япон телләренә кагылышлы тел законнары икенче төрле була алмый дигән караштa торабыз. Бу фикерне башкачарак итеп әйткәндә, «ата», «ана» терминнарына кагылышлы тел кагыйдәләре бер төрле, гади саннарга (аның да әле өчтән алып бишкә яисә тугызга кадәргеләренә) кагылышлы тел кагыйдәләре икенче төрле, фигыльләргә

яисә рәвешләргә кагылышлы тел кагыйдәләре өченче төрле була алмый. Әгәр тел җирдәге барлык раса, барлык «семья», «милләт» кешеләренә хас күренеш икән, димәк, аның башлангыч нормалары, башлангыч кагыйдәләре дә ниндидер уртак принципларга буйсынган булырга тиеш.

Телнең барлыкка килүе турыдан-туры кешенең барлыкка килүенә бәйле. Телдән башка кеше була алмаган кебек, кешедән башка тел дә була алмас иде дип уйларга кирәк. Шуңа күрә, үзеннән-үзе аңлашылганча, телнең ничек, нинди шартларда барлыкка килүе иң элек кешенең ничек һәм нинди шартларда барлыкка килүе белән бергә каралырга тиеш.

Әле күптән түгел генә кеше моннан бер миллион еллар элек барлыкка килгән дигән караш хакимлек итә иде. Инглиз галимнәре Луис һәм Мери Ликиләрнең, шулай ук аларның уллары Ричард Лики һәм башка галимнәрнең Көнчыгыш Африкадагы палеоантропологик табышлары мондый карашның бик үк дөрес түгеллеген күрсәтте. Хәзерге вакытта фәндә: кеше моннан 4—5 миллион еллар барлыкка килгән дигән караш өстенлек итә. Кеше моннан 3—4 миллион еллар элек ике аягына да басып, гәүдәсен төз тотып йөри башлаган, моннан 2 миллион еллар элек исә үз кулы белән төрле кораллар ясый башлаган дип уйланыла. Бүгенге типтагы «чын» кешенең нинди тармактан бүленеп чыгуы һәм ничегрәк формалашуы әле тиешенчә ачыкланып җитмәгән. Шулай да мондый типтагы кеше, күрәсең, моннан ике йөз мең еллар элек барлыкка килгәндер дигән карашлар бар.

Телнең нинди яралгыдан, нинди күзәнәктән оеша башлавын күз алдына китерү өчен без иң әүвәл кыргый табигатькә борылып карыйбыз. Төрле тавыш сигналлары ярдәмендә бер-берсенә хәбәр бирү барлык хайваннарга кошларга, хәтта балыкларга хас нәрсә. Бүгенге көндәге маймуллар да күп төрле тавыш сигналлары чыгара алалар. Мәсәлән, гориллалар 20 дән артык, шимпанзелар 30 га якын тавыш сигналы чыгара алалар. Ата маймул, азык тапкач, тавыш сигналлары ярдәмендә башка маймулларны ашарга чакыра. «Тоткында шимпанзелар «ярсу», «курку», «җылау», «көлү» h.б. тойгыларын белдерә алалар. «Җылаганда» алар күзләрен нычытып йомалар, һәм көчле тавыш белән кычкыралар, ләкин, кешеләрдән аермалы буларак, күзләреннән яшь чыкмый» дип яза Т.Д.Гладкова (Гла, 598 бит).

Монда без шимпанзенең «җылавына» игътибар итмәкче булабыз. Шимпанзе, шулай итеп, тоткында гына «җылый» икән, ләкин анда да аның күзеннән яшь чык-

мый. Димәк, кешенең күз яше түгеп җылавы аңа маймулдан күчмәгән. Кешенең шатланып, кычкырып көлүе дә, күрәсең, маймулдан калган мирас түгелдер. Күз яше чыгарып җылау да, көлү дә, аңлы тавыш сигналлары ярдәмендә «сөйләшә» алу кебек, күрәсең, кешенең иҗади казанышыдыр дип әйтергә була.

Табигатьтә бер нәрсә дә тик торганда гына, үзеннән-үзе генә үзгәрә алмый. Үзгәреш булсын өчен нindидер көчнең тәэсире булырга тиеш. Әгәр дә мәгәр моннан миллион еллар элек табигатьтә ниндидер көчле тәэсирләр булмаган булса һәм тормыш-яшәеш тыныч кына үз көенчә-агуын дәвам иткән булса, күрәсең, маймул организмында беркайчан бернинди үзгәреш тә булмас, җир йөзендә «кеше» дигән аңлы җан иясе дә барлыкка килмәс иде.

Кыргый табигатьтә барлык тереклек ияләре арасында яшәү өчен, нәсел калдыру өчен туктаусыз һәм аяусыз көрәш бара. Яшәү өчен көрәшнең бер формасы — азык табу мәсьәләсе. Бер төрле хайваннар, әйтик, бары үсемлек азыклары белән генә тукланалар, икенче төрле хайваннар үзләреннән көчсезрәк,ваграк җәнлекләрне аулыйлар. Маймуллар күбесенчә агач җимешләре, кош күкәйләре, вак бөҗәкләр белән тукланалар. Кайбер маймуллар үзләренә төрдәш булмаган бала маймулларны һәм үләксәләр дә ашый. Ләкин нигездә маймул ерткыч түгел. Маймул башка хайваннарга каршы аугa да чыкмый, үзара талашканда-сугышканда бер-берсен үтерү дәрәҗәсенә дә җитми. Маймуллар (аеруча шимпанзелар) тыныч холыклы һәм алар кешегә тиз күнегәләр.

Ләкин, белүебезчә, маймулдан яралган кеше ит ашый, бер-берсен үтерә. Кеше дөньяда иң яхшы аучы һәм сугышчы. Димәк, мондый «һөнәрләр» дә кешегә турыдан-туры маймулдан күчмәгән.

Миллион еллар буена маймул үзеннән көчлерәк дошманнар белән аяусыз көрәш алып барырга мәҗбүр булган. Ит ашарга яратучы ерткыч хайваннар тарафыннан җиңелеп, тәмам юкка чыкмас өчен ул, менә шул миллион еллар дәвамында, кулына таш, таяк тотарга һәм шуларны корал сыйфатында файдаланырга өйрәнгән. Миллион еллар дәвамында ул дошманнарының кыланышларын күзәткән һәм, дошманнары кебек үк көчле булу, ерткыч булу теләгенә бирелеп, ерткычларның кайбер гадәтләрен үзләштергән. Маймулда аучылык гадәтләренең барлыкка килүен һәм шул нигездә аның даими рәвештә ит азыклары белән туклана башлавын бары шулай гына аңлатып була. Ит ашау исә маймул-кешенең әкренләп аңы, психикасы һәм тышкы кыяфәте үзгәрүгә сәбәпче булган.

Кыргый табигатьтә маймуллар аерымланган төркем булып яшиләр. Бер төркемгә, гадәттә, ата маймул, юлбашчы маймул баш була. Ана маймуллар, аларның балалары һәм картлар берсүзсез юлбашчыга буйсыналар. Маймуллар гына түгел, кайбер башка хайваннар да аерымланган төркемнәрдә яшиләр яисә ел тәүлегенең билгеле бер вакытында көтү булып туплана алалар. һәр төркем шулай ук «юлбашчыга» буйсына. Мәсәлән, ат өерендә утызлап биянең бер «юлбашчысы» — өер айгыры була. Үз өерендә ул хаким санала.

Аерым төркем булып яшәүче хайваннарның, гадәттә, үзләренең туену җирләре була. Бер төркем икенче төркемне үз җиренә якын җибәрми. Бер үк төрдәге хайваннарның (әйтик, бу очракта маймулларның) күрше төркемнән аерылып чыккан ялгызаклары яңа төркемгә кабул ителергә мөмкин, ләкин төрдәш күршеләр күпләп килә-нитә калса, ике төркем арасында ызгыш-талаш барлыкка килә.

Аерымланып яшәүче маймуллар төркеме янында шул ук төрдәге башка маймул төркемнәре генә яшәмәгән, әлбәттә. Маймул төркемнәренең һәркайсы диярлек бүтән төрле ерткычлар, ерткыч көтүләре белән чолганып алынган булган. Маймул төркемнәренең һәркайсына һәр яктан һәрдаим куркыныч янап торган. Шунлыктан һәрбер аерымланып яшәүче төркем, кемнең кем булуына карамастан, үзенең күршеләрен дошман дип, үтерүче һәм харап итүче дип белгән.

Аңлы тавыш сигналлары бирү ысулы, безнең фикеребезчә, менә шундый аерымланып яшәүче төркемнәрнең берсендә барлыкка килгән. Ниндидер көрәш-сугыш вакытындамы, башка бер очрактамы ниндидер зирәк һәм сизгер маймулда очкын булып аң кабынган. Очкын ялкынга әйләнгән һәм, сүнмичә-сүрелмичә, безнең көннәргә кадәр килеп җиткән. Биологиядә «мутация» дигән термин бар. Мутацияне «буталу» дип атарга була. Мутация булганда көтелмәгән тышкы тәэсирләр аркасында организмда геннарның алдан билгеләнгән мәңгелек тәртибе үзгәрә. Шул нигездә бөтен организмда үзгәреш башлана. Мәсәлән, авыру тудыручы кайбер микробларга каршы берәр төрле даруны чамасыз кулллансаң, авыру тудыручы микробларда яңа сыйфат барлыкка килә. Микроблар көчәеп китәләр һәм аларга әлеге дару тәэсир итми башлый. Шул рәвешчә, микробларның яшәүчәнлеге көчәя. Менә тагын икенче бер мисал. Көчле радиация вакытында якын-тирәдәге тереклек дөньясына бик нык зыян килергә мөмкин. Бүгенге көндә без бу хакта бик күп ишетәбез, бик күп укыйбыз. Чернобыль атом электр

станциясендә авария булгач, якын тирәдәге тереклеккә, табигатькә бик зур зыян килә. Шул ук вакытта шунысы да мәгълүм булган: көчле радиация зонасына туры килгән һәм исән калган имәннәрнең яфраклары гадәттәге имәннәрнекеннән эрерәк, наратларның ылыслары гадәттәге нарат ылысларыннан зуррак һәм авыррак икән. Димәк, радиация тәэсирендә әлеге имәннәрдә һәм наратларда мутация дигән нәрсә барлыкка килгән дип әйтә алабыз.

Бик-бик ерак заманнарда да маймул организмында менә шуңа охшаш мутация барлыкка килгән дип уйларга кирәк. Мутация нәтиҗәсендә туган аң чаткысы кыргый маймулның геннар тәртибенә тәэсир иткән һәм «зарарланган» маймул табигатендә элекке хәленә кайтарып булмый торган үзгәреш башланган. Ләкин маймулдагы мутация, ихтимал, бер генә баскычлы булмагандыр сыман. Икенче төрле итеп әйткәндә, бер мәртәбә мутация булу белән генә кыргый маймул «сөйләшә» алу дәрәҗәсенә күтәрелгән аңлы маймулга әйләнә алмагандыр кебек. Аңлы маймулның барлыкка килүенә сәбәпче булган мутациягә кадәр дә, аннан соң да маймул организмына төрле көчләр тәэсир иткән булса кирәк. Бит миллион еллар дәвамында вулкан атылулар да, кояш активлыгының үзгәрүе дә, башка төрле бәла-казалар да күп булган. Шул ук вакытта маймулның ерткычлар белән яшәү өчен туктаусыз көрәш алып баруын да истән чыгарырга ярамый. Ни генә булмасын, маймулга һәм маймул-кешегә үз гомерендә үлем белән шактый күп очрашырга туры килгән. Шуларның барысы бергә маймулның кешегә әйләнүенә һәм аңлы тавыш сигналларының барлыкка килүенә сәбәпче булган да инде.

### 8. КЕШЕНЕҢ БАРЛЫККА КИЛҮЕ ҺӘМ ҖЫЛАН

Кыргый табигатьтә маймулны адым саен сагалап торган куркыныч дошманнарның да иң куркынычы җылан булган. Күпчелек ерткычлар бары көн яктысында гына актив. Караңгы төшү белән алар йокыга талалар. Маймул да көндез актив, төнлә йоклый. Җыланнарның төрлесе бар — кайберләре төнлә йоклый, кайберләре исә көндез йоклыйлар, төнлә активлашып китәләр.

Бүгенге көндә Җир шарында бик күп төрле җыланнар булуы мәгълүм. Тропикларда, эссе якларда алар аеруча күп һәм төрле. Җыланнар бик тиз хәрәкәтләнәләр, тиз арада җир астына кереп яшеренә алалар, суда йөзәләр, агач башларына шуышып менәләр, биек агач башларыннан сикереп төшәләр, ягъни «очалар». Зур җыланнар үзләренең

корбаннарын буып алалар һәм аларны бөтен килеш, тере килеш йотып җибәрәләр. Мондый җыланнар белән көрәштә маймул гына түгел, хәтта каплан, юлбарыс кебек ерткычлар да җиңелүгә дучар булалар.

Шулай итеп, җыланнан маймул көндез дә, төнлә дә, җир өстендә дә, агач башында да качып котыла алмаган дип әйтә алабыз. Белүебезчә, кеше бернинди сәбәпсез караңгыдан курка. Караңгыдан аеруча балалар курка. Менә бу генетик курку безгә бик борынгы ата-бабабыз Маймулдан, аның төнге ерткычлар белән очрашу-сугышу чорларыннан калган булырга тиеш дип исәплибез. Алай гына да түгел, бүгенге көндәге кешенең дини-мифик карашлары, гореф-гадәтләре, үлемгә, туугa һәм, гомумән, яшәешкә кагылышлы барлык фәлсәфәсе, күрәсең, бик ерак заманнарда ерткыч хайваннар, аеруча җылан белән аяусыз көрәш тәэсирендә формалашкандыр дип әйтәсе килә.

Менә бер мисал. Дөньядагы бик күп халыкларда: кеше үлгәч яңадан терелә дигән ышану бар. Мондый ышануның ничек һәм нинди шартларда барлыкка килүе тиешенчә исбат ителмәгән. Моны, гадәттә, динчеләр, хаким сыйныф вәкилләре уйлап чыгарган дип аңлаталар. Динчеләр хезмәт халкын хуҗагызга турылыклы булсагыз, тырышып эшләсәгез, теге дөньяда оҗмах булыр дип үгетләгәннәр дә, шуңа бәйле рәвештә үлгәч терелү бар дигән нәрсә уйлап тапканнар, имеш. Ләкин шунысы кызык, үлгәч терелү бар дигән карашка динчеләр һәм хаким сыйныф вәкилләре үзләре дә чын күңелдән ышанганнар. Шуңа күрә дә үлгән патшаларның каберләретөрбәләре җир өстендәге сарайлар кебек үк нык итеп, мәңгелек итеп эшләнгән һәм «теге дөньяда» бернинди кайгы-хәсрәт күрмәс өчен, әлеге җир асты сарайларына һәр төрле азык-төлек, савыт-саба, хәтта үтерелгән коллар, хезмәтчеләр, ат һәм арбалар салып калдырылган.

Үлгәч терелү бар дигән ышануның җеп очы турыданторы җыланга барып тоташа. Үзенең корбанын җылан, әйтелгәнчә, тере килеш, дөресрәге, буып үтерелгән килеш, бөтен килеш йота. Бүтән ерткычлар исә үз корбаннарының бугазын чәйниләр, канын эчәләр, эчен актаралар, кыскасы, талап-ботарлап бетерәләр. Моннан миллион еллар элек безнең булачак ата-бабабыз менә шушы дәһшәтле күренешләргә игътибар иткән. Үзенең якыны, туганы яки баласы маймулның бөтен килеш җылан авызына кереп юкка чыгуына да ул, билгеле, бик нык кайгырган, тик шулай да һәлакәткә юлыккан төрдәшенең ботарланмавын күреп, үз-үзен юатырга тырышкан. Ул аны кайчан да булса яңадан терелэчәк, кире кайтачак дип өмет иткән. Яңадан терелү-

не, кире кайтуны ул анадан бала туу рәвешендә күз алдына китергән. Бик ерак заманнарда маймул-кеше исә бала тууның физиологик сәбәпләрен аңлап җитмәгән, шуңа күрә һәр яңа туган бала аңа кайчандыр җылан авызына кереп киткән төрдәше (туганы, баласы) булып тоелган.

Тора-бара адәм баласы туу һәм үлем турында, ихтимал, дөресрәк тә фикер йөртә башлагандыр, ләкин ни генә булмасын, иң әүвәлге карашларыннан ул беркайчан да арынып җитә алмаган. Үлгән, үтерелгән яки ерткыч тарафыннан кабып йотылган кешенең сабый бала рәвешендә яңадан дөньяга тууының сәбәбен аңлату өчен аң үсешенең билгеле бер чорында «җан» дигән нәрсә уйлап табылган. «Җан»ның уйланып табылуын кешенең иң беренче һәм иң зур иҗади казанышы дип атарга була. Бик күп халыкларның дини-мифик карашларында икърар ителгәнчә, «җан»ны кешегә аллалар бирә. «Җан» бирүче алла гадәттә күктә, югарыда яши һәм еш кына ул Атабыз Кояш дигәнне белдерә. Җанны бирүче дә, алучы да — Алла. «Үзе бирде, үзе алды» диләр татарлар сабый бала үлгәч.

Шулай итеп, кешенең үлеме аның ерткыч тарафыннан ашалуына, тууы — ерткычның шәфкать күрсәтүенә һәм кабып йотылган корбанны «җан» рәвешендә кире кайтарып бирүенә тиңләштерелә икән. Алай гына да түгел, динимифик карашларда кешеләрнең (әйтик, ир белән хатынның) үзара мөнәсәбәтләре дә ерткычлык мөнәсәбәтләре — ашау һәм ашалу итеп карала. Бүгенге көндәге бик күп халыкларның өйләнешүгә кагылышлы йолаларында, гореф-гадәтләрендә менә шушы иң әүвәлге һәм иң примитив фәлсәфә үзенең тулы чагылышын таба. Шуның белән бергә, әлеге иң әүвәлге һәм иң примитив фәлсәфә телнең, гаиләнең, кешелек җәмгыятенең ничек һәм нинди шартларда барлыкка килүен ачыкларга да ярдәм итә.

Сүз уңаеннан шуны да әйтеп китик, этнографлар әлеге бу фәлсәфәнең серенә төшенә алмаганнар. Шунлыктан кешенең күп кенә йолалары, гореф-гадәтләре, дини-мифик карашлары бозып аңлатыла. Мисал өчен монда Америка галиме Л.Морганның матриархат, патриархат формацияләре турындагы теориясен искә төшерергә була. Морган уйлаганча, дөньяда иң әлек, имеш, аналар хакимлеге (матриархат), шуннан соң, имеш, аталар хакимлеге (патриархат) булган, патриархаттан соң, имеш, сыйнфый җәмгыять барлыкка килгән. Бу теория әле һаман үз көчендә кала бирә. Һич югы бездә шулай. Чынлыкта исә беркайчан беркайда матриархат җәмгыяте булмаган, чөнки дөнья ятылганда ук ирләр, аталар өстенлек иткән. Моның шулай икәнлеген тел фактлары да, этнография фактлары да раслый.

Бүгенге көнгәчә кешенең аңында һәм язма истәлекләрдә сакланып калган мифларда, легендаларда, ышануларда, сәнгать һәм фольклор әсәрләрендә дөньяның, кешенең, җир йөзендәге барлык җанлы-җансызның барлыкка килүе аллаларга, аларның шәфкатенә, миһербанлылыгына бәйле рәвештә аңлатыла. Борынгы шумер, мисыр, майя һ.б. халыкларның мифларында әйтелгәнчә, дөнья яратылганчы бөтен тирә-якта иксезчиксез су була. Суда бөек Ата белән бөек Ана гына була. Бөек Ата да, бөек Ана да җылан кыяфәтендә. Шул ук вакытта Ана — җир, Ата — су һәм күк.

Мифлар, легендалар нигезендә фикер йөрткәндә, кешенең беренче мифик ата-анасы җылан булган дип әйтергә була. Барлык халыкларда Җир, Су, Күк һәм шулай ук башка төр аллаларның күбесе җылан кыяфәтендә. Күк җисемнәре, табигать күренешләре — җылан. Әкиятләрдәге җир асты патшалары, кеше ашаучы диюләр, һәртөрле уңай һәм кире ияләр — барысы да җылан нәселеннән. Әгәр кеше Җир һәм Су җыланнарның баласы исәпләнелә икән, димәк, ул үзе дә җылан затыннан була түгелме соң? Татар әкиятләрендә, мәсәлән, хатын-кыз юха җыланга әверелә ала. Әкиятләрдә җылан кыяфәтле ирләр дә була. Кайбер халыклар ышануынча, кешеләрне, имеш, кайчандыр җылан йоткан, берәр батыр кеше җыланны җиңеп, аның корсагын ярган да, кешеләрне якты дөньяга чыгарган.

Җылан кыяфәтле аллалар, нигездә, ике төрле булалар. Аларның бер төрлесе кешеләргә һәрвакыт яхшылык эшли, икенче төрлеләре явызлык эшли. Җир — җылан, гадәттә, анага, хатын-кызга тиңләштерелә. Бик борынгы кешенең аңлавынча, ананың, хатын-кызның табигате каршылыклы. Ана буларак, ул — тудыручы, нәселне дәвам иттерүче, хатын-кыз буларак — ашаучы, харап итүче. Җир һәм хатын-кыз, гадәттә, үлем белән, торгынлык, караңгылык, салкынлык белән, су һәм күк, ир кеше активлык, җылылык, яктылык белән тиңләштерелә. Борынгы кытай натурфилософиясендә, мәсәлән, бу хакта ап-ачык әйтелә.

Бик борынгы кешенең җыланга, тууга-үлемгә, атагаанага булган фәлсәфи карашлары аеруча аның телендә чагыла. Югарыда сөйләгәннәргә нигезләнеп, шуны әйтергә була: кешенең маймулдан аерылуында һәм иң беренче мәгънәле тавыш сигналларының, ягъни телнең барлыкка килүендә җыланның роле зур булган. Тел бер үзәктә, аерымланып яшәүче бер коллективта, бер үк төрле дини-мифик карашлар җирлегендә барлыкка килгән. Бу уңайдан атаклы инглиз этнографы Дж.Фрезерның сүзләрен искә төше-

реп китәсе килә. «Борынгы кешенең тарихын өйрәнү безгә шуны күрсәтте: үзенең иң әүвәлге һәм бик үк җитлекмәгән тормыш фәлсәфәсен булдырганда төрле илләрдә һәм төрле гасырларда кешенең рухи дөньясы (кайбер әһәмиятсез тайпылышларны исәпкә алмаганда), искиткеч дәрәҗәдә бер төсле булган» ди инглиз этнографы (Фре, 8 бит).

## 8. СУЗЫК ҺӘМ ТАРТЫК АВАЗЛАР. ТАМЫР ҺӘМ КУШЫМЧА. МӨСТӘКЫЙЛЬ МӘГЪНӘЛЕ ИҢ ГАДИ СҮЗЛӘР

Мәгълүм булганча, тел сүзләрдән, сүз авазлардан тора. ГДРда игълан ителгән мәгълүматларга караганда, Җир шарында 5651 тел бар икән. Менә шул телләрнең барысында да кулланыла торган сүзләрнең гомуми саны бик күп булырга тиеш. Ләкин сүзләр чиксез күп булса да, сүз ясаучы авазлар саны чагыштырмача бик аз. Һәрбер телдә уртача 30—40 аваз бар дип исәпләнелә. Сузык авазлар тартыклардан өч-дүрт мәртәбә кимрәк. Кайбер телләрдә тартыклар һәм сузыклар уртача нормадан йә бик югары, йә бик түбән. Кавказ телләреннән кабарда телендә 48, адыгей телендә 55, абхаз телендә 67 тартык бар. Дөньяда иң күп тартыклары булган тел — убых теле. Бу телдә 82 тартык бар икән. Шул ук вакытта убых телендә 2—3, абхаз, абазин телләрендә икешәр генә мөстәкыйль сузыклар булуы мәгълүм.

Полинезия телләрендә тартыкларга караганда сузыклар күбрәк кулланыла. Көнбатыш Европадагы баск телендә сузыклар саны унөчкә җитә. Татар телендә 10 сузык бар дип язалар китапларда. Чынлыкта татар телендә тугыз сузык бар: *а, ә, о, ө, у, ү, ы, э, и*.

Гамәлдәге тел гыйлеме өйрәткәнчә, сүзләр тамырга һәм кушымчага бүленә. Татарча *таш* сүзенә *чы* иҗеге кушып *ташчы* сүзе ясасак, *таш* — тамыр, *чы* кушымча була. *Балык-чы, тимер-че* дигәндә дә *чы-че* иҗекләре кушымча ролен үтиләр. Шул ук *чы* иҗеге булган *кам-чы, там-чы* сүзләрен алып карасак, *чы* кушымча булган очракта, *кам* белән *там* ни? Бүгенге тел гыйлеме өйрәткәнчә, тамыр сүзләр дә, кушымчалар да элек ниндидер мөстәкыйль мәгънәле сүзләр булганнар. *Ташчы, балыкчы* кебек сүзләрдә *таш* һәм *балык* сүзләренең мөстәкыйль мәгънәле берәмлек булулары үзеннән-үзе аңлашылып тора. Ләкин *камчы, тамчы* сүзләрендәге *кам, там* иҗекләренең һәм шулай ук *чы* кушымчасының ниндирәк мөстәкыйль мәгънәләре булды икән соң?

Тамыр сүз билгеле бер тәртиптәге һәм билгеле бер сандагы авазлардан тора дип исәпләнелә. Төрки телләрдә,

мәсәлән, Н.А.Баскаков фикеренчә, тамыр сүз тартык-сузык-тартык (ТСТ) тәртибендәге өч авазлы морфемадан гыйбарәт. Татарча *баш, таш, сук, йук* кебек сүзләр шушы ТСТ калыбына туры килә. Ләкин телдә бер, ике авазлы сүзләр дә очрый. Мондый сүзләрне Баскаков өч авазлы тамыр сүзләрдән кыскарган дип фикер йөртә. Татарча *су* рәвешендә әйтелә торган сүз куманды телендә *суг*, борынгы төрки телдә *суб*, үзбәктә *сув*, карай телендә — *суй*. Димәк, татарча *су* да кайчандыр *суб, суг, суй* кебегрәк булган дип әйтергә нигез бар кебек.

Төрки сүзенең бүленми торган, таркалмый торган иң беренчел күзәнәген, бүгенге тел гыйлемендә кулланыла торган термин белән әйткәндә, «тамыр морфемасын» ТСТ рәвешендәге өч аваздан, өч элементтан тора дип исәпләү бернинди логикага, бернинди дәлилләүгә нигезләнмәгән. Гап-гади арифметикада өчне өчкә дә, икегә дә бүләргә була. Шуңа күрә телнең иң әүвәлге мәгънәле кисәкләрен эзләүне өчтән түгел, бәлки бердән башлауны дөресрәк булыр дип исәплибез.

Телдә бер генә аваздан торган мәгънәле сүзләр булырга мөмкинме соң? Бик мөмкин! *А, у, о, ы, и, ө, э* кебек сузыкларны төрлечә әйтеп карасагыз, моңа ышануы кыен булмас. Дөрес, татар телендә, әйтик, *а, и* сузыкларыннан гына торган мөстәкыйль сүзләр юк. Ләкин сөйләшкәндә без сүз арасына еш кына ялгыз сузыклар кыстырабыз һәм шуның ярдәмендә күп кенә хис-тойгыларыбызны белдерә алабыз. Татар теле диалектларында ялгыз сузыклардан гына торган тулы мәгънәле мөстәкыйль сүзләр дә очрый. Гәйнә татарлары «ул» алмашлыгын *у* диләр. Мишәрләр һәм шул ук Гәйнә татарлары «өй» диясе урында *ү* диләр.

Бүтән телләргә мөрәҗәгать итсәк, бер сузыктан гына торган сүзләрне күпләп табарга мөмкин булачак. Борынгы кытай теленең инь чорында *и* сузыгы «шәһәр» дигәнне, борынгы кытай телендә *у* сузыгы «биш» дигәнне белдергән. Шумер телендә *ә* сузыгы «өй» дигәнне аңлаткан. Яңа Гвинеядәге бонгу телендә *и* сузыгы «су» мәгънәсенә туры килә.

Бер авазлы сүзләр турында сөйләгәндә шуңа да игътибар итәргә кирәк: бер генә сузыктан торган мөстәкыйль сүзләр булса да, бер генә тартыктан торган мөстәкыйль мәгънәле сүз юк һәм була да алмый. Тартык аваз мәгънәле сүзгә әйләнсен өчен аның янында — йә алдында, йә артында берәр төрле сузык аваз булырга тиеш.

Кагыйдә рәвешендә шуны әйтә алабыз: тулы мәгънәле сүз бер генә аваздан да ясала ала. Иң гади, мөстәкыйль сүз шулай да ике аваздан тора.

## 9. ИҖЕК ҺӘМ АНЫҢ ИКЕ ТӨРЕ

Ике аваздан торган мөстәкыйль сүзләр яисә иҗекләр ике төрдә булалар. Беренче төр: тартык авазлар беренче, сузык авазлар икенче урында килә (ТС). Мәсәлән, *бу, ба, бе, су, са, си*. Икенче төр: сузык авазлар беренче, тартык авазлар икенче урында килә (СТ). Мәсәлән, *ат, эт, ит, ут*.

Шушы төр иҗекләрнең кайсы беренчел, кайсы икенчел? Шуны ачыклап буламы? Була. Алфавит уйлап табылганчы кулланылган борынгы язу системаларының барысы диярлек иҗекле принципка нигезләнгән. Иҗекле язу системаларында «хәрефләр» хәзергечә *а, б, в, г...* дип түгел, бәлки *бе, ве, ге* дип язылган һәм укылган. Белүебезчә, гарәпчә-татарча әлифбада хәрефләрнең үз исемнәре булган һәм аларның күбесе ТС төрендәге иҗекләрдән гыйбарәт. Мәсәлән, *би, ти, си...* Әле дә без тартык белдерүче авазларны, *бе, ве, ге* рәвешендә әйтәбез.

Язу тарихы белгече, немец галиме И.Фридрих «примитив» кешенең сүзләрне иҗекләргә тарката алуы һәм бер дә юктан иҗекле язу уйлап табуы дөньяда бик зур ачыш булган дип исәпли. Язуда тартыкларны чагылдыру исә тагын да зуррак ачыш булган, имеш (Фри, 30—47 битләр). Иҗекләрне, тартыкларны язуда чагылдыру, чыннан да, зур ачыш булгандыр, бәлки. Монда безне икенче нәрсә кызыксындыра. И.Фридрих фикеренчә, дөньяда иң беренче, иң әүвәлге сүзләр берничә иҗекле булган булып чыга. Фридрих исәпләвенчә, иҗекле язу уйлап тапкан заманнарда борынгы кеше нәкъ менә шул берничә иҗектән торган сүзләрне аерым-аерым иҗекләргә таркатырга өйрәнгән дә инде. Борынгы кеше белән чагыштырганда бүгенге кешеләр, аеруча тел галимнәре әллә кайда белемлерәк тә, зирәгрәк тә, тик шулай да нишләптер әлегәчә сүзләрне дөрес итеп иҗекләргә дә бүлә алмыйлар һәм телнең ничек туып нинди шартларда, нинди юнәлештә үсеп-тармакланып китүен дә тиешенчә аңлата алмыйлар. Иҗекле язу уйлап тапкан заманнарда яшәгән бик борынгы «галимнәр», шулай итеп, бүгенге галимнәрдән акыллырак, зирәгрәк булдылар микәнни соң?

Безнеңчә, «примитив» кеше беркайчан да күп иҗекле сүзләрнең иҗекләрен таркату белән шөгыльләнмәгән. Дөнья яратылганда ук аның аңында иҗек төшенчәсе яшәгән. ТС төрендәге иҗек бик борынгы кеше өчен иң изге һәм бөек мәгънәгә ия булган. Җир йөзендә язу системалары моннан биш-алты мең еллар элек кенә уйлап табылган. Бу вакытта иҗекләрнең әүвәлге мәгънәләре, күрәсең, әле онытылып бетмәгән һәм төрле төбәктә бар-

лыкка килгән иҗекле язу системаларында менә шул борынгы карашлар, борынгы мәгънәләр чагылыш тапкан да инде. Алфавит барлыкка килгәч исә, иҗекләрнең әйтелеше сакланса да, «иҗек чоры» турындагы карашлар инде, күрәсең, онытыла башлаган.

Шулай итеп, телнең иң беренче мәгънәле күзәнәге (бер сузыклы иҗекләрне исәпләмәгәндә), *ба, бе, бу, би* рәвешендәге, ТС төрендәге ике авазлы иҗектән гыйбарәт дип әйтә алабыз. Барлык телләрдәге барлык сүзләр ТС төрендәге бер яисә берничә иҗектән ясалган. Бер сузыклы иҗекләрне тулы булмаган иҗек дип беләбез, шунлыктан бу очракта аларны исәпкә алмыйбыз.

Сузык-тартык (СТ) төрендәге иҗекләр мәсьәләсенә килгәндә, мондый иҗекләр икегә бүленә. Мәсәлән, *ат, эт, ит* кебек иҗекләрне *а-т, э-т, и-т* рәвешендә икегә таркатабыз. Таркатылган сузык һәм тартык авазларны кайчандыр тулы килеш кулланылган ТС төрендәге иҗекләрнең калдыклары дип исәплибез. Мәсәлән, *ат* сүзенең тулы әйтелеше элек *(т)а-т(а)*, ит сүзенең тулы әйтелеше *(т)и-т(и)* булган дип фараз кылабыз. Әлеге мисалларда җәяләр эченә алынган тартык һәм сузык авазлар шартлы рәвештә тәкъдим ителә. Ягъни *ат* һәм *ит* кебек сүзләрнең әүвәлге әйтелеше *тата, тити* дә, *сата, сити* дә һәм башкача да булган булырга мөмкин. Шуны да онытмаска кирәк, бу — теориядә шулай. Конкрет алганда, практикада *ат, ит* кебек сүзләрнең, һичшиксез, *тата, тити* булган булуы һич тә мәҗбүри түгел. *Ат, ит* кебек сүзләр барлыкка килгәндә үк инде шул рәвештә булган һәм шул рәвештә кулланылган булырга мөмкин.

Нәтиҗә ясап шуны әйтергә була: сузык-тартык калыбындагы кыска сүзләр чынлыкта бер иҗекле түгел, бәлки, ике иҗекле икән.

Шушы кагыйдәләрне истә тоткан хәлдә без теләсә нинди телдәге теләсә нинди «бозылган» сүзнең әүвәлге формасын һәм мәгънәсен ачыклый алабыз. Дөрес, монда әле тагын күп кенә башка нәрсәләрне дә күз алдында тотарга туры киләчәк.

### 10. ТС ТӨРЕНДӘГЕ ИҖЕК ҺӘМ АНЫҢ ТӨРДӘШЛӘРЕ

Телнең иң кечкенә мәгънәле күзәнәге ТС төрендәге бер иҗеккә кайтып калса да, аның үзенең күп төрле вариантлары бар. Мәсәлән, *б* тартыгы янына, әйтик, татар телендәге барлык сузыкларны язып чыксак, *ба, бә, бо, бө, бу, бү, бы, бе, би* иҗекләре ясарга була. Татар телендә уртача 20 тартык бар дип исәплик. 20 тартыкны 9 су-

зык белән әйткәндә 180 варианттагы мәгънәле иҗек (сүз) барлыкка киләчәк.

Без мәгънәле иҗек яисә мәгънәле сүз дип атаган менә шушы иҗекләр шулай да нәрсә аңлаталар икән соң? Һәрбер иҗекнең үзенә генә хас мәгънәләре бармы, әллә соң монда да уртак күрсәткечләр табарга мөмкин микән?

Хәзер без бары исемнәр турында гына сүз алып барабыз. Татар телендә ТС төрендәге бер иҗекле исемнәрдән *су, бу, би* сүзләрен генә күрсәтергә була, ахрысы. Әгәр башка телләргә мөрәҗәгать итсәк, үзебезне кызыксындырган мисалларны шактый күпләп табарга булыр иде.

Мәсәлән, башка телләрдә *ба* тибындагы иҗекләр (сүзләр) һәм аларның мәгънәләре: бамана телендә ба «хатын», бамбарада *ба* «ана», манинка телендә *ба* «ана», ну телендә *ба* «хатын-кыз», чжуан телендә *ба* «хатын», ненец телендә *йа* «җир», бамилеке, бенгал, кытай, малайа, Тибет телләрендә *ма* «ана», вепса, манси телләрендә *ма* «җир», баганда телендә *на* «ана», борынгы япон, манчжур, нанай, ороч, уде, ульча телләрендә *на* «җир», тибет телендә *са* «җир», борынгы мисыр, мяо III телләрендә *та* «җир» дигәнне белдерә.

Шулай итеп, *ба* тибындагы иҗекләр (сүзләр) күп кенә телләрдә җир, ана, хатын, хатын-кыз дигән мәгънәләрне аңлата икән дип әйтә алабыз. Борынгы дини-фәлсәфи карашлар нигезендә җир, ана, хатын, хатын-кыз төшенчәләренең капма-каршысы — су (күк) ата, ир һәм ир кеше. Мондый мәгънәдәге иҗекләр (сүзләр) *бу, су му, ту* рәвешендә ясала. Түбәндә шуңа мисаллар китерелә: удмурт телендә *ву* «су» дигәнне, япон телендә *йу* «җылы су», ну телендә *лу* «ир», асмат, ассирия-вавилон, XVIII династия чоры борынгы мисыр, солон, эвенки телләрендә *му* «су», селькуп телендә *ну* «күк», дун, корей телләрендә *пу* «ата», корей, татар, телугу телләрендә *су* «су», маори телендә *ту* «ир кеше», япон телендә *тү* «күк», инь чорындагы борынгы кытай телендә *фу* «ата» дигәнне белдерә.

Югарыда без бары *а* һәм *у* сузыклары белән ясалган сүзләргә генә игътибар иттек. Мәгънәле сүз (иҗек) ясауда *а* һәм *у* сузыклары гына түгел, бүтән төрле иҗекләр дә актив катнашалар. Ләкин аларның барысының да төп эчтәлеге җир-су (күк), ата-ана төркемендәге мәгънәләргә кайтып кала. Шунлыктан барлык сузыкларны икегә — *а* һәм *у* төрләренә бүлеп карыйбыз. Татар теле турында сүз барганда, *ә, ы, ә* сузыклары *а* төренә карыйлар, һәм *ба* тибындагы иҗекләрнең эчтәлегенә туры килә торган мәгънә белдерәләр. *Ү* һәм *и* сузыклары исә *у* төренә карыйлар һәм *бу* тибындагы иҗекләрнең эчтәлегенә тәңгәл

килә торган мәгънә белдерәләр. *О* һәм *ә* сузыкларының позициясе тотрыксыз. Бу сузыклар бер очракта *у* сузыгына, икенче очракта *а* сузыгына туры килә торган мәгънә белдерә алалар.

Татар теле өчен яраклы кагыйдә *а* һәм *у* сузыклары булган барлык телләргә карата кулланыла ала. Әйтелгәнчә, кайбер кавказ телләрендә икешәр-өчәр генә мөстәкыйль сузыклар бар. Телдәге иң әүвәлге мәгънәләр бары *а* һәм *у* сузыклы иҗекләр ярдәмендә генә белдерелгәнлектән, бүгенге көндә сузыкларга ярлы телләр яңа сүз ясауда һәм, гомумән, катлаулы фикерләрне чагылдыруда бернинди кыенлык кичермиләр. Сузыкларга ярлылык тартыкларга булган байлык белән һәм, киресенчә, тартыкларга ярлылык сузыкларга булган байлык белән төрләндерелә һәм тигезләштерелә.

Түбәндә *а* һәм *у* сузыклары төренә карый торган башка сузыклар ярдәмендә ясалган бер иҗекле сүзләргә мисаллар тәкъдим ителә.

Борынгы япон, кхмер телләрендә *ме* «хатын-кыз», вьетнам, лаос, тай, чжуан телләрендә *ме* «ана», ну, мяо IV телләрендә *те* «җир» дигәнне белдерә. Энче телендә *би* «су», алур телендә *пи* «су», лаши телендә *чи* «су», борынгы кытай телендә *ши* «ир кеше», манинка телендә *җи* «су» дигәнне белдерә.

Җир һәм Су (Күк), Ата-Ана төшенчәләрен аңлатучы иҗекләр мисалында телнең бик әһәмиятле бер үзенчәлеге ачыклана. Иң әүвәлге сүзнең (иҗекнең) төп мәгънәсе белән, компаративистлар уйлаганча, тартыклар түгел, бәлки сузыклар идарә итә. Тартыктан соң килүче сузык үзгәрмәсә, иҗек башындагы тартык үзгәрү белән генә сүзнең төп мәгънәсе үзгәрми*. Моның шулай икәнлеген башка төрле мисаллар белән дә исбатлап була. Мәсәлән, Исландиядәге елга исемнәренең азагына, *бау, сау, тау, рау, гау, кау* рәвешендәге өстәмә иҗекләр ялгана. Бу иҗекләрнең баштагы тартыклары төрлечә әйтелештә булса да, әлеге өстәмә иҗекләрнең барысының да әүвәлге мәгънәләре «су» төшенчәсенә кайтып кала. Төрки елга исемнәре азагына да еш кына өстәмә иҗекләр ялгана. Бу өстәмә иҗекләр күбесенчә *сай* рәвешендә була. *Сай* борынгы төрки телдә «су», «елга» дигәнне белдергән. *Сай*ның *чай, шай, тай, къай-кәй* вариантлары да очрый. Волоф телендә бер үк мәгънә бел-

* Төрки телләрдә һәм кайбер башка телләрдә л, р, (ихтимал, шулай ук н) тартыклары һәрвакытта да бу кагыйдәгә буйсынмыйлар. Мәсәлән, бу телләрдә ла һәм ра иҗекләре «кояш» дигәнне белдерә. Кояш исә, борынгы карашлар нигезендә, ата да, ана да була ала.

деручe алмашлыклар берничә төрле тартыкка башлана ала. Мәсәлән, беренче дәрәҗәдәге күрсәтү алмашлыгы берлектә *бии, тии; җии, кии, лии, мии, сии, вии* төрләрендә кулланыла. Төрле тартыкка башланган бу алмашлыкларның һәркайсының мәгънәләре бер үк.

Иҗекнең төп мәгънәсен сузык авазлар гына үзгәртә дигән кагыйдә бары тик ялгыз сүзләргә (иҗекләргә) карата кулланганда гына һәм иҗекләрнең беренче мәгънәләрен ачыкларга кирәк булганда гына дөрес булачак. Ни өчен дигәндә, бүгенге телләрдәге сүзләрнең күпчелеге бер генә иҗекле түгел һәм аларның конкрет мәгънәләре дә чиксез күп.

Иҗекләрнең (сүзләрнең) мәгънәләрен төрләндерүдә тартыкларның да роле зур. Бит телдәге сүзләр, әйтик, Исландия елга атамаларының азагына ялгана торган *бау, сау, тау* яисә төрки елга исемнәре азагына ялгана торган *сай, чай* кебек сүзләрдән генә тормый. Мәсәлән, теоретик яктан *ба* да «җир», *та* да «җир», *са* да «җир». Бик борынгы заманнарда бер кабилә җирне *ба* дип, икенче кабилә *са* дип, өченчесе *та* дип атаган. Боларны без шартлы рәвештә *ба кабиләсе, са кабиләсе, та кабиләсе* дип атый алабыз. Әйтик, *ба кабиләсендә* «җир» *ба* булса, *са* — «ана», *та* — «хатын-кыз» була ала. *Са кабиләсендә* исә «җир» *са* дип аталса, *ба* — «ана», *та* — «хатын-кыз» була ала.

Күрәсез, бер үк типтагы иҗекләрдән төрле төшенчә аңлаткан сүзләр дә ясала, шул ук вакытта бик борынгы кешенең дини-фәлсәфи карашы да, мәгънәле сүз ясауда төп принцип та үзгәрешсез кала.

Вакыт үтү белән кешелек җәмгыяте дә үзгәргән: адәм баласының дөньяга карашлары киңәйгән, тирәнәйгән. Шул ук вакытта аның иҗекләр ярдәмендә үзенең фикерләрен, хис-тойгыларын чагылдыру мөмкинлеге дә арттаннан-арта барган. Ләкин *а* һәм *у* тирәндәге аерым сузыклардан яисә тулы иҗекләрдән торган сүзләр генә куллану кешенең ихтыяҗларына тулы җавап бирми башлаган. Тартык-сузык төрендәге иҗекләр ярдәмендә яңарак һәм катлаулырак төшенчәләрне белдерү өчен бөтенләй яңа чаралар кирәк булган. Шул рәвешчә, тел үсешендә яңа чор башланган.

Бу яңа чорның кайчан, кайда башлануын без, әлбәттә, берничек тә белә алмыйбыз. Ләкин дөнья телләренең бүгенге төрлелегенә нигезләнеп фикер йөрткәндә, тел үсешендәге мондый яңалыкның, хәтта сикерешнең булуы шиксез. Тартык-сузык авазлардан торган иҗекләр ярдәмендә яңа төшенчәләр белдерү тел үсешендә ике төрле юнәлештә барган.

Беренче юнәлеш. Яңа мәгънә белдерү өчен бер иҗеккә

икенче иҗек ялганып әйтелгән һәм шул нигездә ике иҗекле сүзләр барлыкка килгән. Ике иҗекле сүзләрдән соң өч, дүрт иҗекле сүзләр формалашкан.

Икенче юнәлеш. Яңа мәгънә белдерү зарурлыгы тугач, бер иҗеккә икенче иҗек ялганмаган, иҗекнең бары әйтелү рәвеше генә үзгәртелгән. Кытай теле һәм кытай теленә охшаган башка телләр башлыча шушы юнәлештә үскәннәр. Бүгенге кытай телендә, мәсәлән, *ма* иҗеге биш төрле рәвештә (тонда) әйтелә һәм биш төрле мәгънә белдерә ала.

Тел гыйлемендә агглютинатив һәм флектив дип аталган телләр, нигездә, беренче юнәлештә үскәннәр. Ләкин бу телләрдә дә кайчандыр бик ерак заманнарда иҗекләрнең әйтелү рәвешен (тонын) үзгәртеп яңа мәгънә ясау ысулы булган. Грамматика китапларында «басым» дип атала торган күренешнең сакланып калуы шул турыда сөйли дә инде. Мәсәлән, татар телендә *кара* сүзе ике төрле басым белән әйтелә һәм өч төрле мәгънә белдерә ала. Шул ук вакытта яңа мәгънәле сүзләр ясауда «басым» методы куллана торган кытай, вьетнам, лаос һ.б. телләрдә икешәр, хәтта өчәр иҗекле сүзләр дә очрый.

Шулай итеп, аз һәм конкрет мәгънәле иҗекләрдән күп иҗекле күп мәгънәле сүзләр ясауга күчү җиңел генә булмагандыр дип әйтә алабыз. Иҗеккә иҗек ялгау ысулы да, иҗекнең әйтелешен үзгәртү дә бер үк телдә бер үк дәрәҗәдә кулланылгандыр кебек. Аерылу, аерымлану шактый вакыт үткәннән соң гына барлыкка килгән, ахрысы. Берәүләргә иҗеккә иҗек ялгау, икенче берәүләргә бер үк иҗекләрне төрлечә тавыш белән әйтү ысулы җайлырак, отышлырак булып тоелган. Ләкин иң әүвәлге иҗекләр һәм аларның төп мәгънәләре барлык телләр өчен үзгәрешсез калган.

### 11. ИКЕ ИҖЕКЛЕ СҮЗ. ИКЕНЧЕ ИҖЕКНЕҢ МӘГЪНӘСЕ

Мәгънәсе билгеле иҗеккә без икенче бер иҗек ялгыйбыз. Ялганган иҗекнең мәгънәсен билгесез дип исәплибез. Мәсәлән, *ба* иҗегенең мәгънәсе билгеле. *Ба* ул — җир, ана, хатын-кыз. *Ба* иҗегенә *ла* иҗеген кушсак, *бала* сүзе барлыкка килә. Ялгыз килеш *ла* иҗеге дә *ба* иҗегенә тәңгәл һәм аларның мәгънәләре бер төсле була ала. Ләкин *бала* сүзендә *ла* иҗеге ба иҗегенә ялганып, буйсынып килә. Шунлыктан, аның әүвәлге мәгънәсе юкка чыкты дип фикер йөртәбез. Шулай да *бала* сүзендәге ла иҗеге конкрет нәрсәне аңлата соң? Монда логик фикерләү таләп ителә. Ләкин без, мәсьәләне тиешенчә ачыклау өчен, башка телләрдән алынган мисалларга мөрәҗәгать итмәкче булабыз.

Ерак Көнчыгыштагы ульча халкы үзен *нани* дип атый.

Ульча телендә *на* «җир», *ни* «кеше» дигәнне белдерә. *Нани* сүзенең киңәйтелгән мәгънәсе ульча телендә «җир — кеше» дип аңлаталар галимнәр. Нанай халкы үзен *наны* дип атый. Нанай телендә *на* «җир», *ны* «кеше» дигәнгә туры килә. Бу сүзнең дә мәгънәсе «җир — кеше» икән. Малайа халкы үзен *бумипутра* дип атый. Малайа телендә *буми* «җир», *путера* «ул» (угыл) дигәнне белдерә икән. Чилиның көнчыгышында яшәүче араукаңнар үзләрен *мапучи* дип атыйлар. Бу сүзнең мәгънәсе «җир уллары» икән. Борынгы Мисыр патшалары үзләрен Кояш улы дип исәпләгәннәр. Шулай ук борынгы Кытай императорлары да үзләрен Күк улы дип атаганнар.

Аерым кешенең, ыру-кабилә һәм халыкларның Җир улы, Су улы, Күк улы, Кояш улы була алулары күп кенә халыкларның мифологиясендә дә чагыла. Африкадагы ориша халкы үзен Олорун исемле күк алласының улы дип исәпли. Көньяк Америкадагы аймара халкының мифларында инкалар Кояш уллары дип атала. Казан татарлары элегрәк үзләрен шулай ук Кояш улы дип белгәннәр.

Кеше балчыктан ясалган дигән ышануда кешенең Җир улы булуы аеруча ачык чагыла. Мондый ышану бик күп халыкларда бар.

Тел һәм мифология фактларын күз алдында тотып фикер йөрткәндә, ульчаларның *нани*, нанайларның *наны* атамаларының мәгънәләрен «җир — кеше» дип түгел, бәлки «җир улы» дип аңлату дөресрәк булачак. Әйтик, нанай телендә *ны*, ульча телендә *ни* иҗекләре ялгыз килеш «кеше» дигәнне белдерсәләр дә, *на* иҗегенә ялганып килгәндә аларның мөстәкыйль мәгънәләре үзгәрә һәм *ни* дә, *ны* да «улы» дигәнгә туры килә.

Татарча *ба-ла* сүзен дә «җир улы» дип аңларга була. Ләкин бик борынгы кеше аңында «җир» белән «ана»ның бер-берсенә тәңгәллеген һәм еш кына бер-берсен алыштырып килә алганлыгын белгәнлектән, *бала* сүзен без «җир улы» дип түгел, «ана улы» дип аңлатабыз. Аннан соң, гомумән, баланы ана гына тапканлыгы һәркемгә мәгълүм нәрсә. Шул ук *бала* сүзе башка телләрдә бөтенләй икенче мәгънә белдерергә мөмкин. Мәсәлән, литва телендә *бала* «саз» дигәнгә туры килә һәм «җир улы» буларак аңлашыла.

Шулай итеп, ике иҗекле сүздәге икенче иҗекнең дә мәгънәсе табылды дип исәплибез.

Кагыйдә рәвешендә шуны әйтергә була: ике иҗекле сүзнең беренче иҗеге *а* сузыклы булса, икенче иҗек Җирнең, Ананың «улын» (баласын) белдерә. Ике иҗекле сүзнең беренче иҗеге *у* сузыклы булса, икенче иҗек. Суның (Күкнең), Атаның «улын» белдерә. Шул ук фикер-

не болай дип тә әйтергә мөмкин: ике иҗекле сүзнең төп мәгънәсе беренче иҗектә була. Беренче иҗеккә ялганып килгән икенче иҗек һәрвакыт ярдәмче рольне үти һәм үзенең мәгънәсе буенча кемнеңдер, нәрсәнеңдер «улы» (баласы) булуын чагылдыра. Ярдәмче рольдә килгән икенче иҗекнең чынлыкта кемне, нәрсәне аңлатуына карамастан, без аны һәр очракта «улы» дип атарбыз. Икенче иҗек *а* сузыклы да, *у* сузыклы да була ала.

## 12. ИКЕ ИҖЕКЛЕ СҮЗ. ТӨРЛЕ МӘГЪНӘДӘГЕ «ҖИР УЛЛАРЫ»

*Нани, бала* кебек сүзләр «җир улы», «ана улы» дигәнне аңлатсалар да, һәр очракта да «кеше», «ыру-кабилә», «халык» төшенчәләрен генә белдермиләр. Җирнең капма-каршысы булган Су да, Күк тә «җир улы» исәпләнә. Татарча *су* «җир улы» дигән мәгънәгә тәңгәл. Русча «су» *вода (вада)* дип атала. Сүзне *ва-да* дип таркатабыз һәм «*ва* улы *да*» дип аңлатабыз. Бу исә «җир улы су» булачак.

Татарча *таң*, русча *небо* сүзләре дә без тикшерә торган ике иҗекле Җир уллары рәтенә карыйлар. Күп кенә елга исемнәре дә «җир улы — су» рәвешендә ясалган. Мәсәлән, бездәге *Кама (Ка-ма)*, Африкадагы *Тана (Та-на)*. Балкан ярымутравындагы *Сава (Са-ва)*, Франциядәге *Сена (Се-на)* елгаларының исемнәре барысы да «җир улы — су» дигәнне белдерәләр.

Бик борынгы карашлар нигезендә, җир өстендәге, җир астындагы җанлы, җансыз нәрсәләр: таулар, ташлар, кыялар, кайбер казылма байлыклар, куышлар, чокырлар, куаклы агачлар, үләннәр — барысы да «җир уллары» исәпләнелә.

Шушы уңайдан *тау* һәм *тагъ* сүзләрен яңадан искә төшерәбез. Бу сүзләр *та-у* һәм *та-гъ* рәвешендә таркатыла. Сүзләрнең икесе дә «җир улы» дигәнгә туры килә. «Улы» төшенчәсен бер очракта *у* сузыгы белдерсә, икенче очракта *гъ* тартыгы белдерә. Бөтен аерма шунда гына, ягъни *у* сузыгыннан *гъ* тартыгы яисә *гъ* тартыгыннан *у* сузыгы ясалмаган.

Шунысы да игътибарга лаек, *дагъ* сүзе кырым-татар телендә «тау» да, «урман» да була ала. «Тау» белән «урман»ны бер үк сүз ярдәмендә белдерү бүтән телләрдә дә очрый. Мәсәлән, нивх телендә «урман» да, «тау» да *пал* дип, борынгы япон телендә *йама*, каннада телендә *мале*, карай телендә *тав* дип атала.

Чагыштырма-тарихи методка нигезләнгән тел гыйлеме *тау* белән *тагъ* сүзләренә ышандырырлык җавап таба алмаган кебек, кайбер телләрдә бер үк сүз ярдә-

мендә «тау» һәм «урман» төшенчәләрен белдерә алуга да җавап таба алмый. Моңа бары иҗек методы ярдәмендә генә дөрес җавап табыла ала. Бүгенге кеше өчен «тау» белән «урман»ның икесе ике нәрсә булып аңлашыла һәм аларның бер үк сүз белән аңлатылуы бары аптырау гына тудыра. Борынгы кеше өчен исә — «тау» да, «урман» да — Җир уллары, һәм аларның һәркайсының аерым атамасы булмау алар өчен табигый саналган.

Татарча *таш* шулай ук ике иҗекле «җир улы». Монгол телендә «таш» *тар* дип атала. «Таш» мәгънәсендәге *тар* төрки телләрдә дә очрый. Хәзерге *Ташкент* шәһәренең исеме Мәхмүт Кашгари заманында (моннан 900 еллар элек) *Тәркән* булган. Сүзнең *тәр* өлеше «таш» дигәнне белдерсә, *көн* өлеше (шулай ук ике иҗекле «җир улы») «шәһәр» мәгънәсен аңлаткан. Татарда каткан зур балчык кисәген һәм, гомумән, таш, балчык, оешкан кар кисәкләрен *кантар* дип атыйлар. Бу сүзнең *тар* иҗекләре шулай ук Җир улы — «таш» сүзенә тәңгәл.

Ике иҗекле «җир уллары»ның бүтән төрләренә мисал итеп татарча *ке-ше, ба-ка* тамилча *а-л* (кеше), русча *ле-с* (урман), *гора* (*га-ра* — тау), гарәпнеке дип уйланыла торган, ләкин чынлыкта төрки *къа-ла* (*шәһәр*) һ.б. сүзләрне күрсәтергә була.

## 13. ИКЕ ИҖЕКЛЕ СУ ҺӘМ КҮК УЛЛАРЫ

Ике иҗекле «су улы» мәгънәсендәге сүзләрнең беренче иҗеге *у* сузыклы, икенче иҗеге *а* сузыклы да, *у* сузыклы да була ала һәм «улы» дигәнне белдерә. Су хайваннарының барысы да — балыклар, кыслалар һ.б. «су улы» төренә карыйлар. Елгалар, коелар, суда үсә торган камыш, су үләннәре, су эчендәге утраулар — шулай ук «су уллары». Җир үзе дә «су улы» буларак аңлашыла. Татарча *җи-р*, русча «коры җир» *су-ша* ике иҗекле «су улы» буларак формалашкан. Шунысы кызык, Татарстанда *Суша* дип аталган елга да бар. Бер очракта (рус телендә) бу сүз «җир»не, икенче очракта (татар телендә) «елга»ны белдерә. Ләкин төрле телдә төрле мәгънә аңлатуларына карамастан, суша сүзе, әлбәттә, «су улы» булып кала бирә.

Татарстанда *Мишә* дип аталган елга бар. Мишә сүзен безнең галимнәр фарсыча бешә сүзеннән ясалган дип аңлаталар. Татарстандагы Мишә буйларына каяндыр иран телле кабиләләр килеп, әлеге елгага нишләп шундый исем куштылар икән дә, нишләп безнең халык бик җиңел генә үз елгасын фарсыча атый икән дип гаҗәпләнүчеләргә безнең галимнәр шулай ук бик җиңел генә җавап та бирәләр:

бик борынгы заманнарда безнең якларда, имеш, иран телле кабиләләр яшәгән. Мишә, имеш, шул заманнардан калган. Мондый аңлатманы исбатлау өчен бернинди ышандыргыч дәлил китерелми. Иң көчле дәлил шул — Мишә елгасы буенда элек, имеш, имән агачлары үскән, фарсыча «имән» *бешә* дип атала икән. Менә шуннан инде «имәнле елга» барлыкка килгән, имеш. Ләкин имән агачы Татарстанда Мишә буенда гына үсми. Елга буйларында чыршы, нарат, усак, юкә, шомырт агачлары да үсә. Әгәр дә мәгәр елга исемнәре яр буенда үсә торган агачлар исеменнән алына торган булса. Идел буеның ерып чыккысыз карурман белән капланган төбәкләрендәге барлык елгаларның һәркайсына «агач» исемнәре кушып чыкмаслар идемени?!

Төрле телләрдә «балык» атамалары, балык исемнәре дә еш кына ике иҗекле «су улы» рәвешендә ясалган. Мәсәлән, «балык» немецча *фи-ш*, кытайча *йу-й* маори, рапануи телләрендә *и-ка* дип атала. Балык исемнәреннән ике иҗекле «су улларын» — татарча *шу-кә*, русча *щу-ка*, татар теленең тобол сөйләшендәге *ту-гу (чөгә)*, русча *ки-т* сүзләрен күрсәтергә була.

«Күк улы» төрләренә карый торган ике иҗекле сүзләр формаль яктан «су улы»на тәңгәл. Шулай да «су улы» белән «күк улы»н аеруы читен түгел. Судагы бар нәрсә «су улы» булган кебек, күктәге бар нәрсә «күк улы» булып аңлашыла. Кошлар, әлбәттә, күк уллары. Мәсәлән, маори телендә «күгәрчен» *ку-ку* дип атала. Шул ук сүз (*куку*) суахили телендә «тавык» дигәнне белдерә. Татарча *кү-ке* «кәккүк» дигәнгә туры килә. «Каз» русча *гу-сь*, мальгаш телендә *ги-са*, «аккош» төрекчә *ку-гу*, Себердәге аз санлы кет телендә — *ти-х*.

Җил-давыл, буран кебек табигый күренешләр дә «күк уллары» исәпләнелә. Русча *ту-ча* (кара болыт), татарча *җи-л* шундыйлар рәтенә карый.

Ерткыч хайваннарның һәм йорт кошларының күбесе — «күк уллары». Мәсәлән, татарча *ку-й* (сарык), *бу-га* (нәсел үгезе), *бү-ре*.

Озын, төз кәүсәле, агачларның барысы да шулай ук — «күк уллары». Татарча *йү-кә*, русча *ли-па* (юкә), *ду-б* (имән) агачлары ике иҗекле «күк уллары»на мисал хезмәтен үти алалар.

Кыйммәтле, төсле металлардан алтын, көмеш, җиз, бакыр, бик борынгы карашлар нигезендә, шулай ук «күк улы» буларак формалашканнар. Шумер мифларында әйтелгәнчә, дөнья яратылганда күк гөмбәзе кургаштан коелган ярым шар рәвешендә булган, имеш. Шул гөмбәз астында Күк алласы белән Җир алиһәсе бергә ятканнар. Эн-

лил дигән алла, җиз пычак алып, күк гөмбәзенең кырыен кисеп чыккан. Шуннан соң күк алласы Ан, аягына баскан да, күк гөмбәзен югары күтәргән. Ан гәүдәсен турайтып, күкне күтәргәндә, кургаш күкнең кырыйлары җиргә коелып төшкән, имеш. Җирдәге кыйммәтле алтын-көмешләр, җиз, бакырлар менә шуның калдыклары икән.

Ике иҗекле «күк уллары» — металл исемнәреннән татарча *җи-з*, борынгы кытайча *ту-н* (бакыр) сүзләрен күрсәтергә була. Кайбер телләрдә «таш» та Күк улы буларак формалашкан. Африкадагы ингессана телендә «таш» мит дип атала. Монда, күрәсең, күктән төшкән «таш» күз алдында тотыладыр дип әйтергә була. Русча *медь* (бакыр) сүзенең дә әүвәлге әйтелеше *мит* булган булырга мөмкин. Маййа телендә «таш» һәм «кыйммәтле таш», кытайча «бакыр» кебек үк, *ту-н* дип атала һәм «күк улы» булып аңлашыла.

## 14. ӨЧ ИҖЕКЛЕ ҖИР УЛЛАРЫ

Өч иҗекле «җир уллары»нда *а* һәм *у* сузыклы иҗекләр өч төрле тәртиптә ялгана.

**Беренче тәртип**. Беренче иҗек *а* сузыклы һәм ялгыз килеш тә «җир» төшенчәсен белдерә. «Улы» — мәгънәсен белдерүче иҗекләрнең беренчесе *а* сузыклы, икенче иҗекнең тартыгы гына сакланып калган була, шуңа күрә аның нинди сузыкка тәмамлануын әйтеп булмый.

«Улы» мәгънәсен белдерүче *а-(а)* сузыклы иҗекләрнең төрле вариантлары булырга мөмкин. Төрле телләрдә еш очрый торган шундый «ул»лардан *ман-мән, мат-мәт, лат-ләт, сак-сәк, сан-сән* һәм аларның күп төрле фонетик вариантларын күрсәтергә була.

«Таш» русча *камень* дип атала. «Таш»ның башлыча «җир улы» булуын белгәнлектән, бу сүзне *ка-мень* дип таркатабыз. Татарча авырлы (булу), корсаклы (булу) мәгънәсендәге *көмән* сүзен *ке-мән* дип төзәтәбез һәм таркатабыз. Татарда *ө* сузыгы еш кына *э* сузыгын алыштырып килә ала. Мәсәлән, тезү-төзү, (йон) тетү-төтү һ.б. Формасы белән камень сүзенә туры килгән һәм «җир улы» булып аңлашылган ке-мән сүзен «ана улы» дип беләбез. Дәүләт исеме *Йә-мән* (русча *Йемен*), төрки «ун мең» *төмән* (ягъни *те-мән*) сүзләрендәге *мән* иҗекләре дә «улы» мәгънәсен белдерәләр.

«Улы» мәгънәсендәге *сан-сән, сын-сен, зан-зән, чан-чән* һ.б. иҗекләр дөньядагы бик күп телләрдә кулланыла. Татар телендәге аерым *сан* сүзенең берничә төрле мәгънәсе бар. *Сан-сән* иҗекләренең иң әүвәлге мәгънәсе

«кеше әгъзасы» булган, ахрысы. Әгъза буларак *сан* гадәттә аяк-кулны аңлата. Татарда «дүрт саным төгәл» дигән әйтем дә бар. *Сан*ның *сын* варианты рус телендә туры-дан-туры «ул», «угыл», «ир бала» дигәнне белдерә, «һинд-европа» телләре дип йөртелгән телләрдә *сан*ның *сон-зон* рәвешендәге әйтелешләре киң кулланыла. Мәсәлән, немец телендә *сон*, рус телендәге кебек, «ул», «угыл», «ир бала» дигәнгә туры килә. Дания, норвег телләрендә *сен* фамилия күрсәткече буларак кулланыла. Мәсәлән, *Амунд-сен, Эрек-сен,* Африкадагы гола телендә «өй» ке-сан дип, Башкортстандагы бер елга *Ба-зан* дип атала. Күп бәхәсләр кузгаткан *Казан* атамасы *Ка-зан* дип таркатыла.

Без тикшерә торган өч иҗекле «җир улы» төренә карамаса да, «улы» мәгънәсендәге *сан-сән* турында сүз чыккач, шушы уңайдан *Чирмешен* атамасын да телгә алып китәсе килә. Хәзерге Татарстанда, борынгы Болгарның үзәк җирләреннән ага торган Чирмешен елгасы исемен безнең галимнәр чирмеш һәм ән кисәкләренә таркатып, әлеге атаманы «чирмеш елгасы» дип аңлаталар. Мишә фарсыча бешәдән үзгәргән, дигәндәге кебек, «чирмеш елгасы»на нигезләнеп, монда җиңел генә нәтиҗә ясала. Чирмешән елгасы «чирмешләр елгасы» булгач, Чирмешән буйларында элек чирмешләр, ягъни марилар яшәгән булып чыга. Шул рәвешчә, компаративистларның телне аңлатудагы буталчык һәм ышанычсыз методлары телләр, халыклар тарихын бозуга киң юл ача. Борынгы Болгар, хәзерге Татарстан җирләрендә элекке заманнарда марилар яшәгән дигән караш, нигездә, менә шушы «Чирмешен — чирмешләр елгасы» дигән уйдырмага таяна. Бу исә, ахыр чиктә, безне хәтта борынгы Болгар җирендә дә килмешәкләр итеп күрсәтү өчен төп таяныч хезмәтен үти. *Чирмешән* сүзен *Чирмеш-ән* дип түгел, бәлки *Чирме-шән* дип таркатсак, *шән* иҗекләре *сан-сән* тибындагы «улы» булачак. Башкортстандагы (Чирмешәнгә аваздаш дип әйтерлек) *Чәрмәсән* елгасы исеменең азагындагы *сән* иҗекләре «шән»гә тәңгәл.

**Икенче тәртип**. Өч иҗекнең беренчесе *у* сузыклы, икенчесе *а* сузыклы. *Уа* рәвешендәге сузыклар икесе бергә «җир» төшенчәсен белдерәләр, «улы» мәгънәсендә килә торган өченче иҗек *а* сузыклы да, *у* сузыклы да була ала. Мәсәлән, татарча *җире-к* (әдәби телдә *зирек*), *җилә-к, җите-н, тирә-к* сүзләре.

Күп кенә елга, тау, авыл, шәһәр атамалары шушы тәртиптә ясалган. Мәсәлән, *Ура-л* (тавы), *Дуна-й* (елгасы). Татарча *куйан, киртә, чирә-м*, немецча «чия» *кир-ше*, русча «чия» *вишня*, татарча *тиме-р* сүзләре дә әлеге тәртиптәге «җир уллары» буларак формалашканнар.

## 15. ӨЧ ИҖЕКЛЕ ҖИР УЛЛАРЫ. «УЛЫ» МӘГЪНӘСЕН БЕЛДЕРҮЧЕ ИҖЕКЛӘРНЕҢ ӨЧЕНЧЕ ТӨРЕ

Өч иҗекнең беренчесе *а* сузыклы һәм ул, гадәттәгечә, «җир» төшенчәсен белдерә. «Улы» мәгънәсен белдерүче иҗекләр *уа* сузыклары ярдәмендә ясала. *У* һәм *а* сузыклары ярдәмендә ясалган һәм «улы» мәгънәсен белдергән сүзләрнең өч варианты мәгълүм.

**Беренче вариант.** Беренче *у* сузыклы иҗек тулы әйтелешле, ягъни иҗекнең тартыгы да, сузыгы да бар, икенче *а* сузыклы иҗек тулы булмаган әйтелешле. Мондый иҗекнең тартыгы йә төшеп калган яисә бөтенләй булмаган. Мәсәлән, латинча «су» *а-къуа* дип атала. Бу очракта *къуа* иҗекләре «улы» дигәнгә туры килә. Гавайи телендә «ата» *ма-куа* дип, урабунна телендә «кыз туган» *ка-куа* дип атала. Нигериядә *Бе-нуэ* дигән елга ага, Фил сөяге ярында *Вавуа*, Финляндиядә *Йе-пуа*, Италиядә *Ка-пуа* шәһәрләре бар.

**Икенче вариант.** «Улы» мәгънәсендәге беренче *у* сузыклы иҗек тә, *а* сузыклы иҗек тә тулы әйтелешле. Мәсәлән, японча «чия» *сакура* дип атала. Русча *виш-ня*, немецча *кир-ше* сүзләрен без әлерәк кенә «җир улы» дип аңлаттык. Башка телләрдә «чия» «җир улы» булгач, японча да ул шулай булырга тиеш дип беләбез. Шунлыктан *сакураны са-кура* дип таркату дөрес дип исәплибез. Татарча язылышта чия булган сүзнең дә мәгънәсе «җир улы», әйтелеше *че-йә* булырга тиеш.

*Кура-кула, гура-гула* һәм аларның фонетик вариантлары рәвешендә кулланылган «улы»лар төрле телләрдә сүз ясауда катнашалар. Мондый «ул»лар ярдәмендә ясалган атамалар төрле җирдә очрый. Мәсәлән, Чехословакиядә *Се-куле*, Анголада *Ка-кури* шәһәрләре, Пермь өлкәсендә *Ке-кур, Ба-гул* авыллары бар.

Мәсьәләгә теоретик яктан караганда, «улы» мәгънәсен белдерүче иҗекләрнең тартыклары төрле телдә төрлечә булырга мөмкин. Мәсәлән, татар теле диалектларында «бала» мәгънәсендә *тума* сүзе кулланыла. Шул ук мәгънәдәге сүз шумер телендә *думу* дип атала. Топонимиядә һәм кайбер телләрдә *тума-туна, мула-була* рәвешендәге «ул»лар ярдәмендә ясалган атамалар очрый. Мәсәлән, Грузиядә *Ба-туми*, Бирмада *На-буле*, Заирда *Фа-тума* атамалары бар. Грузин фамилияләрендә «кызы» дигән мәгънә *а-сули* сүзе ярдәмендә белдерелә. Латинча *аникула* «карчык» дигәнгә туры килә. Сүзне *ани-кула* рәвешендә таркатабыз һәм «әни улы», ягъни әнинең әнисе дип аңлыйбыз. Шулай ук латинча «бишек» — *куна-була*, «асрау кыз», «кол кыз» *фа-мула*, «күлмәк» — *ма-тула* дип атала.

**Өченче вариант.** «Җир» төшенчәсендәге иҗеккә ялганып килгән һәм «улы» мәгънәсен белдергән *кула-кура* кебек иҗекләрнең кыскартылган яисә фонетик яктан беркадәр үзгәргән *ула-уло, улы-уле, ура-ур, оло-ол, эла-эл* һ.б. әйтелешләре дөньядагы барлык телләрдә дип әйтерлек очрый. Моңа мисалларның исәбе-хисабы юк. Без монда аларның кайберләрен генә теркәп узмакчы булабыз.

Грузинча кеше исемнәре азагына *ур-ул-эл* иҗекләре ялгана. Бу иҗекләр кешенең кайсы ыру-кабиләдән булуын аңлата. Тунгус исемнәренең күбесе ул (уль) иҗекләренә тәмамлана. Гарәп теленнән кергән дип уйланыла торган кайбер татар исемнәренең азагындагы улла иҗекләрен дә шушы ук төрдәге «ул»ның бер вариатны дип карарга кирәк. Мәсәлән, *Гали-ул-ла, Вәли-ул-ла*.

Татарстандагы *Баулы* исемен *Бау-лы* дип түгел, *Ба-улы* дип таркату дөресрәк булачак. Пермь өлкәсе Суксун районында *Та-улы* авылы, Анголада *Та-ула* шәһәре бар. Кырымның көньяк яр буе элек *Та-ура* дип аталган. Русча бу сүзне *Тавры, Таврия* дип язалар. Малида *Ба-уле* дип аталган ике елга ага. Фил сөяге ярында *ба-уле* дигән халык яши. Уйгурча «тел», «сүз» — *ка-ул* дип атала. Ләкин моны да, гадәттәгечә, гарәптән алынган дип аңлаталар. Уйгурча *ка-ула* «яшелчә» була. Шул ук *ка-ула* латин телендә «баз», «чокыр» дигәнгә туры килә. XIII гасырда Кореяны Ка-уле дип атаганнар. Көньяк Кореяның башкаласы *Се-ул* буларак мәгълүм. Чилида *Ма-уле* дигән елга ага. Нидерландта *Ха-уле* шәһәре бар. Бретон телендә беренче зат алмашлыгы «мин» *э-ул* дип, яһүд телендә «тамуг» *ше-ол* дип, борынгы грекларның җир алласы *э-ол* дип, грекча «ишегалды», «утар», «түбәсе ябулы түрге зал», «сарай», «җир асты дөньясы» — *а-ула* дип атала. Латинча *а-ула* «чүлмәк» дигәнне аңлата. Латинча *аул-ула* дисәк, бу «кечкенә чүлмәк», ягъни «чүлмәк улы» булачак. Татарча *авыл* дип язылa торган сүзнең әйтелеше һәм дөресрәк формасы — *а-ул*.

## 16. ӨЧ ИҖЕКЛЕ СУ ҺӘМ КҮК УЛЛАРЫ

«Җир» мәгънәсендәге иҗекләргә «улы» төшенчәсен белдерүче ялгыз иҗекләр һәм шулай ук ике иҗекле сүзләр ялгана алган кебек, «су», «күк» мәгънәсендәге иҗекләргә дә шундый ук иҗекләр ялгана ала. Югарыда без «улы» мәгънәсендәге иҗекләрне шактый җентекләп тикшердек кебек. Шунлыктан монда «улы» иҗекләренә түгел, бәлки «су», «күк» төшенчәсендәге иҗекләргә генә игътибар итәчәкбез. Бу төр сүзләр ике тәртиптә ясала.

**Беренче тәртип.** Сүз башындагы беренче иҗек *у* сузык-

лы һәм ялгыз килеш тә «су» яисә «күк» мәгънәсенә ия. Калган иҗекләр «улы» төшенчәсен белдерәләр. Мәсәлән, бүгенге көндәге алтайлылар телендә «җиз» *ку-улы* дип, монголча «күл» *ну-ур* дип атала. Татарча *ту-зан, у-сак, и-мән* кебек сүзләр шушы ук тәртиптә ясалганнар. Көнбатыш Африкадагы бер халык үзен *ди-ула* дип исәпли, канада теленең халакка диалектында «күке» *ку-гула* дип атала. Угандада *Си-гулу* утравы, Танзаниядә *Ши-гури* шарлавыгы бар.

**Икенче тәртип.** «Су» һәм «күк» мәгънәсендәге сүзләр *а-а* яисә *а-у* иҗекләре ярдәмендә ясала. Өченче иҗек «улы» мәгънәсен белдерә. Мәсәлән, «җир» латинча *терра* (*тер-ра*) дип, хет телендә *текан* (*тека-н*) дип, немецча, *эрде (эр-де)*, русча *земля (зем-лә)* дип атала. Татарча күп кенә кош, балык, агач, исемнәре шушы тәртиптә ясалган. Мәсәлән, *балы-к, кыс-ла, кар-га,* русча «чәүкә» *гал-ка*. Озын, төз кәүсәле агачлардан татарча *нара-т, чыр-шы,* русча *сосна (сас-на)* — «нарат». Русча *акула* балыгының исемен *а-кула* дип таркатсак, бу «җир улы» булыр иде, ләкин балыкның бары «су улы» гына булганлыгын белгәнлектән, әлеге сүзне *ак-ула* дип таркатабыз. Бу инде чынлап та «су улы» булачак.

## 17. ДҮРТ ИҖЕКЛЕ СҮЗЛӘР

Сүзнең иҗек саны арта барган саен сузыкларның үзара чиратлашу тәртибе дә төрләнә. Шунлыктан тикшерелә торган сүзне дөрес бүлү кыенлаша. Шулай да, кемнең, нәрсәнең кем «улы» булырга тиешлеген яхшы белсәк, сүзнең «атасын-анасын» билгеләү җиңеләя төшә. Шул ук вакытта, иҗекләрне таркатканда, сүзнең бүгенге мәгънәсен дә исәпкә алырга туры килә. Мәсәлән, *камбала* да, *таракан* да *а-а-а-а* тәртибендәге иҗекләр ярдәмендә ясалган. Камбаланың «су улы» икәнлеге һәркемгә билгеле дип исәплик. *Таракан* «су улы» да, «күк улы» да түгел, «җир улы». Шулай булгач, бу ике сүзнең бүленеше дә ике төрле булачак. Балыкны *кам-бала* дип, бөҗәкне *тарака-н* дип бүләбез. Русча *медведь* («аю»), *человек* («кеше»), немецча *вассер* («су») сүзләре дә *тарака-н* тәртибендә ясалган дүрт иҗеклеләр рәтенә карыйлар.

Дүрт иҗекле сүзләрнең башкачарак тәртиптә ясалганнары да бар. Татарча «козгын» Чулым төркиләре телендә *кускун* дип атала. Сүзнең беренче *кус* иҗекләре «су улы җир» дигәнне белдерә, *кус-ку* исә «җир улы күк» булачак. *Куску-н* — Күк улы. Хотан-сак телендә «бүре» *бирггә* дип атала. Кошлар кебек бүре дә — Күк улы. Сүзне *бирг-гә* дип бүләбез һәм бу чыннан да *бү-ре* мәгънәсенә туры киләчәк.

## 18. КҮП ИҖЕКЛЕ СҮЗЛӘР ЯКИ СҮЗ АЗАГЫНДАГЫ ӨСТӘМӘ ИҖЕКЛӘР

Исландия, Финляндия, Швеция кебек илләрнең географик атамалары арасында алты-җиде, хәтта аннан да күбрәк иҗекләрдән торган сүзләр очрый. Нинди озын сүзләр соң болар? Төрле сүзлекләргә карамыйча да аларның мәгънәләренә төшенеп буламы? Югарыда без телнең башлангыч чордагы принциплары барлык телләр өчен дә уртак дигән фикер әйттек. Географик атамаларга карата кулланганда бу фикер ни дәрәҗәдә дөреслеккә туры килә? Белүебезчә, географик атамаларның бик зур күпчелеге — елга, тау, күл, авыл, шәһәр төшенчәләрен белдерә һәм алар азагына еш кына бер үк төрле стандарт иҗекләр ялгана.

Мәсәлән, Швециядәге күл атамалары азагына *йаурe* иҗекләре ялганган була: *Вастенъяуре* күле, *Мавасъяуре* күле һ.б. *Йауре* сүзен *йа-уре* дип таркатсак, бу «җир улы су» булачак. Димәк, швед телендә күл төшенчәсе «су улы» түгел, «җир улы су» рәвешендә формалашкан дип әйтә алабыз. Ләкин сүзне *йау-ре* дип таркатсак, бу инде «су улы» булачак.

Финляндиядәге күл исемнәре ахырына еш кына *йарви*, елга исемнәре ахырына *йоки* иҗекләре ялгана. Мәсәлән, *Илисуолиярви* күле, *Карвианйоки* елгасы. Финчә *йәрви* «күл», *йоки* «елга» дигәнне аңлата. Швециядәге һәм Финляндиядәге күл һәм елга атамалары азагына кушылган *яуре, ярви, йоки* кебек иҗекләрне өстәмә мәгънә белдерүче сүзләр дип әйтә алабыз. Исландиядәге елга атамалары азагына *сау, бау, тау, кау* кебек иҗекләр ялгануы һәм аларның барысының да «су» мәгънәсен белдерүе турында без инде сүз алып барган идек.

Өстәмә мәгънә белдерүче өстәмә иҗекләр шулай ук авыл-шәһәр атамалары азагына да ялганырга мөмкин. Германиядәге географик атамаларның азагында *дорф* (авыл), *штадт, бург* (шәһәр) кебек иҗекләрне очратырга була. Мәсәлән, *Дюссельдорф, Дармштадт, Гамбург*.

Төрки елга исемнәре азагына кайчагында *су* сүзе ялгана. Мәсәлән, Казакъстанда *Сарысу, Кызылсу, Аксу* елгалары бар. Кайбер елга исемнәре азагына *сай, чай, шай, тай* иҗекләре ялгана. *Сай* сүзе борынгы төрки телдә «су», «елга» дигәнне белдергән. Елга исемнәре азагына ялганган һәм «су» яки «елга» мәгънәләрен белдергән *сай-чай* сыман иҗекләрне бер-берсеннән бик ерак төбәкләрдә очратырга була. Лаос һәм Таиландтагы елга исемнәре азагында *сай, май, фай, рай,* иҗекләре бар. Таиландта, мәсәлән, *Бангсай (Бан̧, сай)*, Лаоста *Бангфай (Бан̧, фай)* исемле елгалар ага. Татарча авыл, шәһәр исемнәре азагында да өстәмә

иҗекләр табарга була. Минем туган авылым, мәсәлән, *Күчтәавыл* дип атала. *Күчтәавыл* исемен халыкта «Күчкән авыл» дип аңлаталар, ләкин ул чынлыкта «Күчкән авыл» түгел, бәлки *Күч-тә*, авыл булса кирәк. *Күчтәавыл* атамасының төп өлеше, шулай итеп, *Күчтә*, өстәмә өлеше — авыл» дип исәплибез. Бит телдә Күчтә дигән тау да, агач та, корал да, кеше дә, хәтта алла да булырга мөмкин. Борынгы сүз иҗат итүчеләр, күрәсең, менә шундый ихтималны күз алдында тотканнар һәм сүзләрне куллануда буталчык килеп чыкмасын өчен, төрле исем-атамаларга өстәмә мәгънә белдерүче өстәмә иҗекләр кушу ысулын уйлап тапканнар дип әйтәсе килә.

## 19. СҮЗ АЗАГЫНДАГЫ АРТЫК ИҖЕКЛӘР ЯКИ АРТЫК АВАЗЛАР

Бүгенге телләрдә барлык сүзләр дә һәр очракта саф «җир улы» яисә «су (күк) улы» рәвешендә генә кулланылмыйлар, әлбәттә. Бер очракта сүзләрнең әүвәлге әйтелешендәге кайбер авазлар, иҗекләр төшеп калса, икенче бер очракта төп мәгънә белдерүче сүзләргә өстәмә иҗекләр ялганырга мөмкин. Әле генә күреп киткәнчә, географик атамалардагы өстәмә иҗекләрне тану әллә ни кыен түгел. Алар, нигездә, бер үк формада булалар һәм еш кабатланалар. Аларның реаль мәгънәләре бар. Ләкин кайчагында сүзләргә бернинди мәгънәсе булмаган артык авазлар да, артык иҗекләр дә тагылып китәргә мөмкин. Мондый артык иҗекләр, авазлар сүзнең баштагы формасын һәм мәгънәсен бозып күрсәтә ала. Шулай да әйтергә кирәк, бу бары теоретик яктан гына шулай. Бит һәрбер сүз безгә кулланыштагы формасы һәм мәгънәсе белән якын һәм кадерле.

Мәсәлән, татарча *баш* сүзе руста *башка, малай* сүзе *малайка* рәвешендә кулланыла. Татар өчен *баш* һәм *малай* дөрес булган кебек, рус өчен *башка* һәм *малайка* дөресрәк һәм кулайрак. Ләкин без русчадагы *ка* иҗеген артык дип исәплибез. Русчадагы *ка* иҗегенең артыклыгын татарча *баш* һәм *малай* сүзләре белән чагыштырып та, бу сүзләрнең кем «улы» булуларын ачыклап та исбатларга мөмкин. Баш сүзенең кем «улы» булуын аңлату катлаулырак, шуңа күрә без монда әлеге сүзгә тукталып тормыйбыз. Болай гына әйткәндә, баш ул «ана улы». Борынгы карашлар нигезендә, кыз балалар «ана улы», ир балалар «ата улы» исәпләнелә. *Малай* сүзен *мала-й* дип таркатсак, бу чыннан да «ата улы» булачак. Русча *ка* иҗеге кушылган башка — «ата улы», *малайка* исә

«ана улы» булып чыга. Шул рәвешчә, бөтен нәрсә киресенә әйләнә. Димәк, *ка* иҗеге монда артык.

Тагын бер кызык мисалга тукталып китик. Татарча *эт* — «җир улы». Немецча «эт» *һунд* дип атала. Сүзне *һун-д* рәвешендә таркатсак, бу шулай ук «җир улы» дигәнгә туры килә. Русча «эт» собака. Әйтелеше — *сабака*. Сүзне *саба-ка* дип таркатсак, бу «су (күк) улы» булачак. Туктагыз әле, бу сүзнең дә *ка* иҗеге артык түгел микән? Моны без татарча *эт* һәм немецча *һунд* сүзләре белән чагыштырып белә алабыз. Ләкин русча «эт»нең дә «җир улы» булуы *собака* сүзенең үзендә үк яшеренеп ята. Татарча этне «чаба! чәбә!» дип куалар. *Чабә-чәбә*нең бик борынгы варианты *сабә-сәбә* булган булырга мөмкин. Бүгенге татар телендә *ч, ш* кулланылган кайбер очракларда элек *с* тартыгы кулланылган. Гомумән, бу тартыклар бер-берсен алыштырып килә алалар.

Русча *собака* сүзен *са-бака* дип тә таркатырга була, әлбәттә. Болай ул чыннан да «җир улы» булачак. Ләкин, беренчедән, *бака* иҗекләренең «улы» мәгънәсендә кулланылуы мәгълүм түгел. Икенчедән, русча *собака* сүзенең, әүвәлге әйтелеше *соба-саба* булуын русча *собачий* сүзе белән дә исбатлап була. *Собачий (саба-чи)* сүзенең ахыргы *чи* иҗеге «...неке» дигән мәгънә бирә. Әгәр дә мәгәр *собака* сүзе бик борынгы заманда ук шул рәвештә ясалган булса, «этнеке» мәгънәсендәге сүз русча *собака-чи* буларак формалашкан булыр иде. Шулай итеп, русча *собака* сүзенең дә *ка* иҗеген артык дип әйтергә тулы нигез бар.

Эскимос телләреннән берсе имаклик телендә рустан алынган *чай* сүзе *сайукъ, сахар* сүзе *сакъарикъ, палатка* сүзе *палаткакъ* рәвешендә әйтелә. Бу сүзләрдәге *укъ, икъ, къ* иҗекләре, әлбәттә, артык.

Татар әдәби телендә *кичә* буларак мәгълүм сүз урынына сөйләм телендә еш кына *кичәгенәк* кулланыла. Сүзне *кичә* һәм *генәк* өлешләренә таркатсак, *кичә*нең мәгънәсе болай да аңлашыла дип исәплик; *-генәк* монда артык иҗекләр булып тоела. Бу сүзнең үзен *генә-к* рәвешендә таркатабыз. *Генә* хәзер *көн* формасында кулланыла торган сүзнең тулы әйтелеше булып тора. Ахыргы *к* тартыгы чыннан да артык. Татарча *күк* сүзенең соңгы *к* тартыгы да артык сыман, чөнки, белүебезчә, *ку* иҗеге ялгыз килеш тә «күк» төшенчәсенә тәңгәл.

Бу урында без кайбер төрки телләрдәге «су» мәгънәсендәге *суб, сув, суг, суй* сүзләрен яңадан искә төшерәбез. Әлеге сүзләрнең әүвәлге әйтелеше, әлбәттә, *су* булган, *б, в, гъ, й* тартыклары, күрәсең, соңгырак дәверләрдә өстәлгән һәм алар чынлыкта артык.

## 20. ҖИР УЛЛАРЫНЫҢ УЛЛАРЫ һӘМ СУ-КҮК УЛЛАРЫНЫҢ УЛЛАРЫ

Моңарчы без «җир улы» һәм «су (күк) улы» төрләренә караган гомуми исем-атамалар турында сүз алып бардык. Хәзер без таррак һәм конкретрак мәгънәле сүзләргә игътибар итеп карыйк. Әйтик, кеше — «җир улы». Кеше әгъзалары кем улы соң? Яисә хайван, кош, балык әгъзалары һәм аларга кагылышлы теге-бу сүзләр ничек формалашкан?

Иң элек шуны әйтергә кирәк, татар телендә кош, балык, хайван әгъзаларының атамалары, нигездә, кеше әгъзаларының атамаларына туры килә. *Баш* сүзе кешегә карата да, кошка, хайванга, балыкка карата да кулланыла. *Аяк* сүзе дә шулай ук дип әйтергә була. Бары тик балыкның гына аягы булмый. *Кул* исә кешегә генә хас әгъза.

Бик борынгы кеше исәпләвенчә, кеше, кош, балык, хайван әгъзаларының, агач ботакларының, яфракларының һәркайсының үзенең җаны бар. Шулай булгач, алар мөстәкыйль рәвештә яши алалар һәм Җирнең, Суның-Күкнең яисә Атаның һәм Ананың тулы хокуклы «уллары» саналалар. Кеше, хайван, кош-корт яисә балык әгъзалары турында сүз алып барганда безгә һәрвакыт менә шушы борынгы ышануны яисә борынгы фәлсәфәне күз алдында тотарга туры килә. Гадиләштереп һәм гомумиләштереп әйткәндә, озынча һәм хәрәкәтчән әгъзалар, ата улы, хәрәкәтсезрәк һәм кайбер специфик әгъзалар «ана улы» булып аңлашыла.

Кеше әгъзаларының «ата улы» һәм «ана улы» буларак формалашуын барыннан да элек җенес әгъзаларын белдерүче сүзләр мисалында аңлатырга була. Җенес әгъзалары турында сөйләү, гадәттә, әдәпсезлек санала. Ләкин кешене фәнни өйрәнүче биолог яисә медик өчен адәм баласының барлык әгъзалары тигез хокуклы. Безнең өчен дә телдәге барлык сүзләр тигез хокуклы. Борынгы карашларның һәм иң әүвәлге телнең ничек барлыкка килүен аңлатканда бары «әдәпсез» сүзләрне генә санга сукмау дөрес булмас иде. Монда тагын шуны да әйтергә кирәк, күп кенә алла исемнәренең, бүгенге телдәге кайбер киң кулланыш сүзләренең әүвәлге мәгънәләре — «әдәпсез». Шулай булгач, «әдәпсез» сүзләрдән без, гомумән, котыла алмыйбыз. Шулай да, мондый четерекле сүзләрне куллану әдәби телдә гадәткә кермәгәнлектән, без ир кешенең җенес әгъзасын латинча *penis* дип, хатын-кызның җенес әгъзасын *vulva* дип атарбыз яисә бөтенләй әйтмичә калдырырбыз.

Мисалларга килгәндә, бонгу телендә *vulva aa* дип, таҗик теленең чистони диалектында (арго) *сала* дип, богати

телендә *йеге* дип атала. Penis бонгу телендә *уу* дип, богати телендә *арбо* дип, хотан-сак телендә *курә*, һауса телендә *бура* дип атала. Мисаллардан күренгәнчә, *penis* Ата улы, *vulva* Ана улы буларак формалашкан.

Күп кенә телләрдә «ир» мәгънәсендәге сүзләр чынлыкта *penis* дигәнне, «хатын» мәгънәсендәге сүзләр *vulva* дигәнне белдерәләр. Мәсәлән, татар телендә *и-р*, ягноб, латин, чуваш телләрендә *ви-р*, русча *му-ж*, ороч телендә *ху-сә*, хет телендә *пеш-на* (җәя эчендә генә әйтеп китик, татарда *пеш-кәк*), малайа телендә *пари-а* сүзләре «ир» мәгънәсендә кулланыла. Ләкин бу сүзләрнең әүвәлге мәгънәләре, әйтелгәнчә, *penis* дигәнгә туры килә. Мальгаш телендә *ва-ди*, нивх телендә *ум-гу*, япон телендә *ка-ка*, русча *же-на*, карай телендә *къа-ры* сүзләре «хатын» мәгънәсендә кулланыла. Бу сүзләрнең әүвәлге мәгънәләре исә *vulva* дигәнне аңлата.

Татар телендәге баш, чәч, теш, тел кебек сүзләр «ана улы» буларак мәгълүм. Алыйк хәзер *баш* сүзен. Бик борынгы карашлар нигезендә, кешенең авызы хатын-кызның җенес әгъзасына, азык ашау, ризык кабул итү — җенси якынлык кылуга тиңләштерелә. Бу хакта сөйли торган этнографик фактлар шактый күп. Кайбер халыкларда кияү белән кәләш бергә утырып бер үк азыкны ашасалар, алар өйләнешкән булып исәпләнеләләр. Татарда «башымны ашады» дигән сүзне күбрәк хатын-кыз әйтә. Моның чын мәгънәсе кеше башын азык рәвешендә ашауны түгел, бәлки бөтенләй бүтән нәрсәне күз алдында тота. Күп кенә халыкларда элек кеше башы ашау гадәте булган. Көньяк Азиядәге кайбер халыкларда бу йола XX гасыр азакларына кадәр сакланган. Кеше башына карата мондый игътибар башны изгеләштерүгә һәм аны хатын-кызның җенес әгъзасына тиңләштерүгә кайтып кала. Татарча *чәч, тел, теш* кебек сүзләрнең «ана улы» рәвешендә әйтелүләре», күрәсең, аларның баш дигән әгъзада булуларына кайтып каладыр дип әйтергә була.

Татар телендә *кул, айакъ* сүзләре «ата улы» буларак аңлашыла. Русча *ру-ка* белән татарча *ку-л* бер-берсенә тәңгәл. Ләкин русча *нога (на-га)* нишләптер «ана улы» сыман тоела. Ләкин чынлыкта бу алай түгел. Югарыда әйтелгәнчә, кайбер телләрдә кайбер тартыклар аеруча изге санала. Мәсәлән, төрки телләрдә *р, л* тартыклары белән әйтелә торган *а* сузыклы иҗекләрнең мәгънәләре *а* сузыклы да, *у* сузыклы да була ала. Мәсәлән, *ра* һәм *ла* иҗекләре «кояш» дигән мәгънәгә туры килә. Кояш исә, татарлар карашынча, Ата да, Ана да. Шундый ук караш, күрәсең, башка халыкларда да булгандыр дип әйтә ала-

быз. Русча *нога (нага)* сүзендәге *на* иҗегенең дә *ра* һәм *ла* иҗекләренә тәңгәл мәгънәсе бар, ахрысы.

Эчке әгъзалардан татарча *бавыр (ба-ур)* — «ана улы». Телдә «бала — бавыр ите» дигән әйтем дә бар. Димәк, бик борынгы татарлар карашынча, бала тудыруда бавырның турыдан-туры катнашы бар дип уйланылган. Русча да «бавыр» *пе-чень* — «ана улы». Татарча *йөрәк (йерә-к)*, *кү-з* — «ата уллары».

## 21. ...УЛЫНЫҢ УЛЛАРЫ ҺӘМ БАШКА ТӨРЛЕ УЛЛАР

Җир улының улы яисә Су-Күк улының улы төрендәге сүзләр «җир улы» һәм «су (күк) улы» мәгънәләрендәге сүзләргә яңа иҗек ялгау юлы белән ясалган. Моңа мисал итеп татарча *күкәй* сүзен күрсәтергә була. Сүзне *кү-кә* дип әйтсәк, бу Күк улы булачак. Күкәйне, гадәттә, «күк уллары» сала. *Күкә* сүзенә *й* тартыгы яисә тулы булмаган бер иҗек ялгау «күк улының улы» мәгънәсендәге яңа сүз барлыкка китергән. Камбатта телендә дә «күкәй» шушы рәвешчә ясалган. Бу телдә «күкәй» мәгънәсендәге сүз *купа-та* дип атала.

Кешедән, хайваннардан, кошлардан бүленеп чыккан «ул»лар тулы хокуклы булып исәпләнелмәгән, ахрысы. Шуңа күрә мондый төрдәге сүзләрне без «улының уллары» дип атыйбыз да. Балык уылдыгы рус телендә *икра* дип атала. Сүзне *ик-ра* дип таркатсак, бу «ана улы» булыр иде. Ләкин «балык»ның да, «балык улының» да «ана улы» булуы мөмкин түгел. *Икра* сүзен без *и-к-ра* дип таркатабыз. Әлеге сүзнең *и-к* өлеше «балык», шуңа *ра* иҗеген кушкач, бу «балык улы уылдык» булачак. Ләкин шунысы кыенрак — рус телендә «балык» *ик* түгел!

Болай булгач, безгә бүтән телләргә мөрәҗәгать итәргә туры килә. Рапа-нуи һәм маори телләрендә «балык» *ика* дип атала. Бик дөрес: *и* — «су», *ка* — аның «улы». Рапа-нуи телендә сөйләшүчеләр Тын океанның көньяк-көнчыгыш өлешендә, атаклы Пасха (Рапа-нуи) утравында, маорилар Яңа Зеландия утравында яшиләр. Бүгенге руслар белән алар арасында нинди уртаклык булырга мөмкин соң? Югарыда күреп киткәнчә, мондый телләрдәге уртаклыкны «һинд-европа» тел гыйлеме кире кага. Ләкин тел фактлары аяусыз. Телисеңме, теләмисеңме, бик борынгы русларның ата-бабалары Полинезия кабиләләренең ата-бабалары белән тугандаш яисә күрше булган дип әйтергә туры килә.

Безгә яхшы таныш рус телендәге тагын бер мисал белән танышып китик. Русча «йодрык» *кулак* дип, кулның һәм аякның кисеп ташлаганнан соң калган өлеше

*культя (кул-тә)* дип атала. Ике сүзнең дә беренче һәм икенче иҗекләре татарча *кул (кула)* сүзенә тәңгәл. Ахыргы *к* һәм *тя (тә)* иҗекләре без тикшерә торган «улының улы» мәгънәсен белдерәләр.

Менә без тагын телнең гаҗәеп бер факты белән очраштык. Компаративистлар кеше әгъзасын белдерүче сүзләр бер телдән икенче телгә күчми дип өйрәтәләр. Ләкин руслар *кулак* һәм *культя* сүзләрендәге *кул* иҗекләрен бик борынгы төркиләрдән алганнар булып чыга түгелме соң? Әллә киресенчәме? Мәсьәләгә теоретик яктан караганда, *кул (кула)* дөньядагы теләсә нинди телдә булырга һәм «кул»ны гына түгел, «аяк»ны да белдерергә мөмкин. Мәсәлән, монгол телләренең берсе дагур телендә дә *кул* сүзе «аяк» мәгънәсенә туры килә.

Без башта ук әйттек: дөньядагы барлык телләр бер үзәктән, бер оядан чыккан, дидек. Шулай булгач, кайбер сүзләрнең төрле телләрдә очравы гаҗәпмени? Телләрнең үзара туганлыгы бик-бик ерак чорларга китә, туганлык тамырлары төрле якка сузылган, чуалып беткән. Монда әле ачыклыйсы нәрсәләр җитәрлек!

Мисаллар белән танышуны дәвам итәбез. Татарча *бүрәнә* сүзенең ахыргы *нә* иҗеге дә «улының улы» дигәнгә туры килә. Сүзнең *бүрә* өлеше мәгълүм *бура* сүзенең нечкә варианты булса кирәк. *Бура*, белүебезчә, әзер өй түгел, бәлки өй өчен юнып-чабып куелган бүрәнәләрне, бүрә-нә исә бураның бер кисәген («улын») белдерә. Өй бүрәнәләренә карата *нирге* сүзе дә кулланыла.

Татарча *торак* сүзенең әүвәлге формасы *турак* булганга охшый. Себер төркиләре телләрендә, диалектларында *тура* «шәһәр», «авыл», «өй» мәгънәләрендә кулланыла. *Тора-къ (тура-къ)* сүзенең ахыргы *къ* тартыгы «улының улын» белдерә һәм аның иң әүвәлге мәгънәсе «шәһәр улы», «авыл улы», «өй улы» булачак.

## 22. АТА УЛЫНЫҢ ҺӘМ АНА УЛЫНЫҢ БҮТӘН ТӨРЛӘРЕ

Кеше кулы белән ясалган эш, сугыш кораллары, савыт-саба, кием-салым һ.б. нәрсәләр Ата улы һәм Ана улы рәвешендә ясалган сүзләр белән аңлатыла. Әйтелгәнчә, озын, очлы, хәрәкәтчән әйберләр «ата улы» буларак формалашканнар һәм иң әүвәлге мәгънәләрендә ир кешенең яисә мифик Атаның җенес әгъзасына тиңләштереләләр. Савыт-сабаларны, эчле, куышлы әйберләрне белдерүче сүзләр «ана улы» буларак формалашканнар һәм иң әүвәлге мәгънәләрендә хатын-кызның яисә мифик Ананың җенес әгъзасына тиңләштереләләр.

Татарча *тайа-к, майа-к, бага-на, сәнә-к, ар-ба,* русча *палка* («таяк»), *пи-ка* («сөңге»), *теле-га* («арба») кебек сүзләр барысы да Ата улы буларак аңлашыла. Шул ук вакытта татарча *ка-сә, чүл-мәк, күбә-тә, ка-зан,* русча *ча-ша* («касә»), борынгы һиндчә «корбан бирүдә кулланыла торган савыт» — *ча-му* сүзләре «ана улы» калыбында ясалган. Татарча *бүре-к, кие-м, күл-мәк* сүзләре дә — «ана уллары». Кайбер киемнәр, киресенчә «ата улы» булып аңлашыла. Мәсәлән, *ту-н*, русча *шу-ба*.

Кеше кулы белән ясалган әйбер атамаларының Ата улы һәм Ана улы төрләренә бүленүе аеруча «ук» һәм «җәя» мәгънәсен белдерүче сүзләрдә күренә. Ләкин мондый бүленеш барлык телләрдә дә чагыла дип әйтеп булмый. Бу исә ук һәм җәя уйлап табылган чорда кайбер телләрдә сүз ясаудагы бик борынгы принципларның онытылган булуы ихтималы турында сөйли. Монда шулай ук ук-җәянең башта бер генә үзәктә уйланып табылуы һәм соңыннан төрле якка таралуы хакында да фикер йөртергә була. Яңа коралны күршесеннән күчереп алучы кабиләдә аның атамасының эчке мәгънәсенә игътибар итеп җиткермәгәннәр булырга мөмкин.

Төрки телләрдә һәм кайбер башка телләрдә «җәя» *vulva*, ук — *penis* булып алышыла. «Ук» һәм «җәя» атамалары нигезендә генә дә телләрне икегә бүлеп карарга була. Бер төрле телләрдә «ук»ның *penis*, «җәя»нең *vulva* булуы таныла, икенче бер телләрдә мондый фәлсәфә кире кагыла, дөресрәге, *ук-җәя* атамаларында мондый принцип сакланмый. Менә шундый аерма телләрнең, әйтик, ук-җәя уйлап табу чорында үзара туган булу-булмауларын билгеләү өчен ышанычлы критерий хезмәтен үти ала.

«Һинд-европа», семит телләре дип аталган һәм кайбер башка телләрдәге «ук», «җәя» атамалары нигезендә әлеге коралларның берсенең «ата улы», икенчесенең «ана улы» булуын билгеләп булмый. Мәсәлән, ассири телендә «җәя» *кас-ту* дип, шул ук мәгънәдәге сүз немец телендә — *боген*, итальян, испан телләрендә — *арко*, русча — *лук* дип атала. Әлеге мисалларда «ата улы», ягъни гомумән «корал» турында сүз бара, ахрысы.

Шушы уңайдан монгол телләрендәге «ук», «җәя» атамалары белән танышу шактый гыйбрәтле булачак. Тел галимнәре безне монголлар белән «генетик туган» дип ышандырмакчы булалар. Югарыда әйтелгәнчә, моннан 3—4 яисә 5—6 мең еллар элек төрки телләр, имеш, гомум «алтай» теленнән бүленеп чыкканнар. Шул заманнардан башлап төрки телләр дә, монгол телләре дә мөстәкыйль үсеш юлына басканнар, имеш.

Корал буларак ук һәм җәянең кайчан уйланып табылуы билгеле түгел. Ләкин Төньяк Африкада, Испаниядә һ.б. төбәкләрдә — кешенең ташка ясап калдырган бик борынгы сурәтләре арасында ук һәм җәя сурәтләре дә очрый. Корал буларак ук һәм җәя язу системасы уйлап табылган заманнардан элегрәк барлыкка килгән. Язу системасы исә Шумерда моннан биш-алты мең еллар элек уйлап табылган дип исәпләнелә. Әйтәсе килгәнем шул: төрки телләр һәм монгол телләре яңа гына туган дип уйланылган чорларда ук инде ук-җәя булган.

Бүгенге монгол телләрендә «җәя» *нум* дип атала. *Нум* сүзенең *ном* варианты да бар (мәсәлән, барин, өннүт, найман диалектларында). Шулай итеп, монгол телләрендә һәм диалектларында «җәя» «ана улы» түгел. Төрки телләрдән кырым-татар, госманлы-төрек, чыгытай телләрендә «җәя» *йай*, карай телендә *йайа*, казан-татар телендә *җәйә* дип атала. Күрәсез, «җәя» атамалары нигезендә фикер йөрткәндә, төрки телләр белән монгол телләре беркайчан «генетик туган» булмаганнар һәм «алтай телләре» дип аталган ниндидер уйдырма телдән аерылып чыкмаганнар. Юкса, һәр ике телдә «җәя» атамасы бер үк калыпта ясалган булырга тиеш түгел идемени?!

Хәзер башка телләргә мөрәҗәгать итеп карыйк. Дравид телләрендә «җәя» *бил* дип, ньямвези телендә — *бута*, суахили телендә *ута* дип атала. Кайбер телләрдә «җәя»-нең «ана улы» булуы чагыла. Мәсәлән, пушту телендә *лин-да*, горима телендә *га-на*, могогодо телендә *па-ћа*, бай телендә *йа-ти* дип атала.

«Ук» атамасы да төрле телдә төрлечә формалашкан. Гиссар парьялары телендә «ук» та, «җәя» дә *ча-ти* дип атала. Оромо телендә «ук» *фул*, лингала телендә *ли-кула* (*ли* — исем күрсәткече; төп сүз — *кула*), баңаңте телендә *кит*, гадаба, манди, паржи телләрендә *амб*, борынгы тамил, каннада, тулу телләрендә *амбу* дип атала.

Төрки телләрдә тууга һәм тудырурга бәйле кайбер сүзләр «җәя» һәм *vulva* мәгънәсендәге һәм формасындагы иҗекләр ярдәмендә ясалган. Телеут телендә «туу», «барлыкка китерү» — *йайан* дип, койбал, качин диалектларында «тудыручы», «барлыкка китерүче» — *йайам* дип атала. Әлеге сүзләрне *йайа-н* һәм *йайа-м* рәвешендә таркатсак, һәр ике очракта «җәя улы» барлыкка киләчәк. Бу уңайдан татарча *йарату* сүзен дә искә төшерергә була. *Йарату* — «сөю», «якын итү» дигәнне генә түгел, «тудыру», «барлыкка китерү» дигәнне дә белдерә.

XIV гасыр татар шагыйре Сәйф Сараи «Гөлстан бит төрки» дип аталган әсәрендә җитмеш яшьлек картның

унсигез яшьлек кызны аталандыра алмавы турында яза. Шагыйрь хатын-кызның җенес әгъзасын җәя белән, ир кешенең җенес әгъзасын ук белән, якынлык кылуны ук ату белән чагыштыра.

Чәкеп йә, тулдырып ук, фарисәнә
Орыр, ликин укы үтмәс нишанә, —

ди шагыйрь.

Менә бу мисал үзе генә дә ук-җәя фәлсәфәсенең төрки аңда никадәр тирән уелып калуы турында сөйли.

### 23. ХӘРӘКӘТНЕ БЕЛДЕРҮЧЕ СҮЗЛӘР

Борынгы карашлар нигезендә, хәрәкәт һәм активлык бары Суга-Күккә һәм Атага гына хас сыйфат. Шуңа күрә хәрәкәт белдерүче сүзләр Су-Күк, Ата мәгънәләренә туры килә торган *у* сузыклы иҗекләр ярдәмендә ясала. Мәсәлән, һауса телендә «берәр юнәлештә «бару», «йөрү», «сәяхәт итү», борынгы кытай телендә «ташлау», «ыргыту», йоруба телендә «тудыру», эве телендә «бөгү» — *би* дип, ороч телендә «кием кисү» «пычак белән кисү» — *ги* дип, вьетнам телендә «йөрү», «бару» — *ди* дип, шумер телендә «төзү», «кору» — *ду* дип, айну телендә «эчү» — *ду* дип, йоруба телендә «эчү» — *му* дип атала.

Монда шулай ук татар телендәге *ку, ту, шу, бу, ки, ти, си, ди* кебек боерык фигыльләрне дә искә төшерергә була. Татарча *туку, сугу* кебек сүзләр дә хәрәкәтне белдерәләр. Ләкин әлеге төрдәге сүзләр *у* сузыклы икешәр иҗек ярдәмендә ясалганнар. Иҗекләрнең берсе хәрәкәтне белдерсә, икенчесе нәрсәне белдерә соң? Әллә ике иҗек тә хәрәкәтне белдерәме?

Төрки тел нормаларына ярашлы рәвештә, исем беренче урында, фигыль, ягъни хәрәкәтне белдерүче сүз икенче урында килергә тиеш. Шушы кагыйдәгә нигезләнеп, әлеге сүзләрне *ту-ку, су-гу* дип таркатсак, һәр ике сүздәге беренче иҗекләр (*ту* һәм *су*) исемне, икенче иҗекләр (*ку* һәм *гу*) хәрәкәтне белдерергә тиеш булып чыга. Моңа тиз генә ышануы да кыенрак. Фикеребез яхшырак аңлашылсын өчен без җиңелрәк икенче бер мисалга тукталмакчы булабыз.

Мәсәлән, *күши* сүзе дә *у* сузыклы ике иҗектән тора. *Күши* белән *сугу, туку* фигыльләренең мәгънәләре бер үк төрле түгел. *Күши* хәзерге вакытта конкрет хәрәкәтне, *туку, сугу* исә, гомумән, хәрәкәтне белдерә. Билгеле булганча, бары сыер гына күши. Дөрес, *күши* сүзе күчермә мәгънәдә кешегә карата да кулланылырга мөмкин. Әлеге сүзне *кү*

һәм *ши* иҗекләренә таркатабыз. Төрки тел кагыйдәсенә ярашлы рәвештә, *күү* исем, *ши* фигыль булырга тиеш. Ләкин татарда *күү* дигән хайван бармы соң? Хәзер инде юк, ләкин бик борынгы заманнарда, күрәсең, булгандыр. *Көтү* сүзе, мәсәлән, шул турыда сөйли. Сүзнең *кө* иҗеген элек *күү* булган дип исәпләсәк, аның чыннан да ниндидер хайванны белдергән булуы ачыкланачак. «Хайван» дигәнебез, билгеле, сыерны күз алдында тота. Бүгенге немец телендә «сыер» турыдан-туры *күү (Kuh)* дип, курд телендә *гу* дип атала.

Күрәсез, без тагын читкә кереп киттек. Төпченә торгач, төрки сүзнең тамыры бөтенләй чит телләргә таба сузылды. Шушы уңайдан *күши* сүзендәге «сыер» *күү* турында тагын бер фикерне теркәп узасы килә. *Күү* ул «сыер» гына түгел, «күк» тә, ягъни русча әйткәндә «небо». Югарыда без татарча *күк* сүзенең ахыргы *к* тартыгы артык дидек. *Күү* иҗеген «небо» дип аңлаганда бу, әлбәттә, шулай. Ләкин күү иҗеген *күши* сүзендәге кебек «сыер» дип аңласак? Бу очракта ахыргы *к* тартыгы «улы» мәгънәсен белдерәчәк һәм күк сүзе тулаем «сыер улы» дигәнгә туры киләчәк! Гаҗәп бит, *күү* иҗеге бер үк вакытта «сыер»ны да, «небо»ны да белдерә, имеш. Мөмкинме бу? Мөмкин икән шул. Борынгы Мисырда, мәсәлән, күкне сыер кыяфәтле итеп күз алдына китергәннәр. (Бу хакта без Мисыр турындагы бүлектә сүз алып барырбыз.)

Хәзергә исә *күши* сүзендәге икенче *ши* иҗегенә игътибар итеп карыйк. Бүгенге *күши* сүзе сыерның ашавын күз алдында тота. *Күү* иҗеге «сыер» булгач, *ши* иҗегендә ашау хәрәкәте чагылырга тиеш сыман. Болай булгач, ялгыз *ши* иҗегенең ашауга катнашы булган берәр мисал табып булмый микән?

Татар телендә дә, башка төрки телләрдә дә аерым *ши* иҗеганнән генә торган мәгънәле сүз юк, ахрысы. Әлеге *ши* иҗеген эзләп башка телләргә мөрәҗәгать итәргә туры килә. Индуизм диненә табынучылар фикеренчә, Шива дигән алла исемендә бөтен дөньяның хәрәкәт ритмы чагыла. Шива дөньяны (яшәешне) бию процессында барлыкка китергән. Дөньяны барлыкка китерүче булгач, Шиваны Җир һәм Ана дип аңларга була. Ләкин шунысы гаҗәп, Ши-ва — ир затындагы алла. Индуизм динендәге кешеләр Шиваны *penis* кыяфәтле алла дип беләләр һәм аны шул кыяфәттә хөрмәтлиләр. Шиваның, бары *penis* кына булмыйча, җимерүче һәм тудыручы, биючe, хәрәкәтләнүче алла да булуын истә тоткан хәлдә, *шива* сүзен башкачарак та аңлатырга була. Сүзне *ши* һәм *ва* иҗекләренә таркатабыз. *Ши* иҗеген «ашаучы» дип, *ва* иҗеген Җир яисә Ана дип аңлыйбыз. Әлеге сүзнең киңәй-

телгән, дөресрәге, яшерен, серле мәгънәсе, шулай итеп, «ашаучы Ана» булачак.

Борынгы аллалар, алиһәләр исемендә еш кына ике төрле, яшерен, серле мәгънә саклана. *Шива* сүзен *Ши-ва* дип таркатсак һәм төрки тел принцибында аңлатсак, бу Су (Күк) улы Җир яисә Ана, төркигә кире принципта аңлатсак, Ана улы Ата булачак. Ләкин бу очракта без Шива сүзендәге *ши* иҗегенең «ашаучы» булуына ныграк игътибар итәбез. *Ши* иҗегенә якын *чи* иҗеге һауса телендә турыдан-туры «ашау» дигәнне белдерә. Кхмер телендә «ашау» *си* иҗеге белән аңлатыла. Татарча *ашый* сүзенең иң әүвәлге әйтелеше *а-ши*, русча боерык фигыль *йешь* сүзенең әүвәлге әйтелеше (теоретик яктан) *йе-ши* булган булырга тиеш дип исәпләсәк, *күши* сүзендәге *ши* иҗегенең дә «ашый» икәнлегенә ышанырбыз дип уйлыйм.

Шул рәвешчә, *туку, сугу* кебек сүзләрнең беренче иҗекләре исемне, икенче иҗекләре хәрәкәтне белдерә дигән фикер дөреслеккә туры килә дип әйтә алабыз.

Кайбер телләрдә хәрәкәт белдерүче сүзләр алдыннан «фигыль күрсәткече» дип аталган махсус иҗекләр кулланыла. Мондый «фигыль күрсәткечләре» бик борынгы заманнарда бер үк әйтелештәге, ләкин төрле мәгънәдә кулланылган иҗекләрне (сүзләрне) бер-берсеннән аеру өчен кирәк булган, күрәсең. Мәсәлән, луганда телендә фигыль күрсәткече *у* сузыклы иҗек ярдәмендә белдерелә. Луганда телендә *ку-лимиса* дисәк, бу «җир эшкәртмәк» дигәнне, *ку-линда* дисәк, «көтеп тору» дигәнне аңлатачак. Сүз башында килгән *ку* иҗекләре фигыль күрсәткече хезмәтен үтиләр.

Югарыда телгә алынган өстәмә иҗекләрне яңадан искә төшерәсе килә. Әйтелгәнчә, кайбер телләрдә авыл-шәһәр, елга һ.б. атамалары азагында «авыл», «шәһәр», «елга» һ.б. мәгънәләрдәге сүзләр ялгана. Кайбер телләрдә исә, мисалга китерелгән луганда телендәге кебек, фигыль күрсәткечләре, исем күрсәткечләре кулланыла. Өстәмә мәгънә белдерүче иҗекләр һәм сүзләр, шулай итеп, төп сүзнең алдына да, ахырына да ялгана ала икән. Мәсәлән, рус телендәге сүз башына ялгана торган *на, по, за, про, при* кебек «күрсәткечләр», ягъни тел гыйлемендә әйтелгәнчә, префикслар чынлыкта өстәмә мәгънә белдерүче иҗек хезмәтен үтиләр.

## 24. СЫЙФАТ БЕЛДЕРҮЧЕ СҮЗЛӘР

Сыйфат белдерүче сүзләрне без гомумиләштереп икегә бүлеп карыйбыз: аларның бер төрлесе уңай сыйфатны, икенче төрлесе кире сыйфатны белдерә. Уңай сыйфат белдерүче сүзләр *у* сузыклы иҗекләр ярдәмендә, кире

сыйфат белдерүче сүзләр *а* сузыклы иҗекләр ярдәмендә ясала. Әгәр без татарча *уңай* һәм *кире* сүзләрен генә алып карасак та, тагын бер мәртәбә борынгы кешенең мәңгелек фәлсәфәсен искә төшерергә мәҗбүр булырбыз. *Уңа-й* сүзе Су-Күк яисә Ата дигәнгә, *ки-ре* сүзе Су-Күк улы Җир, яисә Ана дигәнгә туры килә.

Тува АССР территориясендәге Зур Енисей елгасы тува телендә *Би-хем* дип, Кече Енисей елгасы *Ка-хем* дип атала. Мисаллардан күренгәнчә, *би* иҗеге «зур», «озын» дигәнне, ка иҗеге «кыска», «кечкенә» дигәнне белдерә. Готтентот телләреннән берсе нама телендә ирләр заты суффиксы зур әйберләрне, хатын-кыз заты суффиксы кечкенә әйберләрне белдерү өчен кулланыла. Лими телендә *ха(ка)* иҗеге кечерәйтү күрсәткече булып исәпләнелә. Сото теленең төньяк диалектында сүз ахырында килгән *на* иҗеге сүзгә кечерәйтү мәгънәсе бирә. Банту телләрендә яңа сүз ясаганда *ке* иҗеге ялганса, бу иҗек сүзгә «кечкенә», «әһәмиятсез» дигән мәгънәләр өсти. Төньяк Тогодагы тем телендә кечерәйтелгән исем ясауда *ка* префиксы кулланыла. Кытайдагы дун телендә *лао* сүзе «зур» дигәнне, *ун* сүзе «кечкенә» дигәнне белдерә. Тасмания телендә «яктылык», «ут», «йолдыз», австралия телләрендә — «ут», «ялкын», «кояш» мәгънәләрен белдерүче сүз *мара* буларак формалашкан. Сүзне *ма-ра* дип таркатабыз. *Ра* иҗеге элек күп кенә телләрдә «кояш» яисә «кояш алласын» белдергән. Бик борынгы Тасмания һәм австралия телләрендә дә «кояш» *ра* булган булса, *ма ра* иҗекләре «кечкенә кояш» дигәнне аңлаткан булып чыга. Әлеге сүзне *ма-ра* дип таркатсак, бу — «улы Кояш» булачак.

Безнең эраның 9—23 елларында тәхеттә утырган Хань (борынгы Кытай) императоры Ван Ман борынгы Кореяның атамасы *Когурө* сүзен *Хагурө* сүзенә алыштырырга боера. *Когурө* «бөек Күрө», *Хагурө* исә «Кечкенә Күрө» дигәнне белдерә.

Татарча *аз — күп, кече — зур* дигән сыйфат сүзләренә игътибар итсәк тә, *а* сузыклы иҗекләрнең кире сыйфатны, *у* сузыклы иҗекләрнең уңай сыйфатны аңлатуын күрербез. Тик бу очракта тагын да беркадәр «пластик операция» ясарга туры килә. Мәсәлән, ике иҗекле *кече* сүзен *ке-че* рәвешендә таркатсак, бу Җир улы Су (Күк), ягъни Ата булыр иде. Су-Күк, Ата «кече» була алмый. Шунлыктан кече сүзен ке че дип таркатырга туры килә, бу исә «кечкенә че» дигән мәгънәгә туры килә. *Че* иҗеге бу очракта конкрет булмаган нииндидер нәрсәне белдерә, ахрысы. Әллә соң, киресенчә, конкрет, җанлы нәрсәнеме? *Көтү-че* дигәндә *че* конкрет кешене белдерә. *Таш-чы* дигәндәге *чы* шулай

ук җанлы кешене белдерә. *Тамчы* дигәндәге *чы* да, бәлки, элегрәк җанлы, конкрет нәрсәне күз алдында тоткандыр?

Иң ахырда тагын бер мисал теркәп узыйк. Мари телендә «яңа» дигән уңай сыйфат ялгыз *у* сузыгы ярдәмендә генә белдерелә.

## 25. УҢАЙ СЫЙФАТ БЕЛДЕРҮЧЕ ИКЕ ИҖЕКЛЕ СҮЗЛӘР. *АЛ*

Уңай сыйфат белдерүче сүзләр *у* сузыклы бер иҗек ярдәмендә дә, *а-а* яисә *а-у* сузыклы ике иҗек ярдәмендә дә ясалырга мөмкин. Шундыйлардан төрле телләрдә еш очрый торган *ал* сыйфатына аерым тукталып китәсе килә.

Ялгыз *ал* сүзе бүгенге алтайлылар телендә «бөек», «югары», «күтәренке рухлы», «көчле» сыйфатларын белдерә. Африкадагы афар, сахо телләрендә *ал* «биек», «югары», «калку җир» мәгънәләрендә кулланыла. Шул ук *ал* сүзе якут телендә кайбер иске сүзләрдә «изге» булып аңлашыла. Татар телендә *ал* «ачык кызыл» төсне белдерә һәм сыйфат буларак кулланыла. *Ал* байрак дигәндә байракның төсе дә, изгелеге дә чагыла.

Менә мондый мисалларда *ал* сүзенең сыйфат буларак кулланылуы бернинди бәхәс тудырмый дип уйларга кирәк. Ләкин кайбер сүзләрдәге *ал* иҗекләренең сыйфатмы-түгелме икәнлеге әлегә билгеле түгел. Дөресрәге, бу хакта әлегә беркемнең дә уйланганы юк шикелле. Мәсәлән, *албасты* сүзен һәркемгә таныш дип исәплик. Сүзлекләрдә *албасты* сүзенә «йоклаганда кешене саташтыра, баса торган җен, явыз рух» дигән аңлатма бирелгән. *Албасты* хатын-кыз затыннан булган ниндидер куркыныч нәрсә, ахрысы. Иҗек методы нигезендә әлеге сүзне *ал бас-ты* рәвешендә таркатсак, бу Изге Су-Күк улы Җир (яисә Ана) булачак. Шулай итеп, халык аңында кире типтагы ниндидер серле зат *Албасты* иң әүвәлге мәгънәсе нигезендә Изге Ана булып чыга түгелме соң? Хәер, без моңа әз генә дә гаҗәпләнмибез, чөнки Җир (Ана) борынгылар карашынча, тудыручы гына түгел, караңгылык, салкынлык һәм һәр төрле кире көчләр чыганагы да булып аңлашыла. *Албасты* сүзендә аның менә шул кире яклары чагыла сыман.

Татар теленең Урта диалекты Нократ сөйләшендә «абыстай» *алма* дип атала. *Алманы* без ашый торган җимеш буларак беләбез, монда ул, имеш, дәрәҗәле хатын-кызга әйләнгән. Каян килгән аңа мондый мәгънәсезлек? Бу сүзне *ал ма* дип таркатсак, *алма* (абыстай) чыннан да Изге Ана булачак. Урарту (биайна) телендә «бөек алла» *Алди* дип аталган. Сүзне *Ал ди* рәвешендә таркатабыз. *Ал* — бөек, *ди* — алла булачак. Америкадагы киче телендә «тудыручы

бөек Ана» *Алом* дип атала. *Ал* монда да уңай сыйфат белдерә. *Ом* иҗекләренең әүвәлге әйтелеше *Ам* булгандыр дип фикер йөртәбез. *Ам* төрки телләрдә *vulva* дигәнгә туры килә. Күрәсең, киче телендә дә ул шундый ук мәгънәдә кулланылгандыр. Димәк, *Алом*ның һәркемгә аңлаешлы мәгънәсе «тудыручы бөек Ана» булса да, аның әүвәлге һәм яшерен мәгънәсе «бөек *vulva*» булган дип әйтергә туры килә.

Көнбатыш Себердәге һәм Монголиядәге атаклы Алтай тауларының исемен *Ал та-й* рәвешендә таркатабыз. *Ал* — уңай сыйфат белдерә, та-й — Җир улы «тау». Латинча *алтар* — «корбан бирү урыны» һәм «кабер ташы» дигәнне белдерә. Сүзнең *тар* өлеше татарча «таш» мәгънәсенә туры килә, *ал* исә уңай сыйфат белдерүче сүз. *Алтай* белән *алтар*, шулай итеп, бер үк мәгънәдәге сүзләр булып чыкты. Тик аларның ахыргы тартыклары гына үзгә һәм шулай ук кулланыштагы мәгънәләре үзгә.

Уңай сыйфат белдерүе *ал* иҗекләренең тулырак килеш сакланган вариантлары да очрый. Татарча *алабуга* дигән балык исемен *ала бу-га* дип таркатабыз. Бу Изге Су улы дигән мәгънәгә тәңгәл. *Алабуга* шәһәре исеменең ничек барлыкка килүе мәгълүм түгел. Шәһәр янында элек *Алабуга* дигән елга агып, шәһәр исеме шуннан алынганмы, әллә шәһәр исеме балык исеменә туры киләме — моны берничек тә исбат итеп булмый.

Финляндиядә *Аласуолиярви* дигән бер күл бар. Иҗек методының принципларын истә тоткан хәлдә, без бу ят һәм озын сүзне *Ала Су-оли, йәрви* дип таркатабыз. Йәрви фин телендә «күл» дигәнне белдерә һәм күл атамасына өстәмә мәгънә бирә. Сүз башындагы *Ала* иҗекләре уңай сыйфатны белдерә. *Суоли* сүзен *Су-оли* дип таркатсак, бу бөтенләй диярлек төрки сүз — Су улы булачак. Әлеге фин сүзе тулаем «Изге Су улы, күл» рәвешендә тәрҗемә ителә.

*Ал* сыйфатының *бал* рәвешендәге формасы да мәгълүм. Европаның көньягында *Балкан* ярымутравы бар. *Балкан* ярымутравында *Балкан* таулары, Башкортстанда *Балкан* тавы, Төрекмәнстанда *Балхан* таулары бар. Сүзне *Бал ка-н (Бал ха-н)* рәвешендә таркатабыз. Татарстанда, Башкортстанда *Балтач* авыллары бар. Бу сүзне дә *Бал та-ч* дип таркатабыз. Төньяк Кавказдагы төрки *балкар* халкы атамасын да *бал ка-р* рәвешендә таркатырга була. Бу исә «изге (бөек) Кар» дигәнгә туры килә. Казан татарларының тарихи ата-бабаларының берсе *болгар* атамасының да әүвәлге әйтелеше *балкар* булгандыр, ахрысы, дип әйтәсе килә. *Болгар* белән *балкар* арасында фонетик аерма әллә ни зур түгел — *бол балга*, *гар кар*га тәңгәл дип исәпләү өчен берниндн каршылык юк. Телдә мондый гына күчешләр, үзгәрешләр еш була.

Димәк, безнең болгар бабаларыбыз «изге (бөек) кар»-лар булган дип әйтергә мөмкин. Кемнәр булды икән соң ул изге (бөек) *карлар*? Бу хакта без башка урында сүз алып барырбыз.

### 26. УҢАЙ СЫЙФАТ БЕЛДЕРҮЧЕ *АР* ҺӘМ БАШКАЛАР

*Ал* кебек үк *ар* да һәм, гомумән, *а-а (у)* тәртибендәге теләсә нинди иҗекләр уңай сыйфат белдерә алалар.

Якут телендә *ар* сүзе «изге», «илаһи», «зур хөрмәткә лаек» дигән мәгънәләрдә кулланыла, шумер телендә аерым *ар* — «мактау», «данлау» дигәнне аңлаткан. Борынгы төрки телдә *ары (г)* — «саф», «чиста», «керсез», «изге» дигән мәгънәләр белдергән. Куман, куманды телләрендә *ары* — «саф», «изге», татарча *ару* — «саф», «яхшы», «таза» дигәннәрне аңлата.

Татарстандагы *Арча* атамасын *Ар ча*, ягъни «изге җир» дип тә, «калку җир» дип тә аңларга була. Үзбәкчә «артыш», «чыршы», чыгытайча «нарат» мәгънәсендәге *арча* сүзендәге *ар* сыйфатны түгел, Су-Күк дигәнне белдерә. Без инде беләбез, озын, төз кәүсәле агачлар Су-Күк яисә Ата улы исәпләнелә һәм мифик Атаның җенес әгъзасына тиңләштерелә. *Артыш* агачы озын кәүсәле түгел, ләкин ул хуш исле. *Артыш* әле дә изге санала һәм өйдәге җен-пәриләрне, шайтаннарны куганда кулланыла. *Артыш* сүзен *ар ты-ш* дип таркатабыз. Үзбәкчә *арча* (артыш) сүзе чыршы, нара-т сүзләренә тиңләштерелә. Моны, билгеле, *ар че* ягъни «изге че (ча)» дип тә аңларга була.

*Арча* калыбындагы *арка* турында да бер-ике сүз әйтеп китәсе килә. Кеше «аркасы» арканы да ике төрле: *ар ка* һәм *ар-ка* дип таркатырга була. Төрки географик атамаларда *арка* сүзе тауларга, тау сыртларына карата кулланыла. Бу очракта сүзне *ар-ка* дип таркатабыз һәм «биек (калку) җир» дип аңлыйбыз. *Арка* сүзе кайчандыр урта гасырларда бик зур географик өлкәне дә аңлаткан һәм «ил-дәүләт», «ватан», «туган җир» мәгънәләрендә кулланылган. *Арка* дигән территория Алтай тауларыннан алып Уралгача сузылган булган. Бу очракта *Ар ка* — изге җир дигәнгә туры килә. *Арка* шулай ук «изге ана» мәгънәсендә дә кулланыла ала. Аның мондый мәгънәсе түбәндәге йола җырында күренә:

Карурманнарның башында
Козгын талпына бүрегә;
Аркам, канатым, ана кәбәм,
Әллә ни язгандыр күрергә.

Уңай сыйфат белдергән *ар* иҗекләренең тулырак вариантлары да мәгълүм. Һиндстанның Бихар штатында, мунда телендә «изге әрәмә» *сарна* дип атала. Сүзне *сар на* дип таркатабыз. Моның мәгънәсе «изге җир», «изге урын» булачак. Татарча *әрәмә* сүзе дә *әрә мә* рәвешендә таркатыла. Димәк, *әрәмә* дә бик борынгы төркиләрдә «изге җир», «изге урын» исәпләнелгән һәм, күрәсең, дини йола бәйрәмнәре үткәрү урыны булган.

*Ал, ар* гына түгел, «җир улы су-күк» рәвешендә ясалган ике иҗекле теләсә нинди сүз уңай сыйфат белдерә ала. Татарстандагы *Актаныш* атамасын *Ак та-ны(ш)* дип, Новосибирск өлкәсендәге Бараба даласының, исемен *Бара ба* дип, Алтай крае башкаласы *Барнаул* шәһәре исемен *Бар на-ул* дип тарката алабыз. Брауи телендәге «ана» мәгънәсендәге *амма*, грекча хатын-кыз исеме *Анна* сүзләрен *ам ма* һәм *Ан на* рәвешендә бүләбез. Татарча «су кошы» *акчарлакның* әүвәлге ак иҗекләре «изге», «бөек» дигәнне белдерә. *Чар* — «Су», *лак* — «улы». Татарча тарихи *тархан* сүзенең *тар* иҗекләрен аерып алып карасак, бу тарлыкны, кысынкылыкны белдерә. Ләкин *хан* сүзе алдыннан сыйфат булып килгәндә *тар* — «изге», «бөек» дигән мәгънәләргә ия.

## 27. *АЛЛА* СҮЗЕНЕҢ МӘГЪНӘСЕ

Татарга *алла* сүзе ислам дине белән гарәптән кергән дип уйланыла. Ләкин гарәпнең үзендә «алла» мәгънәсендәге *алла* сүзе юк икән. Гарәп телендә бу сүз *аллаһу* рәвешендә артык *һу* иҗеге белән әйтелә. «Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге»нә *алла* сүзе теркәлмәгән. Сүзлектә бары *илаһ, илаһә* һәм *алиһә* сүзләре генә бар.

Алла сүзе төрки телләрнең барысында да юк. Ул бары казан-татар, кырым-татар телләрендә, Себердә Тобол төркиләрендә, Кырым Карайларында гына кулланыла. Әлеге сүз төрекләрдә, азәрбайҗаннарда аллаһ, казакъларда, кыргызларда *алда* рәвешендә әйтелә.

*Амма, Анна* кебек үк *алла* сүзен дә Изге Җир (Ана) һәм Ата улы *penis* дип тә аңларга була. Руста, мәсәлән, *Алла* дигән хатын-кыз исеме бар. Гарәп теленең Марокко диалектында алланың тулырак варианты *лалла* — «кай-нана», «өлкән кыз туган», «бикә», «ханым» дигән мәгънәләрне белдерә.

Христиан динендәге русларның мөселман «алласы» *Алла* рәвешендәге сүзне хатын-кыз исеме сыйфатында куллануларын берниндн логикага яраклаштырып булмый. Рус телендә бу сүз алынма булган очракта, *алла* гарәпләрдә

ислам дине барлыкка килгәнче үк кулланылган булган һәм руслар аны шул бик ерак чорларда ук алып калганнар дип фикер йөртергә туры килер иде. *Алла* сүзенә тәңгәл дип әйтерлек *Лалла*ның ислам динендәге гарәпләрнең бер диалектында «кайнана», «өлкән кыз туган» һ.б. дәрәҗәсендәге түбәнлеккә төшүе дә мөмкин нәрсә түгел.

*Алла* сүзе төркиләрдә яисә русларда гына түгел, башка телләрдә дә очрый. Кече Азиядәге үле хуррит телендә *алла (аллае)* дигән сүз «бикә» дигәнне белдергән. Гарәп теленең Мальта диалектында *алла* «алла» дигәнгә туры килә һәм сүз ахырында *h* авазы ишетелми. Бөекбританиядә *Аллапул,* Франциядә *Алласак* шәһәрләре бар. Көнбатыш Африкада *Аллада* дигән дәүләт булган. Тагын да ераккарак китсәк, Төньяк Америкада, Калифорниядәге хока телендә *алла* сүзе «кояш» дигәнне белдерә. Дөньяның икенче бер ягында — Индонезиягә карый торган Молук утрауларындагы ватбуела-2 телендә *олла* шулай ук «кояш» дигәнгә туры килә.

Татарча *алла*, мальтача *алла*, хокача *алла*, ватбуела-2 телендәгечә *олла* сүзләренең формасын һәм эчтәлеген чагыштырып карагач, *алла* сүзенең иң әүвәлге мәгънәсе «кояш» булган дигән фикергә киләбез. Серам утравындагы кеффинг телендә «кояш» *ола* дип атала. Сүз башындагы *а* сузыгы *о* га әйләнгән, *а* янындагы *л* тартыгы төшеп калган. Гарәпчә *аллаһу* сүзендәге *һу*, киресенчә, артык булып аңлашыла.

Щулай да *алла* сүзен ничек таркатабыз — *ал ла*мы, әллә *ал-ла*мы? *Ал-ла* дип бүлсәк, «кояш» Күк улы булып чыга. Ләкин Күк улымы соң Кояш? Моны ачыклау өчен этнографиягә мөрәҗәгать итәргә туры килә. Этнографик фактлар исә кояшны кайбер халыкларда ир затыннан, кайберсендә хатын-кыз затыннан булуы турында сөйли. Кайбер халыкларда ул Айның көндезгесе булып тоела. Казан татарлары карашынча Кояш — ата да, ана да.

Күк утрауларында яшәүче дайнҗерлар телендә «кояш» ла дип, таңа (танга) телендә *лаа* дип атала. Майа телендә ла иҗеге турыдан-туры «кояш» дигәнне белдерми, ләкин «олы», «хаким» дигән мәгънәләрдә кулланыла.

Шул рәвешчә, *алла* чынлыкта Күк улы да, Җир улы да түгел икән. *Ал* иҗекләрен уңай сыйфат белдерүче сүз, *ла* иҗеген «кояш» дип уйласак, *ал ла* тулаем «изге (бөек) кояш» дигәнне аңлата торган сүз булып чыга.

Алла сүзенең «изге кояш» булуын ачыкларга безгә *алаша* сүзе дә ярдәм итә ала. *Алаша* бары казан татарлары, кырым-татар, госманлы-төрек телләрендә генә кулланыла икән. Сүзне *ала-ша* дип таркатсак, бу Су-Күк улы булачак.

Ләкин печтерелгән, ягъни ирлек әгъзасының бер өлеше кисеп ташланган хайванның «Су-Күк улы» булуы мөмкин түгел. Татарча «күк улы» булган ат исемнәреннән *айгыр, тулпар, тарпан* атамаларын күрсәтергә була.

Шулай да нишләп мескен *алаша* «күк уллары» рәтенә керде икән соң? Әгәр без *алаша* сүзен кайчандыр ике *л* белән *аллаша* рәвешендә әйтелгән булырга тиеш дип фикер йөртсәк, бөтен нәрсә үз урынына утырачак. Ике *л* белән әйтелә торган *алла* кеффинг телендә *олага* әйләнгән кебек, *аллаша* да бер *л* белән генә әйтелә торган *алашага* әйләнеп калган булырга мөмкин. *Аллаша*ның гадирәк мәгънәсе — «алла улы», киңәйтелгән мәгънәсе исә — «изге Кояшка корбан итеп бирелгән хайван».

Төрки халыкларда кояшка корбан итеп ат бирү элек киң таралган булган. Б.э.к. V гасырда яшәгән массагетлар турында Геродот: «Алар хөрмәт иткән бердәнбер алла ул — Кояш. Кояшка алар ат корбан итеп бирәләр» ди (Г, I, 216). Урта гасыр төркиләрдән берсе савирлар да «Күк һәм яктылык алласы Тәңре ханга ат корбан итеп биргәннәр» (Плет, 175 бит).

Кояшка ат корбан итеп бирү башка халыкларда да булган. Мәсәлән, греклар корбан атын диңгезгә төртеп төшергәннәр. Кояшка багышланган атны төркиләр печтерә торган булганнар. Мәсәлән, туваларда корбанга бирелә торган ат, һичшиксез, печтерелгән булырга тиеш. Геродот телгә алган скиф кабиләләрендә дә корбан атларын печтерә торган булганнар. Скифларның атны печтерүләре турында Геродоттан соңрак яшәгән Страбон да телгә ала. «Атларны юашландыру өчен печтерү йоласы барлык скиф һәм сармат кабиләләренең бер үзенчәлеге булып тора» ди Страбон (С, VII, IV, 8).

Ник печтергәннәр икән соң кояшка багышланган атны борынгылар? Страбон уйлаганча, атларны юашландыру өченме? Юк, аның өчен генә түгел. Безнеңчә, моның тирән мәгънәсе бар. Кояш — әйтелгәнчә, бер үк вакытта ир затыннан да, хатын-кыз затыннан да дип исәпләнелә. Шул ук вакытта ул ир генә дә түгел, хатын-кыз гына да түгел. Галәм масштабында ул үзе Ата һәм Ана улы, ләкин җирдәге тереклеккә карата ул — ата да, ана да. Төнне ул анасы Җир карынында уздыра һәм теге дөньяның хакименә әверелә. Иртән ул яңадан туа һәм Күккә аша. Әгәр кояшның табигате ике җенесле икән, димәк, аңа багышланган корбан аты да ир затыннан гына яисә хатын-кыз затыннан гына булмаска тиеш.

Корбан атын печтерүнең дини-фәлсәфи нигезе, безнеңчә, менә шунда.

Монысы мәсьәләнең бер ягы. Мәсьәләнең икенче ягы да бар. Кояш, дөньяга туып, күккә күтәрелә бару белән, элеккеләр исәпләвенчә, һәр төрле каршылыкка очрый. Җир асты дөньясында да аны «адым саен» дошманнар сагалап тора. Борынгы Мисыр динчеләре исәпләгәнчә, кояш алласы Ра үзенең дошманнары — аждаһалар, җыланнар белән туктаусыз көрәш алып барган. Апопи дигән аждаһа, мәсәлән, Раның иң явыз дошманнарыннан булган, имеш. Кайчагында аждаһа кояшны тотып ала һәм йота башлый. Кояш тотылганда нәкъ менә шундый куркыныч хәл барлыкка килә. Әгәр дә мәгәр аждаһа кояшны кабып йотса, ул вакытта бөтен дөньяны караңгылык биләп алыр, җирдә тереклек туктап калыр иде. Борынгы кеше шулай дип фикер йөрткән. Ул моңа чын күңелдән ышанган. Үзенең дошманнары белән сугышта кояш җиңеп чыксын өчен өзлексез рәвештә аңа көч өстәп торырга кирәк дип уйланылган.

Гомумән, аллаларга багышлап корбан бирү йоласы менә шул җирлектә барлыкка килгән. Корбан бирүнең төрле формасы булган. Борынгы Мексика кабиләләре кояшка корбан итеп сугышта әсир төшкән яшь сугышчыларның йөрәкләрен биргәннәр. Борынгы халыкларда корбан малын чалып, аның канын кояшка багышлау да киң таралган булган. Корбанга шулай ук корбан малының ирлек әгъзасын бирү йоласы да кулланылган. Без инде күреп киттек: бик борынгы заманнарда табигатьтәге барлык хәрәкәт ирлек әгъзасы хәрәкәтенә тиңләштерелгән. Барлык халыкларда аллалар иргә һәм хатынга (Атага һәм Анага) бүленгән. Җенес әгъзаларына табыну, аларны изгеләштерү барлык халыкларда булган.

Ир затындагы атны печтерүнең нигезе менә шуннан гыйбарәт. Төркиләрнең *алаша*ларын борынгы греклар гына түгел, борынгы кытайлар да белгәннәр. Б.э.к. 126 елда Даваньда (хәзерге Фирганәдә) булган атаклы кытай сәяхәтчесе Чжанцань тир урынына кан чыга торган яхшы атларны «тянь ма» — Күк атлары дип атаган. Мондый атларның борынгы кытай текстларында (Хань чорыннан башлап) *алача* сүзе белән аталып йөртелүе ачыкланган.

Шул рәвешчә, татарча *алла* ул «изге (бөек) кояш» һәм шул ук вакытта «алла» да икән. Димәк, дингә табынучылар «алла бардыр, бердер; уңда да түгел, сулда да түгел; артта да түгел, алда да түгел» дип инанган нindидер илаһи көч, серле көч чынлыкта без көн дә күрә торган, безгә җылылык, яктылык бирә торган гап-гади (?!) кояш булып чыкты. *Алла*ның «кояш» булуы динле кешеләр өчен дә, динсезләр өчен дә күптән инде онытылган, тик аның — изге, бөек *Ла*ның үлемсез исеме генә сакланып калган.

## 28. АЛМАШЛЫК БЕЛДЕРҮЧЕ СҮЗЛӘР

Алмашлыкларның бер, ике, өч, хәтта күбрәк иҗеклеләре дә була. Төзелешләре белән алмашлыклар бүтән төрдәге сүзләрдән берни белән дә аерылмыйлар.

Татарча берлек сандагы беренче зат алмашлыгы *мин* сүзен *ми-н* рәвешендә таркатырга һәм Ата улы дип аңларга була. *Мин, мина, минә* рәвешендәге беренче зат алмашлыклары төрки һәм төрки булмаган бик күп телләрдә очрый. Мәсәлән, Көньяк Африкадагы зулу телендә бу сүз *мина*, суахили телендә беренче класс бүленешендә мина, үле тасмания телендә *мина*, фин-угор телләреннән берсе лив телендә *мина*, вепса, фин телләрендә *минә* буларак кулланыла һәм кулланылган.

Төрки телләргә карый торган гагауз телендә беренче зат алмашлыгы берлектә *бән*, уйгур телендә *мән*, каракалпак, үзбәк телләрендә *мен* дип атала. Русча «мин» *йа*, немецча *их* дип атала. Индонезия телендә шул ук мәгънәдәге сүз *сайа* буларак мәгълүм. Көньяк Америкадагы яноама телендә «мин» *каминйа* рәвешендә әйтелә.

Мисаллардан күренгәнчә, әлеге сүзләрдә бернинди уртаклык юк сыман. Шулай да беренче зат алмашлыкларына карата берәр төрле уртак фикер әйтеп буламы? Мәсәлән, *каминйа* сүзен ничек таркатырга? Сүзнең *мин* өлеше безгә якын «мин»гә, *йа* өлеше русча «*йа*»га туры килә дип фикер йөртергәме?

Бу уңайдан без немец телен искә төшерәбез. Немец телендә зат алмашлыкларының билгесез формасы бар. «Мин» төшенчәсен белдергән *их* сүзенә билгесез формада *бин* ялгана. Немецча *их бин* дип әйтсәк, бу «мин бар» булып аңлашыла. Әлеге сүзләрне *их-бин* дип иҗек методы нигезендә аңларга тырышсак, бу «ана улы» булачак. Яноама телендәге *каминйа* сүзен дә *ка-мин(йа)* рәвешендә таркатырга була.

Аккад телендә гомуми «мин» *анаку* дип атала. Шул ук телдә «син» ирләр затында *ат та*, хатын-кыз затында *ат ти* дип атала. *Анаку* сүзен *ана-ку*, ягъни ана улы, «син» мәгънәсендәге *атта* һәм *атти* сүзләрен *ат-та, ат-ти* дип таркатабыз. «Мин» Ана улы булгач, «син» Ата улы булып аңлашыла дип әйтә алабыз. Борынгы яһүд телендә «мин» *аноки* дип аталган. Монда да сөйләүче үзен «ана улы» дип исәпли.

Шулай итеп, беренче зат алмашлыгы «ана улы» да, «ата улы»да була ала. Шулай да беренче зат алмашлыгының кем улы булуы сөйләүченең үзенең кем улы булуына кайтып кала, ахрысы. Әйтик, *мин* сүзен ир кеше әйтсә, ул үзен, һичшиксез, «ата улы» дип исәпли. Бу очракта

ир кеше үзен ир дип белә. Шул ук *мин* сүзен хатын-кыз әйтсә, ул үзен *мин*нең, ягъни ир затындагы кешенең «улы» — капма-каршысы итеп исәпләячәк. Шумер телендә, мәсәлән, хатын-кыз *мин* дип атала. *Мин* урынына *мән* кулланганда шуңа охшаш ситуация барлыкка килә. *Мән* сүзен ир кеше әйтсә, ул үзен ата улы, ир затындагы кеше дип исәпләячәк, хатын-кыз әйтсә, аның өчен *мән* — «ана улы» булып аңлашылачак. Тора-бара болай нечкәләп тору онытылган, *мин, мән, бин, бән* формалары төрле телләрдә ирләр өчен дә, хатын-кыз өчен дә уртак формага әверелгән. Монда, әлбәттә, без төрки телләрне күз алдында тотабыз. Халык иҗатында һәм иске язма әдәбиятта татарда еш кына *мин* урынына *бән* кулланылган. Димәк, татарларның барысы да үзләрен *мин* дип исәпләмәгәннәр.

Кайбер телләрдә ике кешегә карата гына кулланыла торган зат алмашлыклары бар. Коряк телендә «без икәүбез» *муйи* дип, «сез икегез» *туйи* дип атала. Бу сүзләрне *му, йи* һәм *ту, йи* рәвешендә таркатсак, «син дә, мин дә — Ана уллары» дигән мәгънә барлыкка киләчәк.

Алютора телендә «без күбәү» һәм «сез күбәү» мәгънәсендәге зат алмашлыклары *мурувви* һәм *туруввн* дип атала. Әлеге сүзләрне *му, рув, ви* һәм *ту, рув, ви* рәвешендә таркатабыз, һәр ике сүз уртасындагы тулы булмаган *в* иҗеге артык сыман. Ягъни әлеге алмашлыклар әү-вәл *ма, ру, ви* һәм *ту, ру, ви* булган дип әйтә алабыз. Димәк, «без күбәү», «сез күбәү» алмашлыклары алютора телендә «мин», «син», «ул» алмашлыкларын бер-бер артлы санап, тезеп чыгу юлы белән ясалган икән дип әйтергә була.

Дөньядагы күп кенә телләрдә, алютора һәм коряк телләрендәге кебек, беренче зат алмашлыклары *му, ми, ме, мы, ма* иҗекләре белән, икенче зат алмашлыклары *ту, ти, те, ты, та* иҗекләре белән ясала яисә шул иҗекләрдән башлана. Монда бик борынгы кешенең иҗекләргә карата үз карашы чагыла булса кирәк. Мәсәлән, татарча *мин* белән *син* алмашлыкларының сузыклары һәм ахыргы тартыклары бертөсле, сүз башындагы тартыкларның төрлечә булуы да шуңа ук ишарәли. Гадиләштереп әйткәндә, *ми* иҗеге яисә *м* тартыгы бик борынгы төркиләргә якынрак һәм изгерәк, *си* иҗеге һәм *с* тартыгы читрәк һәм кадерсезрәк булган, күрәсең. Японнар өчен киресенчә булган, ахрысы. Япон телендә «сез барыгыз да» мәгънәсендәге зат алмашлыгы *минамина* дип атала. Ике мәртәбә кабатланган мина күплек төшенчәсен белдерә. Күрәсез, японча *мина* татарчадагы һәм кайбер башка телләрдәге беренче затны түгел, бәлки икенче затны, читрәк, ятрак кешеләрне аңлата.

Алмашлык белдерүче сүзләр мисалында без бик борынгы заманнарда нинди телләрнең бер-берсенә тугандаш булуын һәм шул ук вакытта бик борынгы кешенең сузыкларга карата гына түгел, тартыкларга карата да шактый талымчан булуын ачыклый алабыз.

## 29. САН БЕЛДЕРҮЧЕ СҮЗЛӘР

Татарча ике иҗекле *бер, мең* кебек сүзләрнең беренче иҗекләре *а* сузыклы, икенче иҗекләре *а* сузыклы да, *у* сузыклы да булырга мөмкин. Шулай ук ике иҗекле *өч, йөз* кебек сүзләрнең беренче иҗекләре дә элегрәк *а* сузыклы булган. *Ө* сузыгы элегрәк *э* рәвешендә әйтелгән. Кайбер диалектларда *өч* диясе урында *эч* дип сөйлиләр. *Төзү* белән *тезү, тәтү* белән *тетү* нигездә бер үк сүзләр.

*Ике, дүрт, биш, ун* кебек сан сүзләренең беренче иҗекләре *у* сузыклы. Беренче иҗекләре *а* яисә *у* сузыклы булган гади сан сүзләрен чагыштырып карагач, кайбер закончалыклар күзгә ташлана. Мәсәлән, *бер* сүзен *бе-р* дип таркатсак, бу «су-күк» яисә «ата» булачак. *Ике* исә, киресенчә, «җир», «ана» дигәнне белдерә.

Күп кенә башка телләрдәге «бер» һәм «ике» саннарын белдерүче сүзләр шушы ук принципта ясалган. Мәсәлән, лезгин телендә «бер» — *бара*, баск телендә — *бат*, волоф телендә — *бен*, орок телендә — *геда*, һауса телендә — *дайа*, фарсы телендә — *йәк*, мунҗан телендә — *йу*, гавайн телендә — *каһи*, сокоро телендә — *кети*, луганда телендә — му, афар, сахо, хамир телләрендә — *ти*, этруск телендә — *ту*, корей телендә — *хана*, ахвак телендә — *чебе* дип атала.

«Ике» санын белдерүче сүз бурушаски телендә *алти*, ганда (луганда) телендә *бири*, сура телендә *вул*, русча *два*, буги, даяк, илоко, купаң телләрендә *дуа*, негидаль телендә *дүл*, найка телендә *ир*, кави телендә *руа*, бербер, хуррит телләрендә *син*, герка телендә *фуло*, аккад телендә *шина*, чан телендә *җир* рәвешендә формалашкан.

Соңгы мисал аеруча игътибарга лаек. Кайчандыр бикбик ерак заманнарда татарча «җир» дә, чан телендәге «ике» дә бер үк мәгънәдәге һәм бер үк формадагы сүз белән аңлатылган. *Җир* сүзе, күрәсең, ике телдә дә «җир» мәгънәсендә дә, «ике» мәгънәсендә дә кулланылгандыр дип әйтергә була. Бербер, хуррит телләрендә «ике» саны *син*, аккад телендә *шина* буларак формалашкан. Татар телендә *син* «ике»не түгел, икенче зат алмашлыгын, ягъни сөйләүче өчен «икенче дәрәҗәдәге» кешене белдерә. Борынгы шумерларның Ур шәһәрендә ай алласы *Наннага* табынганнар. Нанна алласын күрше семитлар *Син* дип

атаганнар. Монда да шул ук: беренче — Кояш, икенче — Ай; беренче — Ата, икенче — Ана.

Бурушаски телендәге «ике»нең *алти* булуы да безне уйланырга мәҗбүр итә. *Алти (алты)*га охшаш мисалларны башка телләрдән дә табарга була. Мәсәлән, таити телендә «ике» *пити* дип атала, русча «биш» *пять* сүзенең кыек килештәге формасы *пити*.

«Ике»дән соң килә торган сан белдерүче сүзләр ничек ясалган соң — Ата улы, Ана улымы, әллә башкачамы?

Татар телендәге һәм кайбер башка телләрдән «өч» саны сүзләре нигезендә фикер йөрткәндә, мондый сүзләр Ата улы да, Ана улы да түгел, бәлки үзләре үк Ата һәм Ана булып аңлашыла. Мәсәлән, «өч» музгу телендә — *даи*, бурушаски телендә *иске*, борынгы япон телендә *ми*, тай телендә *сам*, кытай телендә *сан*, сван телендә *семи*, хет телендә *тари*, һова телендә *телу*, мультани телендә *ти*, рус телендә *три* (ягъни *тери*) дип атала.

Шул рәвешчә «өч» саны сүзләренең мәгънәләре дә, формалары да «бер» саны сүзләренә тәңгәл икән.

Татар телендә «өч»тән унга кадәр булган берничә сан сүзе «җир» («ана») төшенчәләренә туры килә. Мәсәлән, *биш, алты, җиде, ун*. Татарча *йөз (йез), мең, төмән (темән)* сүзләренең мәгънәләре һәм формалары «бер»гә һәм «өч»кә тигез. Димәк, *бер* дә, *өч* тә, *йөз* дә, *мең* дә, *төмән* дә Су-Күк (Ата яисә күп) дигәнне белдерәләр булып чыга.

Сан төшенчәсен белдерүче сүзләр барлыкка килгәндә, шулай итеп, «ата», «ана» мәгънәсендәге сүзләр төп рольне үтәгәннәр. Күрәсең, бик озак вакытлар дәвамында кешенең санау системасы «ата», «ана» ягъни «бер», «ике» төшенчәсеннән ары узмагандыр. Икегә кадәр булган санау системасыннан соң, ихтимал, өчтән дүрткә яисә бишкә кадәр санау системасы барлыкка килгән булырга мөмкин. Дүрттән-биштән соң унга кадәр санау барлыкка килгән булырга мөмкин. Уннан соң инде йөзгә, меңгә, ун меңгә кадәр санау зарурлыгы туган, һәрбер санау баскычының башында «ата»га һәм «бер»гә тәңгәл мәгънәдәге сүз торган.

Өчтән артык санау системалары булган барлык телләрдә шушы принцип саклангнмы, юкмы — әйтүе кыен. Моны ачыклау өчен бик күп телләрдәге сан белдерүче сүзләрне җентекләп тикшерергә кирәк булыр иде. Татар телендә исә «өч»тән соң килә торган *биш, алты, җиде, ун* сүзләре *ике* калыбында ясалган. Ләкин *дүрт* сүзе карап торуга «бер» булып аңлашыла. Әгәр сүз ахырындагы *т* тартыгын артык дип исәпләсәк, «дүрт»нең элекке формасы «ике»гә тиң дүр булачак. Кайбер телләрдә «ике» саны *дуа, дүл* рәвешендә ясалган. «Ике» була

алган *дуа, дүл* дә, татарча *дүр(т)* тә «дүрт» санын белдерә ала дип фикер йөртәбез. Рус телендәге «дүрт» *четыре* сүзе дә *җир-ана-ике* калыбында ясалган. Димәк, татарчадагы *дүрт* сүзенең ахыргы *т* тартыгын артык дип исәпләү гомуми логикага туры килә дип исәплибез. Шулай ук сигез, тугыз сүзләрендәге ахыргы *з* тартыклары да артык, ахрысы, дип әйтергә туры килә.

## 30. ЯРДӘМЧЕ СҮЗЛӘР

Катлаулы хис-тойгыларны, һәртөрле уй-фикерне белдерү өчен кешегә эти-әни, син-мин, бер-ике, бара-килә кебек гади әйтелешле сүзләр генә җитеп бетми, әлбәттә. Моның өчен бер төрле сүзләр икенче сүзләргә ялганырга, төрләнергә һәм өстәмә мәгънәле өстәмә сүзләр белән тулыландырылырга тиеш. Мөстәкыйль сүзләрне бер-берсенә ялгауда, аларның мәгънәләрен төрләндерүдә һәм конкретлаштыруда кулланыла торган иҗекләрне без ярдәмче сүзләр дип беләбез. Ярдәмче сүзләр төрле телдә төрлечә аталырга һәм аларның функцияләре дә төрлечәрәк булырга мөмкин. Шунлыктан монда барлык телләр өчен нинди дә булса уртак кагыйдәләр чыгару шактый кыен нәрсә. Без монда, гомумиләштерү максатын күз алдында тотмыйча, кайбер телләрдән алынган мисаллар белән генә танышырбыз. Бу танышлык моңарчы күп мәртәбәләр кабатланган һәм иҗек методы ярдәмендә исбатланыла торган төп фикерләрне куәтләүне максат итеп куя.

Немец телендә һәрбер исем алдыннан «артикль» дип аталган ярдәмче сүзләр кулланыла. Ирләр затындагы исем алдыннан *дер*, хатын-кыз затындагы исем алдыннан *дие* артикльләре әйтелә. Мәсәлән, *дер ман* булса «ир кеше», *дие фрау* булса, «хатын-кыз» була. *Дер* артикле монда — «ата», «ир» дигәнне, *дие* артикле — «ана», «хатын-кыз» дигәнне белдерә.

Татар телендә дә исем алдыннан еш кына артикль сыман *бер* сүзе кулланыла. Мәсәлән, *бер* кеше, *бер* өй. Дөрес, татар телендә *бер* ярдәмче сүзе исемнең ир затынданмы, хатын-кыз затынданмы икәнлеген белдерү өчен хезмәт итми. Ләкин бик борынгы заманнарда мондый *бер* дә, бәлки, нәкъ менә немец телендәге кебек үк максатларда кулланылгандыр дип әйтәсе килә.

Майа телендә дә исемнәр алдыннан артикль сыман ярдәмче сүзләр килә ала. Майа телендә *иш* иҗекләре хатын-кызны, *ах* иҗекләре ирләрне белдерә. Мальгаш телендә ир затындагы сүзләрне белдерү өчен — *илай*,

тай телендә — *чай* сүзе, шул ук тай телендә хатын-кыз затын белдерү өчен — *йиң* сүзе кулланыла.

Банту телләрендә исемнәр классларга бүленә. Шунлыктан һәрбер исем алдыннан аның нинди класстан икәнлеген билгели торган ярдәмче сүз куела. Мәсәлән, берәр исем алдында *му* иҗеге булса, бу аның «кеше» икәнлеген аңлата. Луганда телендә *ку* классификаторы-ярдәмче сүзе кемнең, нәрсәнең кем һәм нәрсә өстендә булуын яки кемнән, нәрсәдән ерак булуын аңлата. Луганда телендә кү ярдәмче сүзе фигыль алдыннан да килә ала.

Банту телендә сөйләшүчеләр Африкада, язгулям телендә сөйләшүчеләр Урта Азиядә яшиләр. Банту телләренә бернинди катнашы булмаган язгулям телендә *ку* ярдәмче сүзе берәр төрле хәрәкәт ясарга өндәү мәгънәсен белдерә. Ягъни нәкъ луганда телендәге кебек үк фигыль күрсәткече ролен үти.

Бирма телендә дә классификатор дип аталган ярдәмче сүзләр кулланыла. *Йау* ярдәмче сүзе «кеше»не белдерүче сүзләр янында килә. Бирма телендә русча «голова», «вершина», «начало» дигәнне белдерү өчен *у* ярдәмче сүзе кулланыла.

Африкадагы луо телендә «өстә», «өстендә», «югарыда» мәгънәләрен белдерү өчен *ви* ярдәмче сүзе кулланыла.

*А* сузыклы иҗекләр, *у* сузыклы иҗекләргә капма-каршы буларак, ярдәмче сүз ролендә килгәндә, аста һәм ниндидер конкрет урында булуны аңлаталар. Татарча *җирдә* дип әйтәбез икән, бу җирнең өстендә түгел, бәлки җирнең эчендә яки җир белән бер тигезлектә икәнлекне белдерә. Шул ук мәгънә рус телендә *на* иҗеге ярдәмендә аңлатыла. *На* земле — *җирдә*, ләкин *над* землей — җир өстендә (җиргә тимичә тора). Бирмадагы качин (чҗиңпхо) телендә локатив дип аталган ярдәмче *сүз де (дә?)* иҗеге белән белдерелә, Jan Ka de сүз тезмәсенең мәгънәсе русча «в стране Солнца». Без бирмача белмибез, ләкин нинди сузыкның нәрсә аңлатканын истә тоткан хәлдә, әлеге мисалдагы *ка*ның «җир», *йан*ның «кояш» булуы ихтималын чамалау авыр түгел. *Де* исә татарча *җирдә* дигәндәге *дә* ярдәмче иҗегенә туры килә.

Иң ахырда тагын бер-ике мисал белән танышып китик. һауса телендә ир затындагы сүзләргә *о, у, и* суффикслары, хатын-кыз затындагы сүзләргә *а, ийа* суффикслары, ягъни шул ук ярдәмче сүзләр (иҗекләр) ялгана. Албан телендә ир затындагы исемнәр *и* һәм *у* сузыкларына, хатын-кыз затындагы исемнәр *а* сузыгына тәмамлана. Бу сузыкларны теге кайбер елга исемнәрендәге кебек, өстәмә иҗекләр дип атарга да була.

## 31. КҮПЛЕКНЕ БЕЛДЕРҮ

Телдә күплекне, берлекне белдерү *аз-күп, кече-зур* сыйфатларын белдерүдәге кебек үк принципларга нигезләнгән. Икенче төрле итеп әйткәндә, *а* сузыклы иҗекләр ялгыз килеш тә берлекне, азлыкны, *у* сузыклы иҗекләр ялгыз килеш тә күплекне аңлата алалар. Мәсәлән, луо телендә *ла* иҗеге берлекне, *лу* иҗеге күплекне белдерә. Луо телендә *ла-җок* — «сихерче», *лу-җок* — «сихерчеләр» була. Күплекне белдерү шулай да төрле телдә төрлечә формалашкан. Рус телендә, мәсәлән, күплек төшенчәсе сүзнең басымын яисә сүз ахырындагы иҗекләрнең әйтелешен үзгәртү аша белдерелә. Русча «өй» *дом* сүзенең ахырына *а* сузыгы өстәсәк, бу — «өйләр» булачак. Шулай итеп, *дом*нан *дама* сүзе барлыкка килә. Сүз уңаеннан әйтик, рус телендә күплекне белдерүдә генә түгел, башка төрле мәгънәләрне белдерүдә дә *дом-дамá* рәвешендәге күчешнең роле зур булган, ахрысы. Мәсәлән, халык атамасы рус сүзенең каян, ничек барлыкка килүе турында күптән инде бәхәс бара. Ләкин монда ул кадәр бәхәсләшерлек нәрсә дә юк сыман. Сүзнең иң әүвәлге формасы *рус* түгел, бәлки *руский* булган кебек. *Русский*ның бүгенге мәгънәсе «руснык» дигәнгә туры килә. Әүвәлге әйтелешендә һәм теоретик яктан *рус-ки* ул гап-гади «җир улы»н белдерә. Русча «корсак» мәгънәсендә *пузо* сүзен алып карыйк. «Корсак» — Ана улы булырга тиеш, чөнки корсаклы булу аналарга хас күренеш. Ләкин чынлыкта *пузо* «ана улы» түгел. *Пузатый* (корсаклы) дигәндә *о* сузыгы *а* сузыгына әйләнә, басым да беренче иҗектән икенче иҗеккә күчә. *Пузо* сүзенә *тый*, ягъни *ти* иҗеге ялгана. Мәгънәсе «корсаклы» булса да, *пуза-тый* сүзе русча *живо-т*, татарча *кур-сак* калыбына туры килә торган «ана улы» булып аңлашыла.

Күплекне белдерү немец телендә аеруча катлаулы һәм гомуми тел үсеше күзлегеннән караганда, шактый җитлекмәгән һәм стандартлашмаган. Грамматика китаплары немец телендә күплекне белдерү ысулларын берничә төркемгә бүлеп аңлаталар. Албан телендә исә күплекне белдерү немец телендәгегә караганда да катлаулырак, һауса телендә күплекне белдерү өчен берлек сандагы исемнең соңгы иҗеге үзгәртелә. Мәсәлән, һауса телендә *мижи* — «ир кеше», *маза* — «ир кешеләр» була. Муби телендә күплек төшенчәсе исемнең кайбер сузыкларын үзгәртү нәтиҗәсендә барлыкка килә. *Гир* — «өй», *гаре* — «өйләр» була, ягъни бу телдә дә *дом-дамá* мисалындагы сыман үзенчәлек күзгә ташлана.

Күплекне белдерүнең иң гади һәм иң борынгы фор-

масы берлектәге сүзләрне кабатлап әйтү булган, ахрысы. Татарча *тау-тау, өем-өем, эт-бет, бала-чага, мал-туар* кебек парлы сүзләр моңа мисал була ала. Борынгы төрки телдәге *балбал* белән грекча *барбар* («варвар») сүзләре ике мәртәбә кабатланган *бал* һәм *бар* сүзләреннән гыйбарәт. Русча *лүди* («кешеләр»), ассирича *нишу* («халык») «күп кеше» дигәнне белдерәләр. Бу сүзләрне без *лү, ди* һәм *ни, шу* рәвешендә таркатабыз һәм һәр иҗекне «җир улы», ягъни «кеше» дип беләбез.

Татарча *көтү (кү-тү)* сүзе дә күплекне күз алдында тота. Карай телендә «көтү» *сүрү* дип атала. *Кү* һәм *тү*, *сү* һәм *рү* иҗекләренең һәркайсы «җир улы». Элекке татар телендә «гаскәр» *чиру* дип аталган. Борынгы төрки телдә «гаскәр» *сү* иҗеге ярдәмендә генә белдерелгән. *Сү* үзе генә күплек төшенчәсен бирә алмый. Шулай да әлеге *сү* иҗегенең «көтү» һәм «гаскәр» мәгънәсендәге *сүрү, чиру* сүзләре белән бер оядан икәнлеге үзеннән-үзе аңлашылып тора булса кирәк.

Алмашлыклар турында сөйләгәндә без алютора һәм коряк телләрендә ике кешегә карата гына кулланыла торган зат алмашлыклары белән таныштык. Хәзер шул сүзләрне күплек белдерү күзлегеннән карарга була. Мәсәлән, коряк телендә *муйи*, алютора телендә *мури* «без икәү» дигәнне белдерә. Ләкин чынлыкта болар *сүрү* һәм *чиру* тибындагы сүзләр.

Бүгенге төрки телләрдә, чуваш телен исәпләмәгәндә, күплек төшенчәсе *лар* иҗекләре ярдәмендә белдерелә. Ларның *нар, дар, тар* вариантлары да мәгълүм. Күплек белдерүдә *дар-тар* татар телендә кулланылмый. Карачай-балкар телендә күплек *ла* ярдәмендә генә белдерелә ала.

Шулай да нинди *лар* соң бу? Ничек барлыкка килгән һәм иң әүвәлге мәгънәсе ни булган бу *лар* иҗекләренең? Гамәлдәге тел гыйлемендә, бик күп сорауларга җавап табылмаган кебек, бу сорауга да җавап табылмаган. Бүгенге тел гыйлеме тарафдарлары исәпләгәнчә, бүгенге төрки телләрдә «генетик» төрки сүзләр *л, р, м, н* тартыкларына башлана алмый. Шулай да кайбер төрки телләрдә *л р, м, н* тартыкларына башланган сүзләр очрый икән, алар, гадәттә, башка телләрдән алынган дип игълан ителә. Шул ук вакытта теләсә нинди төрки сүздә дигәндәй (күбесенчә сүз уртасында, сүз азагында) *л, р, м, н* тартыклары бар. Шуңа күрә төрки телләрдә «генетик» *л, р, м, н* тартыклары бармы-юкмы дип сүз кузгату үзе үк урынсыз.

Дөнья телләренең кайберләрендә йә *л* тартыгы, йә *р* тартыгы юк. Ни өчен дигәндә, әлеге телләрдә сөйләшүчеләр дөнья яратылганда ук йә *л* тартыгын, йә *р* тарты-

гын әйтә алмаганнар. Мәсәлән, японнарда *л* тартыгы юк, чөнки японнарның теле бу тартыкны әйтү өчен яраклашмаган. Шунлыктан японнар *л* тартыгы белән әйтелә торган чит сүзләрне үз телләренә кабул иткәндә, аларны (чит сүзләрне) *р* тартыгы ярдәмендә үзләштерергә мәҗбүрләр. Без моны табигый күренеш дип исәплибез.

Төрки телләрдә, әлбәттә, *л* да бар, *р* да бар, тик алар чынлап та сүз башында нишләптер бик сирәк кулланылалар. Тел гыйлеме өйрәткәнчә, кушымчалар кайчандыр мөстәкыйль мәгънәле сүзләр булган дидек без. Бәс, шулай икән, күплек кушымчасы *лар* да кайчандыр мөстәкыйль сүз булгандыр, бәлки? Алайса нишләп ул *л* тартыгына башлана? Әллә безнең күплек кушымчабыз *лар* да гарәп-фарсыдан алынганмы? Күрәсез, бәйләнә китсәң, әллә нәрсәләр казып чыгарырга була.

Күплек күрсәткече *лар*ның ничек барлыкка килүен белү өчен безгә кайбер нәрсәләрне яңадан кабатларга туры килә. Иң әүвәлге сүзләр *а* һәм *у* сузыклы иҗекләрдән гыйбарәт. Бер иҗекле сүзгә икенче иҗек ялгасак, беренче иҗек йә Атаны, йә Ананы, икенче иҗек аның «улын» белдерәчәк. Бик борынгы карашлар нигезендә Кояш Җирнең һәм Суның-Күкнең улы исәпләнелә. Төрки телләрдә «кояш» *ла* дип тә, *ра* дип тә атала. Төрки телләрдәге күплек белдерүче *лар* менә шушы *ла* һәм *ра*ның кушылмасы булып тора.

Белгечләр кытай телендә күплек күрсәткече юк дип язалар. Ләкин мондый фикер бик үк дөрес түгел, ахрысы. Академик Н. И. Конрад «аерым дәүләтләр» мәгънәсендәге *лего* сүзенең *ле* иҗеген «күплек күрсәткеч префикс» дип исәпли (Конр, 421). Димәк, борынгы кытай телендә дә күплек күрсәткече булган һәм ул *ле* иҗеге белән белдерелгән. Бу исә безне шактый еракка һәм тирәнгә алып китә. Шулай да без әлегә ерак тарихка кермәскә тырышабыз.

## 32. ИҖЕКЛӘРНЕҢ ҮЗАРА ЯЛГАНУ ТӘРТИБЕ

Хәзер инде без беләбез: бүгенге көндә «сүз» дип йөртелә торган лексик берәмлекләр чынлыкта мөстәкыйль мәгънәле иҗекләрдән торган аерым фразалар, хәтта кыска-кыска гына җөмләләр икән. Без тикшергән барлык «сүз»ләрнең: исемнәрнең, фигыль, сыйфат, алмашлык һәм саннарның, ярдәмче сүзләрнең иң әүвәлге мәгънәләре җир, су, күк, ата, ана һәм улы төшенчәләренә кайтып кала икән.

Менә шундый сүзләрдә иҗекләр янәшәлек юлы белән ялгана. Ике яисә аннан да күбрәк иҗекнең һәркайсының үз урынында дөрес урнашуы нәтиҗәсендә сүздә,

«җөмләдә» төзек һәм тәмамланган мәгънә барлыкка килә. Әйтик, татарча *бала* сүзендәге *ба* да, *ла* да теоретик яктан бер үк хокуктагы иҗекләр. Ләкин татарча чынлап та «бала» мәгънәсендәге сүз барлыкка килсен өчен *ба* иҗеге беренче, *ла* иҗеге икенче булып әйтелергә тиеш. Чөнки *ла* ул «кояш» һәм галәм киңлегендә *ба*ның улы гына. Шулай итеп, *бала* сүзеннән күренгәнчә, *ба* — буйсындыручы, *ла* — буйсынучы булып аңлашыла.

Әгәр «сүз» алдыннан уңай яки кире сыйфат белдерүче яңа төр иҗекләр килсә, мәсьәлә катлаулана төшә. Төрки тел нормалары нигезендә сыйфат һәрвакыт сыйфатланмыштан алдарак килә. Мәсәлән, уңай сыйфат белдерүче *ал, ар* һ.б. сыйфат сүзләре шул рәвешчә ялгана. Суга-Күккә, Атага хас изгелек, бөеклек, яхшылык, шулай итеп, бар нәрсәдән өстен санала. Кыскасы, төрки телләрдә иҗекләр тәртибендә сыйфатның урыны — түрдә.

Хәрәкәт белдерүче сүзләр исә төрки телләрдә исем артыннан килә.

Сүздә иҗекләрнең менә шул рәвешчә «үз урыннарын белеп», кеченең олыга буйсынуы сыман, билгеле бер тәртиптә ялгануын без уңай ялгану яисә уңнан сулга таба ялгану дип беләбез.

Иҗекләрнең уңай тәртиптә ялгануы төрки телләрдә аерым сүзләрдә, сүз төркемнәрендә, җөмләдә бөтенләй диярлек үзгәрешсез кала. Мәсәлән, «җир улы» дигәндә җир — беренче урында, улы — икенче урында урнаша. Икенче төрле итеп әйткәндә, бала ата-анадан әүвәлгерәк була алмаган кебек, төрки телдә, мәсәлән, рус телендәге кебек Сын земли — «Улы җир» тәртибендәге ялгану була алмый.

Дөньядагы бик күп телләрдә ике-өч, хәтта аннан да күбрәк иҗекләрдән ясалган сүзләрдә, ягъни бүгенге көндә «сүз» дип аталган берәмлекләрдә иҗекләрнең ялгану тәртибе уңай юнәлештә. Тик шулай да һәрбер телдә мондый принцип эзлекле рәвештә сакланмый. Кайбер телләрдә лексик берәмлекләрдәге иҗекләрнең ялгану тәртибе кире юнәлештә. Сүзләрнең үзара ялгануында исә кире тәртип ныграк күзгә ташлана. Бу исә ике-өч, өч-дүрт иҗекле сүзләргә күчкән вакытларда адәм баласының дөньяга караштагы төп принциплары үзгәрешсез калса да, тора-бара ул принципларның төгәл үтәлми башлавы турында сөйли.

Шул рәвешчә, телләр үсешендә (кытай тибындагы телләрне исәпләмәгәндә), нindидер бер чорда бер-берсенә капма-каршы булган ике төрле юнәлеш барлыкка килә. Мондый хәлне кайчандыр бердәм коллектив булган бик борынгы җәмгыятьнең таркалуы белән дә, төрле коллек-

тив арасындагы «дини-идеологик» һ.б. көрәшләр белән дә аңлатырга була.

Шумер телендә төрки сүзләргә охшаш күп кенә сүзләр табарга мөмкин. Шул нигездә төрки телләр шумер теленә тугандаш дигән фикерләр дә әйтелә. Ләкин шумер телендә сүзләрнең үзара ялгану тәртибе — кире юнәлештә. Шумер теленең төрки телләр белән тугандаш түгеллеген исбат итүдә менә шушы хәл төп күрсәткеч ролен үти ала. Мәсәлән, шумер телендә *гар, гал* иҗекләре уңай сыйфатларны белдерә. *Гал* һәм *гар* иҗекләренең һәркайсын аерым алып караганда, әлеге сүзләрдәге иҗекләр уңай тәртиптә ялгана. Моның шулай икәнлеген без *гал* һәм *гар*ны төрки *ал, ар* иҗекләре белән чагыштырып та, *л, р* тартыкларының *га* («җир») иҗегеннән соң килүе белән дә нигезли алабыз. Ләкин шумер телендә зур өй мәгънәсендәге сүзтезмәсе ясарга теләсәк, бу «зур өй» тәртибендәге түгел, бәлки «өй зур» тәртибендәге тезмә булачак. Шумер телендә өй *э* дип, зур, әйтелгәнчә, *гал* яисә *гар* дип атала. *Э гал* шумерча «зур өй» була да инде. Шулай итеп, сыйфатланмыш (өй) зур сыйфаты алдыннан килде һәм лексик берәмлекләрнең үзара ялгануы кире тәртиптә ясалды.

Татарча *Казан* сүзенә *га* иҗеге ялгасак, ялганган иҗек юнәлеш килеш төшенчәсен белдерәчәк. Сүз ясау принцибы нигезендә, өстәмә информация белдерүче иҗекләр исемнән соң урнашалар. *Казан-га* дигәндәге *га* иҗегенең ялгануын без бу очракта өстәмә информация бирүнең бер төре дип карыйбыз. Мадура телендә исә юнәлеш төшенчәсен белдерүче *ка* иҗеге исем артыннан түгел, алдыннан килә. Мадура телендә «аллаяра ка Мадура» сүзтезмәсе русча «поплывает к Мадуре» дигәнне аңлата. Татарча без моны «Мадурага (йөзеп) барыр» дип әйтер идек. Русча «к Мадуре» тезмәсендә дә юнәлеш килеш белдерүче *к(а)* иҗеге, мадура телендәге кебек, исем алдыннан килә.

Нәрсә турында сүз барганын ныграк хәтердә калдыру максатыннан чыгып, тагын бер мисал белән танышып китик. Татарча (фәлән кеше) «исеменә» дигән мәгънәдәге сүз русча «на имя» (такого-то) рәвешендә әйтелә һәм языла. Татарча исеме сүзенә *нә* иҗеге кушсак, янә дә юнәлеш төшенчәсе барлыкка килә. Шушы ук фикерне русча имя («исем») ярдәмендә белдерәбез. Ләкин бу татарчадагы кебек *имя-на* рәвешендә түгел, бәлки татарчага капма-каршы тәртиптә *на-имя* рәвешендә була. Ярдәмче сүз ролендә кулланыла торган һәм юнәлеш килеш мәгънәсен бирә торган *на* иҗеге, шулай итеп, «исем» *имя* алдыннан килә. Кыскасы, улы Атасыннан акыллырак, дәрәҗәлерәк булып чыкты.

## 33. ТЕЛНЕҢ ТАРАЛУЫҺӘМ КҮП ТӨРЛЕ ТЕЛЛӘРНЕҢ БАРЛЫККА КИЛҮЕ

Югарыда без дөньядагы барлык телләрнең бер үк принципларга нигезләнгән булуын күреп киттек. Барлык телләр өчен уртак принциплар исә түбәндәгеләргә кайтып кала:

а) теләсә нинди телдә сүзләр тартык һәм сузык авазларның үзара аралашуы җирлегендә ясала;

б) барлык телләрдә мөстәкыйль мәгънәле иң әүвәлге сүзләр ялгыз сузыктан яисә тартык-сузык рәвешендәге иҗектән гыйбарәт;

в) һәр иҗекнең үз мәгънәсе бар: *а* сузыклы ялгыз иҗекләр Җирне, Ананы, хәрәкәтсезлекне һәм һәртөрле кире сыйфатларны белдерсә, *у* сузыклы ялгыз иҗекләр Суны, Күкне, Атаны, хәрәкәтне һәм һәртөрле уңай сыйфатларны белдерә.

Әгәр дә мәгәр телнең башлангычы бер үк карашларга нигезләнгән икән, димәк, тел бер генә үзәктә, бер генә коллективта барлыкка килгән дип әйтә алабыз. Мондый фикерне ныгыту өчен без маймул-кешенең бик ерак чорларда аерымланган төркемнәрдән торуын һәм һәр төркем әгъзаларының үз күршеләрен дошман дип исәпләүләрен искә төшерәбез. Аерымланып яшәүче төркемдә барлыкка килгән тел дошман исәпләнелгән күршегә яки күршеләргә ирекле рәвештә күчә алмаган, чөнки яңарак кына барлыкка килгән сигнализация ысулының (телнең) мәгънәсе, яшәү өчен кирәклеге-кирәксезлеге күршеләргә аңлашылмаган. Шуның белән бергә, күршеләрнең үзләренең дә күптән күнегелгән әзер тавыш сигналлары булган һәм аларда яңа сыйфатлы тавыш сигналлары булдыру ихтыяҗы әле тумаган.

Тел иҗат ителгән төркемнән, вакыт узу белән, яңа төркемнәр бүленеп чыккан. Яңа төркемнәрдән әкренләп шулай ук бүтән төркемнәр аерылып чыккан. Шулай итеп, телгә ия булган төркемнәр саны күбәйгәннән-күбәя барган.

Тел иҗат ителгән төркемнән бүленеп чыккан яңа төркем кешеләре, төп коллективтан, ягъни ата-баба төркеменнән аерымланып яшәүләре аркасында, күнегелгән сүзләрдәге кайбер авазларны үзгәртеп әйткәннәр. Мәсәлән, ата-баба коллективында «җир» *ба* дип, «су» *бу* дип аталган булырга мөмкин. Башкаланып чыккан коллективта исә «җир» *бә* дип, «су» *би* дип аталган булырга мөмкин. Төп коллективтан бүленеп чыккан яңа төркем вәкилләре иң әүвәлге авазларны, ихтимал, үзләренә ярашлы рәвештә үзгәрткәннәрдер дип әйтергә дә була.

Бер формадагы, бер үк мәгънәдәге иҗекләрнең төрлечәрәк әйтелешенә кыргый кешенең артикуляцион мөмкинлекләренең чикләнгән булуы да тәэсир иткәндер, әлбәттә. Мәсәлән, «җир» мәгънәсендәге *ба* иҗеген бер үк коллектив эчендәге кешеләр дә баштарак, ягъни тавыш сигналлары әйтелешенең нормалары тулысынча канунлашмаган чорларда, *ба, па, фа, ва* рәвешләрендә кулланган булулары ихтимал. Бит хәтта бүгенге телләрдә дә мондый төрлелек еш очрый. Моны бары тик диалектлар калдыгы дип кенә аңлатып булмый. Кайбер авазларның бер үк сүздә, бер үк позициядә бер-берсен алыштырып килә алулары ул тел яралганда ук булган. Бүгенге телләрдәге кайбер күчешләр бернинди үзгәрешсез дип әйтерлек шул борынгы заманнардан ук сакланып киләләр булса кирәк. Татар телендә, мәсәлән әле дә *мич-пич, теләү-келәү* дип сөйләү бар. Татарча *боз*, каракалпакча *муз* сүзләре кулланыла икән, монда инде *б* әүвәлгерәкме, *м* әүвәлгерәкме дип фәлсәфә куерту, гомумән, урынсыз. Төрки тел өчен *м* дә, *б* дә борынгы. Тик монда *у* һәм *о* сузыклары мәсьәләсендә генә беркадәр сүз булырга мөмкин. «Боз»ны Су улы дип белсәк, *му-з* сүзендәге *му* иҗеге «су»ның табигатен төгәлрәк чагылдыра дип кенә әйтергә була.

Телнең һәм телләрнең үсеп, тармакланып китүен, бигрәк тә аларның башлангыч чорларын без менә шул рәвешчә күз алдына китерәбез. Шулай да әйтергә кирәк, аерымланып яшәүче төркемнәрдәге телләр бик озак вакытлар дәвамында бер-берсенә бик якын булган булырга тиешләр. Телгә ия булган күршеләр бер-берсен бик яхшы аңлаганнардыр дип тә уйларга була. Ни өчен дигәндә, иң әүвәлге чорларда телнең кыска-кыска иҗекләрдән, ялгыз сузыклардан торган лексик фонды бик ярлы, грамматик чаралары бик гади булгандыр кебек. Бер иҗекле сүзләрдән соң ике, өч иҗекле сүзләр барлыкка килә башлагач, телләр арасындагы аерма да зурая башлагандыр кебек. Ләкин анда да әле телләр бер-берсеннән нык аерылмаган булырга тиеш. Бүгенге көндә Җир шарының төрле төбәкләрендә яшәгән һәм бер-берсенә туган түгел дип исәпләнелгән халыкларның телендәге охшаш сүзләрнең күп булуы нәкъ менә шул турыда сөйли дә инде.

Телләрнең таралуына һәм төрләнүенә вакыт кына түгел, ниндидер табигый һәлакәтләр дә тәэсир иткән булса кирәк. Борынгы мифларда барлык кешеләрнең элек һәркем аңлый торган ниндидер уртак телдә сөйләшүләре, ләкин аларның масаюлары, аллага каршы баш күтәрүләре

турында әйтелә. Җир тарихында һәртөрле һәлакәтләр — җир тетрәүләр, вулкан атылулар еш булган. Шундый һәлакәтләрдән соң кешеләр, туган җирләрен ташлап, төрле якка сибелергә мәҗбүр булганнар. Мәсәлән, Полинезия халыкларының Тын океандагы хәзерге утрауларына каяндыр читтән килеп урнашулары турында риваятьләр сөйләнелә. Америка халыкларында да борынгы ата-бабаларның ниндидер һәлакәттән соң каяндыр диңгез аръягыннан, көнчыгыштан күченеп килүләре турында төрле риваятьләр сакланган.

Кеше үткән озын гомер юлында телнең үсүе, таралуы гел тигез генә, шома гына бармаган. Телләрнең үсешенә яки томаланып юкка чыгуына күптөрле факторлар тәэсир иткән. Уңай шартлар туу нәтиҗәсендә кайбер телләр көчәеп киткән. Уңай шартлар булмаганда кайбер телләр, киресенчә, көчсезләнеп калганнар яисә, бүтән телләр тарафыннан йотылып юкка чыкканнар. Моның шулай икәнлегенә төшенү өчен төрле сугышлар белән, җиңүҗиңелүләр белән тулы Тарихка бер әйләнеп карау да җитә.

## 34. КЫСКАЧА ЙОМГАК

Без тәкъдим иткән иҗек методы, шулай итеп, телнең яралгы чорын һәм шул яралгыдан аның ничек, ни рәвештә үсеп, тармакланып китүен күз алдына китерергә ярдәм итә. Иҗек методының төп принциплары аерым телләрне, тел семьяларын гына түгел, гомумән, барлык телләрне өйрәнүдә таяныч ноктасы хезмәтен үти ала, чөнки чыгышлары ягыннан дөньядагы барлык телләр бертуган.

Болай дип әйтү кайберәүләргә кирәгеннән артык кыюлык булып тоелырга да мөмкин. Бит моңарчы да тел турында теорияләр, гипотезалар күп булган, ләкин аларның берсе дә тулы яклау тапмаган. Мәсәлән, чыгышлары белән барлык телләр бертуган дигән фикерне Италия галиме А.Тромбетти да әйткән, ләкин мондый гипотеза әлегәчә исбат ителгән дип исәпләнелми.

«Кирәгеннән артык кыюлык»ны аклау максатыннан чыгып без иҗек методы һәм элекке теория-гипотезалар арасындагы кайбер принципиаль үзгәлекләргә тукталып китмәкче булабыз. Иҗек методы иң әүвәлге телдәге иң әүвәлге сүзләр ялгыз иҗекләрдән торган дигән карашны яклый. Мондый фикерне башка галимнәр дә әйткән. Аерма нидә соң? Аерма шунда — башка галимнәр нинди иҗекнең нәрсә аңлатканлыгын да, сүз ясауда сузыклар-

ның ролен дә аңлый алмаганнар. Яңа мәгънәле сүзләр ясауда тартыкларның ролен инкарь итмәстән, без иң әүвәлге сүзләрнең мәгънәләре белән тартыклар түгел, бәлки сузыклар идарә итә дигән карашны яклыйбыз.

«һинд-европа» тел гыйлеме баба тел теориясен байрак итеп күтәрә. Баба тел теориясе телләрне «һинд-европа» «семит», «алтай» һ.б. тел семьяларына бүлеп карый. Иҗек методы мондый тел семьяларының булу ихтималын танымый. Баба тел теориясе бер тел семьялары алданрак, икенче тел семьялары соңыннанрак барлыкка килгән дип ышандырмакчы була. Мондый караш үзе генә дә телләрнең, халыкларның, расаларның башлангыч чорда ук тигезсезлеген икърар итү булып тора. Бу шулай ук биология фәне карашларына да каршы килә. Баба тел теориясе логикасына турылыклы булган очракта, кешеләрнең бер төрлесе — маймулдан, икенче төрлесе, әйтик, дельфиннардан, өченче төрлесе исә күктән төшкән ниндидер фантастик җан ияләреннән барлыкка килгән дип тә фараз кылырга мөмкин булыр иде.

Чагыштырма-тарихи методка нигезләнгән тел гыйлеме телләрнең башлангыч чорын берничек тә күз алдына китерә алмый. Шуңа күрә телләрнең башлангыч чоры ниндидер баба телләр рәвешендә булгандыр дип уйланыла да. Мондый фикер ышандыргычрак булсын өчен теге-бу тел семьясының кайчан барлыкка килүе турында конкрет даталар да күрсәтелә. Иң элек, әйтелгәнчә, «һинд-европа» телләре барлыкка килгән, имеш. Бу хәл моннан 8—10, иң күбе 10—15 мең еллар элек булган икән. Баба телнең генә түгел, гомумән, телләрнең барлыкка килүе, шулай итеп, моннан 15 мең елларны эченә алган чор белән чикләнә. Телләрнең кайчан барлыкка килүен исә чынлыкта бернинди даталар белән билгеләп булмый, чөнки бу мәсьәләдә бернинди ышанычлы таяну ноктасы юк. Ялгыз сузыклардан, аерым иҗекләрдән тернәкләнеп киткән һәм сүз, сүз төркеме дәрәҗәсенә кадәр үскән телнең, телләрнең гомере ун-унбиш, хәтта йөз мең еллар белән генә түгел, миллион еллар белән исәпләнергә мөмкин.

## Икенче бүлек

# ФЕСТ ДИСБЕСЕ ТУРЫНДА ХИКӘЯ

### 1. БАШЛАНГЫЧ БЕЛЕШМӘ

1908 елның 3 июлендә, Крит утравындагы Фест шәһәре янында борынгы сарай калдыкларын казыганда, Италия археологы Л.Пернье эшчеләре түгәрәк такта табалар. Кызыл балчыктан изеп, әвәләп ясалган тактаның диаметры 158—165 мм, калынлыгы 16—21 мм була. Тактаның ике ягына да ниндидер билгеләр, рәсемнәр төшерелгән була. Фәнни әдәбиятта бу тактаны русча «Фестский диск» дип йөртәләр. Без моны татарча «Фест дисбесе» яисә кыскартып «дисбе» дип атарбыз.

Дисбе табылган борынгы Фест сарае безнең эрага кадәр 1700 елларда җимерелгән. Язулы такта да чама белән шул чорларда иҗат ителгән дип исәпләнелә. Дөрес, аның сарай җимерелгәнчегә кадәр үк эшләнелгән булуы да ихтимал, ләкин шулай да һәр хезмәттә диярлек 1700 саны күрсәтелә. Икенче төрле итеп әйткәндә, бу түгәрәк такта кисәге моннан 3680—3700 еллар элек барлыкка килгән дигән сүз. Хәзерге көндә Фест дисбесе Крит утравының башкаласы Ираклейон шәһәре музеенда саклана.

Түгәрәкнең һәр ике ягына спираль сыман сызыклар сызылган. Янәшә сузылган ике сызыкка кыска-кыска аркылы сызыклар төшерелгән. Шул рәвешчә ике сызык арасындагы бушлык бүлгәләнеп беткән һәм аркылы сызыклар арасында озынча шакмаклар барлыкка килгән, һәр шакмакка кеше, кош, балык, балта һ.б.ш. рәсемнәр төшерелгән. Түгәрәкнең ике ягында да 45 төрдәге 242 рәсем-билге бар.

Түгәрәкнең уң ягында 31, сул ягында 30 шакмак урнашкан. Рәсемнәр яндырылмаган кызыл балчыкка алдан әзерләнгән агач яисә металл штамплар ярдәмендә төшерелгән. Фест дисбесендәге рәсем-билгеләрне дөньяда штамп ярдәмендә басылган иң беренче язу үрнәге дип исәплиләр. Хәзерге типография шрифтлары сыман штамп куллану нәтиҗәсендә балчыктагы рәсемнәр тигез, ачык һәм матур булып чыккан. Штамп куллану мондый язулы түгәрәкләрнең үз заманында күпләп җитештерелүе ихтималы турында да сөйли.

Фест дисбесе табылган көннән башлап бик күп галимнәр аның серенә төшенергә тырышып караганнар, ләкин дисбе әлегә кадәр укылмаган исәпләнелә. Болгария галиме В.Георгиев язганча, Фест дисбесе турында йөздән артык

хезмәт бастырылган һәм йөздән артык кеше аның серле язуын укып, үз аңлатмасын тәкъдим итеп караган.

Ничек кенә аңлатмаганнар да, нинди генә телләрдә укып карамаганнар дисбедәге сүзләрне! Бу түгәрәк балчык кисәге кинәт «сөйли» башласа, күпме сер, күпме яңалык ачылыр иде дөнья тарихы өчен! Ләкин «бу язуны уку безнең кулдан килә торган эш түгел» ди инглиз галиме Дж, Чедуик (Конд, 93 бит). Икенче бер инглиз галиме, Крит археологиясе белгече Дж. Пендлбери бу хакта сүз кузгатып торуны да кирәксез саный. «Бу текстны укырга тырышып караулар турында эндәшми калу дөресрәк булыр» ди автор (Пен, 191 бит).

Түгәрәктәге рәсемнәргә игътибар беләнрәк күз йөртеп чыккач, бер дә анда баш җитмәстәй нәрсәләр юк сыман тоела. Әнә чүлмәк, әнә кош, балта, калкан... Берсе әнә кулын күтәреп йөгереп бара. Берсенең кулы бәйле. Бүгенге газеталарда, журналларда шундыйрак рәсемнәр ярдәмендә төзелгән һәртөрле ребуслар, башваткычлар бастырыла. Беркадәр уйланып утырса, андый ребус-башваткычларны теләсә кем укый ала. Моннан өч-дүрт мең еллар элек яшәгән кешеләр ясап калдырган әлеге ребусны исә хәтта атаклы галимнәр дә укый алмый.

Сәбәп нидә соң? Иң беренче сәбәп шул: дисбедәге язуның нинди телдә булуы билгеле түгел. Бит бүгенге ребус-башваткычлар, кайсы газета-журнал битендә басыла, шул газета-журнал телендә төзелә. Әйтик, татарча «Ялкын» журналында шундыйрак берәр ребус бар икән, «Ялкын»ны укый алган кеше: «Бу нинди телдә төзелде икән?» — дип аптырап тормый.

Фест дисбесенең әле булса укылмаган булуының икенче сәбәбе дә бар. Серле язуны башлыча «һинд-европа» тел гыйлеме тарафдарлары укырга тырышып караганнар һәм ачкычны да алар үзләре дөрес дип исәпләгән карашларга нигезләнеп эзләгәннәр.

Фест дисбесе белән мин беренче мәртәбә 1974 елда очраштым. Очрашу белән без таныша да, сөйләшә дә алмадык. Башта мин аны читтән генә күрдем. Күрү белән кызыксыну уянды. Кызыксыну уянгач инде беләсе килү теләге туды. Озакламый миндә дисбегә карата чын-чынлап «мәхәббәт» барлыкка килде. Әле бер генә билгенең дә дөрес аталышын белмәгән килеш тә мин аның, һичшиксез, төрки булырга тиешлегенә инандым. Серле язуга карата миндә аңлатып булмый торган бер сиземләү барлыкка килде. Мондый сиземләүләр, үтә күрүләр турында бүген күп язалар. Бәлки миндә дә шундыйрак берәр нәрсә булгандыр.



Рәсем 1. Фест дисбесенең уң ягы.

Мәсьәләнең үтә җитдилеген истә тотып мин сөйләшү-аңлашу эшен бик ерактан һәм бик тирәннән башларга булдым. Моның өчен туктаусыз укырга, өйрәнергә һәм туктаусыз уйланырга туры килде. Моның өчен, барыннан да бигрәк, гадәти карашлардан, гадәти теория-гипотезалардан баш тартырга һәм телгә, тарихка кагылышлы һәр нәрсәдә үз юлыңны салырга туры килде.

## 2. ФЕСТ ЯЗУЫН ӨЙРӘНҮНЕҢ КЫСКАЧА ТАРИХЫ

Балчык түгәрәктәге язуны галимнәр төрле метод ярдәмендә укырга тырышып караганнар. Кайберәүләргә, мәсәлән, иконография методы дигән ысул отышлырак тоелган. Бу метод белән эш иткәндә билгесез язудагы рәсем-билгеләр билгеле булган икенче бер язудагы билгеләр-рәсемнәр белән чагыштырып карала һәм шул рәвешчә



Рәсем 2. Фест дисбесенең сул ягы.

билгесез язудагы рәсем-билгеләрнең мәгънәләре ачыклана. 1911 елда ук инде А. Кюни дигән галим Фест түгәрәгендәге «хәрефләр»не борынгы мисыр иероглифлары ярдәмендә укырга тырышып караган. Р. Макалистр һәм К. Еппесен дигән галимнәр дисбедәге язуны борынгы Мисыр культурасына якын торган ниндидер Төньяк Африка культурасы язуына охшаш дип исәпләгәннәр.

Фест язуын укуда статистик һәм акрофоник метод дигән методлар белән эш итүчеләр дә булган. Акрофоник метод кулланганда мәгънәсе билгесез булган язудагы «хәрефләр» мәгълүм телдәге сүзләр белән исемләнә һәм шул исемнең беренче авазы яисә беренче иҗеге билгесез язудагы рәсем-билгене чагылдыра торган аваз дип уйланыла. 1911 елда Дж. Хемпель дигән галим Кипр иҗекле язуына нигезләнеп, Фест түгәрәгендәге рәсем-билгеләрне грекча укымакчы булып карый. Фест язуында еш

кабатлана торган рәсем-билгеләрне ул *а* һәм *е* сузыклары булырга тиеш дип исәпли, чөнки грек телендә дә сүз башында *а* һәм *е* сузыклары еш кабатлана икән. Дж. Хемпель фикеренчә, Фест түгәрәгендә Кече Азиянең көньяк-көнбатыш ягына урнашкан Ксифо исемле гыйбадәтханәне грек пиратларының талавы турында сүз бара, имеш.

1955 елда Эрнест Зиттиг дигән галим, статистик һәм акрофоник методлар кулланып, әлеге серле язуны шулай ук грекча укып карый. Э.Зиттиг түгәрәкнең бер ягына җир биләмәләрен бүлү турында, икенче ягына күмү йоласына һәм чәчү бәйрәменә кагылышлы үгет-нәсихәт сүзләре язылган дип исәпли.

Америка галиме Сайрус Гордон алтмышынчы елларда, акрофоник метод кулланып, Фест язуын семит телендә «укый». 1948 елда грек галиме Л. Ктистопулос та, статистик метод кулланып, борынгы рәсем-билгеләрне семит телендә укырга тырышып караган.

1948 елда Эрнест Шертель дигән немец галиме түгәрәк балчык тактада латин теленә якын ниндидер «һинд-европа» телендә Зевска һәм Минотаврга гимн сүзләре язылган дигән фикергә килгән. Артур Эванс Фест дисбесендәге рәсемнәрнең мәгънәләрен бөтенләй үзенчә аңлаткан. Дисбедәге сугышчы һәм сугыш кирәк-ярагы рәсемнәренең күплегенә нигезләнеп, Эванс монда җиңү гимны турында сүз бара, ахрысы, дип уйлаган.

Француз атлантологы Марсель Оме Фест язуында Атлантиданың һәлакәте тасвирлана дип исәпли. Инглиз галиме Ф.Гордон Фест дискысындагы сүзләр баск телендә язылган булырга мөмкин дигән фикергә килә. Болгария галиме В.Георгиев дисбедә «һинд-европа» телләреннән берсе луви телендәге сүзләр язылган дигән караштa тора. Л.Гриневич Фест дисбесендәге язулар борынгы славян телендә булырга тиеш дип исәпли.

1929 елда Г.Ипсен «Индогерманише форшунген» дип аталган немецча фәнни журналда В.Порциг белән бергә язылган мәкаләсен бастыра. Мәкаләдә Фест дисбесенә җентекле формаль анализ ясала. Авторлар, комбинаторлык методы кулланып, дисбенең теле ниндидер флектив тел булырга тиеш дигән нәтиҗәгә киләләр. Әлеге «ниндидер флектив телдә» алар префикслар, суффикслар да бар дип исәплиләр. Ягъни бу аларга әлеге дә баягы «һинд-европа» семьясына карый торган берәр тел булырга тиеш булып аңлашыла. Г.Ипсен белән В.Порциг мәкаләсе бүгенге көндә дә Фест язуы турындагы иң җитди һәм иң төпле хезмәтләрнең берсе дип уйланыла.

Совет галиме А.А.Молчанов та Фест дисбесендәге язу-

ны дөрес итеп укуда бары тик комбинаторлык методы гына ышанычлы дип исәпли.

Күрәсез, уку методлары да төрле, тәкъдим ителгән телләр дә төрле. Тик позиция генә үзгәрешсез кала.

### 3. ЯКЫННАН ТАНЫШУ

Балчык түгәрәктәге рәсем-билгеләр, әйтелгәнчә, спираль рәвешендәге сызыклардагы шакмакларга урнаштырылган. Һәр шакмакта бер сүз булырга тиеш дип уйланыла. Рәсем-билгеләрнең атамаларын без әлегә белмибез, шунлыктан һәр рәсемнең нинди авазны чагылдыруы да билгеле түгел. Дөрес эзгә төшү өчен безгә иң элек шакмаклардагы сүзләрне кайсы яктан укый башларга кирәклеген ачыкларга кирәк.

Элегрәк, гарәп хәрефләре кулланганда, безнең әтиләрәниләр уңнан сулга таба укыганнар һәм язганнар. Бүген без грекча-русча тәртиптә сулдан уңга таба укыйбыз һәм язабыз. Кытайлар исә уңнан да түгел, сулдан да түгел — өстән аска таба язалар һәм укыйлар. Борынгы мисырлылар, башлыча, уңнан сулга таба язганнар һәм укыганнар. Ләкин аларда сулдан уңга таба язу-уку да булган — бер юлдагы язу уңнан язылса, икенчесе сулдан башланып киткән. Борынгы Элемда өстән аска һәм астан өскә таба язу һәм уку кулланылган.

Күрәсез, язудагы юнәлеш мәсьәләсендә борынгы кешеләрдә бернинди уртак принциплар булмаган сыман. Ләкин бу өстән караганда гына шулай тоела. Борынгы кешенең һәр эше, һәр адымы дини-мифик карашларга нигезләнгән. Бу карашларны дөрес аңлаганда элекке кешеләрнең кайбер серләренә төшенү дә авыр түгел. Мәсәлән, борынгы мисыр язуларында кеше рәсемнәренең барысы да бер якка караган. Язу уңнан сулга таба укылса, кешеләр дә уңга таба, сулдан уңга таба укылса — кешеләр дә сулга таба караган. Борынгылар һәр сурәтнең җаны бар дип исәпләгәннәр. Сурәттәге кешеләр уңга таба караган икән, йөзең белән аңа таба борыласың да, сулга таба хәрәкәтләнәсең. Сурәттәге кешеләр, укучы белән күзгә-күз карашып, үзара сөйләшәләр булып чыга.

Дисбедә дә шундый ук принцип сакланган: кешеләрнең барысы да уңга караганнар. Димәк, язудагы кешеләр белән «сөйләшү» өчен безгә дә уңнан сулга таба хәрәкәтләнергә кирәк икән.

Кайбер шакмакларда «сүз» ахырында соңгы рәсем астында кыек сызык бар. Нинди сызык соң бу? Берәр төрле аерым «хәреф»ме, әллә соң рәсемнәрне балчыкка тө-

шергәндә ялгыш тырналып калган сызыклармы? Мондый кыек сызыклар кайбер башка язу төрләрендә дә кулланыла икән. Һиндстан язуларында мондый сызык «вирама» дип, көнбатыш семит язуында «шва» дип, гарәп язуында «сөкүн» дип атала. Әйтик, гарәп язуында сөкүн булса, сүз тартык авазга, сөкүн булмаса, сузык авазга тәмамлана.

«Сөкүн»нең татарчасы — «сәкен». Без инде беләбез, бик борынгы карашлар нигезендә, барлык озынча, хәрәкәтчән һәм очлы әйберләр Су-Күк яисә Ата улы исәпләнелә. Ук, сөңге, күсәк, таяк кебек үтерү кораллары мифик Атаның мифик әгъзасына тиңләштерелә. Бу очракта балчык тактага төшерелгән туры сызык та ук, сөңге, күсәк кебек үк үтерү кораллары белән тигез хокуклы итеп карала. Сүз азагындагы сузык авазны ул әйтерсең төртеп тишә, «үтерә» һәм юкка чыгара.

Шулай итеп, дисбедәге сүз ахырында сәкен булса, ул тартык авазга, сәкен булмаса, сузык авазга тәмамлана.

Югарыда әйтелгәнчә, табигатьтәге барлык эш-хәрәкәт Атага, иргә хас функция булып аңлашыла. Уң як — ирләр ягы. Шулай булгач, барлык эш-хәрәкәт уңнан гына башланырга тиеш. Кеше уң кулының сул кулга караганда активрак булуы менә шушы бик-бик борынгы карашка кайтып кала булса кирәк. Татарда әле дә иң элек уң аяк киемен кияләр, бусага аша атлап кергәндә иң элек уң аякны атлыйлар, яңа өй котларга иң элек ир баланы кертәләр. Берәрсен ерак сәфәргә озатканда «юлың уң булсын» дигән теләк белдерәләр.

Дисбедәге язуны уңнан сулга таба укырга кирәклеген күрсәтә торган тагын бер әһәмиятле деталь бар. Түгәрәкнең ике ягында да, спираль башланып киткән төштә, аркылы сызык өстенә дүрт-биш төртке (нокта) төшерелгән. Ник кирәк булды икән ул төрткеләр? Чәй тәлинкәсе зурлыгындагы балчык дисбене борынгы кеше, күрәсең, карап кына түгел, бармак битләре белән капшап та укыгандыр кебек. Карамыйча укыганда, сүзләрнең тәртибен бозмас өчен, укуны билгеле бер төштән башлап китәргә кирәк булган һәм шуңа күрә «җөмлә» башындагы аркылы сызыкларга әлеге нокталар төшерелгән дип уйлый алабыз.

Дисбедәге сүзләрне уку эшенә керешкәнче, безгә һәр ике яктагы спиральләрне сүтеп турайтырга һәм шакмаклардагы рәсемнәрне үз тәртибендә кәгазьгә күчерергә кирәк. Түгәрәкнең уң ягы A хәрефе белән, сул ягы B хәрефе белән билгеләнә. Уң якның кырыйдагы беренче шакмагы A31 дип, икенчесе A30 дип билгеләнә. Түгәрәк уртасындагы иң соңгы шакмак A1 була. Түгәрәкнең сул

ягындагы рәсемнәр дә В30дан башлап В1 гә кадәр номерлана.

Шакмаклардагы рәсемнәрнең кайберләре бер-ике, хәтта бер генә мәртәбә очрый. Кайберләре еш кабатлана. Рәсемнәрнең безгә — бүгенге кешеләргә аңлашылганнары да, бик үк аңлашылып җитмәгәннәре дә бар. Рәсемнәрдә сурәтләнгән һәр нәрсәнең үз исем-атамасы булырга тиеш. Ләкин исем-атамаларны табу белән генә барлык мәсьәләләр хәл ителми әле. Һәр шакмактагы рәсем атамаларының тиешле «хәрефләрен» (башлыча баш «хәрефләрен») бергә җыярга, «хәрефләрне» уңнан сулга таба урнаштырырга кирәк. Шакмактагы сүзләр мәгънә һәм форма ягыннан үзара ярашырга тиешләр.

Мин әле әйтмәдем бугай — моннан өч-дүрт мең еллар элек язылган бу серле язуны без төрки телдә укырга тиешбез. Димәк, рәсем-билгеләр дә төрки телдә аталырга тиеш, «хәрефләр» дә төрки сүзгә ярашлы рәвештә җыелырга тиеш.


Дисбедә 45 төрдәге рәсем-билге кулланылган дидек. Ләкин бу һич тә Фест язуы телендә 45 төрле аваз булган икән дигән сүз түгел. Кайбер авазларны, иҗекләрне чагылдыру өчен берәр-икешәр рәсем кулланылган булса, кайберләре өчен дүртәр-бишәр төрдәге рәсем-билгеләр кулланылган. *Къ* һәм *к* тартыкларына башланган иҗекләр 14 рәсем-билге ярдәмендә белдерелә. Бу исә Фест чоры төрки телдә *къ, к* тартыкларына башланган сүзләрнең бүтән төрле тартыкларга башланган сүзләргә караганда күбрәк булуын күрсәтә. Бүгенге татар теле дә *къ, к* тартыкларына башланган сүзләрнең күплеге белән аерылып тора. 1966 елда Мәскәүдә чыккан «Татарча-русча сүзлектә барлык сүзләрнең 15% ы *к* хәрефенә (*къ* һәм *к* тартыкларына), 8,4% ы *т* хәрефенә, 6,1% ы *с* хәрефенә, 5,8% ы *б* хәрефенә башлана. Дисбе язуында с тартыгын белдерү өчен биш, *т* һәм *б* хәрефләрен чагылдыру өчен дүртәр рәсем-билге кулланыла. Атамалары *л* һәм *р* тартыкларына башланган рәсем-билгеләр бөтенләй юк.

Кайбер рәсем-билгеләр калын әйтелешле сүзләр ясауда гына, кайберләре нечкә әйтелешле сүзләр ясауда гына кулланыла. Калын әйтелешле рәсем-билге атамасының иҗеге кайчагында нечкә әйтелешлеге, нечкә әйтелешле рәсем-билге атамасының иҗеге калын әйтелешлегә күчәргә мөмкин.

Барлык рәсем-билгеләр, нигездә, бер авазны, бер иҗекне белдерә, ләкин кайбер рәсем атамалары сүз ясауда тулысынча катнашалар. Сүз башындагы *а* сузыгын белдерү өчен исә берьюлы ике рәсем хезмәт итә.

#### 4. БЕРЕНЧЕ АВАЗНЫҢ ТАБЫЛУЫ ҺӘМ БЕРЕНЧЕ СҮЗНЕ УКУ

Дисбедәге сүзләрнең укылу тәртибе яхшырак аңлашылсын өчен без хәзер беренче авазның ничек табылуына һәм беренче сүзнең ничек укылуына киңрәк тукталмакчы булабыз.




Уң яктагы беренче шакмакны без А31 дип номерладык. А31 шакмагындагы беренче рәсем — кеше башы. Таблицада ул 2 дип билгеләнгән. Кеше такыр башлы кебек, ләкин аның түбә өстеннән чәч сыман нәрсә тырпаеп тора. Мондый чәчле кешенең булуы шиклерәк. Бу кешенең кемлеген ачыклау өчен безгә тарихи язмаларга мөрәҗәгать итәргә туры килә.


Атаклы Минос патша һәм карлар турында Геродот: «карлар өч нәрсә уйлап тапканнар... Мәсәлән, грекларны алар сугышчының баш киеменә кош каурыйлары кадарга, калканнарга эмблема ясарга өйрәткәннәр һәм калканнарга беренче булып тотка куя башлаганнар», ди (Г, I, 171). Бу хакта Страбон да яза. Б.э.к. XIII гасырда Мисырга төньяктан төрле кабиләләр басып керәләр. Алар арасында карлар, ликиләр дә була. Мисыр чыганакларында аларны «диңгез халыклары» дип атыйлар. Аларны шулай ук «филистимлян» дип тә йөртәләр. Библиядә әйтелгәнчә, «филистимляннар» Криттан килгәннәр. Хәзерге Палестина гарәпләрен шул элекке филистимляннар дип уйлыйлар.



Рәсем 3. Филистимлян («диңгез халыклары») сугышчысы. Б.э.к. XIII гасыр мисыр фрескаларындагы рәсем.

Мисыр истәлекләрендә менә шул филистимлян сугышчысының рәсеме сакланып калган. Аның башында А31 шакмагындагы кеше башындагы кебек кош каурыйлары тырпаеп тора. Димәк, таблицадагы 2 рәсем «кеше башы» сугышчыны белдерә дип әйтә алабыз. «Кеше» башы янындагы түгәрәк калкан аның чыннан да сугышчы булуын раслый. (Таблицада «калкан» 12 урында.)

«Кеше башы» белән «калкан» дисбенең ике ягында да бары сүз башында гына ягъни шакмакның уң ягында гына янәшә урнашканнар.



Рәсем 4. Фест дисбесендәге билгеләрне күрсәткән таблица.

Дисбедәге рәсемнәрне өйрәнгәндә мин моңа игътибар иттем һәм, күрәсең, монда берәр төрле закончалык бардыр дигән фикергә килдем. Мәсәлән, «кеше башы» белән «калкан» янәшә килгәндә бер төрле, аерым-аерым килгәндә икенче төрле аталырга мөмкин. Чыннан да бу шулай булып чыкты да.

Ярар, «кеше башы» белән «калкан»ның икесен бергә сугышчы дип белдек ди. Ләкин ничек аталды икән соң ул сугышчы бик борынгы төрки телдә? *Ир, нүкер, укчы, сугышчы?* Алай да түгел, болай да түгел. Крит чоры төрки

телдә «сугышчы» *алаб* дип аталган. Бүгенге татар телендә бу сүз *алып* буларак мәгълүм. Татарда Алып батыр — әкият герое. Себер төркиләрендә, казакъ, кыргызларда *алып* — «батыр» дигәнне белдерә. Карай телендә алп — «баш киеме», «өлкән кеше». Борынгы төрки телдә алп — 1) төз атучы; 2) батыр һәм сугышчы. Татарстанда Бишалаб дигән авыл да бар.

*Алаб* бары *а* сузыгын гына белдерә һәм бары сүз башында гына кулланыла. Сүз уртасында, сүз азагында *а* сузыгы башка төрле рәсемнәр ярдәмендә белдерелә. *Алаб*ның бары сүз башында гына кулланылуының, әлбәттә, үз мәгънәсе, эчке мәгънәсе бар. Баш кеше һәм батыр сугышчы бары ир затыннан гына була ала. Ул, һичшиксез, беренче һәм алдынгы булырга тиеш. *Алаб* сүзен иҗек методы нигезендә таркатсак, бу *ала-б*, ягъни Ата улы булачак. Ата улының кемлеге турында инде җитәрлек сүз булды кебек.

А31 шакмагындагы өченче (таблицадагы 13) рәсем **НИЖДАГЪ** дип атала. Шакмактагы дүртенче (таблицада 1) рәсем-билге **ТИ**, бишенче (таблицада 18) рәсем-билге **МӨГЕШ** дип атала. Сүз калын әйтелештә. **МӨГЕШ** астында сәкен бар. Димәк, шакмактагы сүз тартык авазга тәмамланырга тиеш. Рәсем атамаларын шакмактагы тәртиптә урнаштыру өчен уңнан сулга язарга туры килер иде. Без мәсьәләне болай ук катлауландырып тормабыз. Гамәлдәге язу тәртибе сулдан уңга булганлыктан, шакмактагы рәсем-билге атамаларын да сулдан уңга таба урнаштырырбыз. Шулай итеп, беренче ике рәсем-билге **АЛАБ** дип укылды, өченче рәсем-билге **НИЖДАГЪ**, дүртенчесе **ТИ**, бишенчесе **МӨГЕШ**. Сүз башындагы авазларны җыябыз, була: А(*лаб*), Н(*иждагъ*), Т(*и*), М(*өгеш*). А.Н.Т.М. тартыкларын тулыландырып укыйбыз. Булды АНТЫМ — исем, берлек санда, беренче зат кушымчасы белән төрләнә, баш килештә.

### 5. ФЕСТ ДИСБЕСЕНДӘГЕ РӘСЕМНӘР ҺӘМ АЛАРНЫҢ АТАМАЛАРЫ

*(Рәсем атамалары, таблицадагы тәртиптә бирелә)*



1. **ТИ.** Сул кулын күтәреп йөгереп барган бу кеше рәсеме дисбенең А ягында 6, В ягында 5 мәртәбә кабатлана, һәр очракта *т* тартыгын белдерә. **ТИ**не Җир улы, Ана улы «кеше» дип тә аңларга була. Ләкин ул монда, гомумән, кеше түгел, яшь кеше, ахрысы. Татар телендәге *түти, яшьти* кебек сүзләрнең ахыргы *ти* иҗекләре мөстәкыйль мәгънә белдерәләр булса кирәк.



2. Шартлы рәвештә «калкансыз сугышчы» дип атарга мөмкин булган бу рәсем сүз башында гына кулланыла. Дисбенең А ягында 2, В ягында 4 мәртәбә кабатлана. «Калканлы сугышчы» **АЛАБ** дип атала һәм сүз башында *а* сузыгын белдерә. «Калкансыз сугышчы» исә сүз башында *ә* сузыгын белдерә. Рәсемнең төгәл атамасын тәкъдим итеп булмый.



3. **МИҢЛЕ.** Түгәрәкнең А ягында 2, В ягында 2 мәртәбә очрый. Рәсемдәге кешенең уң як чигәсендә 8 ле сыман билге бар. Моны миң дип аңларга була. Шунлыктан рәсем шартлы рәвештә «миңле» дип атала. 8 ле сыман билге Кипр-Миной һәм Кипр иҗекле язуларында *ле* иҗеген белдерә.



4. **БУЛУН.** Рәсем дисбенең А ягында бер мәртәбә очрый. Кулы артка каерылып бәйләнгән кешенең әсир, тоткын булуы бернинди шик тудырмый. Бу әсирне *бөлген* дип тә атарга була. Борынгы төрки телдә «әсир» (пленный, пленник) *булун* дип атала. Рәсем атамасы шуннан алынды.



5. **МАЛАЙ** рәсеме дисбенең В ягында бер мәртәбә очрый. Шакмактагы сүзнең мәгънәсе азакта *м* тартыгы таләп итә. Шунлыктан рәсем шартлы рәвештә «малай» дип атала.



6. **МА.** Рәсем дисбенең А ягында 2, В ягында 2 мәртәбә кабатлана. Бу — изге, бөек Ана. Кече Азиядә бер алиһә Ма дип аталган. **МА**ның «бөек ана» булуы татарча *алма* сүзендә сакланып калган. *Алма (апа)* Нократ сөйләшендә «абыстай» дигәнне белдерә. Сергач сөйләшендә шул ук сүз *алмай* рәвешендә кулланыла.



7. **ИМИ** рәсеме дисбенең А ягында 3, В ягында 15 мәртәбә кабатлана, һәр очракта *и, им* авазларын гына белдерми, кайбер очракта ым, кайбер очракта эм буларак та кулланыла. Хәзерге татар теле диалектларында бу сүз *эми, эмәй* рәвешендә дә әйтелә. Күрәсең, элек тә аның әйтелеше төрлечәрәк булгандыр, ахрысы.



8. **КАЛПАК** рәсеме дисбенең А ягында 1, В ягында 4 мәртәбә кулланыла, *къ* һәм *к* тартыкларын белдерә. Крит (кар) сугышчыларының баш киемнәренә кош каурыйлары кадаулары турында сүз

булды инде. Каурыйлары тырпаеп торган баш киеме 2 рәсемдәге «калкансыз сугышчы» башында да бар. Тик 2 рәсемдә ул өстән-өстән генә сурәтләнгән. Әлеге 8 рәсемдәге **КАЛПАК** аерым күрсәтелә. Аның аскы өлеше кыршау сыман итеп тәмамланган. Борынгы Мисыр рәсемнәрендәге филистимлянның да баш киемендә маңгай турысында кыршау сыман нәрсә бар. Бүгенге татар хатын-кызларының баш киеме *калфак* һәм шулай ук *калпак* (русча, колпак, шапочка) әлеге **КАЛПАК**ның дәвамы булса кирәк.



9. **БАШЛЫК** рәсеме дисбенең В ягында 2 мәртәбә очрый һәм *б* тартыгын белдерә.



10. **ИШКӘК** рәсеме дисбенең А ягында 4 мәртәбә кулланыла һәм *и* сузыгын белдерә.

### 6. ЙАЙА РӘСЕМЕ ҺӘМ УК-ҖӘЯ ТУРЫНДА КАЙБЕР ӨСТӘМӘ ФИКЕРЛӘР



11. **ЙАЙА** рәсеме дисбенең А19 шакмагында гына кулланыла һәм сүз ахырында *йа* иҗеген белдерә. Ук-җәя турында безнең беркадәр сүз булды инде. Монда без «җәя»гә киңрәк тукталмакчы булабыз. «Җәя» карай (караим) телендә *йайа* дип, кырымтатар, госманлы-төрек, чыгытай телләрендә *йай* дип атала. Әлеге 11 рәсемдә кереше бушайтылган җәя сурәтләнгән. М хәрефе формасындагы мондый җәяләрне фәнни әдәбиятта катлаулы җәя («сложный лук»), скиф җәясе («скифский лук»), Гуннар җәясе («гуннский лук»), төркиләр җәясе («тюркский лук»), күчмәләр җәясе («кочевнический лук»), Үзәк Азия халыклары җәясе («Центрально-азиатский лук») дип йөртәләр. Бу атамаларның һәркайсы шушы типтагы җәяләрнең тегебу үзенчәлекләрен күз алдында тотарга мөмкин. Шулай да һәр атамада төп фикер үзгәрешсез кала: *М* хәрефе сыман җәянең дугасы тигез генә бөгелми. Уртадан ул батынкы. Батынкы дуганың ике ягында ике «калкулыгы» бар. Җәя башлары бөгелгән. Җәя агачы берничә кисәктән тора. Ныклык өчен агачның тышкы ягына сөяк пластин-

калар беркетелгән, сеңер белән урап, бәйләп, җилем белән катырылган.

Формасы ягыннан җәя дугасы, нигездә, ике төрле генә була ала. Аның бер төрлесе әлеге М хәрефе рәвешендә булса, икенче төрлесе латинча *D* хәрефе рәвешендә була. *D* рәвешендәге җәя катлаулы җәягә караганда борынгырак исәпләнелә. Берише халыклар бик ерак заманнарда ук *D* хәрефе сыман җәяләр кулланcалар, икенче бер халыклар *М* хәрефе рәвешендәге катлаулы җәяләр кулланганнар.

«Скиф җәясе», ягъни катлаулы җәя Европа-Азия далаларында барлыкка килгән дип исәпли А. М. Хазанов (Хаз, 29 бит). «Скиф җәясе» Көнчыгышта Себергә кадәр таралган һәм Кытайгача барып җиткән, Көнбатышта исә мондый җәя детальләре Фландриядә табылган. Катлаулы җәя грекларда да була. Бу җәяне греклар б.э.к. VI яисә VII гасырларда башка халыклардан күчереп алганнар булса кирәк, ди Хазанов. Шунысы игътибарга лаек, «Крит утравын исәпләмәгәндә, Грециядә җәя беркайчан да киң таралган корал булмаган», ди шул ук автор (Хаз, 30 бит). Димәк, корал буларак җәя Критта гына кулланылган. Безнең эраның II гасыр азакларында һәм III гасырның беренче яртысында яшәгән грек-рим язучысы Элиан да «Крит кешеләре бик яхшы укчылар» ди (Эл, I, 10). «Скиф җәясе» этрускларда да була, ләкин мондый җәяне алар башлыча ауда гына кулланалар.

Төрки халыклар, шул исәптән казан татарлары, *М* рәвешендәге катлаулы җәя кулланганнар. XVI гасырда Мәскәүгә килгән С. Герберштейн ясаган татар сугышчысының рәсемендә баш-башлары бөгелгән, уртасы батынкы җәя сурәтләнгән.

Борынгы кешенең сугыш коралы үсешендә катлаулы җәя уйлап табу зур яңалык булган дип исәпләнелә. Мондый җәянең ату көче арткан дип уйланыла. Шул ук вакытта катлаулы җәяне сүтәргә, җыярга һәм махсус савытка — садакка салып куярга була. Катлаулы җәяне академик А. П. Окладников «җәянең иң соңгы дәрәҗәгә җиткерелгән камиллек үрнәге» дип исәпләгән (Пел, 170 бит). «Җәяләр мәсьәләсендә үз заманының иң зур белгече» Ф.Лушан катлаулы җәяләрне бо-

рынгы төрки халыкларның берәрсе яисә Шумер кешеләре уйлап тапкан булырга тиеш дигән фикер әйткән (Пелих, 170 бит).

Ләкин катлаулы җәя, гомумән, җәянең ату көчен арттыру теләге нәтиҗәсендә түгел, бәлки борынгы халыкларның дини-фәлсәфи карашлары нигезендә барлыкка килгән дип исәплибез без. Мондый фикерне раслый торган дәлилләр җитәрлек. Мәсәлән, катлаулы җәянең генә түгел, көянтә сыман дугалы җәянең дә ату көче шактый зур булган. Менә бер мисал. Б.э.к. XV гасырда хакимлек иткән Мисыр патшасы Аменхотеп II бик көчле булган, имеш. Аның җәя керешен мисыр сугышчыларыннан да, чит ил патшаларыннан да беркем тарта алмаган. Аменхотепның атасы Тутмос III дә көчле булган. Мишень итеп куелган өчилле калынлыгындагы җиз калайга Тутмос ерактан ук атса, аның угы калайны өч карышка тишеп чыккан. Аменхотеп шундый ук калайга атса, аның уклары калайны тишеп чыгып, барысы да җиргә коела торган булган. Аменхотеп ук аткан җәя катлаулы түгел — латинча *D* хәрефе рәвешендә.

Әйтелгәнчә, борынгы кешегә барлык куыш, батынкы әйберләр Ана улы булып, озынча һәм хәрәкәтчән әйберләр Ата улы булып тоелган. Ана улы дигәнебез хатын-кызның җенес әгъзасын, Ата улы дигәнебез исә ир кешенең җенес әгъзасын күз алдында тота. Бик борынгы дини-мифик карашлар, чынлыкта, кешенең җенес әгъзаларын изгеләштерү нигезендә барлыкка килгән. Ата һәм ананың җенес әгъзаларын изгеләштерү, шуларга охшатып эшләнгән әйберләргә, сурәтләргә табыну бик күп халыкларда булган. Мәсәлән, Төньяк Алтай кабиләләрендә ук һәм җәя ярдәмендә имләү соңгы вакытларга кадәр дәвам иткән. Хакаслар җәянең сихри көче бар дип белгәннәр һәм яңа туган ир бала бишегенә, чүпрәккә төреп, кечкенә җәя салып куя торган булганнар. Катлаулы җәя ул сугыш коралы да, шул ук вакытта *vulva* һәм тудыручы бөек Ана символы да. Катлаулы җәя күчмә төркиләрдә яисә борынгы Критта гына түгел, борынгы Мисырда да, б.э.к. 5000—1000 еллар элек Төньяк Африкада һ.б. төбәкләрдә дә булган.


## 7. ФЕСТ ДИСБЕСЕНДӘГЕ РӘСЕМНӘР ҺӘМ АЛАРНЫҢ АТАМАЛАРЫ. ДӘВАМЫ.



12. **КАЛКАН** рәсеме «сугышчы» белән бергә дә, аерым да кулланыла. Дисбенең А ягында «сугышчы» белән бергә 12, В ягында бер мәртәбә очрый. «Сугышчы» белән бергә һәрвакыт сүз башында килә, әйтелгәнчә, **АЛАБ** дип укыла. Рәсем үзе генә А ягында 3, В ягында 1 мәртәбә кулланыла. *КЪ* һәм к тартыкларын белдерә. Кносс сараенда һәм Камарес тау куышында табылган чүлмәк савыт-саба орнаментында әлеге калканга охшаган рәсемнәр очрый. Б.э.к. 1200 елларда XX династиянең Рамсес III (IV) хакимлеге чорында Мисырга «диңгез халыклары» басып керәләр. Мисырлыларның «диңгез халыклары» белән сугышын күрсәткән рельефта Рамсес патша сугышчыларының калканнары — озынча, «филистимлян» сугышчыларыныкы — түгәрәк.



13. **НИЖДАГЪ.** Рәсем дисбенең А ягында 3, В ягында 3 мәртәбә очрый. Тукмак, бәләк яисә янугыч сыман коралларга охшаган бу коралның җайлы сабы бар. Коралның юанрак, озынчарак өлешендәге төрткеләр вак таш, ком кисәкләрен хәтерләтә. Мәхмүт Кашгарый сүзлегендә «кай-



Рәсем 5. Мисыр патшасы Рамсес III (IV) чорында мисырлыларның һәм «диңгез халыкларының» диңгез сугышын күрсәткән рәсем. Мәдинәт-Хабу гыйбадәтханәсендәге рельефларның берсе. XX династия. Б.э.к. XIII гасыр. Мисыр сугышчылары яланбаш, кулларында озынча калкан. «Диңгез халыклары» сугышчыларының башларында калпак, кулларында түгәрәк калкан, сугыш көймәләре Дисбедәге «кәмә» рәвешендә.

рак ташы» (точильный камень) *ниждагъ* дип атала. Рәсем һәр очракта н тартыгын белдерә.



14. **КАМЫТ**. Дисбенең ике ягында да берәр мәртәбә кулланыла. Рәсемдә парлап җигелә торган үгез камыты сурәтләнгән. Критта, башка утрауларда һәм Грециядә җирне элек сабанга пар үгез җигеп сөргәннәр. Бу хакта сөйли торган борынгы рәсемнәр һәм сыннар сакланып калган. *КЪ* тартыгын белдерә.



15. **БАЛТА**. Рәсем дисбенең В ягында бер мәртәбә очрый. *Б* тартыгын белдерә. Ике яклы балта борынгы Кече Азиядә барлыкка килгән дигән караш бар.



16. **САДАК** рәсеме дисбенең В ягында ике мәртәбә кабатлана. Бер очракта *с* тартыгын белдерә, икенче очракта сүз ясауда тулысынча катнаша. Рәсемдәге садакның өске ягында элмәк сыман нәрсәсе бар. Бу аның бил каешына тагылып йөртелүенә ишарәли. Садак элек җәя яки ук салу өчен кулланылган. *Садак* сүзе татарда, казакъ, алтай, телеут һ.б. төркиләрдә мәгълүм.



17. **КАПКАЧ**. Рәсем А8 шакмагында очрый һәм *къ* тартыгын белдерә.



18. **МӨГЕШ**. Дисбенең А ягында 6, В ягында 6 мәртәбә кабатлана, һәр очракта *м* тартыгын белдерә. Рәсемдә «почмак» сурәтләнгәнлеге үзеннән-үзе аңлашылып тора. *Мөгеш* татар әдәби телендә диалекталь сүз исәпләнелә. *Мөгеш*нең *миеш, мөгәш* вариантлары да билгеле.



19. **ТА**. Ике чаты да югары каратылган һәм чатлы багананы хәтерләткән рәсем шартлы рәвештә шулай дип аталды. Рәсем дисбенең А ягында 3 мәртәбә кабатлана һәм һәр очракта т тартыгын чагылдыра.



20. **ӘМ.** Рәсем В26 һәм В18 шакмакларында урнашкан. М тартыгын яисә эм иҗекләрен белдерә. Бу рәсемне «чүлмәк» мәгънәсендә *ам* дип тә уйларга була. Тик шулай да бүгенге төрки телләрдә мондый «чүлмәк» юк, ахрысы. *Әм* сүзе иҗек методы нигезендә торгызыла. Грек һәм латин телләрендәге *амфора* сүзенең *ам* өлеше әлеге «чүлмәк»не чагылдыра сыман. *Фора* иҗекләрен төрки *бор-бора* белән янәшә куеп карарга була. Куман телендә *бор* «шәраб», уйгурча *пор* «шәраб», куман, карай телләрендә *борла* «йөзем бакчасы», кырым-татар телендә *борлалык* «йөзем бакчасы» дигәнне белдерә. Крит чоры төрки телдә *бор-бора* — йөзем», «йөзем шәрабы», *ам-бора* — «шәраб савытын» аңлаткан булырга мөмкин. Бүгенге көндә бөтенләй башка мәгънәдә кулланыла торган *амбар* белән *амфора* чынлыкта бер үк сүз булса кирәк. *Амбар-амфора* шәраб савыты «чүлмәк»не дә, шундый зур чүлмәкләр саклана торган махсус бүлмәне, бинаны да аңлаткандыр дип әйтә алабыз.



21. **КЫРГЫЧ.** Рәсем А15 һәм А3 шакмакларында кулланыла һәм *къ* тартыгын белдерә. Бу ат яисә башка мал-туар кыргычы, ахрысы. «Кыргыч» ике яклы таракны хәтерләтә. Сап уртасында кечкенә чөй бар. Сапны кулга учлап тоткач, чөй ике бармак арасында кысылып калырга тиеш. Ат яисә сыер ябагасын тараганда тигез, шома сап, шулай итеп, кулда шуышып, әйләнгәләп тормаячак. Бу хикмәтле коралны бары шулай гына күз алдына китерергә була.



22. **ДИ.** Чаты аска карап торган баганаңы хәтерләтүче бу рәсем-билге дисбенең В ягында 5 мәртәбә кабатлана һәм *д* тартыгын белдерә. 19 рәсемдәге ике чаты югары карап торган билгене без «җир» символы дип, чаты аска карап торган әлеге билгене «күк» символы дип исәплибез. Рәсем-билгенең чыннан да **ДИ** булуын чагыштыру юлы белән дә исбатлап була (В27 шакмагындагы сүзне укыганда без бу хакта искә төшербез әле).



23. **НИМӘ**. Агач чөйне яисә агач кадакны хәтерләткән бу рәсем дисбенең А ягында 5, В ягында 6 мәртәбә кабатлана, һәр очракта *н* тартыгын белдерә. Ни өчен **НИМӘ** дип атала дигәндә, бу уңайдан кайбер фикерләрне теркәп узасы килә. Халыкта шундый мәкаль бар: «Имә белгәнгә — инә, имә белмәгәнгә — нимә». Мәкальнең бүгенге мәгънәсе: бер кеше имә дә имә (урлаша, байый), имә белмәгән икенче берәү һаман ярлы. Мәкальдәге сүзләрнең туры мәгънәсенә игътибар итсәк, монда күп нәрсә аңлашылмый. Гайнә татарларында *нимә* «әйбер» дигәнне белдерә. Имә белмәгән балага элек, имеш, «әйбер» биргәннәр булып чыга. Хәзерге заманда имә белмәгән кеше түгел, киресенчә, имә белгән кеше «әйбер»ле була түгелме соң? Бит мәкаль нәкъ шундый имүче һәм «әйбер»гә ия булучы кешеләрне күз алдында тота (бүгенге көндә). Мәкальнең бүгенге мәгънәсендә мәгънәсезлек ярылып ята. Болай булгач, тирәнрәк катламнарга төшеп карыйк. Элек имә белгән баланы инә (ана) имезгән, имә белмәгән балага нимә каптырганнар. Фест дисбесендәге **НИМӘ** — озынча «әйбер». Иҗек методы нигезендә фикер йөрткәндә, *ни-мә* — Ата улы. Мәкальнең бик борынгы мәгънәсе: имә торган балага инә кирәк, имүдән туктаган балага нимә кирәк.



24. **ЭЙ**. Рәсем дисбенең А ягында 1, В ягында 5 мәртәбә кулланыла һәм *э* сузыгын, *эй* иҗеген белдерә. Бу бик әһәмиятле һәм аеруча игътибарга лаек рәсем. Өйнең түбәсе гөмбәзле, димәк, планда ул — түгәрәк.

Татар телендә күп очракта *ө* сузыгы элекке *э* сузыгы урынына кулланыла. Шунлыктан бүгенге көндә *өй* булган сүз элегрәк *эй* булган дип исәплибез. *Өй*нең кайчандыр *эй* рәвешендә әйтелүен грек телендә сакланып калган кайбер төрки сүзләр белән дә исбатлап була. «Мегар акрополе «кар кешесе» Кар патша хөрмәтенә карией дип аталган» ди Дж. Томсон (Том, 166 бит). Монда без *карией* сүзен аерып алабыз һәм сүзне *кар и эй* дип таркатабыз. «Пританей сүзенең этимологиясе притан,

өе, ягъни башлык (рәис) өе» дигәнне белдерә ди шул ук автор (Том, 364 бит). Притан грек телендә «башлык», «рәис» булгач, *эй* турыдан-туры «өй» дигәнгә туры килә.

Киң таралган *музей, мавзолей* сүзләре ахырындагы *эй* иҗекләре дә «эй (өй)» дигәнне белдерә. Музейның әүвәлге һәм төркичә әйтелеше *Мус-эй*, ягъни *Мус өе* булган. Бүгенге көндә *Муса* сүзе ирләр исеме санала. Элегрәк *Мус* — ирләргә, *Муса* — хатын-кызга кушыла торган исем булган. Мус рәвешендә ясалган *Нис* исеме дә актив кулланылган. Бүген инде бездә *Нис* дигән ир кеше исеме юк, ләкин *Ниса* дигән хатын-кыз исеме бар. *Мавзолей* исә заманында дөньядагы җиде могҗизаның берсе саналган. Кече Азиядәге Кария иленең патшасы *Мавсол* үлгәч, аның хатыны үзенең сөекле ире хөрмәтенә искиткеч төрбә эшләткән. Менә шул төрбәне *Мавсол эйе* дип атаганнар. Татарда әле дә *Мәүсил* дигән ирләр исеме сакланып калган (Сат, 138 бит). Грекча-русча язылыштагы *Мавсол, Мавзол* менә шул *Мәүсил* булса кирәк.

Шумер телендә «өй» мәгънәсендәге сүз *э* сузыгы белән генә белдерелә дидек без. Теоретик яктан ялгыз *э* берничек тә «өй» була алмый. Димәк, шумер телендәге «өй» мәгънәсендәге *э* сузыгы элегрәк *эй* рәвешендә әйтелгән. Бу сүзне шумерлар үзләреннән дә борынгырак төркиләрдән алганнар һәм үз телләренә яраштырганнар дип әйтергә туры килә.



25. **КӘМӘ** рәсеме дисбенең А ягында 2, В ягында 5 мәртәбә кабатлана. һәр очракта *кәмә* һәм *кемә* дип укыла һәм сүз ясауда тулы килеш катнаша. Татар әдәби телендә «көймә» булган сүз алтай, телеут, куман, чыгытай һ.б. телләрдә *кәмә*, кыргыз, казакъ, сагай, койбал телләрендә *кемә* дип атала. Уйгурча *кемә* — паром (боран), зур көймә, кораб. Татар теленең Минзәлә, Бөре, Гайнә сөйләшләрендә — *кәмә*.

Крит кешеләре яхшы диңгезчеләр булалар. Урта диңгездә регуляр рәвештә йөзү б. э. к. III мең еллык башларында ук барлыкка килгән дип уйланыла. Крит кешеләрендә сәүдә көй-

мәләре, сугыш көймәләре һәм башка көймәләр төзү бик нык алга киткән булган.



26. **ШӨШЛЕ**. Дисбенең А ягында 5, В ягында 1 мәртәбә кулланыла, һәр очракта *л* тартыгын белдерә. Бүгенге төрки телләрдә *л, р* тартыкларына башланган сүзләр бик аз. Крит чорында да, күрәсең, шулай булган һәм шуңа күрә *л, р* тартыкларын рәсемдә чагылдыру шактый кыенлык тудырган. «Ребус»ның төп кагыйдәләреннән читләшеп, *л, р* тартыкларын белдерү өчен, атамалары *л, р* тартыкларына башланган рәсемнәрне түгел, бәлки *л, р* тартыкларына тәмамланган рәсемнәрне сайларга туры килгән.



27. **ТУН** рәсеме дисбенең А ягында 10, В ягында 5 мәртәбә кабатлана, һәр очракта *т* тартыгын белдерә. Кыска җиңле, озын, киң итәкле бу «тун» хатын-кыз күлмәге булса кирәк. Кнос сарае калдыклары арасында табылган алиһә сыннарының, стеналарга төшерелгән хатын-кыз сурәтләренең күлмәкләре әлеге «тун» кебек кыска җиңле һәм озын итәкле. Татарча *тун*, борынгы төрки телдә *тон* «күлмәк», «кием-салым» дигәнне белдергән.



28. **КЪОЙКЪА** яисә **КУЙКА**. Рәсем дисбенең А17, А11 шакмакларында урнашкан. Ике очракта да *кот* (яисә *кут*) сүзен ясауда катнаша. Рәсемдә «сарык аягы» сурәтләнгән. Татар телендә *къойкъа* мал аягыннан пешерелгән азыкны белдерә. *Койка* сүзен иҗек методы нигезендә *кой-ка* дип таркатабыз. Бүгенге *къой* элегрәк *куй* булган дип исәпләсәк, әлеге «сарык» *куй* булачак. Кыскасы, *койка* ул «куй (кой) улы» булып аңлашыла. Элегрәк *къойка* азыгын «койка шулпасы» дип тә атаганнар. «Шулпасы» төшеп калган һәм ике сүздән торган атама *къойка* рәвешендә генә әйтелә башлаган. Карай телендә *туйак* (туйах) «копыто» һәм «студень» (ягъни къойка) мәгънәләрендә кулланыла. Димәк, *тойак* та, *къойка* да бер үк вакытта «мал аягын» да, мал аягыннан әзерләнгән азыкны да аңлата ала икән.



29. **ИР.** Үгез башын чагылдырган бу рәсем дисбенең А ягында 3, В ягында 8 мәртәбә кабатлана. А28 шакмагында ике **ИР** янәшә килә һәм «ирләр» («ир-ат») мәгънәсен белдерә. Башка һәр очракта *и* сузыгын чагылдыра.



30. **КЪУЙ.** Рәсем В4 шакмагында гына кулланыла. Мөгезе түбән таба бөгелеп, түгәрәкләнебрәк торган бу хайванның *куй* (сарык) булуына бернинди шик булырга мөмкин түгел. *Ку* иҗеген чагылдыра.



31. **КОШ** рәсеме дисбенең А ягында 5 мәртәбә кабатлана *кош (куш)* — гомум төрки сүз. *КЪ* тартыгын белдерә.



32. **САЙКА.** Рәсемдә басып торган су кошы сурәтләнгән. Дисбенең А ягында 2, В ягында 1 мәртәбә очрый. *С* тартыгын белдерә. Мисыр иероглифик язуында утырып торган шундый ук су кошы рәсеме *са* иҗеген чагылдыра. *Сайка* сүзе иҗек методы нигезендә торгызыла һәм шартлы рәвештә тәкъдим ителә. Бу уңайдан русча *чайка* (акчарлак) сүзен дә искә төшерергә була.



33. **КАРАУЛ.** Рәсем дисбенең А ягында 2, В ягында 4 мәртәбә кулланыла һәм *къ, к* тартыкларын белдерә. В24 шакмагында сүз ясауда тулысынча катнаша. Рәсемдә «балык» сурәтләнгән. «Балык»ның бер генә төрки телдә дә *караул* яисә *караулы* дигән атамасы юк, ахрысы. Бу да иҗек методы нигезендә торгызылган сүз. *Кара* — «җир улы су». «Балык» бары Су улы гына була ала. Бүгенге төрки телләрдә *кар (кара)* — «су» ярдәмендә ясалган кайбер балык исемнәре һәм балыкка катнашы булган атамалар очрый. Каракалпак телендә *карма* — «умачлы балык ашы», койбал телендә *карба* — «балык җилеме», госманлы-төрек телендә *карасы* — ниндидер «балык». Татарча *кәрәкә*, русча *карась* «балыкларының атамалары да шушы төргә карый.

34. **КОңГЫЗ**. Рәсем А28, В29, В2 шакмакларында очрый һәм *къ, к* тартыкларын белдерә.



35. **КЪ — ?** Нindидер яфраклы агач сабагын сурәтләгән бу рәсемнең дөрес атамасын тәкъдим итеп булмый. Дисбенең А ягында 5, В ягында 6 мәртәбә очрый һәм *къ, к* тартыкларын белдерә.



36. **С — ?** Нindидер агачнымы, үләннеме чагылдырган бу рәсемнең дә төгәл атамасын тәкъдим итеп булмый. Дисбенең В ягында 4 мәртәбә кабатлана һәм *с* тартыгын белдерә.



37. **С — ?** Бу рәсем дә *с* тартыгын белдерә. Атамасы билгеле түгел. Дисбенең А ягында 2, В ягында 2 мәртәбә кабатлана.



38. **КАШКАРЫЙ**. Грекча-русча астра дип аталган чәчәкнең татарча исеме *кашкарый*. Дисбенең А ягында 3, В ягында 1 мәртәбә кулланыла һәм *къ, к* тартыкларын белдерә. Чәчәкнең сигез таҗ яфракчыгы бар. Шундый ук кашкарый рәсеме Әүвәлге Миной III чорына карый торган ташбасмада бар (Пен, 105 бит). Болгар кабер ташларында да сигез яфракчыклы, алты яфракчыклы кашкарыйлар сурәтләнгән.



39. **АЙР**. Дисбенең А ягында 1, В ягында 3 мәртәбә кабатлана һәм *р* тартыгын белдерә. Рәсемдә өч җәпле сәнәк сурәтләнгән. Казакъ телендә «сәнәк» *айр* дип, алтай телендә *айруш* дип атала. Татар йола җырларында «сәнәк», «очлы нәрсә» мәгънәсендә айры сүзе очрый. Мәсәлән:

Зеңге, зеңге, зеңге корт,
Айры башлы зеңге корт;
Алтын башлы атасы,
Айры мегез анасы.



40. **АМ**. Төрки телләрдә бу сүз хатын-кызның җенес әгъзасына карата әйтелә. Әлеге рәсем шуны чагылдыра. Дисбенең А ягында 3, В ягында 3 мәртәбә очрый. Сүз уртасында, сүз

азагында *ам, әм, эм* иҗекләрен белдерә. *М* рәвешендәге катлаулы җәя шушы **АМ** сурәтен хәтерләтә. 1422—1445 елларда тәхеттә утырган һәм Казанның беренче ханы булган Гыясетдин акчаларына лираны яисә кереше тартылган җәяне хәтерләткән тамга сугылган. Шундый ук тамга Кырым ханы Сәгадәт Гәрәй хан мөһерендә дә бар (Мух, XX таблица, 2—6 рәсемнәр; XIV таблица, 4—11 рәсемнәр). Кайбер детальләрне исәпкә алмаганда, акчаларга сугылган тамгалар белән дисбедәге әлеге 40 рәсем бер-берсенә охшаш.



41. **СӨЙӘК** рәсеме дисбенең А ягында 2 мәртәбә кабатлана һәм с тартыгын белдерә.



42. Бу рәсем В22 шакмагында кулланыла, *б* тартыгын чагылдыра, ләкин нәрсә аңлатканын белеп булмады.



43. **ИЛӘК**. Рәсем В25 шакмагында кулланыла. Сүз азагында *к* тартыгын белдерә. Рәсем атамасы шартлы рәвештә тәкъдим ителә.



44. **ТӨРТКЕ**. Рәсем А25 шакмагында кулланыла, *т* тартыгын белдерә. Рәсем атамасы шартлы рәвештә тәкъдим ителә.




45. **ӘН**. Дисбенең А ягында 2, В ягында 4 мәртәбә кабатлана. Тулысынча *ән* дип тә, *ан* дип тә укыла. Дулкын сыман өч сызык «су» символы хезмәтен үти. Бүгенге төрки телләрнең берсендә дә «су» *ән* дип аталмый, ахрысы. Шумерларның алла исемнәрендә *эн (ән)* еш кулланыла. Мәсәлән, *Энки* — су алласы, *Энлил* — җил-давыл алласы. Шумерда, Эриду шәһәрендә *Энки* дигән алла ярым кеше, ярым балык кыяфәтле итеп сурәтләнелгән булган. Татар телендәге *әнкәй* сүзенең *әнкә* варианты да мәгълүм. Сүзне *ән кә* дип тә, *ән-кә* дип тә таркатырга була һәм Изге Җир (Ана) дип тә, Су улы Җир (Ана) дип тә аңларга була. «Су» шумер чөй язуында дулкын-

лы өч сызык белән билгеләнә. «Су» шулай ук мисыр, хет, элам язуларында да дулкынлы өч сызык белән аңлатыла. Борынгы Кытайның Инь чорында «тибу» (разлившиеся воды) вертикаль рәвештәге өч дулкынлы сызык белән, борынгы кытай язуында «су» һәм «елга» вертикаль өч сызык белән күрсәтелә.


### 8. ФЕСТ ДИСБЕСЕНЕҢ УҢ ЯГЫНДАГЫ СҮЗЛӘРНЕ УКУ




A31 шакмагындагы сүз АНТЫМ дип укылды. Шуны монда рәсемдә күрсәтәбез. «Беренче авазның табылуы һәм беренче сүзне уку» дигән бүлекчәдә бу хакта сүз булды инде (103—106 битләрне кара).



A30. Рәсем атамалары, шакмактагы тәртиптә: **ЭЙ, АМ, КАЛКАН**. Нечкә әйтелештә, сәкен юк, ә сузыгына тәмамлана. Тиешле иҗекләрне җыябыз: ЭЙ.АМ.КА. Укыла: ЭЙЕМКӘ — исем, берлектә, беренче зат тартым кушымчасы белән төрләнә, юнәлеш килештә.




A29. Рәсем атамалары: **ИР, ӘН, ИМИ**. Нечкә әйтелештә, сәкен бар, *м* тартыгына тәмамлана. Тиешле иҗекләрне җыябыз: ИР.ӘН.ИМ. Укыла: ИРӘНЕМ — исем, берлектә, беренче зат тартым кушымчасы белән төрләнә, баш килештә.




A28. Рәсем атамалары: **ИР, ИР, КОңГЫЗ**. Нечкә һәм калын әйтелештә, сәкен юк, *а* сузыгына тәмамлана. Ике тапкыр кабатланган **ИР**

«ирләр» мәгънәсендә кулланыла (тау-тау, өем-өем дигәндәге кебек). «Ирләр» төшенчәсе *ир-ат* сүзе ярдәмендә белдерелә. Укыла: ИР-АТКА — исем, формасы белән берлектә, мәгънәсе белән күплекне белдерә, юнәлеш килештә.



А27. Рәсем атамалары: **АЛАБ, БУЛУН, АМ, КАРАУЛ**. Калын әйтелештә, сәкен юк, *а* сузыгына тәмамлана. Тиешле авазларны, иҗекләрне җыябыз: А.Б.АМ.КА. Укыла: АБАМКА — исем, берлектә, беренче зат тартым кушымчасы белән төрләнә, юнәлеш килештә.



А26. Рәсем атамалары: **ТУН, ӘН, ИМИ, КАЛКАН**. Шакмакта ике сүз: берсе калын, икенчесе нечкә әйтелештә. Соңгы рәсем астында сәкен юк. Икенче сүз *ә* сузыгына тәмамлана. Иҗекләрне җыябыз: ТУ.ӘН.ИМ.КА. Ту иҗеге аерым әйтелә. ИМ иҗегенең и сузыгы киңәйтелеп *ие* рәвешендә әйтелә. КА иҗеге нечкә әйтелешкә күчә. Укыла: ТУ ӘНИЕМКӘ. ТУ — уңай сыйфат белдерүче сүз. ӘНИЕМКӘ — исем, берлектә, беренче зат тартым кушымчасы белән төрләнә, юнәлеш килештә.




А25. Рәсем атамалары: **ТУН, ТӨРТКЕ, КАЛПАК**. Калын әйтелештә, сәкен юк, *а* сузыгына тәмамлана. Иҗекләрне, бер авазны җыябыз: ТУ.Т.КА. Укыла: ТУТАКА — исем, берлектә, юнәлеш килештә.



А24. Рәсем атамалары: **АЛАБ, МА, МӨГЕШ**. Калын әйтелештә, сәкен юк, *а* сузыгына тәмамлана. Иҗекләрне җыябыз: А.МА.М. Укыла: АМАМА — исем, берлектә, беренче зат тартым кушымчасы белән төрләнә, юнәлеш килештә.



А23. Рәсем атамалары: **КОШ, ШӨШЛЕ, КЪ — ?** Калын әйтелештә, сәкен юк, *а* сузыгына тәмамлана. Авазларны һәм бер иҗекне җыябыз: КО.Л.КЪ. Укыла: КОДКА (КУЛКА) — исем, берлектә, юнәлеш килештә.



А22 Рәсем атамалары: **АЛАБ, СӨЙӘК, ТА, К — ?** Шакмакта ике сүз, икесе дә калын әйтелештә, сәкен юк, соңгы сүз *а* сузыгына тәмамлана. Бер иҗекне, авазларны җыябыз: А.С.ТА.К. Укыла: АС ТА-КА. АС-уңай сыйфат белдерүче сүз, ТАКА — исем, берлектә, юнәлеш килештә.



А21 Рәсем атамалары: **ТИ, СӨЙӘК, АМ, ИМИ**. Нечкә әйтелештә, сәкен юк, *ә* сузыгына тәмамлана. Иҗекләрне, авазларны җыябыз: Т.С.М.ИМ. Укыла: ТӘСӘМИМӘ? ТӘСӘ-МЕМӘ? ТИСӘМЕМӘ?



А20. Рәсем атамалары: **АЛАБ, САЙКА, НИМӘ, КАШКАРЫЙ**. Шакмакта ике сүз, икесе дә калын әйтелештә, сәкен юк, ахыргы сүз *а* сузыгына тәмамлана. Иҗекләрне, авазларны җыябыз: А.СА.Н.К. Укыла: АС АНАКА. АС — уңай сыйфат белдерүче сүз.

АНАКА — исем, берлектә, юнәлеш килештә.



А19. Рәсем атамалары: **АЙР, ЙАЙА**. Калын әйтелештә, сәкен юк, *а* сузыгына тәмамлана. Бер авазны һәм иҗекне җыябыз: Р.ЙА. Укыла: РАЙА — исем, берлектә, баш килештә.



А18. Рәсем атамалары: **Ә —?, ТУН, КӘМӘ, ИШКӘК, НИМӘ, МӨГЕШ**. Шакмакта ике сүз, икесе дә нечкә әйтелештә, сәкен юк, сүзләрнең икесе дә *ә* сузыгына тәмамлана. Авазларны, иҗекләрне җыябыз: Ә.Т.КӘМӘ.И.Н.М. Укыла: ӘТЕКӘМӘ-ИНӘМӘ — икесе дә исем, берлектә, беренче зат тартым кушымчасы белән төрләнәләр, юнәлеш килештә.



А17. Рәсем атамалары: **КЪОИКЪА, ТИ**. Калын әйтелештә, сәкен бар, *т* тартыгына тәмамлана. Иҗек белән авазны җыябыз: К.Т. Укыла КОТ (КУТ) — исем, берлектә, баш килештә.



А16. Рәсем атамалары: **АЛАБ, КОШ, ШӨШЛЕ**. Калын әйтелештә, сәкен бар, *л* тартыгына тәмамлана. Авазларны җыябыз: А.КЪ.Л. Укыла: АКЫЛ — исем, берлектә, баш килештә.



А15. Рәсем атамалары: **АЛАБ, ТУН, ТУН, К — ?, С — ?, КЫРГЫЧ**. Калын әйтелештә, сәкен юк, *а* сузыгына тәмамлана. Авазларны җыябыз: А.Т.Т.К.С.К. Укыла: АТТА-

КАСКА — исем, берлектә, юнәлеш килештә.



А14. Рәсем атамалары: **КАРАУЛ, НИМӘ**. Калын әйтелештә, сәкен юк, а сузыгына тәмамлана. Иҗек белән авазны җыябыз: КА.Н. Укыла: КАНА — теләк белдерүче кисәкчә.



А13, А16 шакмагындагы АКЫЛ сүзе кабатлана.




А12. А18 шакмагындагы ӘТЕКӘМӘ-ИНӘМӘ сүзләре кабатлана.



А11. А17 шакмагындагы КОТ (КУТ) сүзе кабатлана.



А10. А16 шакмагындагы АКЫЛ сүзе кабатлана.



А9. Рәсем атамалары: **АЛАБ, ТУН, КАМЫТ, САЙКА, МӨГЕШ, ТУН**. Шакмакта ике сүз, икесе дә калын әйтелештә, икесе дә *а* сузыгына тәмамлана. Беренче сүз **МӨГЕШ** рәсемендә тәмамлана. Соңгы ТУН рәсеме *та* теркәгечен белдерә. Авазларны һәм бер иҗекне җыябыз: А.Т-.КА.С.М.Т. Укыла: АТАКАСЫМА ТА. АТАКАСЫМА — исем, берлектә, беренче зат


тартым кушымчасы белән төрләнә, юнәлеш килештә. ТА — җыючы теркәгеч.



А8. Рәсем атамалары: **МА, МӨГЕШ, КАПКАЧ, ТА.** Шакмакта ике сүз, икесе дә калын әйтелештә, сәкен юк, *а* сузыгына тәмамлана. Иҗекләрне, бер авазны җыябыз: МА.М.КА.Т. Укыла: МАМАКА ТА. МАМАКА — исем, берлектә, юнәлеш килештә, ТА — җыючы теркәгеч.




А7. Рәсем атамалары: **КОШ, ШӨШЛЕ, КАЛКАН**. Калын әйтелештә, сәкен юк, *а* сузыгына тәмамлана. Авазларны һәм бер иҗекне җыябыз: КО.Л.К. Укыла: КОЛКА (КУЛКА) — исем, берлектә, юнәлеш килештә.



А6. Рәсем атамалары: **АЛАБ, НИЖДАГЪ, ТИ**. Калын әйтелештә, сәкен юк, *а* сузыгына тәмамлана. Авазларны җыябыз: А.Н.Т. Укыла АНТА. А5 белән бергә «һәм» теркәгече мәгънәсен белдерә.



А5. Рәсем атамалары: **НИМӘ, ТА, К — ?**. Нечкә әйтелештә, сәкен бар, *к* тартыгына тәмамлана. Авазларны җыябыз: Н.Т.К. Укыла: НӘТӘК. А6 шакмагындагы АНТА сүзе белән бергә «һәм» теркәгече мәгънәсен белдерә.




А4. Рәсем атамалары: **ИШКӘК, МИҢЛЕ, КАШКАРЫЙ**. Нечкә әйтелештә, сәкен юк, *ә* сузыгына тәмамлана. Авазларны, иҗекләрне җыябыз:

И.Л.К. Укыла ИЛКӘ — исем, берлектә, юнәлеш килештә.



А3. А15 шакмагындагы АТТАКАСКА сүзе кабатлана.



А2. Рәсем атамалары: **НИЖДАГЪ, ТИ**. Нечкә әйтелештә, сәкен юк, *ә* сузыгына тәмамлана. Авазларны җыябыз: Н.Т. Укыла: НИТӘ? НӘТӘ? НИ ТӘ? НӘ ТӘ?



А1. А4 шакмагындагы ИЛКӘ сүзе кабатлана.

## 9. ФЕСТ ДИСБЕСЕНЕҢ СУЛ ЯГЫНДАГЫ СҮЗЛӘРНЕ УКУ



В30. Рәсем атамалары: **АЛАБ, ДИ, АМ, ИМИ**. Калын әйтелештә, сәкен юк, *а* сузыгына тәмамлана. Авазларны, иҗекләрне җыябыз: А.Д.АМ.ИМ. Укыла: АДАМЫМА — исем, берлектә, беренче зат тартым кушымчасы белән төрләнә, юнәлеш килештә.



В29. Рәсем атамалары: **ТУН, ӘН, ИМИ, К — ?**. А24 шакмагындагы ТУ ӘНИЕМКӘ сүзе кабатлана.




В28. Рәсем атамалары: **Ә — ?, С-?, НИМӘ, МАЛАЙ**. Шакмакта ике сүз, икесе дә нечкә әйтелештә, сәкен бар, соңгы сүз *м* тартыгына тәмамлана. Авазларны җыябыз: Ә.С.Н.М. Укыла: ӘС ӘНӘМ. ӘС — уңай

сыйфат белдерүче сүз, ӘНӘМ — исем, берлектә, беренче зат тартым кушымчасы белән төрләнә, баш килештә.




В27. Рәсем атамалары: **ДИ, КӘМӘ, ТУН**. Шакмакта ике сүз, икесе дә нечкә әйтелештә. ТУН рәсеме астында сәкен юк. Беренче сүз КӘМӘ иҗекләренә, икенчесе *ә* сузыгына тәмамлана. Иҗекләрне, бер авазны җыябыз: ДИ.КӘМӘ.Т. Укыла: ДИКӘМӘ ТӘ. ДИКӘМӘ — исем, берлектә, беренче зат тартым кушымчасы белән төрләнә, ТӘ — җыючы теркәгеч.



В26. Рәсем атамалары: **КАРАУЛ, ЭЙ, ӘМ, КАЛКАН**. Шакмакта калын һәм нечкә әйтелештәге ике сүз, сәкен юк. Соңгы сүз *ә* сузыгына тәмамлана. Иҗекләрне һәм бер авазны җыябыз: КАРАУЛ.ЭЙ-.ӘМ. К. Укыла: КАРАУЛ ЭЙЕМКӘ. КАРАУЛ сүзе сыйфат ролендә килә. ЭЙЕМКӘ — исем, берлектә, беренче зат тартым кушымчасы белән төрләнә, юнәлеш килештә.



В25. Рәсем атамалары: **САДАК, НИМӘ, МӨГЕШ, ИЛӘК**. Соңгы рәсем *к* тартыгын белдерә. Шакмакта калын һәм нечкә әйтелештәге ике сүз. Соңгы рәсем янында сәкен бар, *к* тартыгына тәмамлана. Иҗекләрне, авазларны җыябыз: САДАК.Н.М.К. Укыла: САДАКА НИМӘК. САДАКА — исем, берлектә, баш килештә, НИМӘК — фигыль.




В24. Рәсем атамалары: **НИЖДАГЪ, ТИ, АЙР, КАРАУЛ.** Нечкә әйтелештә, сәкен юк, *ә* сузыгына тәмамлана. Авазларны һәм бер иҗекне җыябыз: НИ.Т.Р.К. Укыла НИТӘРЕКӘ — исем, берлектә, юнәлеш килештә.



В23. Рәсем аңлатмалары: **БАЛТА, ИМИ, НИЖДАГЪ, ТИ, МӨГЕШ.** Нечкә әйтелештә, сәкен юк, *ә* сузыгына тәмамлана. Авазларны җыябыз: Б.И.Н.Т.М. Укыла: БИНТЕМӘ — исем, берлектә, беренче зат тартым кушымчасы белән төрләнә, юнәлеш килештә.



В22. Рәсем атамалары: **ДИ, С — ?, Б — ?, КӘМӘ.** Нечкә әйтелештә, сәкен юк, *ә* сузыгына тәмамлана. Иҗекләрне, авазларны җыябыз: ДИ.С.Б. КӘМӘ. Укыла: ДИСБЕКӘМӘ — исем, берлектә, беренче зат тартым кушымчасы белән төрләнә, юнәлеш килештә.




В21. Рәсем атамалары: **ИМИ, ЭЙ, АМ, К — ?** Шакмакта ике сүз, икесе дә нечкә әйтелештә, сәкен юк. Соңгы сүз *ә* сузыгына тәмамлана. Иҗекләрне, бер авазны җыябыз: ИМ.ЭЙ.АМ.К. Укыла: ИМ ЭЙЕМКӘ. ИМ — сыйфат ролендә килә, ЭЙЕМКӘ — исем, берлектә, беренче зат тартым кушымчасы белән төрләнә, юнәлеш килештә.



В20. Рәсем атамалары: **Ә — ?, ШӨШЛЕ, С — ?, АМ.** Шакмакта ике сүз, икесе дә нечкә әйтелештә, сәкен юк, соңгы сүз *ә* сузыгына тәмамлана. Авазларны җыябыз: Ә.Л.СМ Укыла: ӘЛ ӘСӘМӘ. ӘЛ — уңай сыйфат белдерүче сүз, ӘСӘМӘ — исем, берлектә, беренче зат тартым кушымчасы белән төрләнә, юнәлеш килештә.



В19. Рәсем атамалары: **ТУН, КӘМӘ, КАШКАРЫЙ, ТИ.** Шакмакта өч сүз. Беренче сүз калын әйтелештә, икенче, өченче сүзләр нечкә әйтелештә. Сәкен юк, соңгы сүз *ә* сузыгына тәмамлана. Иҗекләрне, авазларны җыябыз: ТУ КӘМӘ.К.Т. Укыла: ТУ КӘМӘКӘ ТӘ. ТУ — сыйфат яки сан, КӘМӘКӘ — исем, берлектә, юнәлеш килештә, ТӘ — җыючы теркәгеч. Сүзне ТҮКӘМӘКӘ ТӘ дип тә укырга була.



В18. Рәсем атамалары: **ИР, ЭЙ, ЭЙ, ӘМ, К — ?.** Шакмакта ике сүз, икесе дә нечкә әйтелештә, сәкен юк, соңгы сүз *ә* сузыгына тәмамлана. Иҗекләрне, авазларны җыябыз: ИР.ЭЙ.Э.М.К. Укыла- ИР ЭЙЕМКӘ. ИР — сыйфат ролендә килә, ЭЙЕМКӘ — исем, берлектә, беренче зат тартым кушымчасы белән төрләнә, юнәлеш килештә.



В17. Рәсем атамалары: САДАК, КАМЫТ, МӨГЕШ. Калын әйтелештә, сәкен юк, *а* сузыгына тәмамлана. Иҗек-

ләрне, бер авазны җыябыз: СА.КА.М. Укыла САКАМА — исем, берлектә, беренче зат тартым кушымчасы белән төрләнә, юнәлеш килештә.




B16. Рәсем атамалары: **ИР, КАРАУЛ, ТИ.** Шакмакта ике сүз, икесе дә нечкә әйтелештә, сәкен юк, сүзләрнең икесе дә *ә* сузыгына тәмамлана. Бер иҗекне һәм авазларны җыябыз: ИР.К.Т. Укыла: ИРКӘ ТӘ. ИРКӘ — исем, берлектә, юнәлеш килештә, ТӘ — теркәгеч.



B15. Рәсем атамалары: **МА, К — ?, САЙКА, АЙР, КАРАУЛ.** Шакмакта ике сүз, икесе дә калын әйтелештә, сәкен юк, ике сүз дә *а* сузыгына тәмамлана. Иҗекләрне, авазларны җыябыз: МА.К.СА.Р.К. Укыла МАКА САРКА. МАКА — уңай сыйфат белдерүче сүз, САРКА-исем, берлектә, юнәлеш килештә.



B14. Рәсем атамалары: **Ә — ?, БАШЛЫК, ТУН, ТИ.** Шакмакта ике сүз, икесе дә нечкә әйтелештә, сәкен юк, соңгы сүз *ә* сузыгына тәмамлана. Авазларны җыябыз: Ә.Б.Т.Т. Укыла: ӘБЕТИ ТӘ. ӘБЕТИ — исем, берлектә, баш килештә, ТӘ — җыючы теркәгеч.



B13 Рәсем атамалары: **ИР, С — ?, ИМИ, КАЛПАК.** Шакмакта ике сүз, икесе дә нечкә әйтелештә. Беренче сүз *ә* сузыгына тәмамлана, икенче сүз азагында сәкен бар — *к* тартыгына тәмамлана. Иҗек-

ләрне, авазларны җыябыз: ИР.С.ИМ.К. Укыла: ИРСӘ ИМӘК. ИРСӘ — исем, берлектә, баш килештә, ИМӘК — ярдәмче фигыль.



В12. Рәсем атамалары: **ИР, КАЛПАК, НИЖДАГЪ**. Нечкә әйтелештә, сәкен юк, *и* яки *е* сузыгына тәмамлана. Авазларны һәм бер иҗекне җыябыз: ИР.К.Н. Укыла: ИРЕКНЕ (ИРЕКНИ) — исем, берлектә, төшем килештә.




В11. Рәсем атамалары: **ИР, ӘН, ИМИ**. Нечкә әйтелештә, сәкен бар, *м* тартыгына тәмамлана. Иҗекләрне җыябыз: ИР.ӘН.ИМ. Укыла: ИРӘНЕМ — исем, берлектә, беренче зат тартым кушымчасы белән төрләнә, баш килештә.



В10. Рәсем атамалары: **ДИ, ИР, С — ?, ИМИ, КАЛПАК**. Шакмакта ике сүз, икесе дә нечкә әйтелештә. Беренче сүз *ә* сузыгына тәмамлана, икенче сүз азагында сәкен бар — *к* тартыгына тәмамлана. Авазларны, иҗекләрне җыябыз: Д.ИР.С.ИМ.К. Укыла ДИРСӘ ИМӘК. ДИРСӘ — фигыль, ИМӘК — ярдәмче фигыль.



В9. Рәсем атамалары: **ТУН, КОңГЫЗ, НИМӘ, КӘМӘ**. Нечкә әйтелештә, сәкен юк, *ә* сузыгына тәмамлана. Иҗекләрне, авазларны җыябыз: ТУ.К.Н.КӘМӘ. Укыла: ТҮКӘНӘКЕМӘ — исем, берлектә, беренче зат тартым кушымчасы белән төрләнә, юнәлеш килештә.



В8. Рәсем атамалары: **ИМИ, МӨГЕШ, К — ?**. Нечкә әйтелештә, сәкен юк, *ә* сузыгына тәмамлана. Авазларны, бер иҗекне җыябыз: ИМ.М.К. Укыла: ИММӘКӘ — исем, берлектә, юнәлеш килештә.



В7. Рәсем атамалары: **ИМИ, ӘН, ИМИ**. Рәсем атамалары нечкә әйтелештә булса да, сүз нечкә һәм калын әйтелештә. Сәкен бар, *м* тартыгына тәмамлана. Иҗекләрне җыябыз: ИМ.ӘН.ИМ. Укыла: ИМАНЫМ — исем, берлектә, беренче зат тартым кушымчасы белән төрләнә, баш килештә.



В6. Рәсем атамалары: **ИМИ, НИМӘ, МӨГЕШ, ЭЙ**. Шакмакта ике сүз, икесе дә нечкә әйтелештә. Сәкен юк, беренче сүз *ә* сузыгына, икенче сүз *э (е)* сузыгына тәмамлана. Иҗекләрне, авазларны җыябыз: ИМ.Н.М.ЭЙ. Укыла: ИМНӘМӘ ЭЙЕ. ИМНӘМӘ — сыйфат, ЭЙЕ — исем, берлектә, өченче зат тартым кушымчасы белән төрләнә, баш килештә.



В5. В10 шакмагындагы ДИРСӘ ИМӘК сүзләре кабатлана.



В4. Рәсем атамалары: **БАШЛЫК, КУЙ, АЙР, МӨГЕШ, ИМИ**. Калын әйтелештә, сәкен юк, *а* сузыгына тәмамлана. Иҗекләрне, авазларны җыябыз: БА.КУ.Р.М.ИМ. Укыла: БАКУРАМЫМА —

исем, берлектә, беренче зат тартым кушымчасы белән төрләнә, юнәлеш килештә.



В3. Рәсем атамалары: **Ә — ?, МА, К — ?, НИМӘ, ИМИ.** Нечкә әйтелештә, сәкен юк, *ә* сузыгына тәмамлана. Иҗекләрне, авазларны җыябыз: Ә.МА. К.Н.ИМ. Укыла: ӘМӘКӘНЕМӘ — исем, берлектә, беренче зат тартым кушымчасы белән төрләнә, юнәлеш килештә.



В2. Рәсем атамалары: **ИР, КОңГЫЗ, НИМӘ, КӘМӘ.** Нечкә әйтелештә, сәкен юк, *ә* сузыгына тәмамлана. Иҗекләрне, авазларны җыябыз: ИР.К.Н.КӘМӘ. Укыла: ИРКӘНӘКЕМӘ — исем, берлектә, беренче зат тартым кушымчасы белән төрләнә, юнәлеш килештә.



В1. Рәсем атамалары: **ӘН, ИМИ.** Нечкә әйтелештә, сәкен юк, *ә* сузыгына тәмамлана. Иҗекләрне җыябыз: ӘН.ИМ. Укыла: ӘНИЕМӘ — исем, берлектә, беренче зат тартым кушымчасы белән төрләнә, юнәлеш килештә.

## 10. ФЕСТ ДИСБЕСЕНЕҢ УҢ ЯГЫНДАГЫ СҮЗЛӘР ҺӘМ АЛАРНЫҢ АҢЛАТМАСЫ

А31. АНТЫМ. АНТ. Дисбедә бу беренче сүз. Дисбенең ике ягындагы барлык сүзләр дип әйтерлек шушы АНТЫМ сүзенә буйсынып киләләр. Моннан дүрт мең еллар элек яшәгән кеше АНТ игълан итә һәм антның кемнәргә багышланганын белдереп, реаль һәм реаль булмаган нәсел-нәсәбен санап, тезеп китә. АНТЫМнан соң килгән сүзләрнең күпчелеге туганлык терминнары. Арада

дини, социаль-иҗтимагый исем-атамалар да бар. Монда шулай ук гадәти тормыш-көнкүреш сүзләре дә очрый. Сүзләрнең күпчелеге *ма-мә, ка-кә* иҗекләренә тәмамлана. АНТның әлеге исем-атама ияләренә юнәлдерелгәнлеге текстның гомуми төзелешеннән, сүзләренең үзара бәйләнешеннән яхшы аңлашыла.

АНТ сүзе төрки телләрдә бүген дә актив кулланыла. *Ант*ның бүгенге мәгънәсе белән дисбе чорындагы мәгънәсе арасында беркадәр аерма бар сыман. Элекке заманда *ант* «корбан» мәгънәсендә дә кулланылган, ахрысы, ягъни ант бирү, ант эчү буш сүз генә булмаган — бу йоланы башкарганда аллаларга багышлап нидер бирелгән булса кирәк. *Ант* казакъ, кыргыз, кырым-татар, казан-татар, карай, төрек, төрекмән, азәрбайҗан һ.б. төрки телләрдә бар. Шунысы игътибарга лаек, кайберәүләр төрки телләрнең иң борынгысы дип исәпләнгән чуваш телендә *ант* сүзе юк. Чувашча «ант» *тупа, тупа туни* дип атала.

А30. ЭЙЕМКӘ. ЭЙ. Бүгенге татар телендә *өй* рәвешендә әйтелә торган сүзнең әүвәлге әйтелеше бу. Монда *эй* гади торакны түгел, бәлки, дини йолалар башкарыла торган өйне, гыйбадәтханәне белдерә.

А29. ИРӘНЕМ. ИРӘН. Бүгенге татар телендә бу сүз актив түгел. «Аңлатмалы сүзлек»тә *ирән*гә: аллага якын, изге кеше дигән аңлатма бирелгән. Телдә *гаиб ирәннәр* дигән сүз тезмәсе дә бар. *Гаиб ирәннәр* «изге кешеләр» дигәнгә туры килә. Хәзерге төрек телендә *ерен* — алланы танып-белү серләрен төшенүче, изгелек кылучы кеше дигәнне белдерә (На, 173 бит). Карай телендә *эрен* — 1) яхшы, дәрәҗәле, күренекле, белемле, көчле, батыр кеше; 2) ир кеше; 3) ир, хатын ире. Уйгурча *әрән* — яхшы кеше, белемле, көчле, батыр кеше. Ираннең «сугышчы» мәгънәсе татар телендә «Туктамыш дастаны»нда күренә. Дастанда:

Йөз баһадир ирәннән
Йорт-җиреңне бастырдың,—

дигән сүзләр бар.

Шумер телендә *эрен* И.М.Дьяконов аңлатмасында — сугышчы, эшче, (воин, работник), А.И Тюменев аңлатмасында — эшчеләр (рабочие). Әлеге *сүз ирен* формасында Геродотта да очрый. Грекча *ирен* — 20 яшьтән алып 30 яшькә кадәр булган яшь ирләр, спартаннар.

Сүзнең борынгырак формасы Фест дисбесендә, грек һәм татар телләрендә сакланып калган. *Ирәнне ир* һәм *ән* иҗекләреннән торган сүз дип тә, ирә-н, ягъни Ата улы (*penis*) дип тә аңларга була. 20—30 яшьлек ир кеше,

көчле кеше бик борынгы заманнарда билгеле бер урында билгеле бер шартларда аллага тиңләштерелгән һәм алланы алыштыра алган. *Ирән*нең хәтта бүгенге телләрдә дә дини һәм ярым дини сүз буларак кулланылуы шул турыда сөйли дә инде.

А28. ИР-АТКА. ИР-АТ. А29 шакмагындагы ИРӘНЕМ белән ИР-АТ бер-берсен ачыклап киләләр. Хәзерге татар телендә *ир-ат* — гомумән ирләр. Фест чорында бу сүзнең конкрет кемне аңлатуын ачыклау өчен без грек теленә мөрәҗәгать итәбез. Борынгы Грециядә гыйбадәтханәләргә хезмәт күрсәтүче кол ирләрне һәм кол хатын-кызларны, шулай ук гыйбадәтханә хезмәткәрләрен *иеродула (гиеродула)* дип атаганнар. *Иеродулалар* гыйбадәтханә җырләрен эшкәрткәннәр, аллага гыйбадәт кылу эшләрендә ярдәмче ролен үтәгәннәр. Шул ук вакытта гыйбадәтханәләрдә үз ирекләре белән яшәүче, үзләрен аллаларга (алиһәләргә?) багышлаган хатын-кызлар да булган. Мондый хатын-кызлар дини проституция белән шөгыльләнгәннәр. Шундый эштән килгән акча гыйбадәтханә файдасына киткән. Борынгы заманда дини проституция йоласы башка илләрдә, мәсәлән, Кипрда, Вавилонда булган.

Грекча *иеродула* сүзен ир-ат улы дип аңлыйбыз. Ир-ат улы хатын-кызны, ягъни гыйбадәтханәләрдә *ирән* (алла) дәрәҗәсендәге ир-атка бирелүче һәм шулай ук дини проституция белән шөгыльләнүче хатын-кызларны күз алдында тота. Борынгы грекларның мәхәббәт алласы *Эрот* сүзе әүвәлге формасында ир-ат булганга охшый.

А27. АБАМКА. АБА. Борынгы төрки телдә *аба* — тудыручы ата-ана, ата-баба. Абаның кыскартылган *аб* формасы да бар. Алаб сүзенең *аб* өлешен шул ук *аба* дип аңлыйбыз. *Аба*ның *апа* варианты да мәгълүм. Борынгы төрки телдә *апа* таркан титулны аңлаткан.

А26. ТУ ӘНИЕМКӘ. ТУ ӘНИ. Ту иҗеген уңай сыйфат белдерүче сүз дип тә, тудыручы дип тә аңларга була. ТУ ӘНИ сүзен конкрет ана дип түгел, бәлки, мифик ана, иң борынгы, иң әүвәле ана дип аңлау дөресрәк булачак. *Әни* сүзе бары казан татарларында гына сакланган. Бүгенге татар телендәге *дәү әни* әлеге ТУ ӘНИнең беркадәр үзгәрешкә кергән варианты булса кирәк. Моннан ике мең еллар элек Кече Азиядә, Каппадокиядә сугыш алиһәсе *Энио* дип аталган.

А25. ТУТАКА. ТУТА. Татарча *тута* — түтәй, абыстай дигәнне белдерә. Сүзне *ту-та* дип таркатабыз. Туганлык термины буларак, *тута* атаның кыз туганын аңлаткан, ахрысы. *Тута* сүзен *ту Та*, ягъни изге *Та* һәм шулай ук тудыручы *Та* яки иң беренче *Та* дип тә аңларга була.

А24. АМАМА. АМА. Бу сүз *ам*ның тулырак формасы булса кирәк. *Ама* мифик ана түгел, бәлки, реаль ана, тудыручы ана, сөйләүченең үз анасы, ахрысы. Татар теле диалектларында *амам* сүзе бар. Мәгънәсе — апаем, ягъни энемсеңлем, туганым. Сүзне *ама-м* рәвешендә таркатсак, бу «ама улы» булачак. Шумер телендә *ама* «ана» дигәнне, *амар* — «хайван баласы», «бозау» дигәнне белдерә.

А23. КАЛКА. КОЛ (яисә КУЛ). Гомум төрки сүз. Татарча *кол*, кайбер төрки телләрдә *кул* рәвешендә әйтелә.

А22. АС ТАКА. АС ТА. АС — уңай сыйфат белдерүче сүз. ТА — хатын-кыз затындагы кеше. Татар теле диалектларында *астай* сүзе бар. Мәгънәсе — «абыстай». АС ТА әлеге *астай*ның әүвәлге формасы булса кирәк. АС ТАны изге, бөек *Та* дип аңлыйбыз. *Та* борынгы мисыр телендә — «җир». АС ТА Фест чорында ниндидер алиһә булган булырга да мөмкин.

А21. ТӘСӘМИМӘ? ТӘСӘМЕМӘ? ТИСӘМЕМӘ? Бу сүзнең дөрес формасын һәм мәгънәсен белеп булмады. Борынгы грек телендәге «алла» мәгънәсендәге *теос* белән берәр төрле уртаклыгы юк микән дип кенә әйтергә була. Татар телендә *төс* сүзе мәгълүм. *Төсе качкан* дигәндә төс ниндидер җанлы нәрсә булып аңлашыла. *Төс*нең грекча *теос* белән мәгънәдәш булуы ихтимал.

А20. АС АНАКА. АС АНА. АС — уңай сыйфат белдерүче сүз. АНА — «әни» монда конкрет ананы түгел, бәлки алиһә ананы белдерә. Сүзнең *ас* сыйфаты белән әйтелүе шуңа ишарәли. (В28, В27 шакмакларындагы ӘС ӘНӘМ ДИКӘМӘ ТӘ дигән сүзләргә игътибар ит.)

Алтай төрекләренең нәсел башы *Ашина* дип аталган. Алтай төрекләре бүрегә табынганга күрә, бу сүзне, гадәттә, «бүре» дип аңлыйлар. Алтай төрекләренең килеп чыгышы турындагы легендаларда *Ашина* «тудыручы ана» буларак аңлашыла. Крит чоры төрки телдә АС АНАның, *Ас инә* формасы да булган, ахрысы. Мәсәлән, борынгы Грециядә *Асина* топонимы булган. АС АНАны *Ас инә* (*Ашина*) белән бер үк төрдәге «алиһә» дип белсәк, бүренең берничек тә «ана» була алмавы үзеннән-үзе аңлашылып тора дип уйларга кирәк.

А19. РАЙА. Җөмлә шушында тәмамлана. Ант бирүче кеше югарыда санап кителгән реаль һәм мифик туганнарына, нәсел-нәсәбенә изге теләкләр әйтә һәм аларга РАЙА тели. Бу сүз русча *рай* «җәннәт», «оҗмах» сүзенең тулырак варианты булса кирәк. Логик яктан бу бары шулай гына була ала. Татарча *ай* сүзен әлеге РАЙ — РАЙА сүзенең кыскартылган формасы дип исәплибез. Татарча *оҗмах*, борынгы төрки телдә *уҗмакъ* булган сүз,

кайчандыр, димәк, *рай*дан соң килгән һәм *ай*га (*рай*га) очуны күз алдында тоткан. Борынгылар үлгәч яхшы, изге кешеләрнең җаны оҗмахка эләгә, начар кешеләрнең җаны тәмугка эләгә дип исәпләгәннәр. Оҗмахка эләгү, оҗмахка керү очмак сүзе белән белдерелгән. Алтай төрекләренең атаклы ил-гаскәр башлыгы Күл тәгиннең үлеме турында *учды*, ягъни «очты» диелә. Ятимә кыз Зөһрәнең айга менүе турындагы риваятьтә: ятимнәр, ятимәләр изге булалар, үлгәч алар җәннәткә керәләр (*рай*га очалар) дигән караш ята. Татарда бүген дә *рай* катнашында ясалган *Райнур, Райман, Райхан* исемнәре очрый.

А18. ӘТЕКӘМӘ-ИНӘМӘ. ӘТЕКӘ, ИНӘ. Боларның икесе дә гадәти төрки, татар сүзләре. Татарча *әткә, әткәй,* «әти» дигәнне белдерә. Алабуга керәшеннәре телендә *әтеки* формасы да мәгълүм. *Инә* шулай ук киң таралган төрки сүз. Татар теле диалектларында имәнең *инәй, инәкәй* рәвешендәге әйтелешләре билгеле. Элегрәк, хәер-садака биргәч, безнең әниләр (инәкәйләр) «әтекәмә-инәмә» дип багышлап куялар иде. Бүгенге телдә *әтекә, инә* сүзләре конкрет атаны-ананы белдерсә дә, Крит чорында алай булмаган, ахрысы. Хәтта Радлов заманында да (моннан йөз еллар чамасы элек) казан татарлары кояшка «кояш әтекәем-әнекәем» дип эндәшә торган булганнар. Бәлки, Крит чорында да бу сүзләр барлык тереклекнең атасы-анасы исәпләнелгән Кояшка карата кулланылгандыр?

А17. КОТ (КУТ). Гомум төрки сүз. Татар телендә кот — җан, рух, нур һ.б.

А16. АКЫЛ. Гарәптән кергән дип уйланыла торган гомум төрки сүз. Татар телендә төрле мәгънәләре билгеле: 1) кешенең уйлау, фикерләү сәләте, аңлылык дәрәҗәсе; 2) иҗтимагый аң, иҗтимагый фикерләү сәләте һ.б. Крит чорында да *акыл*ның мәгънәләре бүгенге мәгънәләргә туры килгәндер дип әйтәсе килә.

А15. АТТАКАСКА. АТТАКАС. АТТА. Иркәләп, яратып әйтелгән бу сүзнең конкрет нинди «ата»ны күз алдында тотуы мәгълүм түгел. «Әтинең әтисе» булса кирәк. АТТАның татарча балалар телендә әттә формасы мәгълүм.

А14. КАНА. Татар теле диалектларында теләк белдерүче кисәкчә буларак кулланыла.

А13. АКЫЛ. А16 шакмагындагы сүз кабатлана.

А12. ӘТЕКӘМӘ-ИНӘМӘ. А18 шакмагындагы сүз кабатлана.

А11. КОТ (КУТ). А17 шакмагындагы сүз кабатлана.

А10. АКЫЛ. А16 шакмагындагы сүз кабатлана.

А9. АТАКАСЫМА ТА. АТАКАС. АТА. А15 шакмагында АТТАКАСКА рәвешендәге сүз биредә бер генә *т*

белән әйтелә. Бу бары «орфографик хата» гынамы, әллә монда мәгънә аермасы да бармы? Моны кистереп әйтүе кыен. ТА — җыючы теркәгеч.

А8. МАМАКА ТА. МАМА. А19 шакмагындагы райа кебек үк *мама* сүзе дә бүгенге көндә төрки түгел сыман тоела. Рус телендә *мама* — әни. *Мама* киң таралган сүз. *Мама* бер-берсеннән бик нык үзгә кытай, гарәп телләрендә дә «әни» дигән мәгънәдә кулланыла. Төрки телләрдә ул күбрәк әнинең әнисенә, дәү әнигә карата әйтелә. Заманында Радлов теркәп калдырганча, Казан-татар телендә *мама* — «әби», «дәү әни» дигәнне белдергән. (Рад, IV, 2064). Уйгурча *мама* — «карчык», «әби», үзбәкчә *мома* — «имезүче ана», «әби» дигәнгә туры килә. Борынгы Вавилонда *мама* — «алиһә-ана». Крит чоры төрки телдә *мама* «әнинең әнисе» булгандыр сыман. Бәлки Вавилондагы кебек «алиһә-ана» да булгандыр. ТА — җыючы теркәгеч.

А7. КОЛКА. КОЛ (КУЛ). А23 шакмагындагы сүз кабатлана.

А6. АНТА. Хәзерге татар телендә *анда* буларак мәгълүм сүз. Тик шулай да *анда* белән АНТАны тулысынча тәңгәл дип әйтеп булмый. *Анда* башлыча алмашлык буларак кулланыла һәм «кайда?» соравына җавап бирә. «Аңлатмалы сүзлек»тә *анда*га бирелгән мәгънәләрнең 4 мәгънәсе АНТА мәгънәсенә якынрак. Мәсәлән, «тизрәк кыймылдагыз анда!» дигән боерык җөмләдә *анда* «сез кайда?» соравына җавап бирми, бәлки «сез дә», «шулай ук» дигән мәгънә белдерә.

А5. НӘТӘК. Бу да АНТА кебек үк теркәгеч булып килә һәм А6 шакмагындагы сүз белән бергә карала. Чыгытай телендә *нәтәк* «точно так как», уйгурча *нәдәк* «точно так как» (Рад, III, 682), Коръәннең XII—XIII гасырларда Урта Азиядә башкарылган тәфсирендә *нәтәк* «подобно тому, как» (Бор, 228 бит), борынгы төрки телдә *нетәг* «подобно чему, каков», «что за?» (ДТС, 358 бит). АНТА НӘТӘК сүзләрен тулаем «һәм шулай ук» дип аңларга була.

А4. ИЛКӘ. ИЛ. Бүгенге төрки телләрдә *ил* сүзенең төп мәгънәсе: җир-су, дәүләт, кабиләләр берләшмәсе, туган җир, халык, аерым төркем һ.б. Дисбедәге ИЛ дә, күрәсең, нигездә, шундый ук мәгънәләрне белдергәндер дип әйтергә була.

А3. АТТАКАСКА. А15 шакмагындагы сүз кабатлана.

А2. НИТӘ? НӘТӘ? НИ ТӘ? НӘ ТӘ? Бу шакмактагы сүзнең дөрес әйтелешен һәм мәгънәсен ачыклап булмады.

А1. ИЛКӘ. ИЛ. А4 шакмагындагы сүз кабатлана.

## 11. ФЕСТ ДИСБЕСЕНЕҢ СУЛ ЯГЫНДАГЫ СҮЗЛӘР ҺӘМ АЛАРНЫҢ АҢЛАТМАСЫ

В30. АДАМЫМА. АДАМ. Бу — дөньяда бик күп телләрдә кулланыла торган сүз. *Адам* Библиядән алынган дип, яһүдләрдән гарәпләргә күчкән, ислам дине белән төрки һәм башка халыкларга таралган дип аңлатыла. Библиянең иң борынгы нөсхәсе б.э.к. XII гасыр азакларында, XI гасыр башларында барлыкка килгән. Шулай булгач, Библия Фест дисбесеннән кимендә 500 елга соңрак язылган. Библиядә әйтелгәнчә, *Адам* — дөньяда иң беренче кеше, Еваны тудыручы һәм аның ире. *Адам*ның, мәгънәсе — «кеше», *Ева*ныкы — «тормыш» дип аңлатыла. *Адам*ның төзелеше — төрки. Ноль формада — *ада (ата)*.

Дисбенең сул ягында АДАМЫМА сүзеннән соң ТУ ӘНИЕМКӘ дигән сүз урнашкан. Бу сүзне без А26 шакмагында очраттык инде. Шуннан алда, А27 шакмагында АБАМКА сүзе урнашкан. Уң яктагы АБАМКА, ТУ ӘНИЕМКӘ сүзләре мәгънә ягыннан бер-берсенә ярашып киләләр. Иң элек АБА — ир затыннан булган нәсел башы, аннан соң ТУ ӘНИ — хатын-кыз затыннан булган нәсел башы телгә алына. Түгәрәкнең сул ягында да шул ук хәл кабатлана: иң элек АДАМЫМ, аннан соң — ТУ ӘНИ. Димәк, АБА белән АДАМЫМ бер үк мәгънәдәге сүзләр һәм аларның икесе дә ир затындагы ата-бабаны — нәсел башын белдерәләр. ТУ ӘНИ һәр ике очракта үзгәрешсез кала. АБА белән АДАның бер үк мәгънәдәге сүзләр булуын хәзерге татар телендәге *ата-баба* дигән парлы сүз ярдәмендә дә исбатларга мөмкин.

Монда шуны да әйтергә кирәк, Фест дисбесе иҗат ителгән чорда ук *адам* сүзе катып калган бик борынгы формада кулланылган. Дисбе телендә т ләштерү өстенлек итә. Шулай була торып та *ата, атам* булырга тиеш сыман урында *адам* формасы кулланылган икән, димәк, бу сүзне Криттан читтәге башка хаким халыкныкы дип, яисә Крит чорыннан да элегрәк яшәгән һәм дин-идеология мәсьәләсендә үз карашларын булдырган борынгырак, алдынгырак кабилә-диалект сүзе дип уйларга урын кала. Шул ук вакытта Критның үзендә дә *д* ләштереп сөйләшүче башка кабилә булуы ихтималын да истән чыгара алмыйбыз.

Татар сөйләм телендә бу сүз *әдәм*, әдәби телдә *адәм*, казакъ, азәрбайҗан, төрек һ.б. төрки телләрдә — *адам* буларак кулланыла.

В29. ТУ ӘНИЕМКӘ. ТУ ӘНИ. А26 шакмагындагы сүз кабатлана.

В28. ӘС ӘНӘМ. ӘС ӘНӘ. А20 шакмагындагы АС АНА сүзенең нечкә варианты, ахрысы.

В27. ДИКӘМӘ ТӘ. ТӘ — җыючы теркәгеч. ДИКӘ сүзен В28 шакмагындагы ӘС ӘНӘМ белән бергә карарга кирәк. ДИКӘ — изге, бөек «әнә»нең исеме. Борынгы грекларда *Дике (Дика)* Зевс белән Фемиданың кызы, хакыйкать һәм гаделлек алиһәсе. Безнең *Дикә* дә шул ук *Дике* (*Дика*) булса кирәк. Крит чоры төркиләрендә *Дикә* ниндирәк эшләр белән идарә итүче алиһә булгандыр, әйтүе кыенрак.

В26. КАРАУЛ ЭЙЕМКӘ. КАРАУЛ ЭЙЕ. Каравыл өйләре 1917 елга кадәр һәрбер татар авылында булган. Кайбер җирләрдә ул әле дә бардыр дип әйтергә була. *Караулы* — «балык» дигәнгә туры килә. В26 шакмагында балык сурәтләнгән дә. *Кара-улы* сүзен шулай ук «җир» дип тә аңлыйбыз. КАРАУЛ ЭЙЕн Җиргә, Анага табынучылар гыйбадәтханәсе дип беләбез. Җиргә, Анага багышланган гыйбадәтханәләрнең күбесе — «җир уллары». Мәсәлән, немецча «чиркәү» — *кир-хе*, урду телендә — *гир-җа*, азәрбайҗан телендә — *кил-сә* дип атала.

В25. САДАКА НИМӘК. Югарыда санап кителгәннәргә, ягъни: *адамыма, ту әниемә, әс энәм Дикәмә тә, караул эемә* САДАКА бирү турында сүз бара. Татарча садака (сүзлектә: *сәдака*) — приношение, искупительная жертва, подаяние, милостыня. Татарча төп мәгънәләре: хәерсадака, корбанның бер төре. НИМӘК — фигыль. Сүзне *ни-мәк* дип таркатабыз. Ни иҗеге хәзерге татар телендә *нитү* фигыле ясауда катнаша һәм шактый актив кулланыла. *Нитү* белән *бирү* фигыленең мәгънәләре бер-берсенә тәңгәл. НИМӘК сүзенең дә мәгънәсе шулайрак булырга тиеш дип фикер йөртәбез.

В24. НИТӘРЕКӘ. НИТӘРЕ. Бүгенге төрки телләрдә мондый сүз юк, ахрысы. Борынгы мисыр телендәге н.т.р. — «алла» булса кирәк бу. Татар телендәге тәре сүзе шушы нитәренең кыскарганы түгел микән дип әйтәсе килә. Тәре — крест, ләкин аның «икона» мәгънәсе дә бар. Мисырда да, Критта да аллалар сынын, сурәтен ясау тыелмаган, киресенчә, алла һәм алиһәләрнең сыннарын, сурәтләрен һәркайда (бигрәк тә КАРАУЛ ЭЙләрендә) күрергә мөмкин булган. Борынгы мисыр телендә «алла»ның н.т. формасы да бар. н.т. тартыкларын *нитә* рәвешендә тулыландырсак, *нитәре* сүзен *нитә ре* дип таркатырга туры килер иде. Моның мәгънәсе «алла — кояш» булачак. НИТӘРЕне ничек аңласак та, шунысы бәхәссез — Крит төркиләре белән Мисыр төркиләре шактый аралашып яшәгәннәр.

В23. БИНТЕМӘ. БИНТЕ. Төрки телләрдә мондый сүз юк дип исәпләнелә. Гарәпчә *бин* — ул, угыл, *бинт* — кыз,

кыз бала. Шулай да төрки телләрдә дә бу сүзнең кайбер калдыкларын очратырга була. Төрекчә *бинт* — кыз, кыз бала. Татарда *«Гуҗ бине Гоның»* дигән сүз тезмәсе бар. *Бине* монда улы дигәнгә туры килә. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» китабында бинте сүзе очрый. Дисбедәге *бинте* сүзе Крит чоры төркиләренең бүгенге төрки халыклар белән генә түгел, бәлки гарәпләрнең дә күпмедер өлеше белән тугандаш булуы турында сөйли. Бүгенге татар телендәге күп кенә гарәп «алынма»лары безнең бик борынгы ата-бабаларыбыз өчен дә, семит телле кабиләләр арасында үзләренең әүвәлге телләрен югалткан һәм бүген гарәп дип аталган халыклар өчен дә кайчандыр уртак булган.

В22. ДИСБЕКӘМӘ. ДИСБЕ. Татар әдәби телендә *тәсбих* дип аталган сүз кайбер диалектларда (Гайнә, Минзәлә, Камышлы якларында) *дисбе* дип атала. ДИСБЕ әлеге Фест түгәрәгенең үзе.

В21. ИМ ӘЙЕМКӘ. ИМ ӘЙЕ. ИМ монда сыйфат ролендә килә. Татарча *им* — ырым, им-том, дәвалау. Крит чорында *им* сүзенең мәгънәсе башкачарак булган, ахрысы. (Бу хакта В14 — В6 шакмакларындагы сүзләрне кара.)

В20. ӘЛ ӘСӘМӘ. ӘЛ ӘСӘ. ӘЛ — уңай сыйфат белдерүче сүз. *Әсә* башкортча — ана, инә, әни. *Әсә* белән *әнә, ана, инә* сүзләре арасында мәгънә аермасы булгандырмы-юкмы, әйтүе кыен. Ихтимал, бу сүз дисбегә катнашы булган берәр төрле алиһәне күз алдында тотадыр дип кенә әйтергә була.

В19. ТУ КӘМӘКӘ ТӘ? ТҮКӘМӘКӘ ТӘ? Сүзнең төгәл мәгънәсен һәм формасын белеп булмады. В9 шакмагындагы ТҮКӘНӘКЕМӘ сүзенең м варианты булса кирәк.

В18. ИР ӘЙЕМКӘ. ИР ӘЙЕ. *Ир* сүзен буга (үгез) дип белсәк, ИР ӘЙЕ ул буга (үгез) өе булачак. Грек мифларында Критта кеше ашаучы Минотавр дигән үгез булуы турында әйтелә. Минотаврның гәүдәсе кешенеке кебек, башы үгезнеке кебек булган, имеш. Минотавр Лабиринт дигән сарайда яшәгән, имеш. Бу сүзнең «ирләр өе» дигәнне белдерүе дә ихтимал. Әйтик, ИМ ӘЙЕ — хатын-кызлар өе һәм гыйбадәтханәсе, ИР ӘЙЕ — ирләрнең һәм яшүсмерләрнең (ирәннәрнең?) өе булачак.

В17. САКАМА. САКА. Бу сүз монда патша, хаким мәгънәсендә кулланыла. Кара диңгез буе скифлары үзләрен *сколот* дип атаганнар. Сүзнең мәгънәсе «патша кабиләләре» дигәнгә туры килә (Г, IV, 6). Иран кешеләре урта гасырларда үзләреннән төньякта яшәгән күршеләрен *саклаб* дип атаганнар. Абул Гази язганча, мифик Яфәс улларының берсе *Саклаб* исемле булган. *Сколот* сүзен иҗек методы нигезендә *сакалат* дип тулыландырабыз һәм *сака-лат* рәвешендә таркатабыз. *Сака* — патша, *лат* — улы (кабиләсе) була.

*Сакалаб* та — патша улы (патша кабиләсе). Татарча *сакчы* да патша улы, ягъни патшаның кораллы ире. Гап-гади *сакал* сүзендә дә *сака* — патша, л — улы дигәнне белдерә. Борынгы Мисырда, мәсәлән, сакал-мыек үстерү бары патшаларга гына хас нәрсә булган. 18 яшендә үлгән Тутанхамон патшаның алтын маскасы сакаллы итеп эшләнгән. Ашык уенында кулланыла торган иң авыр сөяк — «сугышчы» сөяк татарча *сага* дип атала.

В16. ИРКӘ ТӘ. ИР. Бу сүз монда «сугышчы»ны аңлата, ахрысы.

В15. МАКА САРКА. МАКА САР. *Мака* сүзе *сар*ны ачыклап, аның уңай сыйфатын белдерә. *Мака* — бөек, изге дигәнгә туры килә. *Сар* да *сака* кебек үк «патша» дигәнне белдерә. Тик бу очракта *сар* сакадан олырак, дәрәҗәлерәк патша. *Сарның* патша, хаким мәгънәләрен аңлатуына мисалларны төрле телләрдән табарга була. Борынгы мисыр телендә *с.р.* — патша, юлбашчы, шумер телендә *шар* — патша, аккад телендә *шарру* — патша, борынгы яһүд телендә *шар* — бәк, патша, хаким, гарәп (Мисыр) телендә *сар* — бәк. Страбон заманында Гарәбстандагы рамманитлар кабиләсенең патшасы *иласар*, Һиндстан патшасы *абисар* дип аталган.

Госманлы-төрек, кырым-татар телләрендә *сәр* — баш кеше, баш, юлбашчы, кыргыз (казакъ) телендә *сара* — батырлык, көч-куәт. Татарча *сарай* сүзен *сар өе* дип аңлыйбыз. Тарихи сармат, Саркел һәм шулай ук Татарстандагы *Сарман*, Удмуртиядәге *Сарапул* атамаларындагы *сар(а)* иҗекләрен «патша» дип беләбез. Борынгы грек телендә *саркофаг* сүзе баштарак таштан чокып ясалган табутны, соңыннан табут формасындагы каберне белдергән. *Саркофагны* татарча *сар кабык* дип төзәтәбез, бу исә сарны сала торган *кабык* булачак. *Кабык* сүзе татарда нәрсәнең дә булса тышчасын белдерә. Шул ук вакытта *кабык* — мәетне зиратка алып бару өчен агач кабыгыннан ясалган махсус носилка. (ТТАС II, 12 бит.)

Шулай итеп, тулаем МАКА САР сүзен «бөек патша» дип аңлыйбыз.

В14. ӘБЕТИ ТӘ. ӘБЕТИ. Татар теленең Чүпрәле, Тау ягы, Тархан, Чистай сөйләшләрендә *әбети* — абыстай. ӘБЕТИнең кемлеге В13—В5 шакмакларындагы сүзләр белән бергә генә ачыклана.

В13. ИРСӘ ИМӘК. ИРСӘ — исем, ИМӘК — ярдәмче фигыль. *Ирсә* сүзе *ир-сә* дип таркатыла. *Ир* — ир кеше, шул ук вакытта Ата улы. *Ир-сә* — ир улы, ягъни *ир* яратучы *сә*. Хәзерге татар телендә *ирсә*нең *ирсәк* формасы бар. *Ирсәк* шелтә белән, яратмыйча әйтелә торган сүз. *Ирсәк* — ирлә-

рне ярата торган, ирләр артыннан чаба торган, ирләргә чамадан тыш омтыла торган хатын-кыз. Радлов сүзлегендә *ирсәк* казан татарлары сүзе буларак теркәлгән. Аңлатмасы: «женщина, гоняющаяся за мужчинами» (Рад, I, 1470).

В12. ИРЕКНЕ. ИРЕК. Сүзнең аңлатмасы В10 шакмагында.

В11. ИРӘНӘМ. ИРӘН. А29 шакмагындагы сүз кабатлана.

В10. ДИРСӘ ИМӘК. Төрки телдәге бу иң беренче ташка басылган тезмә сүзләрне бергә тикшереп карау отышлырак булачак. В14, В13, В12, В11, В10 шакмакларындагы сүзләрне яңадан күчерәбез: ӘБЕТИ ТӘ ИРСӘ ИМӘК, ИРЕКНЕ ИРӘНЕМ ДИРСӘ ИМӘК. Төп мәгънә шуңа кайтып кала: хәзерге «абыстай» мәгънәсендәге *әбети* дә *ирсә*, ягъни ир кеше яратучы хатын-кыз, имеш. *Әбети*нең, кемлеге һәм аның теләге кыек сөйләм формасында белдерелә. Безгә монда аңлашылмаган сүз дә юк сыман. Мәсәлән, *ирсә имәк* белән *дирсә имәк* сүз тезмәләрендәге *имәк* ярдәмче фигыль булып килә. Хәзергечә моны *имеш* дип аңларга була. Бу сүз шулай ук *димәк* сүзенең *д* тартыгы төшеп калган варианты булырга да мөмкин. *Ирән*нең кемлеге шулай ук билгеле. Бары ИРЕК сүзе генә беркадәр аптырау тудыра. Ирләр яратучы «абыстай»ның *ирәне*, имеш, ИРЕК булып чыга. Моны ничек аңларга?

*Ирек* гомум төрки сүз. *Ирек (ерк)* ул көч-куәт һәм көч-куәткә ия булу нәтиҗәсендә үзеңне бәйсез, хөр, ихтыярлы итеп тою. Ләкин *Ир*ләр яратучы *әбети*нең ниндидер абстракт хөрлекне, абстракт азатлыкны үзенең *ирәне* дип белүе мөмкин түгел. ӘБЕТИ үзе кем соң? Әлеге сүз тә теркәгече белән әйтелә. Моны без киңәйтеп: барлык хатын-кызлар кебек, *әбети* дә ирләрне ярата дип аңлыйбыз. Кара диңгез буе скифларының *Табити* дигән алиһәләре булган. *Табити* грекларның *Гестия* дигән алиһәләренә тиң. *Табити* белән *әбети*не бер үк сүз дип беләбез. Сүз башындагы *т* грекча әйтү яисә язу өчен яраклаштырып өстәлгән булырга да, шул ук вакытта *әбети*нең диалекталь вариантын чагылдыручы аваз булырга да мөмкин. Грекларда *Гестия* — ут-учак алиһәсе, ягъни Ут-ана. Шулай итеп, безнең ӘБЕТИ дә Ут-ана, ут алиһәсе булып чыга. (Текстның дәвамы В9, В8, В7, В6, В5 шакмакларында.)

В9. ТҮКӘНӘКЕМӘ. ТҮКӘНӘ. Татар теле диалектларында *түкән, түкәнем, түкәлә* сүзләре бар. *Түкәлә* кечкенә ир балага карата әйтелә. *Түкә-н* Гайнә, Камышлы якларында — бүлтерек, кечкенә кеше дигәнне белдерә. *Түкәнем* кечкенә балаларга иркәләп әйтелә торган сүз. «Үскәнем», «нәнием» дигәнгә туры килә. Иркәләп әйтелә

торган *түкәнәк*не әлеге *түкән, түкәнем, түкәлә* сүзләре белән мәгънәдәш дип беләбез. Тик шулай да монда ТҮКӘНӘК — кечкенә буйлы, бүлтерек була алмый. Монда ул «кече туганым», «сеңлем» дигәнгә туры килә.

В8. ИММӘКӘ. ИММӘ. Сүзне *им* һәм *мә* өлешләренә бүләбез. Бөтен мәсьәлә им иҗекләрен ничек аңлауга кайтып кала. *Им*не исә ике төрле аңларга була: 1) *им* — ана; *им-мә* — Ана улы, хатын-кыз. 2) *им* — җенси мөнәсәбәт мәгънәсендәге фигыль булган очракта *им мә* — им эшләре белән шөгыльләнүче *мә* була. *Им* сүзенең бүгенге татар телендәге мәгънәсе аның күбрәк фигыль булу ихтималына ишарәли. *Иммә* ул *ирсә* хатын-кыз һәм *әбети*нең ТҮКӘНӘГЕ — сөекле сеңлесе.

В7. ИМАНЫМ. ИМАН. Татар телендә *иман*ның мәгънәләре: аллага, пәйгамбәрләргә, диннең төп нигезләренә ышану; ышаныч, ышану, инану.

В6. ИМНӘМӘ ЭЙЕ. В21 шакмагындагы ИМ ЭЙЕнең тулырак формасы, ахрысы. ИМНӘМӘ ЭЙЕ — им эшләре белән шөгыльләнү, ягъни дини проституция өе.

В5. ДИРСӘ ИМӘК. Дүрт юллык тезмә шушында тәмамлана. Ут анасы ӘБЕТИ үзенең сөеклесе ИММӘгә ИМАНЫН (тулы ышанычын) белдерә һәм ИМНӘМӘ ЭЙЕн аның карамагына тапшыра. Икенче төрле итеп әйткәндә, ЭЙ хуҗасы ӘБЕТИ — Ут-ана ИММӘнең эшен хуплый, чөнки ул үзе дә хатын-кыз затыннан.

Критта, Кнос сарае калдыклары арасында җиде кат бала итәкле озын күлмәк кигән тулы күкрәкле, озын толымлы яшь, чибәр алиһә сыны табылган (Со, 60, 63) ӘБЕТИ дип аталган алиһә шул үзе түгел микән? дип әйтәсе килә. Болай дип уйлау өчен кайбер дәлилләр дә бар. Төркиләр карашынча, җир җиде кат, күк җиде кат. Алиһә, билгеле, Җирне чагылдыра. Алиһәнең югары күтәрелгән кулларында берәр җылан, баш киеме өстендә — сакчы эт. Ул чибәр, яшь, ләкин куркыныч. Шушы уңайдан ут турында татарның «күрергә күркәм, тотарга куркам» дигән әйтемен искә төшерергә була. Алиһәнең бала итәкле күлмәген татар хатын-кызларының милли киеме саналган бала итәкле күлмәк белән чагыштыра алабыз. К.Насыйри әйткәнчә, XIX гасыр татар хатын-кызлары бала итәкле күлмәкне бик үк яратмаганнар һәм андый күлмәкләрне бары җиңел холыклы хатыннар гына кия дип исәпләгәннәр. Димәк, алар хаклы булганнар!

В4. БАКУРАМЫМА, БАКУРАМ. Сүзнең төгәл мәгънәсен белеп булмады. Чыгытай телендә *бакур* «зур» дигәнне белдергән (Рад, IV, 1443). Чыгытай сүзенең әлеге БАКУРАМга берәр төрле катнашы бармы-юкмы, әйтүе кыен.

В3. ӘМӘКӘНЕМӘ. ӘМӘКӘНӘ. ӘМӘ — «ана», «әни» мәгънәсендәге АМАның нечкә әйтелеше, КӘНӘ — Ана улы, ягъни кыз. Тулаем сүзне «кыз туганыма» дип аңларга була. Латин шагыйре Овидий әсәрләрендә әйтелгәнчә, грекларның җил алласы Эолның кызлары *Канака* дип аталган (Дво, 150 бит). Әлеге *Канака* белән *кәнә* бер үк сүз булса кирәк.

В2. ИРКӘНӘКЕМӘ. ИРКӘНӘК. Сүз башындагы *ир* иҗекләре КӘНӘ(К)нең ир затыннан булуын күрсәтә. Мәгънәсе — «ир туганыма».

В1. ӘНИЕМӘ. ӘНИ. А26 шакмагындагы (ТУ) ӘНИЕМКӘ сүзенең гадирәк формасы.

### 12. ФЕСТ ДИСБЕСЕНДӘГЕ СҮЗЛӘРНЕҢ ТУЛЫ ИСЕМЛЕГЕ

**а) уң як**

А31. АНТЫМ (antym)
А30. ЭЙЕМКӘ (ejemkä)
А29. ИРӘНЕМ (iränem)
А28. ИР-АТКА (ir-atqa)
А27. АБАМКА (abamqa)
А26. ТУ ӘНИЕМКӘ (tu äniemkä)
А25. ТУТАКА (tutaqa)
А24. АМАМА (amama)
А23. КОЛКА (КУЛКА) (qolqa, qulqa)
А22. АС ТАКА (as taqa)
А21. ТӘСӘМИМӘ? ТӘСӘМЕМӘ? ТИСӘМЕМӘ? (täsдmimä? täsämemä? tisämemä? )
А20. АС АНАКА (as anaqa)
А19. РАЙА (raja)
А18. ӘТЕКӘМӘ-ИНӘМӘ (ätekämä-inämä)
А17. КОТ (КУТ) (qot, qut)
А16. АКЫЛ (aqyl)
А15. АТТАКАСКА (attaqasqa)
А14. КАНА (qana)
А13. АКЫЛ (aqyl)
А12. ӘТЕКӘМӘ-ИНӘМӘ (ätekämä-inämä)
А11. КОТ (КУТ) (qot, qut)
А10. АКЫЛ (aqyl)
А9. АТАКАСЫМА ТА (ataqasyma ta)
А8. МАМАКА ТА (mamaqa ta)
А7. КОЛКА (КУЛКА) (qolqa, qulqa)
А6. АНТА (anta)
А5. НӘТӘК (nätäk)
А4. ИЛКӘ (ilkä)

A3. АТТАКАСКА (attaqasqa)
A2. НИТӘ? НӘТӘ? НИ ТӘ? НӘ ТӘ? (nitä? nätä? ni tä? nä tä?)
A1. ИЛКӘ (ilkä)

**б) сул як**

B30. АДАМЫМА (adamyma)
B29. ТУ ӘНИЕМКӘ (tu äniemkä)
Б28. ӘС ӘНӘМ (äs änäm)
B27. ДИКӘМӘ ТӘ (dikämä tä)
B26. КАРАУЛ ЭЙЕМКӘ (daraul ejemkä)
B25. САДАКА НИМӘК (sadaqa nimäk)
B24. НИТӘРЕКӘ (nitärekä)
B23. БИНТЕМӘ (bintemä)
B22. ДИСБЕКӘМӘ (disbekämä)
B21. ИМ ЭЙЕМКӘ (im ejemkä)
B20. ӘЛ ӘСӘМӘ (äl äsämä)
B19. ТУ КӘМӘКӘ ТӘ? ТҮКӘМӘКӘ ТӘ? (tu kämäkätä tükamäkä tä?)
B18. ИР ЭЙЕМКӘ (ir ejemkä)
B17. САКАМА (saqama)
B16. ИРКӘ ТӘ (irkä tä)
B15. МАКА САРКА (maqa sarqa)
B14. ӘБЕТИ ТӘ (äbeti tä)
B13. ИРСӘ ИМӘК (irsä imäk)
B12. ИРЕКНЕ (irekne)
B11. ИРӘНЕМ (iränem)
B10. ДИРСӘ ИМӘК (dirsä imäk)
B9. ТҮКӘНӘКЕМӘ (tükänäkemä)
B8. ИММӘКӘ (immäkä)
B7. ИМАНЫМ (imanym)
B6. ИМНӘМӘ ЭЙЕ (imnämä eje)
B5. ДИРСӘ ИМӘК (dirsä imäk)
B4. БАКУРАМЫМА (baquramyma)
B3. ӘМӘКӘНЕМӘ (ämäkänemä)
B2. ИРКӘНӘКЕМӘ (irkänäkemä)
B1. ӘНИЕМӘ (äniemä)

## 13. ДИСБЕ ТУРЫНДА ӨСТӘМӘ ФИКЕРЛӘР

Менә без Фест дисбесендәге серле язуларны укып чыктык. Язуларның эчтәлегеннән күренгәнчә, бу юка балчык кисәге борынгы гыйбадәтханәдә корбан (ант), хәерсадака биргәндә һәм кайбер бүтән дини йолаларны башкарганда кулланылган булырга тиеш. Дисбене тотып

утырган кеше (ихтимал, хатын-кыз затындагы дин әһеле) аны әкрен генә ике куллап әйләндерә-әйләндерә, бармакларын рәсем-билгеләр өстеннән шудырып, дога сүзләрен әйтеп барган. Доганың эчтәлеге бик гади: корбан (ант), садака бирүче иң элек мифик ата-бабаларына, якын туганнарына, аллаларга мөрәҗәгать итә һәм шуның белән корбанның, садаканың кемнәргә багышланганын белдерә. Шул ук вакытта ул үлгәннәргә — оҗмах (райа), исәннәргә — кот, акыл тели. Болай караганда, язуның эчтәлеге тулысынча дини дип әйтергә була. Шуның белән бергә түгәрәк балчык кисәгендә санап кителгән исем-атамаларда Крит чоры төркиләренең тормыш-көнкүреше, дини карашлары, социаль катлаулары да чагыла.

Дисбедәге күпчелек рәсем-билгеләрнең төрки атамалары табылды дип әйтергә тулы нигез бар. Мәсәлән, 12 һәм 2 («калкан» белән «сугышчы») рәсемнәренең бергә АЛАБ сүзен белдерүе бернинди шик тудырмаска тиеш диясе килә. Шулай ук 7 рәсем ИМИ, 9 рәсем БАШЛЫК, 10 рәсем ИШКӘК, 12 рәсем КАЛКАН, 15 рәсем БАЛТА, 17 рәсем КАПКАЧ, 18 рәсем МӨГЕШ, 25 рәсем КӘМӘ, 27 рәсем ТУН, 30 рәсем КУЙ, 41 рәсем СӨЙӘК һ.б. билгеләрнең исемнәре дә, җисемнәре дә тулысынча бер-берсенә туры килә.

Дисбедә әлегә бик үк аңлашылып җитмәгән рәсем-билгеләр дә бар. Мәсәлән, 35, 36, 37, 42, 43, 44 рәсемнәрнең дөрес атамаларын тәкъдим итеп булмый. Төгәл атамасы билгеле булмаган, ләкин берничә мәртәбә кабатланган рәсем-билгеләрнең нинди авазны белдерүен чагыштыру юлы белән ачыкларга мөмкин. Ниндидер яфраклы агачнымы, ботакнымы сурәтләгән 35 рәсем-билге унбер мәртәбә кабатлана һәм һәр очракта *къ, к* тартыкларын чагылдыра. 36 рәсем-билге дә ниндидер агачнымы, үсемлекнеме сурәтли. Бу рәсем-билге дүрт мәртәбә кабатлана һәм һәр очракта *с* тартыгын белдерә. 42, 43, 44 рәсемнәр берәр мәртәбә генә очрый. Боларның нәрсә аңлатканы билгеле түгел. Бу очракта без атамасы билгеле булмаган рәсем-билгенең янында урнашкан һәм атамалары мәгълүм рәсемнәргә таянып фикер йөртәбез.

Мәсәлән, А25 шакмагында өч рәсем бар: беренче (27) рәсем **ТУН**, өченче (8) рәсем **КАЛПАК** дип атала. Уртадагы икенче (44) рәсемнең атамасы билгеле түгел. **ТУН** да, **КАЛПАК** та дисбенең ике ягында да еш кабатлана. Аларның нинди авазларны чагылдыруы билгеле. А25 шакмагындагы сүзнең беренче иҗеге ТУ, өченче иҗеге КА дип укыла. Уртада аңлаешсыз бер яисә берничә иҗек булырга тиеш. А27, А26 шакмакларындагы АБАМКА, ТУ ӘНИЕМ-

КӘ сүзләре туганлык терминнары рәтенә карыйлар. Димәк, А25 шакмагындагы сүз дә туганлык термины булырга тиеш. Билгесез 44 рәсем т тартыгын белдерсә, сүзне тулаем ТУ-Т-КА дип укырга була. Ул шулай ТУТАКА дип укыла да. Дөрес, бу сүзнең ТУ-ГАН-КА булуы ихтимал дигән фикер дә туарга мөмкин. Ләкин сүзне болай дип укысак, 44 рәсемнең **ГАН** яисә **КАН** дип аталуын исбатларга туры килер иде. Аннан соң, АБАМКА, ТУ ӘНИЕМКӘ сүзләреннән соң ТУГАНКА сүзе килә аламы? Гомумән, ТУГАН үзе «туганлык термины» була аламы? А27—А24 шакмакларындагы сүзләрнең урнашу тәртибенә игътибар итсәк, шул нәрсә күзгә ташлана: иң элек ир затындагы «туган» АБАМКА, аннан соң хатын-кыз затындагы «туганнар» санала. ТУ ӘНИЕМКӘ сүзеннән соң ТУГАН сүзен урнаштырсак, җөмләдә логик мәгънәсезлек барлыкка килер иде. Бит ТУГАН сүзенең җенес күрсәткече юк — ул кыз туган да, ир туган да булырга мөмкин.

Шулай итеп, 44 рәсем т тартыгын белдерә һәм А25 шакмагындагы сүз ТУ-ТА-КА дип укыла.

Сүз ясауда рәсем-билге атамаларының, нигездә, беренче авазлары һәм иҗекләре катнаша. Ләкин, шушы язылмаган кагыйдәгә капма-каршы буларак, 3, 26, 39 рәсем атамаларының соңгы иҗекләре кулланыла. 3 рәсем **МИңЛЕ**, 26 рәсем **ШӨШЛЕ** дип аталалар һәм алар *ле* иҗеген чагылдыралар. 39 рәсем **АЙР** дип аталды. Сүз ясауда **АЙР**ның соңгы *р* тартыгы катнаша. Күрәсең, Крит чоры төрки телдә дә исемнәре *л, р* тартыкларына башланган һәм рәсемдә чагылдырырга мөмкин булган әйберләр табылмаган. Шунлыктан әлеге тартыкларны рәсемле язуда күрсәтү шактый кыенлык тудырган. Моның өчен *л, р* тартыклары сүз азагында килә торган исемдәге әйберләрне сайларга туры килгән.

Дисбедәге рәсем-билгеләрне сайлауда тагын бер үзенчәлек күзгә ташлана. Бу үзенчәлек *къ, к* тартыкларына кагыла. Әйтелгәнчә, бу тартыклар 14 рәсем-билге ярдәмендә белдерелә. Ундүрт рәсем-билге атамасының уникесе калын *къ* тартыгын, икесе нечкә *к* тартыгын чагылдыра. Нечкә әйтелешле *кәмә* сүзендә генә *к* тартыгы сүз башында килә. 43 рәсем-билге нечкә әйтелешле *к* тартыгын белдерсә дә, аның төгәл атамасы билгеле түгел. Шулай итеп, монда тагын кызык хәл барлыкка килә. Димәк, дисбе иҗат ителгәндә атамасы нечкә *к* тартыгына башланган һәм рәсемдә чагылдырырга мөмкин булган әйберләр сайлау шулай ук кыенлык тудырган. Шуңа күрә сүздәге нечкә *к* тартыгын белдерү өчен исеме калын *къ* тартыгына башланган рәсем-билгеләрдән дә файдаланырга туры килгән.

Кайбер шакмаклардагы сүзләрнең төгәл әйтелешен ачыклап булмады. A21, A2, B19, B12 шакмакларындагы сүзләрнең дөрес формасы, B4 шакмагындагы сүзнең мәгънәсе билгеле түгел.

Хәзер дисбегә беркадәр формаль яктан күз төшереп алыйк. Ни өчен түгәрәк формада бу язулы балчык кисәге? Әйтелгәнчә, аны ике куллап тотып, бармак битләре белән капшап укуы җайлырак булгандыр, күрәсең. Шулай да төп сәбәп анда гына түгел. Түгәрәк эчендәге сызыклар спиральне хәтерләтә. Спираль ул — бөгәрләнгән җылан һәм кояш символы. Түгәрәкнең ике ягындагы сызыклар туры мәгънәсендә җыланга охшатып эшләнгән. Спираль эчендәге A1 һәм B1 шакмаклары очлайтып, җылан башы сыман итеп тәмамланган. Очлаеп торган «башлардагы» рәсемнәр күз сурәтен хәтерләтә.

Дисбенең уң ягындагы спираль 31 шакмакка, сул ягы 30 шакмакка бүленгән. Уң якта A18 шакмагында бергә әйтелә торган, димәк, шул ерак чорларда ук инде фразеологик формулага әйләнгән ӘТЕКӘМӘ-ИНӘМӘ сүзләре урнашкан. A12 шакмагында шул ук сүзләр яңадан кабатлана. Фразеологик формула булса да, ӘТЕКӘМӘ-ИНӘМӘне ике сүз дип исәпләргә туры килә. Дисбенең уң ягына, шулай итеп, 31 сүз түгел, 33 сүз сыйдырылган булып чыга. Без монда ТА-ТӘ теркәгечләрен, ТУ-ТҮ сыйфатларын исәпкә алмыйбыз. Кайбер сүзләр, гомумән, икешәр мәртәбә кабатлана. Мәсәлән, ИЛКӘ, КОДКА, АКЫЛ һ.б. Мондый кабатлау бары сүз исәбен арттыру өчен генә кирәк булгандыр дигән тәэсир туа.

Дисбенең уң ягын ике мәртәбә әйләндереп, андагы сүзләрне санап барсак, барлыгы 66 сүз барлыкка киләчәк. Дисбенең сул ягына 34 сүз сыйдырылган. 66 га 34 не кушсак, 100 булачак. Шушы уңайдан без бүгенге көндәге тәсбихны искә төшерәбез. Тәсбихтә 99 төймә була. Һәр 33 төймәдән соң «тәсбих анасы» куела. Тәсбихның эре төймәләр тезеп, чуклап ясалган башы (йөзенче «төймә») «тәсбих мулласы» дип атала. Тәсбих тартучы дога сүзләрен санап әйтә, ләкин «бер», «ике»... дип санап тормый, дога сүзен әйтү белән, бер төймәне шудырып кына куя. «Тәсбих анасы» һәм «тәсбих мулласы» аңа сан исәбен ялгыштырмаска ярдәм итә. ТӘСБИХ сүзенең ДИСБЕ атамасы да бар. Тәсбих гарәпчә, *дисбе* татарча диалекталь сүз исәпләнелә. Фест түгәрәге белән тәсбихның төп принциплары бер-берсенә тәңгәл. Шуңа күрә Фест язуын балчыктан ясалган беренче тәсбих (дисбе) дип тә әйтергә була. B22 шакмагындагы ДИСБЕКӘМӘ сүзе дә моның шулай икәнлеген раслый.

## Өченче бүлек

# КРИТ ЦИВИЛИЗАЦИЯСЕ ҺӘМ АТЛАНТИДА

### 1. БАШЛАНГЫЧ БЕЛЕШМӘ

Урта диңгездәге Крит утравында бик күптәннән бирле греклар яшәгән. Әле дә анда греклар яши. Борынгы Грецияне, борынгы грекларны дөньяда белмәгән кеше юктыр дисәк, ялгыш булмастыр кебек. Җырда-музыкада, сәнгатьтә, әдәбиятта, дин һәм мифологиядә, архитектурада, медицинада, философиядә, гомумән фәндә, җәмгыять тормышында, спортта — һәркайда, һәрнәрсәдә борынгы Греция, борынгы греклар...

«Европаның барлык сәнгате киң мәгънәсендә үзенең тамырлары белән грек традициясенә барып тоташа: Европа художниклары, язучылары, фикер ияләре ирешкән барлык нәрсәдә антик дөньяның зур булмаган бер халкы ирешкән искиткеч уңышларның тирән йогынтысы чагыла»,— дип яза инглиз галиме Дж. Чедуик греклар турында (Чед, 234 бит).

Борынгы заманда адәм баласы нәрсә генә уйлап тапмасын, нинди генә казанышка ирешмәсен, барысы да грекныкы, йә булмаса латинныкы дип исәпләнелә. Грек-латинныкы, димәк, «һинд-европаныкы», димәк, Европаныкы! Төп мәгънә менә шуңа кайтып кала. Инде ничәмә-ничә дистә еллар буена бөтен дөньяга менә шушы фикер таратыла, менә шушы караш көчләп тагыла. Рус культурасы, рус идеологиясе аша мондый караш безгә дә үтеп кергән. Без инде моңа күптән күнегеп беткәнбез. Кайчандыр безнең укымышлылар үзләрен гарәп-фарсының өйрәнчекләре дип һәм шул нигездә гомум ислам культурасының бер кыйпылчыгы дип фикер йөрткәннәр. Шуның белән алар үзләрен чиксез бәхетле санаганнар. Безнең бүгенге галимнәребез татар халкының грек-латин һәм Көнбатыш Европа культурасын үзләштерә алу дәрәҗәсенә ирешүенә чиксез куаныч белдерәләр.

XX гасырда тарих-археология өлкәсендә зур ачышлар ясалды. Зур ачышларның берсе Крит утравында була. 1900 елда инглиз галиме Артур Эванс Критат археологик казу эшләре башлап җибәрә. Утрауның төньягында, Кнос шәһәре янында, Юктас тавы итәгендә Эванс бик зур сарай калдыклары таба. Исәпсез-хисапсыз бүлмәләре, коридорлары, баскычлары, кабул итү заллары, җир асты зинданнары, су үткәрү торбалары, бассейннары, ваннала-

ры, канализациясе булган искиткеч сарай калдыкларын күреп Эванс таң кала. Залларда, бүлмәләрдә, амбарларда өем-өем савыт-саба, эш, сугыш кораллары, тормыш-көнкүреш кирәк-яраклары, төзәнү-бизәнү әйберләре табыла. Боларның барысы да таштан-балчыктан, җиздән-бакырдан, алтын-көмештән ясалган була. Стеналарда төрле төстәге буяулар белән ясалган бизәкләр, сюжетлы күренешләр, кеше, хайван, кош, балык сурәтләре була. Ике яисә өч катлы булган дип уйланылган бу сарайның гомуми мәйданы 16 мең квадрат метр тәшкил итә.


Эванс казып тапкан әлеге сарайны фәндә Кнос сарае дип тә, Лабиринт дип тә йөртәләр. Артур Эванс һәм аның шәкертләре Крит утравының Фест, Маллия, Гурния һ.б. шәһәрләрендә дә, Эгей диңгезенең башка утрауларында да күп кенә борынгы сарай калдыкларын казып чыгаралар.

Шул рәвешчә, борынгы Грециядә (утрауларда) борынгы греклардан да элегрәк яшәгән, моңарчы тарихта бөтенләй билгеле булмаган һәм ниндидер сәбәпләр аркасында юкка чыккан билгесез халыкның бөек культурасы мәгълүм була. Бу культураны фәнни әдәбиятта Крит (Миной) культурасы, Крит (Миной) цивилизациясе дип тә, Эгей (Миной) культурасы (цивилизациясе) дип тә атыйлар.

Крит культурасын Эванс өч чорга бүлеп карый. Иң борынгы чор б.э.к. 3000—2000 елларга, иң соңгы чоры 1600—1100 елларга туры килә. Димәк, Эванс тәкъдим иткәнчә, Крит цивилизациясенең иң әүвәлге чоры моннан биш мең еллар элек башланган була. Бу исә Крит культурасы борынгы дөньяның цивилизация үзәкләре Шумер һәм Мисыр белән бер үк вакытта диярлек барлыкка килгән һәм бер үк гасырларда яшәгән дигән сүз.

«Крит цивилизациясе грек цивилизациясеннән чагыштырмас дәрәҗәдә борынгырак. Хәтта соңгы бронза чорында да Крит культурасы классик Греция культурасыннан югарырак була. Легендаларда Афина шәһәренең Крит патшасы Миноска буйсынган булуы турында әйтелә. Анда грекларның котын алып торган башка халык яшәгән», ди Дж. Чедуик (Чед, 119, 120 битләр).

«Моңа кадәр камиллекнең идеалы исәпләнелгән һәм барлык буын художниклары өчен классик үрнәк булып хезмәт иткән грек сәнгате Урта диңгез буенда үзеннән 2000—1000 елларга элегрәк барлыкка килгән искиткеч дәрәҗәдәге бөек культураның дәвамы гына булып чыга» дип яза совет галиме И.А.Резанов (Ре, 134 бит).




Рәсем 6. Урта диңгез бассейнының көнчыгыш өлеше. Ярым түгәрәк эчендәге Фера (Санторин) утравында Атлантиданың үзәге һәм башкаласы булган дип уйланыла.

Кайчан һәм нилектән юкка чыккан соң Крит культурасы? Бу сорауга җавап эзләп без борынгы грек философы Платонга мөрәҗәгать итәбез.

## 2. ПЛАТОН ҺӘМ АТЛАНТИДА

Б.э.к. 427—357 елларда яшәгән грек философы Платон «Тимей» һәм «Крити» дип аталган диалогларында ниндидер серле утраудагы серле Атлантида дәүләте турында язып калдырган. Атлантида турындагы хикәяне иң элек Солон дигән гыйлем иясе Мисырда ишетеп кайткан. Мисыр гыйбадәтханәләрендәге дин әһелләре аңа борынгы язмаларда әйтелгән сүзләрне сөйләгәннәр. Солон үзе Платоннан ике йөз еллар элегрәк — б.э.к. 640—559 елларда яшәгән. Солон нәселендәге кешеләр аның гаҗәеп хикәясен буыннан-буынга тапшыра килгәннәр. Платон Солон нәселеннән булган. Платон диалоглары аша Атлантида турындагы хикәя бөтен дөньяга тарала.

Платонның әйтүенә караганда, Атлантида дәүләте Геракл баганалары, ягъни Гибралтар бугазы янындарак, Атлантик океанда булган. Аның территориясе Ливия

(Төньяк Африка) белән Кече Азия территориясеннән дә зуррак булган. Иҗтимагый үсеше, экономикасы һәм культурасы ягыннан Атлантида дөньяда иң алдынгы ил булган. Атлантидада көчле патшалар хакимлек иткән.

Атлантида дип аталган дәүләтнең башкаласы шул исемдәге утрауда урнашкан. Утраудагы үзән уртасында изге тау була. Тауда имеш, дөньядагы иң беренче кешеләр яшәгән. Ирле-хатынлы иң беренче кешеләрнең Клейто исемле кызлары була. Кыз үсеп буйга җиткәч, моның атасы-анасы үлеп китә. Ятимә кызга диңгез алласы Посейдон гашыйк була. Клейтоның Посейдоннан биш игезәк ир баласы туа. Диңгез алласы үзенең ун улын да тәрбияләп үстерә һәм утрауны унга бүлеп, балаларына бирә. Баш баласын диңгез алласы барлык уллары өстеннән хаким итеп куя.

Шул ук вакытта Посейдон үзәндәге тау тирәсен тәртипкә китерә. Моның өчен ул тауны су һәм җир бoҗралар белән әйләндереп ала. Җир (туфрак, таш, балчык) боҗра ике, су боҗрасы өч була. Шулай итеп, изге тау боҗралар уртасында торып кала. Таудан ике чишмә ага. Чишмәләрнең берсе салкын сулы, икенчесе кайнар сулы була.

Тау башында патша сарайлары, гыйбадәтханәләр төзелә. Тау уртасында Клейто белән Посейдонга багышланган һәм алтын койма белән әйләндереп алынган изге гыйбадәтханә була. Диңгез алласының үзенә генә багышланган гыйбадәтханә дә була. Әлеге гыйбадәтханә алтынкөмеш һәм җиз белән бизәлгән, түшәмнәре фил сөягеннән ясалган була. Аллага багышланган гыйбадәтханә залларында алтыннан коелган төрле сыннар, һәйкәлләр була. Шуларның берсендә диңгез алласы сурәтләнгән була, канатлы алты ат җигелгән арбада кулларына дилбегә тотып, алла үзе бара, аның тирә-ягында дельфиннарга атланган су кызлары йөзә...

Гыйбадәтханәнең тышкы ягында ун изге патша хатыннарының һәм алар нәселенең алтын сыннары утыра. Кая карама, алтын да көмеш, җиз һәм затлы әйберләр... Бу корылма кайсыдыр ягы белән, варварлар корылмасын хәтерләтә, ди грек философы (Пла, III, 555 бит).

Посейдонга багышланган гыйбадәтханә уртасында тагын орихалк (таш? металл?) багана була, баганага беренче патшалар сүзе — һәртөрле законнар, кагыйдәләр язылган була. Ил белән идарә иткәндә Атлантида патшалары һәрвакыт менә шушы алла сүзләренә туры китереп язылган закон һәм кагыйдәләргә таянып эш итәләр.

Биш-алты елга бер мәртәбә багана янына җыелып алар (ун патша) бөтен дәүләт күләмендәге хәлләрне тикшерәләр. Берәр патша нинди дә булса җинаять эшләсә, җыйнаулашып аны хөкем итәләр. Хөкем алдыннан якындагы болынга чыгып, анда иректә ашанып йөргән үгезне тотып алалар һәм аны язулы багана янында чалалар. Әлеге баганада закон кагыйдәләреннән тыш, законны бозган кешегә бәла-каза килүен теләгән каргыш сүзләре дә була. Үз кагыйдәләренә ярашлы рәвештә корбан биргәч һәм үгезнең барлык әгъзаларын яндыргач, патшалар бер савытка шәраб салып аны сыеклыйлар, һәркем шәрабка оешкан үгез каны сала. Канның калганын утка түгәләр. Язулы ташны бик яхшылап чистарталар. Шуннан соң савыттан һәркем алтын касә белән шәраб ала, шәрабның беразын утка корбан итә. Шул рәвешчә, патшалар бары тик язулы баганадагы закон нигезендә генә хөкем итәрбез дип ант эчәләр.

«Үзләре өчен, ата-бабаларының барлык нәсел-нәсәбе өчен шундый ант сүзләре әйтеп, аларның һәркайсы шәрабны эчә дә, касәне аллага багышланган гыйбадәтханәнең тиешле урынына илтеп куя», ди Платон (Пла, III, 559 бит).

### 3. АТЛАНТИДАНЫ ЭЗЛӘҮ

Атлантида булганмы, әллә булмаганмы? Булса, кайда булган? Кайчан булган? Ике мең елдан артык инде фикер ияләре менә шул хакта бәхәс алып баралар. Шушы вакыт эчендә Атлантидага кагылышлы 25 мең том китап язылган. Ул китапларның кайберсенең калынлыгы 500 биттән артып китә икән.

Атлантида утравы, Платон әйткәнчә, һәлакәтле бер көн һәм бер төн эчендә диңгезгә батып юкка чыккан. Бу хәл, имеш, Солон заманыннан алып исәпләгәндә, 9000 еллар элек булган. Бүгенге чордан алып исәпләгәндә бу моннан 12 мең еллар чамасы элек булган булып чыга. Ләкин, тарихтан билгеле булганча, моннан 12 мең еллар элек дөньяда Атлантида кешеләре ирешкән дәрәҗәдәге бер генә халык та булмый.

XX гасыр башында Артур Эвансның Крит утравында ясаган ачышлары Атлантида мәсьәләсенә яңача карарга мөмкинлек бирә. Тикшерә торгач, Урта диңгезнең көнчыгыш өлешендә урнашкан утрауларның борын-борыннан геологик яктан тынгысыз һәм тотрыксыз булулары ачыклана. Крит утравындагы һәм Критка якын урнашкан башка утрауларда җир тетрәүләр дә, вулкан атылулар да,

«җир йотулар» да була һәм булганда да бик көчле була икән.

Бүгенге көн галимнәре Эгей диңгезе бассейнында берничә мәртәбә көчле җир тетрәү булуын һәм шуның нәтиҗәсендә борынгы шәһәрләрдә сарайлар җимерелүен, җимерелгәннән соң яңадан торгызылуын белгәннәр. Мәсәлән, б.э.к. 1800—1700 елларда шундый көчле җир тетрәү була. Кнос, Фест, Маллия шәһәрләрендәге сарайлар һәм башка утраулардагы күп кенә биналар шул чорда җимерелгән. Ачлык һәм мал-туар кырылу нәтиҗәсендә Крит утравының өч мәртәбә бушап калуы, элекке халыклар урынына утрауга бүтән халыклар килеп утыруы турында Геродот та яза (Г, VII, 171). Борынгы Греция территориясендә грекларга кадәр ниндидер башка халыклар яшәве һәм аларның каядыр күченеп китүләре турындагы хәбәрләрне бүтән авторларның әсәрләреннән дә табарга була. Шул ук Платонның «Кратил» дип аталган диалогында: «Элладада яшәгән беренче кешеләр бүгенге көндә дә күп кенә варварлар хөрмәт иткән аллаларны гына: Кояшны, Айны, Җирне, Йолдызларны һәм Күкне генә хөрмәт иткәннәр», дип яза (Пла, I, 434 бит). Икенче бер грек философы Плутарх та Элладада (Грециядә) грекларга кадәр бүтән халыклар яшәве турында әйтә. «Әле булса (грек телендә) Эллададан күченгән халыклар белән бергә куылып киткән башка төрле бик күп сүзләр сакланып килә һәм алар, чит халыклар арасындагы бүтән ил кешеләре кебек, (грек телендә) яши бирәләр», ди Плутарх (Плу, I, 61).

Б.э.к. XV гасырда Урта диңгезнең көнчыгышында, Крит утравыннан төньяктарак, Санторин утравында тагын бер җир тетрәү һәм көчле вулкан атылу була. Менә шул вакытта Крит цивилизациясе юкка чыга да инде. «Б.э.к. 1450-1400 еллар арасында күпмедер вакыт эчендә Крит утравындагы барлык шәһәрләр, шул исәптән, Кнос шәһәре дә ут тарафыннан юк ителә» ди инглиз галиме Дж. Томсон (Том, 372 бит). «Д.Нинкович һәм Б.Хейзен исәпләвенчә, Миной чоры Крит цивилизациясенең җимерелүе, Мисыр хронологиясенә ярашлы рәвештә, б.э.к. 1450— 1375 елларда була», ди И.А.Резанов (Ре, 108 бит). «Стихия бәла-казасы Миной цивилизациясен юкка чыгарган вакытта Кнос дәүләте үз куәтенең иң югары дәрәҗәсенә ирешкән була», ди А.А.Молчанов (Мол, 18 бит). «Күп кенә археологлар, геологлар, океанологлар фикеренчә, Эгей диңгезендә б.э.к. II меӊ еллыкның урталарында булган Санторин вулканы атылуы нәтиҗәсендә, Урта диңгездәге бөек мәмләкәт юкка чыга; бу

мәмләкәтнең үзәге Крит утравында — Европаның иң борынгы цивилизация бишегендә була», ди А.Кондратов (Конд, 114 бит).

Вулкан атылуның энергиясен билгеле бер куәттәге атом бомбасы энергиясе эквивалентына тигезләп исәплиләр. П.Хейдервари методы нигезендә, бер атом бомбасының энергиясе $8{,}4.10^{14}$ дж. тәшкил итә (Рев, 77 бит). 1883 елда Индонезиядә, Кракатау утравында атылган вулканның атом бомбасы эквиваленты 20.000 берәмлеккә тигез. 1815 елда шул ук Индонезиядә, Сумбава утравында атылган Тамбора вулканының эквиваленты 200.000 берәмлек тәшкил итә, ягъни бу әлеге вулкан атканда җир астыннан чыга торган энергия ике йөз мең (!) атом бомбасы шартлаганда барлыкка килә торган энергиягә тигез дигән сүз.

Крит дәүләтен юкка чыгарган Санторин вулканының атылу энергиясе Тамбора вулканы энергиясеннән көчлерәк булган дип уйланыла. «Шул рәвешчә, б.э.к. XV гасырда булган Санторин вулканы иң зур геологик һәлакәтләрнең берсе исәпләнелә», дип яза Резанов (Ре, 79 бит).

Моның шулай икәнлеген күрсәтү өчен бер-ике мисал китерү дә җитәр дип уйлыйм. Мәсәлән, вулкан атканда җир астыннан чыга торган көл 50 километрга кадәр күтәрелә ала икән. Санторин вулканының көле вулкан атылган үзәктән мең километр ераклыкка таралган. Бүгенге көн галимнәре диңгез төбеннән алган грунт үрнәкләре күрсәткәнчә, Санторин утравыннан 130 километр көньяк-көнчыгышта диңгез төбендә 212 сантиметр калынлыктагы көл катламы утырып калган. Крит утравыннан төньяк-көнчыгышта, 212 сантиметр ноктасыннан көньяк-көнбатыш ноктада диңгез төбендәге көл катламы 78 сантиметр булган.

Вулкан атылыр алдыннан Санторин утравында бик зур шәһәр була. Бүгенге көндә утрауда археологик казулар башкарыла. Монда да Крит утравындагы кебек сарай калдыклары табыла. Санторинда Грециянең Афина шәһәре университеты галимнәре бер, ике, өч катлы биналар, Миной чоры һөнәрчеләре ясаган бик күп әйберләр, йорт кирәк-яраклары табалар. Шәһәрдә 30 мең чамасы кеше яшәгән дип уйланыла. Шәһәрнең төньяк өлеше вулкан атылу нәтиҗәсендә юкка чыга, көньяк өлешен көл-туфрак күмеп китә. Бүгенге көндә Санторин утравының вулкан атканнан соң торып калган вак кисәкләрендә — Тира, Тирасия, Аспрониси утрауларында вулкан көленең — тефраның калынлыгы 30—40 метрга җитә.

Санторин утравында вулкан көле астында күмелеп калган борынгы шәһәрдә мәет калдыклары табылмый. Бу исә кешеләрнең вулкан атылып шәһәр җимерелгәнче качып котылулары турында сөйли.

Б.э.к. XV гасырда көчле вулкан атылу нәтиҗәсендә юкка чыккан Крит цивилизациясен Платон тасвирлаган Антлантида булырга тиеш дип исәплиләр. Дөрес, Платон әйткән нәрсәләр белән Крит культурасы фактлары һәр очракта да туры килеп бетми. Мәсәлән, Атлантиданың юкка чыгуын Платон Солонга кадәр 9000 еллар элек булган ди. Ләкин аның яисә башкаларның бер «нуль»гә ялгышкан булулары да ихтимал. 9000 санын 900 дән исәпләсәк, чама белән Санторин вулканы аткан еллар барлыкка киләчәк.

## 4. ТӨРКИ-ГРЕК УРТАКЛЫКЛАР. ТЕЛ

Рәсми тарихтан билгеле булганча, Крит утравында һәм Эгей диңгезенең бүтән утрауларында госманлы-төрекләрдән башка бернинди төрки халыклар яшәмәгән. Госманлы-төрекләр исә Крит утравын яңарак чорларда, ягъни XVII гасырда яулап алганнар. Төрекләргә кадәр утрауда төрле халыклар хуҗа булган. Тарихта исеме билгеле иң беренче һәм иң борынгы хуҗалар — ахей яки ахай кабиләләре. Ахайлар утрауга Балкан ярымутравыннан басып кергәннәр дип уйланыла. Ахайлар борынгы грек кабиләләренең иң әүвәлгесе исәпләнелә.

Фест дисбесенең төркилеге рәсми тарихны шактый уңайсыз хәлдә калдыра. Каян? Ничек? Нишләп алай? Булырга мөмкинме мондый нәрсә? Бәлки, дисбе Крит утравына берәр ничек читтән килеп эләккәндер? Бит элек тә илләр белән илләр арасында, халыклар белән халыклар арасында алыш-биреш һәм һәртөрле элемтәләр булган. Сәүдә юлы белән яисә күршеләр белән сугыш нәтиҗәсендә бер илдән икенче илгә, бер шәһәрдән икенче шәһәргә төрле ят нәрсәләр китерелгән. Шул рәвешчә, ерак һиндстан, Әфганстан якларыннан кече Азиягә, Урта диңгез бассейны утрауларына кыйммәтле ташлар килгән, һиндстан, Әфганстан, Иран җирләренә, киресенчә, Көнбатыштагы әйберләр барып җиткән. Чыннан да, кайберәүләр Фест дисбесе Крит утравына каяндыр читтән китерелгән булырга тиеш дигән фикерләр әйткәннәр. Тик шулай да күпчелек дисбе утрауның үзендә иҗат ителгән дигән фикерне куәтли.

Фест язуы барлык борынгы язулар арасында үзенә башка урын биләп тора. Мондый төрдәге дисбе дә, мондый төрдәге язу да борынгы цивилизация илләренең берсендә

дә табылмаган. Фест язуының, әйтерсең, элгәресе дә, дәвамы да юк. Ул, әйтерсең күктән төшкән. Шуңа күрә дә бу серле язуга карата игътибарның кимегәне юк.

Әгәр дә мәгәр дисбе күктән төшмичә, нинди дә булса реаль халыкның реаль телен, культурасын чагылдыра икән, ул билгесез халыкның тел һәм культура үзенчәлекләре утрауга үзеннән соң хуҗа булып калган икенче халык телендә һәм культурасында сакланырга мөмкин ләбаса! Мөмкин генә түгел, тиеш. Бу очракта без утрауның билгесез дип исәпләнелгән халкыннан соң монда хуҗа булып калган грекларга һәм грек теленә мөрәҗәгать итәбез.

Югарыда без Крит цивилизациясе белән Платон тасвирлаган Атлантида арасында уртаклык бар дигән карашка яклау белдердек. Атлантиданы җир йоткан, Крит цивилизациясе көчле вулкан атылу нәтиҗәсендә юкка чыккан. Утраулардагы халыкның күпмедер өлеше, билгеле, һәлак булган, ләкин күпмедер өлеше, качып котылган. Бу хакта сөйли торган ышанычлы фактлар да бар.

Һәлакәткә юлыккан утраудагы (дөресрәге, утраулардагы) кешеләр качып китәргә мөмкин булган барлык якларга качып киткәннәр. Мәсәлән, Эгей диңгезенең төньягында яшәүчеләр төньякка — хәзерге Грециягә, гомумән, Балкан ярымутравына, көньяк утрауларда яшәүчеләр — көньякка, Африка илләренә юл тотканнар. Шулай ук көнбатышка, көнчыгышка качучылар да җитәрлек булгандыр.

Крит-Миной дәүләте юкка чыкканнан соң Урта диңгез буе илләренең культура үсеше кинәт туктап кала. Археологлар Сицилия һәм Липар утрауларындагы югары культураның б.э.к. XIII гасыр урталарында үсүдән туктап калуына игътибар иткәннәр. Бу утраулар Крит дәүләтенең колонияләре исәпләнелгән. Дәүләт үзәгенең җимерелүе көнбатыштагы утрауларның культура үсешенә кире йогынты ясаган. Урта диңгездән ераграк урнашкан төбәкләрдә киресенчә, культура бик нык үсә башлаган. Чит җирләрдәге мәдәниятне үстерүдә Крит-Атлантида кешеләренең өлеше чиксез зур була. Мәсәлән, Крит цивилизациясе җимерелгәннән соң Кипр утравында күтәрелеш чоры башлана. Хәзерге Греция территориясендә кинәт Микена шәһәре көчәеп китә. «Микена Эгей дөньясының политика һәм культура үзәгенә әверелә» (Том, 372 бит).

Грек мифларында туфаннан котылган бердәнбер кешеләр Девкалион һәм Пирра дип атала. Тугыз көн буена корабта йөзеп барганнан соң алар Парнас тавына килеп тукталалар. Девкалион Фессалия өлкәсендә Фтия дигән шәһәр салдыра һәм аның беренче патшасы була. Девка-

лион чоры туфанын кайбер галимнәр б.э.к. 1430 елда булган дип исәплиләр. Грек мифларында Девкалион һәм Пирра грек халкының нәсел башы — изге атасы һәм изге анасы исәпләнелә. Крит кешеләренең материкка — хәзерге Грециягә күченеп китүләре Кадм турындагы мифларда да чагыла. Кадм, Грециягә күченгәч, Беотия дигән җирдә Фива шәһәре салдыра. Спартаның дәүләт төзелешендәге яңалыклар Криттан күчереп алынган, ди Геродот (Г, I, 65). Грекларның күп кенә аллалары, мифик геройлары, гомумән, Критта «туганнар».

Шулай итеп, грек мифларында әйтелгәнчә һәм грек язучылары раслаганча, борынгы грекларның беренче шәһәрләрен Криттан күченеп килгән кешеләр салган һәм аларның беренче дәүләтләрен дә алар оештырганнар. Шулай ук грек дине дә Крит кешеләренең дине тәэсирендә көчәеп киткән.

Әлеге фикерләрне тел фактлары белән дә исбатлап булмый микән? Без инде югарыда грек сүзләрендәге төрки элементлар белән беркадәр танышып киттек. Хәзер бүтән төрле мисалларга мөрәҗәгать итеп карыйк.

**Алебастр** сүзен бүген белмәгән кеше юктыр дисәк, һич тә ялгыш булмас. Төзелештә еш кулланыла торган үзле ак балчыкка (гипска) *алебастр* диләр. Бу грек сүзе һәм аның грекча формасы — *алабастр*. Бу катлаулы сүзне *алаб астр* дип икегә бүләбез. *Алаб*ның кемлеге безгә мәгълүм. *Алаб* ул — «көчле», «батыр». Сүзнең *астр* өлешен *ас тр* рәвешендә таркатабыз һәм *ас тар* дип тулыландырабыз. *Ас* иҗекләрен уңай мәгънәдәге сыйфат дип тә, татарча «аскы» дип тә аңларга була. *Тар* иҗекләре исә «таш» дигәнгә туры килә. Тарның «таш»лыгы татарча *кантар*, латинча *алтар* сүзләрендә күренә. Бүгенге татар телендә *астар* — кием эчлеге. Шул ук вакытта ул — нәрсәне дә булса ныгыту, беркетү өчен аскы якка куела торган әйбер (ТТАС, I, 78 бит). Кырым-татар телендә *астар* — русча «грунтовка» (Рад, I, 551). Кырым-татар телендә *астар*ның яисә грекча формадагы алабастарның турыдан-туры төзелешкә бәйле мәгънәсе сакланган.

**Анатомия** — бүгенге медицина термины. Грекча формасы *анатоме*. Мәгънәсе: кисәкләү, һәр әгъзаны аерым кисеп, аерып алу, ярып карау. Сүзлектә *анатомия*нең, өстә яткан бүгенге мәгънәсе теркәлгән. Әлеге сүзне *ана тума* дип икегә бүлсәк, татарча таныш сүзләр барлыкка киләчәк. Бу сүз татар телендә *анадан тума* рәвешендә кулланыла. Татарстанның Нократ сөйләшендә шул ук сүзнең *ана-тума* формасы да бар. Медицинада *анатомия*, билгеле булганча, *ана-тума, анадан-тума* кешеләргә кагыла да инде.

**Басилевс (басилей).** Грекча патшаны шулай дип атаганнар. Сүзнең тулырак мәгънәсе (Гомерда): 1. а) халык яисә кабилә башлыгы; б) өлкән яшьтәге баш кешеләрнең берсе, өлкәннәр киңәшендә — баш кеше; утар яисә йорт хуҗасы. 2. Монарх, хаким, патша (Кос, 229 бит). Сүзне *бас-ил-ев* рәвешендә берничә кисәккә бүләбез. *Бас* иҗекләрен татарча «баш», русча «голова, главный» дип аңлыйбыз. *Ил-ев* иҗекләрен татарча *ил* һәм *эү (өй)* дип беләбез. Ахыргы *с* тартыгы грек теле кушымчасы, артык аваз. Сүзне *басилей* рәвешендә тикшерсәк, артык *с* тартыгы үзеннән-үзе төшеп кала. *Эй* безгә таныш. Өй мәгънәсендәге *эй* дә, *эү* дә татар телендә әле дә кулланыла. Сүзнең грек телендәге мәгънәләреннән күренгәнчә, *басилей-басилевс*ны ил һәм өй (йорт) башы, хуҗасы, хакиме дип аңларга була. Дөньядагы барлык патшаларның өй һәм ил хуҗасы булуларын исбат итеп торасы юк. Аерым-аерым алып караганда *бас* та, *ил* дә, *эй* һәм *эү* дә, әлбәттә, төрки сүзләр. Тик менә аларның ялгану тәртибе генә төрки түгел. Монысына без гаҗәпләнмибез дә, чөнки грек теле төрки телләргә карамый лабаса. Грек теле ул «һинд-европа» телләренең иң борынгысы һәм иң дәрәҗәлесе!

**Илот**. Борынгы грек дәүләтләренең берсе Спартада колларны шулай дип атаганнар. Ләкин *илот* аерым кеше карамагындагы гадәти кол түгел. Спартада эшкәртелә торган җир аерым гаиләләр төркеменә тигез итеп бүленеп бирелә торган булган. Менә шул җирдә эшләүче колларны *илот* дип атаганнар, ягъни *илот* берничә гаиләнең уртак колы булган (ВИ, II, 35 бит).

Сүзне *ил* һәм *от* өлешләренә бүләбез. Грек телендәге *о* сузыгын татарча *ә* дип беләбез. Моңа әле безнең мисаллар булыр, хәзергә шуны гына әйтергә мөмкин: *ил* сүзе нечкә әйтелештә, димәк, *илот* та төрки телдә нечкә әйтелештә яңгыраган. Әле генә әйткәнчә, *илот*лар аерым гаиләләр төркеменнән гыйбарәт оешманың — илнең коллары булганнар. Теоретик яктан *илот* бары «ил улы» гына була ала. Бу очракта ил улы — ил колы, ил кешесе дигәнне белдерә, ләкин ил хуҗасы түгел, әлбәттә.

Татарда *иләт* дигән сүз бар. «Ил — иләте белән, бай келәте белән» дигән мәкальдә (Мә, № 4928) *иләт*нең, турыдан-туры илгә мөнәсәбәтле булуы чагыла. Шулай итеп, грек телендә *илот* рәвешендә сакланып калган сүзнең әүвәлге әйтелеше *иләт* булган дип әйтә алабыз. Бүгенге татар телендә *иләт* сүзе актив түгел. Татарстанда *Илләт* елгасы бар (Гар, 49). Казаннан 60 километр ераклыкта *Илләт* урманы булуы да мәгълүм. Монгол яулары чорында безнең якларга килеп чыккан Рубрук:

«Паскатирларга якын җирләрдә иллаклар яши; иллак шул ук Блак дигән сүз», ди (Руб, 123 бит). Рубрук әйткән «паскатир»ны *башкорт* дип, *Блак*ны Болгар дип уйласак, *иллак*ны *илләт* яисә *иләт* дип аңларга була. Димәк, Рубрук заманында болгарларның күпмедер өлеше *иләт*ләр (*илләт*ләр) булган һәм XIII гасырда Идел буенда болгарлар арасында да, ерак Спартадагы кебек, *илот*-ка тиң хокуксызлар яшәгән дип уйларга тулы нигез бар.

**История**. Бүгенге көндә киң таралган бу сүзне термин буларак беренче мәртәбә «тарих атасы» Геродот кулланa. Аның тугыз китаптан торган атаклы хезмәте «История» дип атала. *История* грек теленең *ио* диалекты сүзе һәм аның әүвәлге мәгънәсе тикшерү (русча исследование) икән. Ләкин аның сведения, знание; сообщения, повествование дигән мәгънәләре дә бар (Дво, 477 бит). Күрәсез, *история* терминының төгәл мәгънәсе әлегәчә табылмаган. Тикшерү, мәгълүмат, хәбәр, хикәя кебек мәгънәләр, историянең бүгенге эчтәлегеннән чыгып кына тәкъдим ителәдер кебек. Әйтик, анатомия сүзен «кискәләү» дип аңлаткандагы кебек.

Сүзнең әүвәлге мәгънәсе татар телендә саклана. *История* сүзендәге *о* сузыгын *ә* дип белсәк, бу *истәриә* булачак. Бу сүзнең *истә* өлеше безгә бик яхшы таныш. *Истәриә*не *истә-лек* дип үзгәртсәк, монда бернинди аңлатма кирәк булмас иде. «Тарих» яисә «история» шул ук истәлек ләбаса инде. *История* сүзенең *истә* өлеше саф төрки булса да, бүгенге төрки телләрдә *риә* дигән кушымча юк шикелле. Шулай да, чынлап торып җыласаң, сукыр күздән дә яшь чыга дигәндәй, бүгенге татар сүзләрендә дә *-риә* кушымчаларын табарга була. Мәсәлән, *хөр, хөрлек* сүзләренең *хөр-риәт* формасы бар. *Хөрриәт*-нең элегрәк *хөрриә* формасы булгандырмы-юктырмы, әйтүе кыенрак. Ләкин *хөрриә* сүзен аерым кешегә кагылышлы хөрлек дип, *хөрриәт* сүзен барлык кешеләргә кагылышлы хөрлек дип аңласак, күрәсең, элегрәк *хөрриә* сүзе дә булгандыр дип фикер йөртергә була.

Шумер телендә *«Аллария»* дигән җыр булган. Галимнәр моның төгәл мәгънәсен белмиләр. Америка шумерологы С. Н. Крамер, мәсәлән, *аллари* сүзен тәрҗемә итмичә генә «шатлык җыры» дип атый (Кра, 245 бит). Әлеге җыр исемендәге *алла* безгә яхшы таныш «алламны белдерсә, *риә*, гадиләштереп әйткәндә, «улы» булачак. Хәзергечә бу, әлбәттә, кушымча. Шуны да әйтергә кирәк, бүгенге татарлар арасында «Аллария» дигән җыр әле дә исән! 1949 елда Татарстанның Азнакай районы Карамалы авылында «Аллария-ләрия» дигән җыр тек-

сты язып алынган (Тат, 90, 91, 502 битләр). Халыкта «Аллари, аллари! Аллари, Камәр әби!» дип башланган такмак җыры да бар.

Шул рәвешчә, бик борынгы төрки телдә *истәриә* сүзе булган һәм ул хәзергечә истәлекне белдергән дип әйтә алабыз.

**Кайно** грек телендә үтерү, үтермәк дигәнне аңлата. Бу сүзнең **Катакайна** дигән формасы да булган (Кос, 857 бит). Бүгенге татар телендә *кыйна, каты, кыйна* турыдан-туры «үтерү»не белдерми, ләкин *кыйнау* һәм *каты кыйнау* нәтиҗәсендә кемне дә булса үтереп булганлыгы үзеннән-үзе аңлашылып тора.

**Каламос** грек телендә камыш һәм камыштан ясалган язу коралын аңлаткан (Кос, 929 бит). Татар телендә «камыш»ның каләм дигәне юк. Язу коралы буларак каләм исә элегрәк киң кулланылган. Әле дә бу сүз телдән төшеп калмаган. Сөйләм телендә *каләм, камыш каләм, каурый каләм* формалары бар. *Каләм* бездә гарәп сүзе исәпләнелә. Болай булгач, *каләм*не гарәпләр греклардан алганнар, без гарәпләрдән алганбыз булып чыга. Традицион логика шуны таләп итә. Ләкин Урта диңгез бассейны илләрендә грекларга кадәр үк төркиләр яшәгән дигән фикерне дөрес дип исәпләсәк, мондый логиканы башаяк әйләндереп куярга туры килә.

**Орга** грек телендә «изгеләштерелгән җир бүлемтеге» (священный участок земли) дигәнне белдерә (Том, 110 бит). Сүзне иҗек методы нигезендә *ор га* дип таркатабыз, *ор*ны *ар* дип аңлыйбыз. Сүзнең төзелеше турында сөйләгәндә без мондый мисал белән очраштык инде. *Ар га* яисә *ар ка* ул чыннан да «изге җир» дигәнгә туры килә.

**Пурой** грекча «бодай» дигәнне белдерә (Бла, 70 бит). *Пурой*ның, татарчасы — *борай. Борай* исә бодай сыман бөртекле ашлыкларның бер төре. Элегрәк борай татарларда иң затлы ашлыклардан исәпләнелгән.

**Фила** сүзе борынгы Грециянең бер өлкәсе Аттикада «кабилә» дигәнне белдергән (СИС, 733 бит). Татарча *биләү, билә-мә* сүзләрендә *Билә (Фила)* сүзенең «кабилә»леге чагыла. *Биләү* фигылен *билә*нең нинди дә булса эшхәрәкәте дип, *билә-мә*не «биләнең җире» дип аңлыйбыз. *Билә* иҗекләре кабилә сүзендә дә бар. Бу очракта «җир» яисә «ана» мәгънәсендәге *ка* иҗеге сүз башында килә. Моны шул ук биләмә сүзенең төркигә кире тәртиптәге формасы дип тә уйларга була.

**Хитон**. Җитен тукымадан тегелгән һәм билбау белән бәйләп куела торган эчке күлмәкне борынгы греклар шулай дип атаганнар. Геродотның әйтүенә караганда, бу

сүзне греклар карлардан (кар кешеләреннән) алганнар (Г, Ү, 87, 88). *Хитон*ны *хи тон*, ягъни озын *тун* (кием) дип тә аңларга була. Шулай да *тон* иҗекләре монда без белгән *тун* сүзенә тәңгәл түгел, ахрысы. Татар теле диалектларында *китән* дигән сүз бар. Сүзнең мәгънәсе «киндер тукыма» дигәнгә туры килә. Грекларның *хито*ны шул *китән* булса кирәк.

**Дәфнә.** Татар телендә лавр агачы шулай дип атала. Безнең якта лавр үсми. Лавр Монголия һәм Алтай якларында да үсми һәм үсмәгән. Күрәсең, бу да әлеге дә баягы гарәп-фарсыдан алынгандыр дип уйларга гына кала. Ләкин, ни хикмәттер, *дәфнә* гарәп телендә дә, фарсы телендә дә юк икән. Шул ук вакытта *daphne (дафне, дафна)* латин телендә лавр дигәнне аңлата икән. Латин теленә бу сүз гректан алынган дип исәпләнелә (Дво, 286 бит). Татар теленә, күрәсең, гректан алынгандыр инде. Әллә киресенчәме соң?

## 5. ТӨРКИ-ГРЕК УРТАКЛЫКЛАР. АЛЛА ИСЕМНӘРЕ

**Аполлон.** Борынгы грекларның иң атаклы аллаларыннан берсе. Зевс белән Летоның улы. Кояш алласы Аполлонга табыну грекларга Кече Азиядән килгән булырга тиеш дип уйланыла, чөнки Троя сугышы вакытында Аполлон грекларны түгел, Троя кешеләрен яклый. Аполлонга багышланган гыйбадәтханәләр Кече Азиядә урнашкан булган. Сүзне *Ап олло(н)* дип таркатабыз. *О* сузыкларын *а* дип укысак, безгә бик таныш *алла* сүзе барлыкка киләчәк. *Ап* иҗекләрен уңай сыйфат белдерә дип исәплибез. *Алабастр* дигәндәге кебек.

**Афина.** Борынгы грекларның иң дәрәҗәле алиһәләре. Иң әүвәл борынгы Микена алиһәсе, соңыннан барлык грекларның уртак алиһәсе булган. Зевсның кызы, Күк алиһәсе. Сүзне *Аф ина* дип таркатабыз. *Аф* иҗекләрен *аб*ның яисә *ап*ның *ф* варианты дип карарга була. Шул ук вакытта *аф*ның, тулырак варианты *наф* яки *нәф* булган булырга да мөмкин. Борынгы мисыр телендә уңай сыйфат буларак *наф* һәм *нәф* иҗекләре еш кабатлана. *Наф* һәм *нәф* иҗекләре татар телендә дә еш кына исемнәр, сүзләр ясауда катнаша. Афина сүзендәге *ина* яки *ины* иҗекләрен төрки *инә* дип беләбез. Әйтергә кирәк, борынгы грекларның Афина алиһәләре исемендә генә түгел, башка күп кенә алиһәләренең һәм алиһә булмаган хатын-кызларының исемнәре азагында *ина-ины, ана-она, апа-опа* иҗекләрен очратырга була. Мәсәлән, *Асина, Эгина, Гермиона, Гесиона, Диона* һ.б. *Инә-имә* иҗекләре бүген-

ге татар хатын-кыз исемнәре ясауда да катнашалар. Мәсәлән, *Әминә, Дәминә, Сәкинә, Галимә, Сәлимә* һ.б.

**Зевс.** Грекларның иң бөек аллалары, башка барлык аллаларның һәм кешеләрнең атасы. Крон белән Рея улы. Анасы Рея Зевсны, имеш, Крит утравында тапкан. Зевс белән Гераның бер улы *Гефест* дип атала. Ир затындагы алла бары Ата улы гына була ала, ягъни *Гефест*ның *Зевс* улы булуы аның исемендә чагылырга тиеш. *Зевс* белән *Гефест* сүзләрен янәшә куеп карасак, угыл-алланың исемендә *т* тартыгының артык икәнлеген күребез. Ләкин, чынлыкта, бу артык *т* түгел, бәлки «улы» мәгънәсен өстәүче тартык. *Зевс* сүзен *Зефес* дип төзәтәбез, *Гефес* белән *Зефесны* янәшә куеп карыйбыз. *Гефестның Ифест* варианты да бар. Бер үк алла исеменең ике төрле язылышы монда тагын өченче вариант булуы мөмкинлеге турында сөйли. Чөнки башка телдә бүтәнчәрәк әйтелгән сүзне күчереп алып, үзенчә үзләштергәндә генә төрлечә әйтелеш барлыкка килергә мөмкин. Кыскасы, грек телендә *Гефест-Ифест* һәм *Зефес (Зевс)* рәвешләрендә әйтеләә торган сүзнең оригиналы башкачарак булган. Менә шул оригиналдагы форманы грек теле ярдәмендә дөрес һәм төгәл итеп әйтә алмаган өчен дә төрле вариантлар барлыкка килгән дә инде. *Гефест-Зефес* сүзләренең төрки оригиналында сүз башында *җ* яисә *й* авазы ишетелгәндер дип әйтә алабыз. Ни өчен дигәндә, грек телендә *җ* тартыгы булмаган.

Төрки мифларда Нух пәйгамбәрнең туфаннан исән калган бер улы *Йәфәс* дип атала. Төркиләр һәм тагын кайбер башка халыклар Йәфәс токымы исәпләнелә. Грекларның Зевс дигән аллалары, чынлыкта, *Йәфәс* яисә әүвәлгерәк вариантта *Җәфәс* булып чыга. Библия традициясе нигезендә *Йәфәс* сүзен русча һәр очракта Япет дип язалар. Библиядә бу исем *Иафет* дип атала. Грек мифларында *Йапет* — титан, ягъни Зевсның атасы Кронның ир туганы. Шулай итеп, грек традициясендә *Йәфәс (Зевс)* белән *Йапет* — һәркайсы аерым-аерым алла икән. Шул ук вакытта Кронның бер туганының *Йапет* булуы Зевсның *Йәфәс* булуы ихтималына өстәмә дәлил хезмәтен дә үти.

Грек мифологиясендә Йапет, әйтелгәнчә, титан. Йапет Азиянең (Асиянең) ире, Прометей, Эпиметей, Атлант һәм Менетинең атасы. Зевска каршы баш күтәргән өчен Йапет башка титаннар белән берлектә Тартарга ташлатыла. Грекларда Тартар — җир астының иң тирән урыны, тәмуг. Менә шушы мифта Атлантиданың, димәк, Крит цивилизациясенең һәлакәткә очравы, диңгез төбенә — бик тирәнгә, җир астына убылып юкка чыгуы чагыла. Атлантиданы җир йоткач, борынгы грекларга атлантлар-

ның кайбер аллалары да шунда ук төшеп юкка чыккан булып аңлашылган. Грек мифларында Крит кешеләренең кайбер атаклы патшалары да үлгәч җир асты дөньясына күчәләр һәм анда да хаким булып калалар. Мәсәлән, мифларда әйтелгәнчә, Крит патшасы Минос үлгәннән соң җир асты дөньясында җинаятьчеләргә җәза бирүдә катнаша.

**Пан**. Аркадиядә Пан дигән алла урман һәм әрәмәләр хуҗасы исәпләнелгән. Туганда ук Пан йонлы булып, мөгезле һәм кәҗә тояклы, кыек борынлы, сакаллы һәм койрыклы булып туган, имеш. Панның анасы мондый кыяфәтле баладан курыккан һәм аны каядыр ташлап калдырган. Баланы Гермес дигән алла табып, Олимп тавына аллалар янына алып барган. Ямьсез кыяфәтле баланы күреп аллалар көлешә башлаганнар. Шуннан соң Панны да үзләре арасына алла итеп алып калганнар, имеш. Греклар уйлаганча, Пан көтүчеләргә, аучыларга, умартачыларга һәм балыкчыларга изгелек эшләгән. Ул көлдерергә ярата икән, ләкин кайчагында аның үзенең генә каласы килә һәм башкаларның борчыганын яратмый икән. Панның «Бөек Пан» дигән атамасы да киң таралган булган (МС, 177, 178 битләр).

Татарча «урман бете» *талпан* дип атала. Үзе кечкенә, үзе ямьсез, койрыгы, мөгезләре бар. Үзе урманда, әрәмәләрдә яши — агач арасына кергән теләсә кемне көлдерергә дә, куркытырга да мөмкин. Бу сүзне *тал* һәм *пан* кисәкләренә таркатсак, *бөек Пан* барлыкка киләчәк. Татарстанда хәтта *Пан* дип аталган елга да бар (Гар, 96 бит).

**Гея** сүзе грек телендә «җир» дигәнне белдерә икән. Гея үзе иң әүвәлге хаостан барлыкка килгән. Уранны (Күкне), Тауларны һәм Диңгезне тудырган. Геяне греклар барлык кешеләрнең беренче тудыручысы һәм җир куенындагы мәетләрнең җыелу урыны дип исәпләгәннәр. Бөтен Грециядә Геяне уңыш бирүче буларак олылаганнар. Гейә сүзен без *җәйә* дип төзәтәбез. Төркиләрдә катлаулы җәянең дини-фәлсәфи мәгънәсе булуы һәм аның, сугыш коралы гына түгел, бәлки «ана улы», ягъни *vulva* символы булуы турында без инде яхшы ук беләбез дип уйлыйм.

### 6. ЯЗМА ИСТӘЛЕКЛӘР. *КАР* ҺӘМ *МИС*

Борынгы грек язма истәлекләрендә кар дигән халык еш телгә алына. Карларны Гомер да, аннан соңгырак чорларда яшәгән язучылар да беләләр. Геродотның, Страбонның күп кенә хикәяләре карларга багышланган. Геродот әйткәнчә, карлар Кече Азиягә утраулардан күченгәннәр. Бик ерак заманнарда алар утрауларда яшәгәннәр

һәм Минос патшага буйсынганнар, лелег дип аталганнар. Ул борынгы заманнарда Минос патша бик күп халыкларны буйсындырган һәм бөтен дөньяда иң көчле патша булган. Миноска буйсынган карлар да, шул рәвешчә, иң көчле халык булганнар. Шуннан соң бик күп вакытлар үткәч, карларны утраулардан грек телле дори һәм ио (русча «ионяне») кабиләләре кысрыклап чыгарганнар. Ләкин шул ук Геродот язганча, материктагы карлар мондый риваятьләрне дөрес түгел дип исәпләгәннәр. Алар үзләрен гомер-гомергә материк кешеләре дип белгәннәр (Г, I, 171). Бүгенге галимнәр уйлаганча, дори һәм ио кабиләләре кысрыклавына түзә алмыйча, борынгы Кнос һәм Фест сарайларының чын хуҗалары — карларның күпмедер өлеше материкка күченгән, күпмедер өлеше греклар кул астында утрауларда торып калган булырга мөмкин.

Безнең өчен иң әһәмиятлесе шул: кар дигән халык булган, бик ерак заманнарда карлар Урта диңгез утрауларында, аерым алганда, Крит утравында яшәгәннәр. Ләкин карлар утрауларда гына түгел, Кече Азиядә дә булганнар. Аларның шәһәрләре башлыча диңгез буена якын җирләрдә урнашкан. Карларның мифик ата-бабалары Кар дип аталган. Карның тагын Лид һәм Мис дигән туганнары да булган.

Бүгенге көндә актив кулланылган *варвар (барбар)* сүзен греклар иң әүвәл карларга карата әйткәннәр. Варвар («дошман») дигәндә, гадәттә, грек телле булмаган халыклар күз алдында тотылган.

Кече Азиядә Геродотка кадәр һәм Геродот заманнарында кар шәһәрләре һәм Кария (Кар өе) дип аталган кар дәүләте була. Күрәсең, Атлантида һәлакәтеннән соң активлашып киткән грек телле кабиләләр баштарак утрауларга, аннан соң Кече Азиягә дә басып керәләр. Кече Азиянең төньяк-көнбатыш өлешендәге кар шәһәрләрендә, авылларында тора-бара грек телле ио кабиләләре өстенлек итә башлый һәм соңыннан бу җирләр Иония дип атала. Бүгенге көндә без белгән грек культурасы иң элек менә шунда — Иониядә барлыкка килә һәм шунда чәчәк ата. Грекларда дәүләт идарәсен, шәһәр төзелешен, сынлы сәнгатьне, язма тарихны, әдәбиятны, географик сәяхәтләрне башлап җибәрүдә, үстерүдә Иония кешеләренең роле аеруча зур. Геродот, мәсәлән, чыгышы белән карлар нәселеннән. Ләкин Геродот Иониядә түгел, Иониядән төньяктарак урнашкан Кария башкаласы Галикарнас шәһәрендә туган (С, XVI, II, 16).

Заманында карлар чыннан да күп һәм көчле халык булганнар, ахрысы. Кар катнашында ясалган исем-атамаларны Урта диңгез бассейны илләрендә һәм якын-тирәдәге,

хәтта аннанерактагы җирләрдә табарга була. Страбонның «География» дип аталган китабында *кар* катнашында ясалган исем-атамаларның саны илледән артып китә. Мәсәлән, хәзерге Персия култыгының көнчыгышында Кармания дигән дәүләт була. Элекке Кармания территориясендә (хәзерге Иранның көньягында) Керман шәһәре бар. Карманияне «карман өе» дип беләбез. *Карман* сүзен *Карман* дип таркатабыз. Бу исә «Кар улы» була. Татарстанда, Башкортстанда бүген дә Карман дигән авыллар бар. Турдетаниядә (хәзерге Испания җирендә) Страбон заманнарында Кармон, ягъни Карман дигән шәһәр дә булган.

Страбон әйткән Кармания дәүләтенә якын җирләрдә, Гарәбстан ярымутравының көньяк өлешендә Бәхетле Гарәбстан дип аталган ил булган. Бу илдә яшәгән дүрт кабиләнең берсе мин (русча «миней») дип аталган. Мин кабиләсенең иң зур шәһәре Карна яки Карнана дип аталган. Миннәр янында сабалар (русча «сабеи») яшәгән. (Сабалар турында без башка урында киңрәк итеп сөйләшербез.) Сабаларның башкаласы Мариаба дип аталган (С, XVI, VI, 2). X—XI гасырларда шул ук якларда гарәпләрнең карматлар дәүләте булган. Карматлар дәүләтен Хамдан Кармат дигән кеше нигезләгән. (Мец, 252, 253 битләр.)

Хәсән Туфанның туган авылы Иске Кармәт дип атала. Бүгенге көндә аз санлы төрки халыкларның берсе карай (караим) буларак мәгълүм. Татарларда элек Кари, Карай дигән кеше исемнәре булган. Татарда Кариев, руста Карев фамилияләре очрый. Башкортстанда Карай, Мордва АССРда Татар-Карай авыллары бар.

X—XIII гасырларда Көнчыгыш Төркестанда һәм Җидесу, Көньяк Тяньшань буйларында Караханнар (караханилар) дәүләте була. О.Притцак Караханнар дәүләтенең төп халкы, хаким халкы карлуклар булган дигән нәтиҗәгә килә. Карлуклар арасында аеруча чигил һәм ягма кабиләләре аерылып тора. Карлуклар турындагы беренче хәбәрләр төрки Орхон язмаларында һәм кытайча Таншу язмаларында очрый. Көнбатыш төрек каганлыгы таркалгач, Чу елгасы үзәнендә 737 елда карлуклар дәүләте оеша. Йосыф Баласагуниның атаклы «Котадгу билик» әсәре карлуклар дәүләтендә иҗат ителә. Төрки телләр сүзлегенең авторы Мәхмүт Кашгари да карлуклар илендә туган һәм шунда иҗат иткән.

Караханилар дәүләтенең бер башкаласы Кашгар дип аталган. Мәхмүт Кашгариның исеме шуннан алынган. Татарстанда элек үзенең мәдрәсәсе белән атаклы Кышкар авылы бар. Тарихчы В. В. Бартольд 544 елга караган бер вакыйга уңае белән Месопотамиядәге (борынгы Шу-

мер, хәзерге Гыйрак җирендәге) Кашкар шәһәрен телгә ала (Бар, II том, 2 кисәк, 278 бит).

*Карлук* сүзен без *Кар-лык*, ягъни «Кар улы» (Кар кешеләре, Кар нәселе) дип, *Кашгар, Кашкар, Кышгар* атамаларын *Каш (кыш)-кар (гар)* рәвешендә таркатабыз һәм әлеге атамаларның һәркайсын «бөек (изге) Кар» дигән мәгънә белдерә дип исәплибез. Безгә якын *Болгар* атамасының әүвәлге әйтелеше *Балкар* булгандыр дип уйларга нигез бар. *Балкар* сүзен *Бал кар* дип таркатабыз һәм шулай ук «изге (бөек) Кар» дип беләбез.

«История» язып үз исемен мәңгеләштергән Геродотның туган шәһәре *Галикарнас* сүзенә игътибар итеп карыйк. Бу сүзне без *Гали Кар, нас* рәвешендә таркатабыз. *Гали* сүзенең «бөек» (изге) мәгънәсен белдерүе күпләргә таныш дип исәплик. *Кар* исә — әле генә телгә алган мифик ата-баба исемен, *нас*, күрәсең, шәһәр, торак дигәнне белдерәдер дип әйтергә була. Бу теге кайбер топонимик исем-атамалар азагында кулланыла торган өстәмә мәгънә белдерүче өстәмә сүз булып тора. *Нас-нәс* рәвешендәге өстәмә иҗекләр кайбер татар авыллары исемендә дә очрый. Мәсәлән, Татарстанда Чикәнәс, Сикәнәс, Шикәнәс авыллары бар. Борынгы Грециядә *нас-нес* иҗекләренә тәмамлана торган исем-атамалар күбрәк булган, ахрысы. Шундыйлардан еш кабатлана торган Парнас, Пелопоннес иле атамаларын күрсәтергә була. Без әле әйтмәдек бугай — Татарстанда Кариле, Олы Кариле, Кече Кариле авыллары, Әстерхан өлкәсендә татарларның «кариле нугайлары» дип аталган этник төркемнәре бар. Рязань өлкәсендә касим татарлары яши торган бер авыл Карлар дип, Татарстанның Буа районындагы бер авыл Карлы дип атала.

## 7. ЯЗМА ИСТӘЛЕКЛӘР. ЭФОРНЫҢ «КРИТ ТАРИХЫ»ННАН КАЙБЕР МӘГЪЛҮМАТЛАР

Б.э.к. IV гасырда Эфор дигән грек тарихчысы яшәгән. Эфор Эолиядәге Кимы шәһәрендә туган һәм б.э.к. 340 еллар тирәсендә үлгән. Эфор «Крит тарихы» дигән китап язган, ләкин аның китабы безнең көннәргә кадәр килеп җитмәгән. Эфордан соң өч йөз еллар чамасы соңрак яшәгән Страбон үзенең «География» китабында Эфор тарихыннан күп кенә өзекләр китерә. Страбонның «География»сендә сакланып калган өзекләрдән без борынгы Крит дәүләте, Крит тәртипләре, Крит кешеләре турында күп кенә кыйммәтле мәгълүматлар таба алабыз.

Идарә эшендә Крит кешеләре ун «архон» (*ар хан? тархан?*) сайлап куя торган булганнар. Аеруча әһәмиятле эш-

ләрне тикшергәндә «геронт» дип аталган киңәшчеләргә мөрәҗәгать иткәннәр. Эфор әйткәнчә, Крит законнары «Дәүләтнең иң зур байлыгы — ирек» дигән принципка яраклаштырып төзелгән. Закон нигезендә яшьләр — аерым төркемнәргә, өлкәннәр — аерым төркемнәргә бүленгәннәр.

Критта яшьләрне тәрбияләүгә аеруча нык игътибар иткәннәр. Аерым төркемнәргә бүленгән яшьләрне Крит кешеләре батыр сугышчылар итеп тәрбияләргә тырышканнар. Үскәч куркак булмасыннар өчен яшьләрне сугыш коралы белән эш итәргә һәм һәртөрле авыр хезмәткә өйрәткәннәр. Төркемнәрдәге яшьләр өсләренә, аякларына хәрби киемнәр киеп йөрергә мәҗбүр булганнар. Сугыш коралы алар өчен иң зур байлык саналган.

Төркем таркалгач, төркемнән чыгарылган яшьләрнең барысын бер вакытта өйләнергә мәҗбүр иткәннәр. Ләкин өйләнгәч тә яшь кияүләр хатыннарын шундук өйләренә алып кайтмаганнар. Булачак яшь хатын йортта хуҗалык итә белгән очракта гына яңа җиргә килен булып төшә алган. (Күрәсең, монда төркиләрдәге кияүләп йөрү йоласы күз алдында тотыладыр дип әйтергә була.)

Балалар укырга, язарга һәм шулай ук закон тарафыннан билгеләнгән җырлар җырларга, музыканың кайбер төрләренә өйрәнгәннәр. Яшьрәк балаларны олыраклар үзләренә ияртеп йөргәннәр. Яшьрәкләр үзләреннән өлкәнрәкләр белән бергә туенганнар, өлкәннәргә һәм үзләренә үзләре хезмәт күрсәткәннәр. Ашаганда җәй көне дә, кыш көне дә җиргә утырып ашый торган булганнар. Билгеле бер вакытларда балаларның үзара сугышларыкөрәшләре оештырылган. Бер төркем балалар белән икенче төркем балалары сугышкан.

Яшьләр төркемен, гадәттә, берәр хәллерәк кешенең баласы оештырган. Төркем оештыручы малайның атасы төркемгә баш булып исәпләнелгән. Баш кеше төркем яшьләрен ауга һәм йөгерү ярышларына алып барган, сүз тыңламаучыларга җәза биргән. Төркем яшьләре халык исәбеннән туенганнар.

Крит кешеләре оста диңгезчеләр булганнар. Бик яхшы белгән нәрсәне белмәгән булып кыланучы кеше турында «Крит кешесе диңгезне белми» дигән мәкаль дә булган.

Лакедемон (Спарта) кешеләренең күп кенә йолалары, гореф-гадәтләре Крит йолаларына һәм гореф-гадәтләренә охшаган (С, X, IV, 16—22).

Крит яшьләренең хәрбиләштерелгән төркеме «көтү» дип аталган (грекчадан русчага тәрҗемә итүче «буквально стадо» дигән искәрмә бирә). Татарда *«гаскәр»* мәгънәсендә *чирү* сүзе бар. Татар теле диалектларында бүре өеренә

карата да *чиру* сүзе кулланыла (ТРС, 637 бит). Чирүнең *сүрү (сурув)* варианты карай телендә «көтү» дигәнне белдерә (КРПС, 485 бит). Борынгы төрки телдә «көтү» *сүрүг* дип аталган (ДТС, 518 бит). Татар телендә күп кеше төркеменә, аеруча балалар төркеменә карата *көтү, өер* сүзләре кулланыла. «Күп бала» дип әйтәсе урында еш кына бер көтү бала диләр.

Шулай итеп, *көтү* дә, *гаскәр* дә бер үк мәгънәгә ия икән. Димәк, Крит яшьләренең хәрбиләштерелгән төркемнәре дә бер үк вакытта «көтү» дә, «гаскәр» дә була алган.

Крит яшьләренең хәрби биюләре *пирриха* дип аталган. Бу сүз әлеге биюне иҗат иткән кеше исеменә бәйле рәвештә барлыкка килгән. *Пирриха* сүзен без *пир-ри-ха* дип таркатабыз. Татар теле диалектларында *пир* — карт кеше, бер төркем фикердәшләр башында торучы җитәкче кеше дигәнне белдерә (ТТАС, II, 516 бит). Хәрбиләштерелгән яшьләр төркеменең җитәкчесе нәкъ менә шундый баш кеше булган лабаса! *Пир* сүзен бездә фарсыдан алынган дип исәплиләр. Баксаң, бу да үзебезнең сүз икән һәм аның да тамыры еракларга сузылган икән.

Эфорга нигезләнеп Страбон язганча, Крит кешеләренең өлкәннәрдән оешкан төркемнәре күмәк ашка җыела торган булганнар. Мондый күмәк аш өчен азык-төлек халыктан алына торган булган. Күмәк аш вакытында тамак аралату булмаган — байларга да, ярлыларга да аш-су тигез итеп бүлеп бирелгән. Өлкәннәрнең күмәк ашлары (русча «общие трапезы») крит телендә *андри* дип аталган (С, X, IV, 16). «Крит кешеләренең күмәк ашлары әле дә «андри» дип атала»,— ди Страбон, үз заманындагы Крит кешеләрен күз алдында тотып (С, X, IX, 18).

Татар телендә *әндери казнасы* дигән сүз бар. Моның мәгънәсе «бетмәс-төкәнмәс байлык» дигәнгә туры килә. Телдә шулай ук *әндери әбәте* дигән сүз тезмәсе дә бар (ТТАС, III, 683 бит). *Әндери*, гадәттә, русча Андрей дигән кеше исеме сымаграк яңгырый. *Әндери әбәте* дигәч, Андрей обеды күз алдына килә сыман. *Әндери казнасы* дигәндә ниндидер серле Андрейдан калган бетмәс-төкәнмәс байлык турында сүз бара сыман. Ләкин, күрәсез, барысы да үзебезнең сүз, үзебезнең тәгъбирләр икән: *әндери* дә, *казна* да, хәтта *әбәте* дә!

Карлар, критлылар турында сөйләгәндә, Кавн шәһәре кешеләренең җыйнаулашып аш-су ясау гадәтләре турында Геродот та яза. «Кавнлылар мәсьәләсенә килгәндә, минемчә, алар — материкның төп кешеләре, тик шулай да алар үзләрен Криттан күченеп килгән дип исәплиләр,— ди тарихчы һәм дәвам итә.— Кавнлыларның иң зур күңел ачу-

лары шул — яшьтәшләре һәм дус-ишләре белән бергәләп, күп кеше булып, алар — ирләр, хатын-кызлар, бала-чагалар — аш-су мәҗлесе оештыралар» (Г, I, 172).

Балаларның яз көне өйдән азык-төлек алып барып, бергәләшеп урманда, чишмә буенда «карга боткасы» пешерү йолалары, өлкәннәрнең күмәкләшеп «яңгыр боткасы» пешерүләре, шулай ук язгы кыр эшләре вакытында күмәк аш пешерүләр татар авылларында әле сугыштан соңгы елларга кадәр сакланып килде. Мондый борынгы гадәтләр, йолалар, ихтимал, кайбер җирләрдә әле дә бетеп җитмәгәндер дип әйтәсе килә.

## 8. ГОМЕР ДАСТАННАРЫ. «ИЛИАДА»

Алдау, алдану турында усал итеп, үтемле итеп әйтергә теләсәк, без, гадәттә, «агач атка атландырды», дибез. Агач атка атлану һәм ... алдану. Нәрсәгә ишарәли бу? Балалар өчен ясалган агач ат булырга мөмкин, баланы агач атка атландыру булырга мөмкин. Таякка, чыбыкка атланып бала шуны «ат» дип чабып йөрергә мөмкин. Ләкин бу очракта «ат» та, чыбык та баланы алдау өчен түгел, аның күңелен күтәрү өчен хезмәт итә. Димәк, әлеге сүз тезмәсендә балалар дөньясы күз алдында тотылмый.

*Агач ат* ярдәмендә берәүләрнең алдавы, икенче берәүләрнең алдануы дөньяда бары бер генә мәртәбә һәм бер генә җирдә булган, һич югы, бүгенге кешеләргә билгелесе бер генә. Бу хакта борынгы грекларның атаклы җырчысы Гомерның «Одиссея» дастанында әйтелә. Агач ат аркасында алдану яисә агач ат белән алдауга сәбәпче булган вакыйгалар турында шул ук Гомерның «Илиада» дастанында сөйләнелә.

«Илиада» дастанының кыскача эчтәлеге шуннан гыйбарәт. Троя шәһәре патшасының улы Парис Спарта патшасы Менелайның хатыны Еленаны урлап китә. Ахайлар (ахейлар), Паристан үч алмакчы булып һәм шулай ук Еленаны үз иренә кайтарып бирү нияте белән, Трояга каршы яу булып киләләр. Грекларның берничә шәһәрдән җыелган, берләштерелгән гаскәренә Микена патшасы Агамемнон җитәкчелек итә. Агамемнон Менелайның бертуган агасы була. Троя шәһәре янында тугыз ел сугыш бара, ләкин ахайлар шәһәрне берничек тә ала алмыйлар. Бары тик унынчы елда гына греклар теләкләренә ирешәләр. Ачыктан-ачык сугышта җиңә алмагач, алар хәйлә уйлап табалар. Греклар бик зур агач ат ясыйлар, атны яр буенда калдырып, үзләре корабларга утыралар да, диңгезгә чыгалар. Алар кайтып киткән булып күре-

нергә тырышалар, ләкин чынлыкта кайтып китмиләр, шундагы бер кечкенә утрауда качып торалар. Троя кешеләре ахайларны чыннан да кайтып киттеләр дип уйлыйлар, капкаларын ачып, агач атны шәһәргә өстерәп кертәләр. Агач ат эчендә грекларның кораллы сугышчылары була. Төнлә барысы да йоклап беткәч, ахайлар ат эченнән чыгалар һәм, сакчыларны үтереп, капканы ачалар. «Кайтып киткән» ахайлар Трояга бәреп керәләр. Троя җиңелә. Троя җимерелә.

Агач ат ярдәмендә алдау яисә «агач атка атландыру» менә шул була. Бу хакта бөтен дөнья белә. Ләкин, әйтергә кирәк, Троя шәһәренең җимерелүен үз күзләре белән күргән яки ишеткән өчен түгел, бәлки Гомер дастаннарын һәм шул турыда исәпсез-хисапсыз хезмәтләрне укыган, ишеткән өчен белә. Гомер дастаннары бүгенге көндә бик күп телләргә тәрҗемә ителгән, аларны мәктәпләрдә, югары уку йортларында укыйлар, өйрәнәләр. Бу хакта әледәнәле фәнни мәкаләләр, диссертацияләр языла. Үзен культуралы, аң-белемле дип исәпләгән кешенең, гомумән, Гомерны белмәве мөмкин түгел.

Ишетеп кенә булса да Гомерны без дә беләбез. Ләкин әлегә бездә «Илиада» да, «Одиссея» дә тәрҗемә ителмәгән, Күңелсез хәл, әлбәттә. Элек тә татар укымышлылары грек телен белмәгәннәр, өйрәнмәгәннәр, аның белән бөтенләй диярлек кызыксынмаганнар. «Илиада», «Одиссея» турында, Гомер турында безнең зыялылар аннан-моннан ишетеп кенә хәбәрдар булганнардыр кебек. Әйтәсе килгәнем шул: «агач атка атландырды» тәгъбире бездә грек дастаннарын уку нәтиҗәсендә барлыкка килмәгән. Киресенчә, дөньяда грек дастаннары мәгълүм булганчы ук инде халык аңында, халык телендә агач атка атландырып алдау турындагы төшенчә булган. Ни өчен дигәндә, агач ат аркасында бик каты алданучылар төркиләр — безнең борынгы ата-бабаларыбыз үзләре булган. Әлеге әйтемдә менә шул бик ерак заманнардагы аянычлы, фаҗигале вакыйга турында информация саклана да инде.

Бу фикерне раслау өчен татар телендәге әлеге әйтемнән башка тагын нинди дә булса бүтән төрле дәлилләр табып буламы соң? Дәлилләрнең иң ышанычлысы — Гомер дастаннары.

Троя шәһәре Кече Азиянең төньяк-көнбатыш өлешендә, диңгезгә якын бер җирдә, хәзерге Төркиядәге Гиссарлык дип аталган калкулыкта урнашкан була. Борынгы Троя калдыкларын 1870 елда немец археологы Генрих Шлиман казып таба. Шуннан соң монда күп кенә археологик казулар үткәрелә һәм б.э.к. 1260 еллар тирә-

сендә шәһәрнең бик озак вакыт дәвамында камалуда булуы, җимерелүе ачыклана. Шулай итеп, Гомер дастаннарында сөйләнелгән күп нәрсә раслана. «Илиада» һәм «Одиссея» дастаннары исә Троя сугышы турындагы истәлекләр нигезендә б.э.к. IX—VIII гасырларда иҗат ителгән дип исәпләнелә.

«Илиада»да әйтелгәнчә, Трояны салуда аллалар катнашкан: диңгез алласы Посейдон белән Аполлон шәһәрне койма белән әйләндереп алганнар (Ил, VII, 453, 454; XXI, 442—449). Белүебезчә, диңгез алласы Посейдон Атлантида кешеләренең мифик атасы исәпләнелгән. Посейдон атлантларның да башкалаларын төзүдә булышкан, үзәктәге тауга кадәр арыклар үткәргән һ.б. Аполлон шулай ук атлантларның һәм башка төрки кабиләләрнең алласы Изге Кояш булган.

«Илиада», билгеле, ахайларны яклый, аларның батырлыгына дан җырлый. Шул ук вакытта җыручы Гомер Трояны һәм Троя кешеләрен дә хурламый. Киресенчә, хурлау сүзләре күбрәк ахейларның үзләренә эләгә. Троя шәһәре һәр очракта бары уңай сыйфатлар белән генә тасвирлана. Трояга карата дастанда бөек, биек, иркен, бай, бәхетле, биек коймалы, нык коймалы эпитетлары кулланыла. Иң еш кулланылганы — изге сыйфаты. Дастанда әйтелгәнчә, Троя кешеләре изгеләр, горурлар, бөекләр, данлылар, асыл затлар, нык рухлылар. Алар бигрәк тә ат яраталар. Троя кешеләре — ат өйрәтүчеләр («укротители коней»), атны егып салучылар («бодатели коней»), атта яхшы сугышучылар, атта төз атучылар һ.б.

Гомер ахейларны көдрә чәчле, аксыл чәчле итеп тасвирлый. Спарта патшасы Менелайның эпитеты — *аксыл чәчле*. Троя батыры Гектор исә *кара чәчле* (Ил, XXII, 402). Троя шәһәрен ныгытуда катнашкан Посейдон һәм Аполлон шулай ук *кара чәчлеләр* (Ил, XX, 149 һ.б.).

Ике як та төрле корал белән, башлыча сөңге белән сугыша. Сугышта кылыч, хәнҗәр, пычак, балта, таш кебек кораллар да кулланыла. Ук-җәя дә еш телгә алына. Ләкин ук-җәя күбесенчә Троя кешеләрен тасвирлаганда очрый. Көмеш уклар атучы Аполлон һәм аның игезәк сеңлесе («горур укчы») Артемида ахыргача Троя кешеләрен яклыйлар. Борынгы һәм урта гасыр төркиләрнең төп коралы — ук һәм җәя. Ук-җәяне изгеләштерү, аларның сугышчан һәм сихри көченә ышану, әйтелгәнчә, төркиләрнең бик борынгы дини-фәлсәфи карашларына нигезләнгән. Троя ягында да, ахайлар ягында да төрле кабилә кешеләре катнаша. Ахайлар ягында, мәсәлән, Крит кешеләре дә бар. Патроклны күмгәндә ахейлар төрле

ярышлар уздыралар. Уктан төз атуда Крит батыры Мерион җиңеп чыга (Ил, XXIII, 860—882).

Троя сугышчыларының һәм Троя яклыларның җәясе турында сөйләгәндә һәр очракта диярлек *кәкре, бөгелгән, төрле кисәктән торган* («кривой», «гнутый», «разрывчатый») сыйфатлары кулланыла. Шул рәвешчә, Троя кешеләренең җәяләре *М* рәвешендә булган дип әйтә алабыз. Ахейларның калканнары катлы-катлы, зур, биек, кабарынкы. Троя кешеләренең калканнары һәр очракта түгәрәк.

Дастанда әйтелгәнчә, Троя хатын-кызлары озын итәкле һәм матур итеп бизәлгән күлмәк кигәннәр. Кнос сарае фрескаларында аяк йөзенә кадәр төшеп торган озын итәкле, матур бизәкле күлмәк кигән хатын-кызлар сурәтләнгән. Шул ук сарайда табылган алиһә сыннарының күлмәкләре дә озын һәм киң итәкле.

Патроклны күмгәндә Ахиллес оештырган ярыш уеннары бүгенге сабан туе уеннарын хәтерләтә. Дөрес, монда башлыча ахейлар катнаша. Троя сугышы чорларында грекларның да, төркиләрнең дә кайбер йолалары, гореф-гадәтләре уртак булган булырга мөмкин. Дөресрәге, ахейлар үзләренең элгәреләре — Крит цивилизациясе кешеләренең кайбер гадәтләрен һәм йолаларын үзләштергән булырга мөмкиннәр. Мәсәлән, күмүдән соң ахейлар ат чаптыралар, көрәшәләр, йөгерешәләр. Монда шулай ук ук ату, сөңге ыргыту, йодрык сугышлары да була. Корал белән сугышу, ук ату сабан туе ярышларында күптән инде онытылган, ләкин ат чаптыру, йөгерү әле дә саклана. Татар әкиятләрендә батырлар төз атуда ярышалар. Революциягә кадәрге Казанда, Кабан күлендә, кыш көннәрендә татарлар белән руслар арасында йодрык сугышлары булган.

Троя кешесе Долон ахейлар ягына шымчы-күзәтче булып чыкканда өстенә бүре тиресе каплап бара (Ил, X, 334, 459). Бүре, белүебезчә, төркиләрдә изге саналган һәм элегрәк дин башлыклары төрле йола бәйрәмнәре вакытында өсләренә бүре тиресе каплый торган булганнар. Рус елъязмаларында әйтелгәнчә, кыпчак кешесе Боняк иртәгә сугыш буласы дигән төнне, төн уртасында далага чыгып, бүре булып улый. Шул рәвешчә, Боняк иртәгә буласы сугышның ничек тәмамланачагын белмәкче була. Скиф кабиләләренең берсе неврларның һәр елны берничә көнгә бүрегә, аннан соң яңадан кешегә әйләнүләре турында Геродот та яза (Г, IV, 105).

Троя батыры Гекторны күмгәндә, мәетне күп итеп өелгән агач өстенә салалар һәм агачны ут төртеп яндыралар. Гекторның янган сөякләрен җыеп алтын савытка тутыралар һәм тирән кабергә төшерәләр. Кабер өстенә

курган өяләр (Ил, XXIV, 786—799). Урта гасырларда Алтай төркиләренең патшалары үлгәч, аларны да яндырганнар һәм көлләрен савытка салып күмә торган булганнар. Уйгурлар исә, Рубрук әйткәнчә, үзләренең мәетләрен элеккеге йола нигезендә яндырып, мәет көлен пирамида (?!) түбәсендә саклый торган булганнар.

Троя шәһәрен салган вакытта Посейдон белән Аполлон кеше кыяфәтендә булалар. Троя патшасы Лаомедон ни өчендер аларны куалап җибәрә һәм эш хакларын басып кала. Патша Аполлонны коллыкка сату белән куркыта, икегезнең дә колагыгызны кисәрмен дип шапырына (Ил, XXI, 442—455). Татарда әле дә бала-чаганы «колагыңны кисәрмен» дип куркыталар, һич югы, без бәләкәй чакта шулай иде.

Монда без, атаклы дастанга нинди дә булса анализ ясауны максат итеп куймыйча, иң өстә яткан һәм күзгә нык ташланган кайбер төрки-грек уртаклыкларга гына тукталдык. Хәзер Гомер дастаннарындагы кайбер исемнәргә игътибар итеп карыйк.

## 9. ГОМЕР ДАСТАННАРЫ. ИСЕМ-АТАМАЛАР

Татар сөйләм телендә *әкәй* дигән сүз бар. Гадәттә ул удмурт, мари, кайчагында чуваш хатын-кызларына карата әйтелә. *Әкәй* сүзендә күрәләтә кимсетү мәгънәсе сизелә. Шунлыктан бу сүз сүзлекләргә кертелми, әдәби телдә кулланылмый.

Тарихта билгеле булган иң беренче грекларны *ахай* яисә *ахей* дип атыйлар. Татар телендәге *әкәй* сүзен без менә шушы *ахай-ахей* атамасына бәйле рәвештә аңлатабыз. Грек чыганакларында *ахай (ахей)* рәвешендә языла торган бу сүзнең төрки әйтелеше *акай* булган дип исәплибез. Бүгенге татар телендә *акай, акай-чукай, акаю* сүзләре бар. *Акай* ул зур күзле, шар күзле дигәнне белдерә. Әлеграк тә аның төп мәгънәсе шундыйрак булгандыр дип әйтәсе килә. Крит-Атлантида төркиләре таррак, кысыграк күзле булганнар. Салкын яктан килгән ахейлар көньяк кешеләренә, күрәсең, зуррак күзле булып тоелганнардыр кебек. Ләкин *акай* атамасы күзнең зурлыгына-кечкенәлегенә генә кайтып калмагандыр сыман. Бүгенге телдә *акай*ның кешегә туры караучы, әдәпсез, оятсыз мәгънәләре дә бар.

Сөйләм телендә тагын «акайдагы-килмәттәге ...берсе дә калмаган» дигән әйтем бар. Моның мәгънәсе «төрле җирдән теләсә кем килеп җыелган — берсе дә калмаган» дигәнгә туры килә. Әлеге сүзтезмәсендә *акай* да, *килмәт* тә читтәге, ерактагы нииндидер ил, авыл, шәһәр һәм шул

ил, авыл, шәһәр кешеләре булып күз алдына килә. Бүгенге көндә нindidер Акайны һәм Килмәтне инде беркем дә белми. Андый исемдәге авыллар да юк. Бу бары телдәге катып калган мәгънәсез сүзләр җыелмасы гына булып тоела. Ләкин Акайны тарихи Ахай дип белсәк, мәгънәсез сүз калдыгы бөек мәгънәгә ия булачак. Килмәт нәрсә? Г. Саттаровның «Татар исемнәре сүзлеге»ндә Килмәк дигән кеше исеме бар, ләкин Килмәт юк. Татар драматургы Сәет Кальметов фамилиясендәге Кальмет, бәлки, Килмәттән үзгәргәндер? Кистереп кенә әйтеп булмый. Килмад формасында бу сүз Библиядә очрый. Библиянең Йезекиил китабы, XXVII бүлегендә Финикия башкаласы Тир шәһәренең Кече Азиядәге һәм Урта диңгезнең көнчыгышындагы төрле илләр-шәһәрләр белән сәүдә итүе турында сөйләгәндә, 23 параграфта «Харан, Кание, Эден, Сава сәүдәгәрләре, Ассур һәм Килмад» телгә алына (Хр, ДВ, 301 бит). Килмад Ассур белән янәшә әйтелә, димәк, Килмад кайдадыр Ассур (Ассирия) ягында, Кече Азиянең көнчыгыш өлешендә булган. «Акайдагы-Килмәттәге» дигән сүзләрне әйтүчене Критта яисә Трояда (хәзерге Мәрмәр диңгезенә якын җирләрдә) итеп күз алдына китерсәк, Килмад Критка һәм Трояга карата кайдадыр еракта — көнчыгышта булачак. Акай исә хәзерге Греция яисә Югославия якларында булачак. Ягъни Акай белән Килмәт дөньяның ике ягындагы, «дөнья читендәге» илләр, халыклар булып чыгачак.

Бүгенге *әкәй* сүзе акайның нечкә варианты булса кирәк. Ләкин *әкәй*, нишләптер, бары хатын-кызга карата гына кулланыла. Бу уңайдан *акай*ның ике *къ* белән әйтелә торган *аккай* формасын да искә төшерергә туры килә. *Аккай* ул апа, абыстай дигәнне белдерә. Бәлки, *акай* чынлыкта *аккай*дан үзгәргәндер? Ни генә булмасын, төрки телдә бик борынгы заманнарда ук *акай* да, *аккай* да, *әкәй* дә булгандыр дип уйларга кирәк. Бу сүзләр грек теленә *ахай* һәм *ахей* рәвешендә кабул ителгәннәр һәм шул килеш сакланып калганнар. Грек телендә *әкәйгә* якын *Эгей* сүзе дә бар. Балкан ярымутравы белән Кече Азия арасындагы диңгез *Эгей* диңгезе дип атала. Эгей грек сүзе түгел икән (МС, 267, 268 битләр), Ахей кабиләләре көчәеп, әлеге диңгезгә хуҗа булгач, якын-тирәдәге халыклар (ихтимал, төркиләр) аны шулай Әкәй диңгезе дип атаганнардыр дип уйларга була.

*Әкәй*нең *акай-ахай* яисә *ахей*нең *әкәй* булуы ихтималын куәтли торган тагын бер дәлил бар. «Илиада» дастанында Терсит дигән ахей кешесе, Агамемнонны һәм барлык ахей халкын хурлап: «Көчсез, куркак халык без — ахей ирләре түгел, ахей хатын-кызлары!» — дип тирги.

(Русчасы: «Слабое, робкое племя, ахеянки мы, а не ахейцы!» Ил, VII, 96). Троя батыры Гектор ахей сугышчысы Диомедка: «һәй, Диомед! Данайлар (ягъни ахейлар.— *Н.Ф.*) сине һәрвакыт хөрмәт итәләр иде. Моннан соң инде хөрмәт итмәсләр: һәркемнән элегрәк син хатын-кызга әйләндең!» — дип кычкыра (Ил, VIII, 161—163).

Димәк, борынгы заманнарда ахай-ахейларның куркак, көчсез, хатын-кыз дигән мыскыллы кушаматлары булган. Бу турыда ахейларның күршеләре генә түгел, ахейлар үзләре дә яхшы белгәннәр булып чыга. Телдә сакланып калган *әкәй* сүзе соңыннан, татарлар Идел буйларына күченеп килгәч, барлык күршеләргә карата түгел, бәлки аларның хатын-кызларына карата гына кулланыла башлаган. Төркиләрдә еш кына хатын-кызлар да сугышчан булганнар һәм ирләр белән бергә, корал асып, атка атланып, яу чапканнар. Атаклы амазонкалар, нигездә, төрки телле булганнар. Мари, удмурт хатыннары, күрәсең, сугышчан булмаганнар һәм Идел буе төркиләренә «әзер килеш» ахей-әкәй булып тоелганнар. Монда, билгеле, борынгы греклар белән мари, удмуртлар арасындагы тышкы охшашлык та исәпкә алынгандыр дип әйтергә була.

«Илиада» дастанында төрле кеше, ыру-кабилә исемнәре, географик исем-атамалар телгә алына. Шуларның кайберләре күрәләтә төрки, кайберләре төркигә охшаш. Мәсәлән, Троя шәһәрен Ил дигән патша салдырган. Ил үзе Зевс улы Дардан нәселеннән булган, имеш (Ил, XX, 215—231). Троядагы Ил — мифик ата-баба. Ил дип аталган патша Трояда читтә һәм Троя сугышлары чорыннан борынгырак заманнарда да булган. Б.э.к. 2600 елларда Шумерда Забалам шәһәренең баш динчесе, соңыннан патшасы Ил дип аталган (Кра, 52—55 битләр).

Троя шәһәренең Илион дигән атамасы да мәгълүм. Илион һәм «Илиада» сүзләрен без мәгълүм төрки ил ярдәмендә ясалган грек атамалары дип беләбез. *Троя* нәрсәне аңлата икән соң? Бәлки, монда да берәр төрле төрки сүз яшеренеп ятадыр? Бу уңайдан без түбәндәге фикерне теркәп узмакчы булабыз.

Борынгы Мисырда, Мемфис шәһәренә якын бер җирдә, Нил елгасының уң ягында яхшы сыйфатлы ак таш алына торган атаклы карьер булган. Бу җир мисырча Айну дип тә, Рааау, Нерау дип тә аталган. Күрәсең, соңгырак заманнарда мондагы авыл-шәһәрнеме, карьернымы *Тура* дип тә атаганнар. Тураны комментаторлар гарәп сүзе дип аңлаталар. Әлеге *Тура*ны греклар... *Троя* дип атаганнар. (Хр. ДВ, 92 бит, иск. 6; 140 бит, иск. 8). Аңлатмада Тура һәм *Троя* атамаларының кайсы чорларда

кулланылуы турында бернинди мәгълүмат юк. Монда бары шуны гына әйтергә була, әгәр *Тура* грекча әйтелештә *Троя*га әйләнә ала икән, димәк, Гомер дастанындагы *Троя*, киресенчә, *Тура* була ала түгелме соң? *Тура* исә төрки телләрдә шактый билгеле сүз. *Тура* «шәһәр», «авыл», «йорт» дигән мәгънәләргә ия. Татарстанда Тура дигән авыл да бар. Татар телендәге *торак* сүзен *тура-к* дип таркатсак, бу «тура улы», ягъни тураның бер өлеше булачак.

Троя яисә Илион кешеләре Криттан күченеп килгәннәр һәм күченеп килүчеләрнең беренчеләре *тевкр* дип аталганнар, ди Страбон (С, XIII, I, 48). *Тевкр* сүзен *тәү кар* дип төзәтәбез һәм тулыландырабыз. *Тәү кар* ул «беренче (әүвәлге) карлар» дигәнне аңлата. Тевкрлар үзләре күченеп килгән яңа җирдәге тауны *Ида* дип атыйлар. Ида тавы аларның туган җире Критта да була. Критта һәм шулай ук Троя илендә Дикта дигән атама да була. *Ида* исеме уңаеннан татарның атаклы дастаны «Идегәй»не искә төшерә алабыз. Идегәй ул дастан исеме генә түгел, кеше исеме дә. *Идегәй* сүзен *Иде-кәй* дип таркатсак, *кәй (гәй)* монда яратып, иркәләп әйтүне белдерә торган кушымча булып тора. Исемнең үзәге — *Иде*, ягъни *Ида (Идә)*. «Одиссея» дастанының төп герое Одиссейның туган утравы *Итака* дип атала. Утрауның исеме Итак дигән герой исеменнән алынган дип аңлаталар. Ләкин геройның исеме *Ита*, утрау исеме — *Ита-ка* дип аңлатсак, бу дөресрәк булачак.

Троя кешеләре лелеглар, киликиләр белән бертуган булалар (С, XIII, III, 7). Бик борынгы заманнарда кар дигән халык утрауларда яшәгән һәм алар лелег дип аталган, ди Геродот. Лелег, күрәсең, карларның гына түгел, гомумән, барлык Атлантида халкының икенче исеме, уртак исеме булгандыр дип әйтәсе килә. *Лелег* сүзен *лелег (лек)* рәвешендә таркатсак, бу Ле (Кояш) улы булачак. Киликиләрнең бүгенге төркиләргә мөнәсәбәте барлыгын исбатлау өчен Татарстандагы Кили, Башкортстандагы Килей авыллары исемен искә төшерергә була.

Дастандагы Ареилик, Акамас, Илионей, Ирти, Мермер, Иялмен, Этион, Эней, Аластор, Аминтор, Гектор һ.б. бик күп исемнәрне игътибар белән рәк тикшереп карасак, аларның һәркайсының төрки сүзләрдән, иҗекләрдән ясалган булуына төшенербез. Мәсәлән, *Ареилик* сүзен *Аре илик* дип бүләбез. *Аре* монда бөек, изге дигәнгә, *илик* ил башы, патша дигәнгә туры килә. *Илик* сүзенең «патша» булуы төрки телләрнең берсе карлуклар телендә сакланып калган. X—XII гасырларда Урта Азиядә Караханилар дәүләтендә патшаларның *илек (илиг-хан)* дигән титулы булган (Бар, II том, 2 кисәк, 519, 520 битләр).

Аластор, Аминтор, Гектор исемнәренең ахырындагы *тор* иҗекләрен *тора* дип тә, *торур* дип тә аңларга була. Бу шулай ук *түрә* булырга да мөмкин. Үзбәкләрнең «Алпамыш» дастанында кайбер кеше исемнәре *түрә* сүзе белән әйтелә. Мәсәлән, Хәким-түрә. Гомер дастанындагы әлеге исемнәрнең *Амин, Гек* иҗекләрен Әмин һәм Гөк (Күк) дип беләбез. *Алас* мәсьәләсенә килгәндә, бу сүз кайбер төрки телләрдә «ерак» дигәнне белдерә. Ләкин Себер төркиләрендә Алас дигән ниндидер ия дә булган. *Аластор* исемендәге беренче иҗекләр чынында *алыс* булмыйча, *алас* булырга да мөмкин.

Гомер дастаннарында бүгенгечә саф татар исемнәре дә очрый. Мәсәлән, Гали (Ил, V, 678), Галия (Ил, XVIII, 40), Фалия (Ил, XVIII, 39), Феруза, ягъни Фирүзә (Ил, XVIII, 43). Бу исемнәр «Илиада»да су кызларын белдерә. Шулар арасында Актея дигәне дә бар. Татар диалектларында актай һәм актай — «иң өлкән кыз туган» дигәнне аңлата.

«Одиссея» дастанында Фессалия патшасы Салмоней дип атала. Салмонейның Тиро дигән кызы, Тironың Эсон һәм Ферет дигән уллары бар (Од, XI, 236, 259). Сәлман, Әсән, Фәрит — болар барысы да бүгенге төрки исемнәр, татар исемнәре. Тироны Тирә дип беләбез. Бу исә «җир» яки «ана» дигәнгә туры килә (тирә-як, тирә-юнь). Шул ук «Одиссея»дә Эхет, ягъни Әхәт дигән ниндидер усал патша телгә алына (Од, XVIII, 85, 116). Шушы ук дастанда тагын бер төрки исем бар. Монысы Ир дип атала (Од, XVIII, 38, 56 һ.б.). Бүгенге татар телендә ялгыз Ир дигән исем юк. Ир сүзе шулай ук төрле исем ясауда катнаша ала. Иң мөһиме, ир — төрки сүз. Бу мәсьәләдә бәхәс булганы юк, ахрысы. Дастанда Ир бәйләнчек, мактанчык һәм көчсез бер карт итеп сурәтләнә. Гомер дастаннарында Галия, Фалия, Фирүзә, Актай кебек хатын-кызларның су кызлары, ягъни су асты дөньясы ияләре, Әхәтнең усал патша, Ирнең мактанчык һәм көчсез карт итеп тасвирлануының тирән мәгънәсе бар. Греклар үзләренә кадәрге төркиләрнең бөеклегенә сокланып карасалар да, хәзер инде алар өчен элекке хуҗалар куркыныч түгел. Хәзер алар лелегләргә көнләшеп тә карамыйлар, аларны изгеләштерергә дә җыенмыйлар. Чөнки аларны җир йоткан, алар су астында.

Диңгез буенда агач ат ясап калдырган ахейлар диңгез эчендәге Тенедос дип аталган кечкенә утрауда яшеренеп торалар. Греклар заманында Тенедоста Тен дигән аллага багышланган гыйбадәтханә була. Тен гыйбадәтханәсенә флейтачыларны (курайчыларны) кертмәгәннәр. Анда шулай ук Ахил исемен телгә алу да тыелган булган. Ахил, билгеле булганча, грек батыры. Троя өчен су-

гышта Ахил Гекторны җиңә һәм шулай итеп грекларга җиңү яулый. Гыйбадәтханәдә Ахил исемен телгә алырга ярамауның сәбәбен грек авторы Плутарх болай аңлата. Теннең үги анасы, ул мине көчләмәкче булды дип, үги улына яла яккан, имеш. Курайчы Молп, Теннең үги анасын яклап, ялган сөйләгән. Шуннан соң Тен дигән җегет үзенең сеңлесе белән бергә әлеге Тенедос дип аталган утрауга качып китәргә мәҗбүр булган.

Ахилның анасы Фетида дигән алиһә үзенең улына Тенне үтермәскә кушкан, чөнки Тен кояш алласы Аполлонның сөеклесе булган. Ләкин Ахил, Тенедос утравына басып кергәч, утраудагы Теннең сеңлесен күреп алган да куа башлаган. Сеңлесен яклап Тен Ахилның юлына аркылы төшкән. Ахил Тенне үтергән, ул арада Теннең сеңлесе качып котылган. Тен үтерелгән җирдә Тен гыйбадәтханәсе салынган, имеш. Менә шуңа күрә Тен гыйбадәтханәсенә курайчыларга керү дә, Ахил исемен телгә алу да тыела икән (Плу, I, 28).

Ахейлар батыры *Ахил* исемен без *Акыл* дип, *Тен* исемен *тән* дип беләбез. Теннең «Аполлонның сөеклесе» булуы аның чыннан да «төн» булуын раслый. Исән чакта ул Кояш алласының дусты (туганы) булса, үлгәч исә караңгылык дөньясының патшасы булып калган. «Төн»гә багышланган гыйбадәтханәгә курайчыларның кертелмәве дә, монда шулай ук «акылны» искә төшерергә ярамавы да аңлашыла — төнлә бар нәрсә йоклый, ял итә. Бу вакытта тавыш чыгару да, акылны эшкә җигү дә тыела.

Сүз уңаеннан әйтик, грек чыганакларында Алкей (Әлки), Аглей (Әгъли), Алфея, Даная (Әлфия, Дания), Талия (Талия), Давлий (Дәүли), Фаилл (Фаил), Эдип (Әдип) кебек исемнәр дә очрый.

### 10. ГОМЕР ДАСТАННАРЫ. «ОДИССЕЯ»НЫҢ СЮЖЕТЫ

Дастанда Троя сугышында катнашкан ахей кешесе Одиссейның туган иленә кайтышлый төрле хәлләргә юлыгуы һәм ахыр чиктә үзенең өенә, хатыны Пенелопа янына кайтып җитүе тасвирлана. «Одиссея» сюжеты «Алпамыш» сюжетына охшаш.

«Алпамыш» яисә «Алпамша» дастаны төрки халыкларның күбесендә бар. Дастан үзбәк вариантында тулырак сакланган. Үзбәктә ул «Алпамыш» дип атала. Татарда дастанның кайбер өзекләре генә исән, ул да булса әкият рәвешендә генә сөйләнелә. Академик В.М.Жирмунский: «Алпамыш» белән «Одиссея»ның сюжет мотивлары бер-берсенә шундый якын,— монда очраклы ох-

шашлык турында сүз булырга да мөмкин түгел. «Алпамыш» белән «Одиссея»ның сюжеты, күрәсең, борынгы әкият сюжетларының гомуми «Шәрык» вариантына кайтып каладыр»,— дигән фикер әйтә (Жир, 333 бит).

Без әлеге дастаннардагы охшаш моментларны санап чыгуны максат итеп куймыйбыз. Без бары бер-ике мәсьәләгә генә тукталып китмәкче булабыз.

Үзбәк вариантындагы «Алпамыш»ның кыскача эчтәлеге шуннан гыйбарәт. Коңгырат илендә Байбүре белән Байсары исемле ике бертуган би була. Картлык көннәрендә Байбүренең бер улы, бер кызы, Байсарының исә бер кызы туа. Байбүренең улына Хәким дип, кызына Калдыргач-аем, Байсарының кызына Барчин-ай дип исем кушалар. Көннәрдән бер көнне Байбүре белән Байсары бозылышып китәләр. Байсары, үзенең илен-көнен, малын-туарын алып, Коңгырат иленнән китеп бара һәм калмыклар җирендә торып кала.

Байбүренең улы Хәким белән Байсары кызы Барчин-ай ярәшелгән була. Үсә төшкәч Хәким яки Алпамыш үзенең кызын эзләп читкә чыгып китә. Күп батырлыклар эшли, төрле хәлләргә юлыга, җиде ел әсирлектә була һәм ахыр чиктә туган иленә кайтып, сөйгәне, ярәшелгәне Барчин-айга өйләнә.

Одиссей, әйтелгәнчә, Троя сугышында катнаша. Сугыштан соң туган иленә кайтырга чыга, диңгездә төрле хәлләргә юлыга һәм чит җирләрдә 20 ел бәрелеп-сугылып йөргәннән соң, туган утравы Итакага кайтып җитә, үзенең хатыны Пенелопага (яңадан) өйләнә.

Хәзер кайбер нәрсәләрне чагыштырып карыйк. Ярәшелгән кызын эзләп киткәндә Хәким-Алпамыш япь-яшь егет була. Аңа нибарысы 14 яшь. Барчин-айга да ундүрт яшь. Яшь җегетнең яшь кызны эзләп китүе, сөеклесе өчен батырлыклар эшләве,— адәм баласы өчен табигый хәл. Яшьлек үз юлындагы барлык киртәләрне җиңәргә һәм үз теләгенә ирешергә тиеш. Табигать законы шуны таләп итә. Одиссейның батырлыклары исә башка төрлерәк. Трояда ул үзенең сөйгәнен түгел, Еленаны коткару өчен сугыша. Өенә кайтканда эшләгән батырлыклары да башкачарак — мәхәббәт өчен түгел, үзенең җанын саклап калу өчен, исән калу өчен көрәшә Одиссей. Туган җирендә аны үз өе, үз хатыны һәм үзе югында туган улы Телемак көтеп тора. Ләкин кайтса, Одиссейның өен кияүләр камап алганнар. Тирә-яктан килгән батыр җегетләр Пенелопага өйләнмәкче булалар икән. Бу вакытта Пенелопага кимендә кырык яшьләр чамасы булырга тиеш, җитмәсә, аның буй җитдән — егерме яшьлек!— улы да бар.

Борынгы греклар өчен мондый хәл, бәлки, табигый саналгандыр. Ләкин «Алпамыш» дастаны күзлегеннән караганда, моны берничек тә табигый хәл дип исәпләп булмый. «Одиссея»ны иҗат итүче яки иҗат итүчеләр «Алпамыш»тан бик нык файдаланганнар, тик шулай да дастанның төп мәгънәсен аңламаганнар яисә аңлы рәвештә аны кабул итә алмаганнар. Төрки дастанда яшьлеккә, батырлыкка дан җырлана. Бу исә төркиләрнең тормыш, яшәеш һәм галәм турындагы мәңгелек дини-фәлсәфи карашларына барып тоташа. Гомер дастаны исә мондый фәлсәфәне чагылдыра алмый, киресенчә, бозып күрсәтә. Ике дастан арасындагы төп аерма, безнеңчә, менә шунда.

«Одиссея» дастанында нигезләнеп җитмәгән тагын бер йомшак момент бар. Тугызынчы җырда Одиссейның һәм аның юлдашларының бер күзле циклоплар утравында күргәннәре турында сөйләнелә. Яр буена якын җирдә, тау куышында бер күзле, бик зур гәүдәле циклоп яши икән. Көндез циклоп көтү көтә, кич көтүе белән бергә тау куышына кайтып куна икән. Одиссей белән аның юлдашлары циклоп үзе юк чагында бернинди максатсыз, бары кызык итеп кенә аның куышына кереп калалар һәм шунда төн кунмакчы булалар. Кич җитү белән циклоп көтүен куып кайта да куышка куалап кертә һәм куыш авызын бик зур таш белән томалап куя. Шул чакны хуҗа ят кешеләрне күреп ала һәм шундук боларның икесен тотып ашый. Троя батырлары куркуга төшәләр. Одиссей шунда бер хәйлә уйлап таба. Ул циклопны шәраб белән сыйлый. Шуның белән ул циклопның күңелен йомшартмакчы була. Циклоп аннан: «Исемең кем?» — дип сорый. Одиссей Беркем түгел (русча «никто») дип җавап бирә. Шәраб тәэсирендә циклоп изрәп йокыга киткәч, иптәшләре белән бергәләп Одиссей куыштагы бер юан агачның башын очлый да очланган агач башын утта кыздыра һәм кеше ашаучының бердәнбер күзен төртеп тишә. Авыртуга түзә алмыйча циклоп бик каты кычкыра башлый. Шул чакны бөтен тирәяктагы циклоплар җыелалар һәм ни булды, ник кычкырасың, әллә үтерәләрме? дип сораштыра башлыйлар. «Никто!» — дип үкерә циклоп тегеләргә җавап итеп. «Беркем түгел булгач, ник кычкырасың шулкадәр?» — диләр циклопның утраудашлары һәм берни аңламыйча таралышып бетәләр (Од, IX, 400—413).

Монда «Шүрәле»нең эчтәлеген сөйләп тормасаң да була дип уйлыйбыз. Тик «Шүрәле»дә батыр җегет үзенең исемен «Беркем түгел» дип түгел, «Былтыр» дип атый. «Кем кысты?» дигән сорауга «Былтыр кысты» дип җавап биргәндә бернинди логик мәгънәсезлек сизелми

сыман. Кемдер шүрәлене былтыр кыскан, имеш. Шүрәле шуны исенә төшергән дә кычкыра башлаган. Ләкин «Ни булды, үтерәләрме әллә?» дигән сорауга циклоп: «Никто! Но своей я оплошностью гибну; Никто бы силой не мог повредить мне»,— дип озын итеп аңлату белән шөгыльләнә икән инде — логикага төзәтеп булмаслык зыян килә. «Шүрәле»дә сорау да, җавап та кыска һәм аңлаешлы. «Одиссея»да соравы да, җавабы да таркау һәм буталчык. Дастан авторы «былтыр»ны «беркем түгел» мәгънәсендәге сүзгә алыштыруның отышсызлыгын үзе дә, күрәсең, яхшы аңлаган, ләкин «былтыр» белән сүз уйнату грек телендә мөмкин булмаган яисә «Одиссея»ны иҗат итүче төрки дастанны (риваятьне?) сүзгә-сүз кабатларга теләмәгән.

«Шүрәле»нең Урта диңгез бассейны илләрендә борынгы дөньяда билгеле булуы турында сөйли торган тагын бер факт бар. Хәзерге Италия җирендә, Кротонда (Каратунда?) борынгы заманнарда, имеш, Милон дигән бер көчле кеше булган. Урманда йөргәндә бу, имеш, бер башы ярык бүрәнәгә юлыккан. Үз көченә ирәгеннән артык ышанып, әлеге Милон бүрәнәне урталай ярмакчы булган һәм аякларын-кулларын ярыкка тыгып, көчәнә башлаган. Ләкин бүрәнә ярылмаган, ярыктагы чөй чыгып киткән дә, Милон, имеш, шунда кысылып калган. Бу хакта безгә үзенең «География» дигән китабында Страбон язып калдырган (С, VI, I, 12).

## 11. ТӨРКИ-ГРЕК УРТАКЛЫКЛАР ТУРЫНДА СӨЙЛИ ТОРГАН БАШКА ТӨР ФАКТЛАР (ЭТНОГРАФИЯ, МИФОЛОГИЯ, ФОЛЬКЛОР)

Бу темага карый торган материаллар шактый күп. Без инде аларның кайберләре белән танышып та киттек. Хәзер шуларның тагын кайберләрен теркәп узмакчы булабыз.

Кара диңгез буе скифларында һәм шулай ук урта гасыр төркиләрдә, борынгы Алтай кабиләләрендә үлгән хуҗа янына кабергә ат чалып салу йоласы була. Шундый ук йола б.э.к. II мең еллыкта борынгы Грециядә дә булган (Бла, 69 бит). Борынгы Грециядә ашлыкны махсус чокырларда саклаганнар. Шундый ук гадәт Идел буе болгарларында да булган. Борынгы Грециядә учак өй уртасында урнашкан, төтен чыгу өчен түшәмдә (түбәдә) төннек калдырылган. Күчмә төркиләрнең өендә учак һәрвакыт өй уртасында булган һәм түбәдә, учак турысында төтен чыгу өчен ачыклык калдырылган.

Геродот язганча, Спарта кешеләре тулы ай булмаса,

яу башларга ярамый дип исәпләгәннәр (Г, VI, 106). Шундый ук караш төрки сөннәрдә (хуннуларда) дә була. «Сугыш башлангач, йолдызларның һәм айның торышын күзәтәләр, тулы ай булса — һөҗүм итәләр, ай кими башласа — чигенәләр»,— диелә борынгы Кытай истәлекләрендә сөннәр турында (Тас, I, 41 бит). Теләсә нинди эшне айга карап эшләү — яңа ай башында эш башлау, иске ай башында тоткарланып тору гадәте татарда әлегәчә сакланып калган дип әйтергә була.

Аттика батыры Тесей турындагы мифларның берсендә әлеге батырның Синиид (Синид) дигән юлбасарны ничек итеп үтерүе турында сөйләнелә. Синид дигән юлбасар юлчыларны тотып ала икән дә, ике яктагы наратларны иеп, кешене агач башларына бәйләп куя икән. Шуннан соң наратларны ычкындырып җибәрә икән дә, үз корбанын урталай өздерә икән. Тесей юлбасарның үзен дә шулай ике аягыннан агач башларына бәйләп куйган да, иелгән агачларны ычкындырып җибәреп, урталай өздереп үтергән (МС, 235 бит). X гасырда төрки гузлар уйнашта тотылган кешеләрне нәкъ шулай җәзалап үтерә торган булганнар (Ибн, 61 бит).

«Канатлы ат» төркиләрдә дә, грекларда да була. «Канатлы ат» грекларда — Пегас дип, төркиләрдә (татарларда) Тулпар дип атала. Якут дастаннарында һәм якутлар ышануынча, атлар, гомумән, Күк уллары, ягъни канатлылар.

Борынгы грек мифларында Прокна һәм Филомена дигән бертуган кызларның кошка әйләнүе турында әйтелә. Татар әкиятләрендә дә кошка әйләнгән кызларны очратырга була. Мәсәлән, «Зөһрә» әкиятендә шундый хәл була. Татарның иң борынгы бәетләреннән исәпләнелгән Сак-Сок бәетендә кошка әйләнгән балалар турында сүз бара.

Грек мифларында әйтелгәнчә, Аргос патшасы Акриси үзенең кызы Данаяны җир асты зинданына ябып куя. Аның янына беркем кертелми. Ләкин тар гына ярыктан төшкән көн яктысы тәэсирендә Даная авырга кала һәм Персей исемле ир бала таба. Аргос патшасы Даная белән аның улы Персейне сандыкка салып диңгезгә ташлаттыра. Ана белән баланы балыкчы коткара. Төрки «Таһир-Зөһрә» дастаны да шундый ук сюжетка корылган.

Борынгы грекларның Афинадагы гыйбадәтханәсендә изге җылан яшәгән. Греклар аңа ай саен корбан биргәннәр. Афина шәһәренә Персия гаскәре һөҗүм итәр алдыннан изге җылан кинәт юкка чыга (Г, VIII, 41). Татарстанда Алабуга янындагы «шайтан каласы» дип аталган таш корылма болгарларның гыйбадәтханәсе булган дип уйланыла. Борынгы риваятьләрдә әйтелгәнчә, анда, имеш,

аждаһа яшәгән. Халык аңа табынган һәм корбаннар биргән. Монголлар һөҗүме алдыннан аждаһа шәһәрне ташлап киткән (Дәү, 135).

Борынгы грекларда кеше канын кою яман нәрсә саналган. Кеше үтергән кеше гөнаһлы була һәм үзенең гөнаһын юар өчен ул бирәр аллага багышланган алтарь янында махсус арыну йоласы башкарырга тиеш була. Татарда да шундый ук ышану бар. «Кан тота» дигән сүз турыдан-туры шуңа ишарәли. Кан коелган җиргә яткан, утырган кеше чирләргә мөмкин дип исәпләнелә.

Борынгы Грециядә Фокея кешеләре, Корсика утравына күченеп китәр алдыннан, Фокеядәге барлык кешеләр китәргә тиеш дигән карар чыгаралар һәм үз туган җирләренә кире кайтмаска булалар. Әйткән сүзләре үтәлсен өчен алар диңгезгә тимер кисәге ташлыйлар һәм шушы тимер су өстенә калкып чыкмаенча торып Фокеягә кире кайтмаячакбыз дип ант итәләр (Г, I, 165). 985 елда рус кенәзе Владимир Идел буе болгарларына яу белән килә. Ахырда ике арада солых килешүе төзелә. Болгарлар: «Безнең арада иминлек юкка чыкса, таш суда йөзә башлар, колмак суга батар»,— дип ант бирәләр (Шпи, 107 бит).

Халык уеннары, төрле ярыш, уен төрләре күп халыкларда очрый. Әмма оешкан төстәге халык уеннары һәм спорт ярышлары «сабан туе» рәвешендә бары тик казан татарларында гына сакланып калган. Башка халыкларның халык уеннарында мәҗүсилек чоры йә булмаса соңгырак чор диннәренең тәэсире нык сизелә. Сабан туе уеннары да элегрәк, әлбәттә, дини эчтәлекле булган, әмма бүгенге көндәге сабан туйлары бик борынгы спорт уеннарының бер калдыгы сыман тоела. Сабан туендагы спорт уеннарына охшаш уеннар борынгы грекларда да булган. «Илиада» дастанында Патрокл үлгәннән соң оештырылган спорт ярышлары турында без искә алдык инде. Бу уңайдан грекларның Арголидада, Немей үзәнендә җәй уртасында уздырыла торган Немей уеннарын һәм шулай ук Элидада, Олимпия шәһәрендә, Алфея елгасы буенда Зевс хөрмәтенә дүрт елга бер мәртәбә уздырыла торган Олимпия уеннарын искә төшерергә була.

## 12. КРИТ ЦИВИЛИЗАЦИЯСЕ. МАТЕРИАЛЬ КУЛЬТУРА. ЭЛЕМТӘЛӘР

Критта шәһәр төзелеше б.э.к. III меӊ еллык ахырларында һәм II меӊ еллыкның беренче гасырларында башлана. Б.э.к. 1900 елларда Кнос, Фест, Маллия, Като-Закро шәһәрләрендә беренче сарайлар барлыкка килә. Шул

ук вакытта Крист осталары чүлмәк савыт-саба ясауда, металлургиядә, сәнгатьтә зур осталыкка ирешәләр. Урта Миной чорының башлангыч гасырларында, б.э.к. 2000 еллар элек, Критта дүрт тәгәрмәчле арбалар барлыкка килә. Шумерда, Мисырда һәм Критта җир эшкәртүдә сабан куллану б.э.к. III мең еллык уртасында башлана.

Легендар Минос патша вакытында Критта һөнәрчелек бик нык алга китә. Монда пычак, ышкы, шакул («отвес»), бораy, җилем уйлап табыла. Критта табылган һәм ташка уеп ясалган сурәтләрдә мачталы һәм реяле, җилкәнле көймә рәсемнәре бар. Борынгы грек авторлары җилкәнне Прометей, Дедал һәм кар диңгезчеләре уйлап тапкан дигән фикерләр әйтәләр. Җилкәннәр ак һәм кара төстә булган. Кноста табылган бер басмада (мөһердә) көймә, ишкәкчеләр һәм ат рәсеме төшерелгән. Хайваннарны көймәгә төяп йөртү турында сөйли торган иң беренче мәгълүматларның берсе бу (Пе, 167 бит). «Ясмык сыман таш басмадагы тау-тәкәнең рәсеме искиткеч нәфис итеп ясалган»,— дип яза инглиз галиме Дж.Пендлбери ташбасмаларның берсе турында (Пен, 162 бит). Кнос сараеның патша тәхете урнашкан зал стенасына ятып торган ике грифон — ярым бөркет, ярым арыслан кыяфәтле мифик хайваннар рәсеме төшерелгән була.

Геродот язганча, Кнос патшасы Минос күрше утрауларны яулап ала, диңгез пиратларын юк итә һәм бөтен диңгездә хакимлеккә ирешә. Диңгездә курыкмыйча йөзү өчен, әлбәттә, төрле зурлыктагы сәүдә һәм сугыш көймәләре кирәк була. Боларның барысын да һөнәрчеләр, балта осталары эшләгән. Диңгездә хакимлек урнаштыру ул көймәдә йөзү осталыгының артуы һәм чит илләр, чит халыклар белән мөнәсәбәтләрнең көчәюе турында сөйли. «Җир шары түгәрәк дигән, җирне төрле яктан Океан елгасы әйләндереп алган дигән карашның барлыкка килүендә Эгей диңгезчеләренең роле чиксез зур... Диңгезне үзләштерүдә Эгей диңгезчеләре иң беренчеләрдән булганнар дигән карашны кире кагуы җиңел түгел»,— дип яза Ю.К.Поплинский (Поп, 45).

Критта һәм Эгей диңгезенең бүтән утрауларында бүгенге көн археологлары Мисырда һәм Кече Азиядә эшләнгән әйберләр табалар. Шул ук вакытта Африканың, Европаның, Азиянең төрле төбәкләрендә Крит әйберләре табыла. Мәсәлән, Сардиния утравында Критныкына охшаш ике яклы балта табылган. Сардиниядәге Нурага культурасына хас кеше сыннарында Крит культурасын хәтерләткән сыйфатлар бар. Крит белән борынгы Испания арасында да элемтәләр көчле була. Бу элемтәләр б.э.к.

III мең еллыкларда ук башлана. Б.э.к. 3000—2700 елларда Крит кешеләре Пиреней ярымутравындагы рудникларны эшкәртүдә катнаша башлыйлар. Британия утрауларында — Темзадан төньяктарак Миной чорыныкына охшаш чынаяк муенсалар, хәнҗәрләр, алтын касәләр табылган. Шул ук вакытта Критта һәм Грециянең Миной чоры каберлекләрендә Балтик буе гәрәбәләреннән эшләнгән әйберләр табыла. Миной чоры сарайларының стеналарында юлбарыс, маймул һәм оча торган балык рәсемнәре күрергә була. Бу исә Крит кешеләренең Көнбатыш Африка кешеләре белән сәүдә мөнәсәбәтләре урнаштырулары һәм аларның экваторга кадәр барып җитүләре турында сөйли. Критта эшләнгән әйберләрне археологлар Месопотамия җирендә дә, ерак Һиндстан якларында да табалар.

Ю.К.Поплинский Төньяк Африкадагы бәхәсле гарамантлар мәсьәләсен Крит цивилизациясенә бәйле рәвештә аңлата. «Гарамантларның сугыш арбалары мисырлыларның сугыш арбаларына охшамаган; алар гаҗәеп дәрәҗәдә Эгей (аерым алганда, Крит) арбаларына охшаганнар»,— дип яза автор (Поп, 200 бит). «Аларның (ягъни гарамантларның.— *Н.Ф.*) иң ерак эзләре Нигер һәм Чад якларына җитеп юкка чыга. Аларның юллары «гарамантлар юлы» буенча дәвам итә; шушы юлның як-ягындагы кыяларга алар үзләренең сугыш арбаларының һәм атларының сурәтләрен ясап калдырганнар», ди шул ук автор (Попл, 206 бит).

Крит һәм Мисыр арасында да элемтәләр көчле була. «Криттагы неолит чоры халкы арасында Төньяк Африка элементлары да бар. Аларның билбауларын һәм җенес әгъзалары футлярларын, шулай ук сигез кырлы калканнарын Ливиядә һәм династияләр чорына кадәрге Мисыр [сурәтләрендә], күрергә була»,— ди Дж. Томсон (Том, 173 бит). «Диңгез ярының иң якын өлеше турыдан-туры материктагы Грециягә һәм Эгей диңгезе утрауларына карап торса да, Кнос халкының тышкы элемтәләре ерак көньяктагы Мисырга һәм көнчыгыштагы Азиягә юнәлтелгән булган»,— дип яза Резанов (Ре, 51 бит). «Б.э.к. III—II мең еллыклар дәвамында Критның һәм Мисырның үзара аралашып яшәве археология тарафыннан исбат ителә һәм бу хәзер билгеле нәрсә булып исәпләнелә»,— ди Никулина (Ни, 137 бит).

Шулай итеп, Крит цивилизациясе кешеләре борынгы дөньяның якындагы һәм еракта гы барлык илләре, барлык халыклары белән даими рәвештә аралашып яшәгәннәр дип әйтә алабыз.

## 13. КРИТ ҺӘМ КЕЧЕ АЗИЯ

Күп галимнәрнең фикеренчә, җирдә беренче цивилизация учагы иң элек Кече Азиядә кабынган. «Дөньяда беренче булып монда игенчелек һәм терлекчелек, авыллар һәм шәһәрләр, әдәбият һәм фән барлыкка килгән»,— ди немец галиме Бурхард Брентьес (Бре, 3 бит). Моннан ун мең еллар элек хәзерге Палестинада утрак тормышта яшәүчеләрнең таш коймалар белән ныгытылган калалары барлыкка килә. Археологлар казып чыгарган шундый калаларның берсендә — Иерихонда — өч мең чамасы кеше яшәгән. Бер-берсенә сыенып утырган һәм яндырылган кирпечтән салынган куышларның нигезе түгәрәк. Учак өйнең уртасында. Иерихон кабиләләрендә баш сөягенә табыну йоласы була. Баш сөягенә табыну күп халыкларга хас. Бу йоланың калдыклары, мәсәлән, Кара диңгез буе скифларында. Төньяк Кытай һәм Монголия сөннәрендә була.

Кешенең баш сөяген гипс белән катырып ясалган маска-портретлар Палестинаның башка төбәкләрендә дә (мәсәлән, Тель-Рамадта) табыла. Мондагы табылдыклар б.э.к. VII мең еллык ахырына карый. Шунда ук спираль сыман рәсемле балчык басма да (мөһер дә) табыла.

Борынгы Мисырда керамикада спираль рәсеме б.э.к. V—IV мең еллыкларда ук кулланыла башлый. Спираль рәсеме Крит-Эгей культурасына да хас. Төрле бизәк-орнаментларда, чүлмәк савыт-сабаларда спираль рәсемнәрен күрергә була. Мәсәлән, Фестта табылган һәм б.э.к. 1800 елларда эшләнелгән полихромлы кувшин савытта спираль рәсемнәре бар. Б.э.к. III мең еллыкта эшләнелгән һәм Аморгоста табылган савытның капкачы һәм корсагы спираль орнаментлар белән бизәлгән. Шулай итеп, Иерихон, Мисыр һәм Крит кешеләре бик борынгы заманнарда кояшка табынганнар дип әйтә алабыз.

Крит цивилизациясе Кече Азия цивилизациясе тәэсирендә барлыкка килгән, диләр галимнәр. «Неолит чорында (б.э.к. 4000—3000 еллардан элегрәк) Крит утравына культура ягыннан Көньяк-Көнбатыш Анатолия һәм Сирия халыклары белән тыгыз бәйләнештә торган кабиләләр күченеп киләләр»,— ди Дж. Пендлбери (Пен, 294 бит). Соңгырак чорларда (мәсәлән, б.э.к. 3000—2200 еллар арасында) Критка һәм башка утрауларга Кече Азиядән ниндидер сәбәпләр аркасында үз илләрен ташлап китәргә мәҗбүр булган кешеләр килеп урнаша. Кыскасы, Критның Кече Азия белән туганлык элемтәләре нык һәм дәвамлы булган. Әлеге фикер ышанычлырак булсын өчен без тагын кайбер белгечләрнең фикерләрен теркәп узмакчы булабыз.

«[Крит] өйләренең бер үзенчәлеге шунда — аларда кызыл балчыктан яисә вак ташлардан ясалган даими учак була. Учак өйнең йә уртасына, йә берәр стена янына урнаша. Әүвәлге бронза чорындагы Кече Азиядә, Грециядә мондый учаклар булуы күптән билгеле» (Пен, 54 бит). «Криттагы барлык сарайлардагы кебек үк, Кнос сараеның төзелеше белән борынгы Анатолия төзелеш традицияләре арасында охшашлыклар булуы бернинди бәхәс тудырмый»,— ди Никулина (Ни, 136 бит). «Крит керамикасы белән Анатолия керамикасы арасында гаҗәеп охшашлык күзгә ташлана»,— ди Пендлбери (Пен, 57 бит). «Кнос һәм Мари сарайларының композициясе һәр ике очракта да үзенчәлекле хәл ителсә дә, аларның төзелешендә искиткеч охшашлыклар булуы таң калдыра»,— ди Никулина (Ни, 135 бит).

Крит культурасы белән Чатал-Гуюк, Хасилар, Халаф һ.б. культуралар арасында да охшашлыклар бар. Мәсәлән, Чатал-Гуюк — Крит уртаклыклары (б.э.к. 5800 еллар) турында Б.Брентьес болай ди: «Бербөтен рәвешендә сурәтләнгән кеше фигураларының хәрәкәтчәнлегенә һәм сабыйларча реализмга гаҗәпләнми мөмкин түгел. Ул заманның рәссамнары бер фигураны икенче фигура белән капламаска тырышканнар, ләкин аларның төрле хәрәкәтләрне чагылдыру ысуллары Кече Азиянең һәм Мисырның соңгырак чор сәнгатендә кабатланмый. Бу чор рәсем сәнгатенә б.э.к. II мең еллыктагы Критның Миной чоры рәсемнәре якынрак тора» (Бре, 77 бит).

Крит һәм Кече Азия кешеләренең дини карашлары да бер үк төсле булган. «Миной диненең иң үзенчәлекле символлары — багана, ике яклы балта һәм үгез мөгезе, ә иң әһәмиятле хайваннары һәм кошлары — җылан, күгәрчен һәм үгез. Боларның барысының да чыгышы — Анатолиядән»,— ди Томсон (Том, 248 бит). «Барлык гыйбадәтханәләргә диярлек куелган йола баганалары тагын да ныграк стильләштерелгән; баганаларның як-ягына бер пардан алып ун парга кадәр үгез башы сөякләре беркетелгән. Мондый баганалар утыртып кую Анатолиядә һәм Критта б.э.к. II мең еллыкка кадәр дәвам итә һәм алар Миной чоры гыйбадәтханәләре алгы ягына урнаштырылган була» (Бре, 85, 86 битләр). «[Чатал-Гуюкта] V катламда табылган гыйбадәтханәнең төп рәсемнәре безне тагын Криттагы Миной чорын искә төшерергә мәҗбүр итә. Ике метр чамасы озынлыктагы кызыл үгезне кешеләр уратып алганнар. Алар бииләр. Бер кеше үгез сыртында сальто ясый. Критта үгез сыртында сикерү дини спортның бер төре исәпләнелгән. Мондый спорт

төре киң таралган була. Бу уен һиндстанга һәм Кытайга кадәр барып җитә» (Бре, 78, 79 битләр).

Шулай итеп, Критның Кече Азия культуралары белән элемтәләре ерактан һәм тирәннән башлана. Чынлыкта аның кайчан башлануы да билгеле түгел. Бу очракта башлану турында сөйләү дә урынсыз кебек. Крит цивилизациясен тудырган халык ул Кече Азия цивилизациясен тудырган халыкның бер өлеше, бер тармагы. Монда шуны да әйтергә кирәк, хәзерге Төркиядәге Чатал-Гуюк, Хасилар, Халаф һ.б. культуралар Тигр һәм Евфрат елгалары үзәнендә моннан биш-алты мең еллар элек барлыкка килгән Шумер цивилизациясеннән дә, Африкадагы Нил елгасы буенда барлыкка килгән Мисыр цивилизациясеннән дә берничә мең елларга борынгырак.

## 14. КРИТ-ТӨРКИ УРТАКЛЫКЛАР. ЭТНОГРАФИЯ. ТЫШКЫ КЫЯФӘТ

Борынгы Крит кешеләрен чагылдырган рәсемнәрдә ирләрнең дә, хатын-кызларның да озын итеп үрелгән чәч толымнарын күрергә була. Үрелгән чәч толымнары яшьләргә, сугышчыларга һәм югары дәрәҗә кешеләренә генә хас булган, ахрысы.

Чәчне озын толымнарга үреп йөрү гадәте төрки халыкларда соңгы вакытларга кадәр сакланып килә. Борынгы Алтай төрекләре (ирләр) чәчләрен озын итеп йөрткәннәр. Көньяк Себер халыклары — алтайлылар, хакаслар, тувалар, тофалар шулай ук чәчләрен үреп йөрткәннәр. (Ирләр һәм хатын-кызлар турында сүз бара.) Төрки телеутларның ирләре XX гасырның утызынчы елларына кадәр чәчләрен озын итеп үреп йөрткәннәр.

Җидесу территориясендә табылган һәм борынгы төрки чорларга карый торган таш сыннар арасында чәчләре толымлап үрелгән ир сугышчы сыннары бар. Кыпчакларның таш сыннарын җентекләп өйрәнгән С.А Плетнева ирләрне һәм хатын-кызларны чагылдырган таш сыннардагы чәч толымнарының өч төрен күрсәтә. Кыпчак сыннарында бер толымлы һәм өч толымлы үремнәрнең төрле вариантлары бар (Плетн, 30 бит, рәсем 9).

XIII гасыр болгар-татар шагыйре Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәрендә тасвирланганча, Йосыфның чәчен Зөләйха унике толымга үрә. Кнос сараенда табылган һәм б.э.к. 1600 елларга карый торган рельефта башына таҗ кигән яшь ир кешенең дә унике толымы бар.

Бик борынгы заманнарны күз алдында тотканда, төркиләрдә сакал-мыек йөртү бары аллаларга һәм патшаларга гына дөрес дип исәпләнелгән. Татар телендәге «сакал»

сүзе шуңа ишарәли. Ләкин «кая барсаң да, кара сакалың артыңнан калмас» дигән әйтем-мәкальдә «сакал» бәхетсезлек чыганагы сыман булып аңлашыла. Мәкальнең мәгънәсе: ярлы, бәхетсез кеше кая барса да, нишләсә дә ул барыбер ярлы һәм бәхетсез булып калачак дигәнгә туры килә. Бүгенге күзлектән караганда, мәкальдә хата бар. Сакал, гадәттә, арттан «йөрми», алдан «йөри». Ләкин элегрәк ияк очындагы сакал гына түгел, ирләрнең аркага салынып торган чәч үремнәре дә, күрәсең, *сакал* дип аталган. Кнос сарае фрескалары арасында кулына сөңге тоткан, озын чәч толымнары аркасына салынып төшкән яшь сугышчы рәсемнәре дә бар. Арттан ияреп йөрүче «кара сакал» турындагы мәкальдә нәкъ менә шундый яшь сугышчыларның зары чагылгандыр кебек. Бит сугышчы, кая гына бармасын, кемгә генә буйсынмасын, барыбер сугышчы булып кала һәм аның язмышын бик үк куанычлы дип әйтеп булмый. Сакаллы сабый сүзе дә элегрәк олы яшьтәге кешегә карата түгел, бәлки менә шундый яшь, тәҗрибәсез сугышчыларга карата кулланылгандыр сыман.

Крит-төрки уртаклыклары турында сөйләгәндә хатын-кызларның өс-баш киемнәренә дә тукталмыйча булмый. Критта һәм башка утрауларда табылган сыннар арасында алиһәләр аеруча игътибарга лаек. Аларның түшләре ачык, күлмәк итәкләре киң, башларында — хикмәтле баш киемнәре.

Б.э.к. II мең еллык урталарында иҗат ителгән дип уйланылган һәм Кнос сараенда табылган бер алиһәнең баш киеме конусны хәтерләтә. Алиһә кулларына дуга сыман бөгелгән җылан тоткан (Со, 58). Б.э.к. 1600 елларда иҗат ителгән дип уйланылган икенче бер алиһәнең дә башында конус сыман баш киеме бар. Бу алиһәнең кулында берни юк (Со, 59). Икенче бер алиһәнең баш киеме яхшырак сакланган. Конус сыман баш киеме өч бүлемнән тора. Иң өстә сары шар сыман нәрсә калкып күренә. Шартлы рәвештә «Париж кызы» дип аталган, иреннәренә кызыл сөрткән купшы хатын-кызның да баш киемнәре калку (Со, 47).

Шундый ук баш киемнәрен хәтерләткән һәм өскә таба очлаеп менгән калку баш киемнәрен без кыпчак хатын-кызларының таш сыннарында да күрә алабыз (Плетн, 39 бит, рәс. 14, табл. 1, 3, 4). Казан татарларының хатын-кызлары XIX гасырга кадәр нәкъ менә шундыйрак биек, очлы баш киемнәре кигәннәр. «Моннан 30 еллар элек татар хатын-кызлары ефәк тукымадан тегелгән һәм башлы шикәр сыман... баш киемнәре кигәннәр... Бу озын конусның очында алтын төсле төймә булган»,— дип язган XIX гасыр башларында К.Фукс (Маза, 66 бит). Кайбер

элекке рәсемнәрдә, гравюраларда сакланып калган татар хатын-кызлары рәсемнәрендә конус сыман баш киемнәре күрергә була. Мәсәлән, «Сөембикә портреты» дип аталган картинадагы утырып торган яшь хатын сары төстәге ефәктән тегелгән һәм очлаеп торган баш киеме кигән.

Кноста табылган һәм б.э.к. 1600 елларда иҗат ителгән, ике кулына да берәр җылан тоткан, җиде кат бала итәкле күлмәк кигән алиһәнең баш киеме киң кырыйлы беретны хәтерләтә (Со, 60—63). Кыпчак хатын-кызларының таш сыннарында да шундый ук баш киемнәре бар (Плетн, 39 бит, рәс. 14 [8, 6, 7]).

Крит кешеләренең тышкы кыяфәте Урта диңгез буе тибы дип аталган типка туры килә. «Барлык баш сөякләре аермачык рәвештә озынча тар битле долихоцефаль типка карый»,— дип яза археолог Дж. Пендлбери Крит кешеләренең баш сөякләре турында (Пен, 62 бит). Крит кешеләрен сурәтләгән рәсемнәр дә бу фикерне раслый.

Төрки халыклар арасында монголоидлар да, европеоидлар да бар. Европеоид төркиләр, борынгы Крит кешеләре кебек үк, Урта диңгез буе тибына карыйлар. Уйгурларның бик зур күпчелеге тышкы кыяфәтләре белән һичшиксез, европеоидлар дигән фикер әйтәләр И.А.Чебоксарова белән Н.Н.Чебоксаров (Чеб, 169 бит). «Караимнар европеоид расаның көньяк тармагын тәшкил иткән Урта диңгез буе тибының Кече Азия яки әрмән типларының берниндн тәэсире булмаган вәкилләре исәпләнеләә»,— ди В.П.Алексеев (Ал, 524 бит). «Идел буе татарларының антропологик нигезен европеоид тип тәшкил итә: сомотологик мәгълүматлар нигезендә бу типны понт (Урта диңгез буе.— *Н.Ф.*) тибы дип әйтергә була»,— ди Алексеев (Ал, 242 бит). Т.А.Трофимова исә: «...Урта Идел буе татарлары беркадәр монголоидлык катнашмасы булган европеоид төркем тәшкил итәләр»,— ди (Тро, 28 бит).

### 15. БОРЫНГЫ УРТА ДИҢГЕЗ БУЕ ИЛЛӘРЕНЕҢ ТОПОНИМИЯСЕ

Ахей кабиләләре Крит утравына б.э.к. XIV гасырда үтеп керә башлыйлар дип уйланыла. Б.э.к. III гасырда утрауны грек телле дори кабиләләре басып ала. Б.э.к. 67 елда Критны римлылар яулап алалар. 395 елда Рим империясе ике өлешкә бүленгәч, Крит утравы Көнчыгыш Рим империясе ягында кала. Көнчыгыш Рим империясен икенче төрле Византия дип тә атыйлар. 823—961 елларда утрауга гарәпләр хуҗа була. 1204 елда Критны тәречеләр басып алалар һәм шул ук елны яңа биләмәләрен Византиягә саталар. 1669 елда утрауны госман-

лы-төрекләр яулап ала. 1898 елдан башлап Критка автономия хокукы бирелә. Балкан сугышларыннан соң, 1913 елда Крит утравы Грециягә кушыла.

Шул рәвешчә, Крит утравында дүрт-биш мең еллар дәвамында бер-ике генә халык хаким булмаган кебек, анда яшәгән халыклар да этник яктан бер генә төсле булмаганнар. Шуңа күрә утраудагы географик атамаларның ни дәрәҗәдә борынгы булуын һәм кемнәр хакимлеге чорында барлыкка килүен билгеләве бик җиңел түгел. Монда төрле чорлардан, төрле халыклардан калган атамалар табылырга мөмкин. Шул ук вакытта географик атамаларның озын гомерле булуын да истән чыгарырга ярамый. Кайбер географик атамалар, яңа хуҗалар теленә яраклашып һәм беркадәр үзгәрешкә кереп, шулай да төп кыяфәтләрен югалтмаган хәлдә, гасырлар буена яшиләр.

Бүгенге Крит утравында Газан елгасы (35)*, Топлу (355), Тузла (377) авыллары бар. Бу исемнәрнең өчесе дә төрекчә әйтелештә формалашкан. Шуңа күрә Газан, Топлу, Тузла атамаларын борынгы заманнарда түгел, бәлки төрекләр хакимлеге чорында барлыкка килгән төрки исемнәр дип уйларга мөмкин. Дөрес, аларның борынгы чорларда барлыкка килеп соңыннан төрекләшкән булуы да ихтимал. Мәсәлән, әйтик, Газан атамасы кайчандыр Казан булып та, соңыннан төрекчә әйтелештә Газанга әйләнгән дип уйласак, монда бернинди кеше ышанмастай нәрсә юк. Ләкин шулай да бу бары бер фараз гына.

Крит картасында әлеге атамалардан тыш күп кенә төрки һәм төркигә охшаш борынгы исем-атамалар очрый. Аларның ни дәрәҗәдә төрки һәм ни дәрәҗәдә борынгы булуын бүгенге Идел-Урал буендагы төрки атамалар белән чагыштырып белә алабыз. Мәсәлән, Критта Аксос (34), Багали (338), Катарос (34), Кундуро (60), Купо (309), Куртес (320), Магаса (44), Матала (310), Саба (307), Самария (42), Сикия (38), Сулия (41) дигән атамалар бар. Хәзер үзебезнең якларга әйләнеп карыйк. Казан ханлыгы чорында Акса (Черны, 284, 290, №№ 13, 151), Татарстанда, Башкортстанда Бакалы, Башкортстанда Катарыш, Татарстанда Кондырлы, Башкортстанда Купай, Курташ, Магаш, Татарстанда Макса, Башкортстанда Мәтеле елгалары, авыллары, Идел бассейнында Самара елгасы, Татарстанда Саба, Сикия, Сүлә авыллары бар.

Борынгы Урта диңгез бассейны илләрендә, аеруча Гре-

---

* Крит топонимиясенә мисаллар Дж. Пендлберинең инглизчәдән русчага тәрҗемә ителгән «Крит археологиясе» (Археология Крита, М., 1950) китабыннан күчерелде. Җәяләр эчендә әлеге китап бите күрсәтелә.

ция, Италия һәм Кече Азия җирләрендә, безнең яктагы топонимик атамаларга яки татар телендәге кеше исемнәренә тәңгәл атамалар тагын да күбрәк. Монда шуларның кайберләрен теркәп узабыз. Борынгы топонимия башлыча Страбонның «География»сеннән күчерелә. Җәя эчендә китап бите күрсәтелә.

Ака, Финикиядәге Птоломаида шәһәренең борынгы исеме (С, 701). Башкортстанда Ака елгасы, Олы Ака, Кече Ака авыллары бар.

Атрак, Фессалиядәге тау (303). Әтрәк татарда ир кеше исеме; Татарстанда Әтрәкле авылы да бар.

Биса, Элидадагы чишмә (339). Башкортстанда Бисә елгасы бар.

Зелия, Троя илендәге, Ида тавы итәгендәге шәһәр (517). Татарда Зәлия — хатын-кыз исеме.

Исмен, Беотиядәге елга (380). Татарстанда Ишман суы бар.

Кабалида, Фригиядәге өлкә (390). Ида монда грекча өлкә дигәнне белдерә. Татарстанда Кәвәл авылы бар.

Кабир, Фригиядәге тау (499). Татарда Кәбир — ир кеше исеме.

Каны, Этолиядәге шәһәр; Каны, Кана, Лесбос утравында борын (422, 544). Башкортстанда Кана елгасы, Татарстанда Кан елгасы бар.

Капр, Фригиядәге елга (541). Татарстанда Кәпәр елгасы бар.

Караны, Диңгез буе Каппадокиясендәге шәһәр (525). Татарстанда Каран елгасы, Каран күле бар.

Кармал, Бөек Каппадокиядәге елга (505). Татарстанда Кармалы авылы бар.

Керкетей, Самос утравындагы тау (464). Татарстанда Керкәле елгасы һәм авылы бар.

Ком, Кельтикадагы шәһәр (184); Альп тавы итәгендәге күл (193). Татарстанда Ком елгасы бар.

Команы, Бөек Каппадокиядәге шәһәр (491). Татарстанда Коман елгасы бар.

Куралий, Фессалиядәге елга (415). Башкортстанда Куралы елгасы бар.

Мамай, Трифилиядәге елга (326). Татарстанда Мамай суы, Мамай сызасы елгасы бар.

Писа, Италиядәге шәһәр (204); Элидадагы чишмә (339). Татарстанда Пичә елгасы бар.

Салмона, Фессалиядәге шәһәр һәм чишмә (339). Татарстанда Салман елгасы, Салман авыллары бар. Татарда Сәлман — ир кеше исеме.

Сарн, Кампаниядәге елга (229); Сарний, Азиядәге (ягъ-

ни Кече Азиядәге) елга (483). Татарстанда Саран, Сарана, Саранай елгалары бар.

Сепиада, Магнесиядәге шәһәр (307); Сепиада, Сепия, Фессалиядәге борын (307).— Ада монда «утрау», «өлкә» дигәнне белдерә. Татарстанда Сәпәй авылы бар.

Сида, Памфилиядәге шәһәр (534). Татарстанда Сиза авылы бар.

Симеф, Сицилиядәге елга (246). Татарстанда Симет елгасы бар. Борынгы исем-атамаларда *т* һәм *ф* тартыклары бер-берсен алыштырып килә алалар. Мәсәлән, Тесей да, Фесей да дип язылa. Латиннарның Сатурн дигән алла исеме татарча Сафура дигән хатын-кыз исемендә саклана. Татарча «Сафура бураннары» дигән әйтем дә бар. Монда Сафура хатын-кыз түгел, бәлки алла.

Солы, Киликиядәге шәһәр (369). Татарстанда Сыла (Солы) суы, Олы Солабаш авылы бар.

Тарс, Киликиядәге шәһәр (126); Тарсий, Троя илендәге елга (550). Татарстанда Тарса елгасы бар.

Тартесс, Иберияддәге елга һәм шәһәр (145). Башкортстанда Тартыш авылы бар.

Тенар, Лакониядәге борын (124). Татарстанда Тинәр елгасы бар.

Тибр, Италиядәге елга (203). Башкортстанда Тибел, Татарстанда Тимер елгалары бар. Бер очракта р белән л, икенче очракта б белән м бер-берсен алыштырып килә.

Эси, Италиядәге елга һәм шәһәр (205). Татарстанда Әче елгасы бар.

Этна, Сицилиядәге тау (27). Татарстанда Әтнә авыллары бар.

Урта диңгез бассейны илләренең борынгы топонимиясендә төрки яисә төркигә охшаш исем-атамаларның башка төрләре дә мәгълүм. Мәсәлән, берничә атама «бөек», «изге» мәгънәсендәге *гали* иҗекләренә башлана. Шундыйларның берсе Галикарнас белән без инде таныш. Македониядәге бер елга Галиакмон (301), Беотиядәге бер шәһәр Галиарт (22) дип аталган. Татарстанда Акман, Арт елгалары бар. Гали төшеп калган.

Күп кенә борынгы исем-атамалар *әй (өй)* сүзенә тәмамлана. Мондый исем-атамалар, гадәттә, «фәләннең өе, торагы (шәһәре)» дигәнне белдерә. Троя илендә агач-таш белән сәүдә итә торган бер базар Аспаней дип аталган (569). Татарда Әсфән — ир кеше исеме. Вифиниядә (528), Мидиядә (486), Сириядә (253) Апамея, Сириядә Баланея (698), Аравиядә Минея (711) дигән шәһәрләр булган. Татарстанда Балан, Баланлы елгалары, Балан-Бүләк, Баландыш, Баланлы авыллары, Мина елгасы бар.

Борынгы топонимиядә *улы-олы* иҗекләренә тәмамланган исем-атамалар да очрый. Италиядәге вольсклар шәһәре Апиола (216) дип, Валери юлы буендагы шәһәрләрнең берсе Карсеолы, икенчесе Кукул (222) дип аталган. Геродотта Ибанолли дигән ир кеше исеме дә телгә алына (Г, Y, 35). Билгеле булганча, бүгенге татар исемнәренең «кайберләре улла рәвешендә тәмамлана. Мәсәлән, Вәлиулла, Галиулла. Борынгы грекларда һәм аларның элгәреләре төркиләрдә Ибан һәм Ибанулла дигән кеше исемнәре дә булган икән дип әйтергә туры килә. Исем-атамалар турында сүз чыккач, тагын бер-ике мисалга тукталып китәсе килә. Страбон һәм Геродот заманнарыннан да борынгырак чорны чагылдырган Библиядә шулай ук безгә таныш исем-атамалар күреп гаҗәпкә каласың. Мәсәлән, Иезекил китабының XXVII бүлегендә Ибанга якын Иаван атамасы очрый (Хр. ДВ, 301 бит). Ибан-Иван исеме элегрәк татарда да булган, ахрысы. Мәрҗани язганча, XVII гасырда Кәче авылында Иванай дигән кеше ахун булган (Мәр, 233 бит). Иезекил китабының шул ук XXVII бүлегендә төркиләрдә киң таралган Саба, Тубал, Узаль (Гүзәл?) дигән исемнәр очрый. Б.э.к. XIII гасырда Мисыр патшасы Рамсес II гаскәрләре белән хетлар арасында, хәзерге Сириянең төньягында, Оронт елгасы буенда сугыш була. Хетлар җиңелә. Бу сугышны, гадәттә, Кадеш янындагы сугыш дип атыйлар. Сириянең төньягындагы бер шәһәр-дәүләт шулай Кадеш дип аталган. Кадеш грекча әйтелештәге һәм язылыштагы шәһәр, ахрысы. Кадешның әүвәлге исеме — Кинза. Бүгенге Татарстанда Кадыш яисә русча әйтелештә Кадышево дигән ике авыл бар. Аларның берсе рус авылы, икенчесе — мукшыларныкы. Ләкин Мәрҗани язганча, Кадыш элек, Казан ханлыгы чорында, татар авылы булган (Мәр, 400 бит).

### 16. КРИТ-АТЛАНТИДА ҺӘЛАКӘТЕ ТУРЫНДАГЫ ИСТӘЛЕКЛӘР

Крит-Атлантида дәүләтенең көчле вулкан атылу нәтиҗәсендә юкка чыгуы кешелек хәтереннән мәңгегә җуеп ташланмаган. Бу турыда Платон язмаларыннан һәм археологлар казып чыгарган борынгы шәһәр, сарай калдыкларыннан башка бүтән төрле фактлар да билгеле.

Төньяк Европа халыкларының легендаларында кайчандыр ерак заманнарда диңгез буенда булган чиктән тыш көчле вулкан атылу турында истәлекләр сакланып калган. Шулар арасында «Аллаларның үлеме» дигәне аеруча игътибарга лаек. Әлеге легендада әйтелгәнчә, Җир

һәм Күк хакиме Один дигән алла була. Ул Валгалла дигән җирдә яши, язу системасы уйлап таба, төрле фәннәр, законнар булдыра һәм көчле дәүләткә нигез сала. Ләкин бер вакыт аллалар арасында озакка сузылган көрәш башлана. Шуның нәтиҗәсендә «дөнья юкка чыга». Шуннан соң өч ел буена тоташтан бик салкын кыш була. Җәйге айларда җәй булмый. Күктән йолдызлар атыла. Кояш белән Айны бик зур бүре кабып йота. «Агачлар төбетамыры белән актарылып чыкты, таулар юк булды, диңгез дулкыннары бөтен җир өстен күмеп китте»,— диелә әлеге легендада (Ре, 105 бит; Зай, 138 бит).

Борынгы фриз телендә язылган һәм Нидерландта, Левенворден китапханәсендә саклана торган борынгы бер кулъязма китапта диңгез тарафыннан йотылган Адланд иле турында сөйләнелә. Бу илне диңгезчеләр Атлан дип атыйлар диелә әлеге китапта. Адланд илен диңгез йотканда җир тетри. «Таулардан ут-ялкын бөркелде, таулар әле диңгез төбенә чумдылар, әле өскә калкып чыктылар. Җир янды, бөтен илне көл, тузан каплады. Елгалар элекке эзләреннән чыкты, яңа таулар барлыкка килде. Мондый хәл өч ел буе дәвам итте. Шуннан соң дөнья тынычланып калды»,— диелә әлеге кулъязма китапта (Зай, 141 бит).

Борынгы Мисыр истәлекләренең берсендә болай диелә: «Тирә-якта буталыш хөкем сөрде... тугыз көн буена сарайлардан чыгып булмады. Бу тугыз көн эчендә һәртөрле бәла-казалар һәм җил-давыллар булды, аллалар да, кешеләр дә бер-берсенең йөзләрен күрә алмадылар. Тирә-як бертуктаусыз күкрәп, гүелдәп торды. Шәһәрләр җимерелде... Югарыгы Мисыр бушап калды... Кая карама кан-яшь... Бөтен илдә үлем-кыран...» (Ре, 107 бит).

Көньяк һәм Үзәк Америка халыкларының барысының да диярлек көнчыгыштан ак тәнле, сакаллы кешеләрнең килүе турында легендалар бар. Майа-киче халкының «Пополь-Вух» дип аталган китабында майа-кичеләрнең көнчыгыштагы, диңгезнең икенче ягындагы илгә — ата-бабалар җиренә сәяхәт ясаулары турында әйтелә. Аннан алар, имеш, язу системасы алып кайтканнар. Аларның ата-бабалары, ул җирдә, имеш, ак тәнле һәм кара тәнле кешеләр белән бергә яшәгәннәр.

Астек халкында Ацтлан дигән илдә туфан булуы турында легендалар бар. Легендаларда әйтелгәнчә, астеклар Мексикага көймәдә килгәннәр. Перуда инкалар сөйләгән легендаларның берсендә әйтелгәнчә, туфаннан исән калган беренче кешеләр, диңгез аръягыннан килеп, хәзерге Венесуэлада, Кариб диңгезе буенда туктаганнар һәм шуннан бөтен Көньяк Америкага таралганнар (Зай, 129 бит).

Крит-Атлантида кешеләренең эзләре Африкада да калган. Төньяк Африканы узып, алар Көньяк-Көнбатыш Африка якларына юл тотканнар. Югарыда әйтелгәнчә, гарамантлар дип аталган халыкларны һәм аларның культурасын кайбер галимнәр Урта диңгез буе илләренә бәйле рәвештә аңлаталар.

Борынгы Урта диңгез буе илләреннән таралган кешеләр Көнчыгыш Азиядәге иң ерак төбәкләргә барып җиткәннәр. Борынгы Кытайда, Инь чорында атлар җигелә торган сугыш арбалары була. Галимнәр мондый арбаларны кытайлар үзләре уйлап тапмаганнар, сугыш арбасын Кытайга ниндидер башка халыклар Көнбатыштан алып килгәннәр дигән фикер әйтәләр (Ку, 138; Кож, 285). Монголиядә, Көньяк Гобида, Хобдо-Сомон кыяларында пар ат җигелгән арба рәсемнәре табылган. Бу исә галимнәрнең арба Кытайга Көнбатыштан килгән дигән фикерен куәтли төшә (Кож, 283, 284 бит). Инь чорында сугыш арбалары кытайларда гына түгел, аларның күршеләре гуйфан кабиләләрендә дә булган (Дум, 14 бит).

Билгеле булганча, тәгәрмәч һәм арба б.э.к. IV-III мең еллыкларда Месопотамиядә уйлап табылган дип исәпләнелә. Сугыш арбалары Критта гына түгел, Мисырда һәм башка илләрдә дә кулланылган. Шуңа күрә Кытайга кадәр барып җиткән сугыш арбалары, һичшиксез, Крит-Атлантида кешеләренеке булгандыр дип әйтүе кыен. Ләкин шунысы бәхәссез — арба һәм кайбер башка нәрсәләр Кытайга Көнбатыштан килгән. Мәсәлән, күп бәхәсләр тудырган кытай язуы мәсьәләсендә фараз рәвешендә бер фикер әйтергә була. Иң борынгы кытай язуларында «җәя» рәсеме М хәрефе рәвешендә (Поз, 208 бит). Ләкин кулланылыштагы җәя Кытайда М рәвешендә түгел, бәлки латинча D рәвешендә булган. Димәк, кытай язуының барлыкка килүендә М рәвешендәге җәя кулланган һәм бу мәсьәләдә үзләренең дини-фәлсәфи карашлары булган төркиләрнең Көнбатыштан килгән Крит-Атлантида, Мисыр һәм, ихтимал, Кече Азия халыкларының турыдан-туры катнашы булган дип әйтергә туры килә.

Инь чорында Кытайда Күк алласы Ди дип аталган (Дум, 22 бит). Крит-Атлантида төркиләрендә дә Ди күкне һәм алланы белдергән. Дисбедәге 22 рәсем **ДИ** һәм В27 шакмагындагы ДИКӘМӘ сүзе шул турыда сөйли. Скандинавия халыкларының Один дип аталган аллалары исемендә дә ди иҗеге бар. Одинның иң әүвәлге әйтелеше Дин булгандыр дип исәплибез. Сүз башындагы о — артык аваз. Бүгенге көндә «дин» (религия) мәгънәсендә кулланыла торган дин сүзе бик борынгы алла исеме булса ки-

рәк. Серле этрускларның иң олы аллалары, мәсәлән, Тин (Тиния) дип аталган (Бу, 164 бит). Русның «бер» мәгънәсендәге *один* сүзе дә, әлбәттә, Скандинавия халыкларының Один дигән аллалары исеменә барып тоташа. «Бер» бу очракта беренче, иң олы дигәнне белдерә.

### 17. ТУФАН ТУРЫНДАГЫ МИФЛАР ҺӘМ ЛЕГЕНДАЛАР

Урта диңгез утраулары цивилизациясенең Көнбатыш Европа, Африка, Америка һәм Көнбатыш Азия халыкларына йогынтысы һәм борынгы чорларда үзара элемтәләр мәсьәләсе фәнни әдәбиятта шактый киң яктыртылган. Крит-Атлантиданың төркиләргә катнашы булуы-булмавы белән әлегә беркем дә кызыксынмаган, ахрысы.

Бу уңайдан без иң элек төрки халыкларның Идел һәм Урал буйларына каяндыр читтән килүләре турындагы, туфан турындагы риваятьләрне искә төшерәбез. Төрки риваятьләрдә шулай сөйләнелә: кешеләр хак дингә күчәргә теләмәгәч, алла аларны туфан белән харап итәргә карар кыла. Нух пәйгамбәргә алла туфанның кайчан буласын әйтеп куя һәм котылу өчен көймә ясарга киңәш итә, чөнки Нух үзенең сиксән кешесе белән хак дингә күчкән була. Бер заман җирдән су чыга, күктән яңгыр коя башлый. Җир өстендәге барлык тереклек үлеп бетә. Нух үзенең кешеләре белән көймәгә утырып китә. Берничә айдан соң су кайта, коры җир ачыла. Нух белән аның өч улы, өч килене исән кала. Хам дигән улын Нух Һиндстан ягына, Самны Иран ягына, Яфәсне төньяк җирләргә җибәрә. Яфәс Идел һәм Җаек буйларына юнәлә. Бу хакта безгә XVII гасыр Хива ханы һәм тарихчысы Абул Гази язып калдырган (Ко, 38, 39 битләр).

С. Вахидов язып алган татарча риваятьтә дә Нух пәйгамбәрнең өч улы булуы турында әйтелә. Нухның уллары Гази, Төрек һәм Алып дип атала. Гази белән Төрек үзара сугышып китәләр һәм бергә яши алмыйлар. Төрек, җиңүче булса да, Газидан ераккарак китә һәм «салкын илдәге бер зур елга буена килеп урнаша». Алып бик көчле була. «Урманнарда бик озак каңгырап йөргәннән соң... бер елганың ярына килеп чыга. Елганың теге ягында Алыплар телен белә торган кешеләр торганнар, алар бөтенләй башка нәселдән булганнар. Ул алар арасыннан бер дыз сайлап ала һәм аңа өйләнә»,— диелә татарча риваятьтә (Бо, 23, 24 битләр).

XVI йөздә билгесез рус авторы тарафыннан язылган «Казан тарихы»нда Казанның ничек салынуы турында бер легенда сөйләнелә. Казан салынасы урында ике

башлы җылан яшәгән, имеш. Бу җыланның бер башы җыланныкы кебек, икенче башы үгезнеке кебек булган, имеш. Беркем дә бу турыдан исән-имин узып китә алмаган, чөнки әлеге җылан бер башы белән кешеләрне, хайваннарны ашый, икенче башы үлән ашый икән (КИ, 47 бит).

Кеше ашаучы җыланнар, аждаһалар һәм һәртөрле хәшәрәтләр турындагы мифларны, ышануларны төрле халыкларда очратырга була. Ләкин кеше ашаучы үгез турындагы миф (финикиялеләрнең үгез башлы Молохларын исәпләмәгәндә) бары грекларда гына була. Монда үгез Минотавр дип аталган. Ул, имеш, Крит патшасының сарае Лабиринтта яшәгән. Казан ханлыгы чорында Минотавр ике башлы җыланга әверелгән һәм аның кеше ашый торган башы да үгезнеке кебек түгел, җыланныкы кебек икән. Бәлки, киресенчә, әлеге миф борынгы чорларда ук «Казан тарихы»нда сөйләнелгән вариантына охшаган булгандыр. Бит Критта җыланга да, үгезгә дә табынганнар. Аннан соң, үгезнең кеше ашамаганлыгы һәм аның хәтта әкияттә дә кеше ашамаска тиешлеге үзеннән-үзе аңлашылып тора түгелме соң?

*Туфан* сүзен, гадәттә, төркиләргә гарәптән кергән дип аңлаталар. Сүзе гарәпнеке булгач, туфан турындагы риваятьләр дә безгә гарәптән кергән дип уйланыла. Без бит, үзегез беләсез, гарәптән башка яши алмаганбыз. *Туфан* русча «потоп», «наводнение». *Потоп*, башлыча, «су басу». Потоп, имеш, иң элек Шумерда булган. Шуннан Библиягә күчкән. Библиядән христиан динендәге халыкларга һәм Коръән аша мөселманнарга күчкән. Шулай итеп, барлык дөнья халыкларына таралган.

Беренчедән, *туфан* ул «су басу» яки «потоп» кына түгел. *Туфан* ул «су басу» белән бергә һәлакәт, җимерелү, харап булу. Татарча *туфан*ның мәгънәсе русча потопның мәгънәсеннән киңрәк һәм тирәнрәк.

Икенчедән, туфан турындагы мифлар, риваятьләр христиан яки мөселман булмаган халыкларда да бар. Мәсәлән, әлеге диннәр барлыкка килгәнче үк инде кытайларда туфан турында мифлар булган. Туфан турындагы риваятьләр Көньяк Америка, Көньяк Азия (Вьетнам, Лаос, Таиланд) халыкларында, Полинезия, Никобар утрауларында һ.б. илләрдә бар. Атаклы фольклор белгече инглиз галиме Дж. Фрезер төрле халыкларда туфан турында сөйләнелгән 200 гә якын миф җыйган. Шулкадәр күп халыкка һәм Җир шарының төрле төбәгенә туфан турындагы мифның бер үзәктән — Шумердан яисә Библиядән таралуы мөмкин нәрсә түгел. Монда бары бөтен Җир шарына тәэсир итә алырлык чиктән тыш көчле вулкан атылу һәм

шуның нәтиҗәсендә көчле һава дулкыннары, су дулкыннары барлыкка килү турында гына сүз була ала.

Шумер мифларында әйтелгәнчә, туфан вакытында Энки дигән бөек алла җирдәге кешеләрне кыру өчен Ирра дигән явыз алланы җибәрә. *Ир-ра* — Җир улы. *Туфа-н* да Җир улы. Татарча туфан грекларның Тифон дигән аллаларына тиңдәш һәм аваздаш. Грек мифларында Тифон — Гейнең һәм Тартарның кече улы. Тифон — йөзләгән җылан башлы хәшәрәт. Аның җылан башларыннан ут-ялкын бөркелә. Тифон төрле тавышлар белән кычкыра ала. Ул әле аллалар тавышы белән кычкыра, әле эт булып өрә, әле арыслан булып үкерә, әле җылан булып сызгыра. Тифон — гарасат алласы. Тифон җир астында яши. Тифон еш кына җирне селкетә.

Борынгы төркиләрнең (Алтай төрекләренең) «Ырк битиг» (русча «Книга гаданий») дигән әсәрендә (XV, 20—22) галәм һәлакәте турында риваять бар. Анда әйтелгәнчә, бу вакытта «өстә караңгылык, аста тузан-туфрак була, ерткычлар, кошлар һәм адәм балалары юлдан язалар». Мондый хәл өч ел буена дәвам итә һәм Күкнең шәфкате аркасында гына туктатыла (Кл, 123—126 битләр). Төньяк Европа халыкларының һәм борынгы фризларның Атлантида һәлакәтен тасвирлаган легендаларында да табигатьтәге бәла-казаларның өч ел буе дәвам итүе турында әйтелгән иде. Бер-берсенә бәйсез чыганакларда сүзгә-сүз диярлек бер үк нәрсә турында сөйләнелә икән, моңа инде ышанмаска мөмкин түгел.

Туфан турындагы мифлар бүгенге алтайлыларда да бар. Алтайлыларның мифлары грек мифларын һәм анда тасвирланган титаннар сугышын хәтерләтә. «Бөтен дөньяда җирдән, җир иясеннән туфан калка. Күккә каршы җир ияләре күтәрелә»,— диелә әлеге мифта (Ды, 66 бит).

XVII гасыр авторы Абул Гази төрки халыкларның килеп чыгышы турында сөйләгәндә туфанга киң туктала. Төрек халкы Аланча хан чорына кадәр мөселман булган, имеш. Ләкин Аланча хан патша булгач, бик нык баеган һәм байлык колына әверелгән, аллаларны онытып мәҗүсигә әверелгән. Кара хан вакытында эшләр тагын да яманга киткән. Улы атасының мөселман икәнлеген белсә, атасын үтергән, атасы улының мөселман икәнлеген белсә, улын үтергән (Аб, 12, 13 битләр).

Әлеге мифта-риваятьтә төрки халыклар тарихының Крит-Атлантида чоры чагыла дип исәплибез. *Аланча* сүзе бик борынгы Атлантиданың Абул Гази заманында формасы да үзгәргән, эчтәлеге дә онытылган, тик шулай да бөтенләй үк онытылып җитмәгән бер әйтелеше булырга

мөмкин. Кара хан исеме Крит-Атлантида тарихында зур роль уйнаган кар, карлар халкы атамасын хәтерләтә. Монда, билгеле, X—XIII гасырлардагы Караханилар династиясе турында сүз бармый. Төркиләрдә «кара» төскә тәңгәл Кара исемле ханның булуы гомумән шикле, чөнки «кара» төс ул «хурлыклы», «түбән дәрәҗәле» дигәнгә туры килә. Хәер, Абул Гази әйткән Кара хан вакытында һәртөрле тәртипсезлекләр булуын һәм Кара ханның «мөселман» түгеллеген күз алдында тотсак, «изге Кар» сүзе аңлы рәвештә кире мәгънәдәге «кара»га үзгәртелгән булырга да мөмкин.

Бала вакытымда мин туфан харап иткән ниндидер сарайлар, һәлак булган «изгеләр», «бабайлар» турында ишетеп үстем. Балаларга атап язылган иң беренче хикәям — «Тегермәндә» — шундый имеш-мимешләр тәэсирендә иҗат ителде. Хикәя геройлары — балалар урман эчендәге серле Бабай-тауны эзләп баралар. Бабай-тауда, имеш, кайчандыр һәлак булган борынгы кешеләрнең алтын-көмешләре күмелеп калган. «Бик борынгы заманда безнең җирләрдә, имеш, бик зур, бик дәү бабайлар яшәгән. Аларның аш пешерә торган казаннарына кадәр, җир сөрә торган сабаннарына, көрәк-сәнәкләренә кадәр алтын-көмештән булган... Ләкин бервакыт коточкыч давыл купкан. Диңгезләр ярларыннан чыккан, бөтен җирне су баскан, тау-ташлар җимерелгән, шәһәрләр-авыллар кырылган, бөтен халык үлеп беткән»,— диелә «Тегермәндә» хикәясендә.

Хикәя 1957 елда аерым китап булып басылып чыкты. Сабаннарның, көрәк-сәнәкләрнең алтыннан булуы мәсьәләсендә арттырып җибәрсә дә, яшь автор халыкта туфан турында сөйләнелгән риваятьләрнең төп детальләрен хикәядә дөрес чагылдырган дип әйтәсе килә.

## 18. КРИТ-АТЛАНТИДА ЦИВИЛИЗАЦИЯСЕ ҺӘМ ТӨРКИ УРТАКЛЫКЛАР

Крит-төрки уртаклыклар турында сөйләгәндә Алтай төрекләренең килеп чыгышы турындагы легендаларны читтә калдыру мөмкин түгел. Кытай рәсми язмаларында («Бэй-шу» һәм «Суйшу»да) әйтелгәнчә, төрекләрнең (төрки халыкларның) ата-бабалары элек «сихай» — Көнбатыш диңгез буенда яшәгәннәр. Күршеләре белән сугыш вакытында аларны кырып бетерәләр. Бары ун яшьлек малай гына исән кала. Малайны ана бүре коткара һәм соңыннан аның хатыны була. Дошманнар малайны да үтерәләр. Ана бүре качып китә һәм тау куышында ун ир бала таба. Ир балаларның берсе Ашина исемле була.

Ашина ыру башына әйләнә. Ашина нәселеннән булган Асян-шад күпмедер вакыттан соң бүре токымын Алтай буйларына алып килә (Кл, 103, 104 битләр).

Легендаларның икенчесендә төркиләрнең ата-бабалары Со дигән җирдә яшәгәннәр диелә. Кабилә башлыгы Абанбуның унҗиде ир туганы була. Шуларның берсе «бүре улы» дип атала. Со дәүләтен дошманнар тар-мар итәләр, исән калган ыру-кабиләләр тирә-якка таралып бетә. «Бүре улы» башкаларга караганда бәхетлерәк булып чыга. Аның өч улы була. Өлкән улы Нодулу-шадның ун хатыны була. Хатыннарның уллары әниләренең исемнәре белән аталалар. Иң кече хатынның улы Ашина дип атала. Әтиләре үлгәч, уллары, кем көчлерәк, кем җитезрәк — шул кабилә башлыгы булыр, диләр. Ашина ярышта җиңеп чыга һәм үзенә Асян-шад исеме алып, юлбашчы булып кала (Кл, 104, 105 битләр). Әлеге легендаларда Платон тасвирлаган Атлантидага барып тоташа торган ышанычлы детальләр бар. Мәсәлән, Атлантида кешеләре — ятимә кыз һәм диңгез алласы Посейдон балалары. Алтай төркиләре — ятим малай һәм ана бүре уллары. Ятимә кызның да, ятим малайның да ун улы була. Сугыштан исән калган малай ун яшьтә. Нодулу-шадның ун улы була. Платон тасвирлаган Атлантида һәлакәткә очрый, ун патша тарафыннан идарә ителә торган дәүләт таркала. Алтай төрекләренең ата-бабалары да нindидер һәлакәткә очрыйлар, тар-мар ителәләр, халык тарала һәм яңа җирдә яңадан берләшеп, дәүләт төзиләр.

Без монда унлы бүленеш системасына игътибар итмәкче булабыз.

Унлы бүленешне һиндләр уйлап тапкан, шуннан ул барлык дөнья халыкларына таралган дип аңлатырга яраталар. Ләкин унлы бүленеш системасы борынгы Мисырда да, Критта да булган. Бик борынгы төркиләрдә ун саны изге саналган. Борынгы һәм урта гасыр төрки дәүләтләрдә унлы бүленеш киң таралган. Алтай төркиләре чорында он ук (ун ук) кабиләләре, уйгурлар чорында он уйгур кабиләләре берләшмәсе булган. Хазар патшасы Иосифның X гасыр урталарында Хасдай ибн Шафрутка язган хатында Тогарманың, ун улы булуы турында әйтелә. Иосиф үзен Тогарма патшасы дип белдерә. Борынгы яһүд әдәбиятында барлык төрки халыкларны Тогарма дип атаганнар, ди «Хазары» китабының авторы С.А.Плетнева (Плетне, 7 бит). Тогарма термины Библиядә дә очрый (Хр. ДВ, 301 бит). Тогарма исә Яфетның (Яфәснең) бер улы исәпләнелә. XI гасыр галиме Мәхмүт Кашгари төрки кабиләләрнең санын егермегә чыгара. Вакыт үтү белән

борынгы «ун кабилә» төшенчәсе үзгәргән дип әйтергә була.

Унлы бүленешкә, күрәсең, Болгарда да аеруча игътибар иткәннәр. Ш. Мәрҗани үзенең «Мөстәфадел әхбәр...» китабында «Болгар җире ун өлештән тора» дигән сүзләр бар (Мәр, 234 бит). Татар әкиятләреннән берсе — «Унберенче Әхмәт» «Әүвәл заманда булган, ди, бер ир белән хатын... Боларның ун малайлары булган» дип башлана (Әк, 277 бит).

Гаскәрдәге унлы бүленеш турында Геродот та яза. Дөрес, Геродот бу турыда б.э.к. V гасырда яшәгән борынгы Иран патшасы Кесркс армиясен тасвирлаганда искә ала. Борынгы Кытай тарихчысы Сымацянь язганча, Сөн дәүләте 24 өлкәгә бүленгән була. һәр өлкә башлыгы кытайча «вань-ци», русча «темник» дип атала. Татарча бу «төмән» яисә «төмән бәге» дигәнгә туры килә. Төмән, билгеле булганча, «ун мең» дигәнне аңлата. «24 төмән бәгенең һәркайсы үзе мең башы, йөз башы, ун башы... билгели»,— диелә Сыма-цянь тарихында (Тас, I, 40 бит). Сөннәрдән соңгырак чорларда яшәгән һәм ил тоткан Алтай төрекләрендә дә гаскәр унлы берәмлекләрдән торган.

Унлы бүленешне, белүебезчә, Атлантидага Посейдон үзе биргән. Атлантида белән алла уллары — ун патша идарә иткән. Шуңа күрә Атлантида гаскәрендә дә унлы бүленеш булгандыр дип фикер йөртергә нигез бар. Бу хакта Платон безгә кайбер мәгълүматлар әйтеп калдырган.

«Сугышка яраклы ирләр мәсьәләсенә килгәндә, монда шундый кагыйдәләр була: үзәнлекнең һәр бүлеге бер сугышчы — җитәкче бирергә тиеш; һәр бүлекнең зурлыгы унга-ун стадий; барлык бүлекләр саны — алтмыш мең; таулардан һәм илнең башка җирләреннән чакыртып алына торган исәпсез-хисапсыз сугышчылар, бүлекләр санына карап, җитәкчеләргә бүленеп бирелә. Сугыш булган очракта һәрбер җитәкче, барлык сугыш арбаларының саны ун мең булсын өчен, үз ат-арбасының алты өлешен патша карамагына бирә»,— дип яза Платон (Пла, III, 558 бит).

Әлеге өзектән шул аңлашыла: бөтен патшалыкта сугыш арбаларының саны ун меңгә кадәр җыелырга тиеш булган икән. Менә шушы деталь күп нәрсәне аңларга ярдәм итә дә инде. Шулай итеп, Атлантида хәрби системасында ун меңлек берәмлек (бу очракта ун меңлек сугыш арбасы) иң зур гаскәри төркем булган дип әйтә алабыз. Нәкъ сөннәрдәге кебек диярлек.

Югарыда Крит-Атлантида һәм борынгы Кытай мөнәсәбәтләре турында беркадәр сүз булды. Монда без тагын бер әһәмиятле детальгә игътибар итмәкче булабыз. Шихуанди

үлгәч, Чин тәхетенә утырган император Эр-шихуанди б.э.к. 208 елда: «Безне «ун мең сугыш арбасына ия булучы» дип хөрмәт итәләр, ләкин чынлыкта безнең (ягъни императорның. — *Н.Ф.*) ул кадәр арбабыз юк», дигән сүзләр әйтә (Сы, 93 бит). Борынгы Кытайда вань чән чжи го — «ун мең сугыш арбасы булган дәүләт» дигән сүз Күк улының, икенче төрле итеп әйткәндә, Кытай императорының символы була. Эр-шихуанди сүзләреннән күренгәнчә, б.э.к. III гасырда «ун мең сугыш арбасына ия булу» тәгъбиренең чын мәгънәсе инде, күрәсең, онытылган булган. Император Эр-шихуанди «ун мең сугыш арбасын» үзенең шәхси карамагында булырга һәм анда-монда барганда шулкадәр күп ат-арба һәм сугышчылар үзен озатып йөрергә тиеш дип исәпли. «Ун мең сугыш арбасына ия булган дәүләт» тәгъбире Хуанхе буйларына, ихтимал, Атлантида якларыннан килгәндер дип уйларга нигез бар.

Критта, Кнос сарае калдыклары арасында 500 гә якын сугыш арбасы һәм аның детальләре табыла. «Таулардан, үзәннәрдән торган утрауның үзендә сугыш арбаларыннан файдалану мөмкин түгел. Хәзерге заман немец галиме Г.Бокиш фараз кылганча, Критта ул арбаларны чит илләргә сату өчен эшләгәннәрдер, Крит кешеләре мисырлыларны һәм хетларны арба белән тәэмин итеп торганнардыр дип уйларга гына кала»,— дип яза әлеге арбалар турында В.Б.Ковалевская (Ков, 39 бит).

Г.Бокиш та, Ковалевская да бу очракта Платон Атлантидасын искә алмыйлар. Крит сугыш арбалары чит илләргә сатып, күршеләрнең хәрби куәтен арттыру өчен түгел, бәлки Атлантиданың иң олы патшасы таләп иткән ун меңне тутыруда үз бурычыңны үтәү өчен эшләнгәндер дип уйлау дөресрәк булыр кебек.

Сүз уңаеннан әйтик, революциягә кадәр татарларда «агачтан экипаж һәм аңа аерым детальләр» эшләү киң таралган була. Казан губернасында эшләнелгән чана һәм тарантаслар бөтен Россиядә дан тота.

Борынгы Эгей цивилизациясе турында сүз барганда, гадәттә, Крит исеме генә телгә алына һәм еш кына бөтен Урта диңгез бассейнының үзәге Крит булып аңлашыла. Ләкин Урта диңгез бассейнында югары культура чәчәк аткан чорларда дәүләтнең үзәге Крит түгел, бәлки Платон тасвирлаган Атлантида утравы булган. Моның шулай икәнлеген исбатлауда югарыда телгә алынган 500 ләп сугыш арбасы һәм аның детальләре ярдәм итә ала. Моны исбатлауда шулай ук дисбедәге САКАМА һәм МАКА САРКА сүзләре дә ярдәм итә ала.

Платон тасвирлаган Атлантида дәүләте шактый зур

территория биләгән. Дәүләт үзе дә, дәүләтнең башкаласы урнашкан аерым утрау да Атлантида дип аталган. Башка утрауларга караганда яшәү өчен уңайрак булган Атлантида утравында цивилизация элегрәк барлыкка килгән. Крит һәм башка утраулар Атлантида утравындагы бөек патшаларга буйсынганнар. Фест шәһәрендә табылган дисбе хуҗасы, күрәсең, турыдан-туры үз утравын яисә үз өлкәсе патшасын күз алдында тотып, САКАМА ди. САКАдан да зуррак патша МАКА САР дип аталса да, ул аны САРЫМА дип якын итеп әйтми, бәлки рәсми рәвештә коры гына МАКА САРКА ди. Шулай итеп, бөтен дәүләтнең баш кешесе исәпләнелгән МАКА САР белән чагыштырганда, Крит утравының яисә Фест өлкәсенең баш кешесе кечерәк дәрәҗәдә булган дип әйтә алабыз.

## 19. ЙОЛА ҺӘМ ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘР УРТАКЛЫГЫ

Платон әйткәннәргә нигезләнеп, Атлантида кешеләренең йолаларын, гореф-гадәтләрен төрки йолалар, гореф-гадәтләр белән чагыштырып карасак, безнең өчен Атлантида ниндидер серле, мифик дөнья булып түгел, бәлки реаль тарихи факт булып тоелачак.

Платон тасвирлаганча, ант бирер алдыннан патшалар якындагы әрәмәдә йөргән үгезне тотып алып киләләр һәм аны язулы таш янында чалалар. Үгез каны язулы ташка агып төшәргә тиеш. Ант биргәч, үгезнең барлык әгъзаларын яндыралар, зур савытка шәраб салып, аны сыеклыйлар. Һәркем сыекланган шәрабка оешкан үгез каны ташлый. Үгез каны катышкан шәрабны алтын касәгә салып эчәләр.

Шушы рәвештә ант бирү (ант эчү) Кара диңгез буе скифларында да була. Дуслык килешүе төзегәндә скифлар ант эчәләр, тик алар шәрабка үгез канын түгел, үз каннарын кушалар (Г, IV, 70). Борынгы сөннәр дә Атлантида патшалары кебек үк дип әйтерлек ант эчкәннәр. Б.э.к. 50 нче елларда кытайлар белән дуслык килешүе төзегәндә алар, тау башына менеп, акбүз ат чалалар, атның канын шәраб белән катыштырып, шәрабны кылыч һәм алтын кашык белән болгатып, алтын белән тышланган дошман баш сөяген касә итеп эчәләр (Тас, II, 38 бит). Атлантида патшалары өчен изге хайван үгез булса, сөннәрнең изге хайваны — акбүз ат. Атлантида патшалары үгезне ниндидер калку уртында, сөннәр атны тау башында чалалар. Изге кан катышкан шәрабны Атлантида патшалары да, сөннәр дә алтын касәгә салып эчәләр.

Платон корбан үгезе турында шактый җентекләп сөй-

ли. Крит кешеләре элек үгезгә табынганнар. Үгез ул — Күк улы. Аны бары таяк һәм ардан белән генә тоталар. Аны тотканда тимер кулланырга ярамый. Ни өчен дигәндә, моның хикмәте бар. Тимер — Җир улы. Таяк та, аркан да, белүебезчә, Күк уллары. Димәк, үгез белән көрәшкәндә көчләр тигез булырга тиеш.

Платон әйткәнчә, Атлантида патшалары бер-берсенә каршы корал күтәрергә, бер-берсенең канын түгәргә тиеш түгелләр. Менә шушы караш борынгы һәм урта гасыр төркиләрдә үзгәрешсез кала килгән, һич югы теориядә дип өстәргә кирәк. Элек патша, хан нәселеннән булган җинаятьчеләрне каннарын чыгармыйча гына үтерә торган булганнар: йә ат койрыгына тагып җибәргәннәр, йә киезгә төреп буып үтергәннәр.

Атлантида патшалары ант эчкәч, үгезнең әгъзаларын, түгелгән канын — барысын яндыралар, ягъни ут-анага тапшыралар. Геродот язганча, скиф җирендә утын аз булганлыктан, корбан итен пешергәндә скифлар кайчагында утын урынына үгез сөякләрен дә яндыралар (Г, IV, 61). Ләкин бу гадәт, күрәсең, утын юклыктан гына барлыкка килмәгәндер. Бит шунда ук Геродот (Г, IV, 62) сугыш алласы Ареска багышлап корбан биргәндә скифларның тау-тау чыбык-чабык өюләре турында да яза. Скифларның үгез сөякләрен яндыруының сәбәбен башка нәрсәдән эзләргә туры килә. Атлантида патшалары корбан үгезенең калдык канын һәм барлык әгъзаларын утта яндырган кебек, скифлар да, күрәсең, үгез сөякләрен яндырып бетерүне дөрес дип исәпләгәннәр.

XIII гасырда кыпчаклар үзара ант биргәндә кан катыштырылган шәраб түгел, кымыз эчкәннәр. «Кеше йөзе сыман итеп ясалган җиз савытка кымыз салалар; сәяхәтче һәм аның юлдашы шушы савыттан кымыз эчсә, алар арасында беркайчан хыянәт булмый»,— диелә бер язма истәлектә (Пл, 204 бит). Кымыз монда элекке заманнарда кан катыштырылган шәрабны алыштыра.

Йолага туры китереп, касәне түгәрәк буенча йөртеп, чиратлашып кымыз эчү йоласы VII гасырда Алтай төрекләрендә дә, соңгырак чор төркиләрдә дә була.

Ант эчкәндә кулланыла торган алтын касә турында да бер-ике сүз әйтеп китәргә кирәк. Атлантида патшалары ант эчкәч, алтын касәне аллага багышланган гыйбадәтханәдәге махсус урынга куялар. Димәк, ант эчүдә касәнең роле бар. Борынгы кеше карашынча, канда җан, рух саклана. Аллага тиң изге үгез канының беркадәр өлешен татып карау ул аның җанын, рухын үзеңә алу, аны үзләштерү һәм шуның нәтиҗәсендә аллаларга хас көч-

куәткә ия булу дигән сүз. Изге кан изге нәрсәгә генә салынырга тиеш. Алтын — Күк улы, алтын — изге. Алтын касә тагын да изгерәк. Касә — тудыручы алиһә, дөресрәге, аның җенес әгъзасы символы.

Касәне изгеләштерүгә бик күп мисаллар табарга була. Мәсәлән, Кара диңгез буе скифлары билбауларына алтын касә тагып йөриләр. Билбау — кендек символы. Үлгән патша янына кабергә шул ук скифлар алтын касә куеп калдыралар. Баш сөягеннән ясалган һәм алтын белән тышланган касә, әйтелгәнчә, сөннәрдә изге санала. X гасырда үлгән гузны (гуз кешесен) күмгәндә, аның кулына касә тоттырып туялар. XIII гасыр кыпчаклары турында Рубрук: «Куманнар, мәетне күмгәч, кабер өстенә зур калкулык өяләр һәм мәетнең таш сынын утыртып куялар. Кендеге турысында «кулына касә тоткан таш сын көнчыгышка таба каратыла»,— дип яза (Руб, 102). Алтай, Монголия, Тува һ.б. илләрдәге-җирләрдәге төркиләрнең таш сыннары шулай ук кулларына касә тотканнар.

Борынгы Шумер һәм Кече Азиянең төрле төбәкләрендәге, төрле чордагы аллаларын, патшаларын чагылдырган сурәтләргә игътибар беләнрәк күз салсагыз, алар кулында да, һичшиксез, касә күрәчәксез. Дөрес, барысында да түгел. Аннан соң, кайбер сурәтләрдә касәләр югары күтәрелгән, кайберләрендә түбән төшерелгән. Кыпчак сыннарындагы кебек нәкъ кендек турысында.

Атлантида патшаларының ант эчү йоласында тагын бер әһәмиятле деталь бар. Ант эчүче «үзе өчен, үзенең бөтен нәселе өчен ант бирә», ди Платон (Пла, III, 559 бит). Фест дисбесендә без менә шуны күрдек тә инде: ант бирүче, үзенең мифик һәм мифик булмаган ата-аналарыннан башлап, барлык аллаларын, туган-тумачаларын, якыннарын санап чыга. Беренче сүзе итеп ул аларга «антым» дип мөрәҗәгать итә. Дисбедә без дөрес укый алган туганлык терминнарына нигезләнеп кенә фикер йөрткәндә дә, Крит цивилизациясе Платон тасвирлаган Атлантидага туры килә дип әйтергә була.

Атлантида патшаларының ант бирү йоласында утның әһәмияте аеруча зур. Корбан үгезенең барлык әгъзалары, аккан каны утта яндырыла. Ант эчәр алдыннан изге шәрабның беркадәр өлеше утка сибелә, ягъни Ут-анага өлеш чыгарыла. Утка табыну, утка корбан бирү, утны изгеләштерү төркиләрнең күбесендә булган. Моның калдыклары бездә бүгенге көнгәчә саклана. Мәсәлән, татарда: утка төкерергә ярамый — авызың кутырлый дигән караш бар. Ашар-эчәр алдыннан утка корбан бирү йоласы алтайлыларда, телеутларда, якутларда, Төркиядәге күчмә

йөрүкләрдә бар яисә, булган. «Скифлар, аеруча изге ант бирергә теләгәндә, тантаналы рәвештә патша учагы аллалары исеме белән ант итәләр»,— ди Геродот (Г, IV, 68). Сарматлар, Алтай төрекләре, борынгы кыргызлар шулай ук утка табынганнар.

## 20. КОЯШКА ТАБЫНУ

Атлантида башкаласында, диңгез алласы Посейдонга багышланган гыйбадәтханәдә алтыннан коелган алла сыны була. Алла канатлы атлар җигелгән арбада бара. Атлар алтау, ягъни өч пар. Посейдонны, гадәттә, кулына өч җәпле сәнәк тоткан килеш сурәтләгәннәр. Посейдон Зевс кебек үк иң олы алла.

Татарда канатлы ат — тулпар башлыча әкиятләрдә очрый. Әкият герое таз малайны яисә ярлы җегетне тулпар күз ачып йомганчы бер илдән икенче илгә илтеп куя; таулар-урманнар аша үтеп, адәм аягы басмаган ят җирләргә алып бара. Тулпар, гадәттә, ак төстә була. Ул диңгез аша чыга, диңгезгә чума яисә диңгез патшасы белән сугышып, аны җиңә.

Атлантида кешеләренең диңгез алласы Посейдон белән ятимә кыз Клейто балалары булуын без инде беләбез. «Борынгы заманда Посейдонны акбүз ат сыйфатында олылаганнар»,— диелә бүгенге заман белешмәсендә (МС, 204 бит). Икенче төрле итеп әйткәндә, акбүз ат яисә канатлы ат чынлыкта грекларның Посейдоны дигән сүз. Менә шуңа күрә дә татар әкиятләрендә тулпарлар бик җитез генә диңгезгә дә кереп китәләр, диңгез патшасын җиңеп тә чыгалар. Тулпарга атлана алган, аны үзенә буйсындыра алган кеше үзенең теләсә нинди теләгенә ирешә — җир астына да төшә, утлы таулар аша да чыга, төн эчендә дөньяның бер читеннән икенче читенә дә барып җитә.

Нинди көч иясе соң ул шулай да оча, йөзә, чума торган, теләсә нинди каршылыкны җиңеп чыга ала торган канатлы акбүз ат? Фольклор материалларыннан күренгәнчә, канатлы ат ул — кояш. Атлантида башкаласындагы, Посейдон гыйбадәтханәсендәге канатлы атлар да, күрәсең, кояш символлары булгандыр дип әйтә алабыз.

Төркиләрдә ат борын-борыннан изге саналган. Алаша атлар, белүебезчә, кояшка багышланган. Скифларның бер кабиләсе массагетлар кояшка багышлап ат корбан итеп биргәннәр һәм иң җитез аллага иң җитез хайван бирелергә тиеш дип исәпләгәннәр. Сарматлар да кояшка ат багышлаганнар. Урта гасыр төркиләрдә, мәсәлән, сабирларда ат иң олы алла — Тәңреханга багышлана торган булган.

Кояш символы ат, үгез яисә куй (сарык) гына түгел. Кояш символларының берсе — спираль. Спираль сурәтен без Фест дисбесендә дә күрәбез. Хәзер без Платон тасвирлаган Атлантида белән дисбе сурәтен чагыштырып карамакчы булабыз.

Башта ук шуны әйтергә кирәк: Платон тасвирлаган Атлантида башкаласы дисбе рәвешендә. Яңадан Платон сүзләрен искә төшерик. Башкала уртасында изге тау бар. Анда гыйбадәтханәләр, патша сарайлары, ягъни идарә үзәге урнашкан. Тауны өч су боҗрасы, ике җир боҗрасы уратып алган.

Дисбенең уң ягында да, сул ягында да җыланның башы — «идарә үзәге» уртага туры килә, уртадагы A1, B1 шакмагындагы рәсемнәр җылан башын хәтерләтә. Дисбенең ике ягында да өчәр тулы боҗра бар.

Дисбенең A31, B30 шакмаклары башланып киткән төштә, шакмаклардан уң якта, түгәрәкнең читенә таба тар гына аралык сузыла. Дисбенең A ягында бу аралык икегә бүленгән: берсе аның A18 шакмагының койрыгы сыман, икенчесе A19 шакмагын тәшкил итә. Дисбенең B ягындагы аралык киңрәк һәм ул B18 шакмагының койрыгы сыман булып тора. Әгәр менә бу аралыкларның тирән мәгънәсе булмаса, борынгы художник аны Г хәрефе кебек итеп түгел, бәлки башкачарак ясар иде яисә бөтенләй ясап та тормас иде. Бу аралыкларны мифик кендек дип аңларга кирәк. Дисбенең A ягында шундый «кендек» янына *райа* (оҗмах) сүзенең туры килүе дә тикмәгә түгел. Борынгы карашлар нигезендә, җәннәткә, оҗмахка керү ул барыннан да элек мифик җылан авызына керү, ашалу дигән сүз. Кендек, бау, аркан менә шул мифик җыланны күз алдында тота да инде.

Шул ук вакытта дисбедәге аралыклар, ягъни «кендек» Атлантида башкаласындагы изге тауны турыдан-туры Су стихиясе — диңгез белән тоташтыра торган берданбер арыкны да чагылдыра дип уйларга кирәк.

Атлантида кешеләренең кояшка табынучылар булуы Крит архитектурасында да күренә. Кояшка табыну, кояш рухына һәм формасына ярарга тырышу Крит төзелешендә аеруча нык күзгә ташлана. Крит гыйбадәтханәләре планда түгәрәк. Үлгән кешенең мәңгелек йорты кабер өстендәге төрбәләр — түгәрәк. Мәсәлән, б.э.к. XXX—XXII гасырларда Критта мәетне диаметры 4 метрдан алып 13 метрга кадәр булган түгәрәк каберләрдә күмү гадәте булган. Б.э.к. XVI—XII гасырларда Крит кешеләре төзегән һәм Крит культурасы тәэсирендә булган Микенадагы бер таш кабернең диаметры 14 метрга җитә. Микена тарихының б.э.к. XV—XIII гасырлардагы чорын «гөмбәзле

төрбәләр династиясе» дип атыйлар, чөнки бу чорда гөмбәзле төрбәләр (каберләр) салу киң таралган була.

Критта һәм бүтән утрауларда планда түгәрәк өйләр белән бергә, әлбәттә, дүрт почмаклы өйләр дә була. Ләкин дүрт почмаклы биналар төзелешендә дә кояшка табыну принцибы саклана. Мондый биналарның уртасында зур бүлмә, аның як-ягында ике-өч кечерәк бүлмә урнаша. Зур бүлмә уртасында, идәндә — түгәрәк учак урыны, учак турысында — түбәдә — төтен чыгу һәм якты төшү өчен ачыклык калдырыла.

Криттагы патша сарайлары да шундый ук принципта төзелгән. Кнос сарае турында Дж. Пендлбери болай дип яза: «Шул рәвешчә, зур үзәк ишегалды барлыкка килгән. Аның тирә-ягына бер-берсеннән аерым корылмалар — «утраулар» урнашкан; аларның күбесенең почмаклары дугаланып торган. Дугаланган почмаклар Кносның бер үзенчәлеге булса кирәк. Моны җир өсте шартлары белән аңлатып булмый... шуңа күрә без бу күренешнең сәбәпләрен башка нәрсәдән эзләргә тиеш булабыз... Ихтимал, Кнос өйләрендә без бик борынгы традиция калдыклары белән очрашабыздыр» (Пен, 115, 116 битләр).

Хамезида табылган өй калдыклары да планда ярым түгәрәк формалы. Уртада ачык ишегалды яисә яктылык коесы урнашкан. «Бу өйнең формасы гадәти түгел һәм ул форма каян да булса читтән алынмаган»,— ди Крит археологиясе белгече Дж.Пендлбери (Пен, 118 бит).

Аерым өйләр, сарайлар гына түгел, Криттагы авыллар, шәһәрләр дә үзәклек принцибында төзелгән булган. «Крит авылларының һәм шәһәрләренең үзенчәлеге шунда — зур гына туры почмаклы мәйдан тирәли төркем-төркем булып торак йортлар урнаша»,— ди Н.М.Никулина. «Шәһәр һәм авылларны төзекләгәндә үз үзәклек принцибыннан файдалану бары Критка гына хас түгел. Мондый принцип Кече Азиядә, Анатолийдә дә саклана»,— ди шул ук автор (Ни, 139 бит).

Кече Азиядәге түгәрәк корылмалар турында безнең беркадәр сүз булды инде. Монда тагын бер-ике мисал белән танышып китәргә була. Мәсәлән, археологлар Көнбатыш Иранда, Аснаб калкулыгында диаметры 10 метрга җиткән һәм б.э.к. X—IX меңъеллыкларга карый торган; Ирандагы Шанидар тау куышына якын» җирдә — Зави Чеми янында б.э.к. X—IX меңъеллыкларда барлыкка килгән түгәрәк һәм ярым түгәрәк торак урыннары тапканнар (Мел, 23 бит).

Кайбер авторлар Крит авылларында һәм шәһәрләрендә өйләрнең тәртипсез рәвештә урнашкан булуы турында язалар. Мәсәлән, Кораку авылы планы шуны күрсәтә.

«Урамнарның урнашулары буенча Критның Миной чоры шәһәрләре белән римлыларның хәрби лагерьга охшатып салынган шәһәрләре бер-берсеннән кискен рәвештә аерылып торалар. Миной чоры шәһәрләрендә (койма булмауны исәпләмәгәндә) өйләр тәртипсез рәвештә урнашкан, алар бер-берсенә сыенып утыралар, урамнар теләсә ничек боргалана, әледән-әле аларның киңлеге үзгәрә. Безнең карашыбызча, мондый шәһәрләр, күзәнәкләр кебек, ничек туры килә шулай үскәннәр. Мондый үсеш бернинди ихтыяҗны һәм нәтиҗәне исәпкә алмаган»,— дип яза А. Лео Оппенхейм (Оп, 138 бит).

Хәзер инде ерак Криттан туп-туры үзебезнең якка — Идел буена, татар авылына кайтып төшик. «Планның бик нык буталчыклыгы, кәкре-бөкре урамнар, аралыклар, тупиклар, дөрес булмаган формадагы йорт урыннары һәм шулай ук хәзер инде юкка чыккан ниндидер үзәк тирәсенә түгәрәкләнеп утырган сыман, йорт урыннарының берберсенә якын урнашулары татар авылы өчен бик типик күренеш булып тора»,— дип яза этнограф Н.И.Воробьев (Во, 64 бит).

«Бик күп татар авылларының иске планнарын анализлап караганнан соң В.В.Егерев... төрле ягына йортлар урнашкан, ат белән керү өчен бер аралыгы — еш кына очракта тупик рәвешендә тәмамлана торган аралыгы булган түгәрәкне иске татар авылының төп күзәнәге булып тора дигән нәтиҗәгә килә... Шул рәвешчә, йортларның түгәрәкләп урнашуы татар авыллары планировкасының нигезе булган»,— дип яза шул ук автор (Бор, 141, 142 битләр).

Татарларда авылларның гына түгел, аерым йортларның да урнашу тәртибе борынгы принципларга нигезләнгән. Элекке заманда өйләр ишегалды ягына чигеребрәк салына торган булган. Өйнең алгы ягы урамга чыгарылмаган, урам яктан өйне биек койма каплап торган. Баерак кешеләрнең өйләре ишегалды уртасына ук диярлек салына торган булган.

Татар авылының төзелеше һәм аерым өйләрнең урнашу тәртибе, шулай итеп, Крит архитектурасына һәм Платон тасвирлаган Атлантида башкаласы рухына һәм формасына туры килә. Ахырда шуны әйтергә кирәк, А.Лео Оппенхейм Крит шәһәр төзелешенең serенә төшенә алмаган.

## 21. БОРЫНГЫ ЦИВИЛИЗАЦИЯЛӘР ҺӘМ КҮЧМӘ ХАЛЫКЛАР

Кара диңгез буе скифларында, Себер скифларында һәм башкаларда югары дәрәҗәгә ирешкән дәүләт системасы һәм бүгенге кешеләрне дә таң калдырырлык югары культура була. Алар нәкъ борынгы мисырлылар кебек үлгән кеше-

ләрнең мумияләрен ясыйлар, аларда металл кою, металл эшкәртү, туку һ.б. һөнәрләр бик нык алга киткән була. Алар киез өйләрдә яшиләр, туктаусыз арбада, ат өстендә хәрәкәтләнәләр, мал-туар асрыйлар. Шул ук вакытта үлгән патшаларын күмү өчен җир астына таштан, агачтан сокландыргыч «сарайлар» салып куялар. Аларның үзләренә генә хас дини карашлары, йолалары, гореф-гадәтләре бар.

Боларның барысын да күрше утрак халыклардан күчереп алу белән дә, талап алу белән дә аңлатып булмый. Карлы-буранлы далаларда, кояшлы чүлләрдә туктаусыз хәрәкәтләнгән, бөтен гомерләре мал-туар арасында үткән кешеләрнең бер дә юктан гына шундый нәрсәләрне барлыкка китерүләре мөмкин түгел. Безнеңчә, болар югары культура учаклары урнашкан яклардан качкан кешеләр. Үзара сугышлардан соң, туфан калкып бөтен нәрсәнең асты өскә килгәннән соң иминрәк, тынычрак җирләргә качып киткән Крит-Атлантида, Мисыр һәм Кече Азия кешеләре утрак дәүләтләрнең меңәр еллык тәҗрибәсен, дини идеологиясен, хезмәткә, һөнәргә булган җәптәшлекләрен, осталыкларын үзләре белән алып киткәннәр. Яңа җирләрдә, яңа шартларда, ихтимал, яңа этник кушылмалар белән бергә алар шуларның барысын да яңача үстергәннәр.

Европа-Азия күчмәләренең дәүләт төзелешендә, культурасында Атлантида һәм Мисыр дәүләт төзелеше һәм культурасы үзенең тулы чагылышын таба. Белүебезчә, Атлантида белән «алла улы» — изге патша нәселе хакимлек итә. «Алла улларының» берсе, өлкәне, агасы иң олы патша санала. Күчмә халыкларда да кабилә берләшмәләрендә изгеләштерелгән патша нәселе хакимлек итә. Буйсынган кабиләләрнең башлыклары һәрвакыт олы патшаның уллары яисә ир туганнары була.

Дини идеология мәсьәләсендә күчмә халыклар гомерләре буена борынгы, әүвәлге дини карашларга турылыклы булып калалар. Барыннан да бигрәк алар — кояшка табынучылар.

Төркиләр һәм кайбер башка халыклар ел буена бер урыннан икенче урынга күченеп яшәгәннәр. Бу күчену теләсә кайда теләсә ничек йөрүне аңлатмаган, һәрбер ыру-кабиләнең алдан билгеләнгән җире-биләмәсе булган һәм, ел тәүлегенә карап, барлык кеше, ил булып, терлек-туарлары белән менә шунда туктаусыз хәрәкәтләнеп гомер иткәннәр. Бу исә яңа шартларда экономик мәҗбүриятне генә түгел, кояш кебек мәңге хәрәкәттә булуны да аңлаткан. Скифларның атаклы «җәнлек стилендә» нәкъ менә шул туктаусыз хәрәкәт һәм омтылыш чагыла да инде. Туктаусыз хәрәкәт шул ук вакытта беркайчан картаймау-

ны, һәрвакыт яшь һәм көчле булуны да аңлаткан. Мәсәлән, скифлар үзләрен дөньяда иң яшь халык дип исәпләгәннәр. Яшь булу монда фәлән яшьтә генә булуны түгел, бәлки яшьләрчә көчле һәм батыр булуны белдергән. Яшьлек фәлсәфәсе борынгы Мисырда да, соңнәрдә дә булган. Мал-туар белән күченеп йөрү генә түгел, бер урында туктап, авыл булып утыру да күчмә халыкларда кояш идеологиясенә турылыклы рәвештә башкарылган. Уртага, үзәккә һәрвакыт ыру-кабилә башлыгының өе, аның тирәсенә түгәрәкләнеп башка өйләр урнашкан. Күчмәләрнең кирмәннәре (хәрби лагерьлары) шулай ук боҗра сыман түгәрәк булган. «Бәҗәнәк һәм кыпчак кабиләләре үзләренең өйләрен түгәрәкләп — кояш тәртибендә тезеп утыртканнар»,— ди С.А.Плетнева (Пле, 140). IV гасырда Кара диңгез буендагы төрки аланнар, Аммиан Марцеллин әйткәнчә, «...киез өйләрен түгәрәкләп тезеп урнаштырганнар» (Пле, 133 бит). 451 елда атаклы Каталаун сугышы вакытында Гуннар патшасы Аттила иң батыр сугышчыларның уртасында кала. Аттиланың кирмәне, коймa сыман итеп, арбалар белән әйләндереп алынган була. (Ио, 105, 107 битләр.) Арбалардан боҗра сыман ныгытма — табор яисә «курень» кору скифларда да була. Б.э.к. IV гасырда булган бер сугыш турында грек тарихчысы Диодор: «Сатир бу хакта белгәч тә күп гаскәр белән аңа каршы юнәлде; Фат елгасын кичеп һәм үзенең дошманнарына якынлашып, ул кирмәнен арбалар белән әйләндереп алды»,— дигән сүзләр язып калдырган (Др, 79 бит).

Гаскәрне боҗра сыман түгәрәкләп тезү скифлардан элегрәк тә булган. Б.э.к. 1312 яки 1296 елда Төньяк Сириядә, Оронт елгасы буенда, Кадеш янында борынгы мисырлылар белән хетлар арасындагы сугыш вакытында Мисыр гаскәрләренең хәрби лагере нәкъ урта гасырлардагы гун, бәҗәнәк, кыпчак, алан һ.б. кабиләләренеке кебек корыла. Үзәккә патша чатыры куела, чатыр тирәли сакчылар, сугышчылар урнашалар. Бөтен кирмән исә тәртәләрен эчке якка каратылган сугыш арбалары һәм бүтән төрле арбалар белән боҗра сыман итеп әйләндереп алына (Ков, 48 бит).

Күчмә халыкларның өйләре дә түгәрәк формада. Өй уртасында һәрвакыт ут-учак яна, өстә, түбәдә төтен чыгу һәм яктылык төшү өчен ачыклык була. Плано Карпини монголлар һәм кыпчаклар өен шулай тасвирлый: «... өйләре аларның түгәрәк, чатыр сыман... Өстә, өй уртасында түгәрәк тәрәзә бар. Аннан яктылык төшә, төтен чыга, чөнки аларның өйләре уртасында һәрвакыт ут яна» (Кар, 27).

XVI гасырда кырым татарларының, XVIII гасырда нугайларның, XIX гасырда Себер татарларының, Алтай

төркиләренең һәм башка төрки халыкларның өйләре түгәрәк формада була.

Күчмә халыклар калдырган курганнар — кабер өстенә өелгән ясалма калкулыклар шулай ук планда түгәрәк формада. Кыпчаклар турында Рубрук: «... мәетне күмгәч кабер өстенә зур калкулык өяләр»,— ди (Руб, 102 бит). Кыпчак курганнары турында археолог Г. А. Федоров-Давыдов: «Тышкы яктан күчмәләрнең курганнары ярым шар рәвешендәге тыгызланган балчык өеменнән гыйбарәт»,— ди (ФД, 120 бит). X гасырда үлгән төрки гуз кешесен күмгәч, кабер өстенә киез өй сыман итеп кызыл балчык өйгәннәр. Бу хакта Ибн Фадлан язып калдырган. Кара диңгез буе скифлары да үлгән патша кабере өстенә бик зур итеп курган өйгәннәр. Тувада, Аржан янында б.э.к. VIII—VII гасырларда яшәгән Себер скифлары калдырган патша курганнарының диаметры 120 метрга, бүгенге көндәге биеклеге 3—4 метрга җитә. Моннан ярты гасыр элегрәк бу урында борынгы төрки телдә язылган кабер ташы табыла. Кабер ташы атаклы «алты мең ат» хуҗасына аталып куелган була.

Нигезе түгәрәк өй, өй уртасындагы учак һәм түбәдәге ачыклык, түгәрәк курганнар, курган әйләнәсендәге таш боҗралар — боларның барысы да, әлбәттә, кояш символлары. Алар безне янә дә Крит-Атлантида һәм Мисыр цивилизацияләрен искә төшерергә мәҗбүр итә.

Урта гасыр төрки халыкларда кабер өстенә үлгән кешенең таш сынын утыртып кую гадәте дә булган. Мондый гадәт VI—VIII гасырларда Алтай төрекләрендә, кыпчакларда һ.б. халыкларда булган. Кыпчакларның үлгән кешеләрнең таш сынын ясап куюлары һәм андый сыннарны бик нык хөрмәт итүләре турында XII гасырда яшәгән Низами да, XIII гасырда яшәгән Рубрук та язып калдырган. Кара диңгез буе скифлары да үлгән кешенең таш сынын ясап куя торган булганнар. Скиф таш сыннары белән төрки таш сыннар бер-берсенә бик нык охшаган (Ше, 32 бит). Төньяк Көнбатыш Монголиядә яшәүче тувалар XIX гасырда да үлгән кешеләрнең каберләренә таштан яисә агачтан ясалган сын утыртып куя торган булганнар.

## 22. АТЛАНТИДА СҮЗЕ ТУРЫНДА

Платон тасвирлаган Атлантида чыннан да булганмы-юкмы икәнлеген ачыклау өчен *Атлантида* сүзен тикшереп карау да җитәр иде кебек. Нәрсә аңлата соң бу сүз? Реаль мәгънәсе бармы аның, әллә аны Платон үзе генә уйлап чыгарганмы?

Иң элек шуны әйтергә кирәк, *Атлантида* сүзе, беркадәр кыскарган, беркадәр фонетик үзгәрешкә кергән хәлдә, төрле телләрдә очрый. Әлеге «Атлантида»ларның барысы да Платонны уку нәтиҗәсендә барлыкка килмәгәндер, әлбәттә. Югарыда телгә алынган һәм шулай ук телгә алынмаган кайбер фактларны искә төшерик.

Көньяк Америкадагы астек халкында *Антлан* дигән илдә туфан булуы турында риваятьләр сөйләнелгән. Борынгы фризләрнең XIII гасырда язылган һәм «Ура линда Бук» дип аталган кулъязма китабында диңгезчеләр телендә Атлан дип аталган *Адланд* иленең диңгез тарафыннан йотылуы турында әйтелә. Борынгы грек мифларында күк гөмбәзен тотып торучы титан (батыр) *Атлан* яисә *Атлас* дип атала. Атлас Япет (Йәфәс) белән Клименаның улы, Прометейның туганы. Ливиядә (Төньяк Африкада) *Атлас* таулары була. Монда яши торган халык *атлант* дип аталган. Геродот заманында Истр (Дунай) елгасының Фракиядән ага торган бер тармагы *Атлант* дип аталган. Страбон язганча, Евбея утравы янында *Атламга*, Пирея утравы янында шулай ук *Атланта* дигән утраулар булган.

*Атлантида* сүзен без иҗек методы нигезендә *ат ла-н, тида* рәвешендә таркатабыз. Югарыда күп мәртәбәләр телгә алынган *ал, ар* сыйфатлары кебек үк, *ат* иҗекләре дә монда сыйфатны белдерә, *ла-н* исә — «кояш улы». *Тида* өстәмә информация бирүче аерым сүз. Су-Күк улы Җир дигәнгә туры килә. Атлантиданың диңгез эчендәге утрау икәнлеген белгәнлектән, *ти-да* иҗекләрен «су улы утрау» дип тә аңларга була. *Атлан, тида* термины тулаем «изге кояш улы, утрау» дигән мәгълүмат бирә. Бу мәгълүмат Платон сөйләгәннәргә дә, Крит археологиясе материалларына да, төрки тел фактларына да тулысынча туры килә.

Мисалга китерелгән *Атлан, Атлас* кебек сүзләрнең берсендә дә *тида* иҗекләре юк. Әлеге мисалларда утрау да, дәүләт тә күз алдында тотылмый, шунлыктан, күрәсең, *тида* иҗекләренең ялгануы кирәк тә булмаган. *Атлант, Атланта* кебек сүзләр исә борынгы Атлантида кешеләренең теле онытылганның соңында грек теле җирлегендә формалашкан терминнар булса кирәк.

Хәзер *Атлантида* сүзенең иҗекләрен башка төрле мисаллар белән чагыштырма рәвештә тикшереп карыйк. Мәсәлән, *ат-әт* иҗекләренең уңай сыйфат белдерүенә Татарстандагы *Әт нә, Әт рәкле, Әт рәч* авыл исемнәрен күрсәтергә була. Борынгы Грециядә Афина шәһәре урнашкан өлкә *Ат ти-ка* дип, массагет һәм сак кабиләлә-

ренең берсе *Ат та-си* дип аталган. V гасырда яшәгән атаклы гуннар патшасының исеме *Аттила* дип языла. Сүзне *Ат ти-ла* рәвешендә таркатабыз, мәгънәсен «изге күк (су) улы» дип беләбез. Шушы уңайдан *ти* иҗегенең су мәгънәсендә килгән очракларына мисаллар күрсәтеп китәргә була. Мәсәлән, Бал-ти-ка диңгезе, Ан ти-ль утраулары, Ан ти-гуа утравы.

Борынгы грек мифларында Уран һәм Геянең (Күк һәм Җирнең) уллары, өлкән буын аллалар һәм аларның балалары *титан* дип аталган. Сүзне *Тита-н* рәвешендә таркатсак һәм *Тита* иҗекләрен *Атлантида* терминындагы *тида* иҗекләренә тәңгәл дип белсәк, әлеге «мифик» аллаларга карата әйтелә торган серле сүзнең тулаем «утрау улы» дигән мәгънәсе ачыкланачак. Бу очракта «утрау улы», әлбәттә, «Атлантида утравы улы» дигәнгә туры килә. Бит борынгы заман грекларына бары тик Атлантида кешеләре генә аллаларга тиң шәхесләр булып тоелган һәм бары алар гына җир астыннан калкып чыккан Тифон белән сугышта җиңелеп, Тартарга (тәмугка) төшеп киткәннәр! Титаннарның грек мифларында өлкән буын аллалар булуына да игътибар итмичә мөмкин түгел. Бу исә тита кешеләренең («утрау улларының») утрауларда борынгы греклардан элегрәк хаким булуларын тану булып тора.

Грекларда «тудыручы алиһә» исәпләнелгән *Гейә*нең иң әүвәл *җәйә* булуы турында безнең сүз булды инде. Әйтелгәнчә, Уран дигән алла грекларда иң борынгы хаким алла исәпләнелгән һәм Күкне чагылдырган. Уран белән Геянең 12 дән алып 45 кә кадәр балалары булган, имеш. Борынгы грек мифларында шулай ук Уран Океан яры буенда яшәгән атлантларның беренче патшасы булган икән дигән караш та бар (МС, 249 бит). Бу инде Уранның чыннан да Атлантида кешеләренең алласы булуына ишарәли түгелме соң? *Уран* сүзен берничә төрле таркатырга була. Монда бары шуны гына әйтәсе килә: *Уран*ның борынгырак формасы *н* тартыгы белән әйтелгән булырга тиеш, бу исә грекча язылыштагы *уран*ны *нуран* дип аңлауга мөмкинлек ача. *Ну-ран* сүзен *нура-н* дип тә, *нур, ан* дип тә тарката алабыз. Һәр очракта безгә таныш сүзләр барлыкка киләчәк. Мәсәлән, *нур*ны без «кояш яктысы» дип беләбез.

Уран-Гея турында сүз чыккач, Уранның бер кызы *Урания* дип аталуын да искә төшерәсе килә. *Уран-ия* чыннан да Уран «улы». Ураниянең икенче исеме — Афродита. Афродита, имеш, диңгез күбегеннән барлыкка килгән, диңгез дулкынына исә Уран җисеме (каны) төшкән булган. Афродита (Урания) менә шул саф каннан (җисемнән) барлыкка килгән, имеш. Икенче төрле итеп әйткәндә, Ура-

ния (Афродита) *нур*дан яралган. Шуңа күрә дә ул грек мифларында саф мәхәббәт алиһәсе исәпләнелгән. Төрки халыклар ышануынча, югары дәрәҗәдәге кешеләр — патшалар, изгеләр, гомумән, кояш нурыннан яралганнар. Афродитаның икенче бер исеме булган Урания сүзен без *Нурания* дип төзәтәбез. Бу инде бернинди мифик исем түгел, бүгенге көндәге гап-гади хатын-кыз исеме.

Татар теле диалектларында *аклан* дигән сүз бар (ТТДС, 29 бит). Урман эчендәге ачык урынны, гадәттә, *аклан* диләр. *Аклан* сүзенең *айаз* варианты да мәгълүм (ТТДС, 24 бит). Татарда *айаз* — кояшлы, болытсыз дигәнгә туры килә. Димәк, урман эчендәге аклан ул «кояшлы утрау» дигәнне белдерә икән. «Җыланчай» дип аталган әкияттә: «Менә шул юл белән баргач, бер җирдә, ут диңгезенең уртасында бер аклан булыр... ут кабынганчы бу утрауда...» дигән сүзләр бар (Әк, I, 121 бит). Шулай итеп, аклан урман уртасында гына түгел, диңгез уртасында да була ала икән. «Җыланчай» әкиятеннән китерелгән өзектә икенче җөмләдә *аклан* сүзе хәзерге укучыга аңлаешлырак утрау сүзенә алыштырылган.

Татар телендә еш кына *т* тартыгы белән *к* һәм *къ* тартыклары бер-берсен алыштырып киләләр. Мәсәлән, *теләү-келәү, тирмән-кирмән, чит-чик, җыпты-җыпкы. Т* һәм *к, къ* тартыкларының бер-берсен алыштырып килүләре чит телләрдә дә очрый. Мәсәлән, татарча, *ахакъ* булган сүз грекча *ахат*, русча *агат* буларак формалашкан. Бүгенге татар телендә сакланып калган *акълан* сүзен *т* тартыгы белән әйтсәк, бу *атлан* булачак. Шул рәвешчә, *акълан* сүзендә атаклы *атлан(тида)* сүзе яшеренеп ята икән.

Татар телендә «атлас» дигән тукыма исеме дә, кеше исеме дә мәгълүм. Безнең һади Атласов дигән тарихчыбыз да булган. Борынгы грек мифларында диңгез уртасындагы «Изгеләр утравы», «Бәхетлеләр утравы» дигән утраулар телгә алына. Бу утрауларда «бәхетле кешеләр», «изге кешеләр» һәм, гомумән, «батырлар нәселе» яшәгән, имеш. Мифларда шулай ук «Кояшлы утрау» атамасы да очрый. *Аклан, Атлан* кебек сүзләрнең чын мәгънәсен, әлбәттә, греклар да яхшы белгәннәр һәм менә шул факт аларның мифларында чагылыш тапкан, дип уйларга кирәк.

### 23. БҮГЕНГЕ ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ БОРЫНГЫ ДӨНЬЯ

**Кадир.** Платон язганча, ятимә кызның диңгез алласыннан туган беренче игезәкләренең өлкәне *Атлант* дип аталган. Игезәкләрнең икенчесе, Атлантның энесе «җирле халык телендә» *Гадир* дип аталган. Атлантида кешелә-

ренең теле турында бердәнбер язма мәгълүмат бу. Гадирның мәгънәсе грекча Евмел дигәнгә туры килә икән. «Евмел»ның мәгънәсе исә русча «богатый стадами», татарчасын «мал-туары күп булган бай кеше» дип әйтергә була.

Гадир биләмәләре Геракл баганаларыннан алып хәзерге *гадиритлар* җиренә кадәр сузылган булган ди Платон. Гадиритлар җире исә Испаниянең Кадикс (хәзерге Кадис) шәһәре тирәсендә булган.

*Гадир* исемен без *Кадир* дип төзәтәбез. Гадиритлар җиренең Кадикс (Кадис) тирәсендә булуы, беренчедән. Платонның Атлантида турында сөйләгәннәренең уйдырма түгеллеген исбат итсә, икенчедән, грекча Гадир дип аталган архонның чынлыкта Кадир (Кадикс-Кадис) булуын исбат итә.

Кадир бүгенге татар телендә күбрәк исем буларак кулланыла, ләкин телдә «кадир алла» дигән сүз тезмәсе дә бар. Көч-куәт иясе, көчле мәгънәсендә һәм кеше исеме буларак *Кадир* 1966 елда чыккан «Татарча-русча сүзлеккә дә теркәлгән. Бу сүз татарда гына түгел, казакъ, уйгур, төрек телләрендә дә бар. Ләкин ул безгә гарәптән кергән дип аңлатыла. «Татарча-гарәпчә-фарсыча алынмалар сүзлеге»ндә *кадир*ның мәгънәсе: көче җитүче, көч-куәт, көч-куәт иясе дип аңлатылган (Алы, 198 бит).

*Кадир* сүзе борынгы төрки телдә дә булган. Тик монда ул каты, усал, кырыс, кансыз мәгънәләрендә кулланылган. Борынгы кар нәселеннән булган карлукларның (Караханнарның) бер патшасы Кадир хан дип аталган. Гарәп телендә дә, төрки телләрдә дә *Кадир*ның, мәгънәләре бер төрлерәк. Шул ук вакытта төрки телләрдәге һәм гарәп телендәге мәгънәләр грекча «Евмел» мәгънәсенә дә каршы килми. Малы-туары күп булган бай кеше, әлбәттә, көч-куәт иясе дә була һәм аның төп сыйфаты усаллык, кырыслык, кансызлык булса да гаҗәп түгел.

Татарстанда Кадир елгасы, Кадир чишмәсе, Кадир авылы, Башкортстанда Кадир авылы бар.

**Койма**. «Аңлатмалы сүзлек»тә әйтелгәнчә, нәрсәне дә булса аерып торган яисә әйләндереп алган ныгытма, корылма *койма* дип атала. Телдә такта койма, читән койма, киртә койма, утыртма койма, таш койма, кирпеч койма кебек сүз тезмәләре бар. «Койма» катнашында ясалган *койма кою, койма коймалау, койма утырту* кебек сүзләр дә кулланыла.

«Койма» төрле материалдан ясалган һәм җиргә утыртып беркетеп куелган ныгытманы аңлатса да, шулай да «күбрәк таш һәм кирпеч корылманы күз алдында тота сыман. Мәсәлән, таш киртә, кирпеч киртә булмый, бары

таш койма, кирпеч койма гына була ала. Шул ук вакытта киртә, читән, чәбе, текмә кебек атамалар «койма» сүзеннән башка да кулланыла ала. Әйтәсе килгәнем шул: иң әүвәл *койма* сүзе теләсә нинди материалдан корылган ныгытмавы түгел, бәлки таштан яисә кирпечтән салынган ныгытманы гына аңлаткан булырга тиеш сыман.

*Койма* сүзе ялгыз да, башка сүзләр белән дә кулланыла ала. «Койма»ны *кой-ма* дип таркатсак, *кой* иҗекләре фигыль булып аңлашыла. Моны боерык фигыль дип уйларга була, ләкин чынлыкта бу боерык фигыль түгел — исем фигыль. *Кою* гадәттә сыек яки сыеклатылган, эретелгән, каты һәм вак әйберләрне бер җирдән икенче җиргә күчерүне аңлата. Агач яфрагын коя, күктән яңгыр коя, яки яңгыр коеп ява, бер савыттан икенче савытка сыек әйберне яки вак бөртекле әйберне коялар, кесәдән акча коела һәм, ниһаять, нинди дә булса металлны эретеп коялар. Оннан ясалган сыек массаны кызган табага коялар да, шуннан *коймак* барлыкка килә. Теоретик яктан *коймак* белән *койма* бер үк мәгънәдәге сүзләр. Бу сүзләрне *кой-ма* һәм *кой-мак* дип беләбез. *Ма* һәм *мак* иҗекләре монда «улы» мәгънәсенә туры килә. *Койма* да, *коймак* та, шулай итеп, «койган әйбер» дигәнне аңлаталар икән.

«Коймак»ны коялар — анысы аңлашыла. Ләкин бит таштан да, агачтан да киртәне, ныгытманы коеп (агызып, түгеп) булмый! «Койма» белән «коймак» нигездә бер үк мәгънәдәге сүзләр икән, шулай булгач, ныгытма, киртә мәгънәсендәге *койма* да кайчандыр «кою ысулы белән эшләнелгән киртә (ныгытма)» булып чыга түгелме соң? Нәкъ шундый *коелган* «койма»лар Платон тасвирлаган Атлантида башкаласында булган да инде.

Серле башкала урнашкан киң үзән уртасындагы тау да, тауны әйләндереп алган һәм су боҗралары белән аралаштырылган җир боҗралар да таштан өеп мендерелгән биек «киртәләр» белән нгытылган булган. Башкаланың читендә диңгез яры буеннан ук башланып киткән бик зур һәм бик озын таш «киртә» дә булган. Платон әйткәнчә, әлеге таш «койма»ларның киңлеге бер плетр, ягъни 30—32 метр чамасы булган. Биеклек, озынлык турында тарихчы бер сүз дә әйтми.

Атлантида башкаласындагы изгеләр тавын әйләндереп алган кечерәк таш «киртә» буйдан-буйга җиз белән, беренче җир боҗраны әйләндереп алган таш ныгытма кургаш белән, икенче җир боҗраны әйләндереп алган таш ныгытма бакыр белән тышланган була. Тау башындагы диңгез алласы белән аның хатыны һәм балалары яшәгән урындагы изге гыйбадәтханәне әйләндереп алган киртә...

алтын белән тышланган була. Платон ап-ачык итеп әйтә: металлны алар эретеп» койганнар, ди (Пла, III, 554, 555 битләр). Ягъни атлантлар таш «киртә» өслегенә алтын, җиз, бакыр, кургаш кебек металларны эретеп агызганнар булып чыга.

Элеккерәк заманнарда *койма* сүзе татарда «киртә»гә карата гына түгел, бәлки эретеп, коеп эшләнелгән металл әйберләргә карата да кулланылган. «Абушай җыры» дин аталган тарихи җырдагы:

> Абушай аягында койма богау,
> Вак-вак атласа да шылдырый,—

дигән юлларны моңа мисал итеп китерергә була (ТЛ, 58 бит).

Борынгы заманнарда металл коеп таш ныгытмаларны, һәйкәлләрне бизәү турында кайбер язма истәлекләр сакланып калган. Ләкин боларның барысы да Атлантида һәлакәтеннән соңгырак чорларга карый һәм Атлантида башкаласындагы *койма* киртәләр белән чагыштырганда, бик кечкенә булып тоела. Мәсәлән, б.э.к. VII гасырда яшәгән Ассирия патшасы Ашшурбанапал елъязмасында Элам башкаласындагы гыйбадәтханәне (зиккуратны) җимерү турында әйтелә. Зиккуратны әйләндереп алган койма тешләре «ялтырый торган җиздән коелган була» (Хр. ДВ, 239 бит). Ашшурбанапал Мисырның Фива шәһәрендәге гыйбадәтханә алдына куелган һәйкәлне дә җимерә. һәйкәл алтын белән көмеш катнашмасыннан коелган була (ХР. ДВ, 233 бит). Б.э.к. 210 елда борынгы Кытай императоры Шихуанди үлгәч, аның табутын тау куышы эченә казып ясалган төрбәгә (кабергә) куялар. Борынгы кытай тарихчысы Сымацянь кабер стенасына эчке яктан бронза (бакыр һәм кургаш катнашмасы) эретеп коюлары турында яза (Сы, 87 бит).

Гомерның «Одиссея» дастанында Җил алласы Эол яши торган Эолия дигән йөзмә утрауның җиз койма белән әйләндереп алынган булуы турында әйтелә (Од, X, 1—4). Без инде беләбез, көчле вулкан атылу нәтиҗәсендә Атлантида утравы диңгезгә батып юкка чыккан. «Баткан утраудан соң калган ләм аркасында су саега һәм шунлыктан бүгенге көнгә кадәр ул тирәдәге диңгезгә кадәр [кораблар] «йөзеп бара алмыйлар», ди Платон (Пла, III, 466 бит).

Диңгезнең саегуын бүгенге галимнәр башкачарак аңлаталар. Көчле вулкан атканда су өстенә бик күп булып һәм озак вакытлар дәвамында көл-туфрак коелган. Платон ләм дип атаган вулкан көчле су өстендә калын катлам хасил иткән. Әкренләп ул оешкан һәм шактый тыгыз массага әверелгән. Менә шул каткан көл-туфрак

массасы (пемза) йөзмә утрау сыман бер урыннан икенче урынга күченә алган. «Одиссея»дагы беркем якын килә алмаслык биек җиз койма белән әйләндереп алынган йөзмә Эолия утравы турындагы сүзләр менә шул күренешне чагылдыра да инде.

**Салкын чишмә.** Сандугач, күгәрчен кебек үк «салкын чишмә» дә безнең өчен туган ил, туган җир символы булып аңлашыла. Чишмәләрнең, гадәттә, үз исемнәре була. Чишмә исеме урман, тау, авыл, кеше исемнәренә бәйле рәвештә аталырга мөмкин. Чишмәләрнең «Салкын чишмә» дигәннәре дә бар. Татарстан җирендә генә дә уналты «Салкын чишмә» бар икән (Гар, 172 бит).

Безнең якларда чишмәләр салкын сулы, шуңа күрә чишмәне «Салкын чишмә» дип атау мәгънәсезлек булып тоела. Бит телдә «салкын елга», «салкын күл» дигән сүзләр юк, шулай ук андый атамалар да юк. Әгәр «салкын чишмә» төшенчәсе халык күңеленә шул дәрәҗәдә тирән кереп утырган икән, бәлки, моның берәр төрле мәгънәсе бардыр?

Мәгънәсе шул — «койма» кебек үк «салкын чишмә» дә безне Платон тасвирлаган Атлантидага алып бара. Платон әйткәнчә, изге таудан ике чишмә агып чыккан. Чишмәләрнең берсе кайнар сулы, икенчесе... салкын сулы булган. Атлантида патшалары чишмә суларын сарайларга, коену бассейннарына, бакчаларга һәм шәһәр өйләренә җибәргәннәр. Шул рәвешчә, башкала өйләренә, бүгенгечә дип әйтерлек, кайнар һәм салкын су килеп торган.

Кайнар сулы чишмә янында салкын сулы чишмә булган җирдә генә, чишмәләрне бер-берсе белән бутамас өчен, сөйләм телендә «кайнар чишмә» һәм «салкын чишмә» тәгъбирләре барлыкка килергә мөмкин. Атлантида башкаласында нәкъ менә шундый хәл булган да инде. Бүгенге татарлар яши торган җирләрдә кайнар сулы чишмәләр юк, шунлыктан, күрәсең, «кайнар чишмә» төшенчәсе онытылып юкка чыккан. «Салкын чишмә» исә сөйләм телендә, җырларда, атамаларда мәңге сакланып калган.

«Салкын чишмә»нең, һичшиксез, Атлантидага барып тоташуын исбатлый торган икенче бер факт та бар. Монысы — «Изгеләр чишмәсе». Белүебезчә, Атлантида башкаласының изгеләр тавында алла уллары — изге патшалар яшәгән. Мифларда, легендаларда әйтелгәнчә, Адланд илен «Изгеләр утравы» дип тә атаганнар. Изгеләр яши торган таудан агып чыккан чишмәләр дә, әлбәттә, изге булып тоелган. «Кайнар чишмә», «салкын чишмә» атамаларының «изгеләр чишмәсе» дигән гомуми исеме дә булган, күрәсең. Монда шуны да әйтергә кирәк, Атлантида утравы вулканик токымнардан торган. Вулканик

токымнарда минераль тозларга бай салкын һәм кайнар сулы чишмәләр булуы гадәти күренеш санала икән. Атлантида чишмәләренең дә, Кавказдагы минераль суларныкы кебек, дәвалау үзенчәлекләре дә булгандыр һәм шунлыктан халык аңында әлеге чишмәләр гомумән изге, шифалы булып тоелгандыр дип тә әйтергә була.

Татарстан җирендә уннан артык «Изгеләр чишмәсе» дип аталган чишмәләр бар (Гар, 158, 179 битләр).

«Илиада» дастанында әйтелгәнчә, Троя (Илион) шәһәре янындагы Ида тавыннан да ике чишмә агып чыккан, имеш. Чишмәләрнең берсе кайнар сулы, икенчесе салкын сулы булган (Ил, XXI, 147—150). Ләкин Страбон язганча, моннан ике мең еллар элек Ида тавыннан салкын сулы бер генә чишмә аккан (С, XIII, I, 43). Бу вакытта чишмәләрнең берсе табигый рәвештә томаланган булганмы, әллә соң Гомер дастанында берәр төрле ялгышлык бармы — без моны хәзер инде белә алмыйбыз. Әмма «Илиада» дастанында кайнар һәм салкын сулы чишмәләрнең телгә алынуы үзе генә дә Атлантида дигән илнең чыннан да булуы һәм Гомер заманнарында аның әле онытылып бетмәве турында сөйли булса кирәк.


## 24. «ДИҢГЕЗ ХАЛЫКЛАРЫ»

Атлантида юкка чыгып 150—200 еллар чамасы вакытлар үткәч, б.э.к. XIII гасыр урталарында Мисырга Эгей диңгезе ягыннан килгән төрле кабиләләр басып керәләр. Мисыр язуларында бу кабиләләрне «диңгез халыклары» дип атыйлар. Б.э.к. 1251—1231 елларда патша булып утырган Мернептах диңгез халыклары белән сугышта күп кенә җиңүләргә ирешә һәм шул хакта: «Либү кабиләсенең кабахәт юлбашчысы Деда улы Мериай үзенең укчылары белән... шерденнары, шекелешалары, акавашалары, лүкү һәм туршалары белән үтерелде»,— дигән сүзләр язып калдыра (Попл, 205, 206 битләр).

Әлеге истәлектә телгә алынган *шерден* кабиләсе башка чыганакларда да очрый. Борынгы Мисыр сурәтләре арасында *шерден (шардана)* сугышчыларының рәсемнәре дә сакланып калган. Сугышчыларның уң кулында түгәрәк калкан, сул кулында очлы, озын хәнҗәр, башларында түбәтәй сыман калпак, калпак өстендә очлары югарыга каратылган мөгез сыман яңа ай һәм ай уртасында — түгәрәк шар, ягъни кояш символы.

Шерден кабиләсен Дж. Томсон Сарда һәм Сардиния утравы кешеләре булырга тиеш дип, туршаны Тирсен яки Тиррен (этруск), акайвашаны ахей (ахай) дип аңлата

(Том, 400 бит). Башка галимнәр дә шундыйрак караштa торалар. Борынгы Сарда һәм хәзерге Сардиния кешеләре арасында шерден (шардана) кешеләре бардырмы-юктырмы, әйтүе кыенрак. Әмма шунысын әйтергә була: кайчандыр борынгы мисырлылар белән сугышкан «диңгез халыкларының кырык мәртәбә үлеп, кырык мәртәбә терелгән, кырык мәртәбә таркалып, чәчелеп тә, яңадан бергә кушыла алган үлемсез кабиләләрнең нәсел-нәсәбе бүгенге көндә безнең белән, безнең арада яшәп яталар. Татар халкының атаклы улы — галим һәм мәгърифәтче Каюм Насыйри *Шырдан* авылында туган. Татарстанда әле дә Иске Шырдан, Олы Шырдан, Кече Шырдан, Рус Шырданы дигән авыллар бар.



Рәсем 7. Шырдан сугышчылары. XIX династия чорындагы мисыр сурәтләренең берсе.

Борынгы Мисыр язмаларында *шека (шекелеша)* дигән кабилә исемнәре Татарстандагы *Шекә, Шекәнәч* авыл атамаларында сакланып калган. Мернептах язуында телгә алынгач *лүкү* сүзен бәлки *ләке* дип укырга кирәктер? Мисыр язуында, гадәттә, тартыклар гына дөрес укыла. Тартыклар янындагы сузыкларның ниндилеген галимнәр һәр очракта да дөрес итеп билгели алмыйлар, чөнки мисыр теле үле тел исәпләнелә. Ләке дигәннән, борынгы дөньяда ләкеләр шактый көчле һәм күп санлы кабилә булганнар, ахрысы,— аларның исеме берничә урында очрый. Мәсәлән, Мисыр патшасы Рамсес III нең, Кадеш янында хетлар белән сугышын тасвирлаган язмада Кече Азиядәге Лек дигән ил телгә алына (ХР. ДВ, 120 бит). Лек һәм лүкү чынлыкта бер үк сүз булырга мөмкин. Әлеге вакыйгалардан соңгырак чорларда барлыкка килгән Спарта дәүләтенең икенче исеме — *Лакедемон*. Борынгы грек телендә «демос» халык дигәнне белдерә. *Лакедемон* атамасының тәрҗемәсе «Лаке халкы» яисә «Лаке өлкәсе» булачак. Татарчасы, иң дөресе моның *Ләке темән. Темән*, ягъни *төмән. Төмән* ул күп һәм ун мең дигәнне аңлата. Күп исә халык та, өлкә дә була ала. Татарстанда Ләке авылы, Азәрбайҗанда Ләки шәһәре бар.

Лакедемонның *Спарта* атамасына килгәндә, бу сүзне без *Ас пар-та* рәвешендә таркатабыз һәм тулыландыра-

быз. Атаклы Спартак (Спарта-к) «Спарта улы» (кешесе) дигәнгә туры килә (гәрчә ул Спартада тумаса да). VII гасырда яшәгән һәм Азов диңгезе буеннан Кара диңгез буена күченеп китеп Болгария дәүләтенә нигез салган төрки болгар ханы *Аспарух* дип аталган. Ханның исемен *Ас пар-ух* дип таркатабыз. Бу шулай ук *Ас пар-та* сүзенә тәңгәл килә, тик «улы» мәгънәсе монда *х* тартыгы белән яисә *ух* иҗекләре белән белдерелә. Төп мәгънә *пар* иҗекләренә кайтып кала. *Пар*, күрәсең, борынгы *кар*ның бер вариантыдыр дип уйларга була. Татарда Алпаров (Гыйбад Алпаров) фамилиясе мәгълүм.

Шулай итеп, борынгы *лүкү, лек, лаке* сүзләре безне янә дә үзебезнең якларга һәм бүгенге көннәргә алып кайтты.

Инглиз галиме Дж. Томсонның *акайваша*ны *ахай (ахей)* дип аңлатуы да безнең файдага. Югарыда без нәкъ шул турыда сүз алып бардык та инде — борынгы грекларның *ахай (ахей)* дигән атамалары *акай* һәм *әкәй* сүзләренә кайтып кала дидек.

Туршаны тирсен (этруск) атамасына тиңләштерү дөреслеккә туры килеп бетми. Боларның һәркайсы аерым сүз булса кирәк. Татарстанның күршесендә, Мари АССРда Турша топонимы бар. Әлеге турша бик борынгы туршаларның бер кыйпылчыгы булырга мөмкин. Казаннан төньяктагы җирләр, күпчелек галимнәр уйлаганча, элекке марилар җире булмыйча, киресенчә, болгарларныкы булган; марилар анда көнбатыштан руслардан качып килгәннәр дигән караш та бар. Марилар, билгеле, болгарлар белән килешү нигезендә килгән булырга тиешләр. Алар, күрәсең, Болгарның һәм соңыннан Казан ханлыгының төньяк җирләрен дошман һөҗүменнән саклаганнар. Казан ханлыгы чорында русларга каршы сугышта марилар күп батырлыклар күрсәтәләр һәм татарлар кебек үк күп кешеләрен югалталар.

Мисыр патшалары Рамсес II һәм Рамсес IV заманнарында б.э.к. XIII—XII гасырларда язылган истәлекләрдә *чакал* дигән халык та телгә алына (ХР. ДВ, 133, 141 битләр; 146 бит, иск. 9). Татарстанда Иске Чокалы, Яңа Чокалы авыллары бар.

Күрәсез, борынгы халыклар, борынгы цивилизацияләр белән безнең әле булса элемтәләр өзелмәгән. Татарстандагы, Татарстаннан читтәге авыл, елга һ.б. исем-атамаларның кайсына гына барып тотынма, аларның һәркайсы диярлек борынгы топонимия белән ялгана.

Бүгенге татар телендә диңгезгә, диңгезчелеккә кагылышлы бик күп сүзләр, сүз тезмәләре сакланып калган. Бу урында моны да искә төшерү зыян итмәс дип уйлыйм.

Әйтем-мәкальләрдә, табышмакларда, халык җырларында, әкиятләрдә «диңгез» сүзе шактый еш кабатлана, вакыйгалар еш кына диңгез буенда бара. Сөйләм телендә «диңгез тубыктан», «көймәсе комга терәлде», «төпсез көймәгә утыртты», «ике көймәнең койрыгын тиң тотып булмый» дигән әйтем-мәкальләр әле дә актив кулланыла. Халык җырлары арасында:

> Ничек килдегез безгә,
> Төшмәенчә диңгезгә,—

дигән сүзләр бар. Табышмакларның берсендә:

> Зәңгәр диңгездә җилкән,
> Ука белән теккән,
> Көмеш белән чиккән,—

диелә.

Мондый сүз тезмәләре, мондый тәгъбирләр бары тик диңгезне яхшы белгән диңгезче халыкта гына туарга мөмкин.

### 25. «КЫЗЫЛ КАР ЯУГАЧ»

Бүгенге сөйләм телендә *таш* катнашында ясалган сүзләр, тәгъбирләр дә күп. Урта гасырларда һәм соңгырак чорларда татарлар яшәгән җирләрдә таш эше бөтенләй булмаган дип әйтү дөрес булмас иде, әлбәттә. Таш эше булган, ләкин төзелеш материалы буларак ул киң кулланылмаган, чөнки безнең якларда ташны алыштыра алган урманнар күп булган. Таш катнашында ясалган күп кенә сүзләрне, сүз тезмәләрен дә без бик борынгы заманнарда һәм бик ерак төбәкләрдә — кояшлы көньяк илләре шартында барлыкка килгән булырга тиеш дип исәплибез. Тарихтан билгеле булганча, төзелештә, сәнгатьтә ташны күпләп куллану иң элек шунда — борынгы цивилизация илләрендә башланган.

«Тузга язмаганны сөйләмә» дигән мәкальнең сөйләм телендә «ташка язмаганны сөйләмә» дигән варианты да бар. Бу мәкаль кеше ышанмастай сүз сөйләүчегә, ялган сөйләүчегә карата әйтелә. «Ташка язган» сүз теләсә нинди ят һәм яңа сүзгә каршы куела һәм алдан ук иң дөрес сүз дип игълан ителә. Моннан шундый нәтиҗә чыгарырга була: димәк, «иң дөрес» сүзне элек ташка язганнар һәм ул һәркем өчен канун көченә ия булган.

Борынгы халыкларда исә канун кагыйдәләрен зур ташларга язып кую гадәте киң таралган. Мәсәлән, б.э.к. XVIII гасырда яшәгән Вавилон патшасы Хаммурапи кануннары зур ташка язып куелган булган. Атлантида баш-

каласында да, белүебезчә, Посейдонга багышланган гыйбадәтханә уртасында алла күрсәтмәләренә ярашлы рәвештә эшләнгән канун кагыйдәләре язылган орихалк багана торган. Орихалк багана ул чынлыкта ниндидер металл белән капланган таш багана булырга мөмкин.

Мендем тауның башына,
Язу яздым ташына,—

диелә халык җырларының берсендә.

Урта гасыр төрки халыклар тарихында билгеле булган язулы ташларны — Күл тәгин, Билге каган, Төнйокук һ.б. кабер ташларын менә шул борынгы гореф-гадәтнең, ягъни ташка канун кагыйдәләре язу гадәтенең бер дәвамы дип белү дөресрәк булыр кебек. *Таш кисү, таш яру, ташка үлчим, ташка кадак кагу, таштан юкә сую, таш юл, таш курчак, таш капчык* һ.б. сүз тезмәләренең әле булса сөйләм телендә актив кулланылуы да безнең бик борынгы ата-бабаларыбызның таш эше осталары булуы турында сөйли булса кирәк.

«Таш»ка кагылышлы тагын бер төркем сүз тезмәләре бар. *Ташка басу, таш басма, таш тамга, ташка тамга салу* кебек сүзләргә аерым тукталырга кирәктер. Революциягә кадәр татарда китап басу эше басма, басмаханә дип аталган. Типография ысулы белән басылган сүзгә, китапка карата әле дә «ташка басылган» диелә. Бүгенге типографияләрдә чынлыкта ташка да басмыйлар, таш басма да кулланмыйлар. «Таш» катнашында ясалган бу терминнарның башлангычы янә дә безне ерак чорларга алып китә. Критта һәм бүтән утрауларда элек кыйммәтле, ярым кыйммәтле ташлардан тамгалар (тамгалы мөһер) ясау бик нык алга киткән булган. Таш бик яхшы итеп шомартылган, эшкәртелгән. Күбесенчә ясмык рәвешендә булган таш мөһергә осталар тарафыннан төрле рәсемнәр, билгеләр, тамгалар ясалган. Тамгалы таш мөһерләрне, башлыча, беләзектә йөрткәннәр. Менә шундый тамгалы ташлар борынгы заман кешесенә хәзерге паспорт хезмәтен үтәгән. Кеше, үзенең шәхесен белдерергә кирәк булса, тамгалы таш мөһерен кызыл балчыкка, балавызга яисә шундыйрак башка нәрсәгә баскан, һөнәрчеләр ясаган әйберләргә дә тамга сугыла торган булган. Җеп, бау уздырылган ишекне, чүлмәк савыт-саба, янчык, капчык кебек нәрсәләрне тамгаланган үзле балчык кисәге яисә балавыз белән бикләп, томалап, каплап кую гадәте киң таралган булган. Бүгенге көндәге сургучлау шул борынгы гадәтнең бер калдыгы булса кирәк.

Тамга төшерелгән балчык яки балавыз кисәге «таш басма» булган. Бу очракта тамгалы таш үзе түгел, бәлки

тамга басылган балчык яки балавыз кисәге «таш» дип аталган. Критта, борынгы Фест сарае калдыклары арасында археологлар 7000 данә таш басма («оттиск») тапканнар (Не, 28 бит).

Бүгенге телдә «имза» мәгънәсендә кул-тамга сүзе дә кулланыла. Кул-тамга элегрәк, күрәсең, гел кулда (беләзектә) йөртелгән тамгалы ташны күз алдында тоткандыр дип әйтәсе килә. «Кул кую» сүзе дә шул ук тамгалы ташка һәм тамгалы таш ярдәмендә *басма* ясауга кайтып кала, ахрысы.

Сөйләм телендә шулай ук *таш, яңгыр, таш яуса да* дигән сүз тезмәләре дә мәгълүм:

Таулар янсын, ташлар яусын —
Ташлар ярым түгелсең,—

диелә халык җырында.

Телдә тагын «кызыл кар яугач» дигән әйтем дә билгеле. Күктән таш та, кызыл кар да яумаганлыгын без бик яхшы беләбез. Мондый хәлләр бары вулкан аткан чакта гына була. Безнең күчмә бабайлар яшәгән җирләрдә — Монголия, Алтай якларында, шулай ук Урта Азия яки Идел, Урал буе далаларында — беркайчан вулканнар атмаган. (Монда миллион еллар элекке чорлар турында сүз бармый, әлбәттә.) Мондый хәл, ягъни вулканнар атылу, югарыда әйтелгәнчә, моннан 3500 еллар элек Урта диңгезнең көнчыгыш өлешендә булган. А.Г.Галанопулос һәм Э.Бэкон язганча, Санторин (яисә элекке Атлантида) вулканы егерме биш ел дәвамында атып торган. Беренче мәртәбә атканда вулканнан кызыл төстәге көл-туфрак чыккан һәм ул якын-тирәдәге утрауларда бик калын таш катламы рәвешендә утырып калган (Гала, 99 бит).

Атлантида башкаласын төзегәндә атлантлар ташны утрауның үзеннән генә алганнар, ди Платон. Аларның өйләре ак, кызыл, кара ташлардан салынган булган. Ак, кызыл, кара төстәге ташлар, гадәттә, вулканик токымнарда очрый икән. Санторин (грекча «Түгәрәк») төркеме утрауларында бүгенге көндә дә ак, кызыл, кара төстәге кыялар бар икән (Гала, 102 бит).

Янар таулар безнең җырга
Каян килеп ничек кергән?
Тау янганын, таш яуганын
Бабайлар соң кайда күргән?
Нәтиҗәсе, минемчә, бер:
Ул бабайлар безнең, димәк,
Бу җирләргә шундый яктан
Күчеп килгән булса кирәк,—

дип яза шагыйрь Әхмәт Исхак «Тарихка бер адым» дип

аталган шигырендә. Шагыйрь сүзләренә өстәп монда ни дә булса әйтергә кирәкми дә кебек.

Телдә тагын *җир йоту, җир убу* кебек сүзтезмәләре, «җир йотсын!», «җир упсын!» кебек каргыш сүзләре дә бар. Вулкан атылуларны, вулкан атканда күктән «кызыл карлар» яуганын, тау-ташларның, авыл-шәһәрләрнең җимерелеп, диңгез төбенә, «җир авызына» кереп китеп юк булуларын үз күзләре белән күргән һәм менә шундый фаҗигале хәлләрне үз башыннан кичергән кешеләрдә генә туарга мөмкин мондый куркыныч сүз тезмәләре.

## 26. ФЕСТ ДИСБЕСЕ ҺӘМ КАЙБЕР БАШКА ЯЗУ СИСТЕМАЛАРЫ

Фест дисбесен җентекләп тикшерүчеләр андагы рәсем-билгеләрнең һәм гомумән дисбенең башка бернинди язуга да охшамаган булуы турында язалар. «Фест дискысы язуы башка төр язулардан аерылып тора. Крит язуларына ул охшамаган һәм каяндыр читтән китерелгән сыман тоела»,— ди И.Фридрих (Фри, 86 бит). Дж.Чедуик та шундый ук фикер әйтә.

Чыннан да шулаймы соң бу? Юк, алай түгел. Барыннан да элек, дисбегә формаль яктан охшаш булган табылдыклар турында әйтергә кирәк. Италиядә, Маньяно-да табылган һәм б.э.к. VI гасырга карый торган кургаш «таблица» Фест дисбесен хәтерләтә. Бу «таблица» дөрес булмаган түгәрәктән гыйбарәт. Түгәрәкнең уң ягына спираль рәвешендә сызыклар сызылган, спираль эченә тоташтан этруск язуы билгеләре төшерелгән. «Таблица»-ның сул ягында спираль сызыклары юк, ләкин язу спираль рәвешендә урнаштырылган (Дир, 565 бит, рәсем 261).

Борынгы Вавилон территориясендә табылган һәм б.э.к. II гасырга карый торган балчык тәлинкә дә Фест дисбесе рухында ясалган. Тәлинкәнең диаметры 18,2 см; аның эчке ягына кечерәйгәннән-кечерәя барган түгәрәкләр рәвешендә арамей телендә сихер сүзләре язылган. Тәлинкә кайчандыр әфсен эшләрендә файдаланылган (КБ, 187 бит).

Фест дисбесе рухы татар халкында да исән. Татарларда тәлинкә эченә спираль рәвешендә түгәрәкләп дога сүзләре язу, шул язуны суда сыеклап эчү гадәте бар. Мондый «шифалы» су төрле авыруларга дәва дип уйланыла. Мәсәлән, «Мулла бәете» дип аталган бәеттә «Зәгъфран белән тәлинкә язам» дигән сүзләр бар (Бә, 170 бит).

Дисбедәге кайбер рәсем-билгеләрнең башка төр язулардагы билгеләргә охшавы турында без инде әйтеп киттек. Мәсәлән, «су» төшенчәсен белдерүче дулкынлы өч

сызык шумер, мисыр, хет, элам, борынгы кытай язу системаларында кулланылган. Гарәп язуындагы *с* тартыгын белдерүче дулкын сыман өч тешле билге дә иң әүвәл «су» дигәнне аңлаткан, ахрысы. «Су» билгесе өстенә өч нокта куйсак, бу *ш* тартыгын белдерәчәк. Күрәсең, бу «шу»ны күз алдында тотадыр. Теоретик яктан *су* белән *шу* бер үк мәгънәгә ия. Гарәпчә *с* тартыгы билгесенең өч тешле булуы һәм *ш* авазын белдерү өчен аның өстенә өч нокта кую «су» билгеләренең башка төр язуларда өч сызыктан торуына ишарәләмичә, тагын нәрсәгә ишарәли соң?!

Дисбедәге «мөгеш», «ишкәк», «сайка», «йайа» рәсемнәре борынгы мисыр язуында да очрый. Бу ике язуның барыннан да бигрәк төп принциплары охшаш. «Мисыр язуында бер үк авазны белдерү өчен төрле билгеләр кулланыла һәм бер аваз күп төрле алымнар ярдәмендә аңлатылырга мөмкин» (Дир, 81 бит). Фест дисбесе язуында без нәкъ менә шундый принцип белән очраштык та инде.

Мисыр иероглифик язуында «җәя» сурәте М хәрефе рәвешендә (Фри, 247 бит, рәсем 20). «Сугышчы» кулындагы җәя дә *М* хәрефе кебек (Дир, 82 бит, рәсем 29/1). Шул ук вакытта Мисыр рельефларында сурәтләнгән сугышчыларның җәяләре *М* рәвешендә түгел! Мәсәлән, номнарның үзара сугышын күрсәткән рәсемдә сугышчыларның җәяләре латинча *D* хәрефе кебек. Димәк, мисыр иероглифик язуын да, дисбе язуын да бер үк дини-фәлсәфи карашларда торган һәм этник яктан бер үк төрле халык вәкилләре иҗат иткән дип әйтергә туры килә.

Фест язуыннан соңгырак чорларда барлыкка килгән язу системаларында дисбедәге билгеләргә охшаш билгеләр табарга була. Мәсәлән, Сириядә, Библда табылган язулы таштагы билгеләрнең берничәсе дисбе рәсемнәренә охшаш. Испаниядә табылган һәм «Иберия ташы» дип аталган язуда, Төньяк Африкада табылган һәм «Ливия язуы» дип аталган язуда, лидия алфавитында Фест дисбесендәге рәсем-билгеләргә охшаш билгеләр бар.

Дөньядагы бик күп халыкларның язу системалары грек һәм латин алфавитларына нигезләнгән. Грек алфавиты үзе көнбатыш семит язулары, аерым алганда, финикия язуы үрнәгендә иҗат ителгән дип уйланыла. Шул рәвешчә, Европадагы, Азиядәге, Америкадагы һ.б. континентлардагы язу системаларының башлангычы семит язуларына барып тоташа булып чыга.

Семит язуы үзе каян, ничек барлыкка килгән соң?

Б.э.к. 3—4 мең еллар элек Кече Азиядә уйлап табылган шумер чөй язуы үз заманында Ассириядә, Вавилонда, борынгы Иранда кулланылган. Ләкин чөй язуы киң

тарала алмаган һәм алфавит дәрәҗәсенә күтәрелмәгән. Димәк, семит язуларын шумер чөй язуыннан чыгарып булмый. Кайбер галимнәр, семит язуы, күрәсең, мисыр язуы үрнәгендә барлыкка килгәндер, диләр. Ләкин мондый фикер дә тулы теләктәшлек тапмый.

«Көнбатыш семит язуының үзеннән элегрәк булган язу системалары белән тышкы формасы буенча да, эчке формасы буенча да бәйләнеше мәсьәләсе хәзергә ачыкланмаган килеш кала. Борынгы Шәрыкның бөтенләй башка төрдәге язу системалары арасында ул үзенә бер урын биләп тора»,— ди язулар тарихы белгече, немец галиме И. Фридрих (Фри, 102 бит).


Америка галиме И. Гельб көнбатыш семит язуындагы билгеләрне семитлар үзләре иҗат иткәннәр дигән фикерне яклый. «Семит язуы билгеләренең формалары нинди дә булса башка язудан күчереп алынган булуы мөмкинлеген тикшереп торуның кирәге дә юк»,— ди Гельб (Ге, 277 бит). Семит язуындагы бер генә билгенең дә формасы иң әүвәл аның рәсем булуы турында сөйләми ди автор. Мәсәлән, финикия язуында беренче хәреф *алеф* дип атала. Семит телләрендә *алеф* сүзе «үгез» дигәнне белдерә. Ләкин *алеф* хәрефенең билгесе чынлыкта үгезгә охшамаган. Икенче хәреф *бет* дип атала. Семит телләрендә *бет* «өй» дигәнне белдерә. Ләкин *бет* хәрефенең билгесе чынлыкта өйгә охшамаган (Ге, 273 бит).

Дисбедәге беренче сүз *а* авазына башлана һәм беренче ике рәсем **АЛАБ** дигәнне белдерә. Дисбедән соң барлыкка килгән язу системаларында, шул исәптән, әлбәттә, көнбатыш семит язуларында менә шул **АЛАБ** күз алдында тотыла. Крит-Атлантида чорында *алаб* ул үгезгә (букага) тиң батыр сугышчы. Дисбедәге «үгез башы» **ИР** дип атала. *Ир* белән *алаб, бука* һ.б. барысы да бер үк мәгънәдәге сүзләр. Соңгырак чор төрки телләрдә *алаб (алып, алп)* «батыр» һәм «сугышчы» буларак мәгълүм. Шулай ук ир сүзе дә шундый ук мәгънәләрдә кулланыла.

Көнбатыш семит язуын иҗат итүче *алаб, бука, ир* кебек сүзләрнең бер үк мәгънә аңлатуын бик яхшы белгән һәм беренче хәрефне *алеф* (ягъни *алаб*) дип атаган. Семит телендә *алаб-алеф* сүзенең «үгез» булуы төрки *алып*ның «сугышчы» һәм «батыр» булуына каршы килмәгән. Шул рәвешчә семит хәрефенең атамасы да *алеф (әлиф)* рәвешендә формалашкан.

Гарәп әлифбасындагы беренче *әлиф* «үгез» рәвешендә түгел, бәлки «таяк» рәвешендә белдерелә. Болай гына әйткәндә, «таяк» ул үгез дә, сугышчы да була алмый. Ләкин иҗек методы принципларына нигезләнеп фикер

йөртсәк, монда бернинди аңлаешсыз нәрсә калмаячак. *Алаб, бука, ир* сүзләре үзләренең төзелешләре белән дә, иң әүвәлге мәгънәләре белән дә Ата улын, ягъни мифик Атаның ирлек көчен белдерәләр. Гарәп әлифбасындагы «таяк» рәсеме әлеге сүзләрнең менә шул мәгънәсенә ишарәли һәм шуны чагылдыра.

Алфавит-әлифбаларда икенче хәреф *б* тартыгын белдерә. Бу хәреф билгеләренең дә башлангычы дисбегә барып тоташа. Б (латинча В) хәрефенең сурәте дисбедәге 40 рәсем АМнан алынган. 40 рәсемне  рәвешендә уңга авыштырып, беркадәр кыса төшсәк, грекча-латинча В барлыкка киләчәк.

Грек алфавитындагы беренче хәреф *альфа*, икенче хәреф *бета* дип атала. Грекча *альфа*ның да, семитча *алеф*, гарәпчә *әлиф*нең дә төрки *алаб*тан алынган һәм беркадәр фонетик яктан үзгәртелгән булуы үзеннән-үзе аңлашылып тора булса кирәк. Икенче хәреф *бета* нәрсәне аңлата соң? Семит телендә бет «өй» дигәнне белдерә, шулай булгач, грекча *бета* да «өй» булырга тиеш булып аңлашыла. Чөнки, әйтелгәнчә, грек алфавиты семит язуыннан алынган диләр бит галимнәр. Хәер, *бета* билгесе дисбедәге 40 рәсемнән күчереп алынган дидек бит әле без. Шулай булгач, аның атамасы да АМ булырга тиеш иде түгелме соң? Ләкин бер үк язу системасында беренче хәреф тә, икенче хәреф тә *а* сузыгыннан башлана алмый лабаса. Грек һәм финикия язуын иҗат итүчеләр АМның төрки телләрдәге башкача әйтелешен дә белгәннәр һәм икенче хәрефнең исемен сүзлекләргә кертелми торган менә шул икенче әйтелештән алганнар да инде. Греклар ул сүзне бөтенләй диярлек тулы килеш кулланганнар, греклар үрнәгендә һәм греклар тәэсирендә алфавит иҗат итүче семитлар *бета* сүзен *бет* рәвешендә, ягъни беркадәр кыскартып әйткәннәр.

Гарәп әлифбасын иҗат итүчеләр дә борынгы заманда мәҗбүри исәпләнелгән карашлардан читләшә алмаганнар. Әлифбадагы беренче хәреф «әлиф» булса һәм *а* сузыгын белдерсә, икенче, өченче хәрефләр *би, ти* рәвешендә формалашкан. *Би* һәм *ти* ул грекларда *бета*, семитларда *бет* булган һәм сүзлекләргә кертелми торган төрки сүзне икегә таркатудан барлыкка килгән иҗекләр генә. И.Гельб семит язуларының мөстәкыйль рәвештә барлыкка килүен яклый. Ләкин аның *алеф* билгесенең «үгез», *бет* билгесенең «өй» сурәтләренә охшамаган булуын тануы көнбатыш семит язуының башка язу системаларына бәйсез рәвештә барлыкка килүен түгел, бәлки, киресенчә, семит булмаган язулар тәэсирендә барлыкка килүен тану да булып тора.

Дисбедәге 40 рәсем **АМ** нигезендә грекча-латинча *м* хәрефе дә ясалган. Бу очракта **АМ** сурәте бер якка да авыштырылмаган, бары тик аның астагы сызыгы гына алып ташланганда, өстәге «таучыклары» туры сызыклар ярдәмендә күрсәтелгән.

Русча-татарча «и» сузыгын белдергән бер «таяк», ягъни латинча *I* дисбедәге «ишкәк» рәсемен хәтерләтә. Латинча *i* хәрефенең баш хәрефе («таяк») төрткесез языла. Латинча баш хәреф *I* белән гарәпчә «таяк» *әлиф*не чагыштырырга була. Бу хәрефләрнең тышкы күренешендә уртаклык барлыгы үзеннән-үзе аңлашылып тора. Эчке мәгънәләрендә дә, күрәсең, охшашлык, уртаклык бардыр дип әйтәсе килә.

Грекча-латинча *T* хәрефен дә без дисбедәге рәсемнәр ярдәмендә аңлата алабыз. Дисбедә атамалары *т* тартыгына башланган һәм формалары белән *т* хәрефен хәтерләткән өч рәсем-билге бар. (Мәсәлән, **ТУН, ТИ ТА.**) Гарәп әлифбасындагы «ти» хәрефе сүз башында һәм сүз уртасында бер «теш» өстенә ике нокта куеп языла. Кызу язганда ике нокта урынына кыска гына аркылы сызыкча төшерергә дә була. Ике нокталы һәм аркылы сызыкчалы бер «теш» шулай ук дисбедәге **ТИ, ТА, ТУН** рәсемнәренең бер чагылышы, ягъни *т* хәрефе булып тора дип әйтә алабыз.

Дисбедәге 22 рәсем *ди* иҗеген белдерә. Борынгы грек һәм фригия алфавитындагы *д* хәрефе өчпочмак сурәте рәвешендә булган. Әлеге *д* хәрефен дисбедәге 22 рәсемнән (*ди* иҗеген белдерүче билгедән) күчерелеп, беркадәр үзгәртелгән булырга тиеш дип исәплибез.

Латинча *S* хәрефе дисбедәге озын муенлы су кошы «сайка» рәсеменнән алынган булса кирәк. Дисбедәге «су» билгесе *эн*нең өч сызыгын төрле рәвештә файдалану нәтиҗәсендә латинча *N (эн)*, грекча Н («эта») ясалган. *Н* («эта») борынгы ио язмаларында *е*не түгел, бәлки *á*ны белдергән, ди Томсон. Әлеге *á* дисбедәге *эн*нең *ә* сузыгын чагылдыра булса кирәк. Б.э.к. XVI гасырда Көнбатыш Кариядә вертикаль өч сызык (III) *э* авазын аңлаткан. Грек-латин алфавитындагы һәм шулар нигезендә барлыкка килгән алфавитлардагы *е* һәм *э* хәрефләрен дә дисбедәге **ӘН** сурәтенең өч сызыгыннан файдаланып һәм *эн* сүзенең әйтелешен күз алдында тотып иҗат ителгән булырга тиеш дип исәплибез. Шушы уңайдан кайбер хәрефләрнең әйтелешен искә төшерергә була. Мәсәлән, латинча *N* русча-татарча *Н эн* дип, *м* хәрефе *эм* дип әйтелә. «Эн»не *эн*, «эм»не *эм* һәм *ам* дип аңлау читен түгел.

Шул рәвешчә, алфавит-әлифбаларның барлыкка килүендә дисбенең тәэсире, һичшиксез, булган дип әйтәсе килә.

## Дүртенче бүлек

# ТӨРКИ-ЛАТИН УРТАКЛЫКЛАР

### 1. БОРЫНГЫ РИМ. ЭТРУСКЛАР

Урта диңгез бассейны илләре турында сөйләп тә, Рим һәм римлыларны онытып калдырсак, борынгы халыклар тарихының бер чите китек булыр иде, мөгаен. Шуны истә тотып, римлылар һәм төрки-рим мөнәсәбәтләр турында да беркадәр мәгълүмат биреп китәргә кирәктер кебек.

Римлылар тарихта греклардан соң калкып чыгалар һәм үз заманында Урта диңгез буе халыклары арасында гына түгел, гомумән Көнбатышта, хәтта бөтен дөньяда иң көчле һәм югары культуралы җәмгыять төзүгә ирешәләр. Римлыларны еш кына европалыларның остазлары дип атыйлар. Римлылар үзләре кем шәкертләре соң дигәндә, барыннан да элек этрускларны искә төшерәләр.

Хәзерге Италия җирләренә этрусклар читтән килгәннәр дигән караш бар. Геродот язганча, этрусклар башта Кече Азиядә яшәгәннәр. Аннан күченгәнче алар лид дип аталганнар. Лидларның иң беренче ата-бабалары Лид дип аталган. Лид исә Кар белән Мисның туганы булган. Кече Азиягә лидлар да, кар һәм мислар да утраулардан күченгәннәр ди Геродот. Хәер, бу хакта безнең беркадәр сүз булган иде инде.

Этрускларның Кече Азиядән күченүләрен Геродот болай аңлата. Лидия илендә Атис дигән патша вакытында 18 елга сузылган ачлык була. Ачлыкны онытып тору өчен лидлар төрле уеннар уйлап табалар. Шул рәвешчә, шакмаклы уйнау, ашык, туп уеннары һәм (шахмат уеныннан кала) башка төр уеннар уйлап табыла ди тарихчы. Ачлыкка түзәр тәкатьләре калмагач, Атис патша үз халкын икегә бүлә. Бер төркемгә үзе баш була, икенче төркемгә улы Тирренны баш итеп куя. Шобага салгач, Тиррен җитәкчелегендәге лидлар, ватаннарын ташлап, яңа җир эзләп китәргә мәҗбүр булалар. Беркадәр вакыттан соң алар Апеннин ярымутравына барып чыгалар, яңа җирдә яңа шәһәрләр корып, аерымланып яши башлыйлар. Күченеп килгән халык үзенең беренче патшасы исеме белән Тиррен (Тирсен) дип атала башлый.

Ләкин б.э.к. I гасырда Римда яшәгән икенче бер тарихчы — Диониси Галикарнаслы Геродот фикерләрен кире кага. Аныңча, этрусклар беркаян килмәгәннәр, го-

мергә шунда, Италиядә яшәгәннәр. Атисның улы да Тиррен түгел, бәлки Тореб булган икән.

Бу серле халыкны греклар тиррен яисә тирсен дип, латиннар этруск яисә туск дип атаганнар. Халыкның үз атамасы расен яки расенна булган.

Италия җирендә б.э.к. IX гасырда ук этруск авыллары, шәһәрләре булган дип уйланыла. Ләкин ышанычлырак мәгълүматлар б.э.к. VIII гасырга карый. Б.э.к. VI гасырда Италиянең төньяк-көнбатыш өлешендә, хәзерге Рим шәһәреннән төньяктарак, 12 шәһәр федерациясе оеша һәм этрускларның иң көчле чагы да шушы чорга туры килә.

Этрусклар сугышчан һәм батыр халык булалар. Аларда атлы гаскәр дә, хәрби диңгез флоты да була. Хәрби максатларда быргы куллануны беренче булып этрусклар башлап җибәрәләр. Безнең эра башында яшәгән рим тарихчысы Тит Ливий: «Римга нигез салынганчы ук инде этрусклар коры җирдә һәм диңгездә бик зур киңлекләргә хуҗа булганнар»,— ди (Бу, 13 бит). Этрусклар хакимлеге Италиянең көнчыгышындагы һәм көнбатышындагы Тиррен һәм Адриатик диңгезләргә, диңгез буендагы илләргә, төньякта исә Альп тауларына кадәр сузылган булган.

Б.э.к. 535 елда этруск флоты, карфагеннар белән берлектә, Корсикада грекларга каршы сугышта зур җиңүгә ирешә. Ләкин күп тә үтми, 524 елда грек колонистларының Апеннин ярымутравындагы Кумы (Киме) шәһәренә каршы сугышта этрусклар җиңелүгә дучар булалар. Шуннан соң 12 шәһәрдән торган этрусклар берләшмәсе көчсезләнә башлый. Б.э.к. III гасырда латиннар, греклар, кельтлар (галлар) белән булган өзлексез сугышлар нәтиҗәсендә этрусклар тар-мар килеп бетәләр һәм Италия җирендә калкып чыккан яңа көч — Рим кулы астында калалар. Тора-бара этрусклар үзләренең телләрен, милли үзенчәлекләрен онытып, тулысынча латинлашалар һәм «римлылар» исеме астында яңа дәүләт, яңа культура иҗат итүдә катнашып китәләр. Б.э.к. II гасырда этруск теле тәмам онытылып юкка чыга.

Этрусклар тарихы, культурасы белән кызыксыну Рим империясе вакытында ук башлана. Мондый кызыксыну гасырлар буена дәвам итә. Бүгенге көндә дә этрусклар мәсьәләсе борынгы Урта диңгез бассейны илләре тарихының ачыкланмаган иң әһәмиятле серләренең берсе булып кала бирә. Этруск культурасы, сәнгате, дине, теле, гореф-гадәтләре әле дә, соклану, гаҗәпләнү белән бергә, бетмәс-төкәнмәс сораулар тудыра.

Әүвәлге этруск өйләре түгәрәк формада булган. Нигезе түгәрәк өйнең түбәсендә төтен чыгу өчен ачыклыгы, идән

уртасында — учагы булган. Этруск каберләре дә түгәрәк формада. Түгәрәк куыш өстенә конус сыман итеп балчык өелгән яисә таш түбә корылган. Бу таш түбәне «ялган гөмбәз» дип тә атыйлар. Ялган гөмбәз Микена каберлегендә һәм гомумән борынгы Шәрык төзелешендә киң кулланылган. Этрускларның латинча Цере (этрускча цисра) дип аталган шәһәрләре янында диаметры 48 метрга җиткән шундый кабер (тумул) калдыгы табылган.

Этруск шәһәре салынасы урынны иң элек түгәрәкләп сөреп чыкканнар. Сабанга үгез белән сыер җигелгән. Булачак түгәрәкнең тышкы ягыннан үгез, эчке ягыннан сыер барган. Сөрелгән сызык эзеннән шәһәр коймасы салынган.

Әүвәлге чор этруск шәһәр калдыкларын тикшереп карагач, археологлар шундый нәтиҗәгә килгәннәр. Этруск шәһәрләре шәһәр төзелешенең идеаль принципларына туры килми икән. Шәһәрләр ничек туры килде, шулай төзелгән, имеш. Шәһәр урамнарының күпчелеге, җир өсте рельефына яраклаштырып, кыек-мыек салынган, төрлечә боргаланып беткән икән. Этрурия шәһәрләрендә бары тик б.э.к. VI—V гасырларда гына бер-берсен туры сызык рәвешендә кисеп чыккан урамнар, кварталлар барлыкка килә башлаган икән. (Бу, 142—144 битләр.) А.Лео Оппенхейм дә Крит шәһәрләре турында шундыйрак фикерләр әйткән иде. Тик урамнарның кәкре-бөкре булуын Оппенхейм җир өсте рельефына сылтамыйча, Крит кешеләренең шәһәр төзелеше мәсьәләсендә бернинди принциплары юклыгы белән аңлаткан иде.



Рәсем 8. Ветулониядә табылган этруск язулы кабер ташы.

Этрускларның тышкы кыяфәтләре европеоид расаның Урта диңгез буе тибына карый. Этруск кешеләрен чагылдырган сурәтләрдә алар озын борынлы, тар, озынча битле итеп күрсәтелгәннәр. Этруск сугышчыларының чәчләре озын, берничә толымга үрелгән. Мәсәлән, Ветулониядәге б.э.к. VII гасырга карый торган Авл Фелуск кабер ташындагы сугышчының чәче шундый. Баш киеме «диң-

гез халыклары»ның калпагын хәтерләтә. Сугышчының сул кулында — түгәрәк калкан, уң кулында — ике яклы балта. Калканга алты яфракчыклы кашкарый сурәте төшерелгән. Этруск көзгесендәге атлы сугышчының да башында каурыйлары тырпаеп торган баш киеме; калпак астыннан озын чәч толымнары чыгып, җилфердәп бара (Бу, 10 бит).

Этрускларның өстәлләре өч аяклы һәм тәбәнәк булган. Борынгы тирсеннар кием-салымнарын сандыкларда саклаганнар. Бәйрәм вакытларында төрле уеннар, ярышлар оештырганнар. Спорт уеннарыннан ат чабышлары һәм йодрык сугышлары булган.

Этруск хатын-кызлары гаиләдә һәм җәмгыять тормышында актив катнашканнар. Алар ирләр белән беррәттән төрле уеннарда һәм күңел ачуларда, ярышларда катнаша алганнар. Б.э.к. III гасырда яшәгән рим драматургы Плавт: этруск кызлары үзләренә бирнәлек мал җыю өчен проституция белән шөгыльләнәләр дигән сүзләр язып калдырган (Бу, 150 бит). Белүебезчә, мондый йола, мондый гадәт борынгы Кипрда, Вавилонда һәм Критта да булган. Ләкин моның нигезенең әхлакый бозыклыкка түгел, бәлки бик борынгы дини карашларга кайтып калганлыгын без инде беләбез дип уйлыйм.

Легендаларда әйтелгәнчә, Рим шәһәре дә «буталчык» план нигезендә салынган һәм аны латиннар түгел, бәлки этрусклар салган. Бу хәл б.э.к. 753 елда булган дип уйланыла. Рим шәһәренең беренче патшалары этрусклар — Тарквини Приск, Серви Тулли һәм Горур Тарквини булган. Бу патшалар үзләре этрускларның унике шәһәр берләшмәсенең берсе — Тарквини шәһәре патшалары нәселеннән булганнар. Латинча язылыштагы Тарквини шәһәре исеменең этрускча язылышы — Тархна. Тархна шәһәренә Тархон дигән кеше нигез салган.

Мифларда әйтелгәнчә, Рим шәһәренең атамасы Ромул исеменнән алынган. Ромул, Рем исемле игезәкләр Рея Сильвия һәм сугыш алласы Марсның уллары булганнар, имеш. Рея Сильвияне Илия дип тә атаганнар. Илия яисә Рея Сильвия үзе Альба Лонганың патшасы Нумиторның кызы була. Нумитор патшаны бертуган энесе Амули тәхеттән бәреп төшерә һәм аның урынына патша булып кала. Киләчәктә игезәк балаларның берәрсе үзен дә тәхеттән бәреп төшерә-нитә күрмәсен дип куркып, Амули патша Рем белән Ромулны Тибр елгасына ташлата. Суга ташланган балаларны дулкын ярга китереп чыгара. Яр буенда аларны ана бүре табып ала, имезә һәм балалар исән калалар. Ана бүре имезеп үстергән малайларны соңыннан Фаустул дигән көтүче белән аның хатыны Акка

Ларенция тәрбиягә алалар. Үсә төшкәч Рем белән Ромул, Амулины үтереп, бабалары Нумиторны яңадан үз тәхетенә утырталар. Соңга таба Рем белән Ромул үзара талашып китәләр, Ромул үзенең энесен үтерә һәм Рим шәһәренең бердәнбер патшасы булып кала. Альба Лонга патшасы Нумитор үзе атаклы Троя батыры Эней нәселеннән була. Эней исә Троя патшаларының тәхеткә хокукы булмаган кече буын нәселеннән дип исәпләнелә. Троя җиңелгәч, яраланган Эней карт атасы Анхизны кулбашына күтәреп, ут капкан шәһәрдән алып чыга һәм качып китә. Төрле җирләрдә бәрелеп-сугылып йөргәннән соң Эней һәм аның юлдашлары булачак Рим җиренә килеп җитәләр. Энейнең бер юлдашы Тархон дип атала.

Римлыларның Эней, Рем, Ромул турындагы мифлары да, бүгенге галимнәр исәпләгәнчә, этруск мифларына кайтып кала. Бу уңайдан Алтай төрекләренең килеп чыгышы турындагы легендаларны искә төшермичә мөмкин түгел. Борынгы төркиләр мифында да яуда исән калган һәм киләчәктә ыру башы булачак ун яшьлек малайны ана бүре үлемнән коткара. Этрусклар да (һәм римлылар да!) — ана бүре токымнары, Алтай төркиләре дә — ана бүре токымы дигән сүз була түгелме соң бу?! Мифларның төп эчтәлеге шуңа кайтып кала лабаса. Аерма тик кайбер детальләрдә генә. Тагын шунысын да әйтик, археологлар Төньяк Таҗикстанда, борынгы Уструшана хәрабәләре астында ике игезәк баланы имезүче ана бүре сурәте тапканнар (Нег, 54—56 битләр)*. Бу инде Рем, Ромул һәм аны имезүче ана бүре турындагы мифны хәтерләтә. Борынгы римлыларда *Таци, Тацит* дигән кеше исемнәре булган. Төркичә бу *Таҗи* һәм *Таҗит* дигәнгә туры килә. Татарда *Таҗи* исеме гадәти булса да, *Таҗит* дигән исем юк. Шулай да *Таҗетдин* бар. Бу исемнең әйтелеше *Таҗит тин*. Таҗит рәвешендәге *Мәҗит* һәркемгә мәгълүм исем. Римлыларда *Тацит (Таҗит)* формасында билгеле булган исемнең *Тацик* ягъни *Таҗик* варианты да булган булырга мөмкин. Бүгенге *таҗик* халкы атамасын кайчандыр һәм ниндидер сәбәпләр аркасында Урта Азия якларына күченергә мәҗбүр булган этрускларның Таҗик исемле атаклы кешеләре исеменнән алынган дип исәпләргә була. Таҗикларның борынгы ата-бабаларының кайчандыр Көнбатыштан күченеп килгән булулары ихтималын

---

*Шул ук хәрабәләр арасында табылган төрбәләрдәге мәетләрнең баш сөякләре махсус рәвештә деформацияләнгән була. әлеге төрбәләр салынган чорларда мондый йола башлыча гуннарда була дип яза археолог А.Белогорский (Бел, 64 бит).

дәлилләргә ярдәм итә торган тагын бер-ике факт бар. Борынгы Ираннан төньякта яшәгән төрки халыкларны Фирдәүси үзенең «Шаһнамә» дастанында тураннар дип атый. Бүгенге көндә этрускларның дөрес укылган сүзләре арасында Туран дип аталган алиһә исеме дә бар. Туран грекларның матурлык алиһәсе Афродита, латиннарның Венера дигән алиһәләренә туры килә. Афродитаның, белүебезчә, Урания дигән исеме дә бар. Уранияне без Нурания дип төзәттек. Нурания белән Туран (ия) бер-берсенә бар яктан да пар килгәннәр дип әйтәсе килә.

Бүгенге галимнәр исбатлаганча, этрусклар Италия җиренә чыннан да Урта диңгезнең көнчыгышыннан күченеп килгән булырга тиешләр. Күченү төрле чорда һәм төрлечә булган, ахрысы. Бу уңайдан галимнәр «диңгез халыклары» шерденнарны һәм туршаларны искә төшерәләр. Ләкин җиңелгән Троя кешеләренең күченүе турындагы хәбәрләр дә дөрес булырга мөмкин. Иң дөресе шул: «диңгез халыкларыннан» да, Троя сугышчыларыннан да элегрәк бу җирләргә тагын да борынгырак Крит-Атлантида кешеләре килеп урнашкан булырга тиешләр. Гомумән, Урта диңгезнең көнчыгышы белән көнбатышы арасында элемтәләр беркайчан тукталып тормаган. Борынгы Сардиния, Корсика һәм Балеар утрауларының югары культурасы моңа дәлил булып тора.

## 2. БОРЫНГЫ РИМ. ТИРСЕННӘР

Этрусклар грек хәрефләре белән язганнар. Металлдан, таштан, балчыктан һ.б. материаллардан ясалган әйберләрдә, кабер ташларында этрускларның кыска-кыска гына сүзләре, җөмләләре сакланып калган. Этруск язулары арасында берьюлы ике телдә, мәсәлән, этруск һәм финикия телләрендә язылган һәм бер үк эчтәлекле дип уйланылган истәлекләр бар. Этруск теленә кагылышлы материаллар шактый күп. Этруск сүзләре чагыштырмача җиңел укыла, ләкин аларны аңлавы гына бик үк җиңел түгел икән. Этрусклар турындагы һәр хезмәттә шундыйрак сүзләр әйтелә. Тик шулай да бу әле этрусклар турындагы фән бөтенләй үк терәлеп, тукталып калган дигән сүз түгел. Этруск теле турында кайбер уртак фикерләр дә бар. Мәсәлән, этрусклар 26 хәреф кулланганнар һәм уңнан сулга таба язганнар. Кайбер сүзләрнең дөрес укылышы да ачыкланган.

Дөрес укылган сүзләр арасында күп кенә алла исемнәре бар. Грекларда Зевс, латиннарда Юпитер булган алла этрускларда *Тин* дип аталган. *Тин* сүзен без татарча *дин*

(«религия»), русча *день* («көн») сүзләре белән тәңгәл дип беләбез. Тинның «хатыны» Уни булган. Бу алиһә латинча *Юнона* дип атала. Унидән бигрәк безгә Юнона аңлаешлырак тоела сыман. Бу сүзне *йүн-ана* дип төзәтсәк, анага аңлатма биреп торуның кирәге дә калмаячак. Татарча *тирә-йүн* дигән парлы сүздәге *йүн* дә ул кадәр үк аңлаешсыз түгел. *Тирә-йүн* тулаем-җир, җир өсте, якынтирә дигәнне белдерә. *Йүн*нең «җ» вариатындагы *җүн* исә *җүнле, җүнсез* сүзләрендә күренә. Бу очракта *җүн — йүн* ниндидер яхшы нәрсә булып аңлашыла. Тинның «хатыны» Йүн (Җүн) начар нәрсә булмас, әлбәттә. Алиһә ләбаса ул!

Этрускларның шулай ук Турмс, Царслан дигән аллалары да булган (Бу, 166 бит). Турмс дигән алла җир асты дөньясының хакиме исәпләнелгән. Турмс үлгән кешеләрнең җаннарын теге дөньяга озатып куя дип уйланылган. Бүгенге татар телендәге «яшәү»гә тиң «тормыш»ның элегрәк, күрәсең, башка төрле мәгънәсе дә булгандыр дип әйтергә туры килә. Бит борынгылар карашынча, теге дөньяда да, үлгәч тә яшәү дәвам итә. Царслан этрускларда сугыш алласы исәпләнелгән. Чиләбе өлкәсендә Миас шәһәре янында Сарслан дигән татар авылы бар. Татар шагыйре Акмулла шунда үтерелә. *Царслан* сүзен бүгенге *арыслан* дип беләбез. Сугыш алласының арыслан булуы бер дә гаҗәп түгел. Этрускларның Кече Азиядәге ватаны — Лидия патшалыгында арыслан изге хайван исәпләнелгән һәм алтын акчаларга арыслан сурәте төшерелгән булган. Арыслан мәгънәсендәге сүз этрускларда *leu* һәм *araz* сүзләре белән дә белдерелгән (Нем, 96 бит). Бер үк хайванның берничә исем белән аталуын этруск телендәге диалектлар чагылышы дип аңларга да була. Ләкин *арыслан* үзе дә *арыс* һәм *лан* кисәкләреннән тора. *Леу, лан* һәм русча *лев* өчесе дә бертуган — Кояш уллары. Белүебезчә, арыслан ул кояш символы, Кояш исә иң бөек һәм иң көчле сугышчы да. Латиннарның сугыш алласы Марс исеме дә этруск теленнән алынган дип уйланыла. Әлеге сүзнең *м* тартыгын алып ташласак, *Арс*, ягъни янә дә *Арыс* барлыкка киләчәк. Хәер, грекларның сугыш алласы *Арей* яисә *Арес* исеменең соңгысы да, күрәсең, *арыс* булгандыр дип әйтергә туры килә. Греклар да, латиннар да үзләренә сугыш алласы «уйлап тапканда» төрки «арыслан»дагы *лан* иҗекләрен генә төшереп калдырганнар.

Этрускларның сугыш аллалары гына түгел, үз атамалары *расен (ра-сен)* шулай ук «кояш улы» дигәнгә туры килә. Рим шәһәренә нигез салучы мифик *Рем* белән *Ромул* да — кояш уллары. Хәер, *Ре-м* генә «кояш улы»,

*Ромул* исә «кояш улының улы», ягъни *Рем* кебек туры-дан-туры «кояш улы» түгел, бәлки чын кешегә якынрак шәхес. Ромулның әүвәлгерәк формасы Рамул булган булырга тиеш. *Рам* исә тулырак әйтелештә *Рама* булгандыр кебек. Бүгенге *Рамазан (Рама-зан)* исемендә *Ромул* мәгънәсе чагыла. Крит патшасы Миносның бер туганы (Зевс белән Европаның улы) Радамант дип аталган. Грек мифларында Радамант формасында сакланып калган сүзнең нигезе Рамазан (Рамадан)га кайтып кала, ахрысы.

Ана бүре имезеп саклап калган балаларны тәрбияләүче Фаустул белән аның хатыны Акканың исемнәре дә төрки. *Фаустул* сүзен *Фаус-тул* дип тә, *Фаус-(т)ул* дип тә таркатырга була. Сүз уртасындагы *т* тартыгын артык дип исәпләсәк тә, исәпләмәсәк тә, мәгънәсе белән дә, формасы белән дә төрки «ул»га зыян килми. Фаус исеменә килгәндә, «Илиада»да Этолиядәге бер патша Фоас дип атала (Ил, II, 638). Татарда әле дә Фәүәс дигән исем бар. Акка исә, белүебезчә, «хөрмәтле хатын-кыз» яисә «апа» дигәнгә туры килә.

Этруск кеше исемнәре арасында Гай исеме дә булган. Гай исеме борынгы римлылар арасында да еш очрый. Мәсәлән, Гай Гракх, Гай Цильний Меценат һ.б. Иң атаклы «Гай»ларның берсе, әлбәттә, Гай Юлий Цезарь. Б.э.к. 100—44 елларда яшәгән мәшһүр рим гаскәр башлыгы, политик эшлекле һәм язучы. Гай бүгенге татарда да бар. Мәсәлән, бию остасы артист Гай Таһиров исеме һәркемгә мәгълүм дип уйларга кирәк. Артист кешенең Гай дип аталуын шигъри исем (псевдоним) дип тә уйларга була, әлбәттә. Ләкин Гай исеме халыкта да бар икән. 1978 елда Казан галимнәренең диалектологик экспедициясе вакытында Башкортстанның Мишкә районы Янагыш авылында яшәүче 68 яшьлек Гай Бикбулатовтан сөйләм тексты язып алынган. 1910 елда туган бу Гайның шигъри исемнәргә-псевдонимнарга берничинди катнашы юктыр дип әйтәсе килә (Бай, 105, 106 битләр). Ялгыз Гай гына түгел, Гайнулла, Гайнетдин кебек исемнәрдәге Гай да бик борынгы *Гай*ларның дәвамы булса кирәк. Мәсәлән, *Гайнулла* исеме *Гай* һәм *Нулла* өлешләреннән тора һәм һәр икесе аерым-аерым исемне белдерә, ахрысы. Борынгы Римның икенче патшасы, б.э.к. 715—672 елларда хакимлек иткән Нума Помпили дигән кеше булган (Дво, 680 бит). Борынгы заманда *Нума* дигән кеше булгач, *Нула* дигән кеше дә була алган дип исәплибез. *Гайнулла* исеме ахырындагы *ла* иҗеге *улы* дигәнне белдерә. Югарыда мисалга китерелгән *Гайнетдин*нең әйтелеше

*Гайнеттин*. Бу сүзне *Гай Нет Тин* рәвешендә таркатабыз. Латиннарның диңгез алласы *Нептун* этруск телендә Нетун дип аталган. *Гайнетдин* исемендәге *нет* шушы *Нетун*ның «яртысы» булырга мөмкин. Ахыргы *тин* исә *нет*ның (дөресе — *нит*ның) «алла» булуын раслый.

Гай Юлий Цезарьның Юлий һәм Цезарь исемнәре дә саф төрки сүзләр. Юли, Юлия исемнәре латиннарда киң таралган. Троядан качкан Энейның улы мифларда Юл дип атала. Гай Юлий Цезарь үзен Эней нәселеннән дип белгән. Аның фамилиясендәге Юлий шуңа ишарәли дә. Римның атаклы императоры Август та Эней һәм Юлилар нәселеннән булган. Б.э.к. 44 елга чаклы ул Гай Октави дип, 44 елдан Гай Юлий Цезарь Октавиан дип аталган. Юлиның *р* варианты русларда Юрий исемендә күренә. Юлиның Юлай формасы төркиләрдә мәгълүм.

Римлыларның легендар Энейлары төрки эне сүзенә тәңгәл. Әле генә әйтелгәнчә, Эней ул, ягъни эне кеше, Троя патшаларының тәхеткә хокукы булмаган кече буын нәселеннән чыккан. Борынгы төрки цивилизацияләрдә ир туганнардан бары өлкән яшьтәгеләрнең генә — агаларның гына тәхеткә хокукы булган. Мәсәлән, шумерларның иң беренче патшалары (Киш шәһәре патшасы) Ага (Агга) дип аталган. Борынгы Мисырда һәм шулай ук Крит-Атлантида дәүләтендә бары агалар гына олы хаким була алганнар. Бүгенге агай-эне сүзендә дә, Эней сүзендә дә ахыргы *й* тартыгы артык аваз. Элеккерәк заманнарда *эне* сүзенең *эней* формасы да булгандырмы, әллә бу мифик Эней азагындагы *й* бары чит тел тәэсирендә генә барлыкка килгәндерме, әйтүе кыен. Монда шуны да теркәп узасы килә: Эней юлдашлары арасында Ахат (ягъни Әхәт), Акмон (Акман), Гиас, Солим, Авлет дигән кешеләр дә булган. Гиасны Гаяз яки Гыйас, Солимны Сәлим, Авлетны Дәүләт дип аңлау өчен бернинди каршылык юк.

Этрускларда тагын Артила дигән исем дә булган (Бу, 47 бит). Бу исем V гасырда яшәгән атаклы гун патшасы *Аттила* исеме калыбында ясалган. *Ат Ти-ла*ның да, *Ар Ти-ла*ның да мәгънәләре дә, формалары да бер үк. Бары тик уңай сыйфат белдерүче иҗекләрнең *р* һәм *т* тартыкларында гына аерма бар.

Этрускларның дөрес укылган сүзләре арасында кайбер сан белдерүче сүзләр дә бар. Мәсәлән, «бер» төшенчәсе этруск телендә *ту* дип атала. Бүгенге татар телендә туның берничә төрле мәгънәсе бар. Сыйфат ролендә килгән *ту* — «симез», «кысыр» дигәнне белдерә. Башка төрки телләрдә *ту*ның «тары», «тау» мәгънәләре дә билгеле. Ту бодай, ту арыш дигәндә ту «симез» дә, «кысыр» да түгел. Бу

очракта ул «былтыр чәчелеп тә, быел яңадан чыккан (арыш, бодай)» дигәнне белдерә, ягъни моның мәгънәсе «былтыргы» яисә «әүвәлге» һәм «беренче» була.

Сөйләм телендә «тумаганга ту бишек, туса кирәк ун бишек» дигән мәкаль бар. Ту монда турыдан-туры ун санына каршы куела һәм «бер» санын белдерә. *Ту*ның «бер» санын белдерүен башка мисаллар белән дә исбатлап була. Мәсәлән, *ту-у, ту-ды* дигәндә нәрсә күз алдында тотылганлыгы үзеннән-үзе аңлашыла кебек. Бу ике сүзнең һәркайсы фигыль дип уйланыла, ләкин чынлыкта болар сан белдерүче сүзләр. *Ту-у, ту-ды, тума* сүзләре нигездә бер үк мәгънә белдерәләр һәм «ике» дигәнгә туры киләләр. Ягъни бу «бер улы ике» булып чыга. Югарыда без «ике» мәгънәсендәге сүзләргә мисал рәвешендә китереп киткән *тул, туа, дуа, два* кебек сүзләр дә татарның әлеге *туу, туды, тума* сүзләренә тәңгәл. Татарда ялгыз мәгънәсендә *дуадак* дигән сүз бар. *Дуа* «һинд-европача» ике мәгънәсендәге *дуа-два*ларга туры килә, ахыргы *дак* исә *так* сүзенә тәңгәл («җөп сан, так сан» дигәндәге так турында сүз бара). *Дуа-дак* ул «ике-бер» булып чыга. Ләкин без моны теге Тукайны Уральскига алып барган «Алты-биш Сапый рәвешендә түгел, бәлки «икенең берсе», ягъни «ялгыз» дип аңлыйбыз.

Этрускларга кагылышлы исемнәрнең берсе тиррен яисә тирсен буларак мәгълүм.

Тирреннар Көнчыгыштан килгәннәр. Күченүчеләр иң элек Сардиния, Корсика, Балеар утрауларын үзләштергәннәр дип уйланыла. Сардиния утравының төрле төбәкләрендә бүгенге көндә җиде меңгә якын гаҗәеп таш корылмалар табылган. Бу корылмалар ялгыз манаралардан гыйбарәт. Манараларның күбесе инде җир белән тигезләнеп беткән, ләкин арада исән калганнары да бар. Нигезе түгәрәк булган бу манараларның зурлыгы төрлечә — кайберсенең диаметры 11, хәтта 14 метрга җитә. Иң зур манаралар элек 18—21 метрлар биеклектә булган. Бүгенге көнгә 17,5 метр биеклектәге бер манара сакланып калган. Бу манараларның төп үзенчәлеге шунда: аларның түбәсе конус сыман булып тәмамлана һәм аларга ялган гөмбәз дигән нәрсә хас. Манараларның конструкциясе Криттагы гөмбәзле корылмаларга охшаш. Сардиниядә археологлар казып чыгарган табылдыклар белән Крит әйберләре арасында шулай ук күп кенә уртаклык бар икән (Иль, 76—91 битләр).

Сардиниядәге менә бу манараларны җирле халык нураг дип атый, шунлыктан борынгы Сардиния, Корсика культурасы фәнни китапларда «нураглар культурасы»

дип атала. Нураглар культурасы белән Крит культурасы арасында гына түгел, этрусклар культурасы арасында да уртаклыклар бар. Шул нигездә А.Н.Немировский этрусклар иң элек утрауларга, аннан соң утраулардан материкка күчкәннәр дигән фикер әйтә (Нем, 49—61 битләр). Шулай итеп, Геродот белән Дионисның һәркайсының да фикере дөрес булуы ачыклана.

Бүгенге галимнәр беравыздан диярлек Сардиния утравының исемен борынгы Мисыр язмаларындагы шерден (шардан) атамасына бәйле рәвештә аңлаталар. Ләкин Татарстанда Шырдан исемле авыллар булуы мондый фаразны кире кага — бит мисыр язуларында сарда түгел, чыннан да Шырдан сүзе чагылыш тапкан. Борынгы дөньяда Сардиниядән тыш Сарда исеме тагын икенче бер төбәктә — Кече Азиядә дә булган. Этрускларның әүвәлге ватаны Лидия башкаласы Сарда дип аталган. *Сарда* сүзен *Сар-да*, ягъни «патша улы» (патша торагы, патша каласы) дип аңлыйбыз. Дисбедә, белүебезчә, МАКА САРКА сүзе бар. Лидиядән күченеп киткән этрусклар өчен Сарда утравы да «патша торагы», «патша җире» булып аңлашылган. Башкала мәгънәсендәге сүз, шулай итеп, яңа җирдә утрауга тагылып калган. Этрускларның патшалары баштарак сар дип аталган, ахрысы. II гасырда яшәгән рим кешесе, сүзлекләр авторы Фест «этрускларның Сарда дип аталган патшалары», дигән сүзләр язып калдырган (Бу, 142 бит; Нем, 55 бит).

Татарстанда Сәрдә, Сәрдек, Сәрдегән авыллары, елгалары бар. Әлеге Сәрдә атамаларын борынгы Сарда сүзенең нечкә варианты дип карарга була. Ләкин шунысы кызык, борынгы чыганакларда «серд» (серда) дигән халык исеме дә очрый. 1960 елда Көньяк Италиянең элекке греклар шәһәре Сибарисның б.э.к. VI гасырда сердалар белән дуслык килешүе төзүләре турында бәян иткән язу табылган. Серда монда Сардиния утравын түгел, бәлки Сибаристан төньяктарак урнашкан этрусклар берләшмәсен күз алдында тота икән (Нем, 55 бит). Шул рәвешчә, тарихи истәлекләрдә төрле исем белән аталып йөртелгән этрускларның бер исеме серда, ягъни безнеңчә сәрдә булган икән дип әйтергә нигез бар.

Сәрдә-этрусклар турында тагын бер-ике фактны теркәп узасы килә. Б.э.к. VIII—VII гасырларда яшәгән борынгы грек шагыйре Гесиод тирсеннарны элек изгеләр утравында яшәгәннәр дип исәпләгән. Борынгы рим тарихчысы Тацит исә этруск шәһәрләренең «тугандаш» лидиларның Сарда шәһәренә ярдәм итүләре турында язып калдырган (Нем, 58 бит).

Шулай да *тирсен* нинди сүз булып чыкты инде? Диониси Галикарнаслы әйткәнчә, тирсен этнонимы *tyrsis* «манара» дигән сүздән алынган, тирсеннар — «манара төзүчеләр» дигәнне аңлата икән. «Манара төзүче» дигән аңлатма ни дәрәҗәдә дөрестер, әйтүе кыен. Бары шунысын гына әйтергә була: Сардиния утравында иң зур елга әле дә Тирсо дип атала. Татарстанда Тирсә суы һәм Тирсә авылы бар.

Сардиниядән төньяктарак урнашкан Корсика утравының исеме лигур телендәге Корса дигән хатын-кыз исеменнән алынган икән. Татарстанда Курса суы елгасы һәм Курса авылы бар. Борынгы этрусклар дәүләте урнашкан җирләргә якын гына, Тиррен диңгезендә Эльба утравы урнашкан. Утрауның этрускча исеме Ильва булган. *Ильва* сүзен *Ил-ба (ва)* дип таркатабыз һәм «ил улы» дип аңлыйбыз. Бу очракта материктагы 12 шәһәр берләшмәсе ил булса, якындагы Эльба (Ильва) утравы илнең бер кисәге дигән мәгънә ята түгелме соң монда?

### 3. БОРЫНГЫ РИМ, САБАЛАР

Борынгы Рим шәһәрен һәм Рим дәүләтен барлыкка китерүдә этрусклардан тыш тагын икенче бер халык та актив катнашкан. Рим шәһәренең төп халкы өч төрле кабиләдән торган. Шуларның берсе этрусклар, икенчесе латиннар, өченчесе... сабалар булган. Сабалар этрусклар федерациясенә кермәгәннәр һәм этрусклардан да, латиннардан да көнчыгыштарак — Апеннин ярымутравының, урта бер җирендәрәк, таулы өлкәләрдә яшәгәннәр. Латиннар, этрусклар исә Тиррен диңгезе яры буена якын җирләрне биләгәннәр. Саба авыллары, шәһәрләре башка кабиләләр җирендә дә булган.

Зур тарихи үзгәрешләр, политик вакыйгалар күбрәк диңгез буе илләрендә барган. Шунлыктан, ахрысы, сабалар читтәрәк калганнар. Ни генә булмасын, сабалар турында мәгълүматлар да азрак, алар белән кызыксыну да юк дәрәҗәсендә. Ләкин Ромул белән Рем турындагы мифта сабалар да телгә алына. Рим шәһәренең бердәнбер патшасы булып калгач, Ромул шәһәр бәйрәменә күршедәге саба яшьләрен дә чакыра. Эчке мәҗлесе вакытында латин җегетләре саба кызларын урлап китәләр. Ике арада сугыш башлана. Урланган саба кызлары үзләренең ирләренең дә, ир туганнарының да сугышта үлеп бетүен теләмиләр һәм шул нигездә ике якны да килештерүгә ирешәләр. Шулай итеп, Рим белән сабалар арасындагы сугыш туктап кала.

Сабаларны Апеннин ярымутравындагы борынгы җир-

ле халыкларның-италикларның бер кабиләсе булырга тиеш дип исәплиләр. Ләкин мифларда сабаларның Спартадан килгән булулары турында да мәгълүматлар бар. Карлар кебек үк сабалар да борынгы дөньяда иң көчле һәм иң атаклы кабиләләрнең берсе булганнар, ахрысы. Хәзерге Ямән территориясендә, Көньяк-Көнбатыш Гарәбстанда Саба дигән дәүләт булган. Саба Библиядә дә телгә алына. Крит утравындагы Саба атамасы әлегәчә исән. Татарстанда Саба авыллары, Саба елгасы һәм Саба районы бар. VI—VII гасырларда көньяк далаларда (Азов, Каспий буйларында) Гуннарның савир кабиләләре шактый көчлеләрдән саналган. *Савир*ны *саб-ир*, ягъни *Саба ир*ләре мәгънәсендә аңлыйбыз.

Борынгы Римдагы сабаларның мифик ата-бабалары Саба дип аталган. Саба үзе Санка исемле алла улы булган, имеш. Сабаларның үзләренең язу системалары булмаган, ахрысы. Саба турындагы мәгълүматлар башлыча грек-латин телле истәлекләрдә сакланып калган.

Без инде кайбер саба кешеләре белән таныш. Мәсәлән, Рим шәһәренең икенче патшасы Нума Помпили сабалардан булган (Дво, 680 бит)*. Сабаларның үзләренең Ромул заманындагы патшалары Тати исемле булган (999). Сабаларның бер алиһәсе Neria, Nerio (Нериена) дип аталган (668). Татарда Нәрия, Наримә, Нәрисә исемнәре бар. Латин чыганакларында «сабаларныкы» дип билгеләнгән тагын берничә исем табарга була. Мәсәлән, римлыларның Клавди (Claudius) дигән кеше исемнәре сабаларныкы булган (193). Бу сүзнең төрки формасы Келәү, Кәләү яисә Келәүче булган булырга мөмкин. Татарда «Кәләү Гайшә» дигән җыр да бар. Кәләүнең Галәү варианты да мәгълүм. Сабаларда шулай ук Clausus (Клавз) дигән исем дә булган (194). Монысын Кылавыз дип аңларга була. Ромул вакытында Римга күченгән Met(t)ius Curtis дигән саба кешесенең дә исеме тарихта сакланып калган (634). Татарда Мәттин исеме бар. Тибр елгасына килеп кушыла торган һәм сабалар өлкәсеннән ага торган бер елга Fabaris (Фабарис) дип аталган. Татарда Фәварис дигән ир кеше исеме бар. Сабалар өлкәсендәге икенче бер елга Himella (Гимелла) дип аталган (475). Татарстанда Имәлле дигән елга бар. Сабалар илендә шулай ук Tolenus (Толен) дигән елга да булган (1017). Бүгенге Татарстанда Түләмә, Башкортстанда Төйлән елгалары агып ята.

---

* Җәя эченә алынган саннар И. Х. Дворецкийның «Латинско-русский словарь. М., 1976» китабындагы бит тәртибен белдерә. Кыскалык өчен алга таба авторның исеме дә төшереп калдырыла.

Сабаларның борынгы башкалалары Reata (Реата) исемле булган (853). Ата сүзенең төркилеген исбат итеп торуның кирәге юк дип уйлыйм. *Ре* иҗеге исә «кояш» дигәнне белдерә. *Реата* тулаем «Атабыз Кояш» дигәнгә туры килә. Реата янында сабаларның Rosea (Розея) дип аталган уңдырышлы җирләре дә булган (885). Розея исемен хәзергечә Разия дип төзәтәбез.

Латин истәлекләрендә сабалар өлкәсендәге берничә шәһәрнең исеме сакланып калган. Мәсәлән, шундыйлардан Ameriola (Америола) шәһәрен күрсәтергә була (66). Әлеге сүзне Амери улы дип тә, Әмир улы дип тә аңларга була. Аниен елгасының Тибр елгасына кушылган төшендә сабаларның Antemna, Antemnae (Антемна) дигән шәһәрләре булган (78). Татарстанда мондый исемдәге шәһәр дә, авыл да, елга да юк. Ләкин сүзнең төзелеше төрки: *Ан Тем-на* яисә *Эн Тен-нә*. Тен борынгы төркиләрдә «төн» алласы булган дидек без югарыда. Тен — кояш алласы Аполлонның дусты. Римның төньяк-көнчыгыш өлешендә, Латия өлкәсендә, сабаларның Cameria (Камерия) шәһәре булган (149). Татарда Камәр, Камәрия дигән хатын-кыз исемнәре мәгълүм. Самния өлкәсендә сабаларның Casperia (Касперия) дигән шәһәрләре була (160). Татарстанда Кәшфәр елгасы бар. Татарларда Кәшферуй, Кәшфел исемнәре бар. Тит Татиның һәм Нума Помпилиның туган җирләре Cures (Куры) дип аталган. Cures шәһәре сабаларның икенче бер борынгы башкалалары исәпләнелә (280). Бу сүзне Кура дип төзәтәбез. Кура ул Тураның *къ* варианты. Татарстанда Тура авылы бар. Шул ук вакытта күп кенә борынгы төрки «шәһәр»ләр, «кала»лар *тура, кура, бура, пура* рәвешендә формалашкан. Мәсәлән, этруск телендә «шәһәр» спур дип аталган (Нем, 103). *С* тартыгы сүз башындагы *ас* иҗекләренең яисә пура алдындагы икенче бер сүзнең калдыгы булса кирәк. Римнан төньяк-көнбатышта сабаларның Cutiliae (Кутилии) шәһәрләре дә булган (282). Бу сүзне Кот (Кут) иле дип аңлый алабыз. Сабаларның шулай ук Ficula (Фикулея-425), Fidenae (Фидены-426), Foruli (Форулы-437) дигән авыллары булган. Фикулея сүзен Татарстандагы Сарабикул авылы исеме белән, Фидены сүзен Фидан дигән ирләр исеме белән чагыштырып карарга була. Форулы сүзен Фор-улы рәвешендә таркатабыз. Фор монда ниндидер изге зат булып аңлашыла. Форның үзен фар дип тә аңларга була. Монда үзеннән-үзе бар, пар, кар сүзләре искә төшә. Болар төрле кабиләләрдә изгеләштерелгән илаһи затлар булса кирәк.

Сабалар өлкәсендә Mandela (Мандела—615), Mutusca (Мутуска — 658), Nersae (Нерсы — 668), Nursia (Нур-

сия — 682), Regillus (Регилл — 863) дигән шәһәрләр булган. Боларның барысы да татарча яңгыраштагы сүзләр. Манделаны Мәндил дигән кеше исеме, Татарстандагы Мәмдәл дигән авыл исеме белән тәңгәл дип беләбез. Мутуска, Нырсы атамалары Татарстанның Саба районындагы (!) Мәтәскә һәм Нырсы авыл һәм елга исемнәре белән бер дип исәплибез. Нурсия исә татарлар арасында әле дә еш ишетелә торган хатын-кыз исеме. Регил шулай ук төрки сүз. Моны *Рег, ил* дип таркатабыз. Рәхил һәм Рәхилә исемнәре шушы Регилдан үзгәргән булырга мөмкин.

Сабаларның бер кабиләсе исәпләнелгән Марслар өлкәсеннән ага торган бер елга Telonum (Телон) дип аталган (1001). Татарстанда Теләнче авылы, Теләнче чишмәсе бар. Сабалар өлкәсендәге пелигннарның бер шәһәре Sulmo (Сульмон) дип аталган (977). Латин шагыйре Овидий шунда туган. Латиядә дә шундый исемдәге бер шәһәр булган. Әлеге Сульмон сүзен Каманың төркичә Чулман сүзе белән янәшә куеп карасак, әллә ни зур гөнаһ булмас дип исәплибез.

Латинча истәлекләрдә кайбер саба сүзләре дә теркәлеп калган. Мәсәлән, teba дигән сүз русча «бугор», «холм» дигән мәгънәләргә туры килә икән (1000). Русча бугор, холм татарча «калкулык» була. Кайбер очракта ул «түбә» дип тә әйтелә. Мәсәлән, өй түбәсе, тау түбәсе. Казагъстанда Актүбә, Кырымда Күктүбә атамалары бар.

Шулай итеп, италикларның бер кабиләсе дип уйланылган сабалар чынлыкта төркиләр — безнең еракта, чит кабиләләр арасында бүленеп калган үз кыйпылчыгыбыз икән.

### 4. БОРЫНГЫ РИМ. ЛАТИН ТЕЛЕ

Римлыларның өченче төркеме, белүебезчә, латиннар дип аталган. Гасырлар буена сузылган көрәш һәм сугышлар нәтиҗәсендә латиннар җиңеп чыга. Этрусклар, сабалар һәм шулай ук башка күп кенә кабиләләр бергә кушылып, ахыр чиктә барысы бергә римлылар дип атала башлыйлар. Латин теле хаким телгә, административ идарә, фән-культура теленә әверелә. Бүгенге көндә латин теле үле тел санала. Ләкин латин телендә язылган төрле юнәлештәге, төрле эчтәлектәге әсәрләрнең күбесе безнең көннәргә кадәр сакланып калган. Урта гасырларда Көнбатыш Европада бик озак вакытлар дәвамында латин теле дин һәм фән теле исәпләнелгән һәм барлык дини, фәнни хезмәтләр латин телендә язылган. Шуның нәтиҗәсендә Көнбатыш Европа телләренә күпләп латин сүзләре үтеп кергән. Бүгенге көндә дә медицинада, биологиядә, юрис-

пруденциядә һәм иҗтимагый тормышның башка тармакларында латин теленең урыны түрдә. Әле дә кайбер яңа телләрдә яңа сүзләр латин теле нигезендә ясала.

Рус теле аша латин сүзләре татар теленә дә үтеп керде. Мәсәлән, *революция, пропаганда, прокуратура, культура, коллектив* һ.б.

Әгәр рим культурасы этрусклар культурасына нигезләнгән икән, борынгы римлылар составында элекке этрусклар да, сабалар да булган икән, безнең көннәргә кадәр яшәп ята торган бу гаҗәеп үле телдә берәр төрле төрки тел калдыклары юк микән?

Рим тарихы белән ныклап торып кызыксына башлагач миндә шундый бер фикер барлыкка килде. Шуны истә тотып мин И.Х.Дворецкийның илле мең чамасы лексик берәмлек тупланган «Латинча-русча сүзлек» китабын җентекләп тикшереп чыктым. Төпчену нәтиҗәсе шактый уңышлы булды. 50 мең лексик берәмлекнең дүрт меңгә якыны яисә, гадиләштереп әйткәндә, өч меңнән артыгы төрки һәм төркигә охшаш сүзләрдән гыйбарәт икәнлеге билгеле булды. Хәзер монда өч мең сүз турында түгел, хәтта өч йөз сүз турында да тәфсилләп сөйләп булмас иде кебек. Шуңа күрә без кайбер сүзләр белән генә танышачакбыз.

*Аккумулятор*лы «җыючы» мәгънәсендәге сүз дип аңлаталар сүзлек төзүчеләр. Латинча ac-cumyla булса, бер өемгә җыю, өю, күбәйтү дигән мәгънәләр барлыкка килә. Авыл хуҗалыгында бу күмү, туфрак белән каплау була. Татарда бәрәңге төбенә балчык, туфрак өюне «күмү» диләр. Мәетне кабергә төшергәч, каберне күмеп куялар. Латинча да humo «погребать», «хоронить» сүзләренә туры килә (482). Cumu...га якын, ләкин монысы инде бәрәңге күмүне түгел, мәет күмүне аңлата.

*Аудитория, диктор, диктат, диктатура* кебек сүзләрдә *Ди* иҗеге катнаша. Татарда *ди* фигыле әйтү, сөйләү мәгънәсендә кулланыла. Латин телендә дә нәкъ шулай. Дөрес, латин телендә *ди* үзе генә сөйләү, әйтү мәгънәсен белдерә алмый. Мондый мәгънә dico, dixi рәвешендә әйтелә (323, 343). Мәсәлән, *диктор* сүзендәге *дик* иҗекләре төрки *дип* иҗекләренә тәңгәл. Латинча *диктор* татарча *диптор* булыр иде кебек. Мисалга китерелгән башка латин сүзләрендәге *ди* иҗекләре дә сөйләү, әйтү, боеру мәгънәләренә ия.

Бүгенге көндә барлык телләрдә дип әйтерлек актив кулланыла торган *ген* сүзен без төрки *җен* дип беләбез. Төрки *җ* тартыгының грек-латин телләрендә кайчагында *г* тартыгы аша белдерелүенә мисал итеп без югарыда грекларның *Гея* алиһәсен *Җәйә* дип аңлаттык. *Г* һәм *җ*

тартыкларының бер-берсен алыштырып килә алулары татарча Гәүһәр һәм Җәүһәр исемнәрендә һәм гәүһәр, җәүһәр (таш) атамаларында да күренә. *Г* һәм *җ* тартыгының берберсен алыштырып килә алуларын шул ук латин һәм рус телләре ярдәмендә дә исбатлап була. Мәсәлән, латинча gesticulor русча жестикулировать дип тәрҗемә ителә (455). Латинча *g* монда русча *ж* тартыгына туры килә. Татарча *җ* тартыгын *ж* тартыгының нечкә варианты дип әйтергә була. Латинча gens 1) род, родовая община; 2) потомок, отпрыск мәгънәләренә ия (453). Латинча сүзнең әүвәлге *g* тартыгын *җ* рәвешендә әйтсәк, бу татарча *җенес* булачак. Җенеснең мәгънәсе латинча gens мәгънәсенә туры килә. Татарча *җен, җенле* дигәндә ниндидер серле нәрсә күз алдында тотыла. Бу серле нәрсә һәркемдә бар. Ул кешене төрле халәткә кертә ала. *Җенес, җенси* дигәндә бу «җен» дигән серле нәрсәнең ирлек-хатынлык сыйфатлары барлыгы аңлашыла. *Җеназа* дигәндә «җене» бар кешенең үлеме күз алдына килә. Русча *жена, женщина, жених* сүзләрендә дә әлеге «җен» (ген) катнаша. Татарча *җан* да *җен* белән тигез хокуклы микән, әйтүе кыенрак. Ни генә булмасын, татар аңындагы «көндәлек» *җен* латинча серле *ген* белән бертуган.

*Коллектив, коллектор, коллекция* кебек сүзләрдә латинча collecta colli иҗекләре катнаша. Collecta, мәсәлән, сбор, складчина, взносы или пожертвования кебек мәгънәләргә ия (203), Prae colligo дисәк, бу «заранее собирать» була (792). Татарча *көлле* дисәк, бу «һәркем», «барысы да» дигәнгә туры килә. Бүгенге көндә без теләсә нинди очракта «барысы да», «бөтенесе дә» дип язабыз, шулай сөйләшәбез. Без үскәндә өлкән яшьтәгеләр көллесе, көллегесе дигән сүзләрне ешрак кулланалар иде.

*Юриспруденция* һәм *юстиция* кебек терминнарның да үзәге төрки сүзләргә кайтып кала. *Юрис...* катнашында ясалган терминнарның үзәге латинча jurandum, jurata, jurator кебек сүзләрдән гыйбарәт. Jurandum латинның архаик телендә клятва, присяга дигәнне аңлаткан. Латинча jurator «приносящий клятву» дигәнне белдерә (567). Татарча бу *юрау* була. Татарда «Юраганга юш килә» дигән мәкаль дә бар. Бүгенге юрау белән латинча «юра»ның мәгънәләре төп-төгәл тәңгәл килми. Юраның мәгънәсе киңрәк. Ул барыннан да бигрәк ант бирүне күз алдында тота. Татарча юрау исә киләчәктә нәрсә булыр икән дип фараз кылуны белдерә кебек. Ләкин элегрәк *юра-у*ның, да мәгънәсе ант биреп (ихтимал, корбан биреп) аллалар белән үзара ниндидер мөнәсәбәтләрне ныгытып куюны аңлаткандыр.

*Юстиция* сүзенең үзәге латинча jus. Мәгънәләре: право, справедливость, преимущества, привилегия, власть, суд, судилище. Татарда *юсык* дигән сүз бар. Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә *юсык*ка: йөреш-торыш кагыйдәләре, устав дигән аңлатма бирелгән (ТТАС III, 615 бит). Ал юсык, кара юсык дигән терминнар да булган. Юсыкның шулай ук тәртипле, әдәпле дигән мәгънәсе дә бар икән. Ягъни юсыкка буйсынган кеше тәртипле һәм әдәпле булып аңлашыла. Юсык-юрык дигән катнаш сүзгә шул ук сүзлектә «һәртөрле рәсми кагыйдәләр» дигән аңлатма бирелгән. Татарда шулай ук «юлчыга сусын бирү — юсын» дигән мәкаль дә бар. Монда инде юсын турыдан-туры закон, кагыйдә дигәнгә туры килә.

Латин телендә tudera сүзе русча горб, шишка, опухоль, нарост мәгънәләренә туры килә (1035). Туберкулез термины әлеге сүздән ясалган. Татарда тубыр, тубырлау сүзе мәгълүм. Тубыр яисә тубырчыкның мәгънәсе латинча tuberculum дигәнгә туры килә.

Латинча kera русча «воск» (172), татарча — кәрәз. Латинча fortuna русча судьба, случай, удел, счастье дигән мәгънәләргә туры килә (437). Татарда нишләптер сүзлекләргә керми калган фарт сүзе бар. «Фарт килеп кенә тора» дигәндә фарт очраклы бәхет, уңайлык дигәнне аңлата. Латинча maturo, maturus сүзләренең җитлеккән, өлгергән, пешкән мәгънәләре бар. Русча бу: зрелый, спелый, ранний, полный, яркий, достигший рассвета һ.б. (623). Татарча матур сүзенең нәрсә аңлатканлыгы һәркемгә мәгълүм дип уйлыйк. Матур ул «чибәр» генә түгел, тулы да, яшь һәм пешкән дә. Латинча mens сүзенең мәгънәләре русча ум, мышление, рассудок, сознание һ.б. (630). Татарда мәнле, мәнсез сүзләре бар. Мәнле булса — уйлы, моңлы, белемле, аңлы; мәнсез булса — моңсыз, уйсыз, аңсыз, мәгънәсез. Латинча nenia русча пустяк, вздор дигәнне белдерә ала (667). Татарда нәни, кечкенә, әһәмиятсез дигәнгә туры килә. Латинча pedis русча вошь (735) булса, татарча бет була. Латинча proterve, protervia, protervus кебек сүзләр русча смело, дерзко, нагло, бесстыдно һ.б. шундый кире мәгънәләрне аңлата (827, 828). Әлеге сүзләр алдыннан килгән pro...ның мәгънәләре күп төрле. Без аңа туктала алмыйбыз. Бу очракта латинча pro юклыкны белдерә. Terve, tervia сүзләренә игътибар итсәк, моның татарча *тәрбия* икәнлеген аңлау читен булмаячак. Латинча pro белән әйтелә торган tervia «тәрбиясез» мәгънәсен белдерә. Русча санап кителгән кире сыйфатларның барысы да тәрбиясезлеккә кайтып кала.

Латинча sero сүзенең ике мәгънәсе бар. Аның берсе:

сплетать, соединять, связывать, завязывать (923). Татарча бу *сыру* һәм *сару* сүзләренә туры килә. Мәсәлән, агачны корт сарып алды. Икенче мәгънә: сеять, ягъни чәчү. Татарда сөрү җир сөрүне белдерә, ләкин борынгы төрки телдә сөрү «чәчү» булган, ахрысы. Мәсәлән, «яз сөрсәң, көз урырсың» дигән мәкальдә җирне сабан белән җырту турында сүз бармый, җиргә орлык чәчеп калдыру турында сүз бара. Чыннан да, яз көне җирне сөреп тә, аңа берни чәчми калдырсаң, көз көне нәрсә урырсың?! Латинча tentum русча задержка, остановка (1005), татарча бу — *тентү*. Латинча *tor*no руста — греметь, издавать гром (1018). Татарда: *тондыру*, колак тондыру — бик каты шаулау. Латинча torno русча точить, обтачивать (1019) булса, татарда бу *тырнау* була. Бүгенге көндә veto дигән халыкара термин кулланыла. Ике ил арасындагы яисә югары дәрәҗәдәге конференцияләрдә берәр төрле килешүгә берәр як veto салса, килешү юкка чыгарыла. Кайбер илләрнең президентлары депутатлар палатасы тәкъдим иткән закон проектларына veto салу хокукыннан файдалана алалар. Veto сүзенең татарчасы *бетә*, ягъни *бетте!* Кире кагылды! Латинча сига катнашында ясалган терминнар да бүгенге көндә шактый актив кулланылалар. Мәсәлән, *куратор, прокурор* h.б. Сиганың русча мәгънәләре: забота, попечение, любознательность, разведение, надзор, опека (279). Латинча vio-curus дип әйтсәк, бу русча «дорожный смотритель» булачак. Vio — юл, curus — күрүче. Югарыдагы сигаларның барлык мәгънәләре татарча «күрү», «күреп, күзәтеп тору»га тәңгәл. Шулай итеп, еш кулланыла торган прокурор терминында да төрки *күрә* яшеренеп ята икән.

Иң ахырда тагын бер кызык кына мисал белән танышып китәсе килә. Латинча vulgo..., vuiga... катнашында ясалган берничә сүз бар. Мәсәлән, vulgator булса, русча бу распространитель булачак. Vulgo булса, переносить, разносить, смешиваться, общаться, сходится булачак (1093, 1094). Безнең өчен соңгы өч мәгънә әһәмияткә ия. Монда төрки *болгату*ның, төп мәгънәсе чагыла. Кушылу, аралашу, үзара якынаю бары болгату нәтиҗәсендә генә барлыкка килә ала. Шунысын да әйтик, Библиянең латинчага тәрҗемәсе Vulgata (Вульгата) дип атала икән. «Болгату», димәк, кайчандыр төрки телдә бер телдән икенче телгә күчерүне дә аңлата алган булып чыга.

Латинча исем-атамалар белән без беркадәр таныш инде. Хәзер тагын борынгы Римга, римлыларга кагылышлы берничә исем-атамага тукталып китик. Сицилия утравында әле дә Aetna (Этна) тавы бар. Этна тавыннан

кайчагында Этна вулканы ата. Этна тавы итәгендә элек шул исемдә шәһәр булган (45). Татарстанда Әтнә авыллары бар. Тибр елгасының борынгы исеме Albula (Албула) дип аталган (54). Татарстанда Була елгасы бар. Сүзнең ал сыйфаты, күрәсең, төшеп калган. Самния өлкәсендә Allifae (Аллифы) шәһәре булган (59). Татарда Әлифә дигән хатын-кыз исеме бар. Латия өлкәсендә Тибрга кушыла торган бер елга Almo (Альмон) дип аталган (60). Татарстанда Әлмәндәр авылы бар. Әлмәндәрнең тулы әйтелеше элек Әлмән-дәрья булган булырга мөмкин. Этрурия өлкәсендә Arnus (Арн) елгасы булган (99). Татарстанда Әрән елгасы бар. Апулиянең төньягында Arpi (Арпы) шәһәре булган (97). Татарстанда Арпаяз авылы бар. Югары Италиядә, Ретия өлкәсендә Athesis (Атес) елгасы булган (110). Татарстанда Әтәч елгасы бар. Апулиядә Barium (Барий) шәһәре булган (127). Татарда Барый — ирләр исеме. Кампания өлкәсендә Bauli (Бавлы) шәһәре булган (127). Татарстанда Баулы эшчеләр поселогы һәм Баулы районы бар. Кампания өлкәсендә Cales (Калы) шәһәре булган (146). Татарстанда Кала елгасы бар. Шул ук Кампания өлкәсендә Callicula (Калликула) исемле таулар тезмәсе булган (147). Татарстанда Кәлли үзәне елгасы бар. Самниядә Волтурн елгасының бер кушылдыгы Calor (Калор) дип аталган (147). Татарстанда Көләр елгасы бар. Тибрның бер кушылдыгы Clanis (Кланис) дип аталган (192). Татарстанда Келәнче елгасы бар. Этруриядә Faesulae (Faesula) (Фезулы) шәһәре булган (413). Бу исемнең тулырак варианты Фәйзулла түгел микән? Умбриядә Fanum (Фан) шәһәре булган (416). Татарстанда Фан чишмәсе, татарда Фән, Фәнни дигән ир кеше исемнәре бар. Көньяк Этруриядә Fregenae (Фрегены) шәһәре булган (439). Үзбәкстандагы Фирганә белән тугандаш түгел микән? Рим шәһәрендә, Капитоли тавының көньягында Jugarius vicus дигән урам булган (565). Латинча vicus — урам, тыкрык була. Jugarius дигәне Югары булмыйча, тагын ни булыр икән соң?!

Латиннарда байлык алиһәсе Copia (Копийа) дип аталган (261). Әлеге сүзне *куп-ия*, күплек иясе, байлык иясе дип аңлыйбыз. Үрчем һәм уңыш алиһәсе Ops, Opis (Опа) дип аталган (708). Монысы Апа булачак. Римлыларның Robigo (Rubigo) (Робиго) дигән аллалары булган (884). 25 апрельдә Робигога багышланган бәйрәм булган. Бу алланың кайсы заттан булуы билгеле түгел дип яза белгечләр. Моны без бүгенге көндә хатын-кыз исеме булган Рабига дип исәплибез. Татарда әле дә Рабига ана турында, аның изгелеге, җитмеш шәкерте булуы турында ри-

ваятьләр бар (Рив, 257 бит, № 335). Татарстанда изге санала торган Рабига күле бар (элекке Болгар шәһәре хәрабәләре янында).

Атаклы рим кешеләренең исемнәре, кушаматлары арасында төрки-татар исемнәр очрый. Император Гай Юлий Цезарьнең Калигула дигән кушаматы булган. Калигула сүзен Кәли улы дип «тәрҗемә» итәбез. Татарстанда Кәли елгасы, Кәләй авылы, татарда Кәлим, Кәлимә, Кәлимулла дигән кеше исемнәре бар. Латиннарда Calybe Калиба дигән хатын-кыз исеме булган (148). Бу исем татарда Галибә рәвешендә сакланып калган. Корнелий дигән исем латиннарда шактый еш очрый. Корнелийлар нәселеннән Сулла кушаматы да (977), Цетег кушаматы да (172) булган. Татарстанда Көрнәле сүзе катнашында ясалган берничә атама мәгълүм. Мәсәлән, Көрнәле Әмзәсе елгасы, Көрнәле елгасы дигән елгалар, Коры Көрнәле, Юеш Көрнәле дигән авыллар бар. Корнелий сүзен Көрнәле дип белсәк, Сулла кушаматын «сулы» дип аңларга була. Бүгенге татарда элекке Сулы Көрнәле урынына Юеш Көрнәле торып калган. Цетег Корнелий атамасын Чытык Көрнәле дип исәпләсәк, монысы, бәлки, хәзергечә Көрнәлегә туры киләдер? Сулланың кайчандыр Сулы рәвешендә әйтелгән булуы ихтималын римлыларның Remmius Ремми (868) исеме ярдәмендә дә исбат итеп була. Латин телендә Ремми рәвешендә ике *м* тартыгы белән әйтелгән исем бүгенге татарда Рәми буларак мәгълүм. Күрәсең, ике *л* тартыгы белән язылган Сулла да элеккерәк заманнарда Сула яисә Сулы булгандыр дип әйтәсе килә. Римлыларда шулай ук Servilius, Servius Сервили, Серви (924), Memmius Меммий (628), Mallius Маллий (614) исемнәре һәм кушаматлары да булган. Татарда Сәрби, Сәрбиназ, Мәмли, Мәмәт исемнәре булуы билгеле. Татарстанда хәтта Маллый дип аталган елга да бар. Латиннарда, грекларда шулай ук Menippus (Менипп) дигән кеше дә булган. Шунысы кызык, латин чыганакларында Гадар шәһәрендәге Менипп дигән киник философның исеме сакланып калган (русча «киник из Гадары» — 629). 60—70 нче елларда Татарстанда, татар матбугатында Мөнип Газар дигән яшь шагыйрь исеме еш телгә алына иде. «Иде» димен, чөнки соңгы елларда Мөнип Газарның шигырьләре күренми. Менипп Гадари белән Мөнип Газар исеменең охшашлыгы, билгеле, очраклы хәл булырга мөмкин. Ләкин латиннарда Менипп, татарда Мөнип дигән исемнәрнең булуы шулай да очраклы хәл түгелдер дип әйтәсе килә.

## Бишенче бүлек

# ПИРАМИДАЛАР ИЛЕНӘ СӘЯХӘТ

### 1. МИСЫР ТАРИХЫ ТУРЫНДА КЫСКАЧА БЕЛЕШМӘ

Борынгы халыкларга багышланган теләсә нинди дәреслекне алып карагыз — Тарих Мисырдан башлана. Дөрес, бу мәсьәләдә уртак фикер юк. Берәүләр әйтә, Тарих Шумердан башлана, ди, икенче берәүләр — Мисырдан башлана, ди.

Мисыр турында материаллар күбрәк сакланган. Шунлыктан Мисыр тарихы да күбрәк, җентеклерәк өйрәнелгән һәм Мисырны без Шумерга караганда күбрәк һәм яхшырак беләбез. Башлары таудай булып күккә ашкан пирамидалар, арыслан сыман сузылып яткан һәм адәми күз карашын еракка төбәгән серле сфинкс, ташларга уеп язылган сәер язулар, кеше сурәтләре, кабер ташлары, кулларын югары күтәреп кояшка табынучы фиргавеннәр... болар барысы да — Мисыр. Борынгы Мисыр. Серле һәм гүзәл Мисыр. Ком чүлендәге яшел пальмалар, бөек Нил елгасы... греклар «папирус» дип атаган камыш урманнары, ташкын булып агылган сыер көтүләре, озын арканга тотынып, коры җирдән чанада таш сөйрәүче коллар... муенына элмәк тагылган сугыш әсирләре... тоташ кыяны уеп ясалган манарадай фиргавен сыннары... боларның барысы да — шулай ук Мисыр. Борынгы Мисыр. Данлы һәм шанлы Мисыр.

Пирамидаларга борынгы хакимнәрне күмгәннәр. Алар янына исәпсез-хисапсыз байлыклар — алтын-көмештән, җиздән-бакырдан, агачтан, таштан, фил сөягеннән сырлап-бизәп ясалган исәпсез-хисапсыз әйберләр салып калдырганнар. Алар инде күптән таланган. Аларны инде йөзәр, меңәр еллар буена талыйлар. Ләкин бүгенге һәм борынгы угрылар күрми калган, ялгыш төшереп калдырган китек-митек нәрсәләр дә, вак-төяк әйберләр дә безне таң калдыра. Исең китәр!— моннан биш-алты мең еллар элек кеше шундый оста итеп төрле кораллар, төзәнү-бизәнү әйберләре ясаган, өй тәүмәлеге ташларны уеп-чукып табутлар, савытлар ясаган, бүгенге көндә дә төсе уңмый торган ачык, якты буяулар белән сурәтләр төшергән, язулар язган. Хәзерге заман кызларының, яшь хатыннарның тагын да чибәррәк, тагын да тәэсирлерәк булу нияте белән кашларын, керфекләрен, иреннәрен буяу, чәчләрен төрлечә кыландырып тарау ысулларын мисыр

чибәрләре инде күптән белгәннәр һәм, күрәсең, чибәрлеккә омтылышның барлык хәйләләрен сынап караганнар. Озын муенлы Нефертити күпләр өчен бүген дә гүзәллек үрнәге булып исәпләнелә.

Мисырда катлаулы һәм югары дәрәҗәгә ирешкән дәүләт системасы була. Авыл хуҗалыгы, һөнәрчелек, төзелеш, язу-сызу, фән, әдәбият-сәнгать бик нык алга китә. Шул ук вакытта Мисыр көч-куәт иясе дә була. Билгеле бер чорларда Мисыр патшаларының хакимлеге шактый еракларга сузыла. Математикада, геометриядә, медицинада, күк җисемнәрен өйрәнүдә, бигрәк тә Нилны, Нил ташуларын өйрәнүдә, коры җирләрне сугаруда, игенчелектә, яшелчәчелектә һәм башка бик күп өлкәләрдә тынгысыз, тырыш һәм булдыклы мисыр кешеләре тиңдәшсез уңышларга ирешәләр. Пирамидаларның ничек салынуы әлегәчә сер булып кала бирә. Күпчелек пирамидаларның эчен-тышын актарып, өйрәнеп, тикшереп бетерсәләр дә, иң биек пирамида — Хуфу пирамидасының эченә әлегәчә беркемнең үтеп керә алганы юк.

Бүгенге көндә киң таралган мөселман һәм христиан диннәренең башлангычы Мисырга барып ялгана. Дөнья халыкларының күп кенә мифларын, әкиятләрен, гореф-гадәтләрен шулай ук Мисыр мифлары, әкиятләре, гореф-гадәтләре белән тугандаш дип әйтергә мөмкин.

Мисыр тарихы, Мисыр культурасы, Мисыр фиргавеннәре, Мисыр пирамидалары турында төрле телләрдә йөзләрчә, меңнәрчә китаплар язылган. Борынгы Мисыр мәктәп яшеннән безнең аңга кереп калган, безнең милли культураның аерылгысыз бер өлешенә әверелгән. Безнең генә түгел, дөньядагы барлык халыкларның уртак хәзинәсе ул Мисыр.

Нил һәм Мисыр турында тыныч кына сөйләү дә мөмкин түгел кебек. Ләкин безгә мөмкин кадәр тынычрак булырга туры килә. Хискә, чит-ят тәэсирләргә бирелмичә без бары фактларга нигезләнеп кенә сөйләргә тырышачакбыз.

Мисыр цивилизациясе Африкада, Нил елгасы буенда барлыкка килә. Нил буенда кеше моннан 200 мең еллар элек үк яши башлаган. Моннан ун мең еллар элек монда сазлы җирләрне үзләштереп иген үстерү һәм мал асрау барлыкка килгән. Мисырда яшәүче кешенең барлык тормышы Нил елгасына бәйле. Геродот Мисырны «Нил бүләге» дип атаган. Нил елгасын мисырлылар «яшәтүче елга» дип исәпләгәннәр. Нил дөньяда иң озын елга. Аның озынлыгы 6671 километрга сузыла, бассейны исә 2 миллион 870 мең квадрат километр тәшкил итә. Хартум шәһәреннән көньякка таба Нил икегә — Ак Нил һәм

Күк Нил тармакларына аерыла яисә, икенче төрле итеп әйткәндә, Хартум шәһәре янындарак Ак Нил белән Күк Нил бергә кушылалар да, Нил дип аталган бер елга хасил итәләр. Нил елгасында аеруча нык танылган алты бусага (катаракта) бар. Луксор шәһәреннән өстәрәк Нил үзәненең киңлеге 3—8, түбәндәрәк 20—25 километрларга җитә. 1200 километр араны Нил бүгенге Мисыр территориясеннән агып бара. Бу арада аңа бер генә елга да, бер генә инеш тә килеп кушылмый. Нил суы елына бер мәртәбә ташый, ярларыннан чыга һәм сусызлыктан корып кипкән, тузанга әйләнгән яисә таштай каткан җирләргә җан кертә, сур өрә. Үзе белән Нил югарыдан — Тропик Африкадан черемәгә әйләнгән органик кушылмалар: тропик урман, туфрак калдыклары һәм шулай ук минераль кисәкчәләр алып килә. Су кире кайткач, уңдырышлы ләм елга буе үзәннәрендә, калку җирләрдә утырып кала.

Суның ташуы тропиктагы язгы яңгырлардан соң башлана. Түбәнге Мисырда су июнь аенда күтәрелә башлый һәм сентябрь ахырына кадәр дәвам итә. Шуннан соң әкренләп кими. Декабрь башында Нил элекке хәленә кайта. Суның иң нык күтәрелгән чагы сентябрьдә, иң нык төшкән чагы май аенда була. Борынгы заманнарда язгы ташу вакытында суның артуы биш метрга кадәр җиткән дип уйланыла.

Мисырда марттан башлап июньгә кадәр көчле кайнар җилләр исә. Көнчыгыштан һәм көньяк-көнчыгыштан, ахырда көньяктан исә торган, аена уртача өч мәртәбә кузгала торган бу көчле кайнар җилне, гадәттә, Хамсин дип атыйлар. Хамсин җиле үзе белән күпләп ком-тузан алып килә. Хамсин еш кына давылга, гарасатка әверелә һәм барлык яшеллекне, барлык тереклекне юкка чыгара. Хамсиннан соң җилнең юнәлеше үзгәрә. Төньяк-көнбатыштан искән җил Мисырга шифалы дым һәм талгынлык алып килә. Мисырның үзендә бөтенләй диярлек явым-төшем булмый. Ел тәүлеге буена монда кояш кыздыра. Бары тик Нил ташуыннан соң гына һәм төньяк-көнбатыш җиле исә башлагач кына кеше монда иркенләп тын ала. Бары Нил ташуы нәтиҗәсендә генә кеше монда иген игә, җимеш, яшелчә үстерә, мал-туар һәм кош-корт үрчетә ала. Элек тә шулай булган, хәзер дә шулай.

Борынгы заманнарда Мисырның климаты шулай да йомшаграк булган дип уйланыла. Тау буйларында ваграк агачлар, су буйларында камышлар үскән. Су кошлары, су хайваннары хәзергегә караганда күбрәк һәм төрлерәк булган. Чүлләрдә, әрәмәләрдә, Нил буе сазлыкларында

филләр, арысланнар, мөгезборыннар һәм башка ерткыч хайваннар яшәгән. Нил суында крокодиллар йөзеп йөргән. Җыланнар, чаяннар күп булган.

Мисыр җирендә таштан башка бернинди казылма байлык юк. Кая карама, таш та ком, ком да таш. Һәм Нил. Аннан соң, кешеләр. Алтын куллы адәм балалары.

Мисыр тарихы чагыштырмача яхшы өйрәнелсә дә, монда да ачыкланмаган яки бәхәсле нәрсәләр җитәрлек. Мисыр тарихының аеруча башлангыч чоры томанга төрелгән. Күп очракта Мисыр тарихын еллар исәбе белән билгеләү мөмкин дә түгел. Еллар, гасырлар кайчагында чама белән генә күрсәтелә. Шунлыктан Мисыр тарихын династияләргә бүлеп карау гадәткә кергән.

Тарихи чорда Мисырда кырыклап өлкә (ном) булган. Бу өлкәләрнең һәркайсы элеккерәк заманнарда аерым, мөстәкыйль дәүләт булган дип уйланыла. Үзара сугышлар нәтиҗәсендә мөстәкыйль өлкәләр әкренләп юкка чыга һәм берзаман берләштерелгән Мисыр дәүләте барлыкка килә. Берләштерелүгә кадәрге вакыт тарихка кадәрге чор дип атала. Моны шулай ук династияләргә кадәрге чор дип тә атыйлар. Аерым өлкәләрне берләштергәннән соң барлыкка килгән дәүләттәге I династия б.э.к. 3000 елларда хакимлек итә башлаган дип уйланыла. II династия хакимлеге б.э.к. 2778 елда тәгәлләнә. III династия б.э.к. 2778—2723 елларда, IV династия 2723—2563 елларда хакимлек итә.

Болардан тыш Мисырда утызлап династия булуы билгеле. Без, әлбәттә, аларның барысына да тукталып тора алмыйбыз. Мисырны берничә мәртәбә чит ил халыклары басып ала. Б.э.к. X гасырда аны ливиялеләр, VIII гасырда эфиоплар, 671 елда ассирилар басып алалар. Б.э.к. 525—405 елларда Мисыр Персия кулы астында була. Б.э.к. 332 елда Мисырны Александр патша, ягъни Искәндәр Зөлкарнайн яулап ала. Безнең эраның 30 нче елына кадәр дәвам иткән бу чорны Птоломейлар чоры дип тә атыйлар. Птоломей грекларыннан соң Мисырда римлылар, римлылардан соң Византия греклары хуҗа була. 642 елда исә бу борынгы культура учагын гарәпләр яулап ала. Алтын урда заманында Мисырга күпләп кыпчак коллары сатыла. Коллар үз хуҗаларына каршы баш күтәрәләр һәм Мисырда... кыпчак хакимлеге урнаштыралар. Гарәпчә аларны «мамлүк», ягъни кол дип атыйлар. Шунлыктан тарихта *мамлүк* сүзе ныграк танылган. Мамлүкләр хакимлеге 1250 елдан алып 1517 елга кадәр дәвам итә. Шуннан соң Мисырны госманлы-төрекләр яулап ала. Госманлы-төрекләр кулы астындагы мамлүкләр Мисырда 1811 елга

кадәр идарә иткәннәр. Төрекләрдән соң Мисырда французлар, французлардан соң инглизләр хуҗа була. Инглиз хакимлеге 1952 елда юкка чыгарыла һәм Мисыр җирендә Берләшкән гарәп республикасы барлыкка килә.

Мисырның кыскача тарихы шуннан гыйбарәт.

Борынгы мисырлылар нинди телдә сөйләшкәннәр соң? Бик озак вакыт моның серенә төшенә алмаганнар. 1822 елда француз галиме Жан Франсуа Шампольон мисыр иероглифларын дөрес итеп укуга ирешкән. Шуннан соң галимнәр бик күп язуларны укыганнар, мисыр теле турында шактый бай мәгълүмат туплаганнар. Бүгенге көндә 20 меңнән артык мисыр сүзенең мәгънәсе билгеле икән. Борынгы мисыр телен, гадәттә, «семит-хамит телләре» семьясына карый дип исәплиләр. Ләкин словак галиме Войтех Замаровский язганча, егерме мең сүзнең бары өч йөзләбе генә семит сүзләре белән уртак икән (За, 128 бит).

Латин теле кебек мисыр теле дә үле телләр рәтенә карый. Күп кенә борынгы мисыр сүзләре яһүд, грек, латин телләре аша башка телләргә дә күчкән һәм алар әле булса актив кулланылалар. Шундыйлардан *папирус, оазис, ибис, базальт* кебек сүзләрне күрсәтергә була. Бүгенге көндәге коптлар борынгы мисырлыларның бер калдыгы дип, копт теле борынгы мисыр теленең бер үрнәге дип исәпләнелә. Ләкин копт телен инде үзен дә үле тел дип әйтергә була.

Мисыр теленә багышланган бер генә хезмәттә дә төркиләр яисә төрки телләр искә алынмый. Мисырдагы төркиләр турында сүз барганда башлыча соңгырак замандагы мамлүкләрне һәм госманлы-төрекләрне генә телгә алалар. Күп очракта яратмыйча, кире яктан телгә алалар.

## 2. КӘМИТ

Бүгенге татар телендә төрки түгел сыман тоелган, әмма сөйләм телендә актив кулланылган *кәмит* сүзе бар. Кәмит ул нинди дә булса хикмәтле нәрсә күрсәтеп, көлдерү, күңел ачу дигәнне белдерә. Телдә ат кәмите, кәмит күрсәтү, кәмит уйнау, кәмитче кебек сүзләр, сүз тезмәләре бар.

Кәмит сүзе гарәптә дә, фарсыда да юк, ахрысы. Ни генә булмасын, «Алынмалар сүзлегендә» ул юк. В.В.Радлов кәмитне татарлар русча комедиядән үзгәрткәннәр дип исәпли (Рад, II, 1210). Комедия үзе грек-латинда булган. Шуннан ул Европа телләренә, аннары рус теленә күчкән. Сүзләрнең каян кая һәм ничек сәяхәт итүе безгә күптән билгеле. Радлов заманында Казанда комедияләр уйналган, әлбәттә. Русча куела торган спектакльләргә кайбер татар

яшьләре качып-посып кына йөрсәләр дә, Казандагы татар халкының күпчелеге театрны ишетеп кенә белгән. Хәтта Казан татарлары театрга күпләп йөргәннәр дип исәпләсәк тә, кәмит сүзенең комедиядән үзгәрүен һәм халык арасында аның шул дәрәҗәдә киң таралуын күз алдына китереп булмый. Кәмит ул Казан шәһәре татарларының гына сүзе түгел, гомумән барлык татар халкының уртак сүзе.

Сәхнә әсәре һәм тамаша төре буларак комедия татарда шул килеш, комедия рәвешендә кабул ителгән. 1895 елда Казанда басылган һәм авторы күрсәтелмәгән татарча беренче сәхнә әсәре «Комедия Чистайда» дип атала. Г.Камалның 1908 елда сәхнәгә куелган һәм шул ук елда басылып чыккан «Беренче театр» әсәренең титул битендә «Комедия, I пәрдәдә» дигән сүзләр бар. «Беренче театр» спектакленә язган рецензиясендә Ф.Әмирхан «комедия» урынына кәмит түгел, бәлки көлке термины куллана.

Менә бу фактлар үзе генә дә Радлов күз алдында торткан заманнарда һәм аннан соңгырак татар матбугатында комедия белән кәмитнең һич тә тиңдәш сүзләр итеп каралмавы турында сөйли. Татар театрының сиксән-туксан еллык тарихы булуына һәм ел саен татарча дистәләгән комедияләр уйналуына да карамастан, комедия сүзенең әле булса кәмит кебек үк халыклашып китә алганы юк.

Шулай итеп, комедия беркайчан татарда кәмит булмаган, кәмит, киресенчә, комедия булмаган. Бүгенге комедия үзенә башка, кәмит үзенә башка сүз. Кәмит ул татарның бик борынгы заманнардан калган үз сүзе.

Әлеге сүзнең нәрсә аңлатканлыгын ачыклау өчен безгә Пирамидалар иленә әйләнеп карамыйча мөмкин түгел. Борынгы Мисыр кешеләре үз илләрен *кмт* дип атаганнар. Мисыр теле үле тел булганлыктан, ул телдәге сүзләрнең төгәл әйтелешен инде белеп булмый. Шунлыктан мисыр сүзләрен фәнни әдәбиятта тартыклар белән генә белдерәләр. Тартыкларны копт телендәге охшаш сүзләр ярдәмендә тулыландыралар. Күбрәк очракта исә тартыкларны шартлы рәвештә *ә* сузыгы белән җанландыралар. Мәсәлән, *кмт* тартыкларын төрле сузык белән әйтеп, төрле яңгыраштагы сүзләр ясарга була. *И* сузыгы белән бу *кимити, ә* сузыгы белән *кәмәтә, у* сузыгы белән *кумуту* булыр иде. Менә шундый төрлелек булмасын өчен, әйтелгәнчә, мисыр тартыкларын *ә (е)* сузыгы белән язалар. *Кмт* тартыклары барлык хезмәтләрдә КЕМЕТ яисә КЕМЕ рәвешендә языла.

Кеме — кемет сүзен гадәттә «кара» төс дип аңлаталар. Мисырның тирә-ягындагы чүлләр кызыл төстә, Нил буеның уңдырышлы үзәннәре кара төстә булган. Шун-

лыктан мисырлылар, үзәннәрдәге җирләрне якынрак күреп, яратып, үз илләрен гомумән «кара» — Кемет (Кеме) дип атаганнар, имеш. Кеме (кемет) сүзенең кайчан да булса мисыр телендә чыннан да «кара» төсне белдергән булуы мөмкин нәрсә. Ләкин Мисыр халкының үз илен, гомумән, «кара» дип атаган булуы шикле. Тарихтан билгеле булганча, Мисыр Югарыгы һәм Түбәнге җирләргә бүленеп йөртелгән. Югарыгы Мисырны Ак өй дип, Түбәнге Мисырны Кызыл өй дип тә атаганнар. Шушы фактны истә тотканда, бөтен Мисыр иле берничек тә «кара» була алмаган. Кара җир, туйдыручы булса да, борынгы кешегә ул үзенең каралыгы белән түгел, бәлки яшел чагы белән — кара җирдә гөрләп игеннәр, яшелчәләр, агачлар үскән чагы белән кадерлерәк булган. Шунлыктан Мисырда яшел төс изге саналган.

Кмт тартыкларын без хәзерге татар телендәге кәмит рәвешендә тулыландырабыз. Кәми һәм Кәмит ил-дәүләт атамасын да, шул дәүләтнең аерым кешесен дә белдерә ала.

Күз буу (иллюзионизм), төрле фокуслар күрсәтү һәм цирк уеннары уйнау иң элек борынгы Мисырда барлыкка килә. Б.э.к. XVI гасыр тирәсендә язылган һәм фәндә «Весткар папирусы» дип атала торган язма истәлектәге риваятьләрнең берсендә гади халык арасыннан чыккан күз буучы Җәди (русча язылышта — Джеди) турында сүз бара. Бу риваять б.э.к. 2400 елларда ук (ягъни моннан 4400 еллар элек) иҗат ителгән дип уйланыла. Бу чор Мисыр тарихының атаклы Хуфу (Хеопс) фиргавен хакимлеге заманнарына туры килә.

Инде дөньяның икенче ягына әйләнеп карыйк. Б.э.к, II—I гасырларда борынгы Кытайга Мисырдан (Александрия шәһәреннән) күз буучылар, фокусчылар килә торган булган. Бу хакта язма истәлекләр сакланып калган. Борынгы Кытайда күз буу, фокус сәнгатенең үсеп китүендә мисырлыларның йогынтысы көчле булган (Вел, 86—87 битләр).

Шул рәвешчә, борынгы Мисыр мисыр телендә кәми дип, Мисыр кешесе — *кәми-т* дип аталган. Борынгы мисырлылар (кәмитләр) күптән инде күз буу, фокус эшенә маһир булганнар дип әйтә алабыз. Бүгенге татар телендә кәмит («Мисыр кешесе») — кәмитче, күз буучы, көлдерүче мәгънәләрендә сакланып калган.

Борынгы мисырлылар якын-тирәдәге илләр, халыклар белән, аерым алганда, Урта диңгез бассейны халыклары белән аралашып яшәгәннәр. Критта, Фест шәһәре янында әле дә Камиляри дигән авыл бар икән (Си, 69 бит). Бу

сүзне без Кәми-ләр (и) дип таркатабыз. Күрәсең, Кәмиләри авылында (шәһәрендә?) ниндидер сәбәпләр белән Критка күченеп килгән яисә китерелгән һәм шунда төпләнеп калырга мәҗбүр булган Кәми кешеләре яшәгәннәрдер дип уйларга була. Страбон язганча, Сицилия утравының мифик патшасы Кокалның башкаласы Камики дип, Бөек Каппадокиядәге бер өлкә Камисена дип, диңгез буе Каппадокиясендәге бер борынгы ныгытма Камисы дип аталган. Бу сүзләрнең һәркайсында кәми иҗекләре катнаша. Шунлыктан әлеге торакларны (шәһәрләрне, авылларны) Кәми кешеләре салган булырга тиеш дип әйтәсе килә.

Бүгенге татар телендә «цирк уены», «фокус» мәгънәләрендәге кәмитнең генә түгел, *күз буу* терминының да исән-имин сакланып калуы безнең бик борынгы бабаларыбызның чыннан да югары дәрәҗәдәге шәһәр тормышы шартларында яшәүләре турында сөйли түгелме соң?! Мал-туар асрап, кышын-җәен бер урыннан икенче урынга күченеп йөргән, бөтен гомере киез өйләрдә, арбаларда, ат өстендә үткән күчмәләр арасында бернинди театр, цирк, күз буу сәнгатьләре туа алмый. Моның өчен барыннан да элек утрак тормыш һәм үзәкләштерелгән дәүләт системасы булу шарт. Күз буучы Җәдиләр вакытында борынгы Мисыр нәкъ шундый ил-дәүләт булган да инде.

Татар телендә борынгы мисыр сүзе кәмиттән башка тагын *Җәди* сүзе дә исән. Татарда Җәдиханов фамилиясе бар (Сат, 249 бит). Гарәпнеке дип уйланылган *җәдит* тә борынгы чорлардан калган мисыр-төрки сүз булса кирәк. XIX гасыр азакларында, XX гасыр башларында бездә хәтта «җәдитчеләр хәрәкәте» булган. *Җәдит* — яңа, яңалык, җәдитче — яңалык яклы кеше дигәнне белдерә. Моннан 4400 еллар элек күз буу һөнәре күрсәтеп, Җәди дигән кеше дә үз заманында бик зур яңалык эшләгән һәм кордашларын таң калдырган. Шуңа күрә дә аның исеме тарихи истәлекләрдә һәм җанлы сөйләм телендә сакланган. Җәди исеменең Җәзи варианты да мәгълүм. Мәсәлән, Мәрҗани үзенең «Мөстафадел әхбәр...» китабында Җәзи исемле кешене телгә ала (Мәр, 372 бит). Җәзинең Җәзилә дигәне хатын-кыз исемен белдерә.

### 3. БИСТӘ

Бистә сүзе хәзер сирәк кулланыла, шулай да телдә аның үз урыны, үз мәгънәсе бар. Шәһәрнең аерымланыбрак торган, читтәрәк урнашкан өлешен *бистә* диләр. Казанда Иске бистә, Яңа бистә бар. Иске бистә инде онытылып бетә язган. Яңа бистә әле дә исән һәм сөйләм

телендә әледән-әле ишетелеп кала. Татарстанда Балык Бистәсе авылы һәм шул исемдәге район да бар.

Мәхмүд Кашгари заманында тухси, чигил, ягма дигән төрки кабиләләр телендә дә бистә сүзе булган. Аның мәгънәсе «кунак өй хуҗасы» булган, ахрысы (ДТС, 103 бит). «Борынгы төрки телләр сүзлеге»н төзүчеләр бу сүзнең аңлатмасы янына сорау билгесе куйганнар, димәк, «кунак өй хуҗасы» дигән мәгънәнең дөреслегенә үзләре дә ышанып җитмәгәннәр. Чыннан да, сүзлектә «бистә белән ярашты» дигән тезмәдәге *бистә* сүзе кунак өй хуҗасын түгел, бәлки бистә халкын, бистәне күз алдында тоткан булырга мөмкин.

Бистә төрки сүзе. Бистәне *бис-тә* дип таркатсак, *бис* иҗекләре «шәһәр»не, *-тә* аның «улын», ягъни шәһәр янындагы өйләр төркемен аңлата булып чыга. Бер генә төрки телле сүзлектә дә авыл, өй, торак мәгънәләрендәге *бис* сүзе теркәлеп калмаган, ахрысы. Моны без иҗек методы нигезендә казып чыгарабыз. Шул ук методка таянып *бис* сүзен *би-с* рәвешендә таркатабыз.

Бер иҗектән торган *би* сүзе безгә күптән таныш. *Би* ул түрә, хаким, хуҗа, морза мәгънәләрендә кулланыла ала. *Би* катнашында ясалган *биана, биата, биага, бием, әби* кебек сүзләр бар. Монда шулай ук *бикә, бичә, бийә* сүзләрен дә искә төшерергә була. Мәсәлән, бикә аксөяк нәселдән булган хатын-кызны яисә, гомумән, ир хатынын белдерә. Сүзне *би-кә* дип таркатабыз. Моның иң әүвәлге мәгънәсе «*Би*нең кәсе», ягъни «*Би*нең ише, хатыны» булачак.

*Бис* сүзендәге *би* иҗеге дә бик борынгы заманнарда мөстәкыйль мәгънә белдергән һәм исем рәвешендә «хуҗа», «хаким» төшенчәләренә ия булган. *Би* иҗегенә ялганган *с* тартыгы бинең «улын» аңлата. Бу очракта «улы» хуҗа, хаким кешенең тору урынын күз алдында тота. *Бис*нең киңәйтелгән мәгънәсен без: хуҗа (хаким) кешенең тору урыны дип, *бистә*нең киңәйтелгән мәгънәсен: хуҗа (хаким) белән бер урында торырга хакы булмаган, ләкин хуҗага буйсынган кешеләрнең тору урыны дип аңлыйбыз.

Геродот язганча, Мисырның беренче патшасы Мин дип аталган. Борынгы грек чыганакларында Мин булган патша Мисыр истәлекләрендә Аха яисә Ага, Гор-Ага дип атала. Гор-Ага б.э.к. 2850 елларда хакимлек иткән дип уйланыла. Мин патша Мисырның беренче башкаласын төзи. Мин яшәгән чорларга кадәр Түбәнге Мисыр, Фива өлкәсеннән кала, тулысынча сазлыклардан гыйбарәт була. Мин патша сазлыкларны туктаусыз сугарып тор-

ган Нил тармагын биек буа белән будыра һәм елга суын таулар арасындагы үзәнлеккә таба борып җибәрттерә. Элекке сазлык урынына шәһәр салына. Башкала грекча язылышта Мемфис дип атала.

Мемфис исемен без Минбис дип төзәтәбез. Башкаланы Мин патша салдыргач, шәһәрнең исеме Мем... түгел, Мин.... булырга тиешлеге үзеннән-үзе аңлашылып тора булса кирәк. *Мемфис* атамасындагы фис иҗекләренең бис булу ихтималы бернинди шик тудырмый. Әле генә күреп киткәнчә, бис ул бинең (патшаның) тору урынын белдергән. Мин исемле патша төзеткән башкала шундый «тору урыны» булган да инде. Урта диңгезнең борынгы топонимиясендә *бис* иҗекләренә тәмамланган кайбер шәһәр исемнәрен очратырга була. Мәсәлән, Страбон язганча, Мисырда Африбис дигән шәһәр булган. Кече Азиядәге Пафлагония өлкәсендә Карамбис, Месопотамиядәге Мигдония өлкәсендә Нисибис, Рим империясенең Испаниядәге бер провинциясендә Сетабис шәһәрләре булган.

Димәк, «шәһәр» мәгънәсендәге бис элекке заманда Испаниядән алып Кече Азиягә, Төньяк Африкага кадәрге җирләрдә таралган булган дип әйтә алабыз.

Борынгы Урта диңгез бассейны илләрендә Мин дә атаклы исемнәрнең берсе булган, ахрысы. Геродот Минос дип атаган патшаны без Мин дип беләбез. Грекча язылыштагы Миносның Мин булуын һәм аның чыннан да кайчандыр Урта диңгез бассейнында хакимлек итүен исбатлый торган фактлар бар. Мәсәлән, Эгей диңгезе бассейнында тарихи чорга кадәр Миноя атамалары сакланып калган. Бер Миноя Сириоста, берсе Аморгос утравында, берсе Делоста, берсе Лакониядә, тагын берничәсе Сирия яр буйларында, Көнбатыштагы җирләрдә, хәтта Гарәбстанда була (Пен, 303, 304 битләр). Бүгенге Крит утравында шулай ук бер Миноя бар. Миноя сүзен Мин өе яисә Мин оя(сы) дип аңларга була. Борынгы Крит цивилизациясен еш кына Миной цивилизациясе дип атыйлар. Крит сарайларын казып чыгарган А.Эванс беренче булып шундый термин куллана. Борынгы халыклар арасында «мин», «миней» кабиләләре булуын да әйтергә кирәк.

Шулай итеп, Мисырның беренче патшасы Мин булган. Крит-Атлантида дәүләтенең беренче патшасы шулай ук... Мин булган. Борынгы Мисырда Мин дип аталган алла булуы да мәгълүм. Мин дигән аллага башлыча Югарыгы Мисырда, Нилның көнчыгышында, грекча Коптос (мисырча Гебтиу) шәһәрендә табынганнар. Күк һәм үрчем алласы Мин мисырларның иң популяр аллаларыннан берсе исәпләнелгән (Кор, 88, 89, 111 битләр).

Күрәсез, Мин ул көч-куәт иясе, Мин — сугышчы, җиңүче һәм шул ук вакытта иҗатчы. Мин Мисырның беренче патшасы, аның беренче башкаласын төзүче. Бәлки, Платон тасвирлаган Атлантида башкаласын да Мин тәртипкә китергәндер? Геродотның Минос патша турындагы хәбәрләрендә җир йоткан Атлантида күз алдында тотыладыр, бәлки?

Бүгенге татар телендә мин катнашында ясалган исем-атамалар бик күп. Татарстанда Мина елгасы, Башкортстанда Миндеш, Миндәк, Минешле, Минйән елгалары, авыллары бар. Танылган Минзәлә атамасында да мин катнаша. Минзәлә Мисырда да бар. Борынгы Мемфис якларында, Нил елгасының түбәнге агымында, Дельтаның төньяк-көнчыгыш өлкәсендә Мензала дип аталган зур гына күл бар. Шул тирәдә тагын Буруллус дигән икенче күл дә бар икән (АФ, 52, 98 битләр). Татарча кеше исемнәрендә очрый торган мин иҗекләрен бездә һәр очракта «миң» дип үзгәртәләр. Сөйләм телендә Миннәхмәт икән, язуда аны Миңлеәхмәт дип, Миннурый икән, Миңленурый дип «төзәтәләр». Мондый «мин»нәрнең кайберләре чыннан да миң булырга да мөмкин, әлбәттә. Бүгенге китапларда русча Мин, Минос, Миной рәвешендә языла торган исем-атамаларның кайберләренең Миң булган булуы да ихтимал. Ләкин МИН формасы да булган һәм бар. Мәсәлән, бүгенге татар исем-фамилияләрендә сакланып калган кайбер «мин»нәрне берничек тә «миң»гә әйләндереп булмый. Татарда Минапова, Мингатин, Миниев, Минин, Миначев, Миншин фамилияләре, Минафига, Минеруp кебек исемнәр бар. Беренче зат алмашлыгы мин сүзендә дә бик борынгы аллалар, патшалар, кабиләләр исеме яшеренеп ятмый микән? Үзен «мин» дип исәпләгән кеше ул Минны бердәнбер алла дип белүче дә, Мин патша кулы астындагы шәхес тә, Мин кабиләсенең («мин»нәрнең, «миней»ларның) бер вәкиле дә була ала.

### 4. БОРЫНГЫ МИСЫР АЛЛАЛАРЫ. *ОСИРИС* ҺӘМ *ИСИДА*

Мисырлылар бик динле халык булганнар. Мисыр диненең төп эчтәлеге гасырлар буена үзгәрешсез калса да, аның конкрет чагылышы — дингә табыну, аллаларны олылау рәвеше бик күп төрле булган. Мисырлылар табигать көчләренә, җиргә, суга, күккә, утка, кояшка, хайваннарга, үсемлекләргә, бөҗәкләргә табынганнар. Бер үк аллага табыну, аны олылау, хөрмәт итү төрле төбәктә, төрле шәһәрдә төрлечә була алган. Әйтик, бер шәһәрдә куй (сарык) изге саналса һәм иң дәрәҗәле алла сыйфатында

хөрмәт ителсә, икенче бер шәһәрдә куй түгел, үгез, өченчесендә кәҗә тәкәсе изгерәк саналган һәм иң олы алла дип исәпләнелгән. Бер төбәктә халыкның бер өлеше, әйтик, балыкны изгеләштергән, икенче өлеше аны нәҗес дип белгән. Күпчелек аллалар төрле хайваннар, ерткычлар кыяфәтендә булган. Мәсәлән, мисырлыларның арыслан кыяфәтендәге 32 аллага һәм 33 алиһәгә табынулары билгеле. Ләкин бу да төгәл сан түгел. Аллаларны шулай ук кошлар, үсемлекләр, бөҗәкләр рәвешендә дә сурәтләгәннәр. Кеше кыяфәтле аллалар да булган.

Мисырлыларның ничә төрле аллага табынулары, гомумән, билгеле түгел. Англия галиме Е. Бадж мисырлылар биш меңнән артыграк аллага табынганнар дип яза ди М. А. Коростовцев «Религия древнего Египта» китабында (Кор, 138 бит). Мисыр аллалары никадәр күп, мисырлылар дине никадәр катлаулы булмасын, шулай да барлык дини үзәкләрдә хөрмәт ителә торган, барлык мисырлылар өчен изге саналган уртак аллалар да булган. Шундыйлардан иң танылган алла Осирисны, аның хатыны Исиданы, кояш алласы Ра һәм башкаларны күрсәтергә була.

Осирис һәм Исида турындагы миф Мисырда бик борынгы заманнарда ук — б.э.к. IV мең еллыкның ахыры белән III мең еллык башларындагы чорларда барлыкка килгән дип уйланыла. Осирис һәм Исида турында мәгълүматлар да күп, бу хакта хезмәтләр дә күп язылган. Бу алла исемнәре «Пирамидалар тексты»нда, «Саркофаглар тексты»нда, «Үлеләр китабы» дип аталып йөртелә торган һәм бүтән төрле исемнәрдәге истәлекләрдә очрый. Осирис һәм Исида турындагы мифның иң төзек варианты 45—127 елларда яшәгән грек язучысы һәм тарихчысы Плутархның «Исида һәм Осирис» дигән әсәрендә сакланып калган.

Плутарх язмасында мифның кыскача эчтәлеге шуннан гыйбарәт. Кронос исемле алла белән яшерен мәхәббәте нәтиҗәсендә Рея дигән алиһәнең биш баласы туа. Балалар ел тәүлеге исәбендә бер айга да карамый торган өстәмә биш көн эчендә туалар. Беренче көнне Осирис туа. Ул туар алдыннан күктән: «һәр җанлы-җансызның хакиме дөньяга килә. Бөеклек һәм изгелек иясе Осирис туа» дигән аваз ишетелә. Икенче көнне Хорур, өченче көнне Тифон, дүртенче көнне Исида, бишенче көнне Нефтида туа.

Аллалар тарафыннан тудырылган шушы биш бала арасында Осирис белән Исида аналары карынында ук бер-берсенә гашыйк булалар. Осирис үсеп патша булгач, үз халкы өчен күп кенә яхшылыклар эшли. Бер җирдән икенче җиргә йөреп ул халыкны культурага өйрәтә, аңа

наданлыктан, караңгылыктан чыгарга ярдәм итә. Осириснең даны Мисырга гына түгел, бөтен тирә-якка тарала. Булдыклы патшаның данынннан, изге эшләреннән көнләшүчеләр дә табыла. Мондый кешеләр Осириснең энесе Тифон тирәсенә тупланалар һәм Осириска каршы төрле хәйләләр кора башлыйлар. Шулай бервакыт чит җирләрдән йөреп кайткан Осирисны тантаналы рәвештә каршылау оештырыла. Аның кайтуына Тифон яклылар бик яхшы сандык (саркофаг) эшләтеп куйган булалар. Кем дә кем шушы сандыкны (саркофагны) үзенә бүләк рәвешендә аласы килсә, сандык эченә ятып карарга тиеш, диләр болар. Сандык (саркофаг) кемнең гәүдәсенә таман гына булса, ул шуныкы булачак, диләр. Сандыкка кызыгучылар күп була, барысы да аның эченә кереп ятып карыйлар, ләкин сандык (саркофаг) беркемнең дә гәүдәсенә туры килми. Башкалар кебек Осирис та ятып карый. Саркофаг Осириска таман гына була. Шул чакны Тифон яклылар сандыкның капкачын шап итеп ябып куялар да, кадаклыйлар да... Нил елгасына ташлыйлар. Сандык диңгезгә агып чыга. Диңгез дулкыны сандыкны Финикиядәге Библ шәһәре янына китереп чыгара. Сандык ярга килеп җитү белән, могҗиза була: сандыктан төптөз агач үсеп чыга, Осирис исә агач тамырлары астында торып кала. Беркадәр вакыттан соң Осирисны Исида эзләп таба, сандыкны (саркофагны) Мисырга алып кайта һәм Нил тамагындагы сазлыкларда яшереп тота. Озакламый явыз Тифон монда да килеп җитә, Осириснең мәетен сандыктан алып аны 14 кисәккә тураклый һәм 14 җиргә күмдерә. Осирис теге дөньяга эләгә. Ләкин ул яңадан бу дөньяга кайта һәм улы Хорны үзе өчен Тифоннан үч алырга өйрәтә. Исида белән Осириснең улы Хор дошманнарга каршы көрәш башлый, Тифонны һәм аның якчыларын җиңә һәм, ахыр чиктә, атасы тәхетенә менеп утыра.

Без монда таныш исемнәр, таныш мотивлар белән очраштык. Ләкин хәзер без аларга тукталып тормыйбыз. Безне бары Осирис һәм Исида гына кызыксындыра. Плутарх версиясен һәм мисыр чыганакларын күз алдында тотып фикер йөрткәндә, Осирис үлеләр патшасы һәм теге дөнья хөкемдары буларак күз алдына килә. Мисыр текстларында исән патша беркайчан Осирис белән тиңләштерелми. Исән патша Хор дип атала, үлгән патша исә Осириска әйләнә.

Борынгы Мисырда һәм грек-латин дөньясында Осириска багышланган дини йола бәйрәмнәре (мистерияләр) үткәрелгән. Шундый бәйрәмнәрнең берсе Нил елгасы ташыган чакта — ташуның соңгы көннәрендә булган.

Дини бәйрәм вакытында Нил ләменнән үле Осириснең сынын ясаганнар. Мисырда, грек-латин хакимлеге заманнарында, Буто шәһәрендә Осирис мистерияләре үрчем алласы Минга бәйле рәвештә үткәрелгән.

Хәзер инде атаклы мисыр аллаларының исемнәрен тикшереп карыйк. Осирис исемен «куәтле» дип аңлатырга була ди Плутарх (Плу, II, 37). Осириснең икенче исеме Мисырда Омфис дип атала һәм аның мәгънәсе «игелекле» (благодетель) дигәнне белдерә икән (Плу, II, 42). *Осирис* исемен Плутарх *ос* (осиос — «святой») һәм *ир* (иерос — «священный») сүзләренә тарката (Плу, II, 61; 240 бит, искәрмә 194).

Плутарх аңлатмасына нигезләнеп шуны әйтергә була: грекча язылыштагы Осириснең борынгырак, дөресрәк формасы *осир* булган икән. Сүз азагындагы *ис* иҗекләре грек теле үзенчәлеген чагылдыра. *Осир*ны без татарча *әсир* дип язабыз. Грек теленә күчкән төрки сүзләр еш кына бик нык бозылган, үзгәргән була, ләкин төрки алла исемнәрен греклар шулай да бозмаска тырышканнар. Тик монда да алар үз телләренең мөмкинлекләре белән исәпләшмичә булдыра алмаганнар. Грек телендә *ә* сузыгы булмаган, шунлыктан киң әйтелешле төрки *ә* грек телендә *о* сузыгына әверелгән. Югарыда күреп киткәнчә, история сүзендә дә төрки *ә о* сузыгына әйләнгән.

Бүгенге татар телендә *әсир* плен төшкән кешене, «пленный»ны белдерә. Бу сүзне без дә Плутарх кебек үк *әс* һәм *ир* иҗекләренә таркатабыз. Иҗек методы нигезендә *әс* уңай сыйфат белдерүче сүз булса, *ир*... «ир» инде. Хатын ире, сугышчы ир, батыр ир һәм башкалар. Саф төрки сүз. *Ир*нең, иң әүвәлге мәгънәсе — Ата улы, ягъни мифик Атаның җенес әгъзасы. Борынгы Мисыр чыганаклары һәм Плутарх мәгълүматлары моның нәкъ шулай икәнлеген раслый. Тагын кабатлыйбыз: Осирис — куәтле, игелекле, Осирис иҗатчы һәм төзүче. Осирис Мин дигән аллага һәм Нил елгасына тиң. Нилны гына түгел, теләсә нинди юешлекне мисырлылар Осиристан бүленеп чыккан юешлек дип исәплиләр. Изге бәйрәм вакытларында алланы, ягъни Осирисны хөрмәт итү йөзеннән, су салынган савыт күтәреп баралар. Патшаны һәм дөньяның көньяк чиген мисырлылар камыш сурәте белән чагылдыралар. Камыш исә, мисырлылар карашынча, дымны (юешлекне) һәм барлык җанлы нәрсәне аталандыруның символы булып тора. Камыш үзенең табигате белән ирлек әгъзасына охшаш дип яза Плутарх.

Бүгенге татар телендә әсир сүзенең Плутарх әйткән мәгънәләре инде күптән онытылган. Бүгенге әсир — су-

гышта дошман кулына төшкән кеше. Мифларда тасвирланганча, Осирис та үз дошманнарының әсиренә әверелә. Киңрәк, гомумирак планда ул шулай ук әсир. Теге дөньяга эләккән Осирис, һәрбер үлгән кеше кебек үк, «үлем» дигән аяусыз дошманның мәңгелек әсиренә әйләнә.

*Исида*, әйтелгәнчә, Осириснең сеңлесе, хатыны һәм Хорның анасы. Осириснең исеме төрки булгач, күрәсең, Исида исеме дә төркидер дип уйларга нигез бар. Грекча Исида рәвешендәге бу исем латинча Isis (Исис) дип языла. Мисырдан көньяктарак урнашкан Мероэ язмаларында шул ук исем Аси дип атала. «Исида улы» дигән сүз мисырча Саисе була. Сүз башында килгән *са* иҗеге мисыр телендә «улы» мәгънәсенә тәңгәл. Исе грекча Исидага якын. Латинча язылыштагы *Исис* сүзенең ахыргы *с* тартыгын артык дип исәпләсәк, грекча язылыштагы Исида сүзенең *да* иҗеге дә артык булып чыга. Ләкин *Исида* сүзен *Иси-да* рәвешендә дә таркатырга була. Төрле телдә төрлечәрәк языла торган, *Исида — Иси — Аси* сүзенең иң борынгы варианты *Иси* булган дип әйтә алабыз. *Иси* сүзен татарча *Ише* дип төзәтәбез. Хәзерге татар телендә *иш* бернең икенчесе дигәнне белдерә. Борынгы төрки телдә *иши* — хатын-кыз, дәрәҗәле кешенең хатыны, бикә дигәнне аңлаткан. Борынгы грек һәм латин телләрендә *ш* тартыгы булмаган, ләкин мисыр телендә ул булган. Коростовцев мисалга китергән Саисе сүзе мисыр чыганакларыннан алынганмы,— әллә болай гына, уйлап чыгарып кына тәкъдим ителәме — билгеле түгел. Ни генә булмасын, борынгы Мисырга кагылышлы һәр хезмәттә бу сүз Исида дип грекча формада языла. Шул ук вакытта Мисырның Карнак шәһәрендә Аменхотеп III заманында, б.э.к. XV гасыр уртасында Мут исемле алиһәгә багышланган Ишеру гыйбадәтханәсе булуы мәгълүм (Хр.ДВ, 104 бит, искәрмә 23). Гыйбадәтханә исемендәге иҗекләрне төрки тәртиптә Ру ише дип үзгәртсәк, бу Руның, күрәсең, ниндидер күк алласының «ише» (хатыны) дигәнгә туры киләчәк. Мут исә мисырлыларда хатын-кыз затындагы алла булган.

Кече Азиядә, Аккад һәм Ассирия дәүләтләрендә Иштар дигән алиһә булуы мәгълүм. Иштарны шумерларның Инанна, финикиялеләрнең Астарта дигән алиһәләре белән тиңлиләр һәм Иштар сүзе дә Астартадан үзгәргән дигәндәйрәк фикерләр әйтелә. Ләкин бу алиһә исемнәренең һәркайсы мөстәкыйль рәвештә барлыкка килгән, ахрысы. Тик аларның функцияләре генә охшаш. *Иштар* сүзен *иш* һәм *тар* иҗекләренә бүлсәк, безнең өчен монда аңлашылмаган бернәрсә дә калмый. Сүзнең һәр

икесе төрки, ләкин аларның ялгану тәртибе генә төркичә түгел. Әгәр Иштар сүзен төркичә Тариш дип үзгәртсәк, ихтимал, бу көчле яңгырамас иде. Шунлыктан дип әйтимме, башка сәбәптәнме, ассирия-вавилоннарның «бөек ише» шулай «иш — бөек» рәвешендә формалашкан.

## 5. БОРЫНГЫ МИСЫР АЛЛАЛАРЫ. *ХОР*

Осирис белән Исиданың улы Хорны мисырлылар бөркет яисә карчыга сыйфатында олылаганнар. Хор-бөркет патша хакимлегенең якчысы исәпләнелгән һәм шул ук вакытта ул исән патшаның бер чагылышы да булган. Мисырда *Хор* катнашында ясалган берничә алла булуы билгеле. Хорга табыну Югарыгы Мисырда да, Түбәнге Мисырда да киң таралган булган. *Хор* исемен кайчагында *Гор* дип тә язалар, кайбер катнаш исем-атамаларда *Хар* дип тә языла. *Хор — Гор — Хар* ул чынлыкта яңа туган, яшь һәм исән алла, ягъни кояш. Хорны Мин дип тә атыйлар. Шул рәвешчә, без яңадан әлеге дә баягы бер үк нәрсәгә әйләнеп кайтабыз — Хор, димәк, Мин кебек үк, Ата улы. Хор — Осириснең дәвамы, аның бу дөньядагы исән варианты.

Хор — Гор сүзен без иң әүвәл *Кор* булган булырга тиеш дип исәплибез. Кор катнашында корал, корбан, корт кебек сүзләр ясалган. Мәсәлән, *корбан*, сүзен алып карыйк. Бу сүзне, гадәттә, гарәптән алынган дип аңлаталар. Корбан латин телендә дә бар... латинча «бүләк» (русча «дар») дигәнгә туры килә; ул, имеш, яһүд теленнән алынган (Дво, 262 бит). «Алынмалар» сүзлегендә гарәпчә «корбан»га аллага якын булу өчен суелган хайван дигән аңлатма бирелгән (Алы, 213 бит). Мондый аңлатма чынлыкта берни аңлатмый. Корбан сүзен «хайван» сүзе белән тәңгәл дип белү бер хата булса, «аллага якын булу өчен» дигәне икенче хата булып тора.

Корбанга бары хайван гына бирелмәгән. Бик борынгы заманнарда, әйтик, тарихи чорларга кадәр кайбер халыкларда сугышта әсир төшкән кешеләрне дә корбан итеп бирү гадәте булган. *Корбан* сүзен киңрәк мәгънәдә кулланганда, җиргә, суга, изгеләргә багышлап бирелә торган азык-төлек дип атарга була. Тик шулай да сүзнең иң әүвәлге мәгънәсе корбан рәвешендә (яһүдчә һәм латинча «бүләк» рәвешендә) *кор*га кан бирүгә кайтып кала. Сүзнең *бан* иҗекләре шуны раслый. Кеше өчен, хайваннар өчен канның ни дәрәҗәдә әһәмиятле булуын без бик яхшы аңлыйбыз. Моны, билгеле, борынгылар да аңлаганнар. Тик аларның аңлавы примитив карашларга нигезләнгән

булган. Белүебезчә, бөтен нәрсәне хәрәкәткә китерүче — Ата һәм Ата улы дип уйланылган. Су атага тиң. Дөнья яратылганда суда, су стихиясендә яратылган. Кан да туктаусыз ага һәм ул да су кебек үк сыек. Борынгылар исәпләгәнчә, дөньяны аллалар хәрәкәткә китерә. Аллалар исән һәм көчле булганга җир йөзендә тереклек дәвам итә: агачлар, ашлыклар үсә, хайваннар үрчи, кешеләр үрчи. Ләкин аллаларның да дошманнары күп. Аллалар мәңге яшәсеннәр һәм һәрвакыт көчле булсыннар өчен аларга әледән-әле кан биреп торырга кирәк. Шул нигездә җир, су, күк ияләренә, ата-бабаларга корбан рәвешендә кан яисә аны алыштыра торган башка нәрсәләр бирелгән. Борынгы Мисырда исә корбан бирү аеруча киң таралган булган. Кояшка, бүтән аллаларга, аларның сыннарына багышлап корбан бирү өчен махсус корылмалар корылган, корбан бәйрәмнәре вакытында көтү-көтү малтуар чалганнар.

Бу уңайдан татарның мал суюга карата булган бер гадәтен искә төшермичә мөмкин түгел. Татар кешесе суелган малның канын тамчысына кадәр агызып бетерә. Бетерергә тиеш. Шунлыктан татар суйган ит тәмлерәк исәпләнелә. Суелган мал канын агызып бетерү гадәтен хәзер мөселманлык белән аңлатырга яраталар. Ләкин моның тамыры мөселманлык чорыннан да ераккарак — борынгы Мисыр һәм, гомумән, борынгы цивилизация заманнарына сузыла.

*Кор* катнашында ясалган тагын бер атаклы сүз бар. Ул да булса, Коръән. Коръән безгә гарәптән кергән. Коръән изге китап. Бу мәсьәләдә без бернинди шик белдермибез. Бездә Коръән күктән иңдерелгән дигән караш та бар. Монысына да шик белдерергә җыенмыйбыз. Шулай да *Коръән* сүзендәге *Кор* иҗекләре безне шактый уйга калдыра. Атаклы Коръәндәге *кор* да шул ук *Хор* лабаса! Бу уңайдан шунысын да әйтергә кирәк, Мисырда Борынгы патшалык чорында яшәгән һәм соңыннан алла дәрәҗәсенә күтәрелгән акыл иясе Имхотепның китабын аллалар күккә алып киткәннәр дә, Мемфис янында кире җиргә ташлаганнар дигән риваять булган (Кор, 159 бит). Әйтик, корбан сүзе гарәпләр, яһүдләр, латиннар белән уртак булгач, Коръән сүзе дә, бәлки, борынгы төркиләр һәм гарәпләр өчен элекке заманнарда ук уртак булгандыр?

*Корал, корт* сүзләрен дә без Кор уллары дип исәплибез. Корның (Хорның) төп функцияләреннән берсе — сугышчанлык, корал исә аның төп «коралы». Кортның татар телендә берничә төрле мәгънәсе бар. Киптерелгән эремчек тә корт, бал корты да, тирес корты да — корт. «Эрем-

чек» мәгънәсендәге корт «сыер агын» күз алдында тота. Бу очракта кор илаһи сыерга тиңләштерелә. «Пирамидалар тексты»ның 1209 параграфында әйтелгәнчә, күк алиһәсе Нутның улы Ра, ягъни кояш, «алтын бозау» дип atала. Сыерны күккә тиңләштерү татар халык иҗатында да очрый. Русча «сыер» корова да Кор улы буларак аңлашыла.

«Бөҗәк» мәгънәсендәге корт сүзенә килгәндә, беренчедән, бал корты Мисырда, гомумән, изге саналган. Югарыгы Мисырның символы бал корты, Түбәнге Мисырның символы камыш булган. Бал корты татарда да изге. Корт аерганда берәрсенең башына корт күче сарылса, ул кеше бәхетле була дигән караш бар. Борынгы Мисырда гап-гади тирес корты (латинча скарабей) кояш символы исәпләнелгән. Скарабейны изгеләштерү төрекмәннәрдә әле дә саклана икән.

Мисыр алласы Хорның чагылышы — бөркет яки карчыга кошлары. Русча моны «сокол» дип тә, «ястреб» дип тә язалар. *Сокол* татарча — бөркет, ястреб — карчыга. Карчыгалар, бөркетләр нәселеннән татарча *шоңкар* дигән кош та бар. *Шоңкар* русча кречет. Татарча шоңкар сүзендәге *кар* иҗекләрен сүз башына, *шоң* иҗекләрен сүз азагына куеп әйтсәгез, *каршоң* барлыкка киләчәк. Чынлыкта, бу русча *коршун* булачак. Шулай итеп, әлеге татарча һәм русча кош атамаларында *кар, кор, кре* иҗекләре катнаша. (*Шун* турында сүз соңыннан булыр.) Монда тагын лачын сүзен дә искә төшерәбез. Бу сүзне *ла-чын* дип таркатсак, бу «кояш улы» булачак. Русча *сокол* сүзен *со-кол* рәвешендә таркатабыз һәм *са-кол* дип төзәтәбез. Мисыр телендә сүз башында килгән *са* иҗеге «улы» мәгънәсен белдерә дип язалар китапларда. *Саисе* сүзе мисалында без инде моның бер үрнәген күреп киттек. Татарча *Сара, сыра, сары* сүзләре дә шул рәвешчә ясалган *мисыр* сүзләре түгел микән дип әйтәсе килә. Ихтимал, сыер сүзе дә шулар рәтенә карыйдыр. *Сыйырның* искечәрәк формасы *сы-гыр* лабаса. Русча *сокол* ахырындагы *л* тартыгы монда *р* тартыгына тәңгәл. *Л* белән *р* еш кына бер-берсен алыштырып килә алалар. Русча *закон* сүзе дә мисырча ясалган, ахрысы. Бу сүзне *за-кон* дип бүләбез һәм «улы кон» дип аңлыйбыз. *Кон*ның борынгырак формасы —*кан*, ягъни мисырча *хан*. Законга тәңгәл төрки-мисыр *канун* сүзе дә *кан (хан)* катнашында ясалган. Бу сүзнең яшерен мәгънәсен «канның (ханның) улы», ягъни ирлек куәте дип аңлатабыз.

Шул рәвешчә, *кар — кор — хор* сүзләрен күк дип тә, кояш дип тә аңларга була. Без инде беләбез, Крит-Ат-

лантиданың бер халкы кар дип аталган. Карлар кояшка табынганнар һәм Кар исемле мифик ата-баба нәселеннән булганнар. Безнең салкын якларда күктән ява торган «мамык» та кар дип атала бит әле. Без сөйләгән кархорларга моның берәр төрле катнашы юк микән? Бар, әлбәттә. Югарыдан «мамык» түгел, күкнең, кояшның «балалары» ява лабаса! Беренче мәртәбә безнең якларга килеп чыккан һәм моңарчы беркайчан кар яуганын күрмәгән көньяк кешеләре, ихтимал, нәкъ менә шул рәвешчә фикер йөрткәннәрдер дип әйтергә була.

Телдә *кар — кор — хор* иҗекләренең башка тартыкларга башланган вариантлары да билгеле. Мәсәлән, *кар* иҗегенә тәңгәл *тар* иҗекләрен күп сүзләрдә очратырга була. *Бар, пар, мар, сар* һ.б. төрдәге иҗекләр дә *кар* һәм *тар* иҗекләренә тиң. Русча *барс*, татарча *барыс*, этрускча *Царслан, Марис*, Латинча *Марс* — һәркайсы кояш уллары. Русча *ворон*, татарча *карга* дәхи кояш уллары. Каргалар, козгыннар борынгы кытайларда һәм скифларда да кояш алласы вәкилләре исәпләнелгән.

Гомернең «Илиада» дастанында Хрис дигән дин башлыгы һәм аның кызы Хрисеида турында сүз бара (Ил, I, 94 һ.б.). Шунда ук Брисеида дигән кыз исеме дә телгә алына (Ил, I, 184). Хрисның кызы Хрисеида булгач, Брисеиданың атасы Брис булгандыр дип уйларга кала. Б.э.к. 80-29 елларда яшәгән грек тарихчысы Диодор «Тарихи китапханә» дип аталган хезмәтендә борынгы Мисырда XXIV династия вакытында (732—726 елларда) патша булып утырган Бокхорис турында сөйли (Хр. ДВ, 164 бит). «Илиада»дагы *Хрисны Хорис* дип, *Брисны Борис* дип төзәтәбез. Мөселманнар *Гайса* дип атаган пәйгамбәр христианнарда *Христос* дип атала. Сүз ахырындагы *тос* иҗекләре «алла» яисә «изге ия» мәгънәсенә тиң. Борынгы грек телендә «алла» *теос* дип атала. Татарда «төсем качты» дигәндә кешенең ниндидер шәхси алласымы, иясеме күз алдына килә кебек. *Хрис-Хорис*ның төркичәсе, әлбәттә, *Харис, Брис-Борис*ныкы — *Барис* булган. *Харис* та *Барис* та бүгенге көндә гадәти татар исемнәре. Татарда шулай ук Тарисов фамилиясе дә бар. Димәк, элегрәк Тарис исеме дә булган. Марис исеме бездә юк, ахрысы, ләкин Марслар белән — буа буарлык. Монда шуны да әйтергә кирәк, «гарәпчә» *хөр, хөрлек, хөррият*ләр дә борынгы мисырлыларның *хор — хөр* дигән атаклы алла исемнәреннән үзгәргән булса кирәк. Гарәп теле аша кергәнме ул сүзләр безгә, әллә без аларны гасырлар буена үз телебездә саклап килгәнбезме — моны әлегә беркемнең дә исбат иткәне юк.

## 6. БОРЫНГЫ МИСЫР АЛЛАЛАРЫ. *СЕТ* ҺӘМ БАШКАЛАР

Осирисның туганы, Осирисны үтерүче *Сет* Мисырда җил-давыл һәм сугыш алласы исәпләнелгән. Чүлләр хакиме буларак Сет Мисырга комлы җил-давыл җибәргән. Тора-бара ул Мисырга басып керүче чит ил гаскәрләренең якчысы дип уйланылган. Гомумән, Сет Мисырда барлык начарлыкны, барлык җүнсезлекне яклаучы явыз рух дип уйланылган. Шул ук вакытта Сетка табынучылар да булган. Исида һәм Осирис турындагы хезмәтендә Плутарх Сетны Тифон белән тиңләштерә һәм аның исеменең мәгънәсен «то, что губит», «то, что совершает насилие», ягъни «харап итүче», «көчләүче» дип аңлата (Плу, II, 49).

Мисыр алласы Сетның барлык сыйфатлары Плутарх аңлатмасына туры килә. Сет дигән алланың табигате шулай ук аның исеменең төрки мәгънәсенә дә туры килә. Русча хезмәтләрдә *Сет* яисә *Сетх* дип языла торган бу исемне без *Сыт* дип аңлыйбыз. *Сыт* сүзе татарда исем түгел, боерык фигыль. *Сыту* татар телендә изү, җәберләү, көчләү, харап итү мәгънәләренә ия. Б.э.к. XXV гасырда иҗат ителгән һәм «Палермо ташы» дип атала торган мисыр истәлегендә *Сед* исемле ниндидер алла телгә алына. Монда Сед бүре кыяфәтле (Хр. ДВ, 17 бит; 24 бит, искәрмә 29). I династия чорындагы Сед дигән алланы соңыннан мифларда һәм риваятьләрдә сөйләнелгән Сет булырга тиеш дип белсәк, Сытның бүре табигате тагын да ачыклана төшәчәк.

Борынгы Мисырда исеме төрки боерык фигыль рәвешендәге тагын бер алла булган. Монысы *Тот* дип атала. *Тот* та *Сет* кебек үк бик борынгы алла исәпләнелә. Тотка да Мисырның төрле җирендә табынганнар. Грекча Гермополь дип аталган шәһәр динчеләре бик борынгы заманнарда Тотны дөньяны яратучы алла дип исәпләгәннәр. Тотның *къ* варианты *Кот* булыр иде. Кот исә чыннан да дөньяны яратучы аллалар рәтендә була ала. *Кот*ның *Тот* варианты бүгенге татар телендә боерык фигыль генә булып аңлашылса да, кайчандыр ул да «кот» дәрәҗәсендәге алла исеме булган, ахрысы. Мәсәлән, «тотылды» дигәндә кемнеңдер кемнедер тотуы күз алдына килә. «Котылды» дисәк, тотылган кемнеңдер Кот тарафыннан азат ителүе күз алдына килә. Кот тарафыннан азат ителү мөмкин булгач, Тот тарафыннан әсир итү дә мөмкин хәл дип исәплибез. Икенче төрле итеп әйткәндә, Тот та, Кот та әлек конкрет сыйфатлары, конкрет функцияләре булган аллалар рәвешендә күз алдында тотылган. *Тот* — тотучы, тикшерүче, *Кот* — коткаручы һәм рух өстәүче.

Мисырда Тотны, гадәттә, ибис кошы кыяфәтле итеп ясаганнар. Тот исеме «Пирамидалар тексты»нда да бар икән. Птоломейлар чоры Мисырында Тот иҗатчы һәм караңгылык көчләрен җиңүче булып аңлашылган. «Сыер китабы»нда һәм башка истәлекләрдә Тот кояш алласы Раның җирне яктыртуда ярдәмчесе, ягъни ай алласы буларак тасвирлана. Монда ул күбрәк «кот» буларак күренә. «Үлеләр китабы»нда исә Тот теге дөньяда үлеләргә хөкем чыгаруда катнаша. Монда ул гөнаһлыларны тотучы, һәркемнең гаебен, гөнаһын ачыклаучы. Мифларда һәм легендаларда Тот патша түгел, патшаның ярдәмчесе һәм киңәшчесе итеп тасвирлана (Кор, 82, 83 битләр).

Борынгы Мисыр телендә бүгенге төрки телдәге боерык фигыль рәвешендәге «бак» термины да кулланылган. Бак «сүзе мисыр телендә «коллау», «кол ир кеше» дигән мәгънә белдергән (П, 338 бит). Мисырча бакенхонсу дигән сүз, мәсәлән, русча «раб (бога) Хонсу» дип тәрҗемә ителә (Кор, 175 бит). Сүз башындагы бак «кол» дигәнгә туры килә. Бүгенге төрки телләрдә бак сүзенең кол һәм кодлау мәгънәләре юк. Бак ул «кара», «күзәт», «күз-колак бул» дигәнне белдерә. Бакның баг варианты да мәгълүм. Борынгы төрки телдә баг — «бау», «богау» дигәнне, бага — исә ниндидер титулны белдергән. Әгәр дә бак һәм баг сүзе мисыр телендә «кол» мәгънәсенә туры килә икән һәм аның мәгънәсе бүгенге төрки телләрдәге «кара», «күзәт» һәм «богау» мәгънәләренә тәңгәл икән, бәлки фарсыча баг, татарча бакча сүзләрен дә борынгы Мисыр чорларындагы *бак*ка бәйле рәвештә аңлатырга кирәктер? Җимеш, яшелчә бакчасы, әйтик, Мисырда гына түгел, теләсә кайда карап, күзәтеп торуны, эшкәртеп торуны таләп итә. Мисырда исә бакча эше аеруча күп кул хезмәте сораган. Бакчаларда, иген кырларында сугару, җир эшкәртү, сөрү, чәчү, утау, күмү, төпләү, уру — барысы да, барысы да буйсынган кешеләр, коллар тарафыннан башкарылган. Бакча сүзен «бак»ның «ча»сы, ягъни «бакларның эш урыны» дип аңлау, безнеңчә, логикага каршы килми.

Бак, күрәсез — алла түгел. Монда ул аллалар арасына бары төрки боерык фигыль формасындагы сүз булган өчен генә килеп керде. Шундыйлардан тагын бер мисалга тукталып китәсе килә. Мисыр телендә, Урта чорда, «рядовой воин» (сугышчы) *анху* дип аталган (КДЕ, 135 бит). Сүзне *ан* һәм *ху* өлешләренә таркатабыз, *ан* ны *аң, хуны ку* дип төзәтәбез. *Аң* сүзенең төрки телдә кош, киек, җанвар мәгънәләре бар. Мәсәлән, борынгы төрки телдә *аңчы* — кош-корт аулаучы дигәнгә туры килә (ДТС, 46 бит). Татар теле диалектларында (мәсәлән, Гайнә сөйлә-

шендә) *аңту* — сагалау, саклап тору дигәнне белдерә (ТТДС, 61 бит). *Аңту*ның *аңдау, аңду* вариантлары да бар. Борынгырак телдә, бу очракта, мисыр телендә аның *аң ку (ан ху)* варианты да булган, күрәсең. *Ку* иҗеген хәзергечә кууның боерык фигыль формасы дип белсәк, *ан ку (анху)* сүзенең киңәйтелгән мәгънәсе «кош-корт, киек, җанвар ку!» булачак. Борынгы Мисырда «гади сугышчы»ның аучы, җәнлек, киек куучы мәгънәсендәге сүз белән аталу ихтималы шулай ук логикага каршы килми.

Аң турында сүз чыккан икән, төрки аңның икенче мәгънәсен дә искә төшереп китик. Бүгенге татар телендә *аң* — акыл, уш, ис дигән мәгънәләрне белдерә. *Аңкау* дисәк, авыз эчендәге куышлык күз алдына килә. Сүзне *аң* һәм *кау* өлешләренә таркатсак, кау — «бушлык» яисә «куыш» була. *Аңкау* сүзе тулаем «аң куышы», «аң оясы» булып чыга. Димәк, борынгылар аңны чыннан да ниндидер җанлы нәрсә дип белгәннәр икән. Мисыр телендәге *анх* сүзен русча «жизнь» дип тәрҗемә итәләр. Мәсәлән, *пер анх* русча «дом жизни» була (КДЕ, 251 бит). Мисырча *анх* сүзен татарча *аң* сүзенә тәңгәл дип, мәгънәсен исә кешене яшәтә торган «ниндидер җанлы нәрсә» дип аңлыйбыз. Төрки аңчылар (аучылар) да, борынгы Мисыр сугышчылары да җәнлекне, киекне яисә дошман сугышчысын үтереп, аларның аңнарын алырга һәм... үзләренеке итәргә тырышканнар да инде.

Хәзер яңадан Мисыр аллаларына әйләнеп карыйк. Мисырда төрле чорда зур-зур шәһәрләр һәм дин, культура үзәкләре булган. Аларның һәркайсында диярлек үзләренең аллаларына табынганнар. Мәсәлән, Мемфиста Пта дигән алланы олылаганнар. Птаның хатыны Сехмет дип аталган. «Птаның ничек барлыкка килүе билгеле түгел», дип яза М.А.Коростовцев (Кор, 73 бит). Геродот язганча, Мемфисның беренче патшасы Мин Птага багышлап гыйбадәтханә салдырган. Птага Мисырның башка шәһәрләрендә дә, хәтта Мисырдан читтә дә табынганнар. Пта дигән алланы динчеләр Нун, Тот, Атум, Сокар, Осирис, Ра, Амон, Себек-Ра һ.б. исемдәге аллалар белән тиң дип белгәннәр. Димәк, бу алла исемнәренең һәркайсының мәгънәсе бер үк төрле дип әйтергә туры килә. Хәер, без әлегә Пта турында гына сүз алып барабыз. Шулай да Птага тиң Тотка игътибар итмичә булмый. Пта яисә кайчагында Птах дип языла торган алла исемен без *пот* дип беләбез. Үлчәү берәмлеге «пот» түгел, «табыну сыны пот» турында сүз бара. Авырлык үлчәү берәмлеге булган «пот» та шушы ук Поттан алынган бу-

лырга, Пот дигән алла сыны заманында иң зур, иң авыр һәйкәл булганлыктан, һәрбер авыр нәрсә соңыннан «пот» булып тоелырга, иң ахырда исә үлчәү берәмлегенә әверелергә мөмкин.

Борынгы мисыр телендәге *Пот*ның бүгенге татар телендә *Бот* формасы да бар. *Бот* — аякның юан өлеше яисә гомумән аяк. Курыкканда без әле дә «котым ботыма җитте» дибез. Бу очракта ботның нинди әгъзаны аңлатуы бик үк аңлашылмый. Шулай ук «җитте» сүзе дә аңлашылып җитми сыман. «Башына җитте» дигәндә «җитте» үтерде дигәнне белдерә. Бәлки монда да Кот Ботны (Потны) үтерде дигән мәгънә бардыр?

Птаның хатыны *Сехмет* сүзен *Зәхмәт* дип беләбез. Сехметның мәгънәсе «могучая» икән (Кор, 22 бит). Сехмет арыслан кыяфәтле булган. Сехмет турында мисырлыларда шундый миф та булган. Бер заман җирдәге кешеләр картайган патша-алла Ра сүзен тыңламый башлаганнар, аллага каршы һәртөрле явызлыклар эшләгәннәр. Ра үзенең бер күзе һәм кызы Сехметны җиргә кешеләрне җәзаларга җибәрә. Сехмет кешеләрне кыра башлый, каннарын эчеп, көчәйгәннән-көчәя бара. Мондый хәлне күреп Ра кешеләрне бик кызгана һәм алиһәгә кан төсендәге кызыл сыра эчерергә боера. Алиһә исерә һәм кешеләрне үтерүдән туктап кала (Кор, 66 бит). Бүгенге татар телендә *зәхмәт* — газап, кайгы-хәсрәт; чир, авыру мәгънәләрендә кулланыла. Телдә *зәхмәт кагылу, зәхмәт тию, бирән зәхмәте* кебек сүз тезмәләре, «зәхмәте төшкере» дигән каргыш сүзе һәм «кырылып бетү» (русча «мор») мәгънәсендә «үләт зәхмәте» дигән әйтем бар.

Мисыр алиһәсе Сехметның *Хатор* һәм *Тефнут* дигән исемнәре дә билгеле. Хатор белән Тефнут та Раның кызлары һәм арыслан гәүдәле, хатын-кыз кыяфәтле алиһәләр булган (КДЕ, 237 бит). *Хатор*ны без *Хәтәр* дип беләбез. Хәтәр бүгенге көндә актив сүзләрнең берсе. Моның мәгънәсен ачыклау өчен сүзлекләргә карап торуның кирәге дә юк дип әйтергә була. Шулай да карап алыйк. *Хәтәр*нең, русчасы — опасность, угроза. Кешеләрне кыручы, кешеләрнең канын эчүче арыслан кыяфәтле алиһә, нинди генә исемдә булса да, адәм баласына куркыныч тудыручы, чир, үлем таратучы булып аңлашылган һәм бүгенге татар телендә моның тулы мәгънәсе исән-имин килеш саклана бирә.

Сехметның өченче варианты Тефнут исемендә бернинди куркыныч мәгънәләр юк. һәм мондый сүз бүгенге татар телендә юк та. Ләкин *Тефнут*ны *Теф* һәм *Нут* рәвешендә икегә бүлсәк, монда да без таныш иҗекләрне

таба алырбыз. *Тефнут* иҗекләр дәрәҗәсендә дә, аерым сүзләрнең ялгану тәртибе дәрәҗәсендә дә — төрки. *Теф* яисә *тәф* рәвешендәге сыйфат сүзе татарча исемнәрдә очрый. Мәсәлән, *Тәфтиләү, Тәфкил (Тәфкилев)* исемнәрендә *тәф* катнаша. Борынгы мисыр телендә *тәф*нең *нәф* варианты да мәгълүм. *Нәф* сыйфаты да исемнәр ясауда катнаша. Мәсәлән, Пта белән Сехметның алла дәрәҗәсендәге уллары Нефертум дип, Осириснең бер сеңелесе Нефтида дип атала. Мемфистагы Пепи I нең пирамидасы mnnfr дип атала. Мемфис сүзе шуннан үзгәргән, ди. М.А.Коростовцев. Ләкин, югарыда күреп киткәнчә, Мемфис сүзен без Минбис дип аңлау дөресрәк булыр дип исәплибез, mnnfr тартыкларын исә *Мин нәф ир* дип тулыландырабыз. *Нефертума*ны *Нәф ир-тума, Нефтида*ны *Нәф Ти-да* дип беләбез.

Татар телендә *нәф* катнашында ясалган бик матур *нәфис* сүзе бар. Нәфис яхшы, күркәм, затлы, зиннәтле, хуш исле кебек уңай сыйфатларны белдерә. Сөйләм телендә *нәфсе*, язмада *нәфес* рәвешендәге сүздә дә *нәф* сыйфаты катнаша. Комсызлыкка әйләнмәсә, нәфсе дә начар нәрсә түгел. *Нәф* катнашында ясалган тагын *нәфрәт* сүзе дә бар. Нәфрәттә бернинди яхшылык, нәфислек юк. Нәфрәт ул ачу һәм җирәнүне белдерә. Ләкин Борынгы Мисырда патша хатыннары гына Нәфрәт дип атала алган. Димәк, бик борынгы заманнарда *нәф* теләсә нинди сүздә бары уңай сыйфатларны гына белдергән.

*Нәф* катнашында ясалган бүгенге исемнәрдән *Нәфкиә, Нәфикъ, Нәфига, Нәфис, Нәфисә, Нәфил, Нәфилә* кебекләрне күрсәтергә була. *Тәф* һәм *нәф*ләрдән кыскарган *әф* иҗекләре катнашында ясалган сүзләр һәм исем-атамалар да бар. Әфәнде сүзе шундыйлардан берсе булса кирәк. *Нәфис, нәфрәт, Нәфикъ* кебек сүзләрнең барысы да бездә гарәп-фарсыдан кергән дип исәпләнелә. *Әфәнде* хәтта «Алынмалар сүзлеге»нә дә кермәгән. *Әф* сыйфаты белән ясалган Әфләтун исеме дә бар әле бездә. Әфләтунны гарәп аша кергән грек исеме Платон дип аңлаталар. Платонның, киресенчә, Әфләтуннан үзгәргән булуы ихтималы турында беркемнең дә башына килгәне юк, ахрысы. Борынгы грекларның Афина дигән алиһәләренең исемендәге *аф* иҗеге дә кайчандыр *тәф* яки *нәф* булмады микән әле! Булырга да мөмкин — борынгы грекларның күп кенә алла исемнәре, дини гореф-гадәтләре, йолалары, законнары Мисырдан алынган, ди Геродот.

Борынгы Мисырда тагын Пахт, Мехит дигән алиһәләргә дә табынганнар. Арыслан кыяфәтле Мехит Инхар дигән алланың хатыны исәпләнелгән. *Пахт* дигән алиһә

исемен без *Бәхет* дип беләбез. Бүгенге татар телендә «бәхет» рәвешендә ясалган *тәхет, ләхет* сүзләре мәгълүм. *Бәхет* тә, *тәхет* белән *ләхет* тә чыгышлары белән гарәп-фарсыдан түгел, бәлки Мисырдан булырга тиеш дип исәплибез. Әлеге сүзләр ахырындагы *хет* иҗекләре шуңа ишарәли. *Мөхит* сүзе татар телендә «тирәяк», «табигать» яисә «җир өсте» дигәнгә туры килә. Мөхит дигән кеше исеме дә бар. *Инхар* дигән алла исемен *(М)ин, хар* дип тулыландырырга мөмкин.

Нилнең беренче бусагасы янында урнашкан Элефантина утравында бик борынгы заманнардан бирле кеше кыяфәтле, ләкин тәкә башлы Хнум дигән аллага табынганнар. Хнумның хатыны Сатис, кызы Анукет дип аталган. Хнум дигән аллага Түбәнге Мисырда да табынганнар (Кор, 51 бит). Саиста (мисырча Сай дигән җирдә) Хнумның хатыны Нейт дип аталган. Нейт та Мисырда бик борынгы алиһәләрнең берсе исәпләнелә. Нейт исеме «Пирамидалар тексты»нда очрый. Греклар Нейт дигән алиһәне үзләренең Афиналарына охшатканнар. Тутмос III заманында Эснеда (мисырча Та-Снида) Хнум кешелек дөньясын, чүлмәк ясаган кебек, чүлмәкче түгәрәгендә ясаган дип исәпләгәннәр. Эсенда Хнумның хатыны Небетуу, улы — Хека дип аталган (Кор, 53, 98, 99 һ.б. битләр).

Иң элек Хнумның үзенә игътибар итик. Хнум сарык тәкәсе кыяфәтендә, ул — тудыручы алла. Борынгы төрки телдә «сарык»ның *къон* дигән атамасы булган (ДТС, 455 бит). *Къон* дигән сүз бүгенге татар телендә дә бар, дөресрәге, *къон* катнашында ясалган «адәм дисәң коны юк, хайван дисәң йоны юк» дигән мәкаль сакланып калган. Мәкальдә *къон* сүзенең мәгънәсе бик үк аңлашылып җитми. Күрәсең, шунлыктан, сүзлектә (ТРС, 276 бит) къон сүзенә русча «толк» дигән аңлатма бирелгән. Мәкальнең бүгенге әйтелешендә къон чыннан да «толк» дигәнгә туры килә кебек. Ләкин борынгы Мисыр дини карашлары нигезендә Хнумның адәм баласын иҗат итүче булуын истә тотсак, «толк» сүзе урынсыз булып калачак. «Адәм дисәң коны юк», ягъни ниндидер мәгънәсез кешене Хнум (Коным) тудырмаган, шуңа күрә аны кеше дип әйтеп булмый дигән фикер барлыкка килә. *Хнум* сүзендәге *м* тартыгы беренче зат тартым кушымчасын чагылдыра булса кирәк. Димәк, бик борынгы заманнарда ук әлеге сүз төрки формада кулланылган һәм шул килеш ул истәлекләрдә сакланып калган.

Хнумның хатыны *Нейт* сүзен *Ниәт* дип төзәтәбез. Ният тә бездә гарәп сүзе исәпләнелә. Бүгенге татар телендә ният бик актив кулланыла. Ният катнашында ясал-

ган күп кенә сүз тезмәләре мәгълүм. Мәсәлән, ниятең — юлдашың; эшнең башы — ният; ният — ярты гамәл һ.б. Берәр зур, җаваплы эш башлаганда «ниятләдек» диләр. Кыскасы, һәр нәрсәдә Ниәт алиһәсенә мөрәҗәгать итәләр һәм аның изгелегенә исәп тоталар. Дөрес, хәзер инде Ниәтнең алиһә булуы онытылган, ләкин телдә ул һаман да ниндидер серле зат буларак саклана бирә.

*Сатис* исемен без *са-Ти* рәвешендә таркатабыз. Ахыргы-*с* тартыгы артык аваз, ахрысы. Мәгънәсе «улы Ти», ягъни Ти улы. Эснедагы Хнумның хатыны Небетуу сүзен «Нәби туы» («Нәби тумасы») дип, аларның улы Хеканы Хак дип аңлау дөресрәк булыр кебек. Хак сүзе гарәпчә туры: чын, дөрес; алла мәгънәләренә тәңгәл. Татар телендә дә хак, нигездә, шул мәгънәләргә ия. Борынгы мисыр телендә хека — «властитель», «владыка» (Хр. ДВ, 135, 136 бит, искәрмә 32; КДЕ, 136 бит). Әлеге хак татарча «Хак Тәгалә» дигән сүз тезмәсендә дә кулланыла. Җыеп әйткәндә, аллалар улы Хека дигән алланың чын исеме Хак булган дип әйтә алабыз. Татар телендә дә, гарәп телендә дә «хак» бары аллаларга карата гына кулланыла торган изге сүз. Хак сүзенең кыскартылган варианты ак бүгенге татарда иң изге төсләрнең берсе исәпләнелә.

## 7. ГЕЛИОПОЛЬ АЛЛАЛАРЫ

Түбәнге Мисырда, Дельтаның көньяк-көнчыгышында, хәзерге Каһирә шәһәреннән берничә километр төньяк-көнчыгышта Гелиополь дигән дини үзәк булган. Гелиополь грекча сүз. Борынгы мисырча бу шәһәр Иуну дип, Библиядә Он дип аталган. Шул ук шәһәр исемен Ана дип тә укыйлар.

Гелиополь динчеләре карашынча, дөньяда иң беренче алла Атум дип аталган. Атумны беркем тудырмаган. Иң әүвәлге хаоста, Нун дип аталган океанда ул үзен үзе барлыкка китергән. «Пирамидалар тексты»нда Атум «аллаларның атасы» дип атала. Нун исә, борынгы мисырлылар карашынча, Җир астында урнашкан. Нил суы шуннан агып чыга дип уйланылган. Атум, Нун суында ялралганнан соң, үсә башлаган «калкулыкка» әйләнгән һәм Хепри дип аталган (Кор, 60, 61 битләр).

Атум, үз орлыгын үзе төкереп чыгарып, беренче алла Шуны, аның хатыны Тефнутны тудырган. Шу белән Тефнуттан Геб дигән алла һәм Нут дигән алиһә туган. Геб белән Нуттан исә, әйтелгәнчә, Осирис, Исида, Сет һәм Нефтида туган. Шу, Тефнут, Геб, Нут дигән аллаларга, алиһәләргә Мисырда махсус табыну урыннары, аларга

багышланган гыйбадәтханәләр салынмаган. Шулай да дини текстларның бик борынгыларында ук һәм һәркайсында диярлек әлеге исемнәр телгә алына.

Гелиополь динчеләре исәпләгәнчә, кешеләр Раның күз яшеннән барлыкка килгәннәр. Раны һәр көнне иртән анасы Нут тудыра. Туу белән Ра күккә күтәрелә һәм юлда очраган дошманнары белән сугышка ташлана. Баштарак ул җәяүле сугышчы буларак тасвирлана, соңга таба исә атлы сугышчыга әйләнә. Шундый сугышларның берсендә Раны агулы җылан чага. «Ра кебек үк күктәге һәм җирдәге бар нәрсәне белеп торучы» алиһә Исида кояш алласының чын исемен сорый һәм шул рәвешчә аның өстеннән хакимлеккә ирешмәкче була. Ра үзенең берничә исемен әйтә. Арада шундыйлары да бар: «Иртән мин — Хепри, көндез — Ра, кичен — Атум» ди кояш алласы.

*Хепри* исеме мисырча «туу», «барлыкка килү» дигәнне аңлата торган *хпр* фигыленнән ясалган икән (Кор, 62 бит). *Хпр* тартыклары белән ясалган һәм мәгънәсе мисырча хепри, хпр сүзләренә якын торган татарча сүз дә бар. Ләкин бу сүзнең мәгънәсе «туу» түгел, әдәби тел өчен ул әдәпсезрәк яңгырый. Шунлыктан без аның татарча әйтелешен язып күрсәтүдән тыелып калабыз.

Атум шулай ук төрки сүз. Моны *а-тум* рәвешендә таркатабыз, бу исә «А улы» булачак. «А улы»н Су дип тә, Ана улы (Ананың җенес әгъзасы) дип тә аңларга була. *Тум*ның *тума* рәвешендәге тулырак варианты татар телендә әле дә исән. *Ра*ның «кояш» мәгънәсендәге *Ла*га тәңгәл икәнлеген без инде беләбез. *Ра*ның *рә, ре* вариантлары да «кояш» дигәнгә туры килә. Татарча *рәшә* җәй көне җир өстендә тирбәлгән кояш нурын аңлата. Бердәнбер төрки алла дип исәпләнелгән *тәңре* сүзенең ахыргы *ре* иҗеге «кояш» дигәнне аңлата. «Кояш» мәгънәсендәге *ра* дөньядагы башка телләрдә дә очрый. Монда бары үзебезгә яхшы таныш рус теленнән берничә мисал белән генә танышып китәргә була. Салават күпере русча радуга дип атала. Сүзне ра дуга дип таркатсак, бу «кояш дугасы» булачак. Русча «кол» раб дип атала. Мәгънәсе «кояш улы» яисә Ата улы. Димәк, бик борынгы русларда да кояшка багышлап корбан бирү гадәте булган дип әйтергә туры килә. Күп кенә телләрдә «елга» төшенчәсен белдерүче сүзләр «су улы», «ата улы» калыбында ясалган. Русча *река, рыба, рак* сүзләрендә *ре, ры ра* иҗекләре «кояш», «су» һәм Ата мәгънәләренә туры килә.

Нут исемен без инде телгә алдык. Нутны күк алиһәсе дип исәпләгәннәр. «Пирамидалар тексты»нда кояш алласы Ра Нуттан туган «алтын бозау» дип атала. Ми-

сыр сурәтләрендә Нутны ике аягы белән дә җиргә басып торган, кулларын югары күтәргән хатын-кыз итеп тә, сыер итеп тә ясыйлар. Хатынның да, сыерның да тәненә йолдыз рәсемнәре төшерелгән була. Мифларда әйтелгәнчә, кояш алласы Ра гына түгел, йолдызлар да Нутның балалары. Нут кичен үзенең балаларын кабып йота, иртән аларны тудыра. Төнлә балалары аның эчендә йөзеп йөриләр. Көн дә үз балаларын ашаган өчен Гебның (ягъни Нут иренең) хатынына ачуы килә. Ир белән хатын бозылышып китәләр. Нут белән Гебның аталары Шу аларны бер-берсеннән аера һәм, шулай итеп, дөньяда «күк» белән «җир» барлыкка килә. Үзенең балаларын ашаган өчен Нутны «үз балаларын ашаучы дуңгыз» дип атаганнар. Бу хакта Сети I төрбәсендә, «Сыер китабы»на якынрак бер урында язып калдырганнар (Кор, 70 бит).

Шулай итеп, Нут тудыручы һәм ашаучы алиһә булып чыга. Мәгънәсе белән ул — Җир яисә Ана һәм шул ук вакытта Күк алиһәсе.

*Күши* сүзе турында сөйләгәндә без кү иҗеген «сыер» дип аңлаттык. Кү-к сүзендә «күк»нең Сыер улы булуы чагыла. Сыерны күк алиһәсе рәвешендә күз алдына китерү татар халык иҗатында сакланып калган. «Зыяндаш теле» дип аталган йола җырында шундый юллар бар:

Кара болыт киләдер,
Кара болыт астыннан
Кара сыер киләдер.
Мөгезе күккә терәлгән,
Җилене җиргә терәлгән... (Йо, 33 бит.)

Өч строфадан торган бу «җыр»ның икенче строфасында «кара сыер» урынына «кызыл сыер», өченчесендә «аппак сыер» сүзләре кулланыла. Башка сүзләр бернинди үзгәрешсез кабатлана. Татарда тагын «ай — мөгезле, алтын канатлы» дигән әйтем дә бар (Мә, 39 бит). Әле дә без сөмсез, әрсез кешегә ачуланып «мөгезсез сыер!» дибез. Сыерның кайсы да әрсез һәм сөмсез була кебек. Ләкин әлеге әйтемдә бары тик мөгезсез сыерның гына начар булуына игътибар ителә. Мөгезле, димәк, яхшы холыклы һәм изге саналган булып чыга. Сөйләм телендә тагын «мөгезле түгелсең әле» дигән әйтем дә бар. Борынгы Мисырда һәм борынгы цивилизация илләрендә мөгез аллаларга гына хас атрибутларның берсе саналган. Мисырда, Критта һ.б. илләрдә мөгезгә табынганнар һәм кайбер аллаларны, алиһәләрне мөгезле итеп ясаганнар.

Борынгы мисырлыларның хатын-кызга һәм сыерга тиңләштерелгән Нут алиһәләре исемендә төркиләрнең ут сүзе яшеренеп ята. Ут җирдән чыга, күккә күтәрелә.

Айның, кояшның, йолдызларның табигате утныкына охшаш. Ай, йолдызлар яктырта, нур чәчә, кояш яктырта да, җылыта да. Җирдәге барлык тереклекнең чыганагы — кояш. Кояш һәр иртәне җир астыннан чыга, һәр кичне җир куенына кереп юк була.

Мисырда, Фива шәһәрендә Амон дигән аллага табынганнар. «Пирамидалар тексты»нда Амон кояш алласы Рага тиңләштерелә. Амонның хатыны Мут дип атала (Кор, 53 бит). Мут шул ук Нутның *м* варианты гына икәнлеге үзеннән-үзе аңлашылып тора булса кирәк. Монда шунысына да игътибар итик, Нут, дөресрәге, *н* тартыгы *м* тартыгына караганда дәрәҗәлерәк булып аңлашыла. Нутның ире Геб, улы — Ра. Мутның ире — Амон, улы Рага тиң генә. Шулай итеп, Мут Нуттан соң туган икенче буын алиһә булып чыга. Бүгенге татар телендә мут сүзе астыртын, шук, шаян, хәйләкәр кебек мәгънәләргә ия. Сөйләм телендә «Тышы ут, эче — мут», «ут — мут» кебек әйтем-мәкальләр дә бар (ТРС, 380 бит). Күрәсез, ут турыдан-туры мутка, мут — утка тиңләштерелә.

Фива алласы Амон да саф төрки сүз. Аман, аманлык татар теле диалектларында исән, исәнлек, иминлек мәгънәләрендә кулланыла. Халык телендә:

Ай күрдем аман белән,
Эчем тулды иман белән,—

дигән бик борынгы дога сүзләре сакланып калган. Аман сүзенең ай белән бергә әйтелүе аеруча игътибарга лаек. Аман монда хәзергечә исәнлек, иминлек мәгънәсендә түгел, бәлки Мисырдагыча, Фивадагыча «кояш» яисә «кояш алласы Ра» мәгънәсендә килә.

Белгечләр исәпләгәнчә, Шу сүзе «пустой» (буш) дигәнне аңлата икән. Шунлыктан Шу сүзен һава алласы, яктылык һәм һава алласы дип, җир белән күк арасындагы бушлык алласы дип аңлаталар (Хр. ДВ, 149 бит, искәрмә 9; Кор, 191 бит). Б.э.к. VIII гасырга карый торган һәм «Пианхи ташы» («Стела Пианхи») дип атала торган истәлектә Мемфис шәһәре «Шуның иң әүвәлге торагы» («Изначальное обиталище Шу») дип атала (Хр. ДВ, 157 бит). Димәк, Шуга табыну иң әүвәл Мемфиста (Минбиста) барлыкка килгән дип әйтергә була.

*Шу*, билгеле, «буш» яисә «бушлык» була ала. Мәсәлән, татар телендә ку сүзенең шундый мәгънәсе бар. Тик шулай да мисырлылар алласы *Шу* буш та, бушлык та, җил дә, һава да түгел. Шу ул «су»ның *ш* варианты. Борынгы мисырлылар карашынча, дөнья бар яктан да су белән уратып алынган булган. Нун океаны, әйтелгәнчә,

җир астында дип, Нил елгасы шуннан агып чыга дип уйланылган. Мисырның үзендә яңгыр бик сирәк яуган. Күктән ява торган яңгырны мисырлылар югарыдагы елгадан коела торган су дип белгәннәр. Шу, күрәсең, менә шул күктәге суны аңлаткандыр дип әйтәсе килә.

Шуның «су» булуы татарча ташу (язгы ташу) сүзендә дә чагыла. Ташу сүзе язгы суның уянуын, хәрәкәтен белдерә. Басу сүзе дә ташу калыбында ясалган. Ба — «җир», Су — «су». Басуда иген игәләр, җимеш, яшелчә үстерәләр. Басу ташудан соңгы сугарылган җирне күз алдында тота. Язгы ташу вакытында Җир-Ана белән Су-Ата бергә кавыша. Бары шуннан соң гына орлыклар тишелеп чыга, игеннәр, яшелчәләр үсә башлый. Басу сүзе «иген кырын» аңлатса да, кавышуны күз алдында тотканда, аның башка мәгънәсе барлыгы беленә.

Татар телендә ялгыз *шу* сүзе боерык фигыль буларак кулланыла һәм суның, гомумән, шома, озын нәрсәләрнең бер сыйфатын чагылдыра. Мәсәлән, җылан шуа, бау, аркан ише нәрсәләр шулай ук җирдән шуып бара. Бау-шу дигән парлы сүздә шу турыдан-туры «бау»га тиңләштерелә. Шау-шу дисәк, монда инде шуның тавыш чыгару сәләте күз алдында тотыла. Русча *шум*, татарча *шом* сүзендә дә шу (шо) катнаша. Русча шум сүзендә «шаушу», «тавыш» мәгънәләре бар, татарча шом (шул ук шум) сүзендә шуның куркыныч сыйфаты чагыла.

Хор турында сөйләгәндә без коршун һәм шоңкар дигән кошларны искә төшердек. Әлеге кош исемнәрендә дә *шун* иҗекләре катнаша. Димәк, коршун һәм шоңкар кошлары, кояш улы булулары өстенә, Шу уллары да икән дип әйтергә туры килә.

Шуның улы Геб дип атала. Моны без Җеб дип беләбез. Җепнең төрлесе була: тегәр җеп, кыл җеп, кәтүк җебе һ.б. Сөйләм телендә юан аркан да, дилбегә, аркалык ише баулар да «җеп» була ала (ТТДС, 171, 570 битләр). Бау-шу да, җепләр-арканнар да, йон, чәч бөртеге дә, борынгы карашлар нигезендә, әлеге дә баягы җыланга тиңләштерелә. Шуңа күрә дә бүген бөтенләй әһәмиятсез сыман тоелган нәрсәләрнең исем-атамалары борынгы кеше аңында көчкуәт ияләре — аллалар исеме белән тиңдәш саналган да.

## 8. *НИЛ* АТАМАСЫ ТУРЫНДА

Шулай итеп, Гелиополь динчеләре исәпләвенчә, иң әүвәл Нун булган, Нуннан Атум барлыкка килгән, Атумнан Шу, Тефнут, Шу белән Тефнуттан Геб һәм Нут, Геб белән Нуттан Осирис һәм Исида, Сет һәм Нефтида бар-

лыкка килгән. Бу исемнәрнең күбесен без тикшердек һәм аларның төркилеген ачыкладык дип әйтә алабыз. Калды Нун. Нун нәселеннән булган барлык алла һәм алиһәләр төрки булганнар икән, димәк, Нун да төрки булырга тиеш. Ләкин төрки телләрнең берсендә дә мондый сүз юк, ахрысы. Һич югы татар телендә Нун дигән сүзнең булуын мин белмим. Хәер, татар телендә Нут дигән сүз дә юк. Туктагыз әле, бәлки, монда да шундый ук хәйлә бардыр?! Нут юк, ләкин аның урынына ут бар да, мут бар!

Чыннан да борынгы Мисырда күп кенә яңа сүзләр элегрәк тулы килеш әйтелгән сүзләрнең баштагы тартыкларын төшереп калдыру юлы белән ясалган, ахрысы. Мондый яңа сүзләрнең тулырак вариантлары мисыр теленең үзендә дә, бүгенге татар телендә дә, башка телләрдә дә табыла. Без инде кайбер мисаллар белән танышып киттек. Мисалларны күбәйтү өчен безгә аллалар дөньясыннан беркадәр читкә чыгарга туры киләчәк.

Борынгы Мисырга кагылышлы хезмәтләрдә төрле исем-атамалар арасында хат иҗекләре еш күзгә ташлана. Мәсәлән, Хатнуб сүзен «усадьба золота» дип тәрҗемә итәләр (Хр. ДВ, 26 бит, искәрмә 115). Хат — «усадьба», нуб — «алтын» дигәнгә туры килә. Хат белән нуб сүзләрен аерым-аерым алып караганда, иҗекләр төрки юнәлештә ялгана. Бу бигрәк тә нуб сүзендә ачык чагыла. Алтын — күк улы. Ну-б сүзе шундый мәгънәгә ия. Мисыр сүзләрендә хат — «куыш», «оя», «өй» мәгънәләрендә дә кулланыла. Хатнуб сүзе Урта Мисырдагы алебастр чыгара торган тау куышына карата әйтелгән. Украин телендә хата «өй» дигәнне белдерә. Татарча ихата, русча «изгородь», «плетень» дигәнгә туры килә. Ихата — бүгенге татар телендәге саф мисыр сүзе. Сүзне ихата рәвешендә таркатабыз, бу исә төркигә каршы юнәлештәге «улы хата» булачак. Хат, хата мисыр сүзе булса да, аның әүвәлгерәк формасы төрки кат-катага кайтып кала. Татардаката — киез аяк киеме, ягъни куыш нәрсә. Кат исә русча «слой», «пласт», «ряд» дигән мәгънәләргә туры килә. Мәсәлән, такталарны бер-берсе өстенә катлап-катлап өяләр, өй бер катлы, ике-өч катлы була һ.б.

Мисыр телендә хат иҗекләре хатын-кыз исемнәрендә дә кулланыла. Мәсәлән, кояш алласы Хорның хатыны, күк алиһәсе мисыр телендә Хатхор дип аталган (Хр. ДВ, сүзлек, 533 бит). М.А.Коростовцев бу исемне «жилище бога Хора» дип аңлата (Кор, 107 бит). XVIII династия вакытында Мисырда Хатшепсут исемле хатын патша хакимлек итә. Хатхор һәм Хатшепсут исемнәре алдын-

нан килгән хат иҗекләре «хатын» мәгънәсенә тәңгәл. Сүз уңаеннан әйтик, Хатшепсут исеменең мәгънәсе «мощная жизненными силами» икән (П, 430 бит). Бу атаклы патша-бикә исемен Хат шеп сут рәвешендә таркатабыз. Хат — хатын, шеп — татарча «шәп», ягъни русча моцная, сут исә татар телендә «сок (растительный)» мәгънәсенә ия. Борынгы мисыр телендә сут «үсемлек суы» гына түгел», бәлки «яшәү чыганагы» да булган, ахрысы.

Хат иҗекләренең «хатын»лыгын исбатлый торган сүз — татарча хатын да бар. Борынгы төрки телдә бу катун һәм хатун рәвешендә кулланылган (ДТС, 436, 637 битләр). *Катун* — госпожа, вельможная дама, женщина знатного происхождения; жена правителя, знатного человека. *Хатун-катун* — саф мисыр сүзе. Ул хәтта «Алынмалар сүзлеге»нә дә кермәгән. Әлеге илаһи сүзне без *хат-ун* рәвешендә таркатабыз. һәр ике сүз бер-берсе белән, «ихата» мисалындагы кебек, төркигә кире тәртиптә ялгана. Моны без *ун*ның *хаты*, ягъни Нун дигән алланың хатын-кыз затындагы дусты дип аңлыйбыз. Дөрес, *хатун* сүзендә уртадагы *н* тартыгы төшеп калган, шунлыктан бу терминны чын мәгънәсендә Нун «хатыны» дип игълан итеп булмый. Ләкин ун рәвешендә кулланылганда да элегрәк, әлбәттә, Нун яисә гомумән изге, бөек шәхес күз алдында тотылган. Шуңа күрә дә борынгы төрки телдә хатун шундый югары дәрәҗәдәге мәгънәләргә ия булган да.

*Ун* иҗекләренә без әле бер әйләнеп кайтырбыз. Хәзергә хат эзеннән китик. *Кат* яисә *хат* сүзенең баштагы *къ* яки *х* тартыкларын алып ташласагыз, безгә бик таныш ат барлыкка килә. Кыргый ат татарда тарпан дип атала. Ат исә кыргый атны кулга ияләштергәч һәм аны сугыш эшендә куллана башлагач барлыкка килгәндер кебек. Атка атланган сугышчыга тарпан кат-хат булып тоелган, ләкин аны кат-хат дип атау, күрәсең, килешмәгән, шунлыктан ат рәвешендәге яңа сүз барлыкка килгән. Русча лошадь сүзендәге *адь* иҗекләре дә аттан үзгәргән булса кирәк. *Лош* иҗекләрен *лаш*, ягъни «кояш-улы» дип беләбез. «Кояш уллары»ның башка төрләре белән бутамас өчен *лаш* иҗекләренә *адь (ат)* иҗекләре ялганган.

Кат-хат уңае белән мисыр телендәге тагын бер сүзгә тукталып китәсе килә. Мисыр телендә яшьләрдән оешкан гаскәр «джам» дип аталган. Моның мәгънәсе «яшьләр» (молодежь) дигәнгә туры килә икән (КДЕ, 136 бит). Русча «джам» дип язылган сүзне без җәм дип беләбез. Димәк, мисыр телендә *җәм* «яшь» мәгънәсенә тәңгәл. Татар телендәге *җәм-йәшел* сүзендә *җәм (йәм)* көчәйткеч

сыман тоела. Баксаң, болар парлы сүзләр икән. *Җәм-ле, җәм-сез* дигәндә матур һәм матур булмау күз алдына килә. *Җәм (йәм)* исә күбесенчә яшьлеккә хас нәрсә.

Телдә *җәм-йәм* катнашында ясалган, ләкин еш кына татарча түгел сыман тоелган сүзләр бар. Мәсәлән, татарда «хатын» диясе урында кайчагында *җәмәгать* диләр. Элегрәк бу сүз бик актив кулланыла иде. Әлеге «гарәп» сүзен *җәмә* һәм *гать* дип икегә бүлеп карасак, бу «яшь хатын» булып чыгачак. *Җәмәгать* кенә түгел, бәлки *җәмгыять* тә бик борынгы мисыр-төрки сүзедер әле. Җәмгыятьне *җәм-гъи-әт* дип таркатсак, «яшь ир, хатын» дигән мәгънә барлыкка киләчәк. «Хатын» мәгънәсендә кат шәфкать сүзендә дә катнаша. *Җәм* иҗекләре белән ясалган берничә исем дә бар. Мәсәлән, *Җәмил, Җәмилә*. Мисыр телендә *л* тартыгы булмаган дип исәпләнелә (Ли, 49 бит). Шуңа күрә тарихи чорда Мисырда мондый исемнәр булмагандыр кебек. Әмма *Җәмил*нең *(Җ)әмир* формасы мисыр телендә булган. Мисырча *әмир* — «правитель», «начальник» (КДЕ, 134 бит). Гарәпчә әмир — «боеручы, өлкә (дәүләт) башлыгы», «хан», «шаһзадә» (Алы, 738 бит). Татарда әмир кулланылмый, ләкин Әмир исеме бар. Татарстанда Әмир елгасы агып ята. Шундый исемдәге елга һәм шәһәр борынгы Урта диңгез бассейнында да булган (С, 419, 605 битләр). Әмир сүзенең әүвәлге әйтелеше җәм *ир* булган дип исәплибез.

Борынгы мисыр телендә «бөек» мәгънәсе ур сүзе белән белдерелә. Мәсәлән, *әмир пер ур* (imj-r pr wr) сүзләренең мәгънәсе русча «управитель великого дома» дигәнгә туры килә (Бе, 161 бит). Тезмә ахырындагы *ур* «бөек» дигәнне белдерә. *Ур*ның тулы әйтелеше татарча *зур* сүзендә саклана.

Безгә яхшы таныш ун да сүз башындагы тартыкны төшереп калдыру юлы белән ясалган. Унның тулы варианты мисыр чоры төрки телдә *Нун* булган дип исәплибез. Шулаен шулай да, татарча «ун» санының Нунга һәм Нуннан кыскарган Унга берәр төрле катнашы бар микән соң? Бар икән шул. Атумнан туган Шу, Тефнут, Геб, Нут, Осирис, Исида, Сет, Нефтидаларны, гадәттә, «изге эннеада» (изге тугыз алла — «девятка богов») дип атап йөртәләр. Бу тугыз саны эченә Атумны яисә Ра-Атумны да кертәләр. Ләкин бит Атум үзе Нуннан яралган! Димәк, изге аллалар тугыз түгел, ун булырга тиеш иде. Мемфис янындагы *Уну* дип аталган шәһәр борынгы мисырлыларның дини үзәкләре булган. Бу шәһәрнең исеме Библиядә *Он* рәвешендә язылган. Уну (Он) шәһәрендә тугыз аллага табынганнар. Унынчы алла исеме шәһәр атамасында булган.

Нунның кыскарак формасы *ун*нан татарча *уң* сүзе дә ясалган, ахрысы. Белүебезчә, уң як ирләр ягы, сул як хатын-кыз ягы исәпләнелгән. Нун исә мисыр мифологиясендә су стихиясен чагылдыра. Су — ирләр затыннан. Ун иҗекләре «ун» санын гына түгел, «ир» дигәнне дә белдерә. *Хат-ун* сүзендә унның «ир» булуы ачык чагыла. Шунлыктан *ун* белән *уң*ны тиңдәш сүзләр дип әйтергә була.

*Н* тартыгына башланган тагын бер атаклы сүз бар. Ул да булса Нил атамасы. Нун, Нут атамаларының борынгы мисыр сүзләре булуы мәсьәләсендә бернинди шик юк. Әмма Нил сүзе мисыр телендә булмаган, Нил атамасы грекча Нейлостан яисә латинча Нилустан алынган булырга мөмкин дигән фикерләр бар. Мисырлылар Нил елгасын Хапи дип атаганнар. Хапи елганы гына түгел, елга алласын да белдергән. Нилның шулай ук мисыр телендә Итеру дигән атамасы да булган. Бу исә «елга» дигән мәгънәгә туры килә икән (За, 121 бит).

Кем сүзе булуына карамастан, Нил сүзе булган, бар һәм әле дә исән. Нил Мисырда гына түгел, башка телләрдә дә кулланыла. Бүгенге көндә татарда, руста һ.б. халыкларда Нил дигән ир кеше исемнәре очрый. Төрки карай телендә *нил* «елга» дигәнне белдерә. Иҗек методы нигезендә фикер йөрткәндә, грекча Нейлос Нил елгасының борынгы Мисыр мифологиясендә тоткан урынын чагылдыра алмый, киресенчә, бөек елганың исемен бозып күрсәтә. Нил Нейлостан үзгәрмәгән, киресенчә, Нейлос Нилдан үзгәргән. Латин телендә Нил атамасының әүвәлге формасы тулырак чагыла.

Борынгы мифларда әйтелгәнчә, Нил елгасы Нун суыннан агып чыга. Үзеннән-үзе аңлашылганча, Нил ул Нун улы, шунлыктан аның исемендә Нунга хас сыйфатлар чагылырга тиеш. Беренчедән, ул *Н* тартыгына башланырга, икенчедән *у* сузыгына тәңгәл сузыклы булырга тиеш. *Ни* иҗеге *Ну*га тигез. Бик борынгы Мисыр динчеләре карашынча, *н* тартыгы *р* дән дә, *л* дән дә изгерәк саналган, ахрысы. Мәсәлән, иң әүвәлге су стихиясе Нун исемендә ике *н* бар. Нил исемендә бер генә!

Нил азагындагы *л* тартыгы да безгә күп нәрсә турында сөйли ала. Мисырда тарихи чорларга кадәр Ла да, Ра да булган, күрәсең. Ләкин Ла телле диалект яисә Лага табынучылар ниндидер тартыш, сугышлар нәтиҗәсендә җиңелергә мәҗбүр булганнар. Шулай итеп, Мисырда *р* диалекты җиңеп чыккан. Шунлыктан, күрәсең, Мисыр язуларында *л* тартыгы булган сүзләр сакланмаган. Нил атамасының тарихи чор мисыр телендә булмавы моңа

бер дәлил булып тора. Шул ук вакытта *л* тартыгы катнашмаган Нун, Нут һ.б. исемнәр Мисыр язмаларында тулысынча сакланып калган. Шул рәвешчә «Нил»ны Мисырдан «куалап» чыгарганнар. Нил атамасы Мисырдан читтәге илләрдә, халыкларда гына исән калган.

Тарихи чорда Мисыр территориясендә Нун, Нут, Геб кебек алла һәм алиһәләргә багышланган гыйбадәтханәләрнең салынмавы, ул вакытта барлык мисырлыларның тугыз, дөресрәге, ун аллага табынулары да игътибарга лаек. Нун, Нут, Нил, Геб (Җеб) кебек алла исемнәре Мисырда *ла* диалектлы төркиләр хакимлеге чорында иҗат ителгән булса да, соңыннан *ра* диалектлы мисырлылар хакимлеге вакытында да аларны юкка чыгармаганнар яисә юкка чыгара алмаганнар, киресенчә, аларны хөрмәт итәргә мәҗбүр булганнар.

*Нун*нан, *ун*, Нуттан *ут*, *хат*тан *ат*, *җәм*нән *әм* сүзләре ясала алган кебек, *Нил* сүзеннән *ил* ясала ала түгелме соң? Хәзер безне менә шушы мәсьәлә кызыксындыра.

*Ил*. Безнең өчен бик тә кадерле һәм якын сүз. Әлегә беркемнең дә илне гарәп-фарсыдан алынган дип аңлатырга батырчылык иткәне юк, ахрысы. Аны шулай ук Библиядән, Кытайдан, һиндстаннан, монгол теленнән алынган дип тә аңлатмыйлар бугай. Никадәр гаҗәп булмасын, безнең *иле*без — төрки сүз, татар сүзе, имеш.

Татар телендә *ил*нең төрле мәгънәләре билгеле. Без инде аларның күбесе белән таныш. Аны без болай да беләбез: ил ул — дәүләт, җир, территория, ватан, халык, җәмгыять, корт оясы, корт күче һ.б. Сөйләм телендә ил катнашында ясалган катлаулы сүзләрнең, сүз тезмәләренең, әйтем-мәкальләрнең, табышмакларның исәбе-хисабы юк. «Ил төкерсә, күл булыр, төкермәсә — чүл булыр» дигән мәкальдә «ил»нең елга булуы, алай гына да түгел, эссе, корылыклы яктагы Нил елгасы булуы чагыла. Борынгы һәм хәзерге Мисырда тормышның ил (Нил) «төкерүенә» бәйле булуы һәркемгә аңлашыла. Нил «төкерсә» коры җирләрдә күлләр хасил була, төкермәсә, чүл була. «Ил агымы белән су агымы бер» дигән әйтемдә дә ил турыдан-туры су, елга белән тиңләштерелә.

Татар әйтем-мәкальләрендә аеруча сугарулы елга буйларына гына хас күл, камыш, көймә, балык, балыкчылык еш телгә алына. Мәсәлән, «Илле — иле белән, җикән — күле белән». «Камышны үз күлеңнән ал», «Болганчык суда балык тотарга яхшы», «Җилкәне юк тал каек җилгә каршы баралмас» һ.б. Әйтик, нәрсә ул «тал каек»? Безнең якларда мондый нәрсәнең булуы шикле. «Тал каек»лар төзелеш материалы буларак агач бик кадерле

якларда гына кулланылган. Борынгы Мисырда камыш көлтәләрдән җыйналган көймәләр булуы мәгълүм. Библиядә әйтелгәнчә, борынгы заманнарда яһүд халкы Мисырга күчерелә. Яһүдләр күбәя башлагач, Мисыр патшасы яһүд балаларын Нил елгасына ташларга боера. Яһүдләр Моисейны (Мусаны) кәрзингә салып агызалар һәм шул рәвешчә Моисей исән кала (Ев, 54 бит). Димәк, Мисырда чыннан да суга батмый торган камыш көймәләр дә, камыш кәрзиннәр дә булган. Татар мәкалендә камыш «тал»га әйләнгән. Бәлки әйләнмәгәндер дә. Нил камышы папирусның төрки атамасын без белмибез. Бәлки ул «тал» булгандыр яисә тал катнашында ясалган икенче бер сүз булгандыр.

Бездә шулай ук «һөнәрле үргә йөзәр», «һөнәрле ком өстеннән көймә йөргезә», «акыллы карачы кара җирдән каек йөртер» кебек әйтем-мәкальләр дә бар. Тарихтан билгеле булганча, борынгы мисырлылар, үргә таба йөзгәндә, бусагалар турысына җиткәч, көймәләрен арканнар белән ярдан тартып барганнар. Бу хакта Геродот та язып калдырган. Безнең якларда Иделдә пароходлар йөри башлаганчы зур көймәләрне, каекларны үргә таба бурлаклар тартып барганнар. Бурлакчылык Идел буе болгарларында да булган.

Җир йөзендә культуралаштырылган игенчелек иң әүвәл Нил, Тигр, Евфрат (Ифрат) елгалары буендагы үзән җирләрдә барлыкка килгән. Баштарак орлыкны табигый рәвештә сугарылган дымлы җиргә чәчкәннәр дә чәчелгән җиргә көтү куалап керткәннәр. Терлекләр чәчелгән орлыкны таптап, җиргә күмдергәннәр. Мисырда борынгырак чорларда моның өчен сарык көтүеннән файдаланганнар, Геродот заманында исә сарык көтүе урынына дуңгыз көтүе кертү киң таралган булган. Тора-бара кеше җирне төрлечә эшкәртеп, иганнең, җимеш, яшелчәләрнең уңышын арттыруга ирешкән. Шул нигездә борынгы игенченең көче, байлыгы арткан. Шул нигездә сугарулы җирләрдә беренче культура үзәкләре, үзәкләштерелгән дәүләтләр, таш-кирпеч корылмалар барлыкка килгән.

Елга үзәннәрендә үз кул көче белән иген игеп, мал асрап көн күргән кешегә читтәге — чүлдәге, таулардагы кешеләр һәрвакыт дошман булып тоелган. Яу һәрвакыт шуннан — чүлләр, таулар ягыннан килгән. Яуда әсир төшкән кешеләрне дә шунда алып киткәннәр. Шумер телендә *кур* сүзе иң әүвәл «тау» дигәнне, соңыннан «чит ил» дигәнне белдергән ди шумер теле белгече С.Н.Крамер (Кра, 180 бит). Шумер телендәге *кур*ның мондый мәгънәсе татар телендәге *кур*кыныч сүзендә чагыла.

Бүгенге татар телендәге *кыр* сүзе әлеге *кур* сүзеннән үзгәргән булса кирәк. Татарда эшкәртелгән һәм иген игү өчен яраклы җир басу дип атала. Кайчагында «кыр» да басу була ала. Шулай да бу аның төп мәгънәсе түгел. Кыр ул читтәге, кырыйдагы җир һәм аның игенчелеккә бернинди катнашы юк. *Кыр* иҗекләре катнашында ясалган *кыргый* — әдәпсез, культурасыз, тотнаксыз, тыелгысыз дигәнне белдерә. *Кыз-кыркын*ның *кыркын* өлеше чыгытай телендә «черная невольница» дигәнне, *кырнак* шулай ук чыгытай телендә төрекмәннәрдәге һәм кыргызлардагы (казакълардагы?) кол хатын-кызны белдергән (Рад, II, 864).

Ил сүзе суны, елганы аңлатса да, ул шулай ук *басу*га да тиң. Ләкин *ил* ул *басу* гына түгел. *Ил*нең мәгънәсе киңрәк, тирәнрәк. *Ил* — ташудан соң утырып калган *басу*лы җир-территория, өлкә һәм, ниһаять, бөтен бер дәүләт. Басулы илдә яшәүчеләр дә, аларның эшләре, һөнәрләре дә, гореф-гадәтләре дә «ил» булып аңлашыла. Борынгы җәмгыятьтә байлык, муллык, көч-куәт — барлык яхшы, изге сыйфатлар бары илдә генә, ил эчендә генә һәм ил белән бергә генә була ала дигән караш яшәгән. Шуңа күрә ил барлык дошман нәрсәгә — кырга һәм яуга каршы куела. Ике гаскәр очрашкач элек «илме, яумы?» дип сораганнар. «Илдә — илле, кырда — кырык» дигән әйтемнән күренгәнчә, *ил* сүзе 50 санын ясауда катнаша. 40 саны исә «кыр» катнашында ясалган. *Кырыкмаса-кырык* — бик күп, исәпсез-хисапсыз булса да, илледән азрак, дөресрәге, илледән көчсезрәк дип уйланыла.

Татар телендә *ил* сүзенең «кояш» мәгънәсе дә бар. Аның бу мәгънәсе «илем-көнем» дигән әйтемдә чагыла.

Нил елгасын Плутарх Осирисның аталык орлыгы дип атый. Мондый мәгънә грекча-русча *илъ* сүзендә дә күренә. *Илъ* — лай, ләм дигәнне белдерә. Борынгы Мисырда Нил *ләме* басуларны гына ашлап калмаган, ул, гомумән, изге саналган һәм һәртөрле кору, төзү эшләрендә кулланылган. Нил ләменнән, мәсәлән, һәр елны ташудан соң Осирисның яна сынын ясаганнар һәм шул сынны киләсе елдагы яңа ташуга кадәр саклап торганнар. Русча *илъ* да, татарча *лай* һәм *ләм* дә «кояш улы» дигәнгә туры килә. «Әлеге сүзләрдә борынгыларның Нил елгасын турыдан-туры кояшка, Нил ләмен исә Атабыз Кояшның аталык орлыгына тиңләштерүләре чагыла.

*Ил* сүзенең «лай», «ләм» мәгънәләре татар телендә дә булган, ахрысы. Радлов сүзлегендә *калын ил* дигән мисал китерелә (Рад, I, 1472). Мәгънәсе: густо населенное, большое село. Безнең аңлавыбызча, калын сыйфаты

күплекне белдерә алмый. *Калын ил*, күрәсең, ләмнең калынлыгын гына белдергәндер дип әйтәсе килә.

Татарда «тарлау җирне саз йотмый» дигән мәкаль бар. Тарлау җир — сөрелгән, чәчелгән иген басуы дигән сүз. «Саз» һәм «тарлау җир» кайда гына була ала соң? Безнең якларда мондый янәшәлекнең булуы шикле. Сазның һәм иген басуының янәшәлеге бары тик сугарулы җирләрдә генә булырга мөмкин. «Көз чәчсәң — көлгә чәч, яз чәчсәң — сазга чәч», «Арыш чәчсәң,— көлгә чәч, солы чәчсәң — сазга чәч» дип киңәш итә халык мәкальләре. «Көл» монда, безнеңчә, көлгә-тузанга әйләнгән коры туфракны, «саз» исә язгы ташудан соң кибеп җитмәгән чәчүлекне күз алдында тота. Безнең бүгенге шартларда саз — бернигә яраксыз сусыл җир. Сазда түмгәк була да, кыяклы үләннәр, вак-төяк куаклар була. Сазга кеше дә керми, мал-туар да керми. Кыскасы, сазга хәзер рәтләп игътибар итүче дә юк. Хәер, мелиораторлардан башка дип өстәргә кирәк. Ләкин татар әйтем-мәкальләрендә, югарыда күренгәнчә, сазга кирәгеннән артык игътибар бирелә.

«Башын ал да, саламына ут төрт» дип киңәш итә икенче бер мәкаль. Безнең салкын якларда саламны хуҗалыкта төрле кирәк-яракка тоталар. Салам ул утын да, төзелеш материалы да, мал өчен азык та. Баш пешәрлек эссе якларда саламның, күрәсең, әллә ни кадере булмаган. Борынгы Мисырда, нәкъ мәкальдә әйтелгәнчә, ашлыкның башагын гына урып алганнар. Борынгы Мисыр рәсемнәрендә уракчыларның артык иелмичә-бөгелмичә генә, игеннең баш өлешен генә кыркып барулары сурәтләнгән.

Без җырларда мактый торган Идел елгасының исеме Урта гасыр төрки чыганакларда *Итил* дип атала. *Итил*не *Ит* һәм *ил* кисәкләренә таркатсак, һәр ике сүздә борынгы Мисырның бөек елгасы исеме яшеренеп ятканлыгын күрербез. Борынгы Мисыр телендә Нил елгасының Итеру дигән атамасы да булган дидек без. *Итил* сүзендә әлеге исемнең төп иҗекләре генә алынган. Борынгы мисыр телендә «алла» *нтр* тартыклары белән белдерелгән. Фест дисбесендә бу тартыклар НИТӘРЕ рәвешендә укыла. Бүгенге галимнәр тәкъдим иткән *итеру* сүзенең тулырак һәм дөресрәк формасы *нитәре* булган булырга тиеш дип исәплибез. Шулай итеп, *Итил* сүзенең беренче иҗекләре *(Ит)* янә дә Нун нәселеннән булган *нитә*дән ясалган булып чыга. Ахыргы *ил* иҗекләре бу очракта «елга» мәгънәсендәге өстәмә информация бирә. Ләкин анысы да, белүебезчә, Нун токымыннан. Менә шундый серле һәм изге икән безнең бөек Идел — Итил елгабызның исеме!

Шушы уңайдан *н* тартыгына башланган Нократ елгасы исеменә дә тукталып китәсе килә. Нократны бездә гарәпчә «көмеш» сүзе белән аңлаталар. Нократ суы, имеш, көмештәй чиста булган да, гарәпләр монда килеп, безнең елгаларга исем биргәннәр. Нократка гына түгел, гарәпләр берьюлы шунда Минзәләгә дә исем кушып киткәннәр бугай әле. Гарәпчә «көмеш» нократ дип аталырга бик мөмкин. Тик шулай да гарәпчә «көмеш»нең Нократ елгасы атамасына бернинди катнашы юк. Бу сүзне без *нук* һәм *рат* иҗекләренә таркатабыз. *Нук* ул әлеге дә баягы Нун токымындагы сүз. *Ра-т* исә янә дә «кояш улы» дигәнгә туры килә. Ләкин монда ул Итил сүзендәге ил кебек, «елга» дигән өстәмә мәгънә белдерә. Татарча сугыш коралы *ук* та әлеге *Нук*тан ясалган булса кирәк. Алай гына да түгел, төрки халыкларның мифик ата-бабасы Яфәснең атасы Нух пәйгамбәр исеме дә әлеге Нократ һәм ук сүзләре белән бертуган. Җыеп әйткәндә. *Нут* һәм *ут* та, *Нок* та, Нук та, *ук* та, *Ните* һәм *Ите* дә, *Нил* дә һәм *ил* дә — барысы да аллалар һәм аллаларга тиң патшалар ватаны Мисырда иҗат ителгән Нун һәм Ун балалары.

*Ил* сүзе Итил — Идел атамаларыннан тыш тагын төрле төбәкләрдәге күп кенә елга исемнәре ясауда катнаша. Мәсәлән, Казагъстанда Или, Иләк елгалары бар, Кубаньның бер кушылдыгы Ил дип атала. Франциядә Ил дигән елга берәү генә түгел, икәү. Урта гасырларда шул ук Франциядә Иль-де-Франс дигән өлкә (провинция) булган. Моны «Франс иле» дип аңлыйбыз. Шумерларда Ил дигән кеше исемнәре булган. Грек дастаннарында Ил Троя патшасы Дардан оныгы. Грек мифларында Итил дигән исем дә очрый. Итил — ир бала исеме. Аны, имеш, ялгышып караңгыда үз анасы кадап үтерә. Латин телендәге ile (иле) «җенес әгъзасы» мәгънәсендә дә кулланылган. Рем белән Ромулның анасы Рея Сильвиянең икенче исеме — Илия. Борынгы гарәп телендә Илан «күк хакиме», «алла» дигәнне белдергән. Иланның Илахан формасы да булган. Күрәсез, безне культура терминнары белән тәэмин итеп торучы гарәпләрнең Иле дә, ханы да чынлыкта төрки сүзләр булган. Семитларның угарит телендә Ил — «алла», самари телендә — «көч-куәт», Көньяк Гарәбстан язма телендә — «алла» мәгънәсендә кулланылган. Борынгы яһүд, финикия телләрендә алла Эл дип аталган.

Татарча *Алла* сүзе, имеш, гарәпчә *Илаһ*тан, *Илаһ* исә борынгы семитларның Элоах, Элохим дигән аллалары исеменнән үзгәргән дип аңлатырга яраталар бүгенге этимологлар. *Алла* белән *Илаһ*ның нигезе «кояш» мәгънә-

сенә кайтып калса да, чынлыкта алар икесе ике сүз. Кем кемнән алган булуын без инде тикшереп тормаска булдык.

*Ил*нең башкачарак мәгънәләре дә мәгълүм. Себердәге аз санлы кет телендә *ил* — «кояш» дигәнне, малаялам телендә — «өй», «урын», тамилча — «өй», «хатын» дигәнне белдерә. Зулу телендә «кояш» *илаңа* дип, татар теленең Тобол сөйләшендә «юлбарыс» *илбис* дип, парья (Гиссар) телендә чеби баса торган ерткыч кош — *или* дип, матната телендә «диңгез» — *илил* дип атала.

Борынгы телләрдә ил катнашында ясалган исем-атамаларны санап бетерерлек түгел. Атаклы Вавилонның әүвәлгерәк атамасы Бабил. Урарту язмаларында Кече Азиянең кайдадыр көньягында булырга тиеш дип уйланылган Бабилу иле телгә алына. Христианнарның Илья, мөселманнарның Ильяс, шулай ук Газраил, Җәбраил, Микаил яисә Самуил, Гавриил кебек атаклы исемнәр *ил* иҗекләренә тәмамлана. Татарның «гарәптән алынган» Фәнил, Наил, Җәмил кебек исемнәрендә дә *ил* иҗекләрен бик җиңел табарга була. Соңгы елларда *ил* иҗекләре катнашында ясалган яңа бер исем еш телгә алына башлады. Ул да булса, *Ркаил*. Мондый исемне минем әле беркайчан ишеткәнем юк иде. «Нинди исем бу? Каян алынган?» дип сорагач, яшь шагыйрь Ркаил Зәйдуллин «Коръәннән» дип җавап бирде. Коръәндә андый сүз бар микән — әйтә алмыйм. Әмма әлеге сүзне *Река* һәм *ил* сүзләренә таркатсак, русча һәм татарча «елга» барлыкка киләчәгенә иманым камил.

### 9. МИСЫР ТЕЛЕ. КЕШЕ ИСЕМНӘРЕ

Югарыда без кайбер кеше исемнәре белән танышып киттек инде. Мәсәлән, XVIII династия вакытында *Хатшепсут* дигән хатын патша хакимлек иткән. «Түгәрәк йөзле, озынчарак күзле һәм кылыч борынлы» бу әбипатша исеменең мәгънәсе русча «мощная жизненными силами» дигәнгә туры килә икән (П, 426 бит). Әлеге исемнән без *шеп* һәм *сут* сүзләрен аерып алдык һәм аларның төрки мәгънәләрен ачыкладык. Безгә таныш *шәп* һәм *сут* сүзләре башка төрле исемнәр ясауда да катнашалар. «Синухет маҗаралары» дигән истәлектә (б.э.к. XIX г.) Сенусерт Беренченең пирамидасы *Хнумсут* дип аталган (Хр. ДВ, 44 бит; 51 бит, иск. 1). *Хнум* да, *сут* та — төрки сүзләр. IV династия вакытында бер патша туганының исеме Птахшепсес дип аталган (П, 359 бит). Шул ук борынгы патшалык чорында икенче бер

дәрәҗәле кешенең исеме *Рашепсес* булган (П, 349 бит). V династия вакытында бер патша *Шепсескара* (П, 372 бит), V династиянең соңгы патшасы *Шепсескаф* исемле булган (Хр. ДВ, 20 бит; 25 бит, иск. 56). Без әлеге исемнәрнең *шеп* һәм *сес* иҗекләренә генә игътибар итмәкче булабыз. «Шеп»не бүгенгечә *шәп* дип, «сес»не шулай ук бүгенгечә — *сүз* дип аңлыйбыз.

Патша исемнәре ясауда еш кына алла исемнәре дә катнаша. Шундыйлардан әле генә Ра, Птах, Хнум исемнәрен очраттык. Арада Амон, Амен, Нут, Мут исемнәре дә бар. XVIII династия вакытында берничә Аменхотеп патша булган. Аменхотеп сүзен русча «Амон доволен» дип тәрҗемә итәләр (П, 502, 503 битләр). Амен — Амонны без Аман дип беләбез, *Хотеп*ны исә *Котып* рәвешендә төзәтәбез. Татар телендәге *котып* — «гарәп» сүзе. Аның мәгънәсе — полюс (көньяк котып, төньяк котып). Котыпның бүгенге телдә «доволен» мәгънәсе юк. Ләкин әлеге *котып* төрки *кот*тан ясалган — менә нәрсәдә хикмәт. Мисырча Хотепны, бәлки, «котлы» дип аңларга кирәктер? Котлы булу, ягъни бәхетле булу «доволен булу»га каршы килми ләбаса. Шуны да әйтик, XIV гасырда Алтын Урда чорында Котб дигән татар шагыйре дә булган.

Мисыр телендә I династия вакытында «хам» сүзе динче, Яңа патшалык чорында кол, хезмәтче мәгънәсендә кулланылган (П, 321 бит). Мисырча *хам*ның төркичәсе — *кам* (Мисырча хам татар телендә Хаммат исемендә сакланып калган). Борынгы төркиләрдә кам дин башлыгын белдергән (ДТС, 413 бит). Мисырда Хам-Ахти дигән дәрәҗәле исем дә булган. Моның мәгънәсе русча «слуга Небосклонного, т. е. Солнца» (П, 351 бит). Әлеге исемдәге хамны кам дип аңласак та, ике сүзнең үзара ярашуы төрки тәртиптә түгел. Төркичә бу Ахти-хам булырга тиеш иде. Ләкин Ахти үзе төркиме соң? Русча небосклон шул ук горизонт яисә офык дигән сүз. Мисырча *ахт* татарча *акты (к)* була. Актыкның *ахыр* варианты да бар. Күк чите, күк ахыры (актыгы) офык яисә горизонт булмыйча, тагын ни булыр икән? Ләкин ахыр заман дисәк, бу дөнья бетү, тормыш, яшәеш чиге булачак. Ахирәт исә турыдан-туры «теге дөнья» дигәнгә туры килә.

IV династиянең бер патшасы Менкаура исемле булган (Хр. ДВ, 20 бит). Без бу исемдәге *мен* иҗекләренә игътибар итмәкче булабыз. *Мен* иҗекләренә башланган тагын берничә исем бар. Мәсәлән, Рамсес Беренче Менпхтир дип тә аталган (Хр. ДВ, 127 бит). Фива патшаларының беренчесе Ментухотеп исемле булган. Тутмос III нең

икенче исеме Менхеперра дип аталган (Хр. ДВ, 117 бит). Яңа чор патшалыкта бер патшаның исеме Менхеперресенеба дигән иҗекләрдән торган (КДЕ, 107 бит). Әгәр шушы исемнәрдәге *мен* иҗекләрен беренче зат алмашлыгы «мин» дип белсәк, борынгы исемнәрнең һәркайсының төрки мәгънәсен ачыклавы кыен булмаячак дип әйтә алабыз. Мәсәлән, *Менкаур* сүзен *Мин Ка улы* дип, *Менпхтир*ны *Мин пәхет (ле) ир, Ментухотеп*ны *мин ту (ганмын) котып (тан)* яисә *Мин — беренче Котып* дип аңлыйбыз.

Мисыр исемнәре арасында нәкъ бүгенгечә, татарча төзелештәге исем-атамалар да очрый. Урта чорда ниндидер *Хертихотеп* дигән кеше булган һәм аның таш сыны сакланып калган (КДЕ, 385 бит). Бу исемне *Хөрти котып* дип төзәтсәк, саф төрки сүз тезмәсе барлыкка киләчәк. Шул ук Урта чор патшалыкка карый торган «Ахтой киңәшләре» («Поучения Ахтоя») дигән истәлек бар (Хр. ДВ, 55 бит). Әлеге *Ахтой*ны без *Актай* дип беләбез. Борынгы чыганакларда Кефи дигән хатын-кыз исеме дә күзгә чалынып кала (Хр. ДВ, 131 бит). Татарча Кафия дигән исем бар. Элекке заманда Кафиянең Тәфия дигән варианты да булган. Мисырлылар арасында Нехи (ягъни Нәкъи.— Хр. ДВ, 131 бит), Хеви (ягъни Кави.— Хр. ДВ, 13 бит), Пахери (ягъни Фәхери.— П, 493 бит), Ченти (ягъни Чәнти.— КДЕ, 155 бит) дигән исемнәр дә булган.

Урта чорда Мисырда Камос дигән патша да булган (КДЕ, 276 бит). Камос рәвешендә тулыландырылган бу борынгы исемне Камаш дип тә, Камис дип тә аңларга була. Татарда бүген Хамис исеме дә бар. Борынгы патшалык чорында, IV династия вакытында Мисырда Мечен дигән кеше яшәгән. Бу кеше үз исемендә уникe авыл (шәһәр?) төзеткән. Мечен нәселе, күрәсең, безнең якларга да килеп чыккан. Татарстанда Мичән елгасы, Мичәнбаш авылы бар (Гар, 86 бит). Меченнең автобиографик язмасында әйтелгәнчә, Түбәнге Мисырда Мендос дигән өлкә булган (Хр. ДВ, 27 бит). Татарстанда Мөндеш авылы бар. Дөрес, Мендес сүзе грекча булса кирәк. Ләкин грекча исем астында Мисырдагы бик борынгы төрки исем саклана дип уйларга кирәк. «Пианхи ташы» дигән истәлектә Месед дигән авылмы, шәһәрме телгә алына (Хр. ДВ, 161 бит; 163 бит, искәрмә 38). Татарстанда Мәчет елгасы, Мәчет кулы суы, Мәчетле авыллары бар. Мисырдагы бер өлкә Метели дип аталган (Хр. ДВ, 27 бит). Башкортстанда Мәтәл, Мәтеле елгалары, Мәтеле авылы бар. Крит утравында шулай ук бер Матала бар. Борынгы Мисырда, Дельтада Сай дигән шәһәр һәм шул исемдәге өлкә булуы мәгълүм (Хр. ДВ, 27 бит). Бу исемнең грекча атамасы —

Саис. Татарстанда Сай, Сайа елгалары бар. Мисырда төрле чорда, төрле төбәктә Пернезер, Сау дигән гыйбадәтханәләр, Хесен дигән утар булган. Хесен (Хәсән) шулай ук кеше исеме дә булырга мөмкин (Хр. ДВ, 27 бит). Б.э.к. VIII гасырда Мисырның Оксирних өлкәсендәге бер шәһәр Чекнеш дип аталган. Татарстандагы Чикәнәс авылы, бәлки, шуның бер кыйпылчыгыдыр?

Б.э.к. VIII гасырны чагылдырган «Пианхи ташында» Кемур дигән топонимик исем телгә алына. Кемурга «Дельтаның көнчыгышындагы күл» дигән аңлатма бирелгән (Хр. ДВ, 163 бит, иск. 34). Текстта «владение Кемура» диелә (Хр. ДВ, 160 бит), шунлыктан Кемур өлкә яисә шәһәр дә булырга мөмкин. *Кемур* сүзе «великая чернота» дип тәрҗемә ителгән (Хр. ДВ, сүзлек, 514 бит). Болай булгач, *кем* — «чернота», *ур* — «великая» булып чыга. Кемнең *тем* варианты татар телендә чыннан да караңгылыкны белдерә ала. Мәсәлән, *төм-сә* дисәк, бу караңгы чырайлы була. *Төм*нең, дөм варианты *дөм-сукыр, дөм-караңгы* дигән сүзләр ясауда катнаша. *Төм*, күрәсең, *төн*нең *м* вариантыдыр дип әйтергә туры килә. Мисырча *кем*нең, *н* варианты кен, ягъни көн — яктылык була түгелме соң?! Грек мифларында да кояш алласы Аполлон белән Теннең бертуган булуы турында әйтелә. *Кем-тем* яисә *кен-тен,* шулай итеп, баштагы тартыклары төрлечәрәк яңгыраган бертуган сүзләр икән. Борынгы төрки телдә «уголь» (күмер) *көмүр* дип аталган (ДТС, 314 бит). Көмүр (күмер), әлбәттә, «великая черната» була ала. Күрәсез, без тагын бер мисыр сүзен — бүгенге татар телендәге борынгы мисыр сүзен казып чыгардык.

## 10. МИСЫР ТЕЛЕ. *ДЖОСЕР* ҺӘМ БАШКАЛАР

Дөньяда иң беренче пирамиданы Мисырның III династия патшасы Джосер салдыра. Моңарчы үлгән патшаларны, дәрәҗәле кешеләрне сандык сыман дүрт почмаклы тәбәнәк төрбәләрдә күмә торган булганнар. Мондый төрбәләрне гарәпчә «мастаба» дип атыйлар. Мастабалар яндырылмаган кирпечтән салынган һәм вакыт үтү белән алар ишелеп, җимерелеп беткәннәр. Джосер заманында атаклы төзүче, фикер иясе Имхотеп кирпеч урынына беренче мәртәбә таш куллана. Шулай итеп, Мисыр тарихында яңа чор — таш биналар, таш пирамидалар чоры башлана. Төзелеш эшендә яңалык башлап җибәрүче Имхотеп элекке традицияләрдән дә тулысынча баш тартмый. Джосер пирамидасын салганда ул, таш корылманың биеклеген арттыру өчен, зуррак мастаба өстенә

кечерәк мастаба утыртып куя. Шул рәвешчә, нигезенең дүрт ягы да тигез булган, югарыга таба баскычланып менгән һәм иң өстә очлаеп тәмамланган сокландыргыч яңача корылма барлыкка килә. Алты баскычлы Джосер пирамидасы бүгенге Каһирәдән көньякта урнашкан Саккара авылы янында әле дә калкып утыра. Пирамиданың элекке биеклеге 60 метр чамасы булган.

Башка пирамидалар да, нигездә, шундый ук принципта төзелгән, ләкин Джосер чорыннан соңгы пирамидаларның тышкы ягын тигез итеп шомартылган таш белән каплый торган булганнар. Шунлыктан Джосер пирамидасы гына баскычлы-баскычлы булып, бүтән пирамидаларның өслеге исә тигез булып күренә.

Б.э.к. XXVIII гасырда хакимлек иткән III династия тарихы Джосердан соң «безнең өчен куе караңгылык белән тәмамлана» дип язалар бүгенге тарихчылар. III династиядән соң, билгеле, IV династия чоры башлана. Бу чорда Мисырда иң биек пирамидалар төзелә. Снофру патша заманында биеклеге 100 һәм 99 метр булган ике пирамида төзелә. Снофруның улы Хуфу салдырган пирамида иң биеге булып чыга. Аның биеклеге 146,5 метр, нигезенең (һәр ягының) озынлыгы 230 метрдан артыграк. Бу пирамидалар әле дә кеше кулы белән төзелгән иң зур могҗизаларның берсе булып исәпләнеләләр.

Беренче пирамида салдырган *Джосер* исемен *Джесер* дип тә язалар. Без моны *Җәсир* дип төзәтәбез. Татарда әле дә *Йәсир* исеме бар. *Җәсир (Йәсир)* сүзен *Җәс ир* рәвешендә таркатсак, безнең өчен бик тә аңлаешлы *йәш ир* барлыкка киләчәк. Гарәпчә ясир кечкенә, аз, җиңел, ансат дигән мәгънәләрне белдерә икән (Алы, 72 бит). «Яшь» белән «кечкенә» арасында мәгънә аермасы бар, әлбәттә, тик шулай да якынлык та юк түгел.

Мисыр телендә «яшь» мәгънәсендә «джам» (*җәм*) сүзе кулланылган дидек без югарыда. *Җәм*нең «яшь»леге *җәмле, җәмсез, җәм-яшел* кебек сүзләрдә күренә. Гарәпчә боеручы, хаким, идарәче мәгънәсендәге «әмир»нең дә борынгырак формасы җәмир булгандыр дигән фикер әйтелде. Җәмирдән әмир ясалган булса, җәсирдән әсир ясала ала бит әле! Җәм дә җәс тә — яшь, көчле дигәнне белдерә. «Йәш»тән яшәү, яшен, яшел сүзләре ясалган. Мисырда яшел төс изге саналган. Ислам диненең яшел байрагының башлангычы чынлыкта борынгы Мисырга барып тоташа.

Хәзер инде без болай уйлап карыйк. Мифларда әйтелгәнчә, җәе (йәш) сыйфатлы ир үзенең туганы Сыт тарафыннан үтерелә һәм ахыр чиктә теге дөнья хакименә

әверелә. Бөек Җәсир Үлем әсиренә әйләнә. Шул ук вакытта (Җ) әмир «әмир» — боеручы, хаким, идарәче булып кала. Әйтәсе килгәнем шул — бүгенге телдәге «җәм»гә һәм «җәс»кә карата булган шушы мөнәсәбәттә борынгы заманнарда булган реаль фактлар чагылмый микән? Әйтик, «җәс» телле кабилә белән «җәм» телле кабилә арасындагы каты тартыштан соң «җәс»ләрнең җиңелүенә ишарә юк микән монда? Мондый фикерне расларга ярдәм итә торган шундый факт та күз алдында: (җ) әмир сүзе татарда бары исемнәрдә генә саклана, ул да әле гарәптән кергән дип исәпләнелә. Әсир исә шактый актив кулланыла. Аннан соң, җиңелгән бөек патшалар исемен изгеләштерү һәм аларны теге дөнья хакимнәре итеп карау, борынгы дөньяда, күрәсең, гадәти нәрсә булган. Бит борынгы грекларга да Минос патшалар, титаннар, Галияләр, Талияләр һ.б. — теге дөнья ияләре булып тоелган.

Снофру һәм Хуфу пирамидалары салынганнан соң 2300 еллар чамасы соңрак яшәгән Геродот Мисырга килә, Мисыр тарихы, Мисыр пирамидалары белән кызыксына. Мисыр динчеләре аңа күп кенә яңалыклар сөйлиләр. Геродот Хуфу пирамидасының ничек салынуын аңлата. Аныңча, Хуфу күмеләчәк кабер-сарай утрау сыман калкулык астында казыла. Җир астындагы кабер-сарай урнашкан калкулыкка яисә тауга арык ясап Нил суы китерелә (Г, II, 124). Шулай итеп, Хуфу мәете җир һәм су астында калган булып чыга. Бүгенге галимнәр Геродот сүзләренә бик үк ышанып та җитмиләр.

Геродоттан бер мең өч йөз, дүрт йөз еллар чамасы соңрак яшәгән һәм безнең Идел буйларына килеп чыккан Ибн Фадлан үлгән Хазар патшасын күмү турында шулай ук кеше ышанмастай сүзләр язып калдырган. Ул язганча, бөек хакан үлсә, аның өчен зур «двор» (гарәпчә «дар») төзиләр. «Двор» эчендә егерме «өй» була, һәр өй эчендә хакан өчен кабер казыла. «Двор» һәм кабер өстеннән елга суы җибәрелә (Ибн, 84 бит).

Борынгы Мисыр пирамидалары янында күптән инде су да акмый, Нил елгасыннан ерып китерелгән арыклар да калмаган. Ләкин җир асты сарайларындагы бүлмәләрнең исәбе-хисабы юк. Нәкъ Хазар патшасыныкы кебек дип әйтергә була. Яисә, киресенчә, Хазар патшасының кабере Мисыр патшаларыныкы кебек үк бик күп бүлмәләрдән («өй»ләрдән) торган. Мәсәлән, IV династия хакимлеге чорында яшәгән Мереук дигән аксөякнең күмү сараенда утыздан артык бүлмә («өй») булган.

Бөек пирамидалар төзү заманында Мисыр халкына бик кыенга туры килгән, әлбәттә. Халык көне-төне патша-

лар өчен бил бөгәргә, таш ташырга, таш кисәргә мәҗбүр ителгән. Бу вакытларда бөтен җирдә хәтта гыйбадәтханәләр дә ябылып беткән. Геродот язганча, гыйбадәтханәләрнең ябылуы Мисыр өчен иң зур бәла-каза булган. «Мисырлылар әлеге патшаларны шул дәрәҗәдә күралмыйлар, алар хәтта ул патшаларның исемнәрен дә теләр-теләмәс кенә телгә алалар» ди Геродот (Г, II, 128).

Грек тарихчысының менә бу сүзләре нигезендә кайбер исем-атамаларның сере ачыла төшә сыман. Мисыр халкының канына тоз салган патшаларның берсе, әлбәттә, Хуфу булган булырга тиеш. Геродот бу исемне Хеопс дип яза. Грекча Хеопс булган бу сүзне бүгенге галимнәр Хуфу дип аңлаталар. Ләкин *хф* тартыкларын *Хуфу* дип тә, *Хафа* дип тә тулыландырырга була. *Хуфу*ның бер улы — үзеннән соңгы патша Хафра дип атала. Хафра сүзендә Хуфуның чын исеме сакланып калмады микән? дип әйтәсе килә. Әгәр *Хуфу* халыкны бетмәс-төкәнмәс кайгыга салган икән, аның исеменең кире мәгънәдәге сүзгә әйләнүе табигый хәл. Мәсәлән, татар телендә *хафа* — борчу, кайгы дигәнне белдерә. Хафаның *җафа* варианты исә тагын да зуррак кайгыны, иза чигүне аңлата һәм хафага караганда да ныграк яратмау белән әйтелә. IV династия чорында Каапер дигән ниндидер патша улы булган (КДЕ, 377 бит). Татарча динсез, җүнсез мәгънәсендәге *кафер, җафер* сүзләре дә, бәлки, менә шушы Каапер һәм Хафраларга кайтып каладыр?

Мисырлылар исеме арасында Нофрет (Нефрет) дигән исем дә очрый. Без моны Нәфрәт дип төзәтәбез. Шул ук IV династия чорыннан Рахотеп дигән ир кеше белән Нофрет дигән хатын-кызның искиткеч реалистик сыннары сакланып калган (КДЕ, 377 бит; Каир, 17 таблица). Нофрет (Нефрет) исеме бары уңай сыйфатлы иҗекләрдән генә тора. Аерым *нәф* — яхшы, күркәм дигәнне белдерә. Бүгенге нәфис сүзе моңа мисал була ала. *Рәт* шулай ук изге сүз — кояш улы. Ләкин «нәфрәтенең бүгенге мәгънәсе — җирәнү, күралмау. Татарча да, гарәпчә дә шулай. Монда инде нинди дә булса аңлатма биреп торуның кирәге юк. Кайчандыр шундый изге, нәфис, гүзәл исемнең халык аңында җирәнгечкә әйләнүе, күрәсең, тикмәгә генә булмагандыр. Хертихотеп исемендәге хөрти дә элек, әлбәттә, бөеклекне, изгелекне аңлаткан дип уйларга кирәк.

IV династия чорындагы исемнәр турында сүз чыккач, шуны да әйтик, бу заманнарда мисырлыларда Хе-

* V династия вакытында бер ир кеше Каипер дип аталган (КДЕ, 305 бит). Татарда Хәйбер дигән исем бар.

сир, Каи* дигән исемнәр дә булган (П, 329 бит; КДЕ, 377 бит). Хәсир исеме бездә сакланмаган, ләкин Хасинә бар. Каиның Гай варианты этрускларда, латиннарда булган, татарда әле дә исән. Кайный, Хәй варианты да мәгълүм. *Хуфу* патшасының анасы Хетепхерес дип аталган. Бу сүзне Котып хирыс дип аңларга була, ягъни «котыб яратучы» дигән сүз. Бруклин музееның 351446 номерлы папирусында әйтелгәнчә, Рехи исемле азиат хатын-кызын мисыр телендә Капунеби дип атаганнар. Бу сүзнең мәгънәсе русча «Владыка мой — это пища» икән. «Владыка» дигәне небига (нәбигә) туры килә, капу исә «пища» булып чыга. Дөрес бит! димичә нәрсә дисең монда? Кабу, кабымлык... бары ашауга, ризыкка карата гына кулланыла. Таш багана (пилон) мисырча «бехен» дип аталган (КДЕ, 202 бит). *Бхн* тартыкларын бахана дип тулыландырсак, бу инде безнеңчә багана булып чыгачак. Борайның бер төре мисыр телендә «беша» дип аталган (КДЕ, 53 бит). Бешаны пеше, пешерү дип үзгәртсәк, монда шулай ук аңлашылмаган нәрсә юк сыман. «Арпа» мисырча ит дип аталган (КДЕ, 57 бит). Бүгенге татар телендә ит үсемлек азыгын түгел, бары терлек, хайван итен генә белдерә. Элегрәк, бәлки, үсемлек орлыгыннан пешерелгән азыкта ит була алгандыр. Мисырча каду (kdw) «строитель» дигәнгә туры килә. Бу сүзне казу дип, киңрәк мәгънәдә казучы дип төзәтергә була. Көмеш акча берәмлеге мисырча ките дип аталган. *Ките (ки-те)* ул «көмеш була ала, *ките-к* исә көмешнең бер кисәген аңлата. Б.э.к. XVI гасырга карый торган һәм «Төзүче Инени язмасы» дип аталган истәлектә *менит* сүзе очрый. Менитка русча «ожерелье с особого рода украшением на нем» дигән аңлатма бирелгән (Хр. ДВ, 89; 92 битләр, иск. 2). Менит, димәк, муенсаның бер төре була. Татар теле диалектларында төзәнү-бизәнү әйберсе (муенса) *манит* дип атала (ТТДС, 300 бит). Манитны русча монетадан алынган дип аңлаталар. Ләкин *монета* да, *манит* та мисырча *менитка* кайтып кала булса кирәк. «Күңелле бәйрәмнәрне мисырлылар сайра дип атыйлар» дип яза Плутарх (Плу, II, 29). Болынга, урманга чыгып күңел ачуны татар әле дә «сәйранга чыгу» ди. *Сәйран* гарәп сүзе икән. Ләкин сандугач сайрый дисәк, сайрый кем сүзе булыр иде икән? Яисә «сабанда сайрашмасаң, ындырда ыңгырашырсың» дигән халык мәкалендәге «сайрашу» нәрсәне аңлата? *Сайра, сайрау, сәйран* — бер үк нәрсәгә, ягъни күңел ачуга, күңел күтәрүгә кайтып калмыймыни?! Мисырча sb (саба) «йолдыз» дигәнне белдерә (КДЕ, 301 бит). Гарәпчә *саба* — көнчыгыштан искән йом-

шак җил дигәнгә туры килә (Алы, 492 бит). Татарда бу сүз «саба җиле» рәвешендә әйтелә. Элекке татар әдәбиятында «саба җиле» еш кабатлана. «Саба җиле» тезмәсендә мисырлык күбрәк сакланган. Мисырлылар өчен шифалы җил — *саба җиле* көнчыгыштан түгел, төньяктан искән. Төньяк исә, мисырлылар карашынча, «сүнми торган йолдызлар иле» булып исәпләнелгән. Сабаның мисырча «обучать» мәгънәсе дә булган (КДЕ, 301 бит). Монысы турыдан-туры *сабак*ка туры килә. Элегрәк балалар мәктәпкә укырга түгел — сабакка барганнар.

Мисырча «прикрывать зерно» дигән мәгънәдәге сүз «сека» дип аталган. Бу урында аңлатманы русча күчерү отышлырак. «Работа сохи обозначалось тем же термином, что и прохождение стада по полю — «прикрывать зерно» («сека») дип яза Т.Н.Савельева (КДЕ, 60 бит). Шулай итеп, җиргә чәчелгән орлыкны көтүдән таптату да, иген басуын сукалау да әлеге сүз белән аталган булып чыга. Сека рәвешендә тулыландырылган *ск* тартыкларын без *сука* дип беләбез. Татарча сука, сукалау да, русча соха да мисырча «сека»дан алынган булса кирәк.

### 11. МИСЫР-ТӨРКИ УРТАКЛЫКЛАР. ЭТНОГРАФИЯ

Төркиләр белән мисырлылар арасындагы уртаклык турында сөйли торган этнографик фактлар бик күп. Монда без шуларның кайберләренә генә тукталачакбыз.

Геродот язганча, мисырлыларда сөннәткә бирү йоласы була. Аның әйтүенчә, сөннәткә бирү йоласы шулай ук колхларда, эфиопларда, Финикиядә һәм Палестина сириләрендә дә була (Г, II, 36, 104). Сөннәткә бирү йоласы татарларда һәм башка төрки халыкларда әле дә кулланыла. Сөннәткә бирү йоласын бездә, гадәттәгечә, гарәпкә, ислам диненә кайтарып калдыралар. Бу йоланы, имеш, гарәпләр яһүдләрдән, яһүдләр мисырлылардан алганнар. Шуннан соң инде иң ахырда безгә дә килеп җиткән, имеш. Ләкин «бу йолага карата Коръәндә бернинди күрсәтмә юк; ул хәтта телгә дә алынмый» икән (Мав, 121 бит).

Шулай булгач, бу йоланы мисырлылар өчен дә, татарларның бик борынгы бабалары өчен дә уртак булган дип әйтергә туры килә.

Мисырлылар дуңгызны нәҗес дип исәпләгәннәр (Г, II, 47). Геродот заманында Мисырда дуңгыз асрау, дуңгыз ите ашау бөтенләй үк тыелмаган. Шулай да дуңгызга, дуңгыз итенә, дуңгыз көтүчеләренә карата кире мөнәсәбәт сакланган. Кем дә булса ялгыш кына дуңгызга кагылып китсә,

ул шундук елгага төшеп юынырга тиеш булган. Дуңгыз көтүчесен гыйбадәтханәгә кертмәгәннәр һ.б.

Татарлар һәм гомумән барлык төрки халыклар гомергомергә дуңгыз асрамаганнар, дуңгыз ите ашамаганнар. Дуңгызны Кара диңгез буе скифлары да, Алтай скифлары да, сөннәр дә, гуннар да асрамаган. Фәнни әдәбиятта моны бик җиңел аңлаталар: төркиләр күчмә булганнар, күчмә тормышта дуңгыз белән күченеп йөрү өстәмә кыенлыклар тудырган. Шуңа күрә, имеш, дуңгыз асрау да булмаган. Шул ук Геродот язганча, Мисыр динчеләре үгез ите һәм каз ите генә ашаганнар. Аларга балык ашау тыелган (Г, II, 37). Үгез турында безнең сүз күп булды инде. Үгез бик борыннан изге хайван саналган. Төньяк Кытай, Монголия территориясендә яшәгән борынгы сөннәрдә дә үгез ите изге саналган. Балык мәсьәләсенә килгәндә, төркиләрдә бөтенләй үк балык ашау булмаган дип әйтеп булмый. Тик шулай да балык ашау бездә киң таралмаган. Казны исә татарның иң яраткан йорт кошларыннан берсе дип әйтергә була. Каз ашлары, каз өмәләре, каз мамыгы һ.б. әле дә исән. Мисыр рәсемнәрендә дә көтү-көтү казлар сурәтләнә. Казны бигрәк тә Түбәнге Мисырда, сазлы, күлле җирләрдә асраганнар дип исәпләнелә. Күчмә тормыш шартларында күченеп йөрү өчен дуңгыз түгел, бәлки каз-тавык ише йорт кошлары ныграк кыенлык тудырырга тиеш иде сыман. Ләкин татар тормышында каз, тавык безнең көннәргә кадәр исәнимин килеп җиткән, дуңгызның исә, мәҗбүри асратуларына да карамастан, әле булса үз булып китә алганы юк.

Борынгы Кытай тарихчысы Сымацянь язганча б.э.к. III—II гасырларда сөннәрдә җиңелрәк җинаять өчен җинаятьчене таяк белән суктыру, авыр җинаять өчен үлем җәзасы кулланылган. Җинаятьчеләрне шулай ук төрмәгә япканнар, ләкин төрмәдә (зинданда) тоту ун көннән артыкка сузылмаган (Тас, I, 40 бит). Сөннәр күчмә тормыш белән яшәгәннәр. Аларда утрак тормышлы авыл, шәһәрләр булмаган. Ләкин сөннәрнең дәүләт төзелеше, суд-хөкем эшләре, гореф-гадәтләре утрак тормыш белән яшәүче, үзәкләштерелгән дәүләт системасы булган халыкның гореф-гадәтләренә охшаган. Мәсәлән, төрмә (зиндан) күчмә тормыш шартларында түгел, бәлки шәһәрләшкән, үзәкләшкән дәүләттә генә барлыкка килә ала. Таяк белән суктыру гадәте шулай ук күчмәләр иҗаты була алмый. Далада, күпчелек халкы атлы гаскәр тәшкил иткән җәмгыятьтә, җиңелчә җинаятьне җәзалауда таяк түгел, камчы, чыбыркы хәлиткеч роль уйнарга тиеш иде кебек. Бит камчы белән җәзалау күчмәләрдә борын-борыннан кулланылган!

Сөннәрдәге таяк белән суктыру гадәте ул бик борынгы традициянең дәвамы булып торган. Борынгы Мисырда хезмәт халкын таяк белән кыйнап, куркытып эшләтү, таяк белән суктырып җәзалау киң кулланылган.

Бөтен Сөн дәүләте 24 өлкәгә, 24 өлкә исә ике өлешкә — уңга һәм сулга бүленгән. 24 берәмлеккә бүленү төрекмәннәрдә дә булган. Төрекмәннәрнең килеп чыгышы турында сөйләгән риваятьләрдә Огуз ханның 24 улы булуы турында әйтелә (Ко, 50 бит). Мисырның Нил елгасы белән урталай бүленгән җирләре табигый рәвештә Көнчыгыш һәм Көнбатыш өлкәләр тәшкил иткән. Мисырны Ике җир иле дип тә йөрткәннәр. Монда шулай ук Төньякка һәм Көньякка бүленеш тә булган. Ел тәүлеген 12 гә бүлеп карау иң элек Мисырда барлыкка килгән. Ел тәүлеге 30 ар көнлек айларга бүленгән. Артып калган биш көн исә ел тәүлегендәге өстәмә көннәр булып исәпләнелгән. Геродот заманында Түбәнге Мисырда гаскәрләр ике төргә бүленгән. Аларның берсе каласирилар, икенчесе гермотибилар дип аталган. Каласирилар барлыгы 250 000 кеше булганнар һәм алар Дельтаның көнчыгышында 12 өлкәдә яшәгәннәр. Гермотибилар Көнбатышта 6 өлкәдә яшәгәннәр. Күрәсез, Дельтаның Геродот заманындагы бүленеше тулысынча диярлек Сөн дәүләтендәге бүленешкә туры килә.

Сөннәрдә елына өч мәртәбә — беренче, бишенче, тугызынчы айларда бөтен ил халкы бәйрәм иткән. Бәйрәм көннәрендә җиргә, суга, күккә, ата-аналарга багышлап корбан бирелгән, күңел ачканнар. Ни өчен өч мәртәбә дә, ни өчен беренче, бишенче, тугызынчы айларда? Моның тамыры янә Мисырдан башлана. Ел тәүлеген унике айга бүлеп карау гына түгел, өч сезонга бүлү дә иң элек Мисырда барлыкка килгән. Әйтелгәнчә, Мисыр кешесенең бөтен тормышы Нилга бәйле. Нилда су арта башлау Мисырда ел авышуны белдергән. Ташу дүрт айга сузыла. Ташудан соң чәчү, чәчүдән соң игеннәрнең, җиләк-җимешнең өлгерү чоры һәм, ниһаять, уру һәм җыю чоры башлана. Шул нигездә ел тәүлеге Ташу, Чәчү, Уру сезоннарына бүленгән, һәр сезон дүрт айга сузылган*. һәр сезон башында халык бәйрәмнәре, корбан бирүләр, күңел ачулар булган. Кырыс, салкын дала шартларында да сөннәр менә шул традицияне дәвам иттергәннәр. Сөннәрдә иң зур бәй-

---

* Элек татарда ел тәүлеге дүртәр айлык өч сезонга түгел, өчәр айлык дүрт сезонга бүленгән. Ел тәүлеген сезоннарга бүлү, шулай итеп, халыкның яңа Ватанындагы табигый шартларга яраклаштырылган.

рәм — җыен бишенче айга туры килгән. Бишенче ай Монголия шартларында җәй башына, Монголиядәге җәй башы исә Мисырдагы ташу кузгалган чорга туры килгән. X гасырда хазарларда да ел тәүлеген өчкә бүлеп карау булган, ахрысы. Ибн Фадлан язганча, Хазар патшасы дүрт ай саен бер мәртәбә халыкка күренгән. Ибн Фадлан Хазар патшасының халыкка нинди айларда һәм нәрсә уңае белән күренүе турында әйтми. Ләкин патшаның халыкка күренүе бәйрәм төсен алган булырга тиеш сыман.

X гасырда хазарларда ил белән бөек хаканның урынбасары хакан-бех идарә иткән. Ләкин ул традиция нигезендә бөек хаканга буйсынган. Ибн Фадлан бөек хакан белән хакан-бехның үзара мөнәсәбәтләре турында шундый нәрсә сөйли. Хакан-бех һәр көн иртән, бик нык түбәнчелек күрсәтеп, кулына утын күтәреп, яланаяк килеш бөек хакан янына керә. Хаканны котлагач, ул утынга ут төртеп җибәрә һәм шуннан соң бөек хакан янына килеп утыра. Шуңа охшаш йолалар сөннәрдә дә була. 110 елда Көньяк сөннәр патшасы Тань, төрле сугышлардан соң бик кыен хәлдә калгач, Кытай императорына буйсыну белдермәкче була. Моның өчен ул «яланбаш һәм яланаяк килеш» императорның кораллы җан сакчылары башлыгы Пансюн алдында бил бөгә. Ибн Фадлан язганча, Болгар патшасы атка атланып базар аша үткәндә һәркем аягына баса һәм башыннан бүреген салып култык астына кыстыра. Болгар патшасы янына кергән һәркем патша алдында тезләнә һәм шулай ук бүреген салып култык астына кыстыра. Бүрекне патшага күрсәтмәскә тырышалар.

Олылар, өлкәннәр алдында баш киемен салу бүгенге көндә олыларга, өлкәннәргә хөрмәтне белдерә. Ләкин мондый гадәт иң элек хакимнәргә буйсынуны аңлаткан. Буйсыну билгесе буларак яланбаш, яланаяк калу гадәте карлы-бозлы Монголиядә яисә Идел буе якларында барлыкка килмәгән. Мондый гадәт, бары тик җылы якларда гына барлыкка килергә мөмкин. Борынгы Мисыр сурәтләренә игътибар беләнрәк карасагыз, андагы гади халыкның — игенчеләрнең, көтүчеләрнең, һөнәрчеләрнең һәркайсының яланбаш, яланаяк булуын күрерсез. Баш киеме тик алла һәм алиһәләрдә һәм аллаларга тиң патшаларда гына. Аяк киемнәре дә башлыча аларда гына.

Хакимнәр алдында буйсынуны белдереп баш киемен салу да, күрәсең, Мисырда барлыкка килгән. Мәсәлән, «Пианхи ташы»нда язылганча, Нечери өлкәсенең башлыгы Тефнахт Напата патшасы Пианхига буйсыну белдерә һәм шул уңайдан «...башым яланбаш, киемем ерткаланып беткән» дигән сүзләр әйтә (Хр. ДВ, 161 бит).

Хакимнәргә буйсыну белдерүнең тагын бер төре булган. Буйсынган яки түбәнлеккә, хурлыкка төшкән кешенең битен карага буяганнар. Б.э.к. II гасыр азакларында Сөн патшасы Увәй янына Кытай иленнән Вану дигән илче килгәч, аңа патша янына кергәнче битенә тушь үкәргә кушыла. Биткә тушь (кара) үкәү бу очракта Хань (Кытай) илчесенең Сөн патшасына буйсынуын белдерә. Халыкларны, ыру-кабиләләрне, аерым кешеләрне акка-карага бүлеп карау борынгы һәм урта гасыр төркиләрдә бик нык таралган була. Мәсәлән, болгарларда, хазарларда ак ырулар, кара ырулар була. Мондый бүленеш калдыклары әле дә саклана. Ак һәрвакыт изге, дәрәҗәле, кара һәрвакыт түбән, ярлы һәм дәрәҗәсез исәпләнелә. Без әле дә кире сыйфатлы кешеләргә карата кара йөз, кара йөрәк, йөзе кара кебек сүзләр кулланабыз. «Кара» сүзе элегрәк кол, хезмәтче, ялчы мәгънәләрендә генә түгел, халык, гаскәр мәгънәләрендә дә кулланылган. Кешеләрне акка, карага бүлеп карау бары тик ак тәнле һәм кара тәнле халыклар яшәгән җирләрдә генә барлыкка килергә мөмкин. Борынгы мисырлылар ак тәнле булганнар, ләкин аларга еш кына кара тәнлеләр белән дә очрашырга туры килгән. Кара тәнлеләргә каршы алар яу чапканнар, аларны әсир итеп, кол сыйфатында төрле эшләрдә файдаланганнар. Кешене хурлау, түбәнсетү өчен аның битенә корым, кара үкәү гадәте төркиләрдә бик озак вакытлар сакланган. Мондый гадәт шулай ук ислам динендәге Мисыр чорында да булган.

Борынгы Мисырда үлгән кешене, әйтик, бездәгечә, бүгенгечә күмү булмаган. Мисырлылар мәетләрен бәлзәмләгәннәр һәм аны табутка салып, махсус бүлмәләрдә, өйләрдә саклаганнар. Үлгән патшаларның, аксөякләрнең мәетләрен саклау өчен, билгеле булганча, таудай пирамидалар, кыйммәтле төрбәләр төзегәннәр. Мәетне бәлзәмләү Кара диңгез буе скифларында, Алтай скифларында да булган. Казагъстанда, Таулы Алтайда археологлар табутка салып күмелгән, бәлзәмләнгән борынгы мәетләрне тапканнар. Сөннәрдә бәлзәмләү гадәтенең булуы-булмавы турында мәгълүматлар юк. Ләкин, Сымацянь язганча, сөннәр мәетләрен эчке һәм тышкы табутларга салып күмә торган булганнар. V гасырда кайдадыр безнең Идел буйларында яшәгән һәм зур гаскәр белән Бельгия, Франция, Италия җирләренә кадәр барып җиткән атаклы гун патшасы Аттила үлгәч, 451 елда аны ике кат кына түгел, өч кат табутка салып күмгәннәр. Табутның беренчесе алтыннан, икенчесе көмештән, өченчесе тимердән була. Аттила янына күп кенә хезмәтчеләр үтереп салына. Бо-

рынгы Мисырда да патшаларның мәетен икешәр-өчәр катлы табутларга салып күмгәннәр. XVIII династия патшасы Тутанхамон мумиясе өч кат табутка салынган, табутларның беренчесе алтыннан, икенчесе, өченчесе агачтан эшләнгән була.

Мисырлылар бик динле булсалар да, ашарга-эчәргә дә, күңел ачарга да яратканнар. Геродот язганча, бай хуҗа, кунак җыйгач, ашаган-эчкән вакытта кунакларның һәркайсына табутта ята торган мәет сынын күрсәтеп чыккан һәм: ашагыз-эчегез, күңел ачыгыз — үлгәч сез дә шундый хәлгә төшәрсез дип әйтә торган булган. Шуңа охшаш гадәт урта гасыр уйгурларда да булган. Рубрук Монгол империясенең башкаласы Каракорумда уйгурларның таш сыннарын күрә. Уйгурлар әлеге таш сыннар турында: «Безнең берәр бай кешебез үлсә, аның улы яисә хатыны, яки берәр башка кеше үзе өчен мәетнең сынын ясата; без аны (үлгән кешене) истә тотабыз, хөрмәт итәбез» диләр (Руб, 129 бит). XVII гасырда яшәгән Хива ханы Абул Гази бик борынгы төркиләр турында: «...Берәр кешенең яраткан кешесе үлсә, аның улы яки кызы, яки туганы үлгән кешегә охшатып аның сынын ясаткан һәм аны үзенең өенә куеп, менә бу безнең шундый-шундый якын кешебез дигән. Үзләренең хөрмәтен белдереп, ашаганда иң элек аңа өлеш чыгарганнар һәм ашамлыкны сын алдына куйганнар, аны үпкәннәр, аның битенә, күзләренә май сөрткәннәр, аның алдында баш игәннәр» дип яза (Абу, 10 бит). Күрәсез, бер-берсеннән бик ерак җирләрдә һәм төрле чорда яшәгән кешеләр сүзгә-сүз диярлек бер үк нәрсә турында сөйлиләр.

Татар телендә «җылан мөгезе» дигән тәгъбир бар. Татарлар ышануынча, җыланнар, имеш, мөгезле була, тик аларның мөгезен бәхетле кешеләр генә күрә алалар. Җылан мөгезен элегрәк төрле им-томнарда кулланганнар. Безнең Идел, Урал буйларында, төркиләрнең борынгы ватаны дип уйланылган Монголия, Алтай якларында мөгезле җыланнар юк. Гомумән, табигатьтә мөгезле җыланнар бар, ләкин алар бары тик эссе, корылыклы җирләрдә генә — Африкада, Гарәбстан чүлләрендә һәм Америка континентының кайбер төбәкләрендә генә яшиләр. Мисырда исә мөгезле җыланнарны бик борынгы заманнарда ук белгәннәр. Мисыр язуындагы *фи* иҗеген чагылдыручы билге мөгезле җылан сурәтен хәтерләтә. Мисырда, Фива өлкәсендә мөгезле җылан изге саналган. Үлгән җыланнарны мисырлылар иң югары дәрәҗәдәге аллаларга багышланган гыйбадәтханәләрдә күмгәннәр. Борынгы Мисырда җылан белән имнәүчеләр еш кына мөгезле җылан-

нардан файдаланганнар. Димәк, бүгенге телдәге «Җылан мөгезе» дә безне ерактагы пирамидалар иле белән тоташтыручы бер дәлил хезмәтен үти ала дип әйтәсе килә.

Урын тарлыкны истә тотып, мисыр-төрки уртаклыкларның барысына да тукталып булмый. Монда без антропологиягә, кием-салым, ашау-эчүгә, эш, сугыш коралларына һ.б. нәрсәләргә кагылышлы фактларны төшереп калдырырга мәҗбүрбез. Шул ук вакытта бер бик әһәмиятле фактка тукталмыйча мөмкин түгел.

Казан шәһәренең борынгы үзәгендә — хан сарайлары урнашкан калку җирендә, Казан суы яр буенда кызыл кирпечтән салынган мәһабәт Сөембикә манарасы очлаеп утыра. Бу манараны татарлар үзләренеке дип, кайбер рус галимнәре һәм аларның җырын җырлаучы үзебезнең докторлар һәм кандидатлар русныкы дип исәплиләр. Манараның кайчан һәм кем тарафыннан салынуы документлар белән расланмаса да, әлеге галимнәр аны XVII гасырда төзелгән булырга тиеш дип ышандырмакчы булалар. Моны раслау өчен һәртөрле вак-төяк дәлилләр китерелә. Казанны яулап алганнан соң руслар безнең башкалада чиркәүләр, хәрби корылмалар һәм башка төрле биналар төзегәннәр. Татарлар нишләптер рус салган бер генә бинага да дәгъва кылмыйлар, бары Хан мәчете турында гына сүз алып баралар. Шулай булгач...

Хәер, иң элек манараның тышкы кыяфәтенә игътибар итик. Манараның аскы өлеше зур гына шакмакны хәтерләтә. Зур шакмак өстенә кечерәк шакмак, анысы өстенә тагын да кечерәк өченче шакмак утыртып куелган. Шулай итеп, манара югарыга таба баскыч сыман үстерелеп бара. Дүрт кырлы өч «шакмакка» тагын сигез кырлы ике «шакмак» утыртылган. Шуннан соң манара очлаянечкәрә барып югары күтәрелә дә, иң ахырда сөңге кебек булып тәмамлана. Манараның төп үзенчәлеге нәрсәдә? Минемчә, төп үзенчәлеге аның баскыч сыман булып күтәрелүендә.

Әйе, Сөембикә манарасы дөньядагы бер генә манарага да охшамаган. Ләкин манара булмаган корылмалар арасында Хан мәчетенең манарасына охшаш бина үзебезнең «аяк астында аунап ята». Борынгы Болгар хәрабәләре арасында могҗиза белән генә сакланып калган «Черная палата» бар. «Черная палата» планда дүрткел. Нигезенең як-ягы җидешәр метр. Бинаның аскы һәм уртанчы өлеше өч «шакмактан» гыйбарәт. Өч «шакмак» өстенә сигез кырлы тагын бер «шакмак» утыртып куелган. Сигез кырлы шакмак өстендә кысыла төшкән гөмбәз сыман түбә калкып тора. «Черная палата»ның икенче ка-

тында, төньягында ишек бар. Ишекнең башы очлы көймә булып тәмамланган (См, 208 бит).

Сөембикә манарасы белән «Черная палата»ның төп үзенчәлекләре бер-берсенә охшаш. «Черная палата», билгеле, тәбәнәгрәк һәм аның өстендә манара да калкып утырмый. Ләкин болары — «вак мәсьәләләр». Төп үзенчәлек, әйтелгәнчә, чагыштырыла торган биналарның баскыч сыман итеп үстерелүендә һәм аскы өлешләренең дүрткел формада булуында. Әлеге архитектура истәлекләрендә тагын бер әһәмиятле деталь бар. Ул да булса, төньяктагы ишек. Дөрес, ишек бары «Черная палата»да гына. Хан мәчетендә ишек юк, аның урынына аскы кат уртасында атка атланган килеш тә, арбалы килеш тә кереп-чыгып йөрү өчен киң ачыклык калдырылган. Ачыклыкның өске ягы көймәле. Аның бер ягы көньякка, икенче ягы төньякка карый.

Хәзер инде ерактагы Мисыр якларын искә төшерик һәм атаклы Джосер (Җәсир) пирамидасын күз алдына китерик. Пирамида алты баскычлы, планда дүрткел. Безнең якларда алты-җиде баскычлы корылмалар салу, күрәсең, мөмкин булмаган. Аннан соң, Болгар чорында да, Казан ханлыгы чорында да борынгы карашлар инде күпмедер дәрәҗәдә үзгәрешкә кергән булырга тиеш дип исәпләргә була.

XIV гасырда салынган «Черная палата»ның нәрсәгә хезмәт итүе мәсьәләсендә уртак фикер юк. Берәүләр аны мәчет ди, икенче берәүләр төрбә, өченчеләре исә хөкем чыгару урыны ди. Хәзер без «палата»ның төньяктагы ишегенә игътибар итеп карыйк. Ни өчен ул төньякта? Моның сере шулай ук Мисырга барып тоташа. Мисырда төньяк «сүнми торган йолдызлар иле», ягъни мәңгелек иле исәпләнелгән. Пирамидаларда һәм төрбәләрдә ишек төньякта булган. Мәсәлән, атаклы Хуфу пирамидасының төньягында җирдән 14 метр биеклектә ишек бар. Ишекнең башы гөмбәзле (П, 382 бит). «Черная палата» да үз заманында төрбә хезмәтен үтәмәде микән дип әйтәсе килә. Болгар хәрабәләре арасында бары дини корылмалар гына исән калган. Болгарларның элекке башкаласы урынына килеп утырган руслар гадәти йортларны, биналарны сүтеп, җимереп бетергәннәр, ләкин кайбер мәчетләрне, төрбәләрне җимерүне шулай да гөнаһ санаганнар, ахрысы. Төньякны изгеләштерү төрки халыкларда да булган. Сөннәр патшасы тәхеттә утырганда төньякка карап утырган. Рубрук язганча, XIII гасырда христиан динендәге уйгурлар үзләренең гыйбадәтханәләрендә дога укыганда төньякка карап тезләнгәннәр (Тих, 224 бит).

## 12. СОҢГЫ СҮЗ УРЫНЫНА

Бүгенге көндә өстенлек иткән рәсми тарихның кайбер карашларын яңадан искә төшерик. Дөньяда иң беренче цивилизация учаклары Кече Азиядә һәм Төньяк Африкада барлыкка килгән. Цивилизация учаклары шулай ук дөньяның башка төбәкләрендә дә — Ганг, Инд һәм Хуанхэ елгалары буенда да булган. Культура бер үзәктән төрле якка таралганмы, әллә һәр цивилизация мөстәкыйль рәвештә барлыкка килгәнме — бу хакта әлегә уртак фикер юк. Көнбатыш белән Көнчыгыштагы цивилизацияләр арасында нинди дә булса охшашлыклар табылса да, мондый охшашлыклар күбесенчә очраклык белән аңлатыла. Көнбатышның Көнчыгышка тәэсире турында сөйләгәндә иң элек Месопотамия күз алдында тотыла. Бу мәсьәләдә Мисыр читтәрәк кала бирә. Мисыр цивилизациясен беркем белән аралашмыйча, утрау сыман яшәгән һәм үзеннән-үзе юкка чыккан дигәндәйрәк аңлатмалар очрый. Инде шулай да бүгенге Европа халыкларында Мисыр культурасы эзләре табыла икән, бу барыннан да бигрәк борынгы греклар һәм латиннар эшчәнлегенә кайтарып калдырыла: греклар мисырлылар белән аралашып яшәгәннәр, күп нәрсәне Мисырдан алганнар, латиннар исә греклардан алганнар. Шуннан соң инде барлык яхшы нәрсә Көнбатыш Европага күчкән. Бик уңай һәм бик җиңеләйтелгән схема менә шуннан гыйбарәт.

Борынгы халыкларның үзара мөнәсәбәтләрендә төркиләр телгә дә алынмый. Төркиләр культура учакларыннан бик еракта, кайдадыр Монголия һәм Алтай якларында барлыкка килгәннәр һәм аларның барлыкка килүләре дә бик соң башланган. Алар тумыштан ук таркау, оешмаган һәм күчмә булганнар. Алар — варварлар, җимерүчеватучылар. Безнең эраның беренче гасырларында алар каяндыр Көнчыгыштан калкып чыкканнар да, ташкын булып Көнбатышка ыргылганнар — утрак тормышлы, югары культуралы дәүләтләрне җиңгәннәр, авыл-шәһәрләрне талаганнар, халыкларны кырганнар. Ләкин культуралы Көнбатыш белән аралашу нәтиҗәсендә, әкренләп аларда да утрак тормыш, һөнәрчелек, игенчелек барлыкка килгән. Семит телле гарәпләр белән аралашу, ислам дине кабул итү исә төркиләрне юашландыруда, культуралаштыруда аеруча зур роль уйнаган. Шулай итеп, урта гасырларда мәдәниятле төрки дәүләтләр, шәһәрләр барлыкка килгән.

Тарих фәнендә безгә карата булган төп фикер менә шундыйрак.

Хәзер инде тарихта булган кайбер билгеле фактларны искә төшереп карыйк. Иксез-чиксез Европа-Азия киңлекләрендә күчмә тормыш белән яшәү урта гасырларда гына башланмаган. «Илиада» авторы Гомер заманнарында ук инде, чама белән б.э.к. X—IX гасырларда Кара диңгез буе далаларында бия сөте (кымыз) белән, ит-сөт белән туклана торган, бар байлыгын арбаларга төяп, мал-туар артыннан күченеп йөрүче күчмә халыклар булган. Кара диңгез буендагы күчмәләрнең, исемнәре билгеле булган иң беренчеләре — киммерилар. Киммерилар каяндыр Көнчыгыштан килгәннәр. Киммерилардан соң Кара диңгез буе далаларына скифлар хуҗа булган. Алар да бу җирләргә каяндыр читтән килгәннәр. Скифлардан соң Европа-Азия далаларында сак, сармат, алан һ.б. күчмә кабиләләр хакимлек иткән. Бу күчмәләрне фәнни әдәбиятта иран телле булган дип аңлаталар.

Кара диңгез буйларыннан бик еракта, дөньяның икенче читендә Төньяк Кытай һәм Монголия далаларында б.э.к. кимендә III гасырдан башлап безнең эраның III—IV гасырларына кадәр сөн дигән күчмә халыклар яшәгән. Кытай хроникаларында сөннәрнең ата-бабалары төрле чорда төрле исем белән аталганнар. Хуанхэ буйларында борынгы Кытай дәүләте барлыкка килгәндә үк инде күрше җирләрдә күчмә кабиләләр булган. Кытайның Инь династиясе б.э.к. XVIII гасырда барлыкка килгән дип уйланыла. Инь чорына карый торган иң борынгы һәм иң беренче язулар, б.э.к. 1300—1200 елларда барлыкка килгән. Бу беренче язуларда сөннәрнең элгәреләре булган төрле кабилә исемнәре телгә алына. Шул рәвешчә, ким дигәндә б.э.к. XIV—XIII гасырларда Кытайга якын җирләрдә күчмә сөннәр хакимлек иткән дип әйтә алабыз.

Бик күп фактлар сөннәрнең төркилеге һәм каяндыр ерак Көнбатыштан күченеп килүләре турында сөйли. Менә бер-ике мисал. Сөннәрдән соң Төньяк Кытай һәм Монголия далаларында төрек дигән кабиләләр баш булып кала. Төрек патшалыгы VI—VIII гасырларда күтәрелеш чоры кичерә. Алар хәзерге Монголиядән алып Идел, Каспий буйларына кадәрге җирләргә хуҗа булалар. Төрекләрнең килеп чыгышы турында ике төрле риваять сакланып калган. Шуларның берсендә әйтелгәнчә, төрекләрнең (төркиләрнең) ата-бабалары кайчандыр Сихай дигән диңгезнең көнчыгыш яры буенда, зур сазлыкта яшәгәннәр диелә. Сихай кытайча «Көнбатыш диңгез» дигән сүз. Сихайны бүгенге галимнәрдән кайберәүләр Арал диңгезе буйларыннан, кайберәүләр хәзерге Монголиядәге күлләр, сазлыклар тирәсеннән эзлиләр. Бит Кы-

тайның көнбатыш өлешендә якын-тирәдә бернинди диңгез юк. Кытайга иң якыны Арал, Каспий диңгезләре. Шуннан да арырак китәргә беркемнең йөрәге җитми. Ераккарак китсәң, Урта диңгез бар, Урта диңгезгә коя торган Нил һәм Нил тамагында атаклы сазлыклар, камышлыклар бар. Монысы инде Мисыр җирләре. Алтай төркиләренең борынгы ватаны Мисыр, имеш. Булырга мөмкинме мондый нәрсә? Бу турыда хәтта уйлавы да куркыныч. Шуңа күрә дип әйтимме, теләсә нинди күлне Сихай дип танырга әзерләр дә инде бүгенге галимнәр. Ләкин, беренчедән, борынгы кытайлар күл белән диңгезне генә аера белгәннәрдер дип уйларга кирәк. Икенчедән, «Сихай» төшенчәсе кытайларда Алтай төрекләре чорыннан элегрәк тә, мәсәлән, сөннәргә кагылышлы истәлекләрдә дә очрый. Димәк, каяндыр Сихай ягыннан күченеп килү турындагы истәлекләр сөннәрдә дә булган булырга мөмкин, тик андый истәлекләр теркәлеп кенә калмаган.

Сөннәрнең чыгышы турында Сымацянь икенче бер риваять язып калдырган. Сөннәрнең беренче патшасы Шуньвәй дип аталган һәм ул борынгы кытайларның Ся династиясе патшасының улы булган, имеш. Сымацянь язганча, Шуньвәй заманнарыннан алып сөннәрнең Тоумань дигән патшалары заманына кадәр мең елдан артыграк вакыт үткән икән. Хәзерге кытай тарихчылары исәпләп чыгарганча, Шуньвәй чама белән б.э.к. 1600 елларда яшәгән. Тоумань исә б.э.к. 209 елга кадәр яши. Шул рәвешчә, Шуньвәйдән алып Тоуманьга кадәр чыннан да мең елдан артык вакыт үткән булып чыга.

Мең еллык дәүләт турындагы караш этрускларда да, римлыларда да була. Мең еллык хакимлекне Шәрык фәлсәфәсенең бер чагылышы дигәндәйрәк аңлатма яшәп килә. Кара диңгез буе скифлары үзләрен дөньяда иң яшь халык дип исәплиләр. Скифларның яңа җиргә беренче булып аяк баскан кешесе Таргитай заманнарыннан алып Дари патшаның скиф җиренә басып керүенә кадәр төптөгәл мең ел булган, имеш. Скифлар җиренә Дари патша исә б.э.к. 514 елда басып керә. Шулай итеп, скифларның беренче патшасы Таргитай Кара диңгез буе далаларына б.э.к. 1514 елда аяк баскан булып чыга.

Скифларның Кара диңгез буена каян килүләре турында Геродот берни әйтми. Ләкин скиф кабиләләренең берсе неврлар турында сөйләгәндә тарихчы безгә шактый кыйммәтле хәбәрләр теркәп калдырган. Неврлар — бүрегә табынучылар, һәр елны берничә көнгә алар бүрегә, аннан кешегә әйләнәләр, имеш. Скиф җиренә Дари һөҗүме алдыннан бер буын элегрәк неврлар хәзерге Днепр

буйларына күченеп килгәннәр. Ни өчен дигәндә, аларның әүвәлге ватаннарында җыланнар күбәйгән икән. Җыланнар чүлләрдән күпләп килеп, кешеләргә һөҗүм иткәннәр (Г, IV, 105). Чүлләр һәм кешеләргә һөҗүм итәрдәй җыланнар, белүебезчә, Днепр буйларына якын җирләрдә түгел, бәлки көньякта — Африкада һәм Гарәбстан ярымутравында гына бар һәм булган.

Б.э.к. XVII гасырда Мисырга уңнан — Азия ягыннан гиксослар басып керәләр. Гиксослар хакимлеге б.э.к. 1670 еллардан алып 1570 елларга кадәр дәвам итә. Кара диңгез буе скифларын да, Монголия далаларындагы сөннәрне дә гиксослар белән сугышта җиңелгән һәм качып китәргә мәҗбүр булган мисыр гаскәриләре дип исәпләсәк, Таргитай* һәм Шуньвәй хакимлеге чорлары турындагы даталарда әллә ни каршылык күрмәячәкбез.

Мисырда динчеләрдән кала гаскәриләр иң дәрәҗәле һәм хөрмәткә лаек катлау саналган. Гаскәриләр бары сугыш эшен генә өйрәнгәннәр — иген икмәгәннәр, һөнәр белән шөгыльләнмәгәннәр. Бала сугыш эшенә атасыннан өйрәнгән һәм тумыштан ук сугышчы исәпләнелгән. Классик типтагы күчмәләрдә нәкъ менә шундый хәл сакланган: иген икмәгәннәр, авыл-шәһәр кормаганнар, һөнәрчелек белән шөгыльләнмәгәннәр. Шул ук вакытта аларда югары дәрәҗәдәге дәүләт системасы була. Монда шулай ук скифларның, борынгы Алтай кабиләләренең искиткеч сәнгатен, төзелештәге, һөнәрчелектәге тиңдәшсез осталыкларын, Мисыр фиргавеннәренекенә охшаш саркофагларын, шумерларныкына охшаш арфаларын һ.б. бик күп нәрсәләрне искә төшермичә мөмкин түгел. Боларны алар күршеләреннән талап та, иткә-сөткә алыштырып та алмаганнар. Боларның барысы да аларның үзләренеке. Профессиональ хәрби буларак, игенчелек, һөнәрчелек белән шөгыльләнергә тиеш булмасалар да, алар арасында, әлбәттә, һәр эшнең остасы булган, алар аңында, аларның гореф-гадәтләрендә, йолаларында әүвәлге ватаннарының югары культура тәҗрибәсе, гореф-гадәтләре, дини йолалары сакланган. Кирәк вакытта яңа җирләрдә дә алар могҗизалар тудыра алганнар.

Гиксослар чоры ул бары бер мисал гына. Көнбатыштагы борынгы илләрдән, шәһәрләрдән качу, күченү, таралу башка чорларда да булган дип әйтә алабыз, һәртөрле сугышлардан, Атлантида һәлакәте кебек һәлакәтләрдән соң

---

*«Кытай» терминын бүгенге галимнәр монгол телле кидань кабиләсе исеменнән алынган дип аңлаталар. Чынлыкта скифларның Геродот әйткән ата-бабасы Таргитай (Тар Гитай) исеменнән алынмады микән дип әйтәсе килә.

халыкның күп өлеше бәхет эзләп, сыену эзләп — Көнчыгышка, яңа җирләргә омтылган. Алтай, Монголия, Казагъстан, Кыргызстан, Тува, Памир, Таҗикстан җирләрендәге ташларга, кыяларга ясап калдырылган исәпсез-хисапсыз сурәтләр (петроглифлар) нәкъ менә шул хакта сөйли. Төрле төбәкләрдә, төрле чорларда ясап калдырылган ат, кеше, корал, кием-салым детальләрен чагылдырган сурәтләр нигездә бер төсле. Мәсәлән, тәртәләп җигелгән сугыш арбалары Месопотамиядә, Мисырда, Микена чоры Грециясендә, Кавказ артында, Төньяк Европада, Алтайда, Монголиядә очрый икән. Шундый ук төзелештәге арбалар Алтайда Пазырк курганнарында, Инь һәм Чжоу чорында Кытай каберлекләрендә табылган (Нов, 73, 74 битләр).

Кыскасы, бронза чорыннан башлап гасырлар буена дигәндәй атлы, арбалы, кораллы качаклар, башлыча гаскәриләр буш, аулак җирләргә таба хәрәкәтләнгәннәр. Шуның нәтиҗәсендә Төньяк һәм Көнчыгыш далаларында күченүчеләрдән яңа берләшмәләр, яңа дәүләтләр оешкан һәм алар безнең бик борынгы телне, культураны тулысынча диярлек саклап калып, буыннан-буынга тапшыра килгәннәр.

Тарихтан билгеле булганча, безнең эра башларында халыкларның бөек күчеш чоры башланган. Бу вакытта инде күчмәләр Көнчыгыштан Көнбатышка таба хәрәкәтләнгәннәр. Урта гасырларда Гуннар Көнбатышка барганнар. Аттила ни өчендер, һичшиксез, Римны яулап алмакчы булган һәм Византиягә, Римга ниндидер дәгъвалар белдергән. Алтай төркиләре шулай ук Көнбатышка таба омтылганнар. Чыңгыз хан да иң элек Монголиядән көнбатыштагы илләрне, халыкларны буйсындырган һәм Көнчыгыш диңгез белән көнбатыш диңгез арасындагы барлык җирләрне яулап алу турында хыялланган. Бу яуларның, хәрәкәтләрнең һәркайсының үзенең конкрет сәбәпләре булган. Төп сәбәп шулай да эчтә, тирәндә яткан — Көнчыгыштан кубып чыккан халыклар, күрәсең, үзләренең әүвәлге ватаннарын онытмаганнар. Ләкин бу вакытта инде аларның әүвәлге ватаннарында башка телдә сөйләшүче, башка дингә, башка аллаларга табынучы бүтән халыклар хаким булганнар. Элекке кан-кардәшләре аларга явыз дошман булып, басып алучы, җимерүче һәм харап итүче булып тоелган. Алар язып калдырган тарихи истәлекләрдә кызыл җеп булып менә шул караш чагыла. Хәер, бу карашның әле дә бетеп җиткәне юк.

Төркиләргә кагылышлы тагын бер-ике детальне искә төшерик. VII—VIII гасырларда яшәгән Бөек Болгар дәүләтенең үзәге Арал диңгезе буенда, Дон елгасының

түбән агымында була. X гасырга кадәр яшәгән Хазар дәүләтенең үзәге Төньяк Каспий буйларында, Идел тамагында була. Казан ханлыгының башкаласы Идел буенда, Казан суы тамагында урнаша. Шул рәвешчә, безнең борынгы ата-бабалар йорт булып утыру өчен суга, сазга, камышка якын җирләрне сайлаганнар дип әйтә алабыз. Монда барыннан да элек борынгы традицияләр һәм дини-мифик карашлар өстенлек иткән булса кирәк.

Скифларның килеп чыгышы турында Геродот ике төрле риваять язып калдырган. Алтай төркиләренең килеп чыгышы турында Кытай чыганакларында шулай ук ике төрле риваять сөйләнелә. Безнеңчә, бик борынгы заманнарда ук инде бер халыкта ике халык — төп чыгышлары белән бер төрле, тик шулай да озак вакытлар дәвамында аерымланыбрак яшәгән тугандаш кабиләләр булган. Бүгенге «көндә дә төркиләр нигездә ике төркемгә — кыпчак телләләргә һәм угыз телләләргә бүленәләр. Очраклы хәлме бу, әллә соң бу да еракган килә торган тамырларның төрлелеге турында сөйлиме? Безнеңчә, бу очраклы хәл түгел.

Тарихи истәлекләрдә теркәлеп калган һәм бүгенге көндә билгеле булган төрки кавемнәрнең барысы да Көнбатыштан күченеп килүчеләр булмаска да мөмкин. Бүгенге көндә Төньякта, Көнчыгышта, Себердә яшәүче кайбер төркиләр ерак чорларда Көнбатыштан күченеп килгән һәм гасырлар буена бу якларда хакимлек иткән халыклар белән аралашу һәм тел-лөгать алмашу нәтиҗәсендә формалашканнардыр кебек.

Төрки халыкларның, шул исәптән, әлбәттә, татар халкының да бөек Шәҗәрәсен без менә шул рәвешчә күз алдына китерәбез.

# ФАЙДАЛАНЫЛГАН ХЕЗМӘТЛӘР ИСЕМЛЕГЕ


Аб — Родословное древо тюрков. Сочинение Абуль-Гази, Хивинского хана. Перевод и предисловие Г.С.Саблукова. Казань, 1906.

Ав — Питер Авери. Иран. 2500 лет истории и культуры. «Курьер ЮНЕСКО» журналы. 1971, октябрь.

Ал — В.П.Алексеев. Очерк происхождения тюркских народов Восточной Европы в свете данных краниологии.— «Вопросы этногенеза тюркоязычных народов Среднего Поволжья. Казань. 1971» китабында.

Алы — Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге. Авторлары: К.З.Хәмзин, М.И.Мәхмүтов, Г.Ш.Сәйфуллин. Казан. 1965.

АФ — Африка. Энциклопедический справочник. Том 2. М., 1963.

Бай — Байкыбаш сөйләше.— «Татар диалектологиясе буенча материаллар. 5. Текстлар. Казан. 1983» китабында.

Бар — В.В.Бартольд. Сочинения. Том II, часть 2. М., 1964.

Бе — Г.А.Белова. Титулатура «царских сыновей Куша» как источник для исследования их функций. «Вестник древней истории» журналы. 1978, № 2.

Бел — А.Белогорский. Сокровища Уструшаны. «Вокруг света» журналы. 1976, № 3.

Бла — Т.В.Блаватская. Греческое общество второго тысячелетия до новой эры и его культура. М., 1976. Борынгы татар әдәбияты. Казан. 1963.

Бор — А.К.Боровков. Лексика среднеазиатского тефсира XII— XIII вв. М., 1963.

Бре — Б.Брентьес. От Шанидара до Аккада. М., 1976.

Бу — Я.Буриан, Б.Моухова. Загадочные этруски. М., 1970.

Бә — Татар халык иҗаты. Бәетләр. Казан. 1983.

Ве — В. А.Вельгус. Александрийские фокусники в Китае.— «Африканский этнографический сборник. X. Л., 1975» китабында.

АИ — Всемирная история, том 1. М., 1955.

Во — Н.И.Воробьев. Происхождение казанских татар по данным этнографии.— «Происхождение казанских татар. Казань, 1948» китабында.

Вор — Н.И.Воробьев. Казанские татары. Казань. 1953.

Г — Геродот. История в девяти книгах. Л. 1972.

Гала — А.Н.Галанапулос, Э.Бэкон. Атлантида. За легендой— истина. М., 1983.

Гар — Ф.Г.Гарипова. Татарстан гидронимнары сүзлеге. Казан. 1984.

Ге — И.Гельб. Западносемитские силлабарии.— «Тайны древних письмен. М., 1976» китабында.

Гла — Т.Д.Гладкова. Отряд Приматы.— «Жизнь животных. Том 6. М., 1971» китабында.

Гук. — В.Л.Гукасьян. Тюркизмы в албанских источниках. «Советская тюркология» журналы. 1977, № 2.

Дво — И.Х.Дворецкий. Латинско-русский словарь. Издание второе, переработанное и дополненное. М., 1976.

Дир — Д.Дирингер. Алфавит. М., 1963.

Дон — О.А.Донских. К истокам языка. Новосибирск. 1988.

Др — Древний мир на юге России. Сборник источников. М., 1918.

ДТС — Древнетюркский словарь. Л., 1969.

Дум — Л.И.Думан. Внешнеполитические связи древнего Китая и истоки даннической системы.— «Китай и соседи. М., 1970» китабында.

Ды — Н.П.Дыренкова. Культ огня у алтайцев и телеут. МАЭ. VI. Л., 1927.

Дьяк — И.М.Дьяконов. Языки древней Передней Азии. М., 1967.

Дәү — Гамир Дәүләтшин. Борынгы Болгар тарихы риваятьләре. «Казан утлары» журналы. 1978, № 8.
Ев — В.В.Евсюков. Мифы о вселенной. Новосибирск. 1988.
Ер — Д.Е.Еремеев. На стыке Азии и Европы. М., 1980.
Жир — В.М.Жирмунский. Тюркский героический эпос. Л., 1974.
За — Войтех Замаровский. Их величества пирамиды. 2-е издание. М., 1986.
Зай — Л.Зайдлер. Атлантида. М., 1966.
Ибн — Путешествие Ибн-Фадлана на Волгу. Перевод и комментарий под редакцией И.Ю.Крачковского. М.— Л., 1939.
Ил — Гомер. Илиада. Перевод с древнегреческого Н. Гнедича, М., 1985.
Иль — Л.С.Ильинская. Легенды и археология. Древнейшее Средиземноморье. М., 1988.
Ио — Иордан. О происхождении и деяниях гетов. М., 1960.
Йо — Татар халык иҗаты. Йола һәм уен җырлары. Казан. 1980.
Каир — Каир. Тысячелетие города. 969-1969 гг. Министерство культуры ОАР. Организация по делам печати.
Кар — Дж.П.Карпини. История монгалов.— «Путешествие в восточные страны Плано Карпини и Рубрука. М., 1957» китабында.
Кл — С.Г.Кляшторный. Древнетюркские рунические памятники как источник по истории Средней Азии. М., 1964.
КБ — Ә.Кленгель-Брандт. Путешествие в древний Вавилон. М., 1964.
КДЕ — Культура древнего Египта. М., 1976.
Кен — С.К.Кенесбаев, Т.Д.Джанузаков. О лексических пластах ономатики казахского языка. «Советская тюркология» журналы. 1976, № 3.
КИ — Казанская история. М.— Л., 1954.
Ко — А.Н.Кононов. Родословная туркмен. Сочинение Абу-л-Гази хана хивинского. М.— Л., 1958.
Ков — В.Б.Ковалевская. Конь и всадник. М., 1977.
Кож — П.М.Кожин. Об иньских колесницах.— «Ранняя этническая история народов Восточной Азии. М., 1977» китабында.
Конд — А.М.Кондратов, В. В. Шеворошкин. Когда молчат письмена. Загадки древней Эгеиды. М., 1970.
Кондр — Н.А.Кондрашов. История лингвистических учений. М., 1979.
Конр — Н.И.Конрад. Избранные труды. Синология. М., 1977. Кор — М.А.Коростовцев. Религия древнего Египта. М., 1976.
Кос — И.А. и К.А.Коссович. Греческо-русский словарь. Часть 1. М., 1848.
Кра — С.Н.Крамер. История начинается в Шумере. М., 1965.
КРПС — Караимско-русско-польский словарь. М. 1974.
Ку — С.Кучера. Китайская археология. М., 1977. Ли — Л.А.Липин. Аккадский язык. М., 1964.
Мав — Р.Р.Мавлютов. Ислам. М., 1974.
Маза — А.А.Мазанов. Одежда татар XVI—XVIII вв. (по старинным рисункам и гравюрам).— «Новое в археологии и этнографии Татарии. Казань, 1982» китабында.
Мел — Дж.Мелларт. Древнейшие цивилизации Ближнего Востока. М., 1982.
Мец — Адам Мец. Мусульманский Ренессанс. М., 1966.
Мол — А.А.Молчанов. Таинственные письмена первых европейцев М., 1980.
МС — Мифологический словарь. Авторы: М.Н.Ботвинник, М.А.Коган, М.В.Рабинович, С.П.Селецкий. Л., 1961.
Мух — А.Г.Мухамадиев. Булгаро-татарская монетная система XII-XV вв. — М. 1983.

Мә — Татар халык иҗаты. Мәкальләр һәм әйтемнәр. Казан. 1987.
Мәр — Шиһабетдин Мәрҗани. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр.) Казан. 1989.
На — Э.Н.Наджип. Историко-сравнительный словарь тюркских языков XIV века. Книга 1. М., 1979.
Не — О.Я.Неверов. Геммы античного мира. М., 1983.
Нег — Н.Негматов. Странствия Бунджикатской волчицы. «Вокруг света» журналы. 1973, № 10.
Нем — А.И.Немировский. Этруски. От мифа к истории. М., 1983.
Ни — Н.М.Никулина. Искусство Эгейского мира и его связи с искусством древнего Востока. «Вестник древней истории» журналы. 1977, № 3.
Нов — Э.А.Новгородова. Мир петроглифов Монголии. М., 1984.
Од — Гомер. Одиссея. Перевод с древнегреческого В.Жуковского. М., 1985.
Оп — А.Лео Оппенхейм. Древняя Месопотамия. М., 1980.
П — Ю.Я.Перепелкин. Древний Египет.— «История древнего Востока. Зарождение древнейших классовых обществ и первые очаги рабовладельческой цивилизации. Часть вторая. Передняя Азия. Египет. — М., 1988» китабында.
Пе — Б.Г.Петерс. О морском деле в Эгейском море.— «История и культура античного мира. М., 1977» китабында.
Пел — Г.И.Пелих. Элементы переднеазиатской культуры у нарымских селькупов.— «Труды Томского гос. университета им. В.В.Куйбышева. Сборник научных работ исторических кафедр. Томск. 1963» китабында.
Пен — Дж.Пендлбери. Археология Крита. М., 1950.
Пл — С.А.Плетнева. Печенеги, торки и половцы в южнорусских степях.— «Труды Волго-Донской археологической экспедиции. Том 1. М.— Л., 1958» китабында.
Пла — Платон. Сочинения в трех томах. М., 1968—1971.
Пле — С.А.Плетнева. О построении кочевнического лагеря — вежи. «Советская археология» журналы. 1964, № 3.
Плет — С.А.Плетнева. От кочевий к городам. Салтово-Маяцкая культура. М., 1967.
Плетн — С.А.Плетнева. Половецкие каменные изваяния. М., 1974.
Плетне — С.А.Плетнева. Хазары. М., 1976.
Плу — Плутарх. Моралии. Греческие вопросы. «Вестник древней истории» журналы. 1977, №№ 1, 2; Об Исиде и Осирисе. №№ 3,4.
Поз — Л.Д.Позднеева. Китайская письменность.— «Древний Восток. Книга для чтения. М., 1953» китабында.
Поп — Ю.К.Поплинский. Африка и Эгеида во II тысячелетии до н.э.— «Африканский этнографический сборник. X. Л., 1975» китабында.
Попл — Ю.К.Поплинский. Гараманты. (К истории культуры древних сахарских цивилизации.) — «Африканский этнографический сборник. XI. Л., 1978» китабында.
Рад — В.В.Радлов. Опыт словаря тюркских наречий. СПб., 1883-1911.
Ре — И.А.Резанов. Атлантида: фантазия или реальность? М., 1975.
Рив — Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар. Казан. 1987.
Руб — Гильом де Рубрук. Путешествие в восточные страны.— «Путешествия в восточные страны Плано Карпини и Рубрука. М., 1957» китабында.
С — Страбон. География. Л., 1964.
Сат — Г.Ф.Саттаров. Татар исемнәре сүзлеге. Казан. 1981.
Сере — Б.А.Серебренников. Вероятностные обоснования в компаративистике. М., 1974.

Си — Н.А.Сидорова. Искусство Эгейского мира. М., 1972.
СИС — Словарь иностранных слов. Под ред. И. В. Лехина и проф. Ф. Н. Петрова. Издание пятое. М., 1955.
См — А.П.Смирнов. Волжские булгары. М., 1951.
Со — Г.Соколов. Эгейское искусство. М., 1971.
Сы — Сыма Цянь. Исторические записки (Ши Цзи). Том II. Перевод с китайского и комментарий Р.В.Вяткина и В.С.Таскина. Под общей редакцией Р. В. Вяткина. М., 1975.
Тас, I — Материалы по истории сюнну (по китайским источникам). Предисловие, перевод и примечания В. С. Таскина. М., 1968.
Тас, II — Материалы по истории сюнну (по китайским источникам). Выпуск второй. Предисловие, перевод и примечания В.С.Таскина. М., 1973.
Тат — Татар халык иҗаты. Казан. 1951.
Тих — Д.И.Тихонов. Хозяйство и общественный строй уйгурского государства X—XIV вв. М.— Л., 1966.
ТЛ — Татар халык иҗаты. Тарихи һәм лирик җырлар. Казан. 1988.
Том — Дж.Томсон. Исследования по истории древнегреческого общества. Доисторический Эгейский мир. М., 1958.
Тро — Т.А.Трофимова. Этногенез татар Среднего Поволжья в свете данных антропологии.— «Происхождение казанских татар. Казань. 1948» китабында.
ТРС — Татарча-русча сүзлек. М., 1966.
ТТАС — Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Өч томда. Казан. 1977—1981.
ТТДС — Татар теленең диалектологик сүзлеге. Казан. 1969.
ФД — Г.А.Федоров-Давыдов. Кочевники Восточной Европы под властью золотоордынских ханов. Археологические памятники. М., 1966.
Фре — Дж.Фрезер. Золотая ветвь. М., 1931.
Фри — И.Фридрих. История письма. М. 1979.
Хаз — А.М.Хазанов. Очерки военного дела сарматов. М., 1971.
Хр. ДВ — Хрестоматия по истории Древнего Востока. М., 1963.
Чеб — И.А.Чебоксарова, Н.Н.Чебоксаров. Формирование антропологического состава населения Китая.— «Этническая история народов Восточной и Юго-Восточной Азии в древности и средние века. М., 1981» китабында.
Чед — Дж.Чедуик. Дешифровка линейного письма Б.— «Тайны древних письмен. М., 1976» китабында.
Ше — Я.А.Шер. Каменные изваяния Семиречья. М.— Л., 1966.
Шпи — С.М.Шпилевский. Древние города и другие булгаро-татарские памятники в Казанской губернии. Казань. 1877.
Эл — Элиан. Пестрые рассказы. Перевод с древнегреческого. М.— Л., 1964.
Як — Б.В.Якушин. Гипотезы о происхождении языка. М., 1984.
Әк — Татар халык иҗаты. Әкиятләр (беренче китап). Казан. 1977.

# МӘКАЛӘЛӘР

## АТЛАНТИДА

Борынгы Мисырны, Шумерны, Вавилонны, аеруча борынгы Грецияне белмәгән, ишетмәгән кеше юктыр дисәк, һич тә ялгыш булмас. Европа халыклары әдәбиятының, сәнгатенең, фәненең, мифология һәм фольклорының башлангычы турыдан-туры грекларга һәм греклар аша борынгы Римгә барып тоташа. Европа телләрендәге фәнни-иҗтимагый, әдәби һ.б. терминнарның бик зур күпчелеге грек-латин сүзләре нигезендә ясалган. Европа телләре аша ул терминнар рус теленә, рус теле аша — татар теленә үтеп кергән.

Грек-латин телләрендә язма истәлекләр күбрәк сакланган. Шуңа күрә дип әйтимме, борынгы дөнья турында сөйләгәндә бар нәрсәне грекларга һәм латиннарга кайтарып калдыру традициягә әверелгән.

1900 елда инглиз галиме Артур Эванс Крит утравында археологик казу эшләре башлап җибәрә. Утрауның төньягында, Кнос шәһәре янында ул борынгы сарай калдыклары таба. Шунда ул бик күп төрле тормыш, көнкүреш әйберләре, эш, сугыш кораллары табыла. Бу табылдыклар моңарчы фәндә билгеле булган һәм грекларныкы дип исәпләнелгән әйберләрдән аерылып тора. А.Эванс Криттә греклардан элегрәк яшәгән һәм грекныкыннан югарырак дәрәҗәдәге культура тудырган ниндидер билгесез халыкның эзенә төшә. Бу билгесез халык тудырган культураны фәнни әдәбиятта Крит культурасы дип тә, Крит-Миной культурасы дип тә атыйлар.

Крит-Миной культурасы б.э.к. 3000 елларда башлана һәм б.э.к. 1100 елларда тәмамлана. Димәк, Крит культурасы Шумер һәм Мисыр культуралары белән бер үк чорларда барлыкка килгән һәм алар белән бер үк чорларда яшәгән. Борынгы греклар исә Эгей диңгезе бассейнында үзләреннән бер-ике мең еллар элегрәк чәчәк аткан бик борынгы халык культурасын гына үзләштергәннәр һәм аларның үзләренеке дип уйланылган күп нәрсәсе чынлыкта әлеге билгесез халык ирешкән казаныш булып чыга.

Криттә дүрт-биш төрле язу кулланылган. Илленче елларда инглиз галиме М.Вентрис Дж.Чедуик белән берлектә «сызыклы Б язу» дип йөртелгән язуны укуга ирешә. Сызыклы Б язу грек телле була һәм ул Крит цивилизациясенең соңгырак чорында — б.э.к. XIV—XIII йөзләрдә кулланыла.

Крит язулары арасында «Фест дискысы» дип аталган язу да бар. Грекча диск «түгәрәк» дигәнне аңлата, без аны дисбе дип беләбез. Бу язу чыннан да түгәрәк формада. Ул юка гына балчык кисәгеннән гыйбарәт. Аның диаметры 16 сантиметр чамасы. Түгәрәк тактачыкның ике ягына да спираль рәвешендә янәшә сызыклар төшерелгән. Сызыклар шакмакларга бүленгән, һәр шакмак эченә төрле рәсем-билгеләр ясалган. Бу язу бүгенге көндәге ребусларны хәтерләтә.

Фест дисбесен Крит утравының көньягындагы Фест шәһәре тирәсендәге борынгы сарай калдыкларын казыганда, 1908 елның 3 июлендә, итальян археологы Л.Пернье эшчеләре тапкан. Борынгы Фест сарае моннан 3500—3600 еллар элек җимерелгән. Шул нигездә «Фест дисбесе» б.э.к. XVII йөздә иҗат ителгән булырга тиеш дип исәплиләр.

Фест түгәрәгендәге язуны галимнәр төрле телләрдә укырга тырышып караганнар. Мин аны төрки телдә укыдым. Бик күпләрнең башын катырган серле язу кинәт телгә килде. Фест язуының, димәк, Крит цивилизациясенең төркилеге ул фәндә яшәп килә торган традицион карашларга — бигрәк тә төрки халыкларның теле һәм тарихы турындагы карашларга капма-каршы килә. Бит фән әһелләре әле дә безне монголлар белән бертуган дип, безнең иң әүвәлге ватаныбыз Монголия һәм Алтай якларында булган дип ышандырмакчы булалар! Шулай булгач, монда бернинди очраклыкка һәм нигезсез фикерләүләргә юл куела алмый. Без бары фактларга гына таянабыз һәм Крит культурасының төркилеген исбат итү өчен, «Фест дисбесе»ннән тыш, бик күп төрле башка материалларга да мөрәҗәгать итәбез. Түбәндә без шуларның кайберләре белән танышып китәрбез.

Сүзне Атлантидадан башлыйк. Атлантида турындагы хәбәрне б.э.к. 427—347 елларда яшәгән грек философы Платон язып калдырган. Бик борынгы заманнарда Атлантик океанда, имеш, Атлантида дип аталган ниндидер дәүләт булган. Бу дәүләтнең биләмәләре бик зур булган — аның территориясе бер яктан Кече Азиягә, икенче яктан Африкага кадәр сузылган. Атлантида белән көчле патшалар идарә иткән. Дәүләтнең башкаласы «Атланти-

да» дип аталган утрауга урнашкан. Платон күбесенчә менә шул утрауны һәм башкаланы тасвирлый.

Утрауда, киң үзән уртасында, диаметры бер километр чамасындагы тау була. Тауда, имеш, дөньядагы иң беренче адәм балалары — ирле-хатынлы кешеләр яшәгән. Аларның бер кызлары булган. Ата белән ана көннәрдән бер көнне үлеп китәләр. Үсеп буйга җиткән ятимә кызга диңгез алласы Посейдон гашыйк була. Ул аңа өйләнә һәм аларның биш пар игезәк уллары туа. Диңгез алласы ун улын да тәрбияләп үстерә, утрауны унга бүлеп, һәр өлкәгә үзенең улларын баш итеп куя. Атлант исемле өлкән улын Алла башкалар өстеннән хаким итеп билгели. Посейдон үзе һәм аның уллары тауны, үзәнне ныгытуга күп көч куялар. Тауны диңгез алласы өч кат су бозҗра, ике кат җир бозҗра белән әйләндереп ала. Бозҗралар биек, киң коймалар белән ныгытыла. Диңгездән тышкы су бозҗрасына кадәр озынлыгы 10 километр, киңлеге 100 метр, тирәнлеге 3 метр чамасындагы канал казыла. Җир бозҗралар аша шулай ук каналлар казыла. Диңгез кораблары, шулай итеп, турыдан-туры үзәктәге тауга кадәр бара алалар.

Җир бозҗраларны әйләндереп алган коймалардан тыш тагын бөтен үзәнне уратып алган һәм диңгез буеннан ук башланып киткән бик зур таш койма да була. Тау янындагы кечерәк койма җиз белән, беренче җир бозҗра янындагы койма кургаш белән, аннан читтәге җир бозҗра коймасы бакыр белән капланган була. Металлны коймага эретеп агызалар ди Платон.

Тауда патша сарайлары, гыйбадәтханәләр урнаша. Кайчандыр, имеш, Алла һәм аның хатыны, ун улы яшәгән үзәктә беркем аягы басмый торган гыйбадәтханә була. Ул алтын койма белән әйләндереп алына. Таудан ике чишмә агып чыга. Чишмәләрнең берсе кайнар сулы, икенчесе салкын сулы була. Диңгез алласына багышланган гыйбадәтханә эчендә, тау уртасында, закон кагыйдәләре һәм законны бозган кешеләргә карата каргыш сүзләре язылган җиз багана тора. Атлантида патшалары җинаятьчеләрне язылган закон нигезендә хөкем итәләр.

Экономикасы, хәрби куәте һәм культура үсеше ягыннан Атлантида бик нык алга киткән була. Ләкин көтмәгәндә ул табигый бәла-каза корбанына әверелә — башкала урнашкан утрауда көчле вулкан ата. Атлантида һәлак була.

Платон заманыннан алып бүгенге көнгә кадәр фән дөньясында туктаусыз бәхәс бара. Атлантида чыннан да булганмы, әллә булмаганмы? Платонның язмалары бик күпләргә мавыктыргыч фантастика, әкият булып тоелган. Ләкин XX гасырда Крит утравындагы һәм Эгей диң-

гезенең башка утрауларындагы археологик ачышлар Атлантида мәсьәләсенә җитдирәк карарга мәҗбүр итә. Бүгенге көннең күп кенә атаклы галимнәре Атлантида ул Крит яисә Крит-Миной цивилизациясе булган дигән карашны яклый. Крит культурасы фактлары тулысынча диярлек Платон тасвирлаган Атлантида фактларына туры килә.

Атлантида утравы юкка чыкканда халыкның күпмедер өлеше, әлбәттә, һәлак булгандыр. Шулай да халыкның күпчелеге качып котылган — вулкан көле астында калган өйләрдә берниндि кеше сөякләре, кыйммәтле әйберләр табылмаган. Утрау кешеләре бик яхшы диңгезчеләр булганнар. Менә шул нәрсә аларны коткарган да инде. Качучылар төрле якка таралганнар. Бер җирдә алар башка халыкларга кушылырга мәҗбүр булсалар, икенче бер җирдә яңа шәһәрләр салып яңа дәүләтләр төзегәннәр. Атлантлар эзен Урта диңгез буе илләрендә дә, Урта диңгездән бик ерак төбәкләрдә дә табарга була. Мәсәлән, алар Көнбатыш Африкага һәм Кытайгача барып чыкканнар.

Төрки фактлар Крит культурасы һәм Платон тасвирлаган Атлантида фактларына туры килә. Монда шулай ук грек-латин дөньясына кагылышлы фактларны да күздән ычкындырырга ярамый. Грекларда туфан калкып, дөньяның асты өскә килүе, тау-ташлар җимерелүе, диңгезнең ярларыннан чыгуы һәм җир аллалары белән күк аллаларының сугышы турында төрле мифлар сөйләнелгән. Җирне селкетә торган куркыныч алла грекча Тифон дип атала. Тифон авызларыннан ут-ялкын бөрки торган йөз башлы җылан кыяфәтле. Аның тавышы әле аллалар тавышын хәтерләтә, әле ул эт булып өрә, арыслан булып ырылдый һәм җылан булып сызгыра. Тифон бөтен нәрсәне җимерә ала. Тифон татарча Туфан дигән сүз. Вулкан атканнан соң җиргә коела торган көл грекча «тефра» дип, Вулкан көле катканнан соң хасил булган таш «туф» дип атала. Тефраның да, туфның да әүвәлгечә әйтелеше — туфра, ягъни безнеңчә туфрак.

Татарда да туфан турындагы истәлекләр сакланган. Бала вакытымда миңа ниндидер изге бабайларны туфан харап итүе турында еш ишетергә туры килә торган иде. («Тегермәндә» хикәясе шуның тәэсирендә язылган.) XVIII гасырда яшәгән Хива ханы һәм тарихчысы Абул Гази язганча, туфан чыгасын белеп, Нух пәйгамбәр зур көймә ясаткан һәм туфан чыгып бөтен дөньяны су басканда, үзенең якын кешеләре белән көймәдә котылып калган. Берничә айдан су кире кайткан, җир ачылган. Нух үзенең өч улы, өч килене белән коры җиргә аяк баскан. Өч улы-

ның берсе Йәфәсне Нух төньяк җирләргә — Идел һәм Җаек буйларына җибәргән. С.Вахиди тарафыннан язып алынган татарча риваятьтә Нухның уллары Гази, Төрек һәм Алып дип атала.

Төньяк Европадагы борынгы фризләрнең бер язма әсәрендә Адланд дигән илнең табигый бәла-каза вакытында харап булуы, тау-ташларның җимерелүе һәм елгаларның элекке эзләреннән чыгуы турында әйтелә. Бәла-каза өч ел буе дәвам иткән — өч ел буе җәй булмаган, күктә кояш күренмәгән. Борынгы төркиләрнең «Ырк битиг» дип аталган әсәрендә дә космик һәлакәт турындагы риваять теркәлгән. Анда язылганча, бу вакытта «өстә караңгылык, аста тузан-туфрак була, ерткычлар, кошлар һәм җир уллары юлдан язалар». Мондый хәл өч елга сузыла.

Борынгы Криттә, язу-сызу эше белән бергә, исәп-хисап эшләре дә киң кулланылган. Монда бердән алып ун меңгә кадәр санау булган. Һәр санның үз билгесе булган. Язу материалы сыйфатында таш, металл, балчык, сөяк кебек әйберләрдән тыш агач, агач яфрагы һәм кәгазь кебек йомшак нәрсәләр һәм шулай ук язу карасы кулланылган дип уйланыла. Әйтелгәнчә, Атлантида белән диңгез алласының ун улы идарә иткән. Шунлыктан ун саны изге саналган.

Унлы бүленеш системасы Урта диңгез буе илләрендә һәм төрки халыкларда бик озак вакытлар дәвам иткән. Алтай төрекләренең килеп чыгышы турындагы легендаларда күршеләр белән сугыш вакытында ун яшьлек малайның исән калуы, ана бүренең иренә әйләнүе һәм ана бүренең ун ир бала табуы турында әйтелә. Борынгы төркиләр чорында «ун ук», «ун уйгур» дип аталган кабиләләр берләшмәсе була. Хазар каганы Иосифның X гасыр урталарында Хасдай ибн Шафрутка язган хатында Тогарманың (ягъни төрки патшаның) ун улы булуы турында әйтелә. XI гасырда яшәгән Мәхмүт Кашгари төрки кабиләләр санын егерме дип белә. Төрки гаскәрдә унлы бүленеш бик озак саклана. Иң кече гаскәри берәмлек ун кешелек этрәт булса, иң зур гаскәри берәмлек төмән, ягъни ун меңлек этрәт булган.

Борынгы Крит сарай калдыклары арасыннан археологлар тапкан төрле сыннарга һәм стеналарга ясалган сурәтләргә нигезләнеп, Крит-Атлантида кешеләренең тышкы кыяфәтләрен, кием-салымнарын шактый тулы итеп күз алдына китерергә була. Төрле сыннарда һәм сурәтләрдә ирләр дә, хатын-кызлар да озын чәчле. Ир сугышчылар ярым шәрә, чәчләре үрелгән. Хатын-кызларның да чәчләре үрелгән. Чигәләрендә бөдрә чәч бөртекләре тырпаеп тора.

Битләренә, иреннәренә кызыл сөртелгән. Изүләре ачык, күлмәк җиңнәре кыска, ләкин итәкләре киң һәм озын — аяк йөзенә төшеп тора. Ирләрнең дә, хатын-кызларның да муеннарында — муенса. Алиһәләр дип уйланылган сыннарның өстендә кыска гына алъяпкыч һәм җиде балаитәкле озын күлмәк. Башларында хикмәтле баш киемнәре. Берсенең баш киеме биек конусны хәтерләтә. Конусның өстендә сары төстәге шар калкып тора.

Урта гасыр кыпчакларның таш сыннарында ирләр дә, хатын-кызлар да сурәтләнгән. Кыпчак хатын-кызларның баш киемнәре Крит сарайларында табылган алиһәләрнең баш киеменә охшаш. Ирләрнең чәч үстерүе мәсьәләсенә килгәндә, моны да бик борынгы төрки йола дип исәпләргә кирәк. Кайбер төрки халыкларда ирләр әле XX гасырның 30 нчы елларына кадәр чәчләрен озын итеп үстереп, үреп йөрткәннәр. Ир сугышчыларны сурәтләгән кыпчак сыннарында да озын чәч толымнарын күрергә була. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәрендә Йосыфның озын чәчле булуы һәм аның шул озын чәчен Зөләйханың үз куллары белән үрүе турында әйтелә.

Крит сарайлары, авыллар, шәһәрләр үзәклек принцибы нигезендә салынган. Бу принципның асылы шуңа кайтып кала: барлык бүлмәләр яисә барлык өйләр бер үзәк — баш кешенең торагы тирәсенә туплана. Шунлыктан сарайлардагы, авыл-шәһәрләрдәге бүлмәләрнең һәм өйләрнең урнашу тәртибе беренче карашка чуалчык булып тоелырга мөмкин. Атаклы Кнос сараен фәнни әдәбиятта «лабиринт» дип тә атыйлар. Бу сүз монда «чуалчык» дигәнне белдерә. Криттә казып табылган борынгы авыл-шәһәрләрдәге өйләрнең урнашу тәртибе дә шактый буталчык. Алар күзгә күренмәгән түгәрәк яисә ярым түгәрәк рәвештә урнашканнар.

Төрле чордагы күчмә һәм утрак төркиләрнең авыл-шәһәр булып утыру тәртибе дә тулысынча үзәклек принцибына туры килә. «Бик күп татар авылларының иске планнарын анализлап караганнан соң, В.В.Егерев... төрле ягына йортлар урнашкан, ат белән керү өчен бер аралыгы — еш кына очракта тупик рәвешендә тәмамлана торган аралыгы булган түгәрәкне элекке татар авылының төп күзәнәге булып тора дигән нәтиҗәгә килә» дип яза этнограф Н.И.Воробьев. Татарда авыллар гына түгел, аерым йортлар да үзәклек принцибында салынган, өйнең алгы ягы урамга чыгарылмаган; урам яктан өйне койма-киртә каплап торган. Баерак кешеләрнең өйләре, дини корылмалар бөтенләй диярлек ишегалды уртасына салына торган булган.

Хәзер тагын Атлантиданы искә төшерик. Башкала

үзәгенә таба диңгездән канал үткәрелгән. Каналдан диңгез кораблары үзәккә кадәр бара алганнар. Иске татар авылларында да ат белән керү өчен бер аралык була. Фест дисбесенең ике ягындагы рәсем-билгеләр спираль сыман уралган янәшә сызыклардагы шакмакларга урнаштырылган дидек. Укуны башлап киткән төштә ике якта да тар гына берәр аралык бар.

Очраклы хәлме боларның барысы да? Юк, очраклы түгел. Фест язуының түгәрәк формадагы балчык тактага төшерелүе һәм андагы спираль сызыклар Атлантида башкаласының киң үзәндә урнашу тәртибен, аның «топографик картасын» чагылдыра. Ләкин шул ук вакытта Атлантида башкаласы да, Фест дисбесе дә һәм иске татар авылларының планировкасы да... бөгәрләнеп яткан җыланны күз алдында тота! Бик борынгы төркиләрдә бөгәрләнеп яткан җылан исә кояш символы исәпләнелгән. Төркиләр гомер-гомергә кояшка табынганнар.

Урта диңгез бассейны илләрендә Крит-Атлантида культурасының тәэсире бик көчле булган. Грек мифларында әйтелгәнчә, грекларның беренче шәһәрләрен туфаннан котылган беренче кешеләр салган. Болар, гадәттә, Крит кешеләре булган. Язма законнарны, дәүләт идарәсе кагыйдәләрен, эш-сугыш коралы төрләрен һ.б. бик күп нәрсәне греклар Криттан һәм башка утраулардан алганнар. Без белгән борынгы грек фәне, әдәбияты, сәнгате иң элек Кече Азия җирендә — Иониядә барлыкка килгән. Иония шәһәрләрендә туфаннан качып котылган элекке атлантлар — карлар, мисләр, лидләр һ.б. күп булган. «Тарих атасы» Геродот, мәсәлән, кар нәселеннән булган. Геродот Кече Азиядәге Кария патшалыгының башкаласы Галикарнас (Гали Кар, нас) шәһәрендә туган. Татарстанда берничә Кариле (Кар иле) авылы бар.

Мифологиядә, этнографиядә, телдә, фольклорда грек-төрки уртаклыкларны күпләп табарга мөмкин. Мәсәлән, канатлы атлар төркиләрдә дә, грекларда да була. Грек мифларында сыңар күзле циклоплар турында сөйләнелә. Татар әкиятләрендә диюләр, дию пәриләре, убырлы карчык Җалмавыз еш кына сыңар күзле була. Грек мифларында Прокна һәм Филомена дигән бертуган кызларның кошка әйләнүе турында әйтелә. Татарның иң борынгы бәетләреннән исәпләнелгән Сак-Сок бәетендә кошка әйләнгән бертуган балалар турында сүз бара. Грекларның Персей белән Даная турындагы мифының сюжеты «Таһир-Зөһрә» сюжетына охшаш. Гомерның «Одиссея»-се белән төркиләрнең «Алпамыш» («Алпамша») дастаны шулай ук охшаш сюжетка корылган.

Грекларның алла исемнәрен тикшереп карагач, аларның күбесенең төрки икәнлеге ачыклана. Гректа иң бөек алла Зевс дип аталган. Ул, имеш, Крит утравында туган. Геродот күпчелек грек аллалары Мисырдан алынган ди. Бу бик борынгы чорлардагы Мисыр — Крит (Атлантида) уртаклыгына ишарәли. Зевс сүзенең әүвәлгерәк формасын без Җәбәс (Җәфәс яки Йәфәс) дип беләбез. Йәфәс — төрки халыкларның ата-бабасы, Нух пәйгамбәрнең улы. Грекларның иң атаклы алиһәләре Афинаның исеме дә төрки. Бу сүзне Аф (аб) инә яисә (Н)әф инә дип беләбез. Һәр ике очракта бу «изге инә» дигәнгә туры килә. Әйтергә кирәк, грек исемнәрендә ана-она, ина (инә), апа-опа, ага сүзләре еш очрый.

Борынгы грекларда пан дигән алла булган. Пан — урман һәм әрәмәләр алласы. Панга Аркадия (ягъни Арка) өлкәсендә табынганнар. Әлеге алланың «бөек Пан» дигән атамасы да булган. Бөек Панның «чын йөзе» татарча Талпан сүзендә күренә. Талпан ул «урман бете». Сүзне Тал пан рәвешендә таркатсак, бу чыннан да «бөек Пан» булачак.

Крит утравында әле бүгенге көндә дә Татарстандагы, Башкортстандагы авыл-шәһәр, елга, тау исемнәренә туры килә торган исем-атамалар очрый. Мәсәлән, шундыйлардан Багалы (Татарстанда, Башкортстанда — Бакалы), Вутас (Татарстанда — Бута), Катарос (Башкортстанда — Катарыш), Кундуро (Татарстанда — Кондырлы), Матала (Башкортстанда — Мәтәле), Саба, Сикия, Сулия (Татарстанда — Саба, Сикия, Сүлә) атамаларын күрсәтергә була.

Урта диңгез бассейны илләре картасында төрки топонимнарның, гомумән, исәбе-хисабы юк. (Монда бүгенге Төркия топонимиясе күз алдында тотылмый.) Мәсәлән, Хиос утравында элек Пелиней дигән тау булган. Сүзне «Пел иней» дип икегә бүлсәк, безнең өчен аңлашылмаган берни калмаячак. Пел бүгенге татар телендә «көр», «симез» дигәнне белдерә. Иней — инәй, ягъни әни. Төньяк Африкада, Триполигә якын җирдә элек Сарман авылы, Испаниядә Кармон шәһәре булган. Татарстанда, Башкортстанда Сарман, Карман авыллары бар. Италиядә, Кече Азиядә Кима, Кимы (Кумы) шәһәрләре булган. Татарстанда Күлле Киме бар.

Бүгенге медицинада «анатомия» сүзе киң кулланыла. Сүзнең грекча формасы — анатоме. Моны без ана томе дип икегә бүләбез. «Ана» болай да аңлашыла. «Томе» дигәне тума, ягъни «улы». Хәзерге татар телендә «шәрә» мәгънәсендә анадан тума сүзе кулланыла. Татар теленең Нократ сөйләшендә бу сүз ана-тума рәвешендә әйтелә.

Анатомия, билгеле булганча, ана-тума кешеләр белән эш итә дә инде. Борынгы грекларның патшалары басилей дип аталган. Сүзне бас ил ай дип таркатабыз. Бу — төркигә кире тәртиптә ялганган төрки сүзләр җыелмасы. Моның төркичәсе: ил, эй (өй) басы (башы) булыр иде.

Грек чыганакларында бүгенге татарларда актив кулланылган кеше исемнәренең очравын да әйтеп үтәргә кирәк. Мәсәлән шундыйлардан (русча язылышта) Алкей, Алфея, Асия, Галия, Талия, Фалия, Даная, Давлий, Наркисс, Фаилл, Эдип һ.б. исемнәрне күрсәтә алабыз.

Урта диңгездә көймәләрдә йөзүне иң элек Крит-Миной культурасы кешеләре үзләштергән дип исәплиләр. Татар әкиятләрендә, әйтем-мәкальләрдә, җырларда, табышмакларда «диңгез», «көймә» сүзләре еш кулланыла. Телдә диңгез тубыктан, көймәсе комга терәлде, төпсез көймәгә утыртты, ике көймәнең койрыгын киң тотып булмый кебек сүзләр бар. Телдә шулай ук «таш» катнашында язылган сүз тезмәләре дә күп. Мәсәлән, ташка басу, таш басма, ташка тамга салган, ташка үлчим, таш яру, таш кисү, таш курчак һ.б. Монда тагын таш яуса, таш яңгыр, җир йотсын, җир упсын, кызыл кар яугач кебек сүз тезмәләрен дә искә төшерә алабыз. «Таулар янсын, ташлар яусын» диелә халык җырында. Һәркемгә мәгълүм — без яшәгән якларда таш та, кызыл кар да яумый, таулар да янмый. Мондый гайре табигый хәлләр бары вулкан атканда, туфан калыкканда гына була ала. Моннан өч-дүрт мең еллар элек Урта диңгезнең көнчыгышында нәкъ менә шундый туфан калыккан һәм серле Атлантида да шул вакытта һәлак булган да инде.

*1991*

## САБА

Әзме-күпме географиядән мәгълүматы булган һәркем Италияне, Римне белә дип әйтик. Әзме-күпме тарихтан мәгълүматы булган һәркем шуны да беләдер: моннан икеөч мең еллар элек Италия җирендә борынгы Рим дәүләте барлыкка килгән. Римлеләр күршеләре белән туктаусыз сугыш алып барганнар, Римдә колбиләүчелек алга киткән, коллар җитәкчесе Спартак безнең эрага кадәр 74—71 елларда хуҗаларга каршы баш күтәргән, римлеләрнең Юлий Цезарь, Август кебек атаклы императорлары булган һәм башкалар, һәм башкалар...

Тарих белән ныграк кызыксынган кеше Рим һәм римлеләр турында, ихтимал, бүтән төрле фактларны да беләдер. Ләкин Италиянең, Римнең, Спартак һәм императорларның безгә — бүгенге татарларга турыдан-туры катнашы барлыгын кемнәр генә белә икән? Андый кеше дөньяга тумагандыр әле дип әйтер идем, шулай да бу бик үк дөрес тә булмас шикелле.

Борынгы Рим дәүләте барлыкка килгәнче Италиянең урта бер өлешендәрәк этрусклар хакимлек иткән. Этрусклар дәүләте унике шәһәр берләшмәсеннән торган. Заманында этрусклар якын-тирәдәге иң көчле һәм алдынгы халык исәпләнгәннәр. Рим дәүләте менә шул этрусклар җирендә, этрусклар тәэсирендә барлыкка килгән. Борынгы римлеләр культурасы этрусклар культурасының дәвамы булып тора. Бүгенге тарих фәнендә шундый караш бар.

Этрускларның нинди телдә сөйләшүләре турында төрле фикерләр әйтелгән. Чит илләрдә (мәсәлән, Төркиядә) этрускларның төрки булуы ихтималы турында да язалар. Бездә, русча фәнни хезмәтләрдә, этрускларның төрки булуы-булмавы телгә дә алынмый. Ләм-мим. Формасы һәм мәгънәсе белән күрәләтә төрки булган этруск сүзләрен тикшергәндә дә рус телле галимнәр андый сүзләрне «семит» яисә «һинд-европа» дип аңлату җаен табалар.

Борынгы Италиядә Рим шәһәре барлыкка килгәнче үк инде этрусклардан кала тагын бер атаклы халык яшәгән. Монысы саба дип атала. Саба? Нинди саба? Саба ул бездә — Татарстанда! диярсез, бәлки. Әйе, бүгенге көнгәчә үз исемен саклап калган, исән-имин яшәп яткан Саба, сабалар бары бездә генә — Татар җирендә генә. Казаннан берничә километр читтәрәк Саба районы бар. Саба районында Сабабаш, Байлар Сабасы, Чәбки Саба, Урта Саба, Сабанай һ.б. авыллар бар. Сабабаш авылында Саба елгасы агып ята. Саба районында сабалар яши. Саба районы 1930 елның 10 августында төзелгән. Саба авылы

Казан ханлыгы чорында да булган. 1184 елгы вакыйгалар уңае белән Саба (Собакули) рус елъязмаларында да телгә алына. 1184 елда руслар белән болгарлар арасында сугыш булган. Болгарның бер кабиләсе сабалар, әлбәттә, болгар патшасы ягында торып сугышканнар.

Саба районы Татарстанның төньяк-көнчыгышында, республика башкаласыннан көнчыгыштарак урнашкан кебек, борынгы Италиядәге Саба өлкәсе дә Римнән... төньяк-көнчыгышта, 30—40 километр чамасы читтәрәк урнашкан булган. Бу, бәлки, очраклы хәлдер, тик шулай да монда ниндидер мәгънә дә бар сыман. Борынгы карталарда Саба иле көньяк-көнчыгыштан төньяк-көнчыгышка таба сузылган, көньяк чиге беркадәр киңәя төшкән территория итеп күрсәтелә. Сабаларның көнбатышында этрусклар, төньягында умбрлар, көнчыгышында пиценнәр, көньягында латиннар яшәгән. Борынгы Италиядә сабалар нәселеннән исәпләнгән пелигннәр, марруциннәр, марслар, герникләр һ.б. кабиләләр дә булган. Аларның барысын бергә сабеллар дип атаганнар. Саба иле таулы, калкулы җирләрдән гыйбарәт булган.

Рим шәһәре этрусклар, сабалар, латиннар күрше булып, үзара аралашып яшәгән төбәктә, Тибр елгасы буенда барлыкка килгән. Тибр елгасы борынгырак заманнарда Албула дип аталган. Татарстанда Була елгасы бар. Рим шәһәре б.э.к. 753 елда салынган. Б.э.к. 509 елга кадәр, ягъни дүрт йөз елдан артыграк Римдә патшалар хакимлек иткән. Шуннан соң республика чоры башланган һәм б.э.к. 27 елга кадәр дәвам иткән. 27 елдан соң Римдә хәрби монархия (империя) урнаша. Рим империясе V гасырга кадәр яши — 476 елда Көнбатыш Рим империясенең соңгы императоры Ромул Августул тәхеттән бәреп төшерелә.

Рим дәүләтенең рәсми теле латин теле булган. Латин теле бүген үле тел дип санала. Латин алфавиты этруск алфавиты нигезендә барлыкка килгән. Бу хәл б.э.к. VII гасырда булган дип уйланыла. Латин телендәге иң беренче язма истәлек тә шушы чорга карый. Б.э.к. чорның соңгы гасырларында һәм б.э. башларында латин теле көчәеп китә. Рәсми, фәнни, әдәби әсәрләрнең иң зур күпчелеге шушы заманнарда иҗат ителгән һәм бүгенге көндә билгеле булган латин теле сүзлекләре шулар нигезендә төзелгән. Римнең әүвәлге чоры турында бернинди ышанычлы язма истәлекләр юк дип әйтерлек. Бу чор турында сөйләгәндә галимнәр күбрәк мифларга, археологиягә һәм соңгырак гасырларда язылган грекча-латинча хезмәтләргә таянып фикер йөртәләр.

Татарстандагы сабаларның төркилегенә без әз генә дә

шикләнмибез. Ләкин Италия җирендәге сабалар да төрки микән соң? Әйтик, б.э.к. VIII гасырдагы сабалар төрки булган булсалар да, аларның төркилеген нәрсәгә нигезләнеп исбат итәргә? Ике-өч мең ел эчендә аларның әүвәлге теле онытылып беткән булырга тиеш түгелмени? Алай ук түгел икән шул. Рим тарихына караган мифларда, грек-латин әсәрләрендә бик күп төрки сүзләр, исем-атамалар сакланып калган.

Без белгән латин теле, әлбәттә, төрки түгел. Әгәр төрки булмаган телдә дә төрки элементлар күпләп сакланган икән, моның ниндидер сәбәпләре булырга тиеш. Сәбәпләрнең иң беренчесе шул: борынгы заманнарда төрки тел киң таралган булган. Борынгы Мисырның, Шумерның әүвәлге чорлары — төрки. Урта диңгез бассейнының грекларга кадәрге культурасы төрки. Дингә, мифологиягә, дәүләт идарәсенә кагылышлы сүзләрнең, исем-атамаларның күбесе иң элек төрки телләрдә барлыкка килгән. Икенче сәбәп шул: Рим шәһәренә, Рим дәүләтенә төркиләр — сабалар, этруслар нигез салганнар. Латин теле, җиңүче тел булса да, аның кайчан, ничек өстен чыгуы, әүвәлге чорда ни рәвешле булуы бик ук билгеле түгел. Латин кабиләләре теле турында сөйләгәндә галимнәр күбрәк исем-атамаларга мөрәҗәгать итәләр. Ләкин белгечләр латинныкы дип исәпләнгән исем-атамалар да еш кына төрки булып чыга.

Латиннарның беренче патшасы Ромул дип атала. Мифларда әйтелгәнчә, Ромулның һәм аның игезәк туганы Ремның анасы Рея Силвия исемле хатын, атасы — сугыш алласы Марс була. Сабый вакытларында Ромул белән Ремны Тибр елгасына ташлыйлар, елга дулкыны балаларны ярга чыгара. Яр буендагы ана бүре аларны үз өненә алып кайта, имезә, үстерә. Үскәч Ромул патша була, күп кенә изге эшләр башкара һәм тере килеш күккә ашып, аллага әверелә.

Ромул чорыннан соңгырак һәм Италиядән бик еракта яшәгән Алтай төркиләренең килеп чыгышы турында да әлеге мифка охшаш легенда сөйләнелгән. Алтай төркиләренең нәсел башы сугышта кырылып беткән ыруның исән калган бердәнбер малае булган. Яраланган малайны ана бүре табып алган, имезгән, үстергән һәм соңыннан аның хатыны булган. Алтай төркиләре, имеш, әлеге малайдан һәм ана бүредән туып, үрчеп киткәннәр.

Күрәсез, борынгы римлеләр дә, Алтай төркиләре дә — бүре балалары. Хәзер инде бөек Ромул исеменә игътибар итеп карыйк. Исемнең ахыргы ул иҗекләре турында сүз куертып торасы да юк кебек. Бу — улы, малае, баласы дигәнен белдерә. Ром нәрсә? Моны без Рам дип төзәтәбез һәм Ра-м дип таркатабыз. Ра — кояш, Ра-м — кояш улы.

Борынгы карашлар нигезендә, бүре дә, арыслан да, кошлар да — гомумән барлык хәрәкәтчән нәрсә — Кояш улы. Изгеләр, аллага якын кешеләр, халык белән идарә итүче патшалар Кояш уллары яисә Кояш улларының уллары. Рам ул кайчандыр менә шундый шәхес булган, ахрысы. Татарда Рам, Рәм иҗекләре ярдәмендә ясалган Рамазан, Рамиз, Рамис, Рамил, Рамус, Рәми, Рәмзи кебек исемнәр бар.

Югарыда телгә алынган соңгы император Ромул Августул исеменең икесе дә «ул»га тәмамлана. «Ромул»ны императорның шәхси исеме, Августул аның нәселен — хәзергечә әйткәндә, фамилиясен белдерә. Шулай итеп, ахыргы *ул* фамилия күрсәткече хезмәтен үти. Борынгы римлеләрдә *ул-ула, оли-ола* иҗекләренә тәмамланган исем-атамалар еш очрый. Мәсәлән, Авиола, Марул, Кариолы. Шундый ук иҗекләргә тәмамланган исем-фамилияләр бүгенге итальяннарда да бар. Мәсәлән, Кастаньоли, Пиганьоли, Джильоли. Соңгы фамилия аеруча игътибарга лаек. Җил улы, имеш! Ягъни Җилдән туган. Бүгенге көндә татарда «җилдән туган» кире мәгънәдәрәк әйтелә. Ләкин элегрәк бары изгеләр генә Җилдән туа алганнар. Ромулның әнисе Рейә Силвия «фамилия»сендәге Сил иҗекләрен дә Җил дип төзәтә алабыз. Җил бийә ул Җил хатыны, ягъни алиһә дигәнне аңлата. Алиһәнең шәхси исеме дә изге. Рейәнең мәгънәсе янә Кояш улы яисә Кояш хатыны дигәнгә туры килә.

Рим шәһәренең халкы баштарак бик аз була. Яңа башкаланың халкын күбәйтү максатында, Ромул патша римлеләр бәйрәменә бервакыт күрше сабаларны да чакыра. Бәйрәм вакытында римлеләр саба кызларын урлап китәләр. Шушы хәлдән соң Рим белән Саба арасында сугыш башлана. Саба кызлары, хатыннары шулай да сугышны туктатуга ирешәләр. Шуннан соң сабалар белән латиннар арасында мәңгелек дуслык урнаша. Бу замандагы сабаларның патшасы Тит Таци дип атала. Тит исеме татарда сакланмаган, ләкин Тит урыста бар. Тацины без Таҗи дип төзәтәбез. Грек-латин әсәрләрендә кайбер саба кызларының исемнәре дә сакланып калган. Шулар арасында Фауция, Тиция, Велития, Аккулея кебек исемнәр бар. Фауцияне Фәүзия дип беләбез. Велитияне Вәлитийә дип, Аккулеяне Ак куллы яки Кулы ак дип аңларга була. Татарда Вәлит-Вәлидә кебек исемнәр бар. Бу әлеге Велитиянең кыскарган варианты булса кирәк.

Бүгенге көндә руста актив кулланылган Валери исеме элек сабаларныкы булган. Борынгы Римдә Валерийләр нәселе иң атаклыларның берсе саналган. Русның бүгенге исемнәрен, гадәттә, христиан дине белән гректан алын-

ган дип аңлаталар. Тикшерә торгач, кайбер исемнәр грекныкы да, латинныкы да түгел, бәлки төркиләрнеке булып чыга. Сирәк булса да, татарда Валери дә, Вадим — Вәдим дә очрый. Шулай да Серги дигән исем юк, ахрысы. Баксаң, Серги дә төрки икән. Итальяннарда бу исемнең Серджи формасы бар. Борынгы төрки телдә *г* тартыгы белән *җ* тартыгы бер-берсен алыштыра алган. Татарда, мәсәлән, гәүһәр дә, җәүһәр дә бар. Русча язылыштагы Серджи, итальянча Серҗи гап-гади Сер-че дигән сүз. Шулай итеп, Сергий, Серги чынлыкта Серче икән.

Ромул чорында яшәгән атаклы саба кешеләренең берсе Атти Клавз дип атала. Аттине латиннар Аппи, Клавзны Клавди дип үзгәрткәннәр. Борынгы Римдә Клавз-Клавдиләр шулай ук атаклы саналган. Клавз-Клавдиләрдән Римдә патшалар, консуллар, императорлар һ.б. эшлеклеләр үсеп чыккан. Атти сүзен без Ат Ти, ягъни «бөек Ти» дип аңлатабыз. *Ти* ул *би*нең *т* варианты. Би исә элегрәк төркиләрдә патша-хаким дә, Алла да була алган. Гуннар патшасы Аттила дип аталган. Клавзның тулырак формасы — Кылавыз. Төрки телдә кылавыз «юл күрсәтүче», «лоцман» дигәнне белдерә.

69—79 елларда Рим императоры булган Тит Флави Веспасиан Саба иленең башкаласы Реата (Атабыз Ре, ягъни «Атабыз Кояш») исемле шәһәр янындагы Фелакрина авылында туган. Веспасианның әтисе ягыннан дәү әнисе Тертулла (Дүрт уллы?) дип аталган. Веспасиан кушаматының каян килеп чыгуын аңлатып, тарихчы Светоний: «Нурсиядән Сполецигә барганда, тау башында, алтынчы миль янында Веспаси дигән җир дә бар», дип яза (VIII, I, 3). «Алтынчы мильне гадиләштереп алтынчы чакрым баганасы дип аңлыйбыз. Римдә юл буйларына таштан чакрым баганалары куелган булган. Алтынчы багана янында йә җиденче, йә бишенче багана гына булырга мөмкин. Монда, күрәсең, бишенче багана турында сүз бара. Император кушаматының Вес иҗекләре шул турыда сөйли. Паси яки пас «багана» була аламы соң? Моны без багана дип түгел, бәлки тас (таш) дип аңлыйбыз. Латин телендә Атти Аппигә әйләнә алган кебек, тас (таш) сүзе дә «пас»ка әйләнә алган дип уйларга кирәк.

Рим тарихында зур роль уйнаган саба кешеләреннән тагын Нума Помпили исемен дә еш телгә алалар. Нума Помпили Римнең Ромулдан соңгы икенче патшасы исәпләнелә. Ул Саба иленең Кура шәһәрендә туган, б.э.к. 715—673 елларда тәхеттә утырган. Тарихчы Тет Ливи язганча, Нума «аллалар һәм кешеләр хокукы турында ул заманнарда белергә мөмкин булган бар нәрсәнең бөек белгече»

булган (I, 18, 1). Нума Римдә динчеләр, һөнәрчеләр берләшмәсе оештыра, җир биләү тәртипләрен җайга сала. Бүгенге галимнәр исәпләгәнчә, римлеләрнең җир биләү законнары Саба җир биләү хокукы нигезендә барлыкка килгән. Римдәге дини йолаларның, законнарның, дини бәйрәмнәрнең башлангычы да Нумага бәйле рәвештә аңлатыла. Мәсәлән, Вестада (Бистәдә) мәңгелек утны саклау, яшен суккан кешене гадәти күмү йолаларыннан мәхрүм итү тәртипләрен иң элек Нума Помпили законлаштырган. Ибн Фадлан язганча, Идел буе болгарлары да яшен суккан кешене, хайваннарны күмеп тормыйча бар нәрсәне ташлап, икенче җиргә күченеп китә торган булганнар.

Валериләр нәселенең когномены («фамилия» кушаматы) Публикола дип аталган. Публиколаның мәгънәсе «халык дусты», «халык хезмәтчесе» икән. Әлеге кушаматны публи һәм кола иҗекләренә бүлеп карагыз әле, берәр таныш сүз килеп чыкмасмы? Чыга. Ул да булса, кола, ягъни колы. Халык колы «халык дусты», «халык хезмәтчесе» булмыйча, тагын кем булыр икән?! Безгә шулай ук публи дә таныш. Рустан алынган яисә русча формада кулланыла торган публика, публичный, публицистика, публицист кебек сүзләрнең барысы да латинча публигә кайтып кала. Публи латинда халык, халыкныкы, дәүләт, дәүләтнеке, халык массасы, күпчелек дигәнне аңлата. Хәер, сүзлекләргә карамыйча да публинең күпли (күпле) икәнлегенә төшенүе читен түгел.

Татар һәм латин телләрендә *т* һәм *к* тартыклары еш кына бер-берсен алыштырып килә алалар. Шул ук вакытта бу тартыклар кайчагында *б, п, ф* тартыкларына да күчә алалар. Күпле, күпчелек, шулай итеп, «халык» һәм «публика» була ала. Шушы уңайдан файдаланып, киң таралган һәм латинныкы исәпләнгән *республика* сүзенә тукталып китәсе килә. Римне, Рим дәүләтен төркиләр төзегән дидек без. Республика сүзе шуңа тагын бер дәлил була ала.

Публи, публиканың нәрсә аңлатканын белдек дип исәплик. Рес нәрсә? Татарда рәсми дигән сүз дәүләткә, югары дәрәҗәдәге идарәгә кагылышлы нәрсәне аңлата. Рәс һәм ми иҗекләренең урыннарын алыштырып мирас сүзе ясыйбыз. Мирас, белүебезчә, ата-бабадан, халыктан калган матди һәм рухи байлыкны күз алдында тота. Шулай итеп, республика — халык байлыгы, халык мөлкәте, халык идарәсе дигәнне аңлата икән дип әйтә алабыз.

Римнең кайбер атаклы дәүләт эшлеклеләре генә түгел, кайбер атаклы галимнәре, фикер ияләре, шагыйрьләре-язучылары да сабалар нәселеннән булган. Мәсәлән, элекке саба кешесе — император Нерон чорында танылган хо-

кук белгече Мазури Сабин яшәгән. Целий Сабин, Гай Сабин, Поппей Сабин төрле чорда консул (ике елга сайлап куелган дәүләт башлыгы) булганнар. Сиксән яшендә «Авыл хуҗалыгы» дигән китап язган Варрон, тарихчы Гай Саллюстий Крисп шулай ук Саба илендә туганнар. Сабалар нәселе пелигннәрнең Сульмон (Чулман?) шәһәрендә б.э.к. 43 елда борынгы заманның бөек шагыйре Публи Овиди Назон туган.

Тарихи хезмәтләрдә сабалар хакында күп кенә мактау сүзләре әйтелә. Элекке авторлар саба ирләренең кырыс табигатьле, батыр сугышчы, хатын-кызларның — сафлык һәм тугрылык үрнәге булулары турында язалар. Грек язучысы Страбон «География» китабында тарихчы Фабиның: «шушы кабиләнең (ягъни сабаларның.— *Н.Ф.*) хуҗасына әйләнгәч кенә римлеләр үзләренең нинди зур байлыкка ия булганлыкларын аңлый алдылар» (V, III, I) дигән сүзләрен теркәп калдырган.

Күпчелек тарихчылар сабаларны борынгы Италиянең үз халкы дип исәпләгән һәм исәпли. Ләкин кайберәүләр, күрәсең, батыр һәм кырыс холыклы булганга, аларны Спартадан күченеп килгән дип уйлаганнар. Спарта, белүебезчә, Италиядә түгел, Греция җирендә булган. Кайчандыр сабалар чыннан да Спартадан күченеп килгән булырга да мөмкиннәр. Ләкин Спарта кешеләре үзләре каян күчендеЛәр икән соң? Геродот әйткәнчә, Спартаның күп кенә йолалары, аллалары Мисырдан алынган икән. Сабаларның да кайбер җеп очлары шул якка сузыла. Мәсәлән, Нума Помпилинең исеме мисырлыларның дөньяны барлыкка китерүче Нун аллалары исеменә якын. Нуманы хәтта Нунның *м* варианты дип атарга да була. Нун латин телендә («нундин» сүзендә) тугыз дигәнне белдерә. Татарның «ун» саны шул ук Нуннан алынган. Бүгенге көндә дә латин теле рәсми тел исәпләнгән Ватиканда нунци, ягъни нунчы сүзе «папа илчесе»н аңлата. Шулай итеп, бөтен дөнья католикларының дин башлыгы папа үзен борынгы Мисыр алласы Нунга тиңли булып чыга!

Римдәге җир биләү тәртипләренең, дини йолаларның башлангычын сабаларга бәйле рәвештә аңлатуның йомшак ягы бар. Артык зур булмаган таулы өлкәдә яшәүче сабаларның тора салып дигәндәй җир биләү һәм дини йолалар мәсьәләсендә башкаларга караганда алдынгырак булулары шиклерәк. Мондый нәрсәләр күп гасырлык тәҗрибә нигезендә генә барлыкка килергә мөмкин. Андый тәҗрибәне сабалар каяндыр читтән, ерактан алып килгәннәр дип фикер йөртү урынлырак тоела. Игенчелек, малчылык, һөнәрчелек шулай ук дин һәм дини йо-

лалар тәҗрибәсе, билгеле булганча, кешелекнең иң әүвәлге цивилизация учаклары Мисырда һәм Шумерда барлыкка килгән. Тагын бер мисал: Атлантида төркиләренең һәм алардан соңгырак грекларның калканнары түгәрәк, сабаларныкы — озынча. Мисырлыларның калканнары шулай ук озынча.

Сабалар борынгы Италиядә генә түгел, дөньяның икенче бер почмагында — Кызыл диңгез яры буйларында да яшәгәннәр. Бүгенге Йәмән республикасы территориясендә бөтен дөньяга атаклы Саба дәүләте булган. Мондагы Саба б.э.к. II мең еллыкта, ягъни Римнән кимендә мең, мең ярым еллар элегрәк барлыкка килгән һәм безнең эраның VI гасырына кадәр яшәгән. Саба дәүләтен грек-латин язучылары да белә, Саба Коръәндә, Библиядә телгә алына. Ислам диненең барлыкка килүендә сабаларның, саба диненең күпмедер дәрәҗәдә катнашы бар. Грек-латин истәлекләрендә бу илне Бәхетле Гарәбстан дип тә йөртәләр. Страбонның «География»сендә Сабага, Бәхетле Гарәбстанга күп кенә урын бирелгән.

Гарәбстан ярымутравының көньяк-көнбатыш өлешендә дүрт зур кабилә яши ди Страбон, үзеннән ике гасыр элегрәк язган Эратосфен сүзләренә нигезләнеп. Кызыл диңгез буендагы беренче кабилә миней дип атала. Аларның иң зур шәһәре Карна яисә Карнана исемле. Минейләрдән көньяктарак — сабейлар. Аларның башкаласы — Мариаба. Сабейлардан төньяк-көнчыгыштарак — каттабаналар. Аларның башкаласы — Тамна. Иң читтәге кабиләнең исеме Хатроматит, башкалалары — Сабата дип атала (XVI, IV, 2). Гарәбстан ярымутравының көньяк-көнбатыш кырыенда, Кызыл диңгез буенда рамманитлар кабиләсе дә була. Рамманитлар кабиләсенең башкаласы Марсиаба, патшалары Иласар дип атала (XVI, IV, 24).

Мисалга китерелгән исем-атамаларның барысын да төрки тел ярдәмендә аңлатырга була. Мәсәлән, миней, сабей дип аталган кабилә исемнәрен Мин өе, Саб (Саба) өе дип беләбез. «Өе» монда кабиләнең иле-җире, яшәү урыны дигәнгә туры килә. Сабаның кемлеген беләбез, Мингә килгәндә,— борынгы заманда шундый исемле төрки кабилә булган. Мариаба, Марсиаба исемнәрендәге аба да безгә таныш. Аба ул ата-баба, нәсел башы дигәнне белдерә. Бу уңайдан римлеләрнең сугыш алласы Марсны искә төшерәбез. Марс чынлыкта сабалар яисә этрусклар алласы. Март аеның исеме шуннан алынган. Март кына түгел, май, июнь (юни), июль (юли) айларының исемнәре дә төрки. Иласар кеше исеме түгел, бәлки патшаның титулы булса кирәк. Ила сар, ягъни ил сары (патшасы) дигән сүз.

Борынгы Саба территориясендәге әлеге кабиләләр, башкалар турында сөйләгәндә Страбон безнең өчен бик әһәмиятле бер фактны теркәп калдырган. «Аларның өрлекләре мисырлылар ысулы белән тоташтырылган, шунлыктан торак йортлар мисыр йортларына охшаш», ди Страбон (XVI, IV, 3).

Сабейлар яисә сабалар Гарәбстан ярымутравына каршы якта — Африка территориясендә дә булалар. Кызыл диңгез яры буенда Нил елгасының Сабаит дигән тамагы, аннан көньяктарак Саба дигән порт һәм шул исемдәге «фил аулау урыны» була. Яр буеннан читтәге өлкә Тенессис дип атала. Анда Псамметихка каршы баш күтәргән мисырлылар яши, ди Страбон (XVI, IV, 8). Күрәсез, тагын Саба һәм мисырлылар Гарәбстан ярымутравының иң кырыйдагы, көньяктагы борынына каршы якта сабейларның Береника һәм Саба дигән шәһәрләре була (XVI, IV, 10).

Саба кабиләләре яшәгән җирләр кайчандыр гөрләп чәчәк аткан — тауларда, үзәннәрдә күкрәп урманнар үскән, шаулап елгалар аккан. Саба бай һәм бәхетле ил булган. Хәзер мондагы җирләр ташландык чүлне хәтерләтә. Монда хәзер урманнар да үсми, елгалар да акмый. Шәп-шәрә. Тау да таш, таш та ком. Бәхетле Гарәбстанда көчле вулканнар аткан, бәхетле Сабаны бер-бер артлы күршеләре яулап алган.

Элекке Саба җирләрендә археологлар адым саен диярлек сарай калдыклары тапканнар. Хәрабәләр арасында шулай ук язулы ташлар да табылган. Нинди телдә сөйләштеләр икән мондагы сабалар дисезме? Галимнәр сабаларны семит телле булган дип исәплиләр һәм борынгы язуларны да семит телләре ярдәмендә аңлаталар. Бүгенге Йәмәндә, Согуд Гарәбстанында нинди дә булса төрки кабиләләр яшәве ихтималын без күз алдына да китермибез. Ләкин, югарыда күреп киткәнчә, Страбон заманында һәм аннан бер-ике гасыр элегрәк бу якларда әле күпмедер дәрәҗәдә төркилек сакланган булса кирәк. Галимнәр укыган борынгы язулар арасында һәм бүгенге Йәмән картасында шулай ук төрки исем-атамалар табарга була. Мәсәлән, борынгы саба телендә Чулпан йолдызының алласы Астар Шаркан дип аталган. Астар — алла исеме, Шаркан — аның эпитеты. Моны Сархан дип беләбез. Астар — бөек (изге) күк дигәнгә туры килә. Тарның *къ* варианты — кар. Язулы ташларда Кайнан дигән ниндидер Алла исеме дә табылган. Кайнанның тулырак формасы — кайнана. Искә төшерик әле: минейләр башкаласы Каранна дип атала. Сабада Йасир, Йадаил дигән патшалар булган. Сабаның әби патшасы Бәлкыйснең чын исеме яисә титулы Бал кыз булмады микән? дип әйтәсе

киләә. Татарда Балбабай, Баләби бар. Борынгы Саба җирендә Йарук дигән сарай, Йасил дигән шәһәр дә булган. Сабада һәм бүгенге Йәмәндә Буа, Караса, Тулайхан таулары, Самана, Хазан үзәннәре, Йарим, Йазан, Йаманат, Баусан, Шабан, Кулан, Кукан, Кутал... дип аталган географик атамалар бар һәм булган.

1977 елның 30 августында «Социалистик Татарстан»-да Йәмән Халык Демократик республикасында археологларның рун язулы ташлар табуы турында кыска гына хәбәр басылды. Алтай төркиләренең язуы «рун язуы» дип йөртелә. Бәлки инде кайбер галимнәр Гарәбстан сабаларының да иң әүвәл төрки телдә сөйләшкән булуларын ачыклый алганнардыр, тик әлегә бу турыда эндәшми торуны артыграк саныйлардыр!

Татар теле белән гарәп телендә бик күп уртак сүзләр бар. Бу бигрәк тә кеше исемнәренә карый. Кемнәрдер әйтеп калдырган ялганга сукырларча ышанып без һәр очракта уртак сүзләрне бары тик гарәпнеке дип исәпләргә күнеккәнбез. Чынлыкта андый «уртаклар»ның башлангычы — төрки. Монда тагын бер нәрсәгә игътибар итәргә була: гарәпләр дә, яһүдләр дә семит телле, ләкин гарәп белән яһүднең антропологик кыяфәте бер-берсеннән бик нык аерыла. Гарәпләрнең күпчелеге европеоид расаның Урта диңгез буе тибына карый. Казан татарлары һ.б. төркиләр шулай ук әлеге тип кешеләре.

Сабаларның тамыры, бер яктан, борынгы Италия якларына сузылып булса, икенче яктан, Кызыл диңгез буйларына таба сузылган өчен яктан ул Идел буйларына килеп җиткән. Шулай да моның башлангычы кайда икән? Әйтелгәнчә, кайбер мисаллар борынгы Нил буйларына барып тоташа. Шул ук вакытта моның тамыры борынгы Шумерда — Евфрат (Җебрат) һәм Тигр елгалары буенда да булырга мөмкин.

Шумерда Нисаба дигән алиһә булган. Нисаба турында беренче мәгълүмат Фара чорына, б.э.к. 26 гасырга карый. Нисаба ашлык, башак («урожай») алиһәсе исәпләнгән. «Нисаба» дигән язуда бөртекле башак һәм ашлык бөртекләре күрсәтелгән. Соңга табарак Нисабаны язу осталыгы, сан, фән, архитектура һәм астрономия алиһәсе дип исәпли башлаганнар. Нисаба шумерларның күк алласы Ан кызы. Лагашта ул Энлил кызы, Урның III династиясе чорында Хаййа дигән алланың хатыны. Язу-сызу Хаййага (Кайга? Гайга?) ярдәм сорап мөрәҗәгать итә торган булганнар.

Нисабаның беренче Ни иҗеген шумер телендәге «алиһә» мәгънәсендәге Нин сүзенең кыскарган варианты дип беләбез. Калды Саба. Нисабаның ашлык (башак, бөртек),

язу-сызу, сан, фән, архитектура һәм астрономия алиһәсе булуы бүгенге татар телендә тулысынча чагылыш таба. Үсемлеккә (әйтик, бодайга, арпага) кагылышлы *сабак*-ны да, уку-язуга, белем алуга кагылышлы *сабак* сүзен дә без бернинди икеләнүсез әлеге Саба (Нисаба) исеменнән алынган дип аңлата алабыз. Игенчелеккә кагылышлы *сабан* (ашлык) та, сөрү коралы *сабан* да, күрәсең, әлеге изге алиһәгә кайтып каладыр дип әйтәсе килә. (Немец галиме Бурхард Брентьес татар сабаны шумер сабанына охшаш дигән фикер әйткән.) Татарның *саба җиле* Нисабаның чыннан да астрономия белән дә шөгыльләнүенә ишарәле булса кирәк. Борынгы мисыр телендә *саба* «йолдыз» дигәнне белдергән. Саба җиле йолдызлардан килә торган шифалы, мифик җилне күз алдында тоткан, ахрысы. «Савыт-саба»дагы *саба* да, татарның атаклы *сабан туе* да, юыну «коралы» *сабын* да Нисаба заманнарында ук барлыкка килмәде микән әле?!

Борынгы Римдә сабаларны Санка дигән алла уллары дип белгәннәр. Итальян телендә Санка Сантага әйләнгән. Итальянча санта «изге» дигәнне белдерә, ләкин татарча сантый нишләптер бик үк изге түгел. Санка сүзеннән Саба сүзен чыгарып булмый. Әмма шумерлардагы Нисабаның сан һәм санау алиһәсе дә булуын истә тотсак, Санканың кемлеген ачыклау әллә ни читен булмас дип уйлыйм. Санка ул «сан анасы» дигән мәгънәгә туры килә. Шулай да монда бер каршылык бар кебек. Нисаба хатын-кыз затындагы алла булса, Санка ир затындагы алла бит. Ничек алай булды икән? Монда бер дә аптырыйсы юк. Борынгы аллалар һәм алиһәләр берьюлы ир дә, хатын да була алалар. Шуның өчен дә алла бит алар! Мондый нәрсә еш кына аларның исемендә дә чагыла. Шул ук Санка сүзен Сан Ка дип тә, сан-ка дип тә таркатырга була. Беренчесе хатын-кыз затындагы, икенчесе ир затындагы алла.

Саба, сабалар... Байлар Сабасы, Чәбки Саба, Урта Саба...

Хәтта ышанасы да килми кебек: безнең Саба, сабалар бик борынгы халыкларның алласы, хакимнәре булган имеш! Сабалар иген игкәннәр, мал асраганнар, безнең беренче сүзләрне иҗат иткәннәр, дөньяда беренче шәһәрләрне, беренче дәүләтләрне төзегәннәр. Сугышканнар, үлгәннәр, хәтта үлгәч тә кешелекнең алга баруында маяк булып, йолдыз булып, балкып янганнар!

## СУЙУРГАП-СУЙУРГАЛ

Моннан сиксән еллар элек Казан губернасының Мамадыш өязе (хәзерге Саба районы) Мамалай авылында Казан ханлыгы чорына караган ярлык табыла. Бу кыйммәтле документ Рәхмәтулла Әхмәровта сакланган була. Ярлыкны тарих укытучысы Сәет Вахидов таба һәм 1925 елда «Вестник научного общества Татароведения» журналында бастырып чыгара. Журналда ярлык текстының тулы күчермәсе, күчермәнең бүгенге татар һәм рус телләренә тәрҗемәсе, ярлыкның фотокопиясе һәм авторның рус телендә язылган сүз башы, фәнни аңлатмалар тәкъдим ителә.

Ярлык 1521—1524 елларда Казан тәхетендә утырган Сәхиб Гәрәй исеменнән 1523 елда язылган. Фәнни әдәбиятта «Сәхиб Гәрәй хан ярлыгы» дип йөртелә торган бу документ төп нөсхәдә сакланган. Шунлыктан татар тарихы өчен аның әһәмияте чиксез зур. Аны хәтта ханлык чорыннан исән-имин калган бердәнбер язма истәлек дип әйтергә дә була.

Сәет Вахидовның фәнни ачышыннан соң илле еллар чамасы вакыт үткәч, Казан ханлыгы чорына кагылышлы тагын бер ярлык табыла. Монысын 1963 елда Мәскәүдә борынгы актлар саклана торган Үзәк архивта Казан дәүләт университеты аспиранты Р.Степанов таба. 1965 елда «Казан утлары»нда М.Госманов, Ш.Мөхәммәдьяров һәм Р.Степанов (моннан соң — «өч автор») имзасы белән әлеге документ турында «Яңа ярлык» дигән мәкалә басыла. Мәкаләдә кереш сүз, ярлыкның транскрипциясе, хәзерге татар теленә тәрҗемәсе, кайбер атамаларга һәм архаик сүзләргә аңлатма, документның фотокопиясе бирелгән.

1963 елда табылган ярлыкның кайчан барлыкка килүе билгеле түгел. Ярлык Ибраһим хан исеменнән язылган. Олуг Мөхәммәд ханның оныгы Ибраһим хан Казан тәхетендә 1467—1479 елларда утырган. Димәк, ярлык 1480 елга кадәр язылган булырга тиеш кебек. Болай булганда ул Сәхиб Гәрәй ярлыгыннан борынгырак. Ләкин Ибраһим хан ярлыгы төп нөсхәдә түгел, күчермә генә. 1685 елда әлеге ярлык күчермәсе Казан өязе (хәзерге Актаныш районы) Тыңнамас авылының Котлымөхәммәт Котлыгышевның рус патшасы исеменә язылган гаризасына кушымта итеп теркәлгән һәм Артык Иманаев дигән кеше тарафыннан русчага тәрҗемә ителгән.

Телгә алынган ярлыкларның икесендә дә суйургап дигән сүз бар. Сәхиб Гәрәй ярлыгында бу сүз суйургап рәвешендә бер генә мәртәбә кулланыла, Ибраһим хан ярлыгында суйургап, суйургал, суйургадык формаларында

дүрт мәртәбә очрый («суйургап» ике мәртәбә кабатлана). Мәсәлән, Ибраһим хан ярлыгының VI юлы түбәндәгечә укыла: «ийәсе суйургап биргән бу ике тамга урманын суйургап, ил агалары берлә иректә суйургадык».

Өч автор суйургап-суйургал сүзенә шундый аңлатма бирәләр: «Суйургап сүзе бүләкләү, бүләк бирү, өлеш бирү, мәрхәмәт күрсәтү дигән мәгънәне аңлата. Суйургал — бүләк, бүләк ителгән милек. Икенче төрле әйткәндә, суйургал — феодализм дәверендә милекле сыйныфлардан чыккан аерым кешеләргә хәрби хезмәттә булу һәм сугыш кампанияләренә актив катнашу шарты белән бирелә торган җир биләмәсе, утар. «Суйургал» алган алпавытлар шул утарны, андагы кешеләрне теләгәнчә изгәннәр, талаганнар».

Өч автор мәкаләсендә тагын шундый фикер дә теркәлгән: «Сәхиб Гәрәй ярлыгында «суйургап» дигән бер сүз бар. Аны тикшереп, галимнәр Казан ханлыгында да «суйургал» дип аталган җир биләү системасы булуын ачыкладылар. Бу — фән өчен әһәмиятле яңалык иде. Чөнки, ярлык җентекләп тикшерелгәнгә хәтле, борынгы Урта Идел буенда нинди җир биләү системасы гамәлдә булуы турында тәгаен генә бернәрсә дә билгеле түгел иде».

## II

С.Вахидов тәрҗемәсендә бу сүз татарчада — «мәрхәмәт кылып... тархан кылдык», русчада — «мы вновь, пожаловав... сделали их тарханами», дип аңлатыла.

Югарыда күренгәнчә, өч автор суйургапның бүләкләү, суйургалның бүләк булуына басым ясыйлар.

Дөрес, алар С.Вахидов тәрҗемәсеннән дә баш тартмыйлар. С.Вахидовның «мәрхәмәт кылып» тәгъбире алар аңлатмасында «мәрхәмәт күрсәтү»гә алыштырыла. Ибраһим хан ярлыгының мисалга китерелгән VI юлы татарча тәрҗемәдә болайрак килеп чыккан: «(элекке) хуҗасы бүләк итеп биргән бу ике тамга урманын ил агалары белән бергә иректә (кремльдә) (яңадан аларга) бүләк иттек».

Өч автор исәпләгәнчә, «бүләкләү», «бүләк итү» һәр очракта суйургап сүзен алыштырырга тиеш булса да, оригиналдагы «ике тамга урманын суйургап» тәгъбирендәге ахыргы сүз тәрҗемә ителмичә калдырылган. Әгәр суйургап чыннан да «бүләк итү»гә тәңгәл булса, әлеге тәгъбир бүгенге татарчада: «ике тамга урманын бүләк итеп... яңадан аларга бүләк иттек» рәвешендә язылырга тиеш иде. Ләкин бу — мәгънәсезлек. Өч автор моңа игътибар итәргә мәҗбүр булганнар һәм бер «суйургап»ны тәрҗемәдә чагылдырмаганнар.

Һәр ике ярлыкта элекке ханнар хакимлеге чорында төрле салымнардан, түләүләрдән, мәҗбүри чаралардан азат

ителгән югары сыйныф кешеләренең хокукларын тану, шул хокукларны яңадан торгызу турында сүз бара. Сәхиб Гәрәй ярлыгы берьюлы өч буыннан торган җиде кешегә, Ибраһим хан ярлыгы «(элек) Хәйдәр-Гали солтан тарафыннан азат ителгән Гөл-Бостан-хатунга, (аның) улы шаһ нәселе, Җанәкә-солтан нәселе Мөхәммәт-Гали Газиз-ханга» һәм аларның Хуш-килде исемле хезмәткәренә бирелгән.

Ибраһим хан ярлыгы турында сөйләгәндә өч автор: «документлардан күренгәнчә, Гөл-Бостан-хатуннар гаиләсен тарханлык язуы белән беренче тапкыр Хәйдәр-Гали исемле солтан (патша) бүләкли. Димәк, Ибраһим хан гамәлдәге тарханлыкны икенче кат раслаучы гына булып чыга» дигән фикер әйтәләр. Бик дөрес фикер бу! Ләкин өч автор шушы дөрес фикерне тиешенчә үстермиләр, «бүләк», «бүләкләү», «җир биләмәсе» кебек төшенчәләр арасында буталып калалар. Мәсәлән, бүләкләү, бүләк бирү тәгъбирләренең мәгънәләре бер-берсенә бик якын булса да, бер-берсенә тәңгәл түгел. Бүләкләү белән бүләк бирүгә өлеш бирү, мәрхәмәт күрсәтү исә якын да килми. Ашаганда мин, әйтик, ризыкның бер өлешен икенче берәүгә бирәм, бу — өлеш, ләкин бүләк тә, күчтәнәч тә түгел. Бу шулай ук мәрхәмәт күрсәтү дә түгел.

«Суйургал — бүләк, бүләк ителгән милек», ди өч автор. Мондый аңлатманың аңлашылып җитмәвен чамалап, «аңлатма»ны алар тагын да киңәйтә төшәләр. Суйургал аларча... «аерым кешеләргә хәрби хезмәттә булу һәм сугыш кампанияләренә актив катнашу шарты белән бирелә торган җир биләмәсе, утар».

Беренчедән, «җир биләмәсе» белән «утар» бер-берсенә тәңгәл түгел. «Җир биләмәсе»ндә урман-сулар да, таулар да, сазлар да, авыл-шәһәрләр дә һәм, әлбәттә, «утар» да, утары булгач, кешеләре, малы-туары да булырга мөмкин. Күрәсез, бу төшенчә бик күп нәрсәне эченә ала. «Утар» менә шул күпләрнең бере генә.

Икенчедән, «бүләк ителгән милек» белән «җир биләмәсе» шулай ук бер-берсенә тәңгәл түгел. «Феодализм дәверендә милекле сыйныфлардан чыккан аерым кешеләрнең «җир биләмәләре төрле төбәктә һәм төрле зурлыкта була алган. Бер кешенең, әйтик, бер яисә аннан күбрәк «җир биләмәсе», шуннан (шулардан) тыш тагын берәр шәһәрдә, авылда аерым йорты, каралты-курасы, малы-туары, ялчылары, алтын-көмеше, шәхси әйберләре булырга мөмкин. Шуларның барысы да әлеге кешенең милке булачак. Димәк, милек «җир биләмәсе»нә караганда киңрәк төшенчә.

Өченчедән, беркайчан, беркайда,беркемгә «җир биләмәсен» яисә анда «утар»ны «хәрби хезмәттә булу һәм су-

гыш кампанияләрендә актив катнашу шарты белән» алдан биреп куймаганнар. Җир биләмәләре, утарлар гына түгел, һәр төрле исем-дәрәҗәләр, титуллар һәм вак-төяк бүләкләр дә бары тик ханга-патшага, ил-көнгә, дәүләткә күрсәткән хезмәт өчен генә бирелгән һәм бирелә. Икенче төрле итеп әйткәндә, башта сугышырга, кан коярга кирәк булган. Җир биләмәләре, утарлар, исем-титуллар туганлык, дуслык-якынлык нигезендә дә бирелгән, әлбәттә. Ләкин өч автор мәкаләсендә «бүләк»нең мондый төре турында сүз бармый, сугышта катнашып «бүләк» алучылар гына күз алдында тотыла.

Дүртенчедән, «милек»не берничек тә бүләк итеп булмый. «Милек» төшенчәсенә милек хуҗасының үз шәхесеннән башка барлык байлыгы керә. Шуңа күрә, кем дә булса үз милкен кемгәдер бүләк итеп бирә икән, андый кеше утарсыз-нисез генә түгел, ыштансыз да калачак. Ханнар, патшалар, белүебезчә, бары әкиятләрдә генә шул дәрәҗәдә юмарт булганнар. Милекне, гадәттә, көч белән тартып алалар, алай да булмаса, милек хуҗасы үз байлыгыннан читләшкәч яисә читләштерелгәч, «милек» дигән нәрсә икенче шәхескә күчә. «Бүләк» исә һәр очракта бер бөтеннең күпмедер өлешен генә тәшкил итә.

### III

Суйургап — суйургал Казан ханлыгы чоры ярлыкларында гына түгел, башка төрки истәлекләрдә дә бар һәм тюркологиядә аның турында инде шактый сүз булган. Мәсәлән, әлеге сүз Радлов сүзлегендә дә, «Борынгы төрки телләр сүзлегендә дә телгә алына. Радловта сойургау: 1) радовать, жаловать; 2) одарить кого; сойургал — 1) милость, милостивый подарок; 2) протеже, получивший дары, «Борынгы төрки телләр сүзлеге»ндә суйурка — 1. Жаловать, пожаловать; 2. Радовать, дип аңлатылган. Шул ук сүзлектә әлеге сүзнең тсуйурка варианты да бирелгән. Мәгънәсе: проявлять жалость, сострадание. Сүз башындагы *тсу* иҗеге кытайча «ана мәхәббәте» мәгънәсендәге цы сүзенә тәңгәл дип күрсәтелгән.

В.В.Радлов билгеләп үткәнчә, суйургап-суйургал госманлы-төрек, уйгур, чыгытай һәм кыпчак истәлекләрендә очрый икән. Конкрет әйткәндә, бу сүз Туктамыш хан ярлыгында, «Кодекс куманикус»та, «Кутадку билик» тә, шулай ук «Огуз-нәмә»нең уйгур вариантында, XII—XIII гасырларда Урта Азиядә башкарылган Коръән тәфсирендә һ.б. истәлекләрдә бар.

Шулай итеп, фәндә әлеге суйургап-суйургалның төгәл мәгънәсе табылмаган дип әйтергә була. Бер очракта бу сүз радовать, икенче очракта жаловать (пожаловать), өчен-

че очракта милость яки проявлять жалость, сострадание дигән мәгънәне аңлатырга мөмкин икән.

С.Вахидов та, өч автор да бу әсәрләр белән таныш, әлбәттә. Шуңа күрә дә алар мәрхәмәт кылу, мәрхәмәт күрсәтү, бүләкләү, җир биләмәсе кебек төшенчәләрне кулланалар да. Ләкин русның, әйтик, милость, жалость кебек сүзләре мәрхәмәт күрсәтүгә туры килсә дә, пожаловать сүзе «бүләк»кә туры килеп бетми. Жаловать (пожаловать) югары дәрәҗә кешеләре тарафыннан бирелә торган нәрсәне аңлата.

«Суйургап»ка бирелгән аңлатмалар арасында бер тәрҗемә аерылыбрак тора. Мәсәлән, XIV гасыр азагында, XV гасыр башында яшәгән һәм Аксак Тимер яуларының тарихын язып калдырган Низаметдиннең «Зөфәр-нәмә» («Җиңүләр китабы») әсәрендә Урыс ханның Тайга дигән кешегә Урук Тимер биләмәләрен суйургавы турында әйтелә, Суйургал сүзен В. Г. Тизенгаузен *лен* дип тәрҗемә итә. А.М.Щербак исә, Тизенгаузенга нигезләнеп, суйургалны «жалование земли» дип аңлата. Шулай итеп, суйургал — «җир биләмәсе бирү» булып чыга.

Урта гасырларда Көнбатыш Европада лен тәртибендәге җир биләү системасы булган. Король яки башка берәр хаким үзенә буйсынган кешегә (вассалга) ни өчендер җир биләмәсе биргән. Корольгә, патшага буйсынган кеше үзенә бирелгән шул җирдән һәм андагы байлыклардан, керемнән файдалана алган. Шуның өчен ул үзенә яхшылык эшләгән хакимне яклап хәрби хезмәттә, хөкем эшендә катнашырга, үзенең хакименә акчалата түләүләр, салымнар бирергә һ.б. мәҗбүри чараларны башкарырга тиеш булган. Лен хокукы нәселдән-нәселгә бирелгән.

«Галимнәр Казан ханлыгында да «суйургал» дип аталган җир биләү системасы булуын ачыкладылар» дип, суйургал — ...«милекле сыйныфлардан чыккан аерым кешеләргә хәрби хезмәттә булу һәм сугыш компанияләренә актив катнашу шарты белән бирелә торган җир биләмәсе» дип язган чагында, өч автор нәкъ менә шушы лен системасын күз алдында тоталар да инде. Лен сүзе монда суйургал сүзе белән генә алыштырыла.

Ләкин лен суйургал түгел, суйургал лен түгел. Моның шулай икәнлеген аңлау өчен Сәхиб Гәрәй ярлыгына игътибар беләнрәк күз төшереп алу да җитә. Сәхиб Гәрәй ярлыгында да, шулай ук Ибраһим хан ярлыгында да хәрби хезмәт һәм сугыш компанияләрендә актив катнашу турында бер сүз дә юк. Монда шулай ук акчалата түләүләр һәм башка мәҗбүри чаралар башкару кирәклеге турында да әйтелми. Хәтта, киресенчә, Сәхиб Гәрәй ярлыгында, мәсәлән, «ясак, калан, салыг... салмасыннар» диелгән һәм

алынмаска тиешле тагын берничә төрле салым-түләү төре санап кителгән. Сәхиб Гәрәй, өч буын кешеләренә тарханлык ярлыгы биреп, үзе өчен чынлыкта берни таләп итми. Ул бары ярлык алучылар «буш чакларында тыныч торып, кич, иртә, көндез һәм төндә безгә вә безнең нәселебезгә догада алкыш кылсыннар» дигән теләк кенә белдерә.

Суйургап-суйургалның, кем сүзе һәм нинди сүз икәнлеген ачыклау өчен без иҗек методы кулланабыз һәм әлеге сүзне иҗекләргә таркатып, һәр иҗекне аерым-аерым тикшереп карыйбыз.

Сүзнең төп өлеше — суйурга. Иҗекләргә таркаткач бу су-йур-га булачак. «Суйурга»ны суйурга-у, суйурга-мак дип тә, ярлыкларда кулланылганча, суйурга-п, суйурга-л дип тә төрләндерергә була. Ләкин, ничек төрләндерсәк тә, әлегә берни аңлашылмый. Аңлашылсын өчен «суйургап»ка охшаш «болгап» сүзенә игътибар итеп карыйк: бол-гап, бол-гау, бол-гамак, бол-гал... Суйургап сүзендәге су иҗеге артык сыман тоела, шуңа күрә йур иҗекләрен генә төрләндерәбез: йур-гап, йур-гау, йур-гамак, йур-гал... Әйтәсе килгәнем шул: суйургап-суйургалның төп мәгънәсе йур иҗекләрендә чагыла. Йурның йул варианты да булырга мөмкин. Татарда йур катнашында ясалган йур-ау, йур-и, йур-амалый кебек сүзләр бар. Йур шулай ук йусык-йурык дигән парлы сүзнең йурык өлешендә дә катнаша. Йусык-йурыкның мәгънәсе: «һәр төрле рәсми кагыйдәләр». Йусык үзе генә дә «тәртип, кагыйдә» мәгънәсендә кулланыла ала. Телдә йусык катнашында ясалган әйтем-мәкальләр дә бар. Мәсәлән, ал йусык, кара йусык, кирәкмәгән йусыкка, ясалмаган йусыкка кысылма. Йусыкның йусын варианты да мәгълүм. «Юлчыга сусын бирү — йусын» дигән мәкальдә йусын турыдан-туры тәртип, кагыйдә, закон дигән мәгънәләргә туры килә.

Хан ярлыкларының закон көченә ия булган юридик документ, суйургап-суйургалның исә юридик термин булуы үзеннән-үзе аңлашылып тора дип уйларга кирәк. Бу сүзнең юридик атама булуы аның ярлыкларда кулланылуы белән генә түгел, бәлки йур, йус иҗекләренең халыкара кулланыштагы юрисдикция, юриспруденция, юрист, юстиция кебек терминнар ясауда катнашуы белән дә исбат ителә ала. Ләкин суйургап-суйургаллардагы, йусык-йурыклардагы йур, йус иҗекләренең халыкара кулланыштагы юрисдикция, юрист, юстиция кебек терминнардагы йур-йуслар белән берәр төрле уртаклыгы бар микән соң?

Бөтен хикмәт тә шунда — уртаклык бар һәм ул бик тирәннән башлана. Юриспруденция, юстиция кебек терминнарның барысы да латинныкы исәпләнелә. Бүгенге

фәндә төрки телләр белән латин теле арасында бернинди якынлык танылмый. Шулай да, әйтик, татар телендә берәр төрле латин терминнары очрый икән, татар теленә алар Европа телләре һәм рус теле аша кергән дип уйланыла. Шуңа күрә дә без татар теленә, тарихына кагылышлы күптөрле фактларны факт дип танымаска, яисә, судан коры чыгу өчен, тузга язылмаган теләсә нәрсә сөйләргә күнегеп беткәнбез. Баксаң, борынгы тарих, борынгы телләр бүгенге галимнәр аңлатканча түгел, бәлки бөтенләй башкача булган икән. Борынгы дәүләтләрнең күбесендә төрки яисә төркигә якын телдә сөйләшүчеләр хакимлек иткән. Конкрет рим-латин дөньясы турында сүз барганда, Рим шәһәрен борынгы төркиләр — сабалар, этрусклар салган, Рим дәүләтенең беренче патшалары да төркиләр булган. Римнең күп кенә дәүләт башлыклары, шул исәптән, атаклы императорлар Юлий Цезарь, Августлар үзләрен Юл нәселеннән дип исәпләгәннәр. Юл исә, Кече Азиядәге Троя (Илион) җиңелгәннән соң, Италия җиренә килеп урнашкан Энейнең улы (кайбер мифларда — улының улы яки туганы) дип уйланылган. Юл, Юли, Юлия латиннарда киң таралган исемнәрдән саналган. Юдинең Р вариантындагысы Юрий русларда әле дә актив. Юри, Юрис сирәк булса да, татарларда да очрый.

Закон, тәртип, кагыйдә мәгънәсендәге йусык-йурык, йусын сүзләрендәге йур, йуслар борынгы Рим императорларының нәсел башы исәпләнгән Йуллары белән бертуган. Татарда «юлдан язган, юлдан чыккан» дигән сүзләр бар. Монда юлдан читкә чыккан, адашкан кеше генә түгел, закон, тәртип, кагыйдәне бозган кеше дә күз алдында тотыла. Йул, йур, йус, йуш...— боларның барысы да изге сүзләр. Иң әүвәл бу сүзләр бик борынгы төрки кабиләләрнең мифик ата-бабаларын һәм ниндидер аллаларын белдергәндер дип әйтергә нигез бар. Йу катнашында ясалган күп кенә сүзләрнең бүген дә дингә, дини тәртип-кагыйдәләргә кагылышлы мәгънәләрдә кулланылуы шул турыда сөйли. Мәсәлән, «юлыңа ак җәймә», «юраганга юш килә» дигән әйтем-мәкальләрдә юл да, юш та ниндидер илаһи көчләр буларак аңлашыла. Бу уңайдан татарның атаклы Йосыф кыйссасын һәм Йосыф пәйгамбәрне искә төшерергә була. Йосыфның әүвәлгерәк әйтелеше — Йусеф, ягъни Йус улы. Йусның ш варианты — Йуш. Монда шулай ук латиннарның Юпитер, Юнона дигән аллаларын да искә төшерәбез. Юпитер латиннарда греклар Зевсларына тиң күк алласы исәпләнгән. Алла исемен Йуп, ит, ер дип таркатабыз. Йуп (б) — Йур, Йул, Йус, Йуш нәселендәге илаһи исем. Ит — борынгы төрки-

мисыр телендәге «алла» Нитәнең кыскарган варианты, ер (әр) — төрки «ир»нең «ә» белән әйтелеше. Этрускларда «ир» урынына «әр» активрак кулланылган. Юнона башта этрусклар, соңыннан латиннар алиһәсе булган. Сүз ахырындагы она, ягъни ана Юнонаның чыннан да хатын-кыз затындагы алла булуы турында әйтеп тора. Йүн әле генә телгә алып киткән Йур, Йуллар белән бертуган. Йүн татарча йүн-ле, йүн-сез (җүнле, җүнсез) кебек сүзләр ясауда катнаша. Ул шулай ук тирә-йүн дигән парлы сүздә дә бар.

Латинча juro (йуро) — ант бирү, ант итү, jus (йус) — хокук, гаделлек, законнар системасы дигән мәгънәләрне белдерә*. Латинча кайбер юридик терминнардагы йур иҗекләрен йустан үзгәргән сыман итеп аңлаталар. Бу, күрәсең, йур йустан, яисә, киресенчә, йус йурдан үзгәрүне түгел, бәлки йурның да, йусның да борынгы латиннарда (дөресрәге, борынгы төркиләрдә — сабаларда, этрускларда һ.б.) әлеге иҗекләрнең бер үк мәгънәләрдә кулланылуын чагылдыра булса кирәк. Мәсәлән, бүгенге йусык-йурык кебек.

Йур, йус, йул иҗекләренең бик борынгы заманнарда дини, мифик шәхесләрне белдерүе һәм бары тик уңай мәгънәләрдә генә кулланылуы суйургап-суйургал мисалында да күренә. Әйтелгәнчә, суйургап-суйургал бәхет, шәфкать, мәрхәмәт, бүләк дигән төшенчәләрне белдерә алган.

Суйургап-суйургалдагы артык сыман суны уңай сыйфат аңлатучы иҗек дип беләбез. Теоретик яктан бу су Йур, ягъни бөек, изге Йур булыр иде. Тик шулай да мондагы су иҗегенең мәгънәсе башкачарак, ахрысы. Латин телендә sui iuris (суй йурис) дигән юридик термин булган**. Ялгыз suiның мәгънәсе: безнекеләр, үзебезнекеләр, туган-тумача, якын кешеләр дигәнгә туры килә икән***. Рим империясе чорында sui iuris термины, мәсәлән, Веста кызларына карата кулланылган, яисә, икенче төрле итеп әйткәндә, Веста кызлары sui iuris кагыйдәләренә туры килә торган шәхесләр исәпләнгән.

Веста кызлары үзләре кемнәр соң, дигәндә, алар Веста (Бистә) утын сүндермичә, көн-төн ут-учак янында сакта торганнар. Веста учагында өзлексез ут яну исә Рим дәүләтенең туктаусыз яшәвен, көчен-куәтен чагылдырган. Шунлыктан Веста уты да, Веста кызлары да изге саналган. Вестада алты кыз булган. Алар, барлык рим хатын-кызлары кебек, аталарына яисә ир туганнарына түгел, бәлки турыдан-туры ил башлыгына — патшага

*И.Х.Дворецкий. Латинско-русский словарь. М., 1976, 567 бит.
** Письма Плиния Младшего. Книги I—X. М., 1983, 320 бит.
*** И.Х.Дворецкий. Күрсәтелгән хезмәт. 976 бит.

(императорга) буйсынганнар. Шул ук вакытта изге кызлар үзләренең барлык байлыкларына үзләре хуҗа булганнар, васыять язуы калдыра, судта шаһит рәвешендә чыгыш ясый алганнар. Шул рәвешчә, Веста кызлары илдә иң өлкән дин башлыгы да булган патшаның (императорның) үз кешеләре, якыннары (sui iuris) исәпләнгәннәр.

Веста кызлары Рим патшалары өчен «үз кешеләр» булган кебек, Казан ханнарыннан суйургал ярлык алучылар да ханның якыннары, туган-тумачалары булган һәм шуңа да алар беркемгә берни түләмәгәннәр, бернинди мәҗбүри чараларда катнашмаганнар.

Борынгы грек язучысы Страбон «География» дигән китабында безнең өчен әһәмиятле бер фактны теркәп калдырган. Рим императорлары Юли Цезарьлар, Августлар, әйтелгәнчә, үзләрен Троя җиңелгәннән соң Италиягә килгән мифик Юл нәселеннән дип белгәннәр. Элекке Троя җирләре Рим империясе кул астына күчкәч, император Юли Цезарь, үзенең Юл нәселеннән булуын истә тотып, элекке Троя кешеләренә җир бүлеп бирә, аларны ирекле дип таный һәм дәүләт файдасына башкарыла торган мәҗбүри чаралардан, бурыч һәм йөкләмәләрдән азат итә. «Хәзерге вакытка кадәр алар (ягъни Троя кешеләре.— *Н.Ф.*) шушы өстенлекләрдән файдаланалар», ди Страбон*. Нәкъ Сәхиб Гәрәйдән ярлык алган җиде буын кешеләре кебек (!) дип әйтер идек, Юли Цезарьның Троя кешеләренә нинди документ бирүен һәм ул документның ничек аталуын белмибез. Ни генә булмасын, Троя кешеләре дә Юли Цезарь өчен, күрәсең, sui iuris — «үз кешеләр» булгандыр дип әйтергә тулы нигез бар.

Суйургап-суйургал төрки йур иҗекләре катнашында ясалган булса да, бу борынгы Рим дәүләте шартларында барлыкка килгән юридик термин һәм ул латинча sui iurisның, төркичәсе булса кирәк. Кайчан һәм ничек килеп кергән ул Алтын Урда, Казан ханнары ярлыкларына һәм башка төрки истәлекләргә? Килеп кергәнме, әллә соң Рим якларыннан безнең борынгы бабаларыбыз белән бергә килгәнме? Бу бөтенләй башка тема, зур тема, шуңа күрә бу мәкаләдә без аңа туктала алмыйбыз.

---

* Страбон. География. Л., 1964, XIII, 1, 27.

## ШУМЕРЧА *ДИНГИР*, ТАТАРЧА *ТӘҢРЕ*

Моннан бик күп гасырлар элек, б.э.к. V мең еллык ахырыннан алып, Көньяк Месопотамиядә — Тигр һәм Евфрат елгаларының түбәнге агымында шумер (сумер) дигән халык яшәгән. Шумерлар биләгән җирләрдә таулар да, урманнар да, челтерәп аккан чишмәләр дә юк. Кая карама — саз да баткаклык, камышлы күлләр һәм үзәннәр. Бу якларның климатик шартлары да шактый кырыс. Язын, җәен монда туктаусыз кояш кыздыра. Сигез ай буена бер тамчы яңгыр төшми. Җәйге температура +30°— +50° тирәсендә тирбәлә. Мондый эсседә җир өстендәге туфрак көлгә, тузанга әйләнә. Елгалар корый, саега. Язгы ташу исә бу яклар өчен соңгарып килә — апрельдә башланып июньгә кадәр дәвам итә.

Менә шушы алла каргаган җирне эшчән, тырыш, талантлы халык гасырлар дәвамында гөлбакчага әйләндерә. Шумерлар, Месопотамиядә беренчеләрдән булып, ясалма сугару кулланып, иген игә башлыйлар. Игенчелек белән бергә терлекчелек, һөнәрчелек һәм алыш-биреш тә алга китә. Беренче кирпечне, беренче кәтмәнне сабанны шумерлар уйлап таба. Беренче тәгәрмәчне, арбаны һәм уен коралы арфаны шумерлар иҗат итә. Беренче гыйбадәтханә — «зиккурат»ларны, беренче шәһәрләрне, беренче дәүләтләрне шумерлар төзи. Шумерлар куллана башлаган чөй язуы аларның дөнья цивилизациясе үсешенә этәргеч ясаган иң зур ачышларыннан берсе санала.

Шумерлар нинди телдә сөйләштеләр икән?

Бүгенге көнгә кадәр бу билгеле түгел дип исәпләнә. Дөрес, сирәк булса да, рус телле фәнни әдәбиятта шумерларның казан татарларына, шумер теленең «төрки-монгол» телләренә якынрак булу ихтималы турында томанлы гына фикерләр дә күренгәләп кала. Мәсәлән, немец галиме Бурхард Брентьес шумер сабаны татар сабанына охшаш дигән фикер әйткән. Ю.А.Краснов, бу фикерне тәнкыйтьләп, болай дип яза: «Попытки проследить генетическую связь двухрукояточных рал Древней Месопотамии с двухрукояточными ралами и плугами столь отдаленных районов, как Среднее Поволжье (татарский сабан) ... представляются, несмотря на свою заманчивость, беспочвенными» (Древнейшие упряжные пахотные орудия. М., 1975, с.51).

Шумер теле турында В.К.Шилейко: «Шумерский язык, агглютинирующий, но с зачатками дальнейшего флексивного развития...» ди (Вотивные надписи шумерийских правителей. Петроград, 1915, с. VII). Билгеле

булганча, «төрки» телләр «агглютинирующий»лар рәтенә карый.

Совет галиме И.М.Дьяконов: «Долгое время распространена была теория, относившая шумерский к числу тюрко-монгольских языков, однако довольно многочисленные приводившиеся сопоставления (например, тюрк. *тэнгри* «небо, бог» и шумер. *дингир* «бог») были в конце концов отвергнуты как случайные совпадения...» ди. (история древнего Востока. Ч.1. Месопотамия. М., 1983, с. 93.)

Безне аеруча Дьяконов фикере кызыксындыра. Автор *тәңре* һәм *дингир*не «случайное совпадение» («очраклы охшашлык») дип атый. Ләкин, күренгәнчә, *дингир* һәм *тәңре* бер-берсенә охшамаган, ягъни монда бернинди «случайное совпадение» юк. Дөрес, бу очракта галим чагыштырма-тарихи метод кагыйдәләренә нигезләнеп фикер йөртә. Чагыштырма-тарихи метод кагыйдәләре нигезендә исә сүзләрнең хәтта «охшаган» — «охшамаган» булуын да исбат итеп булмый.

Без башкачарак фикер йөртәбез.

Сүзне *тәңре*дән башлыйк. Кемне, нәрсәне аңлата бу «алла»? Моны белү өчен без әлеге терминны *тәң-ре* рәвешендә икегә таркатабыз. Ахыргы *ре* иҗеге *ра, рә* иҗекләренә тиң. Борынгы мисыр телендә *ра* кояшны белдерә. Бу билгеле нәрсә. «Кояш» булгач ул, борынгы фәлсәфә нигезендә, «агым су» да, «алла» да, «патша» да була ала. Сүз башындагы *тәң-* не сыйфат дип уйласак, бу «яхшы, изге, бөек» дигән мәгънәләрне белдерәчәк. Ул чагында *тәң-ре* «бөек, яки изге алла» булачак. *Тәң* калын әйтелештәге *таң*-ның фонетик варианты булырга да мөмкин. Алай булганда, бу *таң-ре (ры)* — «таң кояшы, иртәнге кояш» булачак. *Тәң*-не «алла» дип белсәк, *Ре* иҗеге әлеге алланың «шәхси» исеме булып аңлашыла. Ничек кенә аңлатсак та, *тәңре*-нең «алла»лыгына зыян килми.

Шумерча *дингир*-не дә *дин-гир* рәвешендә икегә бүләбез. Татарча *дин* — «религия». Ләкин *дин* «религия» генә түгел. Татарда *дин* катнашында ясалган. Динбай, Динулла, хәтта Дин, Динә дигән кеше исемнәре бар (Г.Ф.Саттаров. Татар исемнәер сүзлеге. Казан, 1981, 76 б.). Татарстанда Динекәй елгасы, Динкә елгасы дигән елгалар бар (Ф.Г.Гарипова. Татарстан гидронимнары сүзлеге. Казан, 1984, 44 б). *Дин*-нең төп иҗеге *ди*. Бу сүз-иҗек *ти, пи, би, фи* кебек сүзләргә-иҗекләргә тиң. Татарча *би*- морза, түрә, кенәз, хуҗа» мәгънәләренә ия. Исем буларак *ди* шулай ук, ягъни *ра* кебек үк, агым суны, кояшны, Алланы, яшьлекне, ирлекне белдерә.

*Ди* иҗегенә *н* тартыгы кушкач, яңа мәгънәдәге сүз

барлыкка килә. Моны без гомумиләштереп «ди улы» дип атыйбыз. Конкрет «ди улы» хатын-кыз затын да, ир затын да белдерергә мөмкин. Кем һәм нәрсә турында сүз барганлыгы, гадәттә, сүз сөрешендә, контекстта аңлашыла. Затлар мәсьәләсендә буталчыклык килеп чыкмасын өчен, еш кына төп сүзгә өстәмә иҗекләр ялгана. Без тикшерә торган *дин-гир* сүзенең *гир* өлеше нәкъ менә шул өстәмә иҗек ролен үти. Татарда «ир» мәгънәсендәге *гир* Җиһан-*гир* дигән кеше исемендә, «сугышчы, яу остасы» яу-*гир* сүзендә сакланып калган. «Ир затындагы ат» *айгыр*-ның әүвәлгерәк формасы *ай-гир* булгандыр кебек.

Татар телендә элек *дингир* дигән «алла» булды микән, юк микән, әйтүе кыен. Әмма бездә *дингир*-нең хатын-кыз затындагысы — *диңгез* бар! Сүз уртасында *ң* тартыгы белән әйтелә торган бу термин кайчандыр *дин-гез* булган дип фараз кылабыз. *Дин-гир*дәге *гир* кебек, мондагы *гез* дә төп сүзгә өстәмә мәгънә бирә. *Гез* ул бүгенге *кыз*-га тиң. Татарда *гез* ярдәмендә ясалган сүзләр күп кенә. Мәсәлән, *ни-гез, си-гез, ти-гез* һ.б.

*Диңгез* «море», шул рәвешчә, хатын-кыз затындагы «стихия» булып чыкты. Иң гаҗәбе шул, татарча *диңгез*-нең башка төрле мәгънәләре дә бар. Мәсәлән, *диңгез*: «2. Кышка каршы өйнең тышкы ягына туфрак, кибәк һәм саламнан өелә торган нигез (завалинка). 3. Төп йорт, туып үскән йорт (дом, принадлежавший предкам данного рода, данной семьи, например, отцу, деду, прадеду)» (Татар теленең диалектологик сүзлеге. Казан, 1969, 126 б.).

Ничек аңларга моны — үзе су — «стихия», үзе туфрак өеме, үзе өй, ата-баба йорты... Бүгенге аң, бүгенге логика белән моңа төшенеп булмый. Моны аңлау өчен үзеңне кимендә биш-алты мең еллар элек яшәгән кеше итеп күз алдына китерергә кирәк. Ул ерак заманнардагы ата-бабалар карашынча, агым сулар — ир затында, диңгез-күлләр — хатын-кыз затында. Кеше үлгәч, аны тудыручы анага кире тапшыралар. Берәүләр җиргә күмелә, икенче берәүләрне салга, кәмәгә (кимәгә) яисә сандыкка салып диңгезгә озаталар.

Шумерлар кешелек дөньясы диңгез эчендәге Дильмун утравында — хәзерге Персия култыгындагы Бахрейнда барлыкка килгән дип исәпләгәннәр (ИдВ, I, с.92). Көньяк Месопотамиядә кыш көне коеп яңгырлар ява, җил-давыллар котырына, төннәрен бик каты суытып җибәрә. Табигать үлә. Табигать үлгәч, билгеле, кешеләр дә үлә дип, дөресрәге, вакытлыча үлә яисә мәрткә китә дип уйланыла.

Борынгы Шумердагы кешеләр, нәкъ бүгенге татар-

лар кебек дип әйтимме, кыш якынаю белән, үзләренең балчык-камыш өйләрен туфрак, салам, чүп-чар белән тирәяктан «диңгезләп» алганнардыр дип уйларга кирәк. Шул рәвешчә җылытылган куыш аларны туры мәгънәсендә туңып үлүдән саклаган. Мондый өйдә алар үзләрен ата-бабаның төп йорты Дильмун утравында сыман хис иткәннәрдер кебек.

Бездә кышка каршы торак өйне «диңгез» белән әйләндереп алу гадәте генә түгел, гомумән суга, диңгезгә кагылышлы кайбер башка нәрсәләр дә исән. Мәсәлән, яңа туган баланы судан — күлдән, коедан, елгадан алып кайталар; без балык карынында яралганбыз; җир балык өстендәге үгез мөгезендә тора дигән карашлар, ышанулар татарда әле дә онытылып бетмәгән. Бала чакта мондый сүзләрне мин күп ишеттем. Мин шулай ук өлкән яшьтәгеләрнең еш кына, авыр сулап, «төп йортка да барасылар бар әле» дигәннәрен бүгенгедәй хәтерлим. Төп йорт алар өчен торып яткан ата-баба йорты түгел, бәлки теге дөньядагы ниндидер мифик «төп йорт» булып тоелгандыр дип әйтәсе килә.

### КИШ КАЛАСЫ — БАШ КАЛА

Шумерлар үз илләрен Kalamma дип атаганнар. Сүзнең мәгънәсе «Страна» дип аңлатыла (В.К.Шилейко. Вотивные надписи шумерийских правителей. Петроград, 1915, с. XII). Әлеге терминны *кал-ам-ма* рәвешендә таркатсак, бу «*Ма*-ның изге, яки бөек (*кал*) гаурәте (*ам*)» булачак.

Мондагы һәрбер сүз-иҗек, шумерча булу белән бергә, татарча да. *Ма* татарда «җир; ана» дигәнгә туры килә һәм җиргә, анага тиңләштерелә торган күп төрле башка мәгънәләрне белдерә. Сүзлекләргә кертелми торган *ам*-ны күпчелек татар аңлый дип исәплик. Шумерча kal сыйфат ролен үти. *Кал*ның кыскартылганы *ал* татарда шулай ук сыйфат буларак кулланыла. Мәсәлән, *ал байрак* — «ал яки кызыл төстәге байрак», «изге байрак». *Кал*ның *гъ* варианты — *гъал (гъәл)*: «гъәли зат», «Гали батыр».

Шумерларның иң борынгы шәһәрләре Эреду[г] дип аталган. Дини корылмадан (гыйбадәтханәдән) үсеп чыккан бу шәһәр Евфрат елгасының диңгезгә (Персия култыгына) койган төбәгенә урнашкан булган. Эреду[г] сүзен И.М.Дьяконов «Добрый город» дип тәрҗемә итә (История древнего Востока. Ч. I. Месопотамия. М., 1983, с.145). С.Н.Крамер бу исемне Эриду дип аңлый. Шумер мифларына нигезләнеп язылган вавилон дастанында («Эпос о Гильгамеше»да) әйтелгәнчә, Эриду аллалар әмере белән Шумер

җирендә барлыкка килгән биш шәһәрнең беренчесе булган (История начинается в Шумере. М., 1965, с.176).

Әлеге шәһәр исемен Эреду дип язсаң да, Эриду дип язсаң да дөрес. Теоретик яктан *ре* һәм *ри*-нең мәгънәләре бер-берсенә тәңгәл. Бу иҗекләрнең һәркайсы монда «Евфрат» дигәнгә туры килә, *э* — «өй, куыш», *ду* [г] — «улы». Эреду[г]ның «Добрый город» дигән мәгънәсе нәрсәгә нигезләнгәндер, аңлашылмый. Теоретик яктан бу «Алиһә өе» дигәнне белдерә. Б.э.к. IV мең еллык башларында барлыкка килгән Эредуг шәһәренең якчы алласы Энки дип аталган. *Эн-ки* — «Су улы». Шул рәвешчә, Эредугны хәтта Энкинең җәмәгате дип тә атарга була.

Эредудан төньяктарак урнашкан икенче бер кала — Ур шумерларның иң атаклы шәһәрләреннән санала (ИдВ, 1, с.145). Шумерча *ур* берничә мәгънәгә ия. Бүгенге татар телендә дә *ур* төрле мәгънәдә кулланыла. Шуларның берсе: «текә ярлы коры елга, тирән чокыр» (Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. III т. Казан, 1981, 310 б., 2 мәгъ.). Татарча *ур* «авыл, шәһәр, корылма» мәгънәсендә кулланыла торган *тура-кура-бура* кебек сүзләрдән кыскартылган булса кирәк. *Ур* катнашында ясалган һәм төзелешкә, авыл-шәһәргә кагылышлы *ур-ам, ур-та, ур-ын* шул турыда сөйли. *Ур* кайбер авыл исемнәре ясауда катнаша. Мәсәлән, минем туган якта Уразы, Татарстанда Урбар, Урманай, Урсай авыллары бар (Татарча-русча сүзлек. М., 1966, 799, 800 б.). В.И.Авдиев, Аккад (Агаде) патшасы Нарамсин (б.э.к. 2290—2254) сугышлары турында сөйләгәндә, аккадларга каршы баш күтәргән ниндидер Курсауры патшасын («царь Курсауры»ны) телгә ала (История древнего Востока. М., 1953, с.69). Курсауры исеменең *уры* иҗекләре татарча «шәһәр» дигәнгә туры килә. Мондый исемдәге шәһәр-дәүләт борынгы Месопотамиянең кайсы җирендә урнашкан булгандыр, анысы билгесез. Әмма шунысы билгеле: бүгенге Татарстанда Курса (Түбән Курса, Югары Курса, Курсабаш) авыллары һәм Курса суы елгасы бар (Тат.-рус.сүзлек. 1966. 799, 801, 793 б.; Г.Ф.Гарипова. Татарстан гидронимнары сүзлеге. Казан, 1984, 74 б.).

Шумерларның Урдан төньяктарак, шул ук Евфрат елгасының уң ягында, Урук дигән шәһәрләре дә булган (В.К.Афанасьева. Гильгамеш и Энкиду. М., 1979, с.6). Исеме нигезендә фикер йөрткәндә, *Ур-ук* «Ур улы» булып аңлашыла. Шумер тарихында атаклы бу шәһәрнең (б.э.к. III мең еллыкта — 2615—2500 еллар чорындагы) патшасы Гильгамеш булган. Гильгамешны элегрәк ярым мифик, легендар шәхес дип исәплиләр иде. Хәзер ул ре-

аль патша булган дип уйланыла. Урук шәһәре менә шул Гильгамеш (яисә Бильгамес — ИдВ, I, с. 169) вакытында биш шәһәр берләшмәсенә буйсынган. Берләшмәнең башкаласы Киш дип аталган.

Эпик легенда хәбәр иткәнчә, Киш патшасы Ага көннәрдән бер көнне Гильгамешка илче юллый һәм аның Киш башлап җибәргән ирригация эшләрендә катнашуын таләп итә. Гильгамеш баш тарта. Ике арада сугыш башлана. Киш җиңелә. Шулай да соңыннан Ага белән Гильгамеш ничектер уртак тел табалар.

Киш патшасының исеме — татарча. Кече ир туганнар бездә өлкән ир туганны *ага, агай* дип атыйлар. Бу сүз туган булмаган кешеләр тарафыннан да кулланылырга мөмкин. Өлкән һәм дәрәҗәле кешегә карата, ягъни. Бу хакта сүзлекләрдә әйтелә. *Ага*ның сүзлекчеләр күрми калган икенче бер мәгънәсе дә бар. «Усал булсаң асарлар, юаш булсаң басарлар, урта юашрак булсаң, ил агасы ясарлар» дигән мәкаль-такмакта *ил агасы* турыдан-туры «патша» булып аңлашыла.

Киш патшасы Аганың әтисе дә патша булган һәм Менбарагеси дип аталган (ИдВ, I, с. 168). Бу исемне без *Мен-бар-агеси* рәвешендә таркатабыз. *Мен*не «мин» дип, *агеси*не «агасы» дип төзәтсәк, бу шулай ук татарча булачак. Сүз уртасындагы *бар* кем, нәрсә булыр икән? Шумер телендә *бару* — «жрецы, занимавшиеся истолкованием знамений» дигән мәгънәгә ия (Сетон Ллойд. Археология Месопотамии. М., 1984, с.48). Шул ук термин аккад телендә «гадатели» («күрәзәчеләр») дигәнне аңлаткан (ИдВ, I, с. 334). Ахыргы *у* күплек күрсәткече булса, *бар* сүзе дин башлыгын белдерә булып чыга. Шулай итеп, Киш патшасы Аганың әтисе дә «ага» һәм аның исеме «Мин дин башлыгы *бар*ның өлкән ир туганы яисә «патшасы» дигәнне хәбәр итә икән.

Шумерга кагылышлы фәнни әдәбиятта Киш исеме еш телгә алына. «Одним из наиболее значительных городов был Киш, который согласно шумерской легенде, получил «верховную власть» от богов сразу же после потопа» ди Крамер (шунда ук, с.43). «Этот город, первый в перечне династийческих столиц, упоминаемых в «Царском списке», весьма чтился шумерами; впоследствии правители других городов, добившиеся гегемонии над всей «Страной» (Шумером), нередко принимали титул «царь Киша» ди Ллойд (шунда ук, с.120).

Биш шәһәр гегемоны Киш исеме татарча *биш* сүзенең фонетик варианты ул. Биш — изге сан һәм аны изгеләштерү менә шул Кишнең аллалар тарафыннан бил-

геләнгән язмышыннан соң башланмады микән дип әйтәсе килә. Мәсәлән, борынгы Месопотамия, Мисыр патшалары үзләрен дүрт якның хакиме дип исәпләгәннәр, ягъни дөньядагы һәр дүрт як үзәктәге Бергә буйсынган булып аңлашыла. Татар бүген дә «дүрт ягым — кыйбла» дип сөйләшә. Болай дигәндә ул үзен дүрт якка баш булган элеккеге хакимнәргә тиңләштерә сыман. Билгеле, аңлы рәвештә түгел — гадәт буенча гына. Платон Атлантидасы белән биш игезәк бертуганнар идарә иткән. Идел буе болгарларында дүрт кечерәк патша бер Олы патшага буйсынган. Казан ханлыгында бер хакимнең дүрт карачысы булган. Татар музыкасы биш тавышка («пентатоника»га) нигезләнгән. Тарихи «биш»кә моның бернинди катнашы юк сыман. Ләкин бу факт үзе генә дә «биш» теориясенең безнең канга никадәр тирән кереп урнашуы турында сөйләмичә, тагын нәрсә турында сөйли соң!

Биш шәһәр берләшмәсе таркалып, аның башкаласы Киш җимерелгәч, чит төбәкләрдә яңа «Киш»ләр барлыкка килгән. Аның берсе — Тигр елгасының югарыгы агымында, хәзерге Ван күленнән көньяк-көнбатышта урнашкан Уркиш шәһәре (ИдВ, I, с. 258; карта «Древняя Месопотамия III-II тыс.до н.э.»). *Ур-киш*-не «Зур Киш» дип тә, «Киш шәһәре» (*уры*)» дип тә аңларга була. Б.э.к. II мең еллыкта Урта диңгез буенда Мукиш дигән бер дәүләт булуы мәгълүм (ИдВ, Ч. II, М., 1988, с.134). *Му-киш* «бу — Киш» («это — Киш») дигәнгә туры килә.

Данлы-атаклы, илаһи «киш»ләр безнең якларга да килеп җиткәннәр. Татарстанның Арча районында Иске Кишет, Яңа Кишет, Кишмәт авыллары бар (Татарстан республикасының адм.тер.бүленеше. Казан, 1992, 54, 53 б.).

## ТАТАР МӘКТӘБЕНӘ ... БИШ МЕҢ ЕЛ?

Шумерларның судан, камышлы күлләрдән башка тагын бер табигый байлыклары булган. Ул да булса, кызыл балчык. Савыт-саба, кирпеч кебек әйберләр генә түгел, иң беренче «кәгазь», «дәфтәрләр» дә Шумерда кызыл балчыктан ясалган.

Салам, яфрак кисәкләреннән, төрле чүп-чардан һәм минераль тозлардан арындыру өчен кызыл балчыкны башта суга салып җебеткәннәр. Суны түккәч, савытта чип-чиста балчык торып калган. Чистартылган юеш балчыкны сыгып, әвәләп, камырсыман хәлгә китергәннәр, тиешле формага керткәннәр. Юеш балчыкка очланган камыш белән җиңелчә басып, сызып язганнар. Язулы балчыкларны кояшта киптергәннәр. Аеруча әһәмиятле

ләпәшкәләрне («табличкаларны») утлы мичләрдә кыздырганнар. Кыздырганның соңында балчыктагы минераль тозлар тәмам юкка чыккан. Шул рәвешчә эшкәртелеп ташка әйләндерелгән язулы балчык кисәкләре, меңәр еллар җир астында ятсалар да, бернинди үзгәрешсез безнең көннәргә кадәр сакланып калганнар (М.А.Дандамаев. Вавилонские писцы. М., 1983, с. 32, 33).

Иң беренче язулы ләпәшкәләр борынгы Урук хәрабәләре арасында табылган. Пиктографик билгеләр төшерелгән балчык кисәкләренең күбесендә хуҗалык исәп-хисабы һәм административ язулар булган. Арада уку-укытуга кагылышлы текстлар да табылган. «Это свидетельствует о том, что по меньшей мере за 3000 лет до н.э. шумерские писцы уже занимались вопросами обучения» ди С.Н. Крамер (История начинается в Шумере. М., 1965, с.17). Б.э.к. III мең еллык урталарында инде Шумерда укырга, язарга һәм башка «фәннәргә» өйрәтә торган төрле типтагы мәктәпләр күп булган.

Фара чорына (б.э.к. 2600—2500 елларга) карый торган административ текстлардан башлап, язулы ләпәшкә («глиняная табличка») шумер телендә dub, писер («писец») dub-sar дип, язу («писать») sar дип аталган (Дандамаев, с.6). Шумерча nam-dub— sar писер эше (писер һөнәре), («писцовое дело (искусство») дигәнне белдергән. Шумерда язу системасы барлыкка килгән чорда (ягъни моннан биш мең еллар элек) уңыш һәм тудыру алиһәсе («богиня урожая и плодородия») Нисаба писерләрнең якчысы исәпләнгән (Дандамаев, с.7).

Дуб, сар, нам, Нисаба... Барысы да шумер сүзләре һәм шул ук вакытта татар сүзләре дә кебек. 1966 елгы Татарча-русча сүзлектә *нам* книжное дип, 1979 елгы Аңлатмалы сүзлектә иске дип аңлатылган (ТРС, 393 б.; ТТАС, II, 433 б.). Мәгънәләре: исем, дәрәҗә, дан, данлылык. Татарда *нам* катнашында күп кенә сүзләр ясалган. Мәсәлән, *намаз, намлы, намдар, намус. Нисаба*ның *ни* иҗеге «алиһә» дигәнне белдерә, *саба* исә бүгенге татарга төрле яктан таныш. Татарстанда Саба авыллары, Саба елгалары, Саба районы бар, сабалылар бар. Шумерга якын җирләрдә — Гарәбстан ярыматавында борынгы заманнарда Саба (Сава) дәүләте булган. Шундый ук исемдәге дәүләтнең Италия җирендә дә булуы мәгълүм. *Саба* татарча «савыт-саба» дигәнне дә, кымыз ясый торган һәм кымыз саклый торган тире капчыкны да, иртәнге талгын, шифалы җилне дә белдерә.

*Сар* күп кенә телләрдә «патша, хаким, алла» дигәнгә туры килә. Шумерча *дуб-сар*-дагы *сар*-ны «патша, алла»

дип тә аңларга була, әлбәттә. Ләкин бу бик үк дөрес булып бетмәс. Мондагы *сар* татарча *сыр*-ны күз алдында тота сыман. Татарча *сыр* русча «грань; резьба, резной узор» була. *Сырлау* дисәк, бу — «делать ребристым (*поверхность чего-л.*)» (ТРС, 496 б.). *Сырлау*, сирәк булса да, «язу-сызу» мәгънәсендә дә кулланыла (ТТАС, II, 704 б., 1 мәгънә).

Татар телендә *дуб* сүзе юк, ахрысы. Татарча-русча сүзлеккә *дуп* «дубленый», *дуп тун* «дубленая шуба, дубленка» теркәлгән (ТРС, 137 б.). Бу сүз, күрәсең, рустан алынган дип уйланыла. Шуңадыр, ахрысы, Аңлатмалы сүзлеккә *дуп* кертелмәгән. Русча-татарча сүзлектә *дубить* «дуплау, кайрылау» дип аңлатылган (Русско-татарский словарь. М., 1985, с.143). Димәк, татарда *дуплау* бар дигән сүз.

Шумерча *дуб-сар* аккадча *тупшарру* дип аталган (Дандамаев, с.6). Шулай итеп, шумерча *дуп* аккадча *туп* булган. Бүгенге татарда *туп* актив сүзләрдән санала. Турыдан-туры *дуп*тан үзгәргәнме ул, аккадча *туп*тан алынганмы, әйтүе кыен. *Туб* һәм *туп*тан *тубык, тупса, тубыр, тубырлу* кебек сүзләр ясалган. *Туп*-ның нечкә варианты — *түп*. Татарча моны сыгынты дип тә атарга була, русчасы — выжимки, жмых (ТРС, 581 б.). *Түп*нең *түб* варианты мәгълүм. Беренче чиратта бу — *түбә*. Өй түбәсе, тау түбәсе, баш түбәсе, түбә-тәй.

Татар телендә *түбә* нинди дә булса калку нәрсәнең өске өлеше булып аңлашыла. Чынлыкта бу алай түгел. *Дуб, туб, туп* кебек түб тә иң элек катылыкны, ныклыкны, тыгызлыкны белдерә. Мәсәлән, *өй түбәсе*. Көньяк илләрдә, билгеле булганча, өй түбәләре яссы формада. Элек тә шулай булган, хәзер дә шулай. Яссы түбәләр, күрәсең, кызыл балчык һәм камыш катыштырып катырылган тоташ масса рәвешендә булган. Көньяк халкының ярты гомере дигәндәй менә шундый яссы түбәдә үтә. Төннәрен анда алар йоклыйлар, көндез җимеш-фәлән киптерәләр, вак-төяк нәрсәләрен куеп торалар. Безнең салкын якларда мондый яссы түбәләр юк. Ләкин бездә әле булса бик ерак та торып калган яссы түбә төшенчәсе яши. Салкын чакта өйдән җылы чыкмасын өчен, кыек астындагы тигезлеккә — түшәмнең тышкы ягына — *туф*-рак (кайбер җирләрдә *туп*-рак) салалар. Туфрак салынган түшәм өстен әдәби телдә *чорма* «чердак» дип атыйлар (ТРС, 640 б.). Минем туган якта (Яңавыл районы Күчтавылда) *чорма* сүзе юк. Русча «чердак» бездә *чарлак*. Ләкин ул «яссы түбә» түгел — «веранда». Бездә туфрак салынган тигезлек тә, кыек түбә дә *өй түбәсе* дип атала. Бер өйдә ике түбә имеш!

*Түб* сүзенең *төп* варианты төрле мәгънәдә кулланыла. Аңлатмалы сүзлектә, мәсәлән, 26 мәгънә күрсәтелгән (ТТАС, III, 254—256 б.). Шуларның кайберләре русча: пень; дно; корень; суть; смысл; главный (ТРС, 574, 575 б.)

Шумердан көнчыгыш якта, таулы һәм үзәнле җирләрдә, бик борынгы заманнарда ук Элам дигән дәүләт булган. Шумерлар менә шул Эламнан күчеп килмәделәр микән ике елга тамагындагы җирләргә дигән фикер дә бар фәндә. Элам телендә «табличка» теппи дип (Дандамаев, с.10), «главный писец» *тепир* дип аталган (История древнего Востока. Ч.I. Месопотамия. М., 1983, с.393). *Тепир*не «главный муж, мужчина» дип тә, «писец глиняной таблички» дип тә аңлатырга була. Татарда *мәктүб* дигән бер сүз бар. *Мәктүб* ул «хат, язулы нәрсә» дигән сүз. Русчасы: «письмо; записка; послание» (ТРС, 384 б.). *Мәктүб*кә якын *мәктәп* бүген һәркемгә таныш дип исәплик. *Мәктүб* һәм *мәктәп*нең *түб* һәм *тәп* иҗекләре шумерча һәм эламча *дуп-туп, теп* терминнарына нәселдәш.

*Мәк* нәрсә? *Мә-к*не без «Мә улы» дип аңлыйбыз. «Мә улы» кайбер очракта «ата, ир кеше» дигәнне белдерә, шулай да күбесенчә «Мә»нең, ягъни мифик Ананың җенес әгъзасын күз алдында тота. Һәрбер савыт, куыш, батынкы җир, борынгы идеология нигезендә, Ананың, Җирнең гаурәтенә тиңләштерелә. *Мәк*нең мондый мәгънәсе, мәсәлән, татарча *кисмәк* «кадка, кадушка» сүзендә чагыла. Терминның кис өлеше шумерча *гиш*кә тәңгәл. Шумерча GIӨ — «агач» (Дандамаев, с.10). Шумерлар эшкә яраклы агачны читтән китерткәннәр. *Гишкис*, бәлки, киселгән агачны гына аңлаткандыр дип әйтәсе килә. Шулай итеп, *кисмәк (кис-мәк)* — киселгән агачтан эшләнгән *мәк* (савыт) булып чыга.

Катырылган ләпәшкәгә язылган текст шумерча IM. DUB дип аталган (Дандамаев, с.16). Б.э.к. VI гасырда Вавилония текстларында immu сүзе «запись», «табличка» мәгънәсендә кулланылган (Дандамаев, с.23). Аккад телендә targumannu («тәрҗемә») булган сүз шумер телендәге eme-bala сүзенә тәңгәл икән (Дандамаев, с.14). Китерелгән мисалларның сүз башындагы IM, im, em иҗекләре татарча *ым*га тиң. Татарда *ымлау, ым кагу, ым ясау, ым теле, ым белән сөйләшү* төшенчәләре бар. Шумерча eme-bala терминындагы *бала* сүзе дә игътибарга лаек. Беренчедән, татарда булган бала «дитя, ребенок», димәк, шумерда да булган. Икенчедән, бер телдән икенче телгә тәрҗемә итүне шумерлар *ым*ның «балалавы» рәвешендә күз алдына китергәннәр.

Язу-сызу (сырлау) һөнәренең кайчан, ничек барлыкка килүе турында Шумерда риваятьләр сөйләгәннәр. Борын-борын заманда, Тигр һәм Евфрат елгалары арасында урнашкан Урук шәһәрендә Энмеркар дигән патша яшәгән. Энмеркар кояш алласы Уту улы булган, имеш. Көннәрдән бер көнне Энмеркар су алласы Энкигә багышлап Эриду шәһәрендә Абзу (Апсу) гыйбадәтханәсе төзергә дигән карарга килгән. Моның өчен аңа күп итеп алтын-көмеш, матур ташлар һәм эшче көчләр кирәк булган. Боларның барысын да ул күршеләрдән алмакчы булган. Үз таләбен әйтеп Энмеркар төньякта таулар артында урнашкан Аратта патшасына илче җибәргән. Шуннан соң Аратта патшасы белән ике арада дипломатик сөйләшүләр башланган. Кыскасы, әлеге риваять язылган «дуб»ларның тәрҗемәчесе, америка шумерологы С.Н.Крамер «Энмеркар һәм Аратта хакиме» дип атаган «поэма»да язу-сырлау ысулын уйлап тапкан беренче кешенең Урук патшасы Энмеркар булуы турында әйтелә икән. Текстның русчасы болай: «Энмеркар... был, по мнению автора поэмы, первым, кто начал писать на глиняных табличках: он якобы избрал этот способ потому, что его «косноязычный» посланец не смог точно передать ответ...» (История начинается в Шумере. М., 1965, с.34, 35).

Русның «косноязычный» дигәне татарча — сакау. Сакау ничек сөйли? Этенеп-төртенеп һәм... ымлап, ымлыклар белән!

*1998*

# ИСТӘЛЕКЛӘР

## ҮЗЕМ ГЕНӘ ТҮГЕЛ

Иң беренче шигыремне мин өченче класста укыганда яздым. Кыш көне иде. Дәрестән соң елга аръягында, Чыршылыкта чаңгы шуып, туңып-ачыгып кайттым да күңелне биләгән шатлыклы тәэсирләрне кәгазьгә төшермәкче булдым. Шигырьне мин «Кыш» дип атадым һәм Яңавыл районында чыга торган «Октябрь юлы» газетасына җибәрдем. Ләкин «шигырьне» басмадылар. Авторга хат-фәлән дә килмәде бугай. Шулай да Яңавылда, редакциядә гарип куллы бер абый каршысында нидер тыңлап утырганым хәтердә калган.

Яңавылда бишенче класста укыганда инде мин кыш турында гына түгел, җәй-көз, яз турында да шигырьләр яза башладым. Кичләрен өстәл почмагына, пыскый каршысына утырам да, бармак белән саный-саный сүзләр чүплим. 1940 елны, ахрысы, «Яшь ленинчы»да минем өч-дүрт юллык хәбәрем басылды. Ул чактагы куанычны хәзер инде сөйләп торуның кирәге юк, дип уйлыйм. Тик шунысын әйтмичә мөмкин түгел: бөтен мәктәптә бу үзенә күрә бер вакыйга булды. Озын тәнәфестә бик күп укучыларны линейкага җыеп, завуч Баямый Мөслимов абый мәкаләне кычкырып укып чыкты.

Минем түбә күккә тиде. Ничектер бер җаен табып, кыюланып, мин Баямый абыйга моңарчы беркемгә күрсәтмәгән шигырь дәфтәремне бирдем. Мөслимов абый олы классларда татар әдәбияты укыта иде. Әдәбият мәсьәләсендә ул, күрәсең, иң зур авторитет булган. Шигырьләрне укып чыккач, минем белән сөйләшеп утырды, киңәшләр бирде. Шуннан башка берни хәтерләмим. Ләкин шунысы истә: Баямый абый кара чәчле, ягымлы, чибәр һәм шат күңелле кеше иде. Укучылар да, укытучылар да аны бик яраталар иде.

Сугышның беренче көннәрендә үк диярлек Мөслимов абый, башка яшь укытучылар белән бергә, үзе теләп фронтка китте. 1941 елның көзге, шомлы көннәрендә аларның төркем-төркем булып Яңавыл читендә марш атлап йөрүләре әле булса күз алдымда тора. Баямый абый

да, башкалар да киткән җирләреннән кире кайтмадылар. Авыр туфраклары җиңел булсын — беренче тәнкыйтьчемә, беренче киңәшчемә һәм шулай ук һәлак булган башка укытучыларга мин хәзер бүтән берни әйтә алмыйм.

Сугыш турында күп язылды. Ләкин күпме генә язылса да, ул елларның дәһшәтен, кайгысын-сагышын беркайчан да тулы итеп тасвирлап булмас иде кебек. Безнең буынның исәеп, ачылып килгән чагы шул чорларга туры килде. Бездән өлкәннәр еракта турыдан-туры дошман белән якалашканда, монда, туган җирдә калучылар көн-төн дип әйтерлек төрле кыенлыклар белән, хәтта үлем белән көрәш алып бардылар. Минем яшьтәшләрнең, кордашларның кайберләре, авыр сынауларга түзә алмыйча, бик иртә кабергә керделәр. Без менә нишләптер чыдамрак булып чыктык.

Бу хакта мин еш уйланам. Бит минем дә кыл өстендә калган чакларым күп булды. Егылмаска, бирешмәскә безгә ул чакларда киләчәккә булган ышаныч һәм яхшы, шәфкатьле кешеләр ярдәм итте... Шундый яхшы кешеләрнең беренчесе итеп мин Баямый абыйның әнисен — ул вакытта атап йөрткәнчә, «Әби»не телгә алмакчы булам. Миңа карата гына түгел, безнең бик зур ишегалдындагы барлык балаларга, барлык күршеләргә карата ул һәрвакыт ягымлы, һәрвакыт ачык күңелле һәм юмарт булды. Тирә-якта ул бердәнбер сыерлы кеше иде. Шуңа күрә, дип әйтимме, кайчан кермә, синең алдыңа сөтенкатыгын китереп куя, ничек тә синең күңелеңне күтәреп, тамагыңны туйдырып чыгара. Ә мин аларга еш керә идем. Әле Казанда укып йөргән чакларда да, юл өсте төшеп, «Әби»ләрдә кунып, ял итеп чыга торган идем.

Үзем укыган Яңавыл мәктәбе укытучыларыннан да мин заманында күп яхшылык күрдем. Шул ук «Әби»нең кызы, Баямый абыйның сеңелесе Гайшә апа Дусметова миңа карата әнисе кебек үк ягымлы һәм киң күңелле булды. Авыр елларда мине аякка бастырган, һәрьяклап миңа булышкан укытучыларымнан Шәрәфел Зәйнуллина, Шәмсенур Шәфиева апаларны, сугышта бер кулын өздереп кайткан Гали абый Хисамовны, Шиһабетдинов абыйны, аеруча Шамил абый Дускаевны мин һәрвакыт рәхмәт хисләре белән искә алам.

Әгәр дә мәгәр ул вакытларда укытучылар һәм башка кайбер кешеләр «шагыйрь булырга» хыялланып йөргән малайга гамьсезлек, битарафлык күрсәткән булсалар яисә берәр төрле ялгыш сүз-киңәш биргән булсалар, күрәсең, беркайчан да миннән язучы чыкмаган булыр иде.

Менә бер генә мисал. Унынчыны бетереп, инде ниш-

ләргә диебрәк йөргәндә, «Октябрь юлы»ның җаваплы секретаре Сөгъдә апа миңа университетның татар бүлегенә керергә киңәш итте. Редакциягә Казаннан «Кызыл Татарстан» газетасы килә иде. «Кызыл Татарстан»да университетка укучылар кабул итү турында белдерү басылган икән. Сөгъдә апаның киңәше минем күңелгә хуш килде. Бернинди икеләнүсез мин документларымны Казанга, университетка җибәрдем.

Шулай итеп, без Казанга килдек.

Университет укытучылары арасында «яхшы кешеләр»дән мин Рабига апа Хәкимованы, Латиф абый Җәләйне һәм Мөхәммәт абый Гайнуллинны әйтеп китмәкче булам. Безнең өчен алар укытучылар гына түгел, шулай ук тәрбияче дә, киңәшче дә булдылар. Мин, мәсәлән, бик тиз арада Җәләй абыйның «коткысына» биреллдем һәм, каникул вакытларында авылга кайткач, халык җырлары, халык сүзләре җыю белән мавыга башладым. Бу эш миңа бик ошады. Бик күп еллар дәвамында мин җырлар, бәетләр, табышмак кебек нәрсәләр җыеп, язып бардым. Халкымның телен, гореф-гадәтләрен аңлауда, үзләштерүдә моның файдасы әйтеп бетергесез зур булды. Халык иҗаты белән кызыксыну миндә шулкадәр көчле иде, университетны тәмамлагач, мин хәтта фольклор буенча аспирантурада калырга да исәпләп йөрдем. Ләкин шулай да әдәби иҗат юлын сайладым.

1955 елда мин беренче зур күләмле әсәремне тәмамладым. Романны иң элек Габдрахман Әбсәләмов укып чыкты. Нииндидер бер җыелышта ул мине мактап телгә алды. Шуннан соң яшь иптәшнең беренче романын башкалар да укыдылар, яраттылар, мактадылар, ләкин... бастырырга ашыкмадылар. Ни өчен дигәндә, романның телендә-стилендә «фольклор материаллары» кирәгеннән артыграк булып чыккан иде. Аннан соң авыл тормышын да автор үзенчәрәк тасвирлаган иде. Яшь иптәшкә романның телен беркадәр үзгәртергә, кайбер нәрсәләрне сызып ташларга киңәш иттеләр. Ләкин автор бернәрсә дә үзгәртергә теләмәде. Журнал редакторы Гази Кашшаф та алай артык күндәмнәрдән түгел иде. Романны бастырудан ул бөтенләй баш тартты, һәм менә шунда Язучылар союзының ул чактагы председателе Гомәр абый Бәширов, бар җаваплылыкны үз өстенә алып, романны шул көенчә бастыруга иреште.

Шулай итеп, минем алда зур әдәбият ишеге ачылды. Дөрес, беренче ишек ачылу белән барлык ишекләр дә җиңел генә, үзеннән-үзе генә ачылган икән дигән сүз түгел. Бер генә зур әсәрем дә минем бәхәссез, каршы-

лыксыз дөнья күрмәде дисәм, һич тә ялгыш булмас. Мисал өчен «Сызгыра торган уклар» романының басылу тарихын искә төшерергә була. Роман «Казан утларын»да инде китте дигәндә, тоткарланып калды. Мәсьәләне ачыклау өчен, ягъни редактор белән автор арасындагы бәхәсне хәл итү өчен, Язучылар союзына мөрәҗәгать итәргә туры килде. Кульъязманы Союз идарәсе һәм редколлегия әгъзалары укып чыкты. Романны тикшерү өчен махсус утырыш җыелды һәм, бер-ике кешене исәпләмәгәндә, барлык язучылар авторны яклап чыктылар.

Монда шуны да әйтергә кирәк, язучыларның күпчелеге бездә татар әдәбиятының, татар культурасының үсүе өчен чын күңелдән янып яшәүче кешеләр. Уртак кайгыны, уртак мәнфәгатьләрне алар һәрвакыт үз кайгыларыннан, үз мәнфәгатьләреннән өстен куялар һәм кирәкле әсәр турында сүз барганда ныклык, принципиальлек күрсәтә беләләр. Моның шулай икәнлеген миңа берничә мәртәбә «үз җилкәмдә татырга» туры килде. Миңа өлкән буын каләмдәшләр дә, кордашлар да, шулай ук яшьләр дә, гомумән, күп булышлык күрсәттеләр. Гомәр Бәширов, Сибгат Хәким, Әмирхан Еники иҗатымда, тормышымда минем чын мәгънәсендә терәк һәм таяныч булдылар.

Иң ахырда мин үземә бары уңай яктан гына тәэсир иткән тагын бер-ике кешегә тукталып китмәкче булам. Икенең берсе — Шәйхи Маннур, икенчесе — Хәмит Ярми.

Гаделлек, дөреслек өчен теләсә кем белән якалаша ала торган Шәйхи Маннур туры сүзле һәм шактый ныкхарактерлы иде. Язган әсәрләрем өчен ул мине якын күрде, җыелышларда, киңәшмәләрдә һәрвакыт мине яклап чыкты. Ләкин кайчагында ул миңа үтемле генә тәнкыйть сүзләре дә әйткәләде. 50 нче елларда ул хәтта миннән җиңелчә көлеп эпиграмма да язды. Тәнкыйтенең төбендә усал ният юклыгын белгәнлектән, мин аңа беркайчан үпкәләп, ачу саклап йөрмәдем.

Фольклор белгече, филология фәннәре докторы Хәмит Ярми белән мин университетта укуымның беренче елларында ук таныштым. Бу танышу Җәләй абый аркасында булды. Минем халык иҗаты белән кызыксынуымны күреп, 1948 елның җәендә Хәмит абый мине үзе белән бергә фольклор экспедициясенә алып чыкты. Шуннан бирле без аның белән әледән-әле очрашып, аралашып тордык.

Хәмит Ярмине Шәйхи Маннурның капма-каршысы, дип әйтергә булыр иде. Йомшак күңелле, ягымлы, һәркем белән уртак тел таба белә. Әгәр, әйтик, сиңа берәр киңәш бирергә теләсә, беркайчан шулай ит, болай ит, дип вәгазь

укымас. Бөтенләй сиңа катнашы юк кебек итеп, үз башыннан үткән, йә булмаса кешедән ишеткән берәр гыйбрәтле хикәя сөйләр. Аңласаң аңлыйсың,— аңламасаң — анысы инде синең эш. Кайбер әдәп, культура кагыйдәләреннән хәбәрдар булмаган авыл малаена аның гыйбрәтле хикәяләре тәэсир итми калмагандыр, дип уйлыйм.

Чыннан да, безнең халыкта элек-электән «Әби», Гомәр Бәширов, Әмирхан Еники, Сибгат Хәким кебек ярдәмчел һәм аңлы, киң күңелле кешеләребез булмаса, без, күрәсең, бүгенге көнебездә ирешкән нәрсәләрнең күбесеннән мәхрүм булган булыр идек.

Язучы булу өчен күп нәрсә таләп ителә. Моның өчен иң әүвәл табигый талант һәм тырышлык кирәк. Ләкин сине аңлаучы, кирәк чакта сиңа ярдәм кулы сузучы халкың — әйе, халкың!— булмаса, ялгыз талант белән генә әллә ни ерак китеп булмый.

# ХӨЙЙЕ БАБАЙ

1934 елда, әткәй үлгәч, без инәкәй белән Күчтавылдан Янтыкка кайтып киттек. Күчтавыл дигәне минем туган авыл, Янтык дигәне — инәкәйнеке. Төп йортта, Янтыкта, инәкәйнең бертуган апасы торып ята. Аның да ире юк, минем яшьтәге бер малае гына бар. Малае Зәйкәт исемле. Инәкәйнең апасын мин «яшәби» димен.

Олыларның үз дөньясы, балаларның үз дөньясы дигәндәй, тиздән Янтыкта мин күрше-тирәдәге малайлар белән аралаша башладым. Үземә күрә төрле яңалыклар белдем. Яңалыкларның берсе шул булды — безнең очта «Партизан бабай» дигән Гаптерәхим яши икән. Авылның икенче очында, бик еракта, Гаптерәхимнең абзасы Гаптерәшит бар икән. Кайчагында ул безнең якка да килеп чыга. Энесе Гаптерәхимнең хәлен белергә.

Өй буенда, урам якта уйнап ятканда, Гаптерәшитне күрү белән, кемдер пышылдап: «Әнә, Хөййе бабай килә!» — ди. Без шундук тынып калабыз. Шунда берәрсе миңа: «Син аңа Хөййе бабай!» — дип кычкыр ди, икенчесе: «Юк, кычкыра күрмә!» — дип кисәтергә ашыга.

Бервакыт, икенчедәме, өченчедәме укыган елны, көз көне, урам як тәрәзәдән карап утырам. Ни күзем белән күрим — Гаптерәшит карт китеп бара. «Партизан» энесеннән кайтып бара бугай. Әле дә күз алдымда: өстендә киндер чапан, башында мескен бүрек, кулында таяк. Тоттым да мин моңа: «Хөййе бабай!» — дип кычкырдым. Кинәт бу туктап калды, барган юлыннан борылды да, ашыгып, капкага таба килә башлады. Котым очты, шундук идәнгә атылып төштем. Каядыр качарга кирәк. Кая? Тоттым да мич башына менеп киттем, аннан мич арасына шуышып төштем. Миннән башка өйдә Зәйкәт белән «яшәби» дә бар иде. Ни булганын алар сизми дә калдылар.

Җилләнеп, өйгә Гаптерәшит бабай килеп керде. Керде дә Зәйкәтне күреп алды. Күреп алды да тотынды моны тиргәргә! Яхшыдан яман туган, ди, тәүфикъсыз, тәрбиясез, ди, мәктәптә сине шуңа өйрәтәләрмени, укытучы апаңа әйтеп колагыңны бордырам әле мин синең, ди.

Зәйкәт тә, «яшәби» дә аптырап калдылар, ни әйтергә дә белмиләр. Гаптерәшит бабай ике сүзнең берендә «хөййе» дигән сүз кыстырырга ярата икән, шуңа аны балачага «Хөййе бабай» дип үрти икән. «Яшәби», күрәсең, белгән моны. Нидер сизенеп, бу юри генә Зәйкәтне тиргәргә тотынды. Олы кешегә кычкырган өчен сөяген он итәм әле мин аның! Үтерәм мин аны, Гаптерәшит абзыкаем, ди.

«Яшәби»нең шулай дип әйтүе булды, «Хөййе бабай» шундук юашланып калды. «Чү-чү, килен, ятим балага суга күрмә!» — ди, Зәйкәтне яклап.

«Хөййе бабай» чыгып киткәч, тузанга буялып, курка-курка мич арасыннан мин килеп чыктым. Хәзер инде болар мине тиргәячәкләр дип уйлыйм. «һи, җүнсез!» — дигән булды «яшәби», елмаюын яшерә алмыйча. Шуннан башка берни әйтмәде. Аның ачуланмавын күреп, мин көлеп җибәрдем.

Җүнсезен җүнсез инде анысы. Шулай да түзәргә була. Хөййе, бабай!

## ПУЛАТ

*(Яңа әсәрдән өзек)*

Әткәйнең биш сеңлесе була. Яшь чагында шаяртып, мактанып: «Кемнең тагын биш сеңлесе бар? Дөньяда миннән бай кеше юк!» дип әйтергә яраткан имеш. Сеңелләренең барысы да кияүгә чыга. Берсе Күчтавылга, икенчесе Айбүләккә, өченчесе Гөтбергә, дүртенчесе Пулатка, бишенчесе, иң кечесе — Көеккә. Күчтавылдагы Майҗиан дигәне әле дә, 1988 елда да исән. Инде туксанга якынлашып килә. Тимергали абый шуның малае.

Әткәйнең барлык туган-тумачалары белән дә аралашырга ничектер җае булмады. Мин бары Күчтавыл Тимергали абыйларны яхшы беләм дә, Пулаттагыларны беләм. Бәләкәй чакта Гөтбергә дә, Айбүләккә, Көеккә дә барганым бар. Әз-мәз генә булса да аларның да тормыш хәлләрен, балаларын беләм кебек. Тик шулай да минем өчен иң якыны — Пулат.

Пулат Янтыктан көнбатышта, өч-дүрт чакрым ераклыкта. Калкулык артында гына. Ушиа дигән елгага коя торган бер чишмә буена утырган. Бер урамы биек яр өстендә, икенче урамы чишмәнең икенче ягында, тигезлектә. Авылның бер башы Ушиа ярына килеп терәлә диярлек. Пулат зур түгел, куп булса йөз, йөз илле йорт.

Карурман Пулатның өстенә аварга тора. Чыршы, каен, юкә, шомырт... Ушиа буенда болыннар, әрәмәләр. Җире таулы-ташлы. Иген игү өчен рәте юк. Кайбер төштә кызыл балчык, кайбер төштә — ком. Елга буендагы, диңгез буендагы кебек. Җәй көне аяк батып тора. Миңа татарның әкият геройлары — шүрәлеләр, пәриләр еш кына шул Пулат урманнарында, Ушиа буйларында яшәгәннәрдер кебек.

Дию пәриен алдаган төлке дә нәкъ Пулатта, ындыр артындагы чыршылыкта гына йөргәндер кебек, күлне күккә асам дип куркыткан батыр малай да кайчандыр шунда, Пулат ягында тугандыр кебек. Пулаттан бер-ике чакрым читтәрәк, Ушиа суында зур гына тегермән бар иде. «Пулат тегермәне»нә бөтен тирә-як килә торган иде. Урман арасында, су-камыш янында көн-төн шаулап, дөбердәп утырган тегермән миңа кайчандыр дөньяның иң сихри үзәге булып, туклык һәм бәхет чыганагы булып тоела торган иде. Минем «Тегермәндә» дип аталган иң беренче хикәям «Пулат тегермәне»н күз алдында тотып язылган.

Безнең әткәй яшь чагында «Пулат тегермәне»нә йөргән, инәкәй дә шул якларда булгалаган. Иң элек алар

шул якта — Пулаттамы, Искактамы танышканнар. Инәкәй Күчтавылга килен булып төшкәч тә Пулат белән араны өзмәгән. Кемнәрдер аша сөйләшеп-киңәшеп, әткәй үзенең Гылмехәят исемле сеңлесен Пулатка Билал дигән кешегә кияүгә биргән. Инәкәй килен булып килгәндә Гылмехәят яшь Салиханың иң якын сердәшенә әверелә. Гылмехәят Пулат Билалга кияүгә чыккач та алар барышып-килешеп торалар. Ике арадагы дуслык-якынлык безнең әткәй үлгәч тә бозылмады.

Гылмехәят әткәйнең иң яраткан сеңлесе була. Гылмехәят тә безнең әткәйне чын күңелдән якын күргән булса кирәк. Әткәйне ул «абзый» ди, инәкәйне «җиңгәй» ди. Ул аларны гел искә алды. Бары яхшы яктан гына искә алды.

Билалны Яңавыл ягында белмәгән кеше юк. Аны Хуҗа Насретдин урынына мәзәк итеп сөйлиләр, төрле кызык хәлне аңа япсарырга яраталар. Элегрәк аның ниндидер сәер гадәтләре булган, ахрысы. Инәкәй сөйли торган иде: бер елны бу алышынып өеннән чыгып киткән, сукасын елгага агызып җибәргән, имеш. Яшь хатынын ташлап үзе Күчтавылга килеп чыккан. Әткәй белән инәкәй җайлап, үгетләп моны Пулатка кайтарып куйганнар. Беркайчан ул колхозда эшләмәде — күбрәк тегермән тирәсендә йөрде, урманда йөрде. Тегермәнче булганын хәтерләмим, ләкин якын-тирәдәге урманнарга бик озак Билал баш булды. Хәзер инде мин уйлыйм: колхозлашу елларында колхозга керүдән котылырга теләп йөрмәде микән ул алышынган кеше булып?

Мин белгән Билал җизнәй бер дә алай алышына торган кеше түгел иде. Эшчән, тырыш, булдыклы. Искечә дә күзе күрә, яңачаны да дөрес сукалый. Калын, көр тавышлы, шаяртып сөйләшергә ярата. Килгән-киткән кеше белән аралашып яши. Башка авылдан, Яңавылдан аларга кеше еш килә. Утынга, урман кисәргә, урман чистартырга, печән чабарга. Кайчан килмә, Билал җизнәй урманда, болында булыр. Ишегалды иркен. Мал-туар асрый. Корт асрый. Сугыш елларында, аннан соң да ат тотты. Рөхсәт белән. Ул елларда урманчыларга рөхсәт ителде. Безнең кебек кыш көне кар ерып урманга утынга йөрми — җәйдән әзерләп куйган каен утыны бер кышка түгел, өч кышка җитәрлек.

Янтыкта чагында мин аларга еш бардым. «Кунакка» барам. Чакыручы юк. Барам да керәм. Әткәйнең сеңлесе Гылмехәятне мин «Әбестәй» дип атыйм. Җизнәй минем килгәнгә әллә ни куаныч белдерми, әбестәй генә ачык чырай күрсәтә. Шулай да аларда күңелле. Аларның дүрт балалары булды. Олы кызлары Мәдәния миннән зуррак,

икенчеләре Әхнәф бер-ике яшькә кечерәк. Без күбрәк Әхнәф белән уйныйбыз. Бер кышны Әхнәфкә магазиннан чын коньки алганнар. Минем андыйны төшемдә дә күргәнем юк. Конькиның бер сыңарын мин тагам, икенче сыңарын Әхнәф тага. Шул кышны урамда, ат юлында сыңар конькида шуып рәхәтләндек үзебез дә!

Аларның тагын Ганс дигән малайлары бар иде.

Сугыш барган елларда Гансны Даниска алыштырдылар. Данис соңыннан эчкечелеккә бирелгән, кайдадыр Себер ягында торып калган. Әхнәф хәрби булды, майор дәрәҗәсенә иреште һәм гомергә Салават шәһәрендә төпләнеп калды. Әбестәй белән Билал җизнәй күптән инде җир куенында.

һибә дигән иң кече кызлары сугыш елларында туды. Мин белгән әбестәй бик чибәр хатын иде. Уртачадан калкурак, җыйнак гәүдә. Йөзе озынчарак, аксыл. Сызылып торган кара каш, кара чәч. һибә — әбестәйгә охшаган. Мин аның иң яшь чагын, иң чибәр чагын хәтерлим. Балкып, нур чәчеп торган шомырт кара күзләр, күпереп, тузгып торган кара чәч, шикәрдәй ап-ак тешләр, җыйнак килешле алсу иреннәр. Теләсә нинди конкурста теләсә нинди гүзәлне ямьсез итеп күрсәтерлек буй-сын.

Безнең әткәй озынча битле, кара чәчле, ләкин куе зәңгәр күзле булган. Күрәсең, ул каяндыр аерым бер тамырдан, сеңлесе Гыйлмехәят аерым тамырдан тармакланган. Әткәй ни дәрәҗәдә матур булгандыр, әйтә алмыйм, әбестәй исә, һичшиксез, бик борынгы гүзәлләр иленнән килгән. Күпме батыр ирләр даулашмагандыр әбестәйләр — һибәләр токымыннан булган сылу кызлар өчен! Борынгы сынчылар Атлантида алиһәләрен нәкъ менә безнең әбестәйләр — һибәләр нәселендәге хатын-кызларга карап ясаганнардыр сыман.

Илленче еллар ахырында, бер кышны, Казаннан Янтыкка кайткач, Пулатка киттем. Элеккечә «кунакка», хәл белергә. Барып керсәм, ишек төбендә яшь кенә бер кыз чыпта үреп тора. Чыпта тасманың үрелгән башы ишек яңагындагы кадакка эләктерелгән, икенче башы идәнгә салынып төшкән. Ул елларда безнең якларда «Заготконтора» ни өчендер шундый чыпталар, киптерелгән тал кабыгы, фәлән-төгән җыя иде. Шуңа күпмедер акча бирәләр. Бөтен тирә-як шундый кәсеп белән шөгыльләнә.

Кызның өстендәге киеме әйтеп сөйләрлек түгел — сәләмә дә сәләмә, ул да сәләмә. Шул сәләмәгә юкә чүбе буялып беткән. Идәндә, аяк астында юкә төргәге, үрелгән чыпта тасмалар аунап ята. Тетелеп теткән киеме аша кызның яшь тәне күренә.

Мин килеп керү белән, мине танып алу белән, каушап калды, елмайган булды, кызарып ачык изүенә үрелде. Ниндидер өн чыгарды да, мунчаласын ташлап гөлбәч ягына кереп китте. Бераздан үзенең рәтлерәк күлмәген киеп чыкты, кул биреп, «Нурихан абыкаем» дип исәнләште. Бала вакытында ул мин килгәч таяктай нечкә беләкләре белән, ястык мамыгына баткан пумала башы белән муенга сарыла торган иде.

Икенче көнне һибә мине авылдан чыкканчы озата барды. Көн буранлы иде Янтыкка кадәр озат дисәм, бер уйламый ияреп барыр иде. Ул чакта һибә миңа бик кызганыч булып тоелды. Юл буена мин аның язмышы турында уйландым. Ул елларда теләсә нинди авылда шундый хәлгә юлыгасың. Ачлык, мохтаҗлык бугаздан эләктереп алган да, һич җибәрер исәбе юк. Сугыш елларында да кытлык күрмәгән Билал өендә дә шундый хәерчелек булгач, башкалар турында ни әйтмәк кирәк? Берәүләр чыпта үрә, икенче берәүләр чабата ясап чабата сата — шуның белән тамак ялгаштырып тора. Кайберәүләр, авылда рәт юклыгын һәм булмаячагын күреп, каядыр чит якларга китеп баралар.

Икенче елны, ахрысы, тагын бардым Пулатка, һибә унны бетергән. Бу юлы элеккегә караганда да чибәррәк һәм кыюрак күренде. Ләкин күңелендә ниндидер борчуы бар. Менә ул унны бетерде. Буй җиткән кыз. Шәһәргә китеп институтка керергә хыялланмый.

Институт ул кемнәрдер башкалар өчен. Аңа табигать кушканча яшәргә кирәк. Кияүгә чыгарга, оя корып, балалар үстерергә. Җегетләре юктыр дип әйтә алмыйм. Ләкин бернинди киләчәге күренмәгән ач-ялангач авылда ничек итеп оя корырга да, ничек итеп яшәп китәргә?

Кешеләр һаман каядыр читкә китә торалар. Ашлык хәзер авылда түгел, шәһәрдә үсә. Себердә, Воркута, Урта Азия якларында. һибә Әхнәф абыйсы янына Салават шәһәренә китәргәрәк уйлаштыра, ахрысы. Шулай ук туган ягын да ташлап китәсе килми бугай. Соңыннан ишетеп белдем: киткән ул Әхнәф янына. Эшкә кергән. Ниндидер утын складына. Ни әйтсәң дә, урман, агач эше аңа таныш. Кемгәдер кияүгә чыккан, балалары булган. Башта абыйсы-җиңгәсе янында торган. Күпмедер азапланып йөргәннән соң «бер кумытлы кывартир» алган. Хәзер инде ул бәхетледер, бәлки. Ире эчеп алкашка әйләнмәгән булса.

Аның кебек бәхет эзләп күпме бәхетсезләр — яшь, сылу кызлар туган авылларын ташлап читкә киттеләр! Кая гына барып чыкмады да, нинди генә хәлләргә юлыкмады безнең мескен татар кызлары!

Сугыштан соңгы Казанны унҗиде-унсигез яшьлек кызлар салды. Юлларны, урамнарны алар төзекләде. Иске Казанның баткак урамнарына асфальт җәю өчен карьердан ташны алар чыгарды, урамда ярдай халык алдында кувалда белән шул ташларны кызлар, хатын-кызлар ватты. Йорт салганда цемент балчыгын алар болгатты, кирпечләрне носилкалап алар ташыды. Без университетка укырга барганда, укудан кайтканда ябулы грузовикларга төялеп эшкә баручы, эштән кайтучы татар кызларын очраттык. Бөтен шәһәрне шаулатып алар «Айли, алмагачлары!» көенә кычкырып җырлап үттеләр. Безнең бер атаклы язучыбыз хәтта гәзиткә язып чыкты: зәвыксыз кызлар, имеш, халык иҗатын ярлыландыралар — алар, имеш, «алмагачларыннан» башка берни белмиләр.

Илленче елларда Казанга газ керә башлады. Сасы исле битумны кайнатып торбаларны кулдан хатын-кызлар буяды. Канаулар, траншеяләр тирәсендә һаман шулар кайнашты. Кайда нинди кара эш, кайда нинди пычрак эш — барысында безнең кызлар булды.

Себердә сөргендә чагында Хәсән Туфан тимер юл буенда лом, чүкеч тотып эшләп йөргән кызларны күреп шигырь язган. «Мин поездда узып киттем сиңа карап кул болгап. Син елмаеп калдың». Елмаерга түгел, җыларга кирәк иде сиңа шагыйрь, аларны кызганып.

Тимер юл буенда лом күтәреп, көрәк күтәреп эшләп яткан ул кызларны мин дә үз күрмәдем. 1952 елның җәендә мин дә ерак Себергә — Төмән, Тобол якларына барып чыктым. Юл буе татарлар белән бардык. Күбесе, иң күбесе — хатын-кызлар. «Агыйделнең аръягына» бәхет эзләп баралар. Безнең яклардан Иртышка барып чыккач, исем китте. Кайсы гына пристаньга барып туктанма, яр буенда тагын кызлар. Татар кызлары. Өсләрендә — тупас сырма, тупас чалбар, аякларында — кирза итек. Кулларында — лом, багор. Сал бушаталар, юан-юан бүрәнәләрне әвеш-түеш китерәләр.

Минем хатынның апасы Роза ундүрт яшеннән туган өен ташлап, читкә чыгып китәргә мәҗбүр була. Анда сугылып, монда сугылып йөргәннән соң Абакан-Тайшет тимер юлын төзүчеләргә барып кушыла. Җәен-кышын такта вагонда тора. Булачак тимер юл өеменә вагоннан таш бушата. Көрәк белән. Төрле хәлләргә юлыга.

Янтыкта, бездән бер өй аша күрше Урта-бабайның кызы Нәрисә унбиш-уналты яшеннән кемнәргәдер ияреп Свердловскига китеп бара, нindidер заводка эшкә керә. Заводтамы, цехтамы авария булгач, тәне пешеп, җәрәхәтләнеп бүлнискә эләгә. Урта-бабай Нәрисә янына барган.

Соңыннан Нәрисәнең хәле бөтен авылга беленде. Көн дә укол кадыйлар һәм... тән тиресен кисеп алалар икән. Үзе янына керүче ак халатлы кешеләрне күрсә, чыр-кылдап кычкыра, качарга тырыша икән. Урта-бабайны күргәч, «Калдырма, алып кайт!» дип әтәсенең муенына сарылган. Урта-бабай алып кайтмаган — ак халатлы кешеләр терелтер дип уйлаган Нәрисәбез мәңге шунда торып калды.

Чит җирләрдә кызларның кайберләре үзләренә оя кордылар. Булдыра алганнары үз татарына чыкты, булдыра алмаганнары башка милләт кешеләренә чыкты. Тик шулай да бик күп кызлар шәһәрләрдә кысан, тынчу, күңелсез баракларда, тулай торакларда җыелып калдылар. Җырлый-җырлый эшкә бардылар, җылый-җылый картайдылар, гарипләнделәр. Казанда минем шундый баракларда, торакларда булганым бар, саргайган, ямьсезләнгән йөзләрне күргәнем бар. Минем тагын шунысын да ишеткәнем бар: сугыш вакытында да, сугыштан соң да озак еллар дәвамында безнең яшь кызларны имансыз бәндәләр Урта Азия якларына алып барып... сата торган булганнар. Идән асты байларына, кол биләүчеләргә.

Уйласаң исең китә. Күңелне әрнү, бетмәс-төкәнмәс әрнү һәм кызгану тойгысы биләп ала. Күпме көчен, күпме талантын югалтты татар милләте безнең күз алдында, безнең күз артында!

*28 май, 1988 ел. Казан*

# ИСТӘЛЕКЛӘР

## ИМЕШ-МИМЕШ

Дөньяга мин Нурттин кызы Саликаның икенче баласы булып туганмын. Беренчесе Тәәүилә дигән бик сәер исемле кыз бала булган. Әллә сәер исемле булганга, әллә башка сәбәптән — тугач Тәәүилә күп тормаган. Миннән соң туган Халисә белән Тәлгать тә озак яшәмәгәннәр. Мин Халисә сеңлемне бөтенләй хәтерләмим. Тәлгатьне бераз хәтерлим. Мин аны гел тәрәзәдән карап торган кебек итеп күрәм. Өстенә кара бөрчекле күлмәк кигән. Күлмәге кендек турысыннан гына. Түш турысы ашка катып, каешланып беткән. Кендектән түбән берни юк — шәпшәрә. Яланбаш. Тәрәзә пыяласына капланган да, кызыгып тышка карый, үзе миңа нидер кычкыра. Минем энем Тәлгать тифтан үлгән бугай.

Ул миннән тазарак булган. Минем чәчтән тота да: «Ах, абыйны, табитатны!» — дип әйтә торган булган, имеш. Мин малай чакта еш кына аның шундый батырлыкларын искә төшереп сөйли торганнар иде.

Мин үзем мең дә тугыз йөз егерме җидедәме, егерме сигездәме туганмын. Мин туганда көз көне булган, солы суккан чак булган. Паспортта мин егерме сигез йөрим. Туган көнем — 25 октябрь, имеш. Ләкин чынлыкта ул октябрьме, ноябрьме — беркем белми. 1928 елны да, 25 октябрьне дә миңа соңыннан паспорт бүлегендә «бүләк итеп» бирделәр.

Менә шул — туганбыз шулай да дөньяга без. Тугач та кычкыра, даулаша башлаганбыз. Мин бик бәләкәй булганмын. «Йодрык кадәр генә» дияр иде инәкәй. Күрше җегетләре керәләр икән дә, инәкәйне үртәп: «һи, җиңгәй, шул да кеше булыр дисеңме?!» — диләр икән. «Сездән артыграк булыр әле!» — дип әйтә торганыем дияр иде инәкәй.

Шулай, бик кечкенә, зәгыйфь кенә, җылак кына булганбыз без. Килен буларак инәкәй юаш һәм йомшак булган. «Синең белән авырлы чакта көн-төн эштә булдым — мал карадым, сыер саудым, эпи пешердем, ашлык суктым. Бар кара эш минем өстә булды»,— дияр иде инәкәй. Кайчагында җылый-җылый сөйли торган иде. Әткәй дә бик юаш холыклы булган. Аның урынына әткәйнең инәсе, ягъни кайнана усал һәм кансыз булган, имеш. «Бидерә тутырып сөт савып керәм — үземә бер кашык сөт алырга куркам»,— дияр иде инәкәй. Иң нык хәтердә калганы шул: минем белән авырлы чагында инәкәйнең бәрәңге ашыйсы килә икән. Кайнанадан куркып, бәрәңге-

не җеп манганда җеп янына салып пешерә икән дә, качып-посып ашый икән.

Мин туар алдыннан инәкәй солы сугуда булган бугай. Мин тугач күп тә тормаган, яңадан эшкә тотынган. Имезергә сөте булмаган, вакыты булмаган. Күрәсең, эш ташлап өйгә керергә курыккан. «Мин» дигән бала көне буена җылап, үз йодрыгын үзе имеп яткан. «Бишегең янына беркем килеп әйләнмәсие»,— ди торган иде инәкәй. «Үлсә, изге җан булыр, үлсә котылырсың, җиңгәй»,— дигәннәр күрше-күлән, яшь килен белән мескен баланы кызганып. «Үлмәсен!» — дигән андый чакта инәкәй ачуланып.

Шулай итеп, без исән калганбыз. Ачлыкка, тифка, җәбер-золымга бирешмичә, без һаман да яши биргәнбез. Беренче баласының үлемен яшь ана үзенең «аңсызлыгыннан, йомшаклыгыннан» күргән. Икенче баласы, ягъни мин тугач, анда, күрәсең, ихтыяр көче уянган. Шуңа да ул мине саклап кала алган. Мин дә алай изге җан булырга атлыгып тормаганмындыр.

Менә шул — үлем белән, җәбер-золым һәм хаксызлык белән көрәш рухы бездә бишектәге заманнарда ук баш калкыткан. Әйтсәм әйтим, бөтен гомерем минем туктаусыз көрәш булды. Кешечә яшәү хокукын мин үземә кем беләндер сугышып-тартышып алгандай алдым.

## ТАРИХ ҺӘМ ГЕОГРАФИЯ

Җир йөзендә Күчтавыл дигән авыл барлыгын дөньяда Күчтавыл кешеләреннән башка беркем дә белмидер дип әйтер идем, ялгыш булыр. Күчтавылны күршеләре беләдер кебек. Элек анда утыз-кырык йорт булган. Совет власте елларында авыл күзгә күренеп үсте, алга китте — хәзер анда илле-алтмышлап йорт бар, ахрысы. Өйләр «елга» дип аталган тар гына, тирән генә су буена утырган. «Су»ның ярлары йомшак, ишелеп-җимерелеп кенә тора, чөнки елга тигез җирдән, үзәннән ага. Елга артында тәбәнәк кенә тау калкып утыра. Тау белән елга арасында тигезлек җәелеп ята. Монда каз, бозау «болыны». Тауның уң ягында серле булып Бәрдәшә чокыры күренә, чокыр буйлап «урман» сузыла. Сул якта таучык, түбәнәя барып, каядыр китеп югала. Аннан да арырак, бик-бик еракта, зәңгәрләнеп, томанланып һәм шулай ук серле булып, Бүә аръяк таулары-урманнары күренә. Күчтавылның үзеннән күренә микән, бик үк ышанып җитә алмыйм. Минем күңел күзеннән генә ул шулай сихри-серле булып күренә.

Күчтавыл исемен картлар «Күчте авыл» сүзеннән чы-

гып аңлаталар иде. Күчтавыл элек, имеш, бик зур авыл булган — әллә җиде мәчетле, өч тегермәнле, әллә өч мәчетле, җиде тегермәнле. Тегермән белән мәчет саннарының нисбәте ничек булгандыр, әйтеп булмый. Тик шунысын ышанып әйтергә була: бик ерак заманнарда Күчтавыл Казан ягыннан күченеп килгән. Хәзерге Күчтавыл элекке бик зур Күчтавылның бер кыйпылчыгы гына, имеш.

Җитмешенче елларда туган авылга кайткач, әткәйнең бер кордашы — ул чакта сиксән яшьлек Фәлән бабай әйткән иде: Бөре ягында да бер Күчтавыл бар дигән иде. 1983 елда Казанда Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» китабы яңадан басылып чыкты. Китапның азагында дастанның халык арасында табылган төрле кульязма нөсхәләренең тулы исемлеге бирелгән. Шунда Башкортстанның Яңавыл районы Күчтавыл авылында табылган нөсхәсе турында әйтелгән сүзләрне укып мин сабыйларча сөендем. Менә нинди атаклы авылда туганмын икән мин!

Күчтавыл — типтәр* авылы. Җирсез-сусыз, урмансыз. Утын урынына элек салам ягалар иде. Урманлы як кешеләре, ягъни Буә-аръяклар Күчтавылны гомер-гомергә «хәерче» дип йөрткәннәр. Күчтавылның бер ягында — Әйбүләк юлы буенда — Күник дигән удмурт авылы, икенче ягында — Ябалак дигән мари авылы. Авыл халкы удмуртны ар ди, марины чирмеш ди. Болар Күчтавыл кебек үк үзәнгә, тигез җиргә утырган якын авыллар. Көнчыгышта — тәбәнәк калкулык артында, биш-алты чакырым ераклыкта — Эткенәвыл, көнбатышта, шулай ук тәбәнәк калкулык артында — Байгуҗа дигән авыл. Байгуҗа типтәр, Эткенәвыл башкорт исәпләнелә. Эткенәвылның җирләре адәм әйтеп адәм ышанмаслык — бөтен тирә-якны каплап алган. Эткенәвыл җирләре элек мин белгәндә генә дә Күчтавылның ындыр артына килеп терәлә иде: Күчтавылның каршысында гына калкып утырган тәбәнәк тау да, Бәрдәшә чокыры да, андагы агачлар-куаклар да Эткенәвылныкы иде. Эткенәвыл чи башкорт түгел. Аларның да ата-бабалары кайчандыр бу якларга Казан ягыннан килгәннәр, «башкорт» булып язылганнар һәм күбрәк җир эләктереп калганнар. Патшага бөтенләй диярлек салым түләмәгәннәр. Алар баемый кем баесын?!

Күчтавылның, җирләре уч төбе кадәр генә дисәм, хәтерләре калыр. Шулай булса да, Күчтавылның җире кара туфраклы, уңдырышлы. Сугыш елларында тирә-яклар

---

* Типтәрләр — Казан ягыннан күчеп килгән татарлар.

ачтан шешенгәндә, Күчтавыллар пох итеп яшәделәр. Колхоз булсалар да, авыл халкы үз җиренә трактор-фәлән кертмәде. Бөтенесе ат көче, кул көче белән эшләнде. Халык бердәм, тырыш булды.

Менә шушы бердәм, тырыш, уңган халык яши торган Күчтавылда туганмын да инде мин.

## ТАРИХНЫҢ ДӘВАМЫ

Бүә суының таулы-урманлы ягында — Яңавылдан турыга сигез-тугыз чакрым чамасы төньяктарак Яңа Уртавыл дигән бер авыл бар. Бүәне картада Буй дип язалар. Без, гадәттә, Бүә-буй, Бүә-буйда дип сөйләшәбез. Ягъни Бүә буе була инде. Моннан фәлән еллар элек карта төзүче урыс иптәш шул «Бүә-буй»ны ишетеп калган да, күрәсең, елга исемен «Буй» дип язып куйган. Менә шуннан киткән Буй буйдан-буйга. Бүә суын Буй дип язган әлеге урыс писере Яңа Уртавылны Новый Артаул дип язган. Шул заманнардан бирле ул шулай Н. Артаул дип языла. Хәзер инде русча гына түгел, татарча да Уртавылны Артавыл дип атыйлар. Уртадан артка калдык, арттан бөтенләй югалып калырбызмы — моны әлегә беркем белми.

Бүә буе җирләрендә иң элек Карман дигән авыл барлыкка килгән. Шуннан соң Карманнан бер егерме чакрым көнчыгышта Яңа авыл оеша башлаган. Күпмедер вакытлар үткәч, Карман белән Яңа авыл, ягъни Яңавыл уртасында өченче авыл үсеп чыккан. Монысын Урта авыл дип атаганнар. 1755 елда урыс колониализмына каршы баш күтәргән мишәр мулласы Батыршаның патшага язган хатында Гәйнә яклары турында сүз бара. Гәйнә бездән төньяк-көнчыгышта, күршедә генә. Шунда Батырша «Урал иле»нең Уртауыл дигән авылын да телгә ала. Бу, күрәсең, безнең яктагы Урта авыл булгандыр инде.

Батырша язганча, моннан ике йөз дә утыз еллар элек Уртавыл кешеләре бик оста укчылар булганнар, чаңгыда яхшы йөргәннәр. «Вә һәм чаңгыда йөрергә шулкадәр осталар, урман эчендә качкан киек котылмайдыр. Алдына аркылы яткан ат биеклеге агачларны аша сикереп чыгалар. Йулдан килүче ат кардан йилгән чаңгылы кешеләремезгә йитмәйдер» дип яза Батырша Уртауыл кешеләре турында.

Яңа Урта авыл Иске Урта авылдан бүленеп чыккан. Яңа Урта авылның Янтык дигән исеме дә бар. Монысы — халык телендә. Иске Уртавыл да, Яңа Уртавыл да башкорт санала. Ләкин чи башкортка аларның бернинди катнашы юк. Эткенәвыллар кебек, алар да кайчандыр

Болгар, Казан ягыннан күченеп килгәннәр. Татарстанның үзәгендә, Лаеш районында Янтык дигән ике авыл бар. Берсе татарныкы, берсе урысныкы. Шул урыс Янтыгы элегрәк безнең Янтык булмады микән? Шул ук районда Кече Елга, күршедәге Балык бистәсе районында Олы Елга авыллары бар. Безнең якта да, Янтыкка күрше генә Елга дигән авыл бар. Аның тулы исеме Булат-Елга. Халык телендә Пулат кына дип йөртелә. Пулатка, имеш, Булат дигән кеше нигез салган. Ләкин Пулатта Булат дигән елга юк — яныннан гына Ушиа дигән елга ага. Димәк, «Елга» исеме ерактан, Казан ягыннан тагылып килгән.

Әткәй минем типтәр ягында, Күчтавылда, инәкәй «башкорт» ягында — Янтыкта туган. Әткәйнең туган елы билгеле түгел. Әткәй белән бергә уйнап үскән «Рәхимҗан абзый» әйткән, имеш, Садырлиман кырык яшендә үлде, дигән. Садырлиман дигәне минем әткәй була. Садырлиманның үлеме исә тарих сәнә 1934 елда булды. Февраль башы иде. Күрәсең, ул 1894 елда тугандыр дип әйтәсем килә. Хәер, аның кайчан тууы да кайчан үлүе бу дөньяда кемгә генә кирәк булыр икән?

Янтык яисә Яңа Уртавыл халкы Бүә аръягына күченеп утыра башлаганда мондагы җирләр карурман белән капланган булган. Кешеләр озын-озын чыршыларны туптуры булачак ишегалды урыныннан гына кисеп алганнар да шунда ук өй салганнар, каралты-кура җиткергәннәр. Әкренләп җир ачканнар — урман яндырганнар. Күрше Мәхмүтҗан бабай сөйли торган иде: көн туу белән олылар урманга китәләр икән, бала-чага җыелышып өйдә кала икән. Урман яндырганда күтәрелгән төтен авылга кадәр килеп җитә торган булган. Төтеннән качып бала-чагалар, ягъни Мәхмүтҗан бабайлар, өйдә генә ятканнар, имеш.

Ни генә булмасын, Янтык — Яңа Уртавыл халкы моңарчы кеше аягы басмаган җиргә килеп утырган, үз тырышлыгы белән яңа җирләр, басулар ачкан. Авыл урынында кайчандыр карурман шаулап утыруын хәтерләтеп, авылның әле бер төшендә, әле икенче төшендә — ишегалларда, ындыр артларында, киртә буйларында әле дә юанюан чыршылар, каеннар моңаеп утыра. Вәрәш ягында, авылга керер алдыннан, юл буенда ялгыз нарат утыра.

Яңа җир ачкач, ишегалды тирәсендә, авыл янында ялгыз агачлар калдыру безнең халыкның борынгы бер йоласы булгандыр дип әйтәсе килә. Бит элек озын кәүсәле агачларга табынганнар һәм аларны «алла» дип белгәннәр. Күчтавылда, авыл каршысындагы тәбәнәк тау буенда шулай ук бер ялгыз нарат үсеп утыра иде. Мин бәләкәй чакта малайлар белән шунда барып нарат төбеннән ниндидер

«серле» ташлар җыюыбызны, наратның чатлы-ботлы ботакларына карап, исебез китеп: «Менә ул алла бабай!» дип сөйләнүебезне хәтерлим. Андый сүзләрне без үзебез уйлап тапмаганбыздыр, олылардан отып алганбыздыр, күрәсең.

Янтыкта да безнең тау буенда, лапас артында ялгыз чыршы шаулап утыра иде. Шундый ук йөзьяшәр чыршылар ишегалдан читтә, урам якта да бар иде. Сугыш елында без аларны утынга кистек. Хәзер рәхәт — агачларга «алла» дип табынучы сабый балалар да юк, йөзьяшәр чыршылар да юк.

Инәкәй ягыннан безнең нәсел гомергә игенчеләр булганнар. Ләкин Янтык җирләре әллә ни уңдырышлы түгел. Тау да таш, чокыр-чакыр дигәндәй. Шуңа күрә, ахрысы, кыш көне халык якындагы базарлы авылларга, шәһәрләргә олау белән йөргән. Революция алдыннан авылда таш кибетләр, елга буйларында зур-зур тегермәннәр барлыкка килгән. Китапта язылганча, безнең якларга да капиталистик мөнәсәбәтләр үтеп кергән.

Инәкәйнең инәсе Вайҗады авылы кызы булган. Мин аның исемен белмим. Бездә өлкәннәрнең исемен кычкырып әйтү, исем белән эндәшү булмаган. Бигрәк тә хатын-кыз ягын. Менә шул «исемсез» Вайҗады кызын Яңа Уртавылның Каюм малае Сукыр Нурттингә кияүгә биргәннәр. Безнең Каюм бабай Янтыкта старшина булып торган. Бер үк авылда, бер үк вакытта ике хатыны булган. Малае Сукыр Нурттин андый ук дәрәҗәгә ирешә алмаган. Үз кул көче белән иген иккән, мал-туар асраган. Аннан соң «булыста», ягъни волость (өяз) идарәсеме, канцеляриясеме урнашкан йортта... каравылчы булып торган. Анысы шул кыр эшләреннән бушаган чагында гына инде. Янтык булысына уналты авыл караган.

Сукыр Нурттин белән Вайҗады кызының алты баласы: дүрт кызы, ике малае булган. Кызларның беренчесе Вазифа, икенчесе Салиха, өченчесе Галимә, дүртенчесе Нәгыймә. Уллары Салих белән Фатих. Салихны бик яшьләй армиягә алганнар — акларга, ахрысы. Ул шунда бик яшьләй һәлак булып калган. Инәкәйнең кече энесе Фатих буранда туңып үлгән. Калган дүрт кыз.

1918 елда тиф чиреннән Нурттин картәтәй дә үлеп киткән, егерме беренче ачлык елында инәкәйнең инәсе дә дөнья куйган. Ул вакытта Вазифаны уналты яшеннән тотып Шатын авылының хатыны-балалары булган бер картка икенче хатынлыкка биргәннәр. Яшьлек түгел, ачлык мәҗбүр иткәндер. Шулай итеп, бөтен авырлык буй җиткән, җитеп килгән япь-яшь кызлар өстенә төшкән. Дөнья көтүдә бернинди тәҗрибәсе булмаган кызлар

аптырап калганнар. Булган бар азыкларын ашап көн күрештергәннәр дә, юк кына бәягә мал-туарларын, каралты-кураларын сата башлаганнар. «Акыллы кешеләр», «туганнар» шулай киңәш иткән, үзләре алучыларын да тапканнар. Кызларның иң кечесе Нәгыймәне көннәрдән бер көнне күрше Уразы авылына бала караучы итеп алып киткәннәр. Нәгыймә әле ул вакытта үзе дә бала гына булган. Бала караучыны аның үзе өчен алырга кирәк булган да бит, ләкин, нихәл итмәк кирәк, әлеге дә баягы Нужа бабай элек усалрак та, кансызрак та булган.

Менә шундый кыен, бик кыен вакытларда егерме ике яшьлек Салиханы Күчтавыл Садырлиманга димләгәннәр дә биргәннәр дә җибәргәннәр. Садырлиман ул көзне Ушиа суына салынган Пулат тегермәненә ашлык тарттырырга килгән булган. Шунда очрашканнар, танышканнар. Егерме ике яшьлек Салиха ни дәрәҗәдә чибәр булгандыр, инде әйтеп булмый. Мин белгән Салиха шундыйрак иде: уртадан калку төз гәүдә, аксыл чырай, кара каш, озын калку борын. Коңгырт күзләре кысыграк, озынча йөз. Сөйләүләренә караганда, затлары алай төшеп калганнардан булмаган.

Салихага өйләнгән чагында Күчтавыл Садырлиман хатынныннан тугыз яшькә олырак булган. Садырлиманның беренче хатыны Җәннәт үпкә чиреннән үлгән. Җәннәтнең ике кызы торып калган. Егерме ике яшьлек Салиха менә шул үги кызлар һәм явыз кайнана янына килен булып төшкән.

Күчтавылның Хәсән малае Садырлиман әллә ни тазалыкка туймаган. Герман сугышында акупта бик каты салкын тидергән дә, шуннан мантый алмаган. Ничәнчедер елда моны аты белән Урал ягына эшкә җибәргәннәр. Монысы инде совет чорында. Утызынчы елларда, күрәсең. Шунда тагын салкын тидергән һәм бик каты чирләп, үлем хәлендә Яңавылга кайтып егылган. Аты кемнәргәдер ияреп кайткан, үзен пуезга утыртып җибәргәннәр. Шул авырудан соң рәтләнә алмаган, бик каты шешенеп, «прукчирса»дан вафат булган.

Ике кызы һәм усал анасы булган чирлекәш киявен яратты микән Салиха? Бик үк яратмагандыр дип уйлыйм мин. Хәер, ул елларда, алар заманында мәхәббәт дигән нәрсәне алай хәзергечә бизмәнгә салып, минеке бер грам артык тарта, синеке бер грам ким тарта дип сатулашып тора алмаганнар. Мәхәббәтне түгел, язмышны үлчәү тәлинкәсенә салганнар ул чакларда. Шуның аркасында без менә исән калганбыз.

Яшь кеше буларак, яшь хатын буларак яратмаган ул Күчтавылдагы тормышын. «Яратып бардыңмы соң?» —

дип сорагач, туганнарына: «Күргәч тә аты ошады»,— дигән. Тегермәнгә килгән Садырлиманның үзе түгел, арбага җиккән аты ошаган, имеш! Болай дип әйткән чагында ул бераз гына шыттыргандыр кебек. Хуҗасын ошатмаса, ихтимал, атын да ошатмас иде. Шулай да гомере буена ул яратып, сагынып әткәйнең шул сөйкемле атын сөйләде. Атларга карата аның күңелендә искиткеч бер җылылык хисе бар иде. Күчтавылдагы тормышын искә төшергәндә генә түгел, Янтыкта үткән бала чаклары турында сөйләгәндә дә аның телендә гел атлар булды. Ул аларның төсен, буен-сынын, кыланышларын үзенчә матур итеп, сагышланып сөйли белә торган иде.

Әткәй белән ул тугыз ел торган. Юаш булганга, үзенчә иркәләп, әткәй аны «тешсезем» дия торган булган. Әткәй чирләп урын өстенә егылгач, инәкәй көн-төн аның янында булган. Утыз өч яшендә тол калган. Шуннан соң аны төрле җиргә димләп тә караганнар, ләкин риза булмаган. «Нуриханымны ятим итәсем килми»,— дигән. Бәлки монысы аның сылтау гына булгандыр. Бит мәхәббәтне кешегә сөйләп йөрмиләр. Ни генә булмасын, үзенең Садырлиманын ул мәңге онытмаган.

Әткәйнең инәсен мин әнкәй дип атый идем. Безнең әнкәй Күчтавылга Уракайдан килен булып төшкән. Әткәйнең беренче хатыны Җәннәт тә шул Уракай кызы булган. Шуңа күрә беренче киленен якынрак күргән. Улының яшь Салиханы алып кайтуын ул яратып җиткермәгән. Шуның өстенә ятим калган ике кызны да какмый-сукмый карап үстерергә кирәк бит әле. Үги ана ничегрәк булыр аларга карата? Шуларның барысын да уйлап, безнең әнкәй бөтен өйне үз кулында тотмакчы булган. Икенче киленен бик яратмаса да, мине, имеш, яраткан. Соңыннан, үләр алдыннан инәкәйгә җылый-җылый сөйләгән: шул явызлар (ягъни үги кызлар) аркасында кыерсыттым сине, киленкәем, дигән. Синнән әйбәт киленем булмады, бәхил бул инде, дигән. Бәхилмен, дигән инәкәй, дөньяныкы дөньялыкта калсын, дигән.

## КҮЧТАВЫЛДА, КҮҢЕЛ КҮГЕНДӘ

Әткәй үлгәч безнең инәкәй ике бала белән торып калган. Икенең берсе — мин, икенчесе — Тәлгать. Миннән тазарак булса да, ничәнчедер елны Тәлгать тә әткәй артыннан китеп барган. Шуннан соң инәкәй мине күтәргән дә туган авылы Янтыкка кайткан да киткән. Киткән чакта законлы тәртиптә бүленеп, судлашып йөрмәгән. Ярлы Садырлиманның хәерче йортында бүлешер берние булмаган.

Шулай итеп, кайтып киткәнбез без Янтык — Яңа Уртавылга. Минем аңлырак бала чагым тулысынча шунда узды. Туган як, бала вакыт дигәндә иң элек мин таулы-ташлы, урман-сулы Янтыкны күз алдында тотам. Ләкин Күчтавыл да минем «балачак». Анда узган берничә ел җуелмаслык булып хәтердә сеңеп калган. Минем өчен Күчтавыл бүгенгегә дә, элеккегә дә катнашы булмаган ниндидер сихри бер дөнья булып тоела.

Әткәй мине бик яраткан, имеш. Нуриханым үсеп, сука башы тотарлык булса, үлсәм дә үкенмәсием, дип әйтә торган булган. Инәкәй дә яраткан, башкалар да яраткан. Тик нишләптер мин аларның яратуын бик үк хәтерләмим. Күңел күгендә башкачарак күренешләр, башкачарак төсләр-бизәкләр торып калган. Менә төн. Коеп яңгыр ява, әледән-әле нәрсәдер дөбер-шатыр килә, ялт-йолт итеп яшен яшьни. Караңгы өй почмакларында, идәндә гөлт итеп куркыныч яктылык балкып китә. Бөтен тирә-як дер селкенеп тора. Мин идәндә йомшак ястыкка чумганмын. Бер якта — әткәй, икенче якта — инәкәй. Куркып мин кемгәдер сыенам.

Җил-давыллар, яшенле яңгырлар, гомумән, онытылмый. Бер җәйне бик каты давылдан соң күршеләрнең юан-юан тупыллары урталай сынып төште, икенче бер күршеләрнең өй түбәләрен куптарып ташлады. Көчле яңгырдан соң шунысы кызык була — дөнья тынып калу белән, йөгереп без урамга чыгабыз, бер-беребезне узышып, су чәчрәтеп, яшел чирәм өстеннән йөгерәбез, канаудагы суда көймәләр — йомычкалар агызабыз.

Кояшлы көндә без елга буенда чыр-чу киләбез, йомшак туфрак өстендә чокырлар казыйбыз, юллар салабыз. Иске чабатага чирәм йолкып тутырабыз да өйгә «печән» алып кайтабыз. Бервакытны тилгән тырнагыннан ычкынган, ләкин куркуыннан аяк сузган бер чебине бик кадерләп, бик нык кызганып кабергә күмүебез истә калган. Заманына күрә уены да табылган. Бит балалар күбесенчә олыларны кабатлыйлар.

Елгада су кереп туйгач, яр өстенә менеп чирәмдә ауныйбыз, каз каурыйлары җыябыз. Каз каурыеннан аткый ясыйбыз — кемнеке ераграк, кемнеке биегрәк оча дип ярыша башлыйбыз.

Аннан соң каерылып үскән арыш басулары истә калган. Арыш басуы уртасыннан Күник ягына арба юлы бара. Көн кичкә авышкан. Бик зур кояш түбәнәя башлаган. Аксыл болытлар арасыннан күк читенә саргылт сызыклар сузылган. Арыш арасындагы юлдан без малайлар белән кояшка таба йөгерәбез. Күчтавыл хатыннары иртән иртүк

Бүә буена карагатка* китәләр. Алар анда көне буе йөриләр, кичкә кайталар. Без шуларны каршыларга барабыз. Алар арасында, билгеле, инәкәй дә булырга тиеш. Ул булмаса мин каты юлдан аягымны авырттырып барып та тормас идем. Кайтканда алар бидерәләрен көчкә күтәреп кайталар. Бидерәләр туп-тулы эре, сусыл карагат. Кайчагында шомырт була. Мин әле дә инәкәй алып кайткан шул бидерә тулы карагатның, шомыртның тәмен, исен тоям кебек.

Бервакыт миңа куе зәңгәр төстәге гап-гади ситсыдан күлмәк, ыштан һәм кепка тегеп бирделәр. Яңа кием кисәм нишләптер минем авыз ерылырга гына тора. Мактанасы, макталасы килә башлый. Сөенечемнән кая басканымны белмичә, шундук урамга чыгып йөгердем. Малайлар янына, билгеле. Берәрсе мактады микән, юк микән, хәзер инде онытылган. Уен белән мавыгып без яңгыр килгәнен сизми калганбыз. Яңгыр сибәли башлагач, таралышырга туры килде. Өйгә кайтып җиткәндә генә коеп ява башлады. Ярый әле күршеләрнең өй артында туктап калдым. Шулай да яңгырдан сакланып булмады. Җылыйҗылый кайтып кердем өйгә. Ни өчен дигәндә, бөтен өс чыланып, пычранып беткән, кепканың козерегы җебеп, күзгә салынып төшкән. Иң кызганычы шул кепка козерегы булды, ахрысы.

Күчтавылдагы кышкы юлларны, чана шууларны мин бөтенләй хәтерләмим. Ләкин суык бик нык истә калган. Кыш җиттеме, тәрәзәләргә бармак калынлыгы боз ката. Җилле көннәрдә бүрәнә ярыкларыннан, тәрәзә яңагы арасыннан суык җил өрә. Мондый чакта тышкы яктан тәрәзәгә салам чыпта бөркәп куялар. Өй эче караңгыланып кала, ләкин җил өрү тынып калгандай була. Кыш көнендә иң җылы урын — мич башы. Мичкә બездә салам ягалар. Саламны көлтәләп бәйлиләр дә өйгә кертеп тутыралар. Шуннан көне буе мичтә ут өзелми. Мич дөрләп янганда дөньялар ямьләнеп китә.

Саламның көле күп була. Авыл кешесе көлне йә бакча ягына, йә өй янына гына түгә. Яз көне ул кар суы белән агып китә. Мин Күчтавылда чакта инде күмәкләшү башланган, авылда колхоз оешкан була. Колхоз һәр өйдән көл җыя. Колхоз дигәннән, безнең әткәй үлгәнче колхозга кермәгән, авылда иң соңгы аерым хуҗалык булган. «Үлсәм ярарые, күрмәсәм ярарые шул калхузларын»,— дип теләгән. «Теләге кабул булды мәрхүмнең»,— диде еш кына инәкәй. Исән чагында әткәйгә бер көн тынгылык бирмәгәннәр — башкаларга караганда күбрәк са-

---

* Карагат — карлыган.

лым салганнар, барлы-юклы мал-туарын, ашлыгын алып чыкканнар. Бер елны яңа урган-суккан ашлыгын бөтенләе белән Яңавылга илтеп тапшырырга мәҗбүр иткәннәр. «Чәчүлеккә дә калдырмадылар»,— дип сөйли торган иде инәкәй әрнеп, ачынып. Шулай кыса, талый торгач, ишегалдагы келәтне сүтеп алып чыкканнар да елга буена күчереп утыртканнар. Тәбәнәк кенә, бәләкәй генә ул келәтнең яр буенда моңаеп утыруын мин әле дә хәтерлим.

Безнең шул ялгыз келәткә колхоз кыш буе көл җыйдыра. Күп тә үтми, келәт янып китә. Бу хәл төнлә була. Соңыннан берәрсе ут төртмәде микән дигән сүз дә була. Ләкин такта идәнле агач келәткә көл тутыргач ул ут төртмәсәң дә янарга тиеш булгандыр.

Төне буе балкып янды безнең келәт. Беркем сүндерергә бармады. Безнекеләр бары тәрәзәгә капланып догаларын укыдылар да туктаусыз сукрануларын белделәр. «Аллага шөкер, игелеген күрмәделәр!» — диде әнкәй сөенгән сыман.

## МӘКТӘП

Күчтавылда башлангыч мәктәп бар иде. Мәктәп ниндидер зур гына йортка урнашкан. Беренчедән дүртенчегә кадәр барлык балалар бер бүлмәдә утыралар. Аларны бер үк укытучы укыта. Минем үги апалар — Фәүзия белән Нәкыйбә көн дә шунда укырга баралар. Фәүзияне мин түтәй димен, Нәкыйбәне чибәрттәй* димен. Көн дәме, көн аралашмы безгә Уфада чыга торган «Коммунар» дигән газета килә. Түтәй белән чибәрттәй укудан кайталар да төрле аңлашылмаган ят сүзләр сөйлиләр, иҗекләп газета укыйлар. Беркөнне болар мине дә үзләре белән ияртеп мәктәпкә алып киттеләр. Башта мин алар янында партада утырып тордым. Аннан соң, тәнәфес вакытында, ахрысы, укытучы апа мине үз бүлмәсенә алып керде. Укытучының тора торган бүлмәсе шул ук мәктәп бинасында гына иде бугай.

Өйләренә алып кергәч, укытучы апа чәй эчәргә утыртты. Күрәсең, үзенең дә ашый торган вакыты булгандыр инде. Зур итеп бер телем эпи кисеп куйды, сөтсез генә кайнар чәй ясады. Укытучы апа кисеп биргән шул зур телем, тәлинкәдәге кайнар чәй әле дә күз алдымда тора. Мәктәптәге беренче дәресем минем шул булды.

Мәктәптән кайткач, түтәй белән чибәрттәй «Коммунар» уку белән генә шөгыльләнмиләр. Алар тагын китап-

* Чибәрттәй — өлкән кыз туганга, апа кешегә яратып әйтелә торган сүз.

тан кычкырып укыйлар, ап-ак дәфтәр битенә нәрсәдер язалар, сызалар, рәсемнәр ясыйлар. Мин, күрәсең, бик кызыкканмын боларга. Әткәйнең тәрәзә башындагы ярыкка кыстырып куя торган нечкә генә «химически» карандашы бар иде. Ул аны миннән, түтәйләрдән яшереп куйгандыр инде. Аның шул саклап кына тоткан карандашын кая куйганын карап торганмын да, ничектер җаен китереп, алганмын мин моны. Ак кәгазьне каян тапканмындыр, анысы инде онытылган. Тик шунысы хәтердә: тәрәзә төбенә капланып рәсем ясыйм. Карандаш очын телгә тидерәм дә сызгалыйм үземчә. Тәрәзәдән карый-карый, үзебезнең ишегалдагы яшь тайны ясыйм.

Мин инде беркем күрми дип уйлаганмындыр. Ләкин бер заман якында гына, колак төбендә генә олыларның чыш-пыш килүләрен, көлешүен ишетеп алдым. Куркып артыма борылып карасам, ни күрим — барысы да җыелышып мине күзәтеп торалар! Мин кып-кызыл булдым, карандашымны шундук артыма яшердем. Ләкин олыларның карандашта эшләре юк — мин ясаган рәсемгә карыйлар да көләләр, карыйлар да көләләр. Аларның ник көлгәнен мин соңыннан гына төшендем кебек. Үзебезнең яшь айгырны мин ничек бар шулай, «шәрә килеш» күчереп ясаганмын икән.

## КИЛӘ-КИТӘ

Безнең инәкәй никадәр юаш һәм тешсез булмасын, илдәге үзгәрешләр аңа да тәэсир итми калмаган. Аның кагылып-сугылып яшәве турында авыл советында да белеп алганнар. Кемдер аңа Садырлиманнан аерылырга киңәш иткән. Янтык туганнары да аның нинди кыен хәлдә яшәвен күргәннәр. Алар да аерылырга киңәш иткәннәр, ахрысы. Шулай тамыза торгач, котырта торгач, бер елны бу, әйтелгәнчә, мине алып үзенең Янтыгына кайтып киткән.

«Түзә алмыйча» гына кайтып китүләре аның элегрәк тә булгалаган. Андый чакларда бер-ике көннән әткәй безне ат белән барып ала торган булган.

Күчтавылдан Янтыкка турыдан егерме чакрым чамасы. «Турыдан» дигәне аның Яңавылга сугылмыйча дигән сүз. Яңавыл — район үзәге. Барлык юллар Яңавылда кисешә. Бүә аръягы авылларына барганда, урау булса да, турыдан түгел, Яңавыл аша йөриләр. Турыдан йөри торган юл аулаграк та, ятрак та. Монда Бүә буе болыннары, әрәмәләр аша үтәсең, Бүәдән чыгасың да икенче як ярга аяк басасың. Бүәне Иске Уртавыл турысыннан чыксаң, юл тагын да кыскара төшә. Монда карурман аша, Очлы

тау аша үтәсе була. Урманда әле аның качкысы да булырга мөмкин. Элек безне гел шулай «качкы» белән куркыталар иде. Гражданнар сугышы елларында Бүә буе урманнарында качкылар гына түгел, «изәртил»ләр дә яткан, имеш.

Бервакыт инәкәй Янтыкка җәй кайтып киткән. Турыдан, иске, борынгы юлдан. Иске Уртавыл тегермәне турысында икенче якка чыккан да яр буенда ял итәргә туктаган. «Яр буена, ташлыкка сине утыртып куйдым, чүпрәкләреңне юып кибәргә элдем. Көн ямьле. Кояш... кошлар сайрый...» — диде инәкәй.

Шулай яшь чакларын исенә төшерде дә күз яшьләрен сөртеп куйды. Мин шундук барысын да күз алдына китердем. Сихри таллар, нидер пышылдап-чылтырап аккан көмештәй саф су. Таллыктагы кошлар чыр-чуы. Болар бит минем мәңгелек сердәшләрем!

Икенче бер вакытны ул тагын туган авылына кайтып киткән. Монысында яз көне, ат җигеп. Бу юлы кунакка гына кайткандыр, ахрысы. Юл өзеге алдыннан бу кире Күчтавылга кайтырга чыккан. Әлеге дә баягы тагын без икәү генә булганбыз. Иске Уртавылга җитәрәк, шундагы бер кечерәк елга аша чыгарга кирәк булган. Чанага мине төреп салган да, йоклаткан да, атның үзен генә җибәргән. Үзе арттан атлап бара икән. Көн матур булган. Язгы кояшка рәхәтләнеп бара торгач инәкәй онытылып киткән, арткарак калган.

Берзаман ат елга янына килеп җиткән дә туктап тора икән. Ат янына килеп җитсә инәкәй, елгада су күтәрелгән ди, шаулап ташу агып ята ди. Ат, аны-моны уйлап тормыйча, су аккан елга аша чыгып киткән булса, чанага су кереп, чанадагы «мин» агып китәсе булганмын икән. Инәкәй үзләренең җирән аты турында сөйләгәндә гел аны «акыллы» дип, «әдәм акылы бар» дип мактый торган иде. Атның яр кырында туктап калуын да ул аның «акыллы» булуы белән аңлатты. «Атның башыннан сөясөя, рәхмәт әйтә-әйтә җыладым»,— диде.

Безнең җирән атыбыз гына акыллы булды микән, атларның барысы да акыллы булалар микән? Әйтергә кирәк, атларның «акыллы» булулары аркасында миңа тагын берике мәртәбә үлемнән калырга туры килде. Бер мәртәбә (шул ук Күчтавылда, ахрысы) көлтә ташыганда арба башыннан егылып төшүемне, арба астында калуымны хәтерлим. Икенче мәртәбәсе Янтыкта булды. Җәйге эсседә, тырмадан кайтканда, малайлар белән узышканда аттан егылып калдым. Тузан туздырып, дөп-дөп басып минем өстән атлар узып китте. Шуларның берсе-бер ялгышып та тоягын миңа тидермәде.

Инәкәйнең Күчтавыл белән Янтык арасында йөргән чакларыннан тагын шул истә калган: җир өсте ап-ак кар. Бүрәнәләрендә иске обой кәгазьләре салынып торган тәбәнәк өйдән туп-турыга — ниндидер абзар-кура ягына тирән сукмак сузылган. Минем аякта яңа гына басылган кара киез итек. Сукмактан бик авырлык белән атлап мин абзарлар ягына барам. Абзар ишеген ачу белән, каршыда бик зур ак сарык басып торганын күреп алдым. Бер-беребезгә караганбыз да торабыз шаккатып. Шул чакны сарык алгы аягының берсен күтәрде дә шап итеп идәнгә тибеп алды.

Шатын авылыннан аерылып кайткан Вазифа — инәкәйнең апасы бер кышны колхоз фермасында сарык караучы булып эшләгән. Вәрәш очындагы үз өйләрен калдырып, Бүә очындагы фермага күченеп килгән булганнар. Кышны шунда кышлаганнар. Ул чактагы «Очкын» колхозының сарык фермасы авылдан бер чакрым чамасы читтә, Бүәгә якынрак бер җирдә урнашкан булган. Без, күрәсең, менә шунда кунакка килгәнбез. Әле дә күз алдында: каршыда гына биек булып таулар калкып утыра, тагын да арырак — Бүә буенда карурман белән капланган Очлы тау зәңгәрләнеп күренә. Монда бөтенләй икенче дөнья. Серле, моңсу һәм гүзәл дөнья. Күчтавылның тәбәнәк тавы белән, балчык ярлы елгасы, каз үләне үскән «болыны» белән чагыштырганда бу яклар — үзе бер әкият.

Әткәй чирләп урын өстенә яткач, авыру кешене борчымасын диптер инде, минем үземне генә Янтыкка кайтарып куйдылар. Бу вакытта мин нидер сизендем, киреләндем. Янтыкта күңелле булса да, гел үзебезнең авылга — «хәерче» Күчтавылга, әткәй янына, инәкәй янына кайтасым килә.

Кыш көне иде. Тышта буран котыра. Вазифа, ягъни «яшәби» ул көнне кызу итеп мичкә якты, кунак ашы — орлык бөкәсе пешерде. Бер дә кирәкмәгәнгә миңа ягымлы сүзләр әйтә, кыстый-кыстый бөкә ашата. Шул чакны безнең капка турысына ниндидер атлы кеше килеп туктады. Яшәби тәрәзәдән карап алды да кунакны каршыларга чыгып китте. Нишләптер болар бик озак керми тордылар. Мин аларның чоланда пышылдап кына сөйләшүләрен ишетеп калдым.

Керделәр болар. Күчтавылдан Сафа дигән кеше — безнең күрше килгән. Мине алырга җибәргәннәр. Әткәйнең хәле начар икән. Мин инде болай да шомланып, борчылып утыра идем — үзем дә сизмәстән кычкырып җыларга тотындым. Шулай итеп, беренче мәртәбә башка олы кайгы төште.

Без Сафа белән Күчтавылга кайтып кергәндә буран тынды. Урамда безнең капка төбендә ниндидер ят кешеләр

күренә. Минем дус малайлар — Заһир, Назиф, тагын кемнәрдер читтән генә безгә карап калдылар. Аларның барысы да миңа кызганып карыйлар сыман тоелды. Олылар да никтер мине кызганалар, юату сүзләре әйтәләр. Өй эчендә әкрен генә, пышылдап кына сөйләшәләр, күз яшьләрен сөртәләр, кайберсе җылый. Түр сәкедә, калку урында... әткәй сузылып ята. Хәрәкәтсез, тынсыз, нурсыз. Әткәйне шундый хәлендә күрү белән мин тыела алмыйча кычкырып җыларга тотындым. Кемдер мине тотып алды, юата башлады. Мин тыпырчынам, әткәй янына бармакчы булам.

Шул чакта могҗиза булды. Көтмәгәндә кемдер минем учка ялтырап торган бик зур биш тиенлек бакыр китереп салды. Биш тиенне мин шундук чытырдатып учыма йомдым. Мондый биш тиенне минем тотып карау түгел, якыннан күргәнем дә юк. Безнең өчен иң зур байлык, иң тәти нәрсә — бизәкле, ялтыравыклы чынаяк китекләре йә булмаса елга буендагы шома вак ташлар. Мин тынычланып, юашланып калдым. Ул арада олылар мәетне югары күтәреп, тавыш-тынсыз өйдән алып чыга башладылар.

Биш тиенгә алданып мин, билгеле, дөрес эшләмәгәнмен. Ләкин, алданмаган очракта да, нәрсә генә эшли алыр идем икән соң мин ул чакта? Алты-җиде яшьлек сабыйларны гына түгел, аннан ислерәк, акыллырак абзыйларны да өч тиенлек, биш тиенлек бакыр белән алдыйлар түгелме соң бу дөньяда?!

## КҮЧТАВЫЛ ТУРЫНДА ТАГЫН БЕР-ИКЕ СҮЗ

Туган авылымда мин бик аз яшәп калганмын. Сабый чакның истәлекләре дә сабыйларча — өзек-өзек. Әллә ни искитәрлек вакыйгалар да юк. Шулай да әйләнәмтулганам да Күчтавылны искә төшерәм. Иң күңелле, иң бай һәм мәгънәле тормыш бары шунда — өч-дүрт... бишалты яшьлек чагымда булгандыр сыман тоела. Бәлки, минем тарих белән кызыксынуым да Күчтавылдагы истәлекләрдән арына алмавыма кайтып каладыр?

Менә җәйге иртә. Битемдә кояш җылысы тоеп мин уянып китәм. Тышта, тәрәзә башында моңлы итеп, оетып күгәрченнәр гөрли. Чормада кыек астында аларның оясы бар. Күгәрченне біздә изге санийлар, күгәрчен гөрләсә сөенәләр. Кайчагында тәрәзә башында чәүкәләр чәрелдәшә. Чәүкәне бик үк яратмыйлар. Кәрниз тактасы арасында аларның да оясы бар. Без, малайлар, чәүкәләрнең күкәйләрен алабыз. Олылар күрсә ачуланалар, кош оясын туздырырга ярамый, үз ояң тузар, диләр. Алар сүзе дөрескә чыкты. Күчтавылдагы оя да тузды, Янтыктагы оя да тузды.

Безнең генә түгел, бөтен илнең, бөтен халыкның оясы тузды. Барлык тузулар, пыран-заран килүләр безнең чәүкә ояларын туздырудан башланачагын белгән булсак, курка-курка менеп йөргән булыр идек микән ул тузанлы чормаларга?!

Хәер, чормада үзе бер дөнья. Иске-москы арасында ниндидер «чатыр» дигән нәрсә бар. Тимер таягыннан тотып, кечкенә бөҗрасын өскә таба шудырсаң, чатыр киңәя, кабара, бөҗраны аска төшерсәң, җыела. Хәзер моны «зонтик» диләр. Каян безнең өй түбәсенә, ягъни чормага килеп менгәндер ул «чатыр», берни әйтә алмыйм.

Иртән торып тамагыңны туйдыру белән, тизрәк урам якка чыгып китәсең, күршеләргә керәсең. Кайчагында кереп булмый, капка бикле була. Дус малаеңның чыкканын көтеп урамда йөренеп торасың. Күршедә генә безнең мичче Галләм бабай йорты. Беркайчан капкалары бикле булмас. Ике арадагы киртә аша да керергә була. Өй тулы бала-чага. Күбесе малайлар. Авылда Галләм бабайны мич чыгарырга чакыралар. Кызык итеп без гел аның тирәсендә буталабыз.

Тимергали абыйлар очында, елга буенда — Фатих бабайлар өе. Кай яктандыр Фатих бабайлар безгә туган, ахрысы. Аларның да малайлары бар. Нурлый, Нурлыкай дип йөртәбез. Мин аларга да барып чыгам. Кыска кара сакалмыеклы, озын, чандыр Фатих бабай еш кына сәгать төзәтә. Мин аның янына ук барырга да куркам — сихерләнгән кебек ишек төбендә кулларына карап тик утырам. Ул ниндидер бармак башыдай чүкечләр белән шакы-шокы килеп, безләр, эскәкләр белән, сырлы тәгәрмәчләр, шөрепләр белән булаша. Сәгатьне борып, юри күкесен кычкыртса, синең өчен бөтен бер бәйрәм була. Көне буе шуны уйлап, исең китеп, хыялланып йөрисең. Ничек кычкыра икән дә кем кычкыра икән ул сәгать эчендә? Аннан соң ул бит әле «йөри»! Ничек «йөри» соң ул! Һич шуңа баш җитми.

Якында гына, урам аша, безгә чапырыш, Хасинә апалар өе. Алар укымышлы абыстай затлары. Аларда һәрвакыт чиста, якты. Идәннәре ап-ак итеп юылган булыр. Алар да кайсыдыр яктан безгә туганнар бугай. Аларның малайлары юк. Шуңа мин аларга керергә дә яратам. Кайчан кермә, Хасинә апа китап күчерә. Ләкин ул дәфтәргә язмый. Ап-ак кәгазь битләрен бер-берсенә ябыштырып теркәгән дә, шуннан бик озын тасма барлыкка килгән. Ярты дәфтәр киңлегендәге тасманы гармун сыман итеп җыйган, шуларга җырлар, бәетләр, мөнәҗәтләр, догалар, тагын әллә нәрсәләр яза. Зур үскәч, мин шуны белдем: борынгы Мисырда да нәкъ шундый тасмаларга язганнар «китап»ларны.

Тагын шул: кышларын бездә туктаусыз җеп җегерлиләр, җеп маналар, киндер сугалар. Мин юри генә, кызык итеп кенә йә буш калтырчаны әйләндерергә тотынам, йә әвернә канатларын этеп җибәрәм. Билгеле, олылар күрмәгәндә генә. Яисә, исем китеп, инәкәйнең шакы-шокы киндер сукканын карап утырам. Сәгатьнең ничек йөргәнен аңлый алмаган кебек, шулкадәр күп җепләрнең буталмыйча, чуалмыйча киндергә әйләнүен дә мин рәтләп аңлый алмадым.

Әткәй минем сука башы тотарлык булуым турында хыялланса да, Күчтавылда мин иген эшенә кагылышлы берни хәтерләмим. Күчтавыл халкы гомер-гомергә иген игү белән бергә вак-төяк кәсеп һәм аз-маз һөнәрчелек белән шөгыльләнгән. Менә шундый һөнәр ияләре, күрәсең, миңа күбрәк тәэсир иткәндер.

Күчтавылның мәчетенә каршы гына, почмакта, бер урам икенчесе белән кисешкән төштә гаҗәп серле бер йорт бар иде. Йорт хуҗасы — балта остасы, агач остасы. Исеме Хәтмулла, ахрысы. Өй кыегына ул малайларның күзен кыздырып хикмәтле җил тегермәне ясап куйган. Җил тегермәненең канаты зур — бер метр чамасы булыр. Әз генә җил чыгып канат әйләнә башладымы, канат үзәге беркетелгән озын агач кисәгенең уртасында ике тимерче алмаш-тилмәш чүкеч суга башлый. Тимерчеләрне дә, аларның кулына беркетелгән чүкечне дә Хәтмулла агачтан кырып-юнып ясаган. Ерактан караганда алар шундый чын булып күренәләр — аларның шулай чүкеч сукканын күрдеңме, һич аерыла алмыйча, карап торасың да торасың.

Карап тору бер нәрсә. Үзеңнең дә шундый ук җил тегермәне ясыйсың, малайларның исен китерәсең килә башлый. Күчтавылда чагында мин Хәтмулланыкы кебек җил тегермәне ясый алмадым — анысы бары хыял гына булып калды. Әмма кирпеч сугарга, мич чыгарырга Күчтавылда чакта ук өйрәндем дип әйтергә була. Көннәрдән бер көнне күршем Заһир белән бәләкәй генә кирпечләр суктык та өй артында, такта чоланга якын гына мич чыгардык. Мичкә чүп-чар, йомычка ягып җибәрдек. Мичтә ут яна, мөрҗәдән ургылып төтен чыга. Кызык! Бер заман бөтен тирә-як төтен белән тулды. Өйдән йөгерешеп кешеләр чыкты һәм... калганы билгеле инде. Утны сүндерделәр, безне тиргәделәр. Шуннан соң мин мичләрне өй янында, тышта түгел, өй эчендә генә чыгардым. Анысы олыгайгач булды. Үз кулым белән барлыгы дүрт мич чыгардым. Әле дә менә дигән тарталар.

# ТӨРЛЕСЕННӘН

## БЕЗ — ЯҢАВЫЛЛАР

16, 17, 18 июнь, 1993 ел. Казанда Яңавыл көннәре. Нинди Яңавыл, кайсы Яңавыл?

Башкортстанның төньягында, Пермь белән чиктәш җирләрдә, Удмуртия һәм Татарстанга да якын бер төбәктә Яңавыл районы урнашкан. Район үзәге — Яңавыл шәһәре. Хәзер шулай диләр. Без малай чакта Яңавыл дөньяда иң матур шәһәр булып тоелса да, ул әле «эшчеләр поселогы» гына иде, «эшчеләр поселогының» 80—90%ы исә авыл халкы — татарлар иде.

Элекке Казан тимер юлы Урал, Себер якларына Яңавыл аша уза. Казан белән Яңавыл арасы 450 км чамасы. Көньяктан Яңавылга Уфа юлы килеп тоташа. Киң, такыр юл Пермь ягына да чыгып китә. Европадагы барлык юллар Римгә алып барган кебек, бу төбәктәге юллар да Яңавылда кисешә. Якын-тирәдәге Борай, Аскын, Тәтешле, Балтач, Калтасы районнары һәм күршедәге гәйнәләр өчен Яңавыл географик үзәк хезмәтен үти.

Яңавылның җире таулы-ташлы, урман-сулы. Иң зур елга Бүә дип атала. Русча «Буй» дип язалар. Камага коя торган Бүәнең үзенә төньяктан Беҗ, Ушиа сулары килеп кушыла. Район җирендә тагын исемле һәм исемсез кечерәк елгалар, чишмәләр күп. Елга үзәннәрендә — болыннар, уңдырышлы иген басулары.

Яңавыл яклары кайчандыр Болгар, Болгардан соң Казан җирләре булган. Болгарларга кадәр монда бәҗәнәкләр яшәп яткан булса кирәк. Беҗ елгасы аларның төньяк-көнчыгыш чикләре булган, ахрысы. 1755 елда рус колонизаторларына каршы баш күтәргән Батыршаның рус патшасына язган хатында Яңавыл яклары да чагылып кала. Хатта Яңавылга якын төбәкләр — Гәйнә иле, Илеш телгә алына. Шунда ук «Урал иленең Уртауыл дигән авылы» да бар. «Уртауыл» авылы халкы турында болай диелгән: «Урал илендә алты-йите көн тордым... Әйтделәр: «Безнең урман тарафлы хәлайыкларымыз... гайәт дә пәһлуаннардыр. Вә һәм ук атарга мәргәнләрдер. Кырыгар-иллешәр тиенлек санай йәйәләремез йалан башкорт-

ларының унар-йегермешәр сумлык әдернә йәйәләрендән артыктыр. Андый әдернә йәйә эссе көндә йигерме-утыз мәртәбәдән артык йарамайдыр. Безнеке ни кадәр эссе һава көн булса да атышкан саен куәтләнәдер. Аткан укларымыз һәргиз киеккә туктамайдыр. Ботакка кунган тиенне, сусарны атканда ботагы берлә өзеп төшерәдер. Вә һәм чаңгы йөрергә шул кадәр осталар, урман эчендә качкан киек котылмайдыр. Алдына аркылы яткан ат биеклеге агачларны аша сикереп чыгалар. Йулдан йилүче ат карда йилгән чаңгылы кешеләремезгә йитмәйдер... Урман халкы пәһлуанлыкка йалан халкы булмас имде».

«Урал иле»ндә Бүә суы үзәненә иң элек Карман килеп утырган. Карманнан соң утырган икенче авыл Яңавыл булган. Күпмедер вакыттан соң алар арасына өченче авыл — Уртавыл килеп төпләнгән. Батырша телгә алган пәһлуаннар менә шул Уртавыл ягы кешеләре булганнар да инде. Әлеге хатта тагын: «Гәйнә иле уртасына меңләгән урыс пулкы килеп, арбадан кальга сукып йатды гәйнәне чабу өчен» дигән сүзләр дә бар.

Яңавыл халкының күпмедер өлеше Казан ягыннан күченгән. Минем инәкәйнең туган авылы Яңа Уртавыл Иске Уртавылдан, ягъни Батырша әйткән «Уртауыл»-дан бүленеп чыккан. Яңа Уртавылның рәсми булмаган икенче исеме — Янтык. Татарстанда Татар Янтыгы, Урыс Янтыгы бар. Яңавылның Карман авылы да Казаннан күченгән булырга тиеш. Татарстанда ике Карман авылы бар. Карман — бик борынгы исем. Байсар да борынгы исем. Мисыр фиргавеннәре Байсар нәселеннән булган дигән язма истәлекләр сакланган. Татарстанда бер Байсар, Яңавыл районында икенче Байсар бар.

Сугыштан соңгы елларда Яңавыл бик нык үзгәрде. Җәбер-золымнан, мохтаҗлыктан качып күпләр Урал, Себер, Урта Азия якларына киттеләр. Яңавылның үзенә читтән килмешәкләр килеп тулды. Яңавыл җирендә нефть чыга башлады. Әмҗе янына спирт заводы салып куйдылар, Карман янында, торбаларын күккә терәтеп, ГРЭС калкып чыкты. Җир тапталды, елгалар пычранды, чишмәләр корыды. Әкияттәге сыман гүзәл Бүә хәзер Казандагы Болак сыман, Яңавылны тәмам корыту, урыслаштыру өчен атом бомбасы гына шартлатасы калган иде бугай. Анысын да шартлаткан булырлар иде, ярый әле, Кабан авылы янындагы АЭС дигәннәрен туктатканнар сыман.

Бөтен илдәге үзгәрешләр, шифалы җилләр Яңавылны да читтә калдырмады. Яңавыл тарафларыннан җанга якын хәбәрләр ишетелә башлады. Элекке ихтыярсыз, фикерсез җитәкчеләр урынына үзенең тамырын онытмаган һәм хал-

кына, милләтенә хезмәт итәргә әзер торган яшьләр килде. Бу уңайдан Яңавылның бүгенге администрация башлыгы Нәзир Зиазов һәм аның урынбасары Рәзинә Габделхакова исемнәрен аеруча хөрмәт белән телгә аласы килә.

Безне, башлыча, тел, әдәбият, мәктәп хәлләре борчый. Шунысы куанычлы, Яңавылда хәзер татар теленә, татар мәктәбенә, татар матбугатына игътибар арта бара. Бүгенге Яңавылның үз язучылары, шагыйрьләре баш калкыта. Монда Язучылар союзы бүлеге оешкан. Татар матбугатында Кәүсәрия Шафикова еш күренә. Озакламый Казанда Яңавылның Әкълимә Саяпова, Фәрит Суфияров, Рафис Мөхәмммәтдинов һәм Кәүсәрия Шафикова шигырьләреннән төзелгән аерым җыентык басылып чыгар дип өметләнәбез.

Яңавыл ягы Батырша заманында гына түгел, бүгенге көндә дә пәһлуаннар белән данлыклы. Монда тырыш, эшчән һәм талантлы халык яши. Яңавылда ике Советлар Союзы герое — Мәгъсүм Имаметдинов белән Гайнан Хәйдәршин, Социалистик Хезмәт геройлары Флера Әминова, Әлфиза Гыйниятуллина, Зикаф Даутов туып үскән. Самарада яшәүче Социалистик Хезмәт герое Шамил Мөхәммәтдинов та, Мурманскидагы «Арктика» атом бозваткычы капитаны Фидүс Әсхәдуллин да Яңавыл кешеләре. Чиләбедә яңавылларның күренеклеләреннән берсе Әхәт Ганиев яши. Доктор. Ленин премиясе лауреаты.

Әхәт тә, аның энесе Наил дә, аларның сугышта һәлак булган абыйлары Хәйбер дә безнең Яңавыл татар урта мәктәбен тәмамладылар. Наил Ганиев Казанда Доктор, профессор. Сеңелләре Мөзәйнә, энеләре Вил шулай ук фән докторлары. Бер гаиләдән дүрт доктор һәм барысы да данлылар, атаклылар! Чыгышлары белән Истәк авылыннан булган дүрт бертуган Харисовларның яраткан эше — халык мәгарифе. Фираз Харисов Казан Педагогия институтында проректор. Энеләре Фарис белән Фәнит — гимназия директорлары. Фәрит дигән энеләре Яңавылда мәктәп директоры урынбасары.

Татарстанда хуҗалыкның төрле тармакларында эшләүче яңавылларны санап бетерерлек түгел. «Татнефтепродукты» фирмасының техник директоры Зәнфир Закиров, инженер-химик Әхсән Арсланов, инженерлар Рәүфә Сибгатуллина, Рәүфә Рәхимова, Фоат Ибраһимов, Рәис Даутов, Эмил Зарипов, баш конструктор Равил Даутов, экономия фәннәре кандидаты Фәнәис Мусин, КФЭИ доценты Назыйм Сафин һ.б. Медицинада атаклы докторыбыз, ГИДУВ проректоры Илдус Низамов, КГМИ доценты Зәһәйрә Якупова, югары квалификацияле врач Руфи-

на Фәттахова, Зөһрә Хәйруллина, Заһидә Зәйнуллина һ.б.— барысы да Яңавыл кешеләре.

Филология, журналистика өлкәсендәге мәрхүм доктор Әнвәр Ахунҗанов, фән кандидатлары һәнүз Мәхмүтов, Фәнис Исламов, яшь шагыйрә Нәҗибә Сафина шулай ук Яңавылда туып үскән кешеләр. Татарстан радиосы баш редакторы урынбасары Рәзин Нуруллинны аерым атап китәргә кирәк. Казанда Яңавыл көннәре оештыруда, якташлар белән элемтә тотуда ул иң актив кешеләрнең берсе.

Күрәсез, исемнәр күп. Болар әле бары мин белгәннәре генә. Ләкин без әдәбият, сәнгать әһелләрен бөтенләй диярлек телгә алмадык. Иң элек Уфада яшәүче атаклы җырчылар Радик Гәрәев белән Фәнәви Салиховны искә төшерик. Татарстан артисткасы Диләрә Ильясованың да, художник Эрот Зариповның да Яңавылдан икәнлеген онытa күрмәгез. Яңавылда туган язучылар белән буа буарлык дисәм, әллә ни арттыру булмас. Иң өлкәнебез — Риза Ишморат, аннан кала Сәет Кальметов. Һәм, әлбәттә, Сажидә Сөләйманова белән Әдип Маликов, Рәмзи Илалов. Иң атаклыларыбыз — Илдар һәм Нил Юзиевләр.

Менә шундыйлар без — яңавыллар.

Хуш киләсез, якташлар, ата-баба җире Казанга, Татарстанга!

*8 июнь, 1993 ел.*

# КОТЛАУ СҮЗЕ

*(Казанда яңавыллар белән очрашканда сөйләгән котлау сүзе)*

Хөрмәтле милләттәшләр!

Кадерле якташлар — яңавыллар, казаннар!

Бүген без шушы якты залда тарихи очрашуга җыелдык. Безнең барыбыз да тумышыбыз белән Яңавыл кешеләре булсак та, бер өлешебез күптән Казанда төпләнеп, казанлашып беткән, икенче өлешебез монда кунак булып килгән.

Бер уйлаганда, нинди җиңел! Әкияттәге... тулпар атка атланган таз малай... күз ачып йомган арада җирнең бер читеннән икенче читенә барып җитә алган кебек... хәзерге заманның утарбаларына утырасың да, бер төн эчендә киләсең дә җитәсең Казанга. Ләкин Яңавыл белән Казан арасы бер төнлек кенә булса да, ул төннең озынлыгы сәгатьләр белән түгел, еллар белән исәпләнә.

Бастырылулар, газаплы ыңгырашулар һәм кан-яшь белән тулы 440 еллык төн бүген менә юкка чыкты сыман. Безгә дә таң атты. Без уяндык, туганнарым! Сезнең Казанга, Татарстанга... изге ата-баба җиренә сәҗдә кылырга килүегез үзе генә дә шул турыда сөйли. Казан сезне онытмады. Сез дә Казанны исегездән чыгармагансыз. Чын күңелдән рәхмәт сезгә!

Яңавыл ягы борын-борыннан болгар җире, Казан җире булган. Идел белән Урал арасында йөрешү беркайчан да өзелеп тормаган. Безнең Яңавыл урман-суга, икмәккә, нефтькә бай. Безнең Яңавыл халкы эшчән, тырыш, булдыклы. Яңавылның бүгенге җитәкчеләре — яшьләр, кыюлар... иң беренче чиратта халык һәм милләт кайгысын кайгыртучылар. Борай, Аскын, Балтач, Тәтешле, Калтасы якларының күршедәге гәйнәләрнең юлы да, сукмагы да Яңавылда кисешә. Бүгенге Яңавыл бөтен тирәякның үзәге ул. Киләчәктә Яңавылның культура үзәге булу ихтималы да зур.

Кадерле якташлар! Хәзер сезнең... безнең төп бурыч — телне, рухны торгызу, милләтне аякка бастыру. Моның өчен безгә яңадан тупланырга, берләшергә, аралашырга кирәк.

Без килмешәк түгел, илсез-көнсез сукбайлар, җилкуарлар түгел. Без — борынгы халык, без — бөек халык.

Татар турында туктаусыз сөйләнә торган, языла торган гайбәткә ышанмагыз, татарны кемнәр беләндер кушуга, буташтыруга, ахыр чиктә безне юк итүгә юнәлдерелгән

коткыга бирелмәгез. Бәхетне читтән, чит халыклар арасыннан эзләмәгез. Бәхет — үзебездә. Бары үзебездә генә!

Үз җирегездә хуҗа булып, нык басып, бөерегезгә таянып торыгыз. Мәңгелек итеп таштан сарайлар салыгыз, итәк тутырып балалар үстерегез. Ачлык, мохтаҗлык, җәбер-золым моннан соң безнең йортка аяк басмасын. Татар җирендә шат җырлар яңгырасын, татар җирендә тормыш гөрләп торсын.

Амин. Шулай булсын.

*9 июнь, 1993 ел.*

## НУРИХАН ФӘТТАХНЫҢ 50 ЯШЬЛЕК ЮБИЛЕЙ КИЧӘСЕНДӘ СӨЙЛӘГӘН СҮЗ

Шулай итеп, сиңа да илле яшь тулдымыни, Нурихан иптәш? Әле кайчан гына син ун яшьлек малай идең, егерме яшьлек җегет, утыз яшьлек буйдак, кырык яшьлек ир идең!

Дөньяны иңләп алырдай булып, күкрәк сугып, тузынып, этәчләнеп нинди шәбәеп йөри торганыең син яшьрәк чакларыңда. Шәбәеп кара хәзер — сиңа... илле яшь. Чәчләреңә чал кергән, койрыгың бозга каткан.

Юбиляр булгач та, кайберәүләр сине мактыйлар, данлыйлар. Белмичә алар сине әллә кем дип уйлыйлар. Чынлыкта син беркем түгел. Дөньяга син җылап тудың һәм ярты гасырлык гомереңне җылап-сыктап узгардың.

Хәтерлисеңдер, сиңа биш-алты яшь чагында әтиең үлеп китте — кабергәчә син аны җылап озаттың. Әтиең үлгәч, сезнең йорт-җирегез тузды. Сез, туган авылыгызны ташлап, башка авылга күченеп киттегез. Яңа җирдә сине иш итмәделәр. Хурланып, кимсенеп син туктаусыз балавыз сыктың.

Җирдә син гомумән башка авыл кешесе булып, килмешәк булып яшәдең. Үсә төшкәч, сине малай-шалай түгел, дәү абыстай — Тормыш үзе кыерсытты. Турысын әйткәндә, гомерең синең типке астында узды. Шулай да син, Нурихан ифтәш, беркайчан да акылга утыра белмәдең.

Җүнле кешеләр, аракы эчеп, мактанышып яшәгән бер вакытта син: татарга аракы кирәкми, татарга яхшы романнар, яхшы шигырьләр кирәк дип кычкырынып, көфер сүзе сөйләп йөрдең.

Җүнле кешеләр, туган телләренә төкереп, балаларын тырышып-тырышып урыслаштырганда син: татар телен сакларга кирәк дип, татар балалары өчен татарча яслеләр, бакчалар булдырырга, татар мәктәпләрен ныгытырга кирәк дип, соткы таратып йөрдең.

Әнә, күр инде, кимендә мең еллык тарихы булган татар мәктәбе бетү алдында тора. Ышанмасаң, кара: ярты миллион чамасы татар яши торган синең башкалаңда — Казанда татар мәктәбен инде юк дип әйтергә була. Мәктәбе дә юк — кайгысы да юк. Мәктәп бетсә, синең телең, әдәбиятың бетәчәк, тел-әдәбият бетсә,— культура, культура бетсә,— халкың-милләтең бетәчәк.

Шулай булгач, кемгә кирәк син, кемгә кирәк синең язганнарың, синең илле еллыгың, Нурихан Фәттах Садрильманович?!

Бармыйм мин синең юбәләй кичәңә, и синең үзеңә дә киңәш итмим анда күренеп йөрергә,— дип әйтеп әйтте миңа бер җүнсез танышым.

Җүнсез танышыма каршы мин әйттем:

Юбилей кичәсенә мин бармый кала алмыйм дидем. Анда мин Нурихан Фәттахны күрер өчен түгел, анда мин әдәбият, сәнгать дусларын күрер өчен барам. Анда мин Нурихан Фәттахны тапкан, үстергән, кеше иткән бөек халкымның уллары-кызлары белән очрашу өчен барам дидем.

Дуслар! Туганнар!

Илле яшькә җиту — куркыныч түгел. Кеше башына андый гына бәла-казалар килгәли. Иллегә җиткән өчен генә без әле үләргә җыенмыйбыз. Муса Җәлил әйтмешли:

Сез үлсәгез, мин дә онытылырмын,
Яшәсәгез, мин дә яшәрмен.

Иншалла, яшәрбез.

*1978*

ЭЧТӘЛЕК

*Ә.Еники.* Милләт аңардан күпне көтә . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7
Шәҗәрә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 8

**Мәкаләләр**

Атлантида . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 322
Саба . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 331
Суйургап-Суйургал . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 342
Шумерча дингир, татарча тәңре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 351

**Истәлекләр**

Үзем генә түгел . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 362
Хөййе бабай . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 367
Пулат . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 369
Истәлекләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 375

**Төрлесеннән**

Без — яңавыллар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 392
Котлау сүзе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 396
Н.Фәттахның 50 яшьлек юбилей кичәсендә сөйләгән сүз . . . . . 398

Литературно-художественное издание

Фаттахов Нурихан Садрильманович

*(Нурихан Фаттах)*

Избранные произведения
в пяти томах

Том 5

(на татарском языке)

Мөхәррирләре *Р.Х.Корбанов*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *Н.П.Клипова*
Корректоры *М.Ш.Хәйруллина*

Нәшриятка 04184 номерлы лицензия
2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал макеттан басарга кул куелды 18.09.2002. Форматы 84 108 1/32.
Офсет кәгазе. «Школьная» гарнитурасы. Офсет басма.
Шартлы басма табагы 21,0+вкл.0,84+форз.0,21. Шартлы буяу-оттиск 22,15.
Нәшер-хисап табагы 25,28+вкл.0,78+форз.0,36.
Тиражы 3 000 данә. Заказ Б-457.

Татарстан китап нәшрияты. 420111, Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111, Казань, ул.Баумана, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы дәүләт унитар предприятиесе.
420066, Казан, Декабристлар ур., 2.